ISSN 0206—4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

2. 1992



*Авторлар игътибарына*

Редакция кулъязмаларны рецензияләми, әсәрне журналда басты-ру-бастырмау турында гына авторга хәбәр итә.

Кулъязмалар, автор тарафыннан почта чыгымнары алдан түләнгән очракта, кире җибәрелә.



# КАЗАН УТЛАРЫ


АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**2**

**(832)**

**1992**

КАЗАН


## *Бу санда*


ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Ә. БАЯНОВ. Айга ялвару. *Шигырьләр* ..... 3
К. СИБГАТ. Акылдан язган рәссамнар күргәзмәсе. *Шигырьләр* ..... 8
Р. КӘРАМИ. Каргышлы юллар. *Роман* ..... 12
Г. ЗӘЙНАШЕВА. Яңа җырлар ..... 77
З. ХӘКИМ. Изге җир. *Шигырьләр* ..... 80
Г. ИСХАКЫЙ. Көз. *Повесть* ..... 83
Х. ТӨХФИ. Газәл. *Шигырьләр* ..... 115
Ф. ДӘҮЛӘТБАЕВ. Язмыш. *Шигырьләр* ..... 117

ПУБЛИЦИСТИКА

Ф. ДУНАЙ. Иманнар какшаган дәвер ..... 119
Г. КАШАФ-ҮЗИЛЕ. Фаҗига ..... 134

МӘДӘНИЯТЕБЕЗ ТАРИХЫНА

Б. СОЛТАНБЕКОВ, Д. ШӘРӘФЕТДИНОВ. Фаҗигале язмыш ..... 139
М. СОЛТАНГАЛИЕВ. Мин ялгыштыммы? ..... 140
Р. МОСТАФИН, Р. ДАУТОВ. Репрессияләнгән татар язучылары ..... 149
Еллар авазы. *(Кереш сүз белән)* ..... 159
Ф. ГАРИПОВА. Тарихи катламнарыбыз ..... 163
М. ӘХМӘТҖАНОВ. Сабирҗан акын ..... 169

ДӨНЬЯ ӘДӘБИЯТЫ ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ

Т. ӘЙДИ. Тыелган исем һәм иҗат ..... 172
Ф. НИЦШЕ. Уймак уйлар ..... 173

ТАТАР ХАЛКЫ: ТӨРЛЕ ТОБӘКЛӘРДӘ, ТӨРЛЕ ИЛЛӘРДӘ

И. НАДИР. Финляндия татарлары ..... 176

Котлыйбыз ..... 175
189
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ..... 190
Тышлыктагы сурәтләр ..... 192

*Баш мөхәррир*

**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*

**Гариф Ахунов**
**Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова**
**Тәлгат Галиуллин**
**Аяз Гыйләҗев**
**Салих Маннапов**
**Зиннур Мансуров**
**Ростәм Мингалимов**
**Фәрвәз Миңнуллин**
**Минтаһир Минһаҗев**
**Мөхәммәт Мәһдиев**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Рашат Низамиев**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Индус Таһиров**
**Марс Шабаев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Тәуфикъ Әйди**
**Марсель Әхмәтҗанов**

Безнең адрес: 420066,
Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 53-07-60,
баш мөхәррир урынбасары —
53-07-09,
җаваплы сәркатип — 53-36-12.

*бүлекләр:*

чәчмә әсәрләр, шигърият,
очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать,
хатлар — 53-07-63,
корректорлар — 53-07-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

Окончание романа Р. КАРАМИ «Проклятые дороги», повесть Г. ИСХАКИ «Осень», стихи А. БАЯНОВА, К. СИБГАТА, Г. ЗАЙНАШЕВОЙ, З. ХАКИМА, Х. ТУХВИ, Ф. ДАВЛЕТБАЕВА.

«Публицистика»: статьи Ф. ДУНАЯ «Когда исчезает вера...», Г. КАШАПОВА «Трагедия».

«К истории культуры»: статья Б. СУЛТАНБЕКОВА и Д. ШАРАФУТДИНОВА «Трагическая судьба»; в статье «Ошибся ли я?» публикуются секретные материалы, связанные с допросом М. СУЛТАНГАЛИЕВА. Статья Р. МУСТАФИНА и Р. ДАУТОВА «Репрессированные татарские писатели». «Эхо прошлых лет» — публикации татарских писателей 20 – 30-х годов из журнала «Безнең юл»; статья Ф. ГАРИПОВОЙ «Исторические пласты татарского народа»; статья М. АХМЕТЗЯНОВА «Сабирзян акын».

«Шедевры мировой литературы»: статья Т. АЙДИ «Запрещенное имя и творчество». Афоризмы Ф. НИЦШЕ.

«Татарский народ: в различных регионах страны и мира»: И. НАДИР «Финские татары».

В номере отмечаются 50-летия К. Сибгата, Р. Карами, А. Гаделя.

Дневник общественно-политической жизни.

На наших обложках: картина Р. Гаитова «Путешествие Насретдина»; портрет лауреата премии М. Джалиля, писателя Ф. Яруллина.

*Мөхәррирләр:* Мансур Вәлиев, Рәдиф Гатауллин, Шамил Маннапов, Кояш Тимбикова, Тәуфикъ Әйди, Рәшит Әхмәтҗанов.
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзада Моратова, Лилия Гатауллина.

Производствога бирелде 18.12.91 ел. Басарга кул куелды 18.02.92 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 39228. Заказ И-607. Бәясе 1 сум 80 тиен.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1992 ел.

# Әхсән Баянов

## Айга ялвару

Нәрсә булды бу дөньяга —
Җир дә, күк тә чайкала.
Болытларны айкый-айкый,
Кай табадыр ай чаба.

Болытларны җәтмә итеп,
Кем айны тотмак була?
Өстерәп аны кара көч
Тиз кабып йотмак була.

Сулга тайпылмак була ай,
Уңга каерылмак була.
Болыт җәтмәләрне ертып,
Җирдән аерылмак була.

Әй, ашыкма, үз төягең
Рәтле кем ташлап кача!
Караңгыда якты көткән
Җир синең әнкәң ләса!

Һич курыкма, каралыкның
Куллары җитмәс сиңа.
Кояштан, җирдән аерылсаң,
Яшәүләр бетмәс димә.

Бер заман сине төшергәч,
Өстерәп баулар белән,
Китмәдең ерак барыбер
Син әнкәң күкрәгеннән.

Теткәләнде, бетте дигәч,
Син кабат калка тордың.
Урак булып, көлтә-көлтә
Безгә җыр, моңнар урдың.

Инде без, җир балалары,
Сине яклардык, шөкер.

---

Әхсән БАЯНОВ *(1927) — шагыйрь, әдип, «Елларга сәяхәт», «Язмыштан узмыш», «Тау ягы повесте» — барысы өч дистәгә якын китап авторы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

Йолдызлар белән бергәләп,
Яңа аклыклар китер.

Караңгылык, үчлек белән
Янаса да куркыныч,
Дөньяның вөҗданы булып,
Кал биектә, бул тыныч.

## Ашыкмагыз

Бүлмәләрдә көзгеләр бар.
Көзгеләр әллә ничә.
Кара бик үпкәләмичә,
Кара бик әрләмичә.

Синең гомерең фасыллары —
Киләчәккә ядкарьләр.
Яшең, эшең теркәгәннәр
Катыркалар, дәфтәрләр.

Бүлмәләрдә көзгеләр бар —
Алдаша, ялгышалар.
Алтынлы диплом, йолдызлы
Медальләр, афишалар.

Батырлык йолдызы балкый
Куркаклык киштәсендә.
Кемдер даһилар рәтендә
Төшеп калган рәсемгә.

Егерменче гасыр соңы.
Күп хезмәтләр. Буш саннар.
Ашыкмагыз сокланырга,
Күргәзмәгә куйсалар.

* * *

Дөнья күрде: мәрмәр һәйкәлләр дә
Фаш булдылар, җиргә баш ордылар.
Оялмыйча илдә бил катырып
Тормас өчен егылып таш булдылар.

Күпкә өйрәтмәле гыйбрәтләрен
Күп булмады истә саклаганнар.
Биеклекләр яулап калыр өчен
Күтәрелде яңа каһарманнар.

Уйлый алар диварларны таш дип,
Дивар аша күрми диеп халык.
Ләкин күрә дөнья, алар — гүя
Аквариум эчендәге балык.

Яши алар безгә хаклык хас дип,
Без илдәге бар халыкка баш дип.

Шәфкать, канун дигән сүзләр чәчеп,
Тараталар имансызлык, ачлык.

Иптәш рәис, иптәш сәркатибләр,
Президентлар, бүтән төрле типлар!
Үзгәртелгәч, тормыш — чынлап башка,
Күпләрегез әйләнәчәк ташка.

Мактаулырак, намуслырак чөнки
Җирдә аунап яткан таш булулар.
Иң оят эш хәзер — сезнең кебек
Баш булулар.

* * *

Узам, кызлар, сезнең турыгыздан.
Тәрәзәгез җәйгә ачылган.
Сезнең тавышларда илгә кайткан
Кошлар сөенече бар сыман.

Сезнең ачык тәрәзләрдән безгә
Сөенечләр элек күп дәште.
Сезнең шуклык җитә иде килеп
Кояш куяннары рәвешле.

Мин әле дә көтәм еллар аша:
Куянчыклар йөгереп узачак.
Күзләр чагылачак, өскә баксам,
Шатлыгыгыз чиксез булачак.

Тәрәзәгез әле дә ачык җәйгә,
Тик үзегез әллә көзгесез —
Куянчыклар, никтер, төшермисез,
Карасам да, никтер, көлмисез.

Ятсынасыз — әллә башкамы сез?
Әй, таныгыз — мин бит, мин бит бу!
Минем өчен сез танышлар һаман —
Юк онтылу һәм юк оныту.

* * *

Яшьлегеңдә кигән күлмәкләрең
Хәзер генә гүя тегелгән.
Алар белән күпме истәлекләр
Чыккан дисең хәтер төбеннән...

Кайсындыр син басма өсләрендә
Кер чайкаган чакта кигәнсең.
Ә кайсындыр, бәлки, иң беренче
Очрашуга киеп килгәнсең.

Син, кайсындыр киеп, сабыйларны
Озаткансың бакча, мәктәпкә.
Күпме, күпме сөенеч үрелеп калган
Һәрбер җөйгә, җепкә, сәдәпкә.

Минем башка килгән һәм килмәгән
Уйлар анда, хисләр, сурәтләр.
Кызыбызга атап тегелгән кук
Син яшьлектә кигән күлмәкләр.

Яшьлегеңдә кигән күлмәкләрең
Аңа бигрәк, бигрәк килешә.
Яшь чагың дип, мин ымсынып идем,
Күзләремә кинәт күренсә.

Матурлыгың, сылулыгың еллар
Чәчмәгән дә икән, түкмәгән.
Кызың түгел, үзең киенгән кук —
Бәйрәмнәрең әле үтмәгән.

Елмаябыз яшьлегебез безнең
Киләчәктә озак яшәр дип.
Күзеңдә тик елтырый сары моңмы,
Мөлдерәргә торган яшьләрме...

Син ишектән кызны озатканда,
Елмай тагын, зинһар — түзсәнә.
Елмаюың үзәгемне минем
Елаулардан артык өзсә дә.

* * *

Тынлык тыныч калыр иде,
Җил «сагындым!» димәсә.
Истәлекләр шикелле җил
Битләрдән сыйпый, дәшә.

Якында черки безелди
Нәзек тавышы белән.
Сызлана, шыңшый, елыймы,
Әллә әйтәме: «Сөям!»

Тавышы шикелле нечкә
Борыны белән чәнчә.
Каным эчеп үлә... Гүя
Сөеп булмый бүтәнчә.

* * *

Әзер идем үч алырга синнән,
Эзләдем дә бугай әмәлен.
Синең туклык минем ачлык иде,
Синең бәхет — минем әҗәлем.

Гөлчәчәкләр шиңде минем өчен,
Чишмәләрем акмый — тукталды.
Төшендем тик безнең уртак ярның
Хыянәтче булып чыкканын.

Синең дә бит узар бәйрәмнәрең,
Һәм аңларсың мине бер заман.
Нинди хәлдә калачагың уйлап,
Инде хәзер сине кызганам.

* * *

Яшисең кебек дөньяга
Бер рәнжешсез, каргышсыз.
Ә җанда дөрләү, тетрәүләр —
Төтенсез тик, тавышсыз.

Тәкъдирнең үзе белән үк
Килгән бугай ялгышлар.
Бию көе, күңелле көй,
Шунда да бит сагыш бар...

* * *

Елгаларың ята сырхап, ага сыктап.
Чишмәләрең калыр төсле таңда туктап.
Үзәннәрең язган балан-миләшләрдән,
Урман шаулап торган таулар пеләшләнгән.

Кая китте каз һәм торнаң, үрдәкләрең?
Кая китте чөлдиләрең һәм тартаең?
Әй, туган җир! Мәңгелек дип йөргән идек,—
Безгә ни сан! — Син булып бит син картайдың!

Аналары тәүфыйк белгән балаларның
Тиз картаймый. Ахрысы без — тәүфыйксызлар.
Үкенсәк тә инде безгә кайтмас маза.
Җаннарыбыз синекедәй сыктар, сызлар.

*1991.*

# Кадыйр Сибгат

## Акылдан язган рәссамнар күргәзмәсе

Акыл белән туа,
килә кеше.
Акыл белән хаким булып ала.
Реакторда атом янган кебек
башларында аның акыл яна.
Үлемне дә җиңә акыл белән.
Гомерне дә җиңә —
атыла да.
Акылга да утырта ул яшәү,
яздыра ул кайчак акылдан да.
Бирелсә дә күпме,
Үзе генә
Бөек итә алмый шәхесләрне.
Беркайчан да алыштыра алмый
җанда ургып яткан уй-хисләрне.
Безнең акыл камил.
Фикерлибез
яшәү, тормыш, дөнья, ил хакында...
Акылыннан язган очракта да,
мохтаҗ түгел даһи бу акылга.
Табигать сау:
үлән, яфрак исән;
Язлар, җәйләр —
төсләр уйнап тора...
Бетмәгән бит әле кешеләрнең
гамь-зары —
төсләр уйлап тора...
Көрәшәләр төсләр...
Күңел арган...
Уйларының талган канатлары.
Бер почмакта акыл посып калган.
(Эзәрлекли акыл талантларны).
Яраларга мөмкин,
үтерергә...
Кадерләрен белми кеше аның.
Акылыннан яздырырга һич тә
мөмкин түгел икән кеше җанын.
Кала икән барыбер үзе белән
кеше ничек кенә булып үзгәрсә дә.
Акылыннан язган рәссамнарның
ярылып ята җаны күргәзмәдә...

---

Кадыйр СИБГАТ (1942) — *шагыйрь, татар һәм рус телләрендә нәшер ителгән дистәгә якын китап авторы. Чаллыда яши.*

## Сандугач

Халыкларда матур исеме бар,
тарихларга кергән даны бар.
Андый моңнар каян килер иде —
мәхәббәте,
димәк,
яры бар.
Яшәр иде бераү
даны белән
айга,
кояшларга үрелеп.
Торыр иде биек сәхнәләрдә,
оҗмах гөлләренә күмелеп.
Күрим дисәң,
күреп булмый аны,—
мәйданнарга җырлап чыгалмый.
Алкышларың кирәк түгел аңа,
шау-шуларга бу кош чыдамый.
Түгелзгә аны чакырмагыз,
чакырмагыз туган көннәргә.
Дөньясыннан әгәр аерсагыз,
сандугачлар мөмкин үләргә.
Безнең өчен җырламый ул.
Кеше
лаекмы соң аны тыңларга?
Без якын да килалмыйбыз бугай,
сандугачта булган моңнарга.
Күренмәс ул биек һаваларда.
Һаваларда очмый сандугач.
Тал ботагы җитә,
моңы булгач,
яннарында якын җан булгач...

## Казанда 1 градус җылы

Читтә йөргән вакыт.
Сөендерә,
безнең яктан җилләр иссәләр.
Кошларга да кул болгыйсы килә,
безнең якка таба китсәләр.

Радиодан кайчак хәбәр килә...
Һава торышлары...
Өемнән...
Казанда, ди, бер градус җылы...
Җылы булган өчен сөенәм.

Бер градус җылы...
Йә, ходаем!
Шуннан ары инде суытма.
Бер градус җылы...
Ярый әле ул!
Бик әйбәт ул...
Шушы суыкта!

## Картлар йорты. Сентябрь

Каен яфраклары сөйләшмиләр.
Агачларның яшел шавы беткән.
Өзелә дә төшә,
өзелә дә...—
гомер үткән икән,
гомер үткән.

Ипләп кенә.
Җайлап.
Ашыкмыйча.
Уйлый-уйлый гына туктап-туктап,
яфракларга карап атлый картлар.

Күпме көзләр инде яфрак койган.
Уйлар җитә уй-моң кирәкләргә.
Гомер яшел чакта уйлар яшел.
Көзләр җиткәч уйлар зирәкләнә.

Тыңлый картлар яфрак кыштырдавын.
Ни кылганын тәкъдир үзе белә.
Илаһилык нуры балкып китә,
көзләр карый картлар күзе белән.

Өзелә дә төшә,
өзелә дә...
Салмак кына,
тыныч,
сабыр гына.
Көзләр җитте инде,
көзләр җитте...
Мәңгелеккә кала тамыр гына.

## Чәчәк сатучы карт

Күзләрең камашып куя,—
чәчәк — кая карама.
Тезелешкәннәр карчыклар,
бер карт та бар арада.

Мактый-мактый сата һәркем.
Товар ул шулай үтә.
Карт кына бер сүз дә дәшми.
Бу карт соң нәрсә көтә?

Күтәрелеп карамый ул
үтеп баручыга да.
Игътибар юк күршесеннән
чәчәк алучыга да.

Карап тордым да ышандым:
чәчәген кызганадыр;

бер чәчәген алсалар да
күңеле сызланадыр.

Үзе карап үстергән шул...
Чәчәк бит — җан баласы.
...Текәлгән дә карап тора
Моңлы картның карашы.

## Юлда

Арган гына атлар...
Арган гына...
Туарылган әле атларыбыз.
Бөтенләйгә туктап калу түгел,
хәл алырга яткан чакларыбыз.
Сулыш алу гына —
юлда күптән.
Йөз елын да,
мең елын да үткән.
Бара-бара шактый ерак киткән.
Көчне,
  тирне,
              канны шактый түккән.
Туктый-туктый кәрвансарайларда,
ераклардан килә олы кәрван.
Үтелмәгән әле озын юлы,
үтелмәгән әле олы фәрман.
Юл газабы авыр.
Маңгайларга
чыккан иде салкын тирләр булып.
Тирләр кипте,
хәлсез чаклар үтте,
малайлар да җитте ирләр булып.
Юллар сикәлтәле.
Йөзәр елга
сабырлыклар тагын кирәк алда...
Атлар түзәр.
Барып җитәр кәрван
мең ел әрнеп янган йөрәк барда.
Кичерелмәс!
Юк та безнең,
булмас
ярты юлда туктар хакларыбыз!
...Кузгалырга вакыт,
юл ташына
тоякларын бәрә атларыбыз.

## ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

## Рәфкать Кәрами

# КАРГЫШЛЫ ЮЛЛАР

РОМАН

### XIV

Ачлы-туклы яшәсә дә, физик көчне күп сарыф итмәгәнлектән, Мотаһирга әле җан асрарга була иде. Урын күчүләр дә табигый хәл. Үз иркендәге кеше булмагач, бик сырланып тора алмыйсың — кая кушсалар, шунда барасың. Әйтик, Мамесгов участогыннан соң ул дүртбиш ай район үзәге булган (дөрес, авылны читтән генә күрде) Березникта эшләп алгач, Шидровога күчерүне дә әллә ни бәхетсезлеккә юрамады. Дөрес, юлда бик йончыдылар. Ләкин Вага буена килеп, ныклап урнашкач, тагын үз мохитына чумган иде ул: шул ук санчасть, шул ук авырулар, аларга кулдан килгәнчә ярдәм итәргә тырышу, этап кабул итү. Чөнки этап килү белән мунчада санитария эшкәртүе ясала. Яңа килгәннәрне унбиш көнгә аерым баракка ябалар. Килүчеләр арасында яңалары да, төрле лагерьлардан җыелганнары да бар. Тоткыннарны гел күчереп йөртәләр. Бердән, үзара татулашып-берләшеп китүдән куркалар, икенчедән, әйбер булудан — пычак яки башка корал юнәтүдән шикләнәләр бугай. Араларында осталар күп бит. Шуңа күрә урын алыштыру зарури санала.

Менә шул: этап килгәч, Мотаһир чәч алучыга әйтә, мунча яктыра. Мунча, гомумән, барысына да тиеш: график белән, ун көнгә бер, Мотаһир анысын төгәл, берсүзсез үтәргә тырыша.

Әнә шундый мәшәкатьләр белән көн артыннан көн уза. Такы-токы ризык белән җан асрыйлар.

Әмма бу юлы бәхетсезлек бер Мотаһир яки башка тоткыннар өстенә генә төшмәде, ә бөтен илне кара кайгы басты.

Билгеле, тоткыннарга моны беркем дә хәбәр итмәде, сафларга тезеп игълан да ясалмады. Багана башына репродуктор да, баракларда гәзитфәлән дә юк. Киресенчә, гел белгертмәскә тырыштылар. Ләкин илкүләм, алай гына да түгел, дөньякүләм бу вакыйга төрле юллар аша лагерьга да килеп ирешге. Колактан-колакка сүз йөри башлады.

— Сугыш чыккан икән, тоткыннарны да шунда җибәрәләр икән.

Кем башлаган ул сугышны, кайчан — боларны Мотаһир баштарак анык кына белмәде. Ләкин тора-бара барысы да ачыкланды.

Бу хәбәр бигрәк тә десятниклар, сакчылар колагына әйтелә. Әмма җил яки «чыбыксыз телефон» аны тоткыннар колагына да ирештерә.

---

Ахыры. Башы 1 нче санда.

Тоткыннар, бер-берсенә нык ышанганнары,— түгәрәкләнеп утыра да гәп кора.

— Сугыш чыккан әнә...

— Безне нишләтерләр? Атып үтерерләр микән?

— Бүген өч йөз грамм ипи ашадык.

— Иртәгә ни ашарбыз икән?

Әйе, алар шулайрак баш вата. Чөнки сәбәбе бар: тоткыннар күпләп чирли, ашау җитмәгәннән үлә.

Хәер, тоткыннар да илгә киная тотмый. Чөнки басып алучылар аларның да изге җирен таптый бит. Күпчелек — эшендә тырыша.

Күпләр сугышка җибәрүне сорап язды, шул исәптән, Мотаһир да. Тик берсенә дә җавап килмәде. Ул арада аларны кабат Березникка җибәрделәр. Анда төпләнеп калырбызмы, дип торганда, февральнең унҗидесендә тагын этап — Обозерскийга хәтле.

Кыш. Чатнама суык. Йөзгә якын кеше, бер-бер артлы тезелешеп, атлый да атлый. Табаны машина баллонынннан әмәлләнгән, мамыктан эчлек ясалган олы ботинкалар астында өзлексез кар шыгырдый. Һәр чакрым гүр газабына тиң авырлык белән үтелә. Якасы һәм җиң очлары кызгылт-көрән тасмалы кара бушлатлар әле уңга, әле сулга чайкала. Кайчагында, көчле җил искәндә, алар чайкалып кына калмый, ук яки пуля эләккән каргалар кебек ап-ак кар өстенә дә авып төшкәли...

Мотаһир, агачлар арасыннан күренгән аксыл күк йөзенә карап бара торгач, аның ничектер киңәеп китүен сизде. Әйе, урман бетеп, алар ачыклыкка, тар гына елга буена килеп чыкканнар икән. Елганың теге ягында, калкурак урында, авыл йортлары тезелеп киткән. Алар безнең яклардагы кебек бер-беренә елышып, тыгызланып утырмаганнар. Барысы да зурлар — ике катлы, кечкенә булса да күп тәрәзәле, кар баскан такта түбәле, ә һәр кыекта ат башы сурәте. Өйләр бер-беренә ипле ятып торган нарат-чыршы бүрәнәләрдән салынган. Алар барысы да бер юанлыкта, кәкре-бөкресе юк, почмаклары тигез итеп киселгән. «Әйе, бездәге салам түбәле, усак бүрәнәдән корыштырган дүрт почмаклы өйләр түгел инде болар»,— дип уйлады Мотаһир, хәйран калып. Бүрәнәләрнең каралган булуына башта гаҗәпләнсә дә, соңыннан төшенде: болар сумаласы агызылмаган агач бит һәм кайбер йортларның салынуына да йөзәр ел бардыр.

Авыл эчендә агач сирәк. Монда халык өй түренә агач утыртмый, хәтта куак та үстерми, чөнки кыска вакытлы җәй айларында кояшны күреп, аның җылысын тоеп калырга тырыша. Ә поляр төннәр башлангач, кояш бөтенләй күренми, көндезен дә — эңгер-меңгер.

Авыл эченә кергәндә аларны печән төягән бер ат узып китте. Аның бар нәрсәсе дә урынында, дуга, камыт, ыңгырчак, дилбегә... Мотаһир, йөге бәләкәй булса да, аның бастырыклап төялүенә һәм хуҗа кешенең йөк өстендә бер гамьсез утырып кайтуына да игътибар итте, аннан көнләшеп куйды. Авыл баласының авыл урамына кергәч бернигә дә битараф калмавы гаҗәпмени?

Әйе, шул ук сиртмәле кое, көянтә-чиләк белән су алып кайтучы юантык гәүдәле хатын да кайдадыр күргән кебек. Олтанлы итеге, кыска кара бишмәтенә хәтле таныш сыман. Әнә бер читтә, кар баскан елга буенда, этләр чабыша, балалар тау шуа... Бер агай агач көрәк белән сукмак чистарта. Кичә кар яуганмы? Әллә өченче көннекен бүген күриме? Мотаһир үзе түзмәс иде өченче көннекен бүгенгегә калдырырга. Хәер, бөтен йөзен ап-ак сакал-мыек баскан, ак кашлары салынып төшкән картны гаепләп тә булмый: уллары сугыштадыр, үзе бетешкән. Әле дә рәхмәт өй-тирәсен караштырып торуына... Ни булса да, рәхәт инде ул капка төбеңә юл ачу! Килгән кунакны әйткән дә юк, хәтта күрше-күлән генә керсә дә йөзең якты сыман.

Конвойның өлкәне әмер бирде:

— Туктарга!

Һәм ул, колоннаны озата килүче җирле кеше белән, авыл советына кереп китте. Анда озак юанмадылар, солдат шинеленең сул җиңен кесәсенә тыккан, йолдыз урыны беленеп торган бүреген кыңгыр салган председательне ияртеп, авыл читендәге хәрабә хәленә килә язган чиркәүгә киттеләр.

Сизрәгән диварлары кызыл кирпечтән өелгән чиркәү эченә кергәч, конвой башлыгы:

— Привал! — дип кычкырды.

Әйтмәсә дә аңлашыла иде инде.

Мотаһир аның янына барып:

— Гражданин начальник, анда берничә кеше бик хәлсез, — диде.— Кайнаган су сорап булмасмы?

— Кофе кирәк түгелме? Салкын су да бик житкән.

Авыл советы председателе, гәүдәгә җиңел фронтовик егет, шундук чыгып та китте. Ярты сәгать тә үтмәде, ул өстендә булары чыгып торган бер чиләк күтәреп килде.

— Мәгез.

Аның артыннан ук бер хатын һәм үсмер тагын ике чиләк су китерделәр.

Коры паекны бераз чылатып, тамак ялгап алдылар. Эчкә җылы керде. Шуннан конвой башлыгы, Березниктан озата килүче адәм һәм авыл советы председателе киңәшләшеп алдылар. Күрәсең, икенче авылга шактый ерак, төнгә каршы юл чыгуны берсе дә өнәми иде. Шуңа күрә, монда ял итеп, иртәгә таң белән кузгалырга булдылар.

Мотаһирга бүгенгә эш юк иде — тоткыннар барысы да исән-имин килеп җиткән. Ул авыл советы председателе белән барып, тимер мич алып килде. Урман авылга авып торганлыктан, утын җитәрлек икән. Мич ягып җибәрделәр. Кем йоклап, кем сөйләшеп, кемнәрдер өзлексез мич ягып, котсыз зур чиркәүне әллә ни җылыта алмаса да, төн үткәрделәр.

Рәхмәт төшкере, иртән тагын кайнаган су булды — ике чиләк тимер мич өстендә иде. Ә урамга чыксалар — буран кузгалган. Әмма берничә карамыйча кузгалырга кирәк. Чаңгы таккан озатучы да бар, ләкин кичәге түгел, шушы авыл кешесе. Ул колоннаны алдагы авылга җиткерергә тиеш. Аннары кире кайтачак. Менә шулай соңгы пунктка барып җиткәнче аларны юл белүче җирле кешеләр озата барачак.

...Буран дулый. Мотаһирның керфегенә, йөзенә кар бәрә, зәһәр җил ач бүре кебек бертуктаусыз колак төбендә улый. Бәлки, бу җил түгел, бүре авазыдыр. Бигрәк яман аның тавышын ишетүләр... Изүгә кар тула, суыгы йөрәккә төшә, эчәкләргә хәтле шакыраеп ката кебек. Каршыдан көчле җил искәндә Мотаһир чайкалып аркан барып төшәр сыман. Шулай итмәсен өчен ул иелә, куырыла, канатлары асылынган чәүкә кебек кулларын артка суза. Гәүдәне аз гына турайттыңмы — җил тынга каплана. Кычкырып елыйсы, кемнедер каргыйсы килә. Ә кемне? «Кем гаепле безнең монда җәфа чигүгә? — дип уйлый ул.— Кем? Кем? Ни эш кылган бу хәтле интектерерлек? Кемгә ни зыяныбыз тигән? Бер генә көнгә, бер генә сәгатькә үзләрен шушы мескеннәр арасына кертәсе, бер генә чакрым юл үткәртәсе иде. Нигә безне һаман этап белән куалар? Ару гына бер җирдә эшләтсәләр, ашарга-эчәргә җитәрлек кадәр бирсәләр — без илгә файда китермәс идекмени? Менә бу хәлсезлектән йөзтүбән капланып төшкән тоткын Ватанга ни зыян китергән? Нинди җәфа салган? Әйтегез, иптәш Сталин?! Әйтегез, Берия?!» Юк, дәшүче юк. Сорауларга колак та салмыйлар. Хәер, бу тышка бәреп чыккан тавыш түгел, ә күңел авазы гына. Мондый сүзләр белән сөрән салсаң, иртәгә үк тагын да төньяккарак китәсеңне көт тә тор. Көт тә тор... тор... «Тор, иптәш! Абзый, тор! Тор, туган! Тор, агайне! Калма! Үләсең! Миңа да авыр бит. Тордыңмы? Менә шулай. Эчәсең киләме? Түз. Ашыйсың киләме? Түз. Түз, түз...»

Колакчыннарын төшереп кигән юка бүрекләр астында башлар өшеде, иске мамыктан тегелгән зур бияләй эчендә арык бармакларның сөяге ша-

кыраеп катты. Бер кат юка чалбар эченә кергән суык бу мескен ирләрнең иң нечкә җирләрен рәхимсез рәвештә куырып-куырып алды. Андыйлар, үксез бала кебек, тавыш-тынсыз яшь агызды, бияләйләрен салып, эчтә әзме-күпме калган җылы тыннарын кулларына өреп, ике бот арасын ышкыды, үзенең яраксызга чыгачагын уйлап ачыргаланды, туктап-туктап хәл җыйды. Ә туктарга ярамый. Колонна барырга тиеш, билгеләнгән урынга, әйтелгән көнгә килеп җитәргә тиеш. Шуның өчен аңа маршрут бирелгән, бу тирәнс яхшы белүчеләр — озата баручы агайлар беркетелгән. Алар булмаса, кара урман һәммәсен йотачак.

Бу юлы тоткыннарны атлар кардасына куып керттеләр. Фатирга кертүче табылмады, хәтта су да булмады. Ат абзарында кайсы саламга, кайсы печәнгә башын төртеп, бер-беренә елышып ятып, ял иттеләр. Аннары...

## XVII

...Тагын юл. Юл. Кара урман эченнән, бормаланып-сырмаланып, бара да бара ул. Әле йөзәр яшьлек карагач, чыршы-наратлар астыннан үтә, әле куян-төлке эзләре белән чуарланган аланлыкка килеп чыга, янә урман эчендә югала кебек. Тоткыннар сафын агач ботакларына яшеренгән тиеннәр, тукраннар, урман тавыклары сагаеп озатып кала.

Өч-дүрт чакрым узгач, бер тоткын тәмам хәлсезләнде.

— Бара алмыйм, гражданин начальник,— диде ул, конвойчыга тилмереп карап.

— Атла!— дип җикеренеп торгызмакчы булды аны конвойчы.— Атла, симулянт! Ну?! Кемгә әйтәм?! Атла!

— Булдыра алмыйм, гражданин начальник.

Өшәнгән тоткынны торгыза алмагач, конвойчы сафка таба борылды.

— Санитар! Живо, ко мне!

Тавыш ишетеп, Мотаһир алар янына килде. Күрә, тоткын бер аягы белән карга тезләнгән.

Мотаһир аны баядан бирле күзәтеп килә иде инде.

— Бөтенләй хәлең юкмыни?— дип сорады ул иелеп.

— Юк.

Тоткын җиргә ауды.

Аның янына конвойчы тагын берәүне чакырып китерде.

— Күтәрегез шуны!— диде ул үзе читтәрәк торып.

Мотаһир белән икәүләп тотынгач, тегене аякка бастырдылар һәм, ике ягыннан култыклап, ары алып киттеләр.

Конвойчының хәлсез тоткынны калдырмаска тырышуы табигый: әгәр берәр кеше югалса, аның үзен утыртачаклар.

Конвойчыларның катылыгы, тоткыннар белән сөйләшмәве һәм аларны үзләренә якын китермәве дә аңлашыла. Күптән түгел булып узган бер хәлдән соң алар тагын да кырысланды.

Вакыйга болай була. Утыз ике кешелек бригаданы бер сакчы гына озата бара. Сафтан икәү арткарак кала да аңардан тартырга сорый. Бер катлы адәм тәмәке биргән арада моны эләктерәләр. Мылтыгын тартып алып, үзен агачка бәйлиләр һәм сафтан дүрт кеше качып та китә. Ахырда, боларны җиде эт белән эзли чыгалар. Илле-алтмыш чакрым узгач кына куып җитәләр. Әмма тиз генә бирелми кораллы тоткыннар, бер-бер артлы ике этне үтерәләр. Ләкин патроннары беткәч, барыбер эләктерәләр үзләрен... Шундый хәлдән соң конвойчыларның тагын да явызлана төшүе табигыйдер.

...Караңгы төшкәндә бер авылга килеп керделәр. Иң кырыйдагы ике катлы зур нарат йорт каршында колонна туктады. Баягы хәлсез тоткын янына тагын икәү өстәлгән иде.

— Болар ары бара алмый,— диде Мотаһир конвой башлыгына.— Берәр өйгә кертик.

— Ярар. Әйдә минем белән.

Алар бик матурлап эшләнгән агач баскычтан менеп, өйалдыннан икенче катка күтәрелделәр. Зур өйнең җиделе лампа белән яктыртылган бер бүлмәсенә керделәр. Хуҗа хатын кара мунча миче шикелле зур мич тирәсендә кайнаша иде. Конвойчы калын тавыш белән сәлам бирде:

— Исәнмесез.

Чәчәкле ситсы кофта кигән, «җен тиресе» дип йөртелә торган тупас тукымадан тегелгән кара итәкле хатын гәүдәсен турайтты, керүчеләргә борылып карады. Аның башында кара яулык, аягында олы гына олтанлы киез итек иде.

— Исәнме,— диде ул.

— Хуҗа кайда?

— Хайван карый.

— Бар, чакыр.

Хуҗа хатын, башын читкә борып:

— Ксеня! — дип дәште.

Икенче бүлмәдән унике яшьләр чамасындагы сары чәчле, озын күлмәкле бер кыз чыкты. Ул яланаяк иде.

— Кызым, бар, атаңны чакыр.

Кыз итек киеп ишеккә якынлашуга, конвойчы Мотаһирга:

— Бар, син дә чык,— диде.— Белмәссең аларны.

Мотаһир кыз артыннан чак-чак ияреп, караңгы баскычтан беренче катка төште. Ләкин бая үзләре кергән болдырга түгел, ә арт якка чыктылар. Монда ат йөге сыешлы зур капка икән, ул ачык, бер яктагы бүлемгә мал-туар — бозавы белән сыер, бәрәнле сарыклар ябылган, икенчесендә — печән. Шунда ук, аерым бүлемдә, сука, тырма ише эш кораллары, ат сбруйлары.

— Әти!

Кызы дәшүгә, кыска кайры тун, колакчынлы чүпрәк бүрек, киез итек кигән тәбәнәк гәүдәле хуҗа маллар яныннан чыгып, Мотаһир каршына килде.

— Исәнмесез,— диде Мотаһир ачык йөз белән.

— Исәнме,— диде җирән сакалына печән кибәге ябышкан хуҗа, тире бияләен салмыйча гына.

Кызы тиз-тиз:

— Әти, сине әни чакыра,— диде дә, ялт борылып, юк та булды.

— Без этап белән барабыз,— диде Мотаһир дәшми калу уңайсыз булыр дип.— Авырулар бар.

Кем икәнен киеменнән үк аңлаган хуҗа Мотаһирга җавап биреп тормады. Өстен каккалап, атлап китте.

Өйгә кергәч, ул, шикләнеп, конвойчыга карады.

— Бер-ике көнгә сездә калып торсыннар әле,— диде конвойчы.

Хуҗаның моңа артык исе китмәде: коелып та төшмәде, шатланмады да, каршы да килмәде.

— Ярар...— дип кенә куйды ул.

Бераздан авыруларны өйгә керттеләр.

— Менә монда,— дип хуҗа хатын бер бүлмә күрсәтте.

Зур гына бүлмәнең идәнендә берничә рәт суккан паласлар җәелгән иде. Алар өстенә салам тутырылган зур матрацлар җәйде хуҗа хатын. Ситсы кисәкләреннән тегелгән мендәрләр һәм шундый ук шакмаклы-шакмаклы, чуар одеал шикелле нәрсә дә алып керде.

Бу бүлмәнең җиһазы күп түгел иде. Аяклары сырлап эшләнгән борынгы зур өстәл, ике эскәмия һәм чыра яндыру өчен җайланма. Мотаһир башта аңа гаҗәпләнебрәк карады. Су салынган кечерәк тагарак, аның бер башына тимер таяк утыртылган, ә таякның өске өлешенә чыра кыстырылган. Түшәмдә лампа-фәлән күрмәгәч, Мотаһир моның чыра яндыру өчен

көйләнгән әйбер икәнен аңлады. Стена буенда тәрәшле каба. Түр почмакта — икона.

Авыруларны урнаштыргач (алар янында бер конвойчы да калды), чыгып барышлый, мич яныннарак бакыр чүмеч эленгән агач кисмәк күреп, Мотаһир хуҗага дәште:

— Су бирмәссезме?

Салкын суны күтәреп эчкәндә Мотаһир сәндерәдән үзенә карап торган дүрт күз күрде. Икесе — баягы кызныкы, икесе җирән чәчле, сипкел битле бер малайныкы иде.

— Рәхмәт, — диде Мотаһир, тегс мөлдерәп торган күзләргә карап елмайды һәм тиз генә конвойчы артыннан юнәлде.

Бүген аларны авыл читендәге чат агач бүрәнәдән генә эшләнгән часовняга урнаштырдылар. Әлбәттә, башка вакытта һәм бүтән шартларда булса, Мотаһир бу гаҗәеп корылманың гадилегенә һәм шул ук вакытта мәһабәтлелегенә шаккатыр иде. Часовня ике түгәрәк башлы, биек агач тәреле. Бер башы зуррак һәм кыңгырау-чаң ачылган түше ачык калдырылган — колонналар гына түгәрәкләнеп тезелгән, ә икенчесенең — кечерәгенең гөмбәзе вак такта белән тышланган, балык тәңкәсен хәтерләтә. Часовняның кыек түбәсендә кар ята, баскыч өстендәге чак кына авышрак түбә такталары да кардан сыгылып тора. Тышкы кыяфәте белән бу алла йорты Мотаһирның туган авылы Түгәрәк Күлдәге агач мәчеткә тартымрак иде. Әмма агачны, тактаны бизәкләп-сырлап эшләүдә бу тирә осталарына берәү дә тиңләшә алмыйдыр. Бүрәнә булса, җеген-җеккә туры китереп, такта булса, юнып-ышкып шулкадәр чиста һәм нык эшләнгән ки, гасырлар буена торадыр кебек. Храмның эчендә, түшәмендә, рәсемнәре дә әле генә төшерелгән кебек. «Изге аналар, изге аталардыр инде болар», — дип уйлап куйды Мотаһир. Ләкин... Монда нужа куа кешене — тамак ялгап аласы, хәл җыясы бар. Чөнки иртәгә тагын юл көтә бу бичараларны.

Биш сакчының берсен һәм дүрт тоткынны (салкын тидергән тагын берәү иртәнге якта кызыша башлаган иде) бу авылда калдырырга туры килде. «Әле ярый уголовниклар юк, барыбыз да илле сигезләр», — дип сөенде Мотаһир.

...Мескеннәр, нинди аяныч хәлдә булсалар да, туктап ял иткәндә төрткәләшеп тә алалар, сөйләшергә дә сүз табалар тагын.

— Суык, — ди берсе зарланып, аякларын бәргәләп.

— Туныңны калдырмыйлар аны, — ди икенчесе мыскыллап, җылыныр өчен кулын кулга шапылдатып.

— Әйе, — ди өченчесе, өшегән борынын бияләй белән капларга тырышып, — төлке тун кисәң бу салкын сәлам бирел үтәр иде дә, ертык бушлатның кесәнә ук керә шул, каһәр.

Тагын кемдер тәрттерә:

— Хатыныңа ни алып кайтырсың икән?

— Нигә? — ди беркатлы бәндә.

— Бәй, өшегән бармакны кисеп аталар бит.

— Минем кулым өшемәде лә.

— Шул шул...

Үзара тыйнак кына көлеш, юаш кына тел чарлау озак дәвам итә алмый, чөнки авыз туңа. Ялның тәмам булуын белдереп, команда яңгырый:

— Кузгалырга!

Ничәнче көн инде Мотаһир карусыз атлый да атлый. Вакыт-вакыт оеп та китә. Андый чакларда ирексездән күзләр йомыла, аң томалана, ә аяк — атлавын дәвам итә. Кемгәдер килеп бәреләсең дә дерт итеп китәсең, йә булмаса арттагы берәрсе сиңа танавын төртә. Аннары, тагын йокылыуяулы хәлгә чумасың.

— Әнкәй, майлангач, йомарлаклап бирерсең әле...

Үз сүзләреннән үзе сискәнеп, Мотаһир авырлык белән күзен ачты. Тагын йомды һәм әле генә күз алдына килгән күренеш янә пәйда булды: әни-

се тимер килегә салып, киндер орлыгы төя, ә Мотаһир, аннан төйгән орлык сорый, имеш.

Мотаһир авырайган күз кабакларын күтәрде, көч-хәл белән әлеге хәленә кайтты: ак кар, ачы җил, өнсез-хәлсез тоткыннар сафыннан гыйбарәт иде бу чынбарлык...

Беркөнне алар болан көтүенә юлыктылар. Йөзләгән болан, таралып, карны актарып лишайник, ак мүк ашый иде. Шунда Мотаһир беренче мәртәбә Архангельск өлкәсенең төньягында яшәүче ненец дип атала торган кешеләрне күрде.

Юл өсте булгач, конвой башлыгы бераз гына аларның өе янында туктап алырга рөхсәт итте.

Йортлары — чум дигән түгәрәк өй, эче-тышы йонлач тире икән. Ишек һәм ике тәрәзәсе бар.

Чум янында икешәрләп аллы-артлы дүрт болан җигелгән җиңел чананарта тора. Бернигә эт утыра. Чит кешеләрне күргәч, алар тынычсызлана, һау-һулап өрә башлады. Тавышка чумнан, өстенә болан тиресеннән тегкән чапан һәм итек кигән, сирәк сакал-мыеклы хуҗа чыкты. Ул тәбәнәк гәүдәле, кысык күзле, киң чырайлы иде. Күрәсең, тоткыннар кәрванын беренче генә очратуы түгелдер, аптырап калмады. Конвой башлыгына елмаеп сәлам бирде.

Мотаһир ненецның русчаны бик начар белүен, әмма үз кирәген генә сорый да алуын аңлады.

— Чәй бармы? — диде ул.

— Ни бирәсең?

— Болан. Кайсын телисең?

— Юк шул, — диде конвой башлыгы мескенгә салышып.

Ненец башын чайкап:

— Начар, — диде.

Ул арада чумнан тагын бер ир, матур туннар кигән ике хатын, өч бала чыкты. Алар үзара гәпләшеп алдылар. Ир кеше конвойчыдан:

— Аракы бармы? — дип сорады.

— Нәрсә бирәсең?

Ненец башындагы озын колаклы, яшь болан мехыннан тегелгән эчетышы йон бүрекне салып, кулына тотты.

— Мә.

— Юк шул, — диде конвойчы.

Ул, күрәсең, боларны юри ирештерә һәм шул үртәүдән тәм таба иде. Аннары ул нартага күрсәтте.

— Утыртып йөрт әле!

Сакал-мыеклы ялындырып тормады, кулына озын таяк алып, нартага барып та утырды.

Конвой башлыгы шинель чабуларын җыеп, киез итеген күтәреп, җайлап урнашуга, ненец боланнарга кычкырып җибәрде:

— Һайт!

Һәм китте гайрәтле боланнар, китте боланнар — кар тузаны гына бөтерелеп калды.

Конвой башлыгы югыннан файдаланып, колоннаны озата килүче җирле халык кешесе бер читтә яшь ненец белән гәп корып җибәрде. Күрәсең, аның үз планнары һәм боларга кирәкле әйберләрне табар чамасы да бар иде. Чөнки ул авылына кире кайтышлый тагын болар яныннан үтә бит. Моны чамалап-сизеп торган Мотаһир үзалдына елмаеп: «Шулай инде, берәү янчык тегә, берәү мал җыя», дип уйлап куйды эчтән генә.

Аннары Мотаһир һәм башка тоткыннар әсәрләнеп, боланнарның аякларны туры алып, типтереп-юртып баруларына сокланып карап тордылар. Боланнар аякларын сыдырып йөрми, тигән җиргә тия, тимәгән җиргә юк — очалар гына. Менә алар бераздан әйләнеп тә килделәр. Тагын бер солдатны утыртып, янә нартаны алып чаптылар.

«Бәхетле кешеләр — дип уйлап куйды Мотаһир, ненецларга карап. — Нинди иркендә, ирекtә яшиләр. Кайда туктасалар, шул төш алар өчен үз авылы кебектер инде. Меңләгән чакрым тундраның теләсә кай урыны — алар өчен туган җир. Безнең генә туган җирләр ерак...»

Ачык зәңгәр күк йөзе, аның читендә күренгән аксыл болытлар, якындагы урман, еракта зәңгәрләнеп торган калкулыклар — болар барысы да кешеләр өчен бит, югыйсә. Озын поляр төннәрдән соң бик азга гына күренә башлаган кояш та барысына тигез карый. Рәхәтләнеп яшә иркенлектә, эшлә, туйганчы аша... Ни теләсәң, шуны ки...

Үзенең һәм башка тоткыннарның өстенә карагач, хәлләренең мөшкелләгән, мескенлекләрен тагын бер кат йөрәге аша кичереп, язмышына чын рәнҗү белән рәнҗеде Мотаһир. Ненецлар янынннан кузгалып киткәч тә каерылып-каерылып карады ул урман буендагы ялгыз чумга, һаман бәләкәйләнә барган кешеләргә, чатлы мөгезле горур боланнарга. Бәлки, иртәгә монда күз ачкысыз буран котырып, суык кошларны куырып төшерер, тик барыбер төньякның бу ирекле халкына Мотаһир көнләшеп карар. Чөнки алар — ирекле.

...Мең газап белән соңгы пунктка — Обозерский стансасына барып җиттеләр. Әмма, ни-нәрсә булгандыр, бер атнадан аларга тагын кузгалырга әмер булды. Бу юлы бәләкәй генә авылга — Кяма станциясенә хәтле бардылар.

## XVIII

...Мотаһирның кулдашы күрексез генә кыяфәтле Яковлев фамилияле карт иде. Бот төбеннән кар ерып, десятник күрсәткән агач төбенә көч-хәл белән килеп җиттеләр. Мәһабәт чыршы, бу бетешкән бәндәләрне бар дип тә белмәгәндәй, мәгърур кыяфәттә башын күккә терәгән; үзе юан, озын, ботаклары киң.

— Менә монысы бара, — диде десятник һәм нинди сортларга аерыргакисәргә икәнен аңлатырга кереште. — Пиловочный... экспорт... эчке базар...

Әйе, һәрберсенә тиешенчә үлчәп кисәргә кирәк. Десятник шулай аңлатты да китеп барды. Ләкин кискәнче әле ул агачны аударасы бар. Хәлсез, бетешкән бу карт белән ни майтарасың?

Мотаһир көрәк белән агач тирәсен кардан арындырды. Хәл җыйды. Аннары:

— Әйдәгез, Модест Петрович, керешик булмаса, — диде ул бер читтә басып торган конвойчыга кырын-кырын карап һәм пычкыга ябышты.

Пычкының икенче башына Яковлев та тотынды. Ләкин ул бичара хәлсез: өч-дүрт мәртәбә генә тарта да туктап кала, тагын бераз Мотаһир тартканга ияреп бара да туктарга мәҗбүр була. Кайвакыт Мотаһирның ачуы да чыга. Ул пычкыны үзенә таба тарта да, этми. Чөнки Яковлев тартып алырга тиеш бит. Ә теге бичараның дәрманы юк. Алтмыштагы карт нишләсен, ничек тартсын ул пычкыны һәм колач җитмәслек чыршыны кисеп чыгарсын. Тагын Мотаһирның үзенә көч куярга кирәк. Юк, тартырга гына түгел, пычкыны тегеңә таба этәргә дә кирәк. Ә ул күпмегә чыдар? Үзе дә ач бит. Аның да паегы шул ук — ике йөз грамм ипи дә балык ашы. Ай ул балык ашлары... Төнлә төшләренә кереп йөдәтә Мотаһирның... Кабып йота ул балык башлары, үткен тешләре белән шатыр-шотыр аның үз башын чәйни, җегәре беткән кул-аякларын тешләп-тешләп ала... Нишләп шултикле гайрәт чигерә икән бу балык башлары? Югыйсә, Мотаһир балык күрмәгән кеше түгел: Олы күлдә аны капчык-капчык тоталар иде бит. Табан балык бик тәмле дә була иде. Әле булгандә үтә кызык: капчыкларны тезеп куялар да, берәүне читкә каратып кычкырталар.

— Бусы кемгә?

— Фәләнгә.

— Бусысы кемгә?

Әһә, бусысы диелде. Ә моны белүче һәм кычкырып торучы гына белә. Хәер, моның серен барысы да беләләр, ләкин кызык өчен белмәмешкә салышалар иде.

— Бусысы кемгә? — дип кайтарып сорый бүлүче.

— Миңа.

И заманалар, сагынып сөйләргә генә калды. Яшьтәшләренең күбесе сугыштадыр инде хәзер...

— Ава бит!

Мотаһир, шунда гына Яковлев кычкырганга айнып китте һәм бер кырыйга чак тайпылып өлгерде.

Көне буе яуган кар астында эшләүдән аларның кисме юешләнеп бетте. Гомуми учак янына барып утырдылар. Яковлев, тәне оеп, шундук йоклап та китте.

Мотаһир аңа карап уйга калды. Хәлсез, ач кеше ничек норма үтәсен, булмый — ярты норманы гына үтәп булыр. Димәк, паек та артмый. Паек арттырыр өчен норма үтәргә кирәк, ә норма үтәр өчен — ашау кирәк. Ниндидер сәер түгәрәк эченә кереп басканнар диярсең. Мотаһир байларның ындыр табагындагы ат молотилкасын исенә төшерде. Аны әйләндерер өчен камыт, валек баулары белән дүрт ат җигелә иде, ә ике малай әкрен генә арттан куалый. Һәм шулай... көннәр буе түгәрәктән чыга алмыйсың...

Ә бу вакытта, алардан ерак кына түгел, тагын тоткыннар, тагын ач бәндәләр... Урман кисәләр.

Әнә икәве, башларын артка ташлап, агач башына караган да гәп кора.

— Евгений Петрович, бу агачны кайсы якка авар дип уйлыйсың?

— Белмим инде, Иван Харламович.

Озын пычкыга икәү тотыналар, эз салалар һәм... кисәләр. Болар урман кисүчеләр түгел, шуңа күрә агачның кайсы якка аварга тиешлеген, җилгә чамалап, ботакларының кай тарафка күбрәк булуыннан чыгып, кәүсәсенең авышлыгын да шәйли алмыйча эш итәләр. Чөнки аларның берсе күп илләрне гизгән дипломат, ә икенчесе — өлкә-край белән җитәкчелек итәргә сәләтле партия работнигы.

Мотаһир аларга илтифат итмәгән кебек, алар да Яковлев белән Мотаһирга борылып карамый. Алар бары агач кисүне генә белә. Конвойчы да дәшми. Чөнки фәлән вакыттан соң боларның расходка чыгасын, качар рәтләре югын белә ул. Тегеләр учак янына юнәлсә дә, дәшми.

— Евгений Петрович, җылынып алыйк.

— Әйдә, Иван Харламович.

Пыскып чи ботак-чатак яна, төтен күтәрелә, шулай да җылысы бар үзенең.

Бераздан урман кисүчеләр аяклана.

— Әйе, Иван Харламович, ут янында утыру күңелле. Бүксәне ничек тутырырбыз?

— Әйтмә инде... Булыр микән бер рәхәт көннәр? Туйганчы ашау, кояшта җылынып утыру...

Хәлләре бетеп, әмма норма үтәлмәгән килеш, лагерьга кайттылар.

— Ах, алла гынам, нәрсә эшләргә? Ашханәгә ничек барып килергә?

Яковлевны тагын җәлли Мотаһир. Әйе, хәтта шул ике йөз грамм ипи белән балык ашын барып капкаларга да хәле юк бит. Ул гына түгел, күпләр шулай, әкренләп сула тоткыннар...

Исән калганнары җыелышып, түгәрәкләнеп, гәп куерта.

— Менә килер заман, чыгарырлар. Өйләргә кайтырбыз...

Шуннан хыял дөньясына чумалар. Ләкин бераздан чынбарлыкка, бүгенге көнгә әйләнеп кайтырга мәҗбүрләр.

— Нишләп болай булды бу? Нишләп безне фронтка җибәрмиләр? Әллә без сугышмас идекме?

— Немец Архангельны да бомбага тота икән...

— Безнең гаилә нишләр инде?

Ә мескен Яковлев һаман үз белгәнен сөйли. Ул — галим, тарихчы, сөйләү куәсе — хәйран калырлык. Мотаһир моңарчы ишетмәгән нәрсәләрне ул әле бүген генә, кичә генә үзе күргәндәй сөйли. Юлий Цезарь, Геродот, Александр Македонский, Сократ һәм тагын әллә кемнәр белән тулган аның башы. Ул Иван Грозный, Петр Беренче кебек шәхесләрнең кайбер эшләрен мактый, беришләрен яманлый. Петр Беренченең Архангельскида кораблар төзү кебек эшләрен, мәсәлән, ул бик хуп күрә. Мотаһирга — укый-яза белсә дә, төпле белем ала алмаган сала кешесенә — аның бу хикәятләре кызык, ләкин ул кирәкле нәрсә кебек түгел, ә аулак өйләрдә сөйләнә торган мажаралы, мавыктыргыч әкият төсле генә иде. Мескен картның башына зыян килмәде микән, дип тә уйлаштыра Мотаһир. Ләкин Суворов, Наполеон, Кутузовлар һәм соңгы вакытта Гитлерга кагылышлы фикерләре аның акылы камил булуын раслый сыман. Ул хәтта, үзе христиан динендә булса да, Мөхәммәт пәйгамбәргә кагылышлы хәл-әхвәлләр турында да хәбәрдар иде. Иң шаккатырганы шул булды; карт гарәпчә дә сукалый икән.

Беркөнне, Мотаһир кәгазь кисәге алып, үзенең исем-фамилиясен гарәпчә язды да Яковлевка сузды.

Башын иеп, йокымсырап, нарда утырган карт әүвәл аңышмыйча торды. Күрәсең, ничә еллар яраткан хезмәтеннән аерылган, китаплардан мәхрүм булган галим тиз генә зиһенен җыя алмады. Ул, башын күтәреп, Мотаһирга карады. Аннары, күзләрен кыса төшеп, янә язуга текәлде һәм:

— Мотаһир...— дип иҗекләп укыды.— Дөресме?

Аның талчыккан чырае яктырып китте. Мотаһир да елмайды.

— Әйе.

Шуннан Мотаһир картның да исем-фамилиясен яза башлады. Ләкин ул аның исемен язуга, карт түзмәде, каләмне алып, фамилиясен үзе язып куйды. Көлешә башладылар.

— Сез кайда укыдыгыз? Кайсы университетта?— дип сорады Яковлев.— Казандамы?

— Авылда.

— Ничек?

— Мәдрәсәдә.

— Ах, әйе, шулай бит, шулай. Сезнең һәр авылда мәдрәсә булган бит. Дөресме? Әйе. Сезнең халык турында Владимир Ильич язып калдырган мәгълүматлар да бар. Укымышлы халык. Элек-электән, укымышлы, әйе. Хәтта Коненковның «укып утыручы татар» дигән скульптурасын да күрдем. Хәтерем ялгышмаса, ул 1912 елны ясалган. Димәк, революциягә хәтле. Сезнең халыктан байтак галимнәр дә чыккан. Бигрәк тә көнчыгыш телләре буенча...

Билгеле, Мотаһир өчен болары караңгы иде. Бу хакта сүз барганда аңа фәкать, әйе шул, шулай шул, дип баш кагып утырырга гына кала. Ул картны тыңлый, ә үзе аның язмышы, тормышы хакында уйлана. Шундаен галим кешеләрнең монда әрәм булып ятуларына офтана.

Дөресен генә әйткәндә, Мотаһирның да тора-бара күзе ачыла төште. Элегрәк ул кулга алынучылар арасында байлар, муллалар, кулаклар күпчелек тәшкил итәдер, дип уйласа, Яковлевка карап, икенчерәк фикер йөртергә мәҗбүр иде. Лагерьларда ул хәрбиләрне, галимнәрне, инженерларны, интеллигенцияне, партия-совет хезмәткәрләрен күбрәк очратты түгелме соң? Дөрес, Мотаһир алар белән якыннан аралашмады. Алар — Мотаһир тиңе түгел. Аны чолгап алган таныш-белешләре — үзе кебек сала агайлары, завод эшчеләре — кара хезмәт кешеләре. Шулай да Яковлев, Золотилов кебек зыялыларны ул монда байтак күрде. Әмма кем генә булмасын, алар — бөтенесе дә бушка тир түгүче эш атлары. Күпләр рухи яктан сына бирдә.

Әлеге картка килгәндә, Мотаһир Яковлевның инсафлы, намуслы булып кала алуы хакында уйланды һәм моның сәбәбенә төшенергә тырышты. Уйлана торгач, ул моның эзенә төште дә шикелле. Яковлевның бөтен тормышы яшьли үк шушы юнәлешкә китү — тиешле тәрбия алуында иде. Һәм шушы картка бәйле рәвештә Мотаһир үз язмышы хакында да фикер йөртте.

Ул да төрле хәлләргә юлыкты бит. Әмма кыйбласын югалтмады. Нилектән бу? Югыйсә, Мотаһир шундый мәтәвекләргә килеп эләккәләде — чын-чынлап җинаять эшләү ихтималы да бар бит. Тик аны гел нидер тотып торды. Нәрсә соң ул «нидер»? Уйлана торгач, ул аны аңлады: асылына төшенде, бу — туган җиреңне ярату, ата-анаңа хөрмәт, ата-бабаңның кем булуы, нәсел-нәсәбең хакындагы уйлар, ягъни «Яхшыдан яман туган» дип әйтмәсеннәр. Гаиләң алдындагы бурыч, авылдашларың алдындагы абруең төшүдән, мәсхәрәгә калудан курку. Ә иң мөһиме — кечкенәдән килгән тәрбия, үзеңнең кайсы халык баласы икәнеңне ачык тою, үзеңә кадәр яшәгәннәрдән үрнәк алу. Болар барысы бергә кушылып, олы бер төшенчәне — иман дигән төшенчәне тәшкил итә иде. Юк, буниндидер дингә яисә хискә-хорафатка бәйле иман түгел, ә чынбарлыкта, тормышта, аның туып-үскән авылы җирлегендә барлыкка килгән әхлак нормаларын — холкын-фигылен формалаштырган иман иде. Кешене ач-ялангач яшәргә дучар итәргә, аның иреген буарга була, әмма аның зиһенен-аңын томалап, иманыннан ваз кичтереп булмый. Чөнки ул ана сөте белән кергән, туган туфрагының һәр бөртеге белән сеңгән. Мотаһир күңеленнән моңа сөенә һәм үзенең шулай булуына шөкрана кылып бетерә алмый. Ул шушы тәмугны үткәннән соң да исән калган иманын киләчәктә дә күз карасыдай сакларга тырышыр, аны балаларына да җиткерер, яңа буыннарга тапшырыр. Шушы хакыйкатьне аңлау аны үз күз алдында да, башкалар каршында да бермә-бер күтәреп җибәрде. Бәлки шуңа күрәдер, аңа хәтта уголовниклар да хөрмәт белән карыйлар иде. Халыкта иң яман кешегә әйтелә торган «имансыз», «денсез» сүзен аңа беркайчан да, беркемнең дә әйткәне булмады.

Тагын бер нәрсәгә сөенде Мотаһир: аның тирәсендә яхшылыкка яхшылык белән җавап бирүче кешеләр булды, алар аны өметсезлеккә бирелмәскә, иленә-ватанына, халкына ышанычын югалтмаска өндәделәр, бәхетенең алда икәненә, бу мәхшәрдән кайчан да булса бер котылачагына өмет бagларга булыштылар. Аларның үгет-нәсихәтеннән башка ул бәлки күптән һәлак булыр, үзен югалтыр иде.

Мотаһир тагын бер нәрсәгә ышанды: кешеләргә этлек эшләмәү, һәр кешене кеше дип санау, бәхетсезләргә кул суза белү дә аның үзенә игелек булып кайта икән. Әлбәттә, ач-ялангач килеш башына мондый уйлар килү гайре-табигый сыман тоелса да, ул моңа гаҗәпләнмәде. Чөнки туган җиреннән, якыннарыннан аерылган кеше үз эченә бикләнебрәк яшәүчән, хискә-уйга бирелүчән була.

...Беркөнне Мотаһир электән таныш доктор Золотиловның да монда икәнен белде һәм, тәвәккәлләп, аның янына китте.

Доктор аны ачык чырай белән каршылады, хәл-әхвәл сорашты. Үзенә әйтмәсә дә, ул Мотаһирның сулган йөзенә, эчкә баткан яңакларына карап хәле шәптән түгел икәнен аңлаган иде. Бердән, аның җәлләү тойгысы уянса, икенчедән, эш сөючән медицина хезмәткәре табылуга сөенеп туя алмады.

Ахырда:

— Стационарда эшләргә телисезме? — дип сорады доктор.

Мотаһир өздереп кенә әйтмәде. Чөнки мондагы хәлне белеп бетерми.

— Әгәр урын булса...

Золотилов Архангельскига телеграмма бирде һәм өч көннән Мотаһирны стационарга билгеләделәр. Аның карамагына туберкулез бүлеге тапшырылды.

Кереп урнашкач та Мотаһир доктор Золотиловка үзенең кулдашы Яковлев карт турында әйтте.

— Син аны стационарга сал,— диде Золотилов.

Мотаһир шулай итте дә. Бер атнадан Яковлевны чыгарырга кирәк иде. Золотилов аны карагач, башын чайкады һәм, бир читкә китеп, Мотаһирга әйтте:

— Чыгарсаң, үлә инде бу.

— Нишләргә соң? — дип аңа өмет тулы күз карашын төбәде Мотаһир.

Тоткыннар йөзләгән, меңләгән, барысы да кызганыч, барысының да тормышы кыл өстендә. Әмма Яковлев аңа бигрәк тә җәл тоелды. Шуны гына исән калдырса да, аның намусына хилафлык килмәс төсле иде. Моны Золотилов та аңлады булса кирәк. Ул да картның — олы галимнең — исән-имин котыла алса, әле ватанга күп файда китерә аласына ышана иде. Озак баш ваткач, ул ныклы карарга килде:

— Син аны санитар итеп ал.

Калганын Мотаһирга әйтеп-аңлатып, өйрәтеп торасы юк иде.

Тора-бара Яковлев аның иң якын ярдәмчесенә әверелде: ул авырулар-га аш алып килә, үлгәннәргә акт яза, кабер өсләрендәге баштактага буяу белән аларның исем-фамилияләрен һәм дело номерын язып куя. Кыскасы, карт галим Мотаһирның да, Золотиловның да эшенә хәл-хәленчә булышлык итә. Ул эше белән генә түгел, үзенең тормышка гашыйк булуы, күтәренке рухы белән дә аларга уңай тәэсир итә иде.

Бервакыт Яковлев, ачылып китеп, Мотаһирга:

— Яшисе килә бит,— диде.— Аристотель әйтмешли, җиһанда безгә бик аз гына вакыт бирелгән — яшәү бәхете. Бу бөек һәм гүзәл бүләк.

— Әйе шул, Модест Петрович,— диде Мотаһир да аның белән килешеп,— һич кенә дә үләсе килми.

Шулай да Яковлев картның да күңеле төшенке чаклар була.

— Безнең гомер үткән инде, без яшисен яшәдек,— диде ул берчакны уйга талып.— Киләчәк буыннар кызганыч. «Тереклек иясенә рәхимсезлек кылган ил хәерче булыр»,— дигән Лев Толстой.

## XIX

Архангельск белән Ленинград арасындагы Кодина станциясе иде Мотаһирның чираттагы тукталышы. Кодина үзе бер-ике катлы агач йортлардан гыйбарәт булган зур поселок, лагерьдан ике чакрымда. Ә Мотаһирларны целлюлоза заводына китерделәр. Ни-нәрсә ясыйлардыр — билгесез. Заводта атлар да, машиналар да бар иде. Әйләнә-тирәсендә күчмә юллар да ясыйлар. Бер участокта урман сирәкләнгәч, икенче җирдән кисә башлыйлар. Ә хәзергә тоткыннар үзләренә тактадан барак әмәлләделәр, авырулар өчен — бүрәнәдән стационар. Баракның тактадан гына булуына башта бик уфтанганнар иде дә, соңыннан сөенделәр. Чөнки ахырдан шул беленде: бүрәнәдән салган йортта каһәр суккан кандала тиз үрчи икән.

Лагерьга кеше өстәлгәннән өстәлә торды. Ә кайда тоткын — шунда авыру. Икенче, тора-бара өченче стационар хәстәрләргә туры килде. Мотаһир башта беренчесендә иде, аннары өченчегә күчерделәр.

Ни кушсалар, кая кушсалар да риза — башкалар әнә урман кисә. Алар әле Мотаһир кебек авыл гыйбадлары түгел, инженер да конструктор. Алар исә кайда да инженер булып кала икән. Моның шулай икәненә Мотаһир бервакыт үзе ышанды.

Пычкы кайрап, балта үткенләп тору өчен махсус билгеләнгән берничә кеше бар иде. Беркөнне шуларның берсе колония начальнигына мөрәҗәгать итте:

— Гражданин начальник, эшне җиңеләйтергә һәм тизләтергә рөхсәт бирмәссезме?

Начальник тегенең буй-сынына, килеш-килбәтенә күз ташлап:

— Ничек? — дип сорады.
— Стан ясап.
Һәм тоткын башында туган уй-фикерне начальник биргән кәгазьгә сызым итеп төшерә башлады. Күрәсең, колония начальнигы да туң баш түгел, бу тәкъдимнең файдасына тиз төшенде.
— Яхшы. Фамилияң ничек?
— Мартынов.
— Үзеңә ике булышчы сайлап ал.
Шуннан начальник үзенең урынбасарына — сугыштан гарипләнеп кайткан офицерга — тегеләрне эштән азат итү, тиешле материал, кирәк-ярак белән тәэмин итү хакында күрсәтмә бирде.
Атна-ун көн узды микән, Мотаһир пычкы кайрый, балта чарлый торган сарайда җыйнак кына бер станок күрде. Әлеге эшнең башында торган инженер Мартынов фин пычкысын станокка җайлап-кыстырып куя да, кнопкага баса. Гүләгән тавыш ишетелә, ниләрдер хәрәкәткә килә һәм берничә секундтан пычкы разводы алынган, үткенләнгән һәм тигезләнгән хәлендә, яңа гына заводтан кайткан кебек тешләрен ялтыратып, станокның икенче ягыннан килеп тә чыга.
Мотаһир гына түгел, бик күпләр моны хәйран калып карап торды. Ләкин араларында башкача фикер йөртүчеләр дә булган икән.
— Безгә ул станок нигә кирәк? — диде берәү. — Әле ничә кеше җиңел эштә иде, хәзер аларны урман кисәргә куялар.
Икенче тоткын каршы төште:
— Хезмәт җитештерүчәнлеге арта бит.
— Дивана, аннан сиңа ни файда?..

## XX

Бервакыт, йомышы төшеп, Мотаһир каптеркага* керде. Аның бирегә беренче генә килүе түгел, каптеркачы да таныш — Оренбург ягы кешесе иде. Ничә керсә дә каптеркачы Юра өстәлгә кырын яткан була. Әмма үзе уяу — кеше кергәч, гәүдәсен турайта да, өстәлгә куя. Әмма бүген баш киеме юк иде аның. Билгеле, Мотаһир башта каптеркачының бу сәер кыланышына игътибар итмәде. Ләкин бу юлы колагына ниндидер тавыш чалынып киткәндәй булды. Ул шикләнеп каптерчыга карады. Теге бермәлгә каушап калгандай булды, әмма сер бирмәде. Мотаһир үзенә кирәкле әйберне сорагач, каптеркачы өстәл ягыннан китәргә мәҗбүр булды. Ул таянып торган өстәл бушап калды. Шулчак Мотаһир анда беленер-беленмәс кенә тишек барлыгын шәйләде, баягы аваз шуннан ишетелә иде...
Бер-береңнән шикләнү — тоткыннар арасында була торган һәм бик хәтәр нәрсә иде. Кемдер сүзен әйтеп бетерми икән, икенчең төпченеп аптыратмый икән — моңа үпкәләүче юк, бу — гадәти хәл. Ләкин каптеркачы Юра белән Мотаһир якташлар булганлыктан (картада өч чабата арасы җир, дип шаярталар алар), икеле-микеле уй да калмасын өчен, Мотаһир туп-туры сорады:
— Әллә... радиомы?
Теге стенага терәтелгән, чигенер урыны юк, якташы да булгач, турысын әйтүдән башка чарасы калмады.
— Әйе.
Мотаһир риясыз, сабыйларча беркатлылык белән авызын ерды.
— Кая, тыңлап карыйм әле.
Каптеркачы ишеккә карап алды, моның белән генә канәгатьләнмичә, аны ачып, тышка да күз салды. Бары шуннан соң гына, өстәлгә баягыча кырын ятып, Мотаһир шәйләгән төртке-тишеккә колагын куйды. Аның

* Каптерка — кием-салым, вак-тояк әйберләр саклана торган урын.

урынына килеп, шул ук хәрәкәтне Мотаһир да кабатлады, сөенеченнән кычкырып җибәрде:

— Менә әкәмәт! Менә сиңа мә...

Ул, үз колагына үзе ышанмыйча, хәйран калды: Мәскәү сөйли ләбаса! Левитан тавышы! Совинформбюро хәбәрен тапшыра. Сугыш хәлләрен сөйли.

— Йә хода! Илдә ниләр барын да белмибез бит. Ә бу... Менә могҗиза, менә әкәмәт!..

Юра ишектән күзен алмады.

— Ярар, икенче керерсең,— диде ул.— Тик...

Мотаһир юләр түгел, иптәшен сатарга башы икемени?! Ул бармагын иренена тидереп алды, уголовниклардан ишеткән блатной сүзне әйтте:

— Могила!

Шуннан алар тегене-моны сөйләшеп утырдылар. Ахырда Мотаһир, сабырын җуеп, каптеркачының үзенә карата шик тотмавын күреп, сорарга җөрьәт итте:

— Юра, ничек моны әмәлли алдың?

— Рәтен тапсаң, кар да яна,— диде якташы серле генә.

Мотаһир тәвәккәлләде.

— Мин дә эш урынында күбесенчә берүзем бит...

Гәптәше аның тел төбен аңлады.

— Белмим,— дип иңбашын сикертте.— Әйтеп карармын.

Бу вакыйга Мотаһирның уеннан чыкмаса да, аңа якын көннәрдә генә каптеркага керергә туры килмәде. Дөресен генә әйткәндә, тиктомалдан каядыр биләмгә йөрүне ул өнәми дә. Аның бит эше — авыруларны карау, дәвалау, лагерьда профилактика чаралары үткәрү. Аннары, минуты-сәгате белән дигәндәй берәр түрәнең килеп чыгуы, аны таптыру ихтимал. Мәсьәләнең тагын бер четерекле ягы бар: беркем дә үз янына еш килеп йөрүне өнәми. Чөнки моның син барган кешедә дә һәм моны күргән бүтәннәрдә дә шик тудыруы мөмкин. Шулай да әлеге уй — үзенә дә шундыйрак нәрсә әмәлләү — башыннан китмәде. Гәрчә, әләгә-нитә калса, ахыры хәерле булмаячагын аңласа да, Мотаһирның теләге зур иде. Күрәсең, Юра да моны онытмаган.

Беркөнне ул, Мотаһирны ашханәдә күреп, агач кашыгын ялый-ялый, шыпырт кына:

— Кереп чык әле,— диде.

Мотаһир, «ярар» дигәнне аңлатып, баш какты.

Ул кергәндә каптеркада ят кеше бар иде. Ят дигәч тә, ул да Мотаһир кебек үк тоткын. Аның да өстендә көрән якалы, түшендә кызгылт-көрән каплавычлы кара гимнастерка, җиң очлары да кызгылт-көрән. Туры гына тегелгән, кесәсез кара чалбар, аягында зур ботинка. Башында маңгаена төшереп бәйләп куйган чүпрәк кисәге. Монысы да гаҗәп түгел, кем нәрсә таба — башына шуны чәпи. Фуражкаң юк икән, чүпрәк кисәге дә ярап куя.

Каптеркачы аларны таныштырды. Сары чәчле, ябык йөзле, чандыр гәүдәле бу егет тә әллә ни ерактан түгел икән — Чиләбедән булып чыкты. Тегесен-монысын сөйләшеп утырдылар. Ни әйтсәң дә уртак язмышлар. Чиләбе дә ят җир түгел. Хәтта Мотаһир, егетләрне көлдереп, такмаклап та алды:

— Бездә болайрак җырлыйлар: «Әйдә киттек Чиләбегә, ник монда чиләнергә. Чиләбедә кызлар беткәч, кайтырбыз өйләнергә».

Ул җырны русчага да тәрҗемә итеп бирде.

— Килештек, болай булгач, мин сезне үзебезгә алып кайтам,— диде Владимир.— Минем бөтен дуслар — татар егетләре.

Янә көлештеләр. Ахырда, Юра әйтеп куйды:

— Бик кирәксә, Володя эшләр...

— Әйбәт булыр ие,— диде Мотаһир әле берсенә, әле икенчесенә карап.— Ә мин сезгә нинди изгелек эшли алам?

Владимир җавабын кыска тотты:

— Вакланмыйк.

Күрәсең, оста куллы һәм түгәрәк башлы бу егеткә кемгә дә булса яхшылык эшләве үзе бер бәхет иде.

Озак та үтмәде, берничә көннән Владимир стационарга бер бәләкәй калай банка кертеп чыкты. Икенче-өченче керүендә ниндидер чыбыклар да бар иде. Ул үзе бүлмәдә кайнашканда Мотаһир сакта, тоткыннар теле белән әйткәндә «шухер»да торды.

Соңгы килүендә Владимир озак маташмады. Ун-унбиш минут үтте микән, ишекне ачып, әкрен генә дәште:

— Кер.

Мотаһир үз бүлмәсенә үтте. Ләкин бернинди үзгәреш сизмәде. Билгеле, ул теге әйбернең кая яшерелгән булуын, кергән бер кешенең күзенә бәрелеп тормаска тиешлеген яхшы аңлый. Ләкин нигәдер, аны могҗиза көткәнгәме, керүгә тавышын ишетер сыман иде. Ә ул могҗиза, чыннан да, бар: ул шушы бүлмәдә, тәрәзә төбендә генә, калай банкада!

— Кил якынрак,— диде Владимир аның җиңенә кагылып.— Тыңлап кара...

Мотаһир банкага колагын куйды. Сөйли! Дөресрәге, уйный. Кемдер берәү үтә дә моңлы итеп скрипкада уйный иде.

— Булган бу! — диде Мотаһир сабыйларча сөенеп.

— Шыпырт,— диде Владимир бармагын иренена тидереп.— Ярый, мин киттем.

— Рәхмәт,— диде Мотаһир һәм, кадерле банкадан аерылып, аны озата чыгарга җыенды.

— Кирәкми. Монда кал.

Владимирның сүзен тыңлап, Мотаһир үз бүлмәсендә калды. Һәм бераздан, ишекне ачып карады да, янә банкага колагын куйды. Баягы скрипка һаман моңлана, күңелнең иң нечкә кылларын тибрәтә, дулкынландыра, уеңны әллә кайларга алып китә. Хәер, әллә кайларга түгел, ә туган авылына... Әйе, скрипка тавышы аңа туган авылын хәтерләтә. Чөнки алар урамында да бер скрипкачы карт яши иде. Ул сукыр карт гомер буе скрипка уйнап көн итте. Аның уйнавына сокланмаган, хәйран калмаган кеше юк иде. Бигрәк тә әбиләр ярата иде аның уйнавын. Җылый-җылый тыңлыйлар иде. Никадәр моң, нихәтле сагыш булды икән аның йөрәгендә? Нинди бетмәс-төкәнмәс хәсрәт булды икән аның күңелендә?...

Шулай итеп, күңеле сынык Мотаһир өчен бәхетле (әгәр тоткындагы кеше хакында шулай әйтергә яраса) көннәр башланды: тәрәзә төбендәге кечкенә калай банканы колагына куя да, радио тыңлый, үзен ил-көн белән аралашып яшәгәндәй хис итә. Чәнечкеле тимер чыбык белән кат-кат әйләндерелгән, кәнә-төнә сакчы һәм этләр саклый, атна саен тенту-тикшерү үткәрелә торган лагерьның шифаханәсендә, башлыкларның борын төбендә радио сөйләсен әле! Бу могҗиза түгелмени?! Мотаһир очынып йөрсә дә, сөенеп туя алмаса да, каптеркачы Юра кебек сак булырга кирәклеген белә иде. Ул, тышта аяк тавышы ишетелдә исә, банканы әйләндереп куя. Аннары, теләсә кайсы вакытта ул аңа барып кагылмый да. Чөнки радио әллә ни сөенечле хәбәрләр ирештерми — фронтта хәлләр шәптән түгел. Дөрес, фашистлар Мәскәү янында тар-мар ителеп, чигенә башлаганнар. Монысы — зур сөенеч. Кайчандыр Мотаһир хезмәт иткән Смоленск та азат ителгән. Ләкин сугыш якын гына: Ленинград камалышта, Кола ярымутравында һәм Карело-финда кан коеш. Сталинградта коточкыч авыр сугышлар бара, дошман Иделгә чыккан. Ә аннан Саратов, Куйбышев, Ульяновск һәм... Казан да ерак түгел. Моны уйласа, Мотаһирның йөрәге сыкрап китә. Ә уйламыйча булдыра алмый. Куркыныч — күз алдында. Тагын бер ягы бар: ул, сау-таза килеш дип әйтерлек, кулына корал тотып илен дошманнардан саклаша алмый. Радио көн саен совет солдатларының тиңдәшсез батырлыгы хакында сөйли. Ул каһарманнар арасында татар егетләренең исемнәре дә еш телгә алына. Ә Мотаһир кемнән ким? Әллә ул сугыша белмиме? Ул бит өч ел хәрби хезмәттә булган кеше, аның бөтен

нечкәлекләрен өйрәнгән кеше. Димәк, аның урыны — яу кыры. Әйе, фәкать яу кыры. Егет күрке яуда сынала, дип юкка гына әйтмәгән бит халык. Әмма... Мотаһир яу кырында үзенең ватанга тугрылыклы кеше икәнен, халык дошманы түгеллеген җаны-тәне белән исбат итә алмый. Көнбатыштан ябырылган кара болытка күкрәген калкан итеп куеп, иленҗирен һәм сөекле нарасыйларын фашист баскыннарыннан саклый алмый. Әллә тагын язып карарга мы фронтка җибәрүләрен сорап? Тегесенә җавап килмәде бит. Күрәсең, илкәйне саклап калу өчен Мотаһир кебекләр кирәкмидер... Ә бит сугыш зәхмәте һәркемгә тигез кагыла. Тоткындагы кешеләр, ихтимал моны ныграк та сизәләрдер әле...



## XXI

Мотаһир лагерь тормышына да ияләнгән, дөресрәге, җайлашкан, бирелгән паек белән җан асрый, каты бәрелеп кыерсытучы да юк шикелле.

Шулай да беркөнне, үзе дә сизмәстән һәм теләмәстән, Золотилов аңа беренче карашка әллә ни әһәмиятле булмаган сүз әйтте. Моннан берничә чакрымда поселок бар иде. Анда да стационар эшли. Доктор Золотилов еш кына поселокка барып кайта, кул астындагы медицина хезмәткәрләренең эшен тикшерә, киңәшләрен бирә, авыру тоткыннарны карый. Чөнки аңа көнлек пропуск алып, чыгып йөрергә рөхсәт ителә иде. Бу юлы, рөхсәт юнәтеп, Мотаһирны да үзе белән иярттe.

Барышлый ул берзаман ягымлы гына сорап куйды:

— Иптәш Нәбиуллин, мин синең фамилияңне беләм, ә исем-отчествоң ничек?

— Бездә әти исеме белән әйтмиләр. Исемем — Мотаһир.

Золотилов аның исемен бер-ике мәртәбә кабатлады да, елмаеп, баш чайкады.

— Әйтергә бик читен икән. Әгәр Михаил дип әйтсәк?

Мотаһир ризалык белән җавап кайтарды.

— Ярар соң...

— Отчество... Иванович дисәк?

— Әйтегез.

— Ә минем Валериан Иванович икәнне беләсең инде. Болай отчество ягыннан адашлар да булырбыз.

— Әйе...

Бу турыда сүз шуның белән бетте. Барып җиткәч, эшкә күчтеләр: авырулар, аларны дәвалау, медицина кирәк-яраклары, дарулар...

Алар кайтырга җыенгач кына аягына балта белән чапкан бер авыруны китерделәр. Ә Мотаһирның пропускада күрсәтелгән вакыты аз калган иде инде. Шуңа күрә Золотилов:

— Син кайта тор, — диде.

Мотаһир, байтак юл үткәч, доктор белән булган сөйләшүне исенә төшерде. Һәм ул үзен нидер югалткан кешедәй тойды. Барган җиреннән туктап ук калды. «Бәй, ничек була соң инде бу? Минем хәзер исемем бүтәнмени? Мулла кушкан, атам-анам биргән, ничәмә-ничә еллар дусларымның, туганнарымның, Мөсәмирәмнең күңеленә ятышлы исемем юкмыни? Фамилиямне алыштырулары гына җитмәгәнме? Мин кем соң? Кем?!»

Бу якларда яз соң килә. Май аенда гына су китә. Әмма ташулар гаҗәеп көчле. Бездәге кебек яз хәбәрчеләре — сыерчыклар күп, аю да йокысыннан уянып чыга. Шуңа күрә Мотаһир биек агачлар яныннан, ургып аккан су буйлап сукмактан барганда әледән-әле урман яңгыратып кычкырып җибәрә:

— Һә-һә-һәй!

Шулай итсәң, аюга тарымыйсың. Әле дә ярый бүре юк бу тирәдә. Май аенда чемченер нәрсә дә аз: узган елдан калган мүк җиләге очраса гына инде. Ләкин бүген аның кайгысы түгел.

Бара-бара да Мотаһир тагын урман яңгыратып сөрән сала:

— Һә-һәй-һәй!

Тик хәзер ул моны аю качырыр өчен түгел, ә йөрәгенә укмашкан канны таратыр өчен, бөтен дөньясына булган ачуын башкача баса алмаган өчен, барлык рәнҗү-үпкәләрен тышка чыгарыр өчен җан көченә кычкыра, тилереп, шашынып берөзлексез сөрән сала:

— Һә-һә-һәй! Һә-һә-һә-ә-ә!..

Ичмаса урман-елгалар ишетсен аның эчендә ут булып янган хәсрәт авазын, ичмаса урман-таулар күрсен аның күзеннән бәреп чыккан ачы яшьләрне... «Йә, ходаем, никләргә мине бу хәсрәтләргә салдың? Кемнәргә ләгънәт укыйм бу кимсенүләрем өчен?! Үз исемем белән дәшүче дә юк бит миңа...»

Бара-бара да, Мотаһир уйлары белән янә Золотиловка әйләнеп кайта.

Золотиловны никадәр генә хөрмәт итсә дә, ул әйткән сүзнең асылына төшенгәч, җәберсенде, нигәдер аңа карата күңелендә рәнҗү хасил булды. Дөрес, Мотаһирны кимсетү теләге Золотиловның уенда булмагандыр. Ләкин, шуңа да карамастан, күңелдә моның юшкыны утырып калды.

Һәм икенче юлы Золотилов аңа, Михаил Иванович, дип дәшкәч, Мотаһир әүвәл аңышмый торды... Әмма докторның тавышындагы хөрмәт билгесен, якын иту хисе тойгач, аңа карата булган үпкәсе бетте, кинә сакламады. Бары ачы язмышына, кешенең тугач та бирелә торган һәм үлгәнче үзенеке булырга тиешле исемен дә югалттыра торган ачы язмышына булган үпкә хисләре генә калды.

## XXII

Тормыш, кайда, нинди шартларда гына узмасын, гел борчу-хафалардан гына тормый, сирәк кенә булса да юаныч тапкан чаклар да була. Болар — өйдән хат алу сәгатьләре. Меңләгән чакрым араларны үтеп, суына башлаган күңелләрне җылытып, изге хисләрне яңартып ике арада хатлар йөри. Ир белән хатын, ата белән бала, туганнары һәм авылдашлары арасын өзми торган нечкә, әмма чыдам җеп ул хатлар.

Кош теледәй ул хатларны Мотаһир сагынып көтә, сабый баладай шатланып кулына ала, күз нурларын тамыза-тамыза бер ялгызы гына укый. Кат-кат укый, сүзләрен ятлап бетерә хәтта. Ләкин укыган саен сөенеч кими бара. Ике төрле хис били башлый аны. Бер яктан — сөенү, икенче яктан, авылдагы хәлләрне белеп, көенү тойгысы били. Мөсәмирәнең җилкәсенә төшкән тау кадәр мәшәкатьләрне уйлап борчыла. Өендә эш, колхозда утау утап, урак урып иза чигә; әнә шуларга өстәп язгы пычракларда чабаталы аяк белән егерме-утыз чакрымнан ачлы-туклы килеш симәнә ташып чиләнүләрен күз алдына китерә.

Ә ул сөекле хатынының хәлен ничек җиңеләйтсен? Мәшәкатьләренең беразын гына үз иңенә салсын! Юк. Мөмкинлеге юк. Мотаһир үзенең якыннарына-гаиләсенә берни белән дә ярдәм итә алмавыннан гаҗиз. Шуннан аларны тагын да ныграк сагына, юксына башлый. Андый вакытларда Мотаһир уй-хисләренә бирелүчән, үз-үзенә йомылучан булып китә, йөзенә сары коела. Белми әйтмәгәннәр шул: «Кайгы ирне картайта, сагыш ирне саргайта».

Бер хатында Мөсәмирәсе әйтеп яздырган (чөнки хатны Мөсәмирә әзмәз русча сукалый торган бер күрше абзыйдан яздырта, татарча хатны кабул итмиләр бит) юллар бик озак күз алдыннан китмәде Мотаһирның: «Заем түләргә дип кәнсәләргә барган ием, ике йөз тәңкә акча. Шунда Гайдул районнан килгән кешегә: «Син аның иренең кайда икәнен сора», — диде. Ә беркөнне кече улыбыз әйтә: «Атаң кайтыр дип әйтәсең, моңынчы кайтыр иде инде. Юктыр ул». Ни әйтергә дә белмәдем...»

Мотаһир, хатынының хәлен күз алдына китереп, гаҗизләнеп елады. «Халык дошманы» — нинди авыр сүз, нинди яман нахак. Аның шаукымы

Мотаһирның үзенә генә түгел, хатынына, балаларына да тия. «Кайчан кайтып шул бичараларны юатырмын?! Ничә еллар бит инде...»

Кисәк кенә Мотаһир бүген нинди көн, кайсы ай һәм ничәнче ел икәнен исенә төшерде дә, аһ итте: аны алып киткәннәренә биш ел ярым тулган түгелме соң? Аның үзенә ничә яшь соң? Утыз җидеме? Әйе шул. Йә, хода, ул әле утыз җиде яшьтә генә икән бит. Әмма үзен алтмыштагы карт кебек хис итә, тәне генә түгел, аның рухы да картаеп таушалды, ул күзгә күренеп олыгайды, килеш-килбәтендә һәм йөрешендә генә түгел, уйлавы-фикерләвендә дә бу бик нык чагыла башлады. Бәхетле тормыш, сөен...ләр генә яшәртә кешене. Ә аның ни шатлыгы, ни куанычы бар? Юк, берние дә юк. Әз генә шатлык килсә, аңа хәсрәт өстәлә. Тимерне ашаган тутык кебек, йөрәген ачы сагыш кимерә. Нишләргә? Фәкать бер генә юл кала — көтәргә! Бары шул өмет бар — карурман, чытырманлык артында һичшиксез якты алан, түгәрәк мәйдан булган кебек, үзенә дәшеп, тартып тора торган кайтып күрешү шатлыгы бар. Түзәргә, сабыр итәргә, көтәргә генә кирәк...

Әле, бәлкем, сугыш бетеп, амнистия булмасмы? Быел гел өметле хәбәрләр бирә радио: Ленинград блокадасы өзелгән, Сталинград янында Паулюс армиясе әсир төшкән. Үзе кулына корал тотып сугышмаса да, Мотаһирның горурланырга хакы бар: ир туганнарының барысы да фронтта. Бер энесе хәбәрсез дә югалган икән. Анысы тагын ни белән бетәр? Исәнме, юкмы?.. Телгәләнә, өзгәләнә шулай ярсу йөрәге... Кая барып сугылырга белмичә талпынган, оясыннан аерылган кош кебек...

Өч айга бер килгән хатның да кайчагында кайбер юллары сызылган була. Әлбәттә, аны НКВД аша үткәрәләр. Моннан киткәнне дә карап-тикшереп озаталар, билгеле. Мотаһир хатны яза, конвертка сала һәм илтеп өстәлгә куя. КВЧ* начальнигы, ялланып эшләүче ирекле кеше, үзе ябыштырып җибәрә. Өйдән килгәнне дә ачып карыйлар. Кыскасы, икеләтә тикшерү уза бер гөнаһсыз хатлар.

Бу хатны да, гадәтенчә, күрше абзый русча язган. «Вам передает поклон ваша жена. Живет хорошо...— дип шактый дәвам иткән дә, авыл хәлләренә күчкән.— Дядя Сөфәк пришел с войны. Одна нога оторвал. На два месяц три человек ранин пришел. Пять человек умирал, сообщение пришел. Что уж написано, господи...» Хат ахырына ул хатны кем язганын да әйткән. Ләкин бу хатның уртасында сызылган юл бар иде. Мотаһир озак баш ватты, тегеләй әйләндерде, болай борды, яктыга да куеп карады, әмма ничек кенә кыландырса да укый алмады. Нәрсә сыздылар икән? Шул тынгы бирмәде, кызыксыну артканнан арта-барды. Кара каләм белән язылган хат юллары өстеннән шәмәхә белән йөрткәннәр. Ни булса — шул булыр дип, Мотаһир врач янына керде.

Ул кесәсеннән хат чыгарды да сызылган урынын күрсәтте.

— Доктор Золотилов, әйт әле, зинһар, бу хатны ничек укырга?

Үзе куркып та калды. Врач хатны алып бер генә күз салды да иясенә кире бирде.

— Әй, бу бик гади нәрсә,— диде ул исе китмичә.— Мамык ал, нашатыр спиртенә ман һәм... укы.

Мотаһир шулай итте дә. Ә хатта мондый сүзләр язылган иде: «Халык бик күп үлә, нindидер авыру бар».

Мотаһир соңыннан белде: безнең якларда септик ангина белән кеше бик күп кырылган икән.

Ә бер вакыт Мотаһир хат алган саен, хатың юк, дигән юллар укый башлады. Аптырый калды. Ничек инде? Ул яза бит, гадәттәгечә җибәрә дә. Ни-нәрсә булган? Шуннан Мотаһир тагын Золотилов катына барды. Хәлне аңлатты.

Доктор аңа тагын төпле киңәш бирде:

— Ә син, Михаил Иванович, акча сал.

---

КВЧ* — (культурно-воспитательная часть) — мәдәни тәрбия бүлеге.

— Һмм. Ничек?

Чыннан да, ничек? Каян алып? Кем аша салырга? Хәер, Мотаһир, хуҗалыкта хезмәт күрсәтүче сыйфатында эшләүче буларак, аена утыз сум акча ала иде. Урман кисүчеләрнең, сал агызучыларның түләү эш башыннан, тиешле хезмәт хакы исәп-хисап кенәгәсенә языла, кулга акча бирелми. Әгәр кирәк икән, гариза язып кына алалар. Бу яктан Мотаһирның хәле җиңелрәк иде. Ләкин акчасы бик бәләкәй. Ә Золотилов аена алтмыш сум ала иде. Күрәсең, Золотилов, шуларны уйлап, кесәсеннән акча чыгарды. Ни әйтергә белмичә, ияген сыпырып торган Мотаһирга санап җитмеш сум акча бирде.

— Мә, Михаил Иванович.

Мотаһир катгый рәвештә баш тартты.

— Юк, Валериан Иванович, мин моны алалмыйм. Мин аны сезгә тиз генә кайтарып бирә алмыйм лабаса.

— Ал,— диде Золотилов кырыс кына.— Әҗәткә түгел.

Алса да читен, алмаса да җайсыз. Менә шундый ике ут арасында дигәндәй калды Мотаһир. Ахырда, рәхмәтләр укып, акчаны алды.

Золотилов яныннан чыккач, ничек җибәрергә белмичә баш ватты. Ахырда, уйлана торгач, җаен тапты шикелле. Чөнки поселокта аның бер танышы бар иде.

Бу болай булды. Чумбаров фамилияле тоткын бик бетереште. Мотаһир Золотиловка әйтте бер көнне:

— Чумбаров бик хәлсез. Нишләтим?

Золотилов — тәвәккәл кеше, ике уйлап тормады.

— Син аны нәрәтчиккә әйт тә, кухняга билгеләт.

Шулай итте Мотаһир. Чумбаров кухняда эшләде. Срогы бетеп котылгач, ул өенә кайтмады (гәрчә Архангельск өлкәсе кешесе булса да), поселоктагы бер хатынга йортка кереп калды. Шуннан файдаланып, Мотаһир аңа серен чишәргә булды. Ләкин акчаны хатыныннан җибәрттерү кулайрак иде.

Бу якларда җәйге төн бик кыска була. Кояш әз генә батып, әйләнеп кенә чыга. Июнь — август айлары — ак төннәр. Әйе, өч ай дәвам итә бу озын көннәр. Шуңа күрә, барасы җиреңә иртән иртүк тә, кич соң гына да барырга була. Ләкин Мотаһирның, тоткындагы кешенең, алай иркенләп йөрергә мөмкинлеге юк. Тагын шул әлеге дә баягы рәхимле бәндәгә — Золотиловка йөз суын түгеп, барып егылды. Тегесе аңа берничә сәгатькә пропуск юллап бирде. Шуңа күрә Мотаһир көндез, урман аша тар гына юлдан үтеп, поселокка барып чыкты.

Башта ул бераз вакыт тимер юл буйлап барды. Аннары, уңга борылып, юл буенда стенадай утырган куе урман эченә кереп китте. Кирә-керешкә сумалалы карагачның бик тәмле исе борынына килеп бәрелде. Куе җирдә үскән төз, озын карагачның ботаклары юан, үзе наратка да, чыршыга да тартым ул. Һай бу урман! Мотаһирның башлары әйләнеп китә шушында керсә... «Ни кадәр байлык! Никадәр хәзинә!..» — дип уйлый Мотаһир һәм бераздан елга ярына килеп чыга. Иңе ике-өч адымнан артмаган тар һәм сай елганың суы чиста, балыкларына хәтле күренә. Мотаһир бу якларда хариус, бәртәс, чуртан, чабак, алабуга, ленок кебек балыклар булуын белә. Әлбәттә, болар барысы да иректәге кешеләр өчен. Ә аңа әнә шулай читтән кызыгып-сокланып барырга гына кала...

Урман бетте. Алда поселок күренде. Яр буенда чишмә, ахры, көянтәчиләк аскан бер хатын судан кайтып бара. Мотаһир кечкенә елга яры буена салынган мунчалар яныннан үтеп, киң урамга керде. Урамның ике ягында да зур-зур өйләр. Өйләрдән читтә — бүкәнгә утыртылган, җирдән күтәрелгән амбарлар.

Ихаталарга күз сала Мотаһир. Бакчаларда шомырт, миләш, балан, кура җиләге, карлыган кебек агачлар еш күренә. Сәрви һәм сирень дә бар, бу якларда алма белән чия генә юк икән. Өй тирәсендә, ишек алдында

яшелчә дә үстерәләр: бәрәңге, суган, сарымсак. Ләкин шунысы гаҗәп: түтәлләр ярым түгәрәк итеп өелгән, түтәл аралары тирән — су аксын өчен. Чөнки монда дым күп.

Урамда да, ихата тирәсендә дә кешеләр аз күренә. Халык эштәдер, ахрысы. Мотаһир бер карчыктан Маруся түтинең өен сорады.

Урамнан беразбаргач, Мотаһир Чумбаровлар өе янына килде. Ялтйолт каранып, капканы ачты да баскыч төбенә хәтле сузылган такта басмадан атлады. Өйгә кергәч:

— Исәнмесез,— диде тартынып кына.

Аш вакытына туры килгән икән. Өйгә таралган хуш истән — ризык исеннән аның башы әйләнеп китте. Борын тишекләрен киңәйтеп сулу алды. Шулай да моны сиздермәскә тырышты. Өй хуҗасы җәһәт кенә урыныннан торып, килеп күреште. Мотаһирны өстәл янына дәште.

— Уз, уз табынга! Маруся, безнең доктор бу,— дип җәмәгате белән таныштырды.

Хуҗа хатын, тулы гәүдәле булса да, йөгереп кенә дигәндәй агач бадьян, агач кашык алып килде. Өстәлдәге агач табактан борчак боткасы салып бирде. Каерып киселгән бер телем ипи дә куйды.

— Әйдә, житешегез, Миша.

Мотаһир ипине бер-ике капкач та нидән пешерелгәнен аңлады, шулай да мактый-мактый ашады.

— Бик тәмле.

— Әй,— диде хуҗа хатын офтанып,— әйтмәгез инде, элекке ипиләр юк хәзер. Ак мүкне киптереп, шуны төеп, онга кушабыз бит. Кая барасың...

Чумбаров хатынына:

— Маруся, синең бирәр нәрсәң юкмы анда? — дип ым какты.

Мотаһир моны аңлап алды.

— Юк, юк, Маруся түти, берүк кирәк түгел. Минем хәлне үзегез беләсез.

— Ярар, алайса ирексезләмим,— диде хуҗа.

Мотаһир, күп еллар шыксыз бараклан һәм сасы больницадан гайре нәрсә күрмәгән кеше буларак, рәхәтләнеп, ниндидер эчке бер җылылык тоеп, иркенләп утырды. Хуҗалар белән гәп корганда өй эчен дә күзәткәләде.

Өй чиста, иркен. Нарат бүрәнәдән салынган зур йорт. Бала-чага юк. Суккан палас өстендә, идәндә, дәү генә җирән песи йокымсырап ята. Өстәлдә самавыр гөжләп утыра. Түр почмакта — икона. Тәрәзә төбендә ниндидер ят гөл үсеп утыра. Искерәк кенә шкафта савыт-саба, ләкин артык бай түгел. Гомумән, өйдә артык байлык күзгә ташланмый. Шулай да бар булган кадәресеннән чисталык, пөхтәлек сизелә. Күрәсең, хуҗа хатын иренчәклердән түгел.

Кызгылт йөзе тулышып, гәүдәсе калынаеп киткән, кыяфәтендә олпатлык галәмәтләре чагыла башлаган Чумбаров әледән-әле Мотаһирны кыстады.

— Аша, аша,— диде ул һәм аның бадьянына кыздырылган хариус балыгы салды, яшел суганны да аңа табарак этәрде.

Мотаһир, билгеле, ялындырып тормады. Мүк җиләгеннән ясалган квасны да эчеп куйды. Өстәл өстенә коелган ипи валчыкларын җыеп капкач, рәхмәтләр укып йомышын әйтте:

— Маруся түти, менә бу акчаны шушы адрес белән җибәреп булмасмы?

— Ярар,— диде хатын артык төпченеп тормыйча.— Борчылма, Миша, эшләрмен.

Рухына гаилә җылысы алып, матур тойгылар белән кайтып китте Мотаһир бу өйдән. Күңелендә үз өен, үз гаиләсен сагыну хисләре кабат канат кагынды...

...Озакламый акчаның барып җитүе хакында хат та килде. Түбәсе күккә тиде Мотаһирның. Чөнки ул акча өчен хатыны куанганына сөенде. Аларга әз генә булса да кучтәнәч җибәрә алуына үзен бәхетле тойды. Хатыны исә акчага иренең исәнлеге турында хәбәр буларак сөенде.

Мотаһир бу эшнең уңышлы үтүе хакында Золотиловка да әйтте. Ләкин врач артык шатланмады, киресенчә, йөзенә борчу чыкты.

— Әле син ишетмәдеңмени?

— Нәрсәне? — диде Мотаһир аптырап.

— Поварны эләктергәннәр бит.

— Ни өчен?

— Үз паегын сатып, акча җыйган. Михаил Иванович, берүк сак бул, сирәк-мирәк пекарняга керәсең икән ипине аша, ләкин үзең белән алма. Акча белән дә сак бул.

«Гаҗәеп акыллы кеше бу, — дип уйлады Мотаһир Золотиловның арыган кыяфәтенә карап. — Ул булмаса, нишләр идем икән? Ә менә мин аның язмышын җиңеләйтү өчен берничек тә булыша алмыйм».

Хәер, Золотиловның үзенең дә кулыннан килерлек түгел ул. Котылып чыга алса, бәлки кайсы кая таратылган балаларын эзләп табар. Ә хатыны... аның каберен эзләсә генә инде.

Бу сөйләшүдән соң Мотаһир итәк җиңен тагын да ныграк җыеп йөри башлады.

Гомумән, зонада тәртип бик каты. Өч-дүрт көндә бер тентү булып тора. Матрацларны актарып бетерәләр. Кайчагында көне буе диярлек урамда сафка бастырып торгызалар. Әйбер чыкса, нар башындагы язудан тоткынның исем-фамилиясен һәм дело номерын язып алып чыгып китәләр. Аннан берәм-берәм чакырталар... Бервакыт идәнгә каныктылар. Аларның барагы җир идәнле, әзрәк ком сибелгән. Билгеле, салкын. Тоткыннар эштән такта кисәге чәлдереп кайталар да ике нар арасына кадаклыйлар. Чүкеч-кадак тавышы ишетелүгә, надзиратель кереп тә җитә, кубарып та ата. Тоткыннарда да этлек җитәрлек: икенче көнне тагын такта кисәкләре эләктереп кайталар...

## XXIII

Мотаһир үзенең эш бүлмәсендә — стационарда, түгәрәк пычкыга кулы киселгән бер авыруның ярасын бәйләү белән мәшгуль иде. Конторда идән юуучы, үзе дә бытовой статья белән утыручы, кирәк чакта посыльный хезмәтен дә башкаручы тоткын килеп керде. Ашыкканы күренеп тора.

— Сез Нәбиуллинмы? — дип сорады ул ишек төбендә туктап.

— Әйе, — диде Мотаһир бу яңа кешене танымыйчарак.

Посыльный, солдат кебек, һәр сүзен чатнатып, җиренә җиткезеп, йомышын әйтте:

— Сезне идарә начальнигы чакыра. Хәзер үк лагерь башлыгы кабинетына барыгыз.

— Яхшы.

Посыльный, ничек кергән булса, шулай җәһәт кенә чыгып та китте. Мотаһир аның артыннан чатыр чыгып йөгермәде. Ул эшен дәвам итте: авыруның кулын яхшылап чистартты, җәрәхәт тирәләренә йода сөртте, бинт белән бәйләде.

— Сызлыймы? — дип сорады ул йомшак кына.

Авыру тешен кысып, тезләрен тезгә тидереп, исән кулы белән урындыкка ябышып утыра иде. Ул, куырылып утырудан туктап, тәнен язды. Кулын ычкындырды.

— Әзрәк бар, — дип Мотаһирга карады.

— Түз, — диде Мотаһир аны юатып. — Озакка бармас, төзәлер.

Авыру урындыктан күтәрелде, рәхмәтле карашын табибка төбәп, җылы гына саубуллашты.

Мотаһир халатын салып, лагерь администрациясе йортына китте.

Ул кергәндә кабинетта аның хуҗасы, аннары Архангельскидан ук килгән лагерьлар идарәсе башлыгы, шушы лагерьның сак начальнигы һәм Мотаһирга таныш тагын берәү бар иде.

Мотаһир, ишек катында туктап, рапорт бирде:

— Гражданин начальник, сезнең чакыруыгыз буенча килдем.

— Син түгелме соң бу Нәбиуллин? — дип сорады әлеге таныш кеше Мотаһир рапорт бирү белән.

— Әйе, — диде тоткын тыйнак кына.

Воробей фамилияле бу адәм лагерьлар идарәсендә санитария бүлеге башлыгы иде.

— Ничә ел инде күрешмәгәнгә?

— Ике.

Идарә начальнигы, тулы гәүдәле, ике иякле, олы яшьләрдәге кеше, аптырап боларга карап торды.

Аннан:

— Сез танышлар икән... — диде.

Аның тавышында моңа шатлану яисә көенү дә чалынмады, бары факт буларак аны раслап кую гына сизелә иде.

Воробей кыскача гына танышлыкларының нидән гыйбарәт икәнен әйтеп үтте. Хәтта Мотаһирны мактап та куйды:

— Менә дигән белгеч ул.

Мотаһир боларны игътибар белән тыңласа да, санитария бүлеге начальнигының тел төбендә олы түрәгә ярарга тырышу да, бу бичара тоткынны яклау да күрмәде. Ул үзенең ни өчен чакырылуын белмәгәнгә күрә, аны билгесезлек борчый иде.

Воробейның Мотаһир хакында уңай яктан әйтелгән сүзләреннән идарә башлыгының бу тоткынга булган карашы йомшарды сыман.

— Утыр, — диде ул ишек катындагы урындыкка ымлап.

Билгеле, лагерь начальнигының да Мотаһирга булган мөнәсәбәте үзгәрде. Гәрчә ул моны моңарчы юньләп белмәсә дә, үзенең кул астында эшләгәч, һәм олы түрәләр дә ихтирам белән дәшкәч, ул гына каш җыерып утыра алмый бит инде. Моңа сәбәп тә юк әлегә.

Идарә башлыгы гражданский киемнән — кара бостон костюм, ак күлмәк, галстуктан иде, тез өстенә куйган таза кулын чалбарына суккалап, өстәлдәге катыргы тышлы делога караштырып, көр тавыш белән, сүз башлады. Башта аның исем-фамилиясен, каян булуын, милләтен сорады.

— Ә, нацмен алайса, — диде ул. — Кем хөкем итте?

— Белмим.

— Ничек?

— Мин берни дә белмим.

— Өеңдә кемнәр бар?

— Хатын, балалар...

Беразга гына тынлык булып алды. Идарә башлыгы әүвәл Воробейга, аннан соң сак начальнигына карап алды. Инде, канәгать булып, сүзен дәвам итү нияте белән хәтта бераз гәүдәсен авыштырып, авызын ачкан иде, бу уеннан кире кайтты. Аның карашы лагерь начальнигына төбәлде. Бу бары бер секунд эчендә булды. Алар бер-берен тиз аңлаштылар, ахры.

Түрә тагын тезенә шапылдатып сукты. Күрәсең, бу — мәсьәлә уңай хәл ителә, дигәнне аңлата иде.

— Аңа пропуск бирергә кирәк, — диде ул һәм Мотаһирга дәште. — Ярар, без сиңа пропуск бирәбез.

Мотаһир, шулхәтле киеренкелектән соң, алдын-артын уйламыйчарак, тиз генә сорау бирде:

— Аның белән нишләрмен?

— Пропуск белән йөрерсең.

Түрәләр үзара киңәшеп алдылар.

— Алтыга хәтле бирик.

— Әллә озаккаракмы?

— Юк. Унсигез сәгатькә хәтле җитәр.

Сүзгә санитария бүлеге начальнигы кушылды. Мотаһирга мөрәҗәгать итеп:

— Монда поселок бар,— диде ул.— Син шунда барырсың, Нәбиуллин.

Моннан берничә чакрымдагы әлеге авылны Мотаһир белә. Бервакыт Золотилов белән барып та кайткан иде бит. Сак начальнигы:

— Күрсәтелгән маршруттан бер адым да читкә китмисең,— дип кисәтте.

Шулай итеп, Мотаһир хәзер чагыштырмача ирекле тоткын.

Ләкин бервакыт ул күрсәтелгән вакыттан сәгать ярымга соңарып кайтты. Вахтада аны:

— Нигә соңга каласың? — дип җикеренеп каршыладылар.— Ничәгә хәтле пропускаң? Унсигез дә ноль-нольгә. Син эчке тәртип кагыйдәләренә буйсынмыйсың.

— Анда авырулар. Аларны калдырып китә алмадым,— дип акланды Мотаһир.

Барыбер бу хәл начальникка барып ирешге. Ә анысы, Мотаһирның бәхетенә каршы, пропускны төнге унга хәтле озайтты.

Мотаһир кышын поселокта эшләде. Ул иртән китә дә, кичен лагерьга әйләнеп кайта. Бармый калган чагы сирәк. Бары Золотилов укырга калдырган чакларда гына эшкә бармый иде. Анысы еш түгел, әллә нидә бер, ләкин даими рәвештә булып тора. Бу — квалификация күтәрү кебек әйбер. Золотилов аңа һәрвакыт медицина китаплары биреп тора, аннары имтихан шикелле нәрсә оештыра. Кыскасы, ул үзенең кул астындагы медицина хезмәткәрләренең үз эшләренең остасы булулары турында кайгырта иде. Бу — Мотаһир өчен олы бер мәктәп булды.

1944 елның язына чыккач, аны тагын лагерь башлыгына дәштеләр. Бу юлы да сөйләшү әлеге поселокка бәйле һәм Мотаһирның эш режимы хакында булды. Ләкин Архангельск түрәләре юк иде. Лагерь һәм сак начальниклары икәве генә бу мәсьәләне хәл иттеләр.

— Син пропуск белән йөрисеңме? — дип сорады лагерь башлыгы, гәрчә моны яхшы белсә дә.

— Әйе,— диде алар каршында басып торган Мотаһир.

— Утыр. Кайчанга хәтле?

Монысы да аңа мәгълүм, югыйсә. Шулай да тоткын сорауга төгәл җавап бирергә тиеш.

— Егерме ике сәгатькә хәтле.

— Сиңа шулай кулаймы?

— Юк.

— Нишләп?

Мотаһир һәрвакыт авыруларга уңайлы якны сайларга тырыша иде. Шушы хакта лагерь башлыгына турысын әйтүне кирәк тапты:

— Кайчагында минем арттан бик соң гына да киләләр. Ә мин авыруны ташлап китәргә мәҗбүрмен.

— Тәүлек буена бирикме соң?

— Бик әйбәт булыр иде.

Ике начальник бер-беренә карашып алды. Билгеле, алар моны тоткын кергәнче үк хәл итеп куйганнар иде инде. Ләкин үз күзләре белән аның моңа ничек каравын, бу хәбәрне ничек кабул итүен белү — икесе өчен дә мөһим, күрәсең. Ахыр чиктә, бу тоткын алар карамагында һәм аның ышанычлымы-юкмы икәнлеге өчен җавапны икәве бирәчәк.

Шулай итеп, Мотаһир тәүлекнең теләсә кайсы вакытында лагерьдан чыгып китә һәм кайтып керә ала иде. Авырулар өчен, һичшиксез, бу бермә-бер уңайлы, аның үзенә дә иректә булу әйбәт. Ләкин кайчак аңа коеп яуган яңгыр астында да чыгып китәргә туры килә шул. Әмма Мотаһир аңа карап кына барасы җиренә бармыйча калмый.

Дөрес, көзнең аяз вакытлары да була. Ул чагында урман да ягымлырак күренә. Гомумән, Мотаһирның туган ягындагы урманнардан, ул армия хезмәтен үткән Смоленск якларыннан да аермалы бу яклар.

Менә ул ат юлыннан урман эченә килеп керә. Кәрә-керешкә сагыз исе, хуш ис борынга килеп бәрелә. Урман үзе күбрәк чыршы-нараттан тора. Ә юлдан чыгып, агач арасыннан барсаң, аяк асты йомшак — тоташ яшел мүк. Кайвакыт утрау-утрау булып ак мүк күренә. Ул да яшькелт, ләкин аксыл-яшькелт. Мотаһирның башы әйләнеп китә, күзләрен йома, сукмакка чыга. Урман эче җиләс. Ә агачлар... аларның үтә юаннары да, нәзекләре дә, күтәрелеп карагач очы күренми торганнары да, тәбәнәкләре дә бар. Сирәк кенә каен да очрый. Агачлардан вак, яшел яфраклы тәбәнәк үлән өстенә, мүк өстенә күләгәләр сузылган. Ә кайвакыт юл буенда толотнянникка — аю колагына яисә көртмәлеккә, кызыл бөрлегән һәм саз җиләгенә тап буласың. Ә сазлык тирәсендә сазанак, күк җиләк, каражиләк өлгерә.

Дөрес, урман үз нигъмәтләрен алай җиңел генә бирергә теләми. Кигәвен, черки, мошкара — вак черки мыжгып тора. Кигәвене генә дә ничә төрле: карасу төстәгесе, саргылт, тагын бармак башы кадәр башка төрлесе. Арада иң нык тешли торганы — саргылт кигәвен, корт чакканнан ким итми! Ә мошкара — анысының кермәгән җире юк. Энә күзеннән үтә, каһәр.

Биек агачларда саргылт булып чыршы күркәсе асылынып тора. Куе яшел агачта аларны әллә каян шәйлисең. Әнә корып бара торган чыршы. Төсе аксыл, ботаклары салынкы. Әйләнә-тирәдәге ямь-яшел чыршылар арасында ул шат күңелле кешеләр уртасындагы боек адәмне хәтерләтә... Ул инде адәм балаларына бүтәнчә ярдәм итә алмаячагын уйлап моңсулана бугай.

Табигать бит һәр җирдә үз балаларын ачтан үтермәскә тырыша, таный-күрә белсәң, анда елның теләсә кайсы фасылында тамак ялгар нәрсә табыла. Паеклары ике йөз грамм сохарига калган тоткыннар өчен ни булса да ярый, сырланып-сайланып тормыйлар. Мотаһирның да ашамаган әйберсе калмады. Үзе генә ашап калмый, җай туры килсә, иптәшләренә дә өлеш чыгара. Әйтик, урманда беренче булып волнушка — йөнтәс гөмбә, аннары — ак гөмбә, кара һәм нарат җиләкләре кебек тәмле ризыклар күренгәли. Ә иң соңыннан мүк җиләге җитешә. Аның монсын ашханәдә дә бирәләр иде. Ашханә дигәннән, кызгылт төстәге тюлень итен, ап-ак акула, кып-кызыл морж итләрен дә сирәк кенә авыз итәргә туры килде.

Әмма болар гына хәлне үзгәртә алмый иде. Халык ачлыктан кырылып үлә башлады. Ә аларны врачлар, карап-тикшереп, мәңгелек йортларына озаталар.

Бервакыт Мотаһир, үлүчеләрне зиратка алып киткәндә, доктор Золотиловтан сорады:

— Валериан Иванович, әллә сез бөтен мәетләрне дә ярып карыйсыз инде?

Золотилов Мотаһирга өстән аска таба сөзеп карады, җилкәсен сикертеп алды.

— Юк. Бөтенесен дә түгел.

— Бөтенесен дә...

— Юк, дим бит.

— Алайса, нишләп соң?.. Әйдәгез әле күрсәтәм...

Золотилов Мотаһирга ияреп, мәетләр янына атлады. Ул аларны берәмберәм карагач, аптырап китте. Чыннан да, мәетләр барысы да ярылган иде. Доктор үзе ярган эзне яхшы таный. Менә кайберләре башкача ярылган. Болары — аның кулы түгел.

— Кем эше булыр бу? — диде Золотилов аптырап.

Мотаһирның кылт итеп исенә төште. Бервакыт, баракка кергәч, метрлы утын ягыла торган ике зур мичнең берсе янында тоткыннар кайнашуын

шәйләп алды ул. Аларның кулында чыбык очына киертелгән ит кисәкләре иде. Фельдшерны күргәч, уголовниклар аңа арка белән борылдылар, берсе ит кисәген тиз генә авызына капты, икенчесе учына яшерде.

Ишек катындагы нарда утырган өченче амбал, авызын сөрткәләп урыныннан күтәрелде дә, җыр көйли-көйли, ялкау адымнар белән Мотаһирга якынлашты:

— Раз ку-ку, два ку-ку, һоп в муку. Сам в муке, нос в муке, а рука в кислом молоке. Шулай бит, доктор?

Сагая калган Мотаһир дәшмәгәч, ул кисәк кенә бармак белән аның эченә төртте.

— Син безне күрмәдең! — дип кисәтте ул. — Син бернәрсә дә белмисең! Шулай бит?! Ни а, ни б, ни ку-ка-ре-ку...

Ул вакытта Мотаһир алар кулында мәет эченнән ярып алынган әгъзалардыр дип уена да китермәгән иде, бака яисә бүтән нәрсәдер, дип уйлаган иде.

Золотилов бер-ике мәетнең күкрәк читлеген аерып карады, башын чайкап, уфтанып әйтте:

— Менә ачлык нишләтә...

Золотилов хаклы иде. Халык чебен урынына кырыла. «Безнең өчен алар хәзер мәет кенә, — дип уйлады Мотаһир җансыз гәүдәләргә карап. — Ә туганнары өчен — газиз бала, сөекле ата, гомерлек яр... Күпме ботарланган язмышлар. Кем моңа җавап бирер?!»

Ашамаган нәрсәсе калмады тоткыннарның. Лагерьда эш шуңа барып җитте ки, хәтта тере кешегә үк ябыштылар.

Лагерьга яңа гына этап белән килгән бер үсмер егет — уголовник югалды. Тикшерү-барлау вакытында карыйлар — кеше тулмый. Моңарчы күрелмәгән катылык белән җентекләп тенту-тикшерү башланды. Лагерьның астын-өскә китерделәр, бөтен җирне актардылар. Монда НКВД кешесе дә, икенче һәм өченче бүлек начальниклары да, прокурор белән судья да — барлык тармаклар хәрәкәткә килде.

Ниләр генә чыкмады тенту вакытында. Берәүдән хәтта пычкы да табып алдылар. Ул фуражка әйләнәсенә тар фин пычкысы тыгып алып кайткан икән. Тентүдә фуражкасын кулына тотты да:

— Менә, карагыз, — дип кулларын югары күтәрде.

Кайсыдыр берсе ялгыш кына кепкасына кагылмаса, бәлки шул килеш узган да булыр иде...

Шулай да, эзли торгач, таптылар бичара үсмернең мәетен. Уголовникларга кышлык өчен корылган йорт-баракның чарлагыннан килеп чыкты. Золотилов белән Мотаһирны дәшеп китергәндә, мәрхүмне түбәдән төшергәннәр иде инде.

Золотилов иелеп, аның муен тирәләрен капшаштырды.

— Бәрелгән-сугылган җире юк. Баш сөяге исән, — диде. — Аны буып үтергәннәр.

Лагерь начальнигы үсмернең муенында калган бармак эзләрен күрде. Аннары:

— Киемен салдырыгыз, — дип боерды.

Мәетнең өстеннән күлмәген һәм чалбарын салдырдылар.

— Әйләндерегез.

Мәрхүмне йөзтүбән каплагач, якын-тирәдәге бөтен кеше аһ итте: аның ике утракса бите кисеп алынган иде...

Башланды тикшерү-сорашу... Бу эштә катнашы булырдай шикле унике кешене изоляторга яптылар. Ләкин эш судка барып җиткәнче алар үлеп котылды.

...Мотаһир доктор Золотилов бүлмәсендә утыра. Ул, элеге хәлләргә ялгап, үзенең балалык вакытын искә алды.

— Валериан Иванович, мин егерме беренче елгы ачлыкны хәтерлим. Ул чакта хәер сорашып йөрүчеләр күп иде. Күрше авылда бер саилченең урам башындагы өйгә кереп киткәнен күргәннәр, ә чыкканын юк.

— Булгандыр, Михаил Иванович,— дип авыр сулап куйды Золотилов,— ышанам. Тарихта әллә нинди вәхшәтле хәлләр турында мәгълүматлар бар.

— Әйе, тамак тәмугка кертер, диләр бездә. Егерме бердә бигрәк әшәке булды шул. Соңга табарак Америкадан килгән он өләшкәнне яхшы хәтерлим. Анда кием-салым да бар иде әле: ботинка, оекбашлар...

Доктор Золотилов үзенең дөньяви карашы, тормыш тәҗрибәсе, гомумән, аң-белеме ягыннан да гади авыл кешесе булган Мотаһирдан күп өстен иде. Тыштан тыныч күренергә тырышса да, лагерьдагы вәхшилек мисаллары аны тетрәндерде. Кеше, гомумән алганда, дөньяда берданбер илаһи аңлы, миллион еллар дәвамында бер генә мәртәбә туа торган хикмәтле җан иясе. Әле үтерелгән үсмер дә кем булмас иде дә, дөньяга нинди игелекләр китермәс иде. Әлбәттә, тиешле тәрбия булганда. Аннары, табигать баласы буларак та, һәр җан иясе яшәргә хаклы. Инде тагын башка яктан килсәк, әйтик, социалистик дәүләтнең, дөньяда тиңе булмаган яңача дәүләтнең, шәхеснең үсүенә бөтен мөмкинлекләрне бирәчәк дип лаф орган җәмгыятьнең шул үсмерне юк кына гаеп өчен лагерьга озатуы (аны гына түгел, меңнәрне) — үзе үк вәхшилек түгелме соң?! Менә Золотилов шуларның очына чыга алмый. Меңләгән кешеләрнең «халык дошманы»на әверелүе — бу акылга сыймаслык хәл. Ярар, унга-йөзгә берәү шпион, диверсант та булсын, ди. Чыннан да, дәүләткә куркыныч кеше, зыян китерү ихтималы булган кеше сыйфатында җәмгыятьтән аерып, ябылырга тиеш, ди. Ә меңләгән, йөз меңләгән кеше (хәзер Золотилов аның масштабын да чамалый, бары әйтергә генә курка) ни өчен мондый хәлгә дучар ителергә тиеш?!

Золотилов Мотаһир белән гәпләшеп утырса да, әңгәмәнең очын югалтмаса да, аңа әйткән сүзләрдән башкачарак фикер йөртә. Чөнки ул үзе, горурланып, Питер кешесе, ди, димәк, гыйлем иясе, зыялы затлар шәһәреннән. Аң ирешмәслек хәлләрдән, каты сәке-нарда йокысыз үткәргән төннәрдән аның башы чатный, зиһене чуала.

Хәер, бер аның гына микән...

Уйлана торгач, Золотилов тагын бер коточкыч ачыш ясады: илле сигезенче статья белән хөкем ителгәннәрнең күбесе гади эшче яки крестьян түгел, алар — илнең аң, акыл дәрәҗәсен үстерүче, аның көч-куәтен арттырырга сәләтле кешеләр. Моны ничек аңларга?! Ни өчен һәр милләтнең иң укымышлы, алдынгы карашлы, аның каймагы булган асыл затлары юкка чыгарыла?!...

## XXIV

Кыш көне Мотаһирга тагын бер вазифа йөкләнде: ул көн саен күрше авылдагы НКВД фермасына барып, егерме литр сөт алып кайтырга тиеш иде.

Ни өчен Мотаһир дигәндә, элек бу эшкә билгеләнгән тоткын беркөнне гөнаһлы булды. Гадәттә, сөт бидоннарына пломба салына. Ә бу юлы берсенең пломбасы өзелгән була.

— Нишләп пломба ачык?— дип сорыйлар моннан.

— Егылдым,— ди тоткын.

Бидонны ачып карыйлар: сөт кимегән.

— Аңлашыла...

Һәм шуннан сөт ташырга Мотаһирны куйдылар.

Фермада көнкүреш статьясы белән эләккән шушы як кешеләре — берничә ир-ат эшли иде. Хатын-кызлар исә иректә хезмәткәрләр. Алты-җиде хатын сыер сава, сыерлары да күп түгел — кырык-илле тирәседер.

Мотаһир фермага ике буш бидон күтәреп килә. Аларга сөт тутыралар һәм пломба салалар. Шуннан... ач тоткын, гәрчә иңендә аллы-артлы аскан

егерме литр сөт булса да, көч-хәл белән аны тиешле урынга — ашханәгә кайтарып җиткерә.

Бер килүендә, сыер савучыларның өлкәне, Клавдия атлы хатын, аңа сынап карады да:

— Миша (аңа монда шулай дәшәләр иде), син бөтенләйгә кайчан чыгасың инде? — дип сорады.

— Күп әле, — диде Мотаһир уйчан гына.

Шунда икенче хатын сүзгә кушылды.

— Ә азат булгач кая барасың?

— Өйгә кайтам.

— Ә нигә монда гына калмыйсың? — диде Клавдия елмаеп. — Әнә Авдотья синнән күзен алмый.

— Алайса — калам, — диде Мотаһир да сүзне уенга алып. — Гаиләмне дә чакыртам.

— Ике хатын белән торасыңмыни?

— Әйе. Безгә шәригать рөхсәт итә. Элек өч-дүрт белән дә торганнар.

— Акылың алтын икән, — диде Авдотья чытлыкланып.

Клавдиянең йөзе җитдиләнде.

— Юк, Миша, син андыйга охшамаган, — диде ул һәм Мотаһирны бер читкәрәк алып китте дә, бишмәт кесәсеннән нидер алып, аның учына төртте.

— Мишенька, бигрәк хәлсез күренәсең, әзрәк капкала.

Мотаһир бу кара әйбернең ни икәнен аңламаса да, ашарга ярый торган нәрсә икәненә төшенде.

— Рәхмәт.

— Сак бул, Мишенька, — диде хатын өтәләнеп, — охран очраса, ташла. Мишенька, сак бул, юкса безне дә харап итәрсең.

Эш шунда: сыерларга көнбагыш түбе кайта икән. Ул бер кул яссуы хәтле кисәктән гыйбарәт. Шуның яртысын Клавдия Мотаһирга бирде. Ул учка сыеп бетәрлек, шырпы кабыннан чак кына зуррак иде.

Ферма күздән югалып, урман эченнән атлаганда, Мотаһир әлеге «күчтәнәч»не караштырды. Кара-көксел төстә икән. Кабып карады. Майлы, үзе тәмле. Әкрен генә, кайта-кайтышка Мотаһир аны конфет урынына суырып ашап та бетерде.

Урман — һәрчак серле дөнья. Монда бигрәк тә. Гомер буе кеше аяк басмаган озын-озын чыршы, карагачлар янында син үзеңне кечерәеп калгандай хис итәсең. Монда урман җәнлек-кошларга да күпкә бай: көртлек, суер, аю... Ләкин аю итләре тоткыннарга түгел, түрәләргә эләгә. Аларга, узган атнадагы кебек, әзрәк поши калҗасы да ярап торыр иде әле.

Бераздан әкрен генә җепшек, йомшак кар ява башлады. Мотаһир аланлык шикеллерәк җиргә килеп чыкты. Аның әйләнә-тирәсендә вак чыршы, наратлар. Алар тын гына утыралар. Ботакларын кар сарган. Гүя, кул чәбәкләргә җыенып утыручы ак куян, аю балалары инде. Менә тагын бер мизгел... һәм алар бөтерелеп, түгәрәк әйләнеп уйный башлар төсле. Алар арасында Мотаһирның малайлары да бар: әнә олысы, ә аның янәшәсендә — кечесе. Мотаһир, гомерендә бер мәртәбә күрмәсә дә, кечесе турында да гел уйлана, аны күзалларга тырыша. Әлбәттә, ул аларны шат, бәхетле итеп күрергә тели... Табигать! Син һәр җирдә матур! Синдә яшәүче кешеләр дә матур! Һәм алар бәхетле булырга тиеш!

Мотаһир, йөген бер иңеннән икенчесенә авыштырып, карлы юлдан шыгырт-шыгырт атлавын дәвам итә. Уйлана, илен-җирен, туган-тумачасын сагына. Ә кайчагында, үзе дә сизмәстән, сәясәткә кереп китә. Аның күз алдына авыр эштә эшләүче акыл ияләре, стационарда тезелешеп киткән койкалар пәйда була... Койкалар үзгәрешсез кала бирә, ә авырулар алмашынып тора. Этап килә. Тагын йөзләгән кеше лагерь өрәкләренә әйләнә, аларның яртысы кырылуга тагын этап... Әйтерсең, алар — әсир төшкән дошман солдатлары, үлемгә дучар ителгәннәр. Хәер, әсирләр белән дә болай кыланмыйлар...

Дошман дигәннән, 1944 ел бераз җиңеллек китерде: икенче фронт ачылды, Америкадан сөт һәм йомырка порошогы килә башлады, киертылган сөт күренгәләде. Ит булмаса да, балык житәрлек иде. Фронтта да хәлләр сөенечле: Выборг, Петразаводск азат ителде...

Уйларына чумып кайткан Мотаһир, каршысында кинәт пәйда булган усал карашлы ике кешене күреп, аптырап калды, шып туктады, чүгеп куйды. Кисәк кенә артка омтылмакчы булып, әйләнеп караса... анда да кашларын җыерган тагын берәү басып тора. Киемнәренә, төк баскан чырайларына караганда, болар кайсыдыр лагерьдан качкан тоткыннар, мөгаен. Мотаһирның кулы ирексездән түшендәге бидонга таба күтәрелде.

Кулына пычак тоткан әзмәвер бидоннарга төртеп:

— Анда нәрсә? — дип сорады.

— Сөт, — дип дөресен әйтте Мотаһир.

— Җиргә куй! — диде әзмәвер, ә үзе уңга-сулга каранды.

Мотаһир аллы-артлы аскан йөген янтаеп иңеннән төшергәндә арттагы бәндә аның муен тамырына китереп сукты. Мотаһир аяк астындагы бидон өстенә капланды. Исенә килеп өлгергәнче, каршыдагы тәбәнәк гәүдәле икенче бандит аның эченә типте. Кар өстендә ыңгырашып яткан Мотаһирны калдырып, икәве пломба чыбыкларын шатыр-шотыр кубардылар да, бидоннарны ике куллап югары күтәреп, агыза-агыза, йотлыгып, сөт чөмерә башладылар.

Мотаһир көч-хәл белән торды.

— Нишлисез сез?! Миңа бит карцер моның өчен!

— Замри, сука! — диде Мотаһирдан күзен алмаган пычаклысы. — Яшисең киләме?

— ...

— То-то.

Тегеләре, бидоннарның капкачларын ябып, сукмакка куйдылар. Пычаклысы, авызыннан агып төшкән ап-ак сөтне җиңе белән сыпырды да:

— Нәрсә, расходкамы? — дип иптәшләренә карады.

Тәбәнәк гәүдәле каршы төште.

— Нигә әрәм итәргә? Кирәге чыгар. Ябык булса да бераз ите бардыр.

Пычаклы:

— Дөрес әйтәсең, — диде. — Үзебез белән алыйк. Әйдә, атла! Бидоннарны да үзең күтәрерсең.

Шунда өченчесе, кашларын тагы да җыера төшеп, Мотаһирга текәлеп карады да шаркылдап көлеп җибәрде.

— Ба, Михаил Иванович, ә мин сине танымадым! Фраерлар, бу бит безнең фельдшер. Билләһи, менә очрашу! Син мине танымадыңмы, Михаил Иванович?

Бу халыктан иман көтмәгәнгә, Мотаһир андый чакта ничегрәк эш итәргә, нәрсә әйтергә кирәген белә иде инде.

— Юк, — диде ул тегеңә туры карап. — Мин сезне беренче тапкыр күрәм.

— Неужели? Син мине дәваладың бит. Кабердән тартып чыгардың. Үлгәнче онытасым юк, Михаил Иванович.

— Хакмы бу? — дип сорады тәбәнәк буйлысы.

— Век свободы не видать! — дип ант итте Мотаһирны таныганы. — Этот — свой в доску!

Пычаклы качкын:

— Алмыйкмыни? — дип сорады.

Мотаһирның лагерьдашы:

— Юньлерәк нәрсә очрар әле, — диде. — Хай живе. Алар халкы болай да нужаны күп күргән.

Ул Мотаһирдан бу юлның кая илтүен, әйләнә-тирәдә ни-нәрсә барын сораштырды. Күрәсең, болар адашканнар иде.

Белгәннәрен әйткәч, Мотаһирның эченә җылы керде. Ул:

— Бер бидонны гына булса да бирегез,— дип аны таныган качкынга ялварды.

Пычаклы әзмәвернең күзләре зәһәр ялтырады.

— Нәрсә? — дип кайтарып сорады ул һәм тәбәнәк гәүдәле качкынга баш какты:— Кореш, бир шуңа!

Мотаһирның ике каш арасына йодрык килеп төште. Ул, йөзен каплап, чалкан ауды.

Ә торып басканда качкыннар да, сөт бидоннары да юк иде инде. Ике күзен кан басканга гына түгел, сөтсез кайткан өчен лагерьда аны ни көтәсен уйлап, аның күз аллары караңгыланды...

## XXV

Мотаһир үзенең эш бүлмәсендә, авыруларга эчертү өчен, ылыс төнәтмәсе әзерли иде. Ул, ваклап, ун литрлы шешәгә ылыс тутырды, кайнар су салды. «Ике-өч көн торсын»,— дип шешәне идәнгә куйды. Шулчак ишектә бер тоткын пәйда булды.

Ул әкрен генә керде дә, исәнләшеп, туктап калды.

Мотаһир аны шундук таныды. Моннан ун көн элек, этап килгәч, ул бу кешене чамалап калган иде. Чөнки аның фамилиясе Илтазаров. Мотаһир аны эзләп йөрмәде, фәкать хәтеренә сеңдереп кенә калды. Чөнки белә: иртәме-соңмы, һәр тоткын амбулатор кабул итүгә киләчәк, табибларга мөрәҗәгать итәчәк. Ә Илтазаров беренче күргәндә үк бераз аксый иде инде.

— Утыр,— диде Мотаһир йомшак кына.

Ул Илтазаровны тануын да, фамилиясенә караганда милләттәше булырга тиешлеген дә һәм шуңа бәйле рәвештә күңелендә туган якын итү хисләрен дә белгертмәде. Аның йөзе тыныч, үз-үзен тотышы гадәти — җитди һәм игътибарлы иде.

— Кай җирең авырта?

— Минә аяклар шеште.

Мотаһир юка гәүдәле, тәбәнәк буйлы Илтазаровка текәп карады. Аксыл чырай, чыгынкы яңаклар аның хәлен әйтеп тора иде. Җитмәсә, аяклары...

— Чалбар балагыңны күтәр.

Мотаһир аның шешкән аякларына бармак бите белән басып-басып карады. Баскан җир батып кала иде. «Безбелковый отек икән монда,— дип уйлады Мотаһир башын чайкап.— Ачлык галәмәте». Аннары ул авыруны бастырды, янә утыртты. Аның йөрәген, үпкәсен тыңлады. Үзе дә өстәл артына барып утырды. Илтазаровның кан басымын тикшерде. Кулына каләм алды.

— Фамилияң ничек?

Авыру фамилиясен әйткәч, Мотаһир тагын берничә сорау бирде, кирәкле мәгълүматларны язып куйды.

— Алай икән. Яхшы,— диде Мотаһир сузыбрак һәм кисәк кенә татарчага күчте:— Син кай яклардан?

Тоткын башта югалып калды, аңышмыйча торды. Чөнки озак вакытлар туган телен ишетмәгән кеше мондый чакта, гадәттә, аптырап калучан була.

Башын иеп, җилкәләрен салындырып, мескен кыяфәттә утырган Илтазаров кисәк кенә турайды, калкынып куйды, күзләрен зур ачып, Мотаһирга карады. Ирен читләре җәелеп китте, сөенеп, ул җәһәт кенә:

— Татарстаннан,— диде.— Син дә татармыни? Мин монда татарлар юк дип торам.

— Әрекмән белән кычыткан үскән һәр җирдә татар бар,—диде Мотаһир авыр көрсенеп.— Безне язмыш шулай тараткан инде. Кайсы районнан?

— Әлмәттән.
— Бездән ерак түгел икән...
Моны ишеткәч, токтынның күзләре очкынланды, йөзе нурланды, якын туганын күргәндәй Мотаһирга йотылып карады. Ул аякларын, кулларын кыймылдатып алды, уң кулын әле өстәлгә куйды, әле тезенә төшерде, бөтен гәүдәсе хәрәкәткә килде. Батыраеп, үзе дә сорауга күчте:
— Ә син каян?
— Коры Елгадан.
— Шулаймыни?
— Әйе.
Илтазаров көлеп җибәрде.
— Ә мин сине «тавык тәпие» таккан дип торам. Урысча әйбәт сөйләшәсең.
— Монда кемгә дә әйләнерсең,— диде Мотаһир уйчан гына һәм янә сораштыруга күчте:— Күптәннән авырыйсыңмы?
— Байтактан. Килә потлап, китә мыскаллап, дигәндәй, чир бер эләктерсә,-тиз генә ычкындырмый, каһәр. Монда бигрәк тә.
— Нәрсә, эшли алмыйсыңмыни?
— Юк шул.
— Ярар, яткырырмын. Кичә бер урын бушаган иде.
— Рәхмәт, якташ,— диде токтын, аның йөзенә өмет нуры кунгандай булды.
Мотаһир урыныннан торды. Ләкин шулчак бүлмәгә бер үсмер керде. Исәнләште. Ишек катында туктады. Мотаһир бу токтынны да белә. Аның беренче генә килүе түгел. Чире начар — буыла, тәлләрен тешли... Мотаһир: «Моны солдатка җибәрү хәерле булыр»,— дип уйлады.
— Костров, тагын килдеңме?
— Әйе, доктор.
— Нишлибез соң?
— Белмим инде.
— Солдатка барасың киләме?
Әлбәттә, хәзерге кыяфәтенә караганда, чирен дә искә алсаң, ул данлы армиянең көч-куәтен арттырырлык кеше түгел иде. Күрәсең, үзе дә үз чамасын белә. Бик атлыгып та тормый.
— Белмим.
— Ярар, бүгенгә кайтып тор. Үзем әйтермен.
Үсмер чыгып киткәч, Мотаһир өстәл янына утырды. Үсмерне бу мәхшәрдән коткаруның бердәнбер юлы фронтка җибәрү икәненә ул тәмам инанды. Чөнки бума кеше эшләрдәй эш монда юк иде. Иртәме-соңмы, ул агач астында калып үләчәк. Мотаһир начальник исеменә рапорт язды. «Солдатка барып эләксә, озак тотмаслар, яраксыз табып, өенә җибәрерләр»,— дип фикер йөртте ул үзенчә.
Аннары Мотаһир Илтазаровка сорау бирде:
— Син каян килдең әле?
— Сорок Лагтан.
— Кайсы төштә булдың?
— Обозерский тирәсендә.
— Шулаймыни,— диде Мотаһир сузып кына.— Урман кистеңме?
— Эшләмәгән эш калмады,— диде Илтазаров җанланып һәм, якташына тәмам ышанып, җәелеп китте.— Күрде башлар... тегермән ташына салып онга гына әйләндермәделәр. Аннары ат белән йөрдем. Ашханәгә йөк ташыдым.
— Алайса гел ач булмагансың икән.
— Әй, исеме генә инде. Шулай да ашар нәрсә табыладыр ие. Чүпне араласаң, кесәл кисәкләре, башкасы чыга.— Көлеп өстәде:— Ашказаны шәп минем.
Мотаһир да аңа кушылып көлде. Ул Илтазаровка бер кружка мүк җиләге сыгынтысы салып бирде.

— Мә, эч.
— Нәрсә ул?
— Курыкма,— дип елмайды Мотаһир.— Экстракт, витамин урынына. Пиллагра элəкмәсен. Бүтән сыем юк.
— Рәхмәт, якташ.
Мотаһир буш кружканы бер читкә алып куйды.
— Әйдә, Илтазаров, стационарга.
Ул палаткага килеп керүгә, «дуга бөгеп» яткан берәү зарлана да башлады.
— Эч бора, доктор,— диде инәлеп.— Хәлем авыр.
Мотаһир аның янына килде, өстен ачты.
— Чалкан ят. Суз әле аякларыңны.
— Авырта, доктор.
Мотаһир аның эченә кул тидереп алды, юатты.
— Ышанам, агайне, ышанам. Түз. Авырмас сөяк булмас. Рәтләнерсең.
Юньле дару булмауга эченнән көенеп, авыруның кружкасына мүк җиләге сыгынтысы салып, ул ары китте. Тагын берәү янына килде.
— Хәлең ничек? Бир син дә кружкаңны.
Анысының бөтен тәнен чуан, сызлавык баскан иде.
— Ярыйсы,— диде авыру тоткын сабыр гына.— Әле бүген төш күрдем.
— Йә,ниләр күрдең?
Мескен авыру зәңгелә чиреннән коелып беткән тешсез авызы белән елмаерга итте.
— Ат күрдем.
Күршедә яткан берәү, муены һәм бите чабырган адәм, шундук ашыга-ашыга:
— Өстеңнән ялган сөйләгәннәр,— диде.— Менә, мин сиңа кичә әйттем бит. Әйттемме?
Мотаһир белә: кем дә булса берәү төшендә ат күрсә, аны нигәдер ялган күрсәтүгә юрыйлар иде, ягъни аның өстеннән судта ялган мәгълүмат биргәннәр, йә язып җибәргәннәр. Нигә алай юрыйлар — анысы Мотаһирга караңгы. Әллә инде русча лошадь һәм ложь дигән сүзләр охшашрак булгангамы? Мотаһир табибның беренче дәвалау коралы сүз икәнне һәрчак исендә тотып, әңгәмәне дәвам итте:
— Ат киттеме яныңнан, юкмы?
— Китте,— диде теге мескен сөенеп.
— Төшең әйбәт икән, әле савыгып өеңә дә кайтырсың, иншалла.
— Рәхмәт, доктор, яхшы сүзеңә.
Чыкмаган җанда өмет бар шул.
— Сугыш беткәч кайтарырлар,— диде Мотаһир һәм буш койкага күрсәтте:— Илтазаров, син шунда ятарсың.
Илтазаровны яткызгач, Мотаһир авыруларны карады, вазифасы кушканча башкарырга тиешле эшләрен тәгалләгәч, ишек алдына чыкты. Якындагы баракка керде.
Нарда яткан берәүне күреп, дежурныйдан сорады:
— Бу нишләп ята?
— Ул чирли,— диде дежурный күзен дә йоммыйча.
Шулай да Мотаһир, нидер сизенеп, үзе барып карыйсы итте.
Тегенең өстен ачса, аптырап китте.
— Бу үлгән ләбаса.
— Ә, шулаймыни? — дигән булды дежурный, белмәмешкә салышып.
Мотаһир мәетнең баш очындагы салам мендәргә кагылды. Анысы да суынып, катып беткән.
Ни өчен дежурный тегенең үлүе хакында хәбәр итмәвен дә белә Мотаһир: ипиен алыр өчен. Бу хәл беренче мәртәбә генә кабатланмый инде.
Барактан чыккач, Мотаһир шундый күренешкә тап булды: зона ишек алдында өч тоткын сөйләшеп тора, ә проходной ягыннан лагерь башлыгы белән бер надзиратель киләләр. Менә башлык тегеләр янына житте.

— А-ну тарал! — дип боерды ул коры гына.

Уголовниклар, алай җыелышып торырга ярамаганны белгәнгә, теләр-теләмәс кенә аерылыштылар. Шулай да берсе, инде кузгала башлаган «хуҗа»га таба атлап:

— Гражданин начальник, минем ашарыма юк, — диде.

Моны ишетеп, икенчесе дә артына борылды һәм, юри мескенләнеп, сүзгә кушылды:

— Гражданин начальник, синең ипиең юкмы?

Өченчесе дә еламсыраган булды.

— Миңа да бир әле, «хуҗа».

Начальник:

— Карцерга утыртсам, тамагыгыз туяр! — диде дә китеп барды.

Ул да, тегеләр якынлашуга, сагая калган иде. Чөнки көнкүреш статьясы белән утыручылардан теләсә нинди этлек көтәргә мөмкин. Өстенә ташланырга, кадарга да күп сорамаслар. Ә начальник зонага коралсыз керә. Надзиратель дә буш кул белән.

Лагерь башлыгы карцерга бара икән, үзе белән Мотаһирны да ияртте. Мотаһир аңардан бераз арткарак калып барды. Читтән караганда начальникның йөрүе кызык икән. Мотаһирга ул сажинлап җир үлчәгән колхоз бригадирын хәтерләтә: салмак-салмак, озын-озын итеп атлый. «Кадровый гаскәриләргә бер дә охшамаган бу», — дип уйлады Мотаһир.

Карцер агачтан бурап эшләнгән аерым бинадан гыйбарәт иде. Почмаклары тимер белән беркетелгән. Эчтә, уртада, коридор һәм әрле-бирле йөренүче коралллы надзиратель. Коридорның ике ягында да камералар.

Начальник ишекләрдәге «волчок»тан караштырып алды да китеп барды.

Мотаһир исә, сакчы белән, камерадагыларны берәм-берәм тикшереп чыкты. Камераның җиһазы юк диярлек, өч ягында өч эскәмия генә, ишек ягы буш, ятар җир юк. Түшәм биек, югарыда ике бүрәнәне тишеп кенә уелган бәләкәй тәрәзә.

Мотаһир камераларда бик сак йөрде. Чөнки монда, ачлык игълан иткән яки юк-бар гаеп өчен ябылганнар белән бергә, әшәке җинаятьчеләр дә бар иде. Паеклары җан асрарлык кына аларның: ике йөз грамм ипи, ике йөз грамм су.

Тоткыннарның берсе бик бетешкән иде. Мотаһир: «Масленниковны, начар хәлдә булуы сәбәпле, карцердан чыгаруыгызны үтенәм...» — дип, лагерь начальнигы исеменә рапорт язды.

Әлбәттә, үзе дә тоткын буларак, Мотаһир бу бичара бәндәләрнең хәленә керергә тырыша. Ләкин ул да бик сак эш итә. Чөнки аның һәр сүзе, һәр рапорты нык дәлилләнгән булырга тиеш. Югыйсә, үзенең кыен ашавы ихтимал. Моны Мотаһир беркайчан да исеннән чыгармый иде.

Бер атна узды. Илтазаровның хәле яхшырмады, аягының шеше бетмәде. Аны тагын күпме яткыра ала Мотаһир? Бер атна, ике... ә алга китеш күренмәс сыман. Шуннан Мотаһир, гасабилы уйларын бер якка куеп, санчасть башлыгы белән сөйләшеп карарга булды.

— Сергей Филиппович, авыру Илтазаровның хәле начар, — диде ул җай белән генә.

— Нәрсә булган?

— Аяклары авырта. Бер атна ята инде, яхшыга бармый. Төзәлми.

— Шуннан?

Мотаһир, һәр сүзенә басым ясап, әйтте:

— Актлаштырыйк. Ул үлә.

Бу сөйләшү Мотаһирның эш бүлмәсендә бара иде. Начальник кисәк кенә аңа карады, кашлары җыерылды, йөзе кырысланды. Ул икеләнә калды. Чөнки тоткыннарны актлаштыру бик сирәк очракта гына була, бу — гадәттән тыш вакыйга. Узган ел ике күзе дә сукырайган берәүне — гади крестьянны — шулай иттеләр. Өенә кайтып китте. Сүз дә юк, тома сукыр монда беркемгә дә кирәк түгел, тегендә дә андый «халык дошма-

ны»ннан әллә ни зыян тимәс. Шуңа күрә каршы килүче булмады. Ә Илтизаровның аяклары гына шешкән. Азмыни андыйлар?! Санчасть начальнигы үзенең кул астында эшләгән Мотаһирга янә текәлеп, сынап карады. Әлбәттә, ул аңа ышана иде. Ләкин, тәшвишләнүе бетсен, томанлы, икеле-микеле уйлары бөтенләй таралсын өчен, ул ашыкмаска булды.

— Әйдә, керик әле.

Доктор авыруны җентекләп карарга, бәйнә-бәйнә сораштырырга уйлады. Чөнки мондый четерекле эшнең мәшәкате күп. Бер селтәнүдә генә хәл итә торган түгел. Бөтен җаваплылык, ахыр килеп, аның җилкәсенә төшәчәк. Хата җибәрсәң, төзәтеп булмаячак.

Авыруны карагач:

— Тагын бер атна ятсын,— диде башлык Мотаһирга.

Атна узуга янә җентекләп тикшерде. Бары шуннан соң гына, аның карарына тел-теш тидерүче булмаячагына инангач, өмете өзелә башлаган Мотаһирга:

— Документ әзерлә,— дип боерды.

Илтазаровны актлаштырып, өенә кайтарып җибәрделәр. Өсте бик сәләмә иде, жәлләп, Мотаһир бер пар күлмәк-ыштан бирде. Ул киткәч, Мөсәмирәгә хат язды.

* * *

Илтазаров кайтып киткәч, Мотаһир ике төрле хис кичерде. Бер яктан, ул якташын үлемнән йолып калуга сөенсә, икенче яктан, аның өенә кайтуын, хатынын, әти-әнисен, бала-чагасын, туган-тумачасын күреп куанасын уйлап, үзенең дә күңеле алгысыды. Бер җай белән генә аккан тормыш елгасына ярдан таш, балчык кантарлары төшеп, аны актарылып, бөтен тирәюньне дөбер-шатыр китереп, быгырдап агарга мәҗбүр иткән кебек булды. Аның йөрәге ярсыды, күңел чоңгыллары айкалды-чайкалды... Ни генә башына килмәсен, бу арада уйлары гел өе турында. Ә өйгә ялганып туган авыл, аның кешеләре күз алдына килә. Үзенең каһәрле язмышы һәм ни өчен газап чигүе хакындагы уйлар тынгы бирми.

...Кызыл Армиядән кайткач, Мотаһирны хәрби комиссариат берничә мәртәбә Казанга — осталыгын арттырырга җибәрде. Утыз бер, утыз дүрт, утыз алты һәм утыз җиденче елларны барды бугай. Әйе, шулай булды. Һәм менә соңгысы аермачык хәтерендә: 1937 елның июнь — август айлары Казанда булды.

Кайтуга, колхоз рәисе аның башына таяк белән суккандай итте:

— Сине район советы эшеңнән чыгарды.

— Ничек? — дип аптырады Мотаһир.

— Син унбиш көнгә отпускы аласың да, эшеңнән китәсең, айлар буе югалып торасың,— диде председатель күзен дә йоммыйча.

— Мине военкомат хәрби уеннарга җибәрде.

— Анысын мин белмим.

Мотаһир моның каныгу, үчләшү галәмәте икәнен аңлый иде. Хезмәте буенча турыдан-туры рәискә буйсынмаганлыктан, ул аның белән авыз чайкап тормады, каңгырып, район үзәгенә китте.

Гаҗәп хәл: рәиснең сүзе хак булып чыкты. Әмма ни өчен чыгарылганын әйтмәделәр.

— Алайса сез миңа белешмә бирегез,— диде Мотаһир райздрав мөдиренә.— Фәлән елдан фәлән елга хәтле фельдшер булып эшләде, дип.

— Булыр,— диде мөдир тәкәббер генә.

Район үзәгеннән бик күңелсезләнеп кайтты Мотаһир. Ләкин тик ятып булмый — колхоз эшенә йөри башлады. Аны ындыр табагына, барабанга көлтә бирү эшенә куйдылар. Анда хезмәт көне күп төшә икән. Күпсенеп, салам эскертләүгә күчерделәр. Монысыннан да алдылар һәм көлтә кертергә

куштылар. Мотаһир эштән курыкмады. Ат белән кәлтә китер, сәнәк белән эскерткә ат. Бөтен көчен биреп тырыша иде...

...Илтазаров кайтып киткәч, Мотаһир шуларны хәтеренә төшерде. Авыр башына җиңеллек килмәсме дип, авыз эченнән генә җырлап та җибәрә иде. Ә җыруы гел бер:

Күгәрченнең мескенкәйнең
Ак йоны бар түшендә.
Тагын ниләр күрәм икән,—
Сулар йөздем төшемдә.

## XXVI

...Июль ахырында Мотаһирны лагерь башлыгына чакыртып алдылар.
— Син Кушага барырсың,— диде бүлмәсендә берүзе утырган хуҗа.
— Еракмы соң ул? — дип сорарга җөрьәт итте Мотаһир.
— Онегага барганда... Малошуйка станциясенә китәрсең... Пропуск алырсың. Унбиш көнгә командировочный яздыр. Бухгалтериягә кер.
Начальник анда кемнәр һәм ни эшләвен дә аңлатты. Хәер, әйтмәсә дә, Мотаһир чамалый: сине анда конфет фабрикасы көтеп тормый.

Бу яклардагы һәр станция кебек, монысы да зур агач бинадан гыйбарәт иде. Тирә-ягында складлар, ярдәмче хуҗалыклар. Берничә рәт тимер юл рельслары ялтырап ята. Станция зур поселокның нәкъ уртасында урнашкан.
Мотаһир баштарак вокзал эченә кереп, байтак вакыт агач эскәмиядә утырды. Каядыр барырга җыенган төрле кыяфәттәге юлчыларны күзәтеп аргач, стенадагы язуларны укырга, плакатларны карарга кереште. Бер плакат аның игътибарын бигрәк тә җәлеп итте. Алгы планда, тимер караватта, ап-ак урын-җирдә бер бала ята. Аның өстенә фәрештә кук хатын-кыз иелгән. Аста язу: «Окружим сирот материнской лаской и любовью!» Башта бу сүзләр бала караватына иелгән хатын авызыннан әйтелгән кебек тоела. Ләкин җентекләбрәк, башыңны күтәребрәк карасаң, эшнең асылын аңлыйсың. Плакатның арткы планында (беленер-беленмәс кенә) — Сталин сурәте. Ул кулына бала күтәргән. Икесе дә бәхетле елмаялар. Икесе дә чәчәккә күмелгәннәр...
Ниндидер ачыну биләп алды Мотаһирның күңелен. Ул урамга чыкты. Ләкин (әйтерсең, аның һәр адымын күзәтеп торырга җыенган) монда да бөек юлбашчы сурәтенә юлыкты. Монда да зур плакат. Ул станция бинасының тышкы диварына кадакланган. Даһи ата бөтен халыкларга юл күрсәтә. «Под знаменем Ленина, под водительством Сталина — вперед к новому расцвету советской Родины, к полной победе коммунизма в нашей стране!» Язу сул якта, Сталин — уңда. Ул хәрби киемнән, яланбаш. Түшендә зур йолдыз. Үзе горур, житди. Аның артында Ленин шәүләсе...
Мотаһир поезд көтеп тора. Зур станция булганлыктан, монда беркайчан поездлар да, халык та өзелми. Әнә бер яктан платформаларга танклар, туплар куелган хәрби состав ажгырып килсә, икенче яктан яралылар төягән санитар вагоннары шуыша. Бер, ике, өч... Йә хода, гарипләнгән никадәр солдат!.. Нихәтле техника агыла! Очы-кырые юк. Кайчан бетәр бу мәхшәр?! Кешеләрне имгәтеп, илне бөлгенлеккә төшереп бетерә ич бу сугыш!
Мотаһир, әче итеп, үзәкләрне өзеп паровоз кычкыртуга түзә алмыйча, елар дәрәҗәгә житеп башын тота... Кулларын алуга, пассажир поезды килеп житә. Тәрәзәдә хәрбиләр, хатын-кыз, бала-чага... Кая бара болар, кая юл тота? Бәгыре киселеп, үзенең нарасыйларын юксына Мотаһир... Салкын рельсларга ятып җылардай, колак салып тыңлардай була ул туган илдә

ниләр барын... Их, утырып ла китәсе иде шушы вагоннарның берсенә... Ленинград, Мәскәү, Казан... Йә хода, үзең сабырлык бир!

Мотаһир күз яшьләренә буыла...

Аның поезды әле һаман килми. Ә ул, аны көтеп, перронда тора. Әнә өлкән яшьләрдәге бер хатын, сумкасын актара башлады. Билет эзлиме? Тапты, ахры. Ашыгып китеп бара. Чү, ни бу? Мотаһир, әле генә хатын басып торган урында кошелек күрде. Ул әлеге хатын артыннан кычкырды:

— Гражданка! Гражданка!

Хатын борылды, аптырап, аңа эндәшкән кара киемле арык кешегә карады.

— Сез миңа әйтәсезме?

— Әйе. Әнә, төшереп калдырдыгыз.

Хатын сумкасын кармаларга тотынды, йөгереп килде дә кошелегын җирдән күтәрде. Аны кулында тоткан хәлдә:

— Рәхмәт. Рәхмәт сезгә,— дип ашыгып китеп тә барды.

Перронда хәрбиләр күренгәли, халык тыз-быз йөри. Әнә тагын бер хатын Мотаһирның игътибарын җәлеп итте. Кечкенә баласы белән яшь ана. Йодрык хәтле генә бала, бурлак кебек җигелеп арба сөйри... Тик Мотаһирның аны бүтәнчә итеп күрәсе килә. «Кирәкми, ана, җәфалама шул сабыйны... Өлгерер әле тормыш тартырга...»

Нишләп гел ямьсез уйлар гына килә соң Мотаһирның башына. Югыйсә, монда матур күренешләр дә җитәрлек бит. Әнә, күгәрчен һәм чыпчыкише кошлар рельс, шпал араларында йөреп, ризык эзлиләр, тамак мәнфәгатен кайгырталар... Тоткыннар да шулайрак бит: алар да шул ач кошлар хәленә төшкән, кешелекләрен югалтыр дәрәҗәгә җиткән — ни очраса, шуны кабып йотарга әзер...

Менә Мотаһирга кирәкле поезд да килеп җитте. Керде. Урнашты. Янында таушалганрак костюм-чалбар кигән бер ир-ат. Сөйләшеп киттеләр. Теге башта текәлеп карап торды, аннары:

— Син нишләп утырасың? — дип сорады.

— Мин утырмыйм, барам,— диде Мотаһир тәкәллефсез генә.

— Кая?

Мотаһир аның төс-кыяфәтенә, өс-башына күз төшерде. Уртача гәүдә, тулы йөз, кыяфәте артык күзгә бәреләә торганнардан түгел. Ләкин гәүдәсен төз тота, чалбар балагын яхшы күнитек куныычына кыстырган. Сөйләшкәндә сүзләрен ачык итеп әйтә — команда биргән кебек. Күңеле нидер сизенеп, Мотаһир бу адәмгә алдан ук дөресен әйтте:

— Кушага.

— Каян киләсең?

— Кодинодан.

— Пропускаң бармы?

— Бар.

— Күрсәт!

Мотаһир, түш кесәсеннән алып, рөхсәт язуын күрсәтте, ләкин кулыннан ычкындырмады. Һәм, үз чиратында, батыраеп, сорау бирде:

— Ә синең пропускаң бармы?

Теге елмаеп куйды. Кара нинди кыю, янәсе.

— Бар.

— Күрсәт.

Адәм уң янтыгындагы наганга ымлады.

— Әнә,— диде ул һәм кабат Мотаһирга төбәлде.— Син нинди кеше?

Мотаһир, икеле-микеле уйларга урын калдырмас өчен, үзенең кемлеген әйтүне кирәк тапты. Кызыл хачлы сумкасын капшап:

— Мин — врач,— диде.— Анда печән чабучылар бар, җитмешләп кеше. Конвойсыз җинаятьчеләр, Архангельск өлкәсе кешеләре.

— Аңлашылды.

— Ә син кем?

Юлчы тиз генә әйтмәде, серле генә елмаеп куйды. Аннары, як-ягына күз йөртеп чыккач:

— Оперативник,—диде.

— Ә ул нишли? —дигән булды Мотаһир.

— Синең кебекләр белән дуслаша.

Көлешеп алдылар. Шуннан оперативник, баягыча кырыслык белән түгел, ә гади генә сорап куйды:

— Син балык тота беләсеңме?

— Юк,—диде шиге бетмәгән Мотаһир чөнки лагерь еллары аны чит кешеләр белән сөйләшкәндә сак булырга өйрәткән иде.

— Безнең авылда зур елга юк, инеш кенә.

Вак-төяк сөйләшеп, ара-тирә тәрәзәгә карап, хәтта бераз ятып ял иткәләп, Малошуйкага җиттеләр. Поезд туктады.

— Син консерва банкасы эзлә,—диде оперативник.—Суалчан алырбыз. Мин кибеткә киттем.

Мотаһир бу адәмнең балык тотарга һәвәс кеше икәнен аңлады. Шпаллар арасыннан консерва банкасы табып, юл читендә таяк белән җир тырнаштырып, берничә суалчан тапты. Тегенең килгәнен көтә башлады.

Оперативник күп итеп кармаклар сатып алган икән.

— Банкаңны әйбәтләп яп,—диде ул, вагонга кереп утыргач.

Кузгалдылар.

Архангельск өлкәсенең бу яклары Котлас яки Березник тирәләреннән бераз аермалырак икән. Монда Ак диңгезнен, дөресрәге, Онега култыгының тәэсире нык сизелә. Һава дымлы, диңгездән өзлексез җил исеп тора. Төрле-төрле зурлыктагы күлләр белән чуарланган урманнар чыршы һәм нараттан гыйбарәт булса да, елга буйлары гел таш кына, хәтта елга төбенә дә вак таш түшәлгән кебек. Кайвакыт җир өстендә зур-зур ташлар очрый: аларның кайберләре яртылаш җиргә баткан. Әйтерсең, Алып батыр таш ыргытыш уйнаган да аларны җыймыйча калдырган. Таш ярыкларында, хәтта аларның шома өсләрендә дә ап-ак кашкарыйлар чәчәк атып утыра.

Куша авылы—Нименьга култыгыннан ерак түгел урнашкан балыкчылар совхозы, диделәр. Аңа җиде чакрымда, елга буенда, аз сроклы тоткыннар печән чаба икән. Мотаһир шуларны эзләп табарга тиеш иде.

Кушага барып җиткәч, оперативник:

— Бергә барырбыз,—диде.—Башта балык тотыйк.

Авыл читендә, су буенда туктадылар. Оперативник кармакларын җиргә куйды, җайлый-көйли башлады. Эшен бетергәч, банкадан бер суалчан алып кармакка эләктерде дә суга ташлады. Озак та үтмәде, бер бәләкәй балык капты. Аны оперативник зур кармакка эләктереп, суга ыргытты. Анысына ярты метрлы чуртан капты. Шуннан ул әйберләрен җыештырды.

— Киттек.

Әлбәттә, балык тотарга яратса да, ул бер генә минутка да үз эшен онытмады: кармак сабын тотып, суга караган хәлендә Мотаһирны гел сөйләштереп торды, кем икәнлеге хакында шактый мәгълүмат җыйды.

Тиешле урынга барып җиттеләр. Оперативник лагерь башлыгы белән күреште:

— Кунаклар килде,—диде.

— Андый кунакларны беләм мин,—диде тегесе Мотаһирга салкын карап ташлап.

— Мә, егетләреңә бир әле, кыздырсыннар,—диде оперативник һәм чуртанны начальникка сузды.

Ул бер кармагын Мотаһирга бирде:

— Мә, юлдаш.

...Разъездда яшәде Мотаһир. Унбиш көн саен командировка кәгазенә тамга салдырды. Чөнки тегендә кайтасы килми иде. Ул лагерь башлыгына керә дә:

— Гражданин начальник, мин Кодинага кайта алмыйм, авырулар күп,— ди.— Командировканы озайтмассыз микән?

НКВДга кереп, рациядән генә әйттерәләр дә, аның командировка срогын озайталар иде. Шулай итеп, стационарга кайтмады. Чөнки разъездда да стационар бар, үзе мөдир булып эшләде.

Ике-өч көндә урнашып, биләмәләрен барлап чыккач, балык тотып карарга булды.

— Син бакага тот,— дип акыл бирде аңа яр буенда бер карт.

Бәхетеңә, әләкте балык. Нишләргә? Кыздыртсаң яки пешертсәң була булуын. Әмма ул балыктан гарык инде, косасылары килә Мотаһирның. «Туктале,— диде ул үз-үзенә,— станциягә поездләр килә бит. Анда — ресторан».

Икенче көнне иртән станциягә китте. Нәкъ поезд килгән чак иде. Вагон-ресторан каршында туктады. Тәрәзәдә күренгән ак калпаклы берәүгә ым какты. Үзе ишеккә таба китте. Ике иякле, йонлач куллы, ак халатлы пешекче ишекне каплап чыгып басты.

— Нәрсә кирәк? — диде ул төксе генә.

— Сезгә балык кирәкмиме?

— Кая балыгың?

Мотаһир иске сумкага салган балыкларын күрсәтте.

— Менә.

— Ә сиңа ни кирәк?

— Ике буханка ипи.

— Була ул.— Һәм йонлач кул балыкларны алып куйды да ике буханка ипине чыгарып бирде. Кош тоткандай шатланды Мотаһир бу байлыкка һәм кире тартып алмасыннар, дигән кебек, тизрәк станциядән ычкыну ягын карады.

...Беркөнне Мотаһир, печәнчеләр янына баргач, түзмәде, берәүдән чалгы сорап алып, печән чабарга кереште. Ул бер тизлек алып, каерып-каерып чапты. Әлбәттә, ничә еллар аерылып торган эш башта бераз көйсезрәк барды. Ләкин тора-бара ул күптәнге үз асылына кайтты. Тез тиңентен куе үлән аның каршында авып, пакуска әверелә. Ә ул аякларын шуыштырып кына атлап, чабыпмы чаба. Менә тәне җылына, маңгаеннан тир ага башлый. Ләкин ул туктамый чыжлатып чаба да чаба... Печәннең хуш исе аны исертеп җибәрә. Йөрәген өзеп, янә туган авылы исенә төшә Мотаһирның...

Июнь ахыры, июль башларында ул ел саен печән чаба иде бит. Аннан пакус әйләндерергә бара, күбәли, чүмәлә сала... Әлбәттә, үзе генә түгел, егет чакта — әти-әнисе, туганнары, өйләнгәч — Мөсәмирәсе белән... Атка төяп алып кайтулары нинди күңелле иде! Мондагы шикелле богыл куймыйлар иде. Үз авыл болынының хуш исле үләннәре, үлән арасындагы бармак башыдай эре кызыл җиләкләре, өзлексез сайраган кошлары гына түгел, шәмәхә башлы шайтан таягы, берәр агачта утырган мәче башлы ябалак яки каргасына һәм, оясыннан чыгып, кечкенә баганадай арт аякларына басып торучы йомраннарына кадәр якын иде... Баш түбәсендә күпереп торган болытларына яисә очсыз-кырыйсыз зәңгәр күкләренә кадәр газиз иде... Ә ул авыл сабан туйлары, андагы төрле тамашалар... Кайда калды барысы да? Ай, дөнья, әйләнде дә куйды бит! Куласа кебек әйләнде дә куйды...

Мотаһир инде күңеле белән әллә кайчан үзенең Түгәрәк Күлендә, яшьтәшләре, туганнары, гаиләсе янында... Нинди якын, кадерле, миһербанлы кешеләр иде барысы да. Ә монда...

Һәм, аның уен раслагандай, бер уголовникның мыскыл итеп әйткән сүзе колагына килеп бәрелде:

— Карале, бу «болтун» печән дә чаба белә икән.

Ул әле тагын бераз аны үртәп, мыскыл итеп торды. Бу вакытта Мотаһир чабудан туктаган, ләкин чалгысын иясенә бирмәгән иде әле. Ул чалгы сабын чытырдатып тоткан, күзләре отыры усаллана. Әллә шуны күреп,

әлеге дә баягы уголовник аны юри ирештерә. Шулай да эш зурга китмәде. Чалгы иясе, әкрен генә килеп, чалгы сабына тотынды. Бераздан Мотаһир кулын бушатты. Чалгы хуҗасы теге уголовникка:

— Ну?! — диде коры гына.

— Нәрсә нулыйсың? Җикмәдең бит әле.

— Зерә бәйләнмә.

— Мин бит сиңа бәйләнмим. Артыңа сукмаганга ботыңны күтәрмә.

— Аңа да тимә. Ша! Кемгә әйттем!

— Нишләп әле син аны яклыйсың? — дип, теге хәзер моңа ябырылды. — Ул — контр! Ул совет хөкүмәтенә каршы килгән. Андыйларны сытарга кирәк!

— Ә син үзең? — дип һөҗүмгә күчте чалгы хуҗасы.

Теге горурланып:

— Мин карак, — диде. — Контр түгел...

Мотаһир сүзсез генә алар яныннан китеп барды. Бераздан тынычланды. Елга буендагы тез тиңентен печәнгә шактый озак сокланып карап торды... «Бездә күрәне дә калмый торган иде. Аны да, кыш көне мал ашар әле, әйбәт печән булыр, дип чаба идек. Ә монда аңа әйләнеп тә караучы юк», — дип уйлады.

Мотаһир елганың тиз агымына, чиста су астында күренгән ташларга карап, шактый вакыт уйланып утырды.

Берзаман, яшел урман ягыннан куерып болыт килеп чыкты, җил купты. Күк йөзен урталай ярып, аңа өстән аска хәтле канлы җәрәхәт ясап, кызыл камчы — яшен телеп үтте. Аның артыннан ук коеп яңгыр ява башлады...

...Ашыга-ашыга көз килеп җитте. Уйсу җирләрдә печән богыллары калкып чыкты, игеннәр дүрт букән өстендә утырган бура амбарларга җыеп салынды, җил һәм су тегерменнәренә эш артты, болай да сүрән кояшның нурлары инде җылытмас булды. Аюлар кышкы йокыга җыенды. Әйе, монда көз иртә килә. Әзрәк сабыр итсә дә ярар иде. Ни әйтсәң дә Мотаһир өчен әллә ни шатлык китерми бит. Чөнки яңадан өченче стационарга кайтырга мәҗбүр.

Поляр төннәр башланды. Төне бик озак, көне кыска аның. Иртән тугыз-уннарда гына яктыра да, өчләрдә-дүртләрдә караңгы да төшә башлый. Әмма аңа карап эш сәгатен киметмиләр, ул һаман иртәнге алтыдан кичке алтыга хәтле — төгәл унике сәгать.

Мескен тоткыннар чирдән арынмый. Мотаһирга эш өстәлеп кенә тора. Кайбер хәлсезрәкләре аңа килеп ялвара:

— Михаил Иванович, бер генә көн ял иттер, зинһар.

Аларга карап, йөрәге әрни Мотаһирның.

Әмма быелгы көз сөенечле хәбәр дә алып килде: октябрь аенда Карелия фронты гаскәрләре, Төньяк флот белән берлектә, дошманны Печенгадан бәреп чыгарганнар. Ә ел ахырында СССРның дәүләт чиге элекке хәленә кайтарылган. Дошманны үз оясына таба кысрыклау башланган.

Кыш чыгып, яз җиткәч, көтеп алынган Җиңү килде! Ил белән бергә бу тантанага тоткыннар да чиксез куанды. Язгы ләйсән яңгырына кушылып, аларның да шатлык яшьләре акты...

Җәй башында Мотаһир янә Кушага китте дә, көзлектә генә әйләнеп кайтты. Шулай кайта-китә йөреп, ике ел узды.

Аннары аларны, меңгә якын кешене, этап белән ябык лагерьга, урман эченә кудылар. Ул лагерьда утыз җиде мең кеше бар, диделәр.

Тагын зона. Ике рәт чәнечкеле тимер чыбык, арада такта тротуар — сакчылар йөрер өчен. Аларның күзәтү каланчасы да шунда.

Лагерьда такыр башлы, ябык, усал төс-кыяфәтле, җиту сакал-мыеклы тоткыннар. Бөкрерәк гәүдәле, сеңерләре һәм кан-тамырлары беленеп торган каты куллы зеклар...

Әйе, бирсдә алар, чыннан да, каты куллы булып чыкты.

«Усалларның усалын монда күрергә язган икән», — дип уйлады Мо-

таһир. Чөнки беренче көнне үк ул шундый күренешкә тап булды. Электән монда ябылуда яткан бер уголовник яңа килгән сәяси тоткыннар арасында алтын тешле берәүне күреп алды.

— Әй, син, фиксатый, кил әле бире,— диде ул аны бармак белән генә чакырып.— Әйе, әйе, син. Кем сине монда борынчыксыз кертте? Ә? Ха-ха-ха... За что загремел? Ни өчен утырасың?

— Илле сигезенче статья.

— Кызлар көчләмәвең күренеп тора. Ничәнче часть буенча, дип сорыйм.

— Икенче.

— О, хөкүмәткә каршы... Әйбәт түгел, хөкүмәткә каршы бару яхшы нәрсә түгел,— дигән булды уголовник.

Шуннан икенче бер сәяси тоткын килеп, иптәшен якламакчы булды.

— Тимә син аңа,— диде ул.— Понял?

— А ты меня на «понял» не бери. Я за этот «понял» пять лет отсидел. Понял?! Эт фәлән нәрсәсен тыкмаган җиргә борыныңны тыкма.

Сәяси тоткынның да бирешәсе килми иде:

— Тимә, дидем.

— Ты че возникаешь? Тебя, че, давно не били?

— Мин сиңе кисәттем.

— Ә мин сиңа төчкерәм, миндә — томау.

Моңа ярдәмгә тагын берничә уголовник килеп җитте.

— Нәрсә хай күтәрдегез? — дип сорады арадан берсе.

— Әнә, бер фиксатый килгән,— диде уголовник һәм тагын теге сәяси тоткынга бәйләнде: — Нәрсә миңа күзеңнең агы белән карыйсың? Кыяфәтем ошамыймы әллә? Мин начар киенсәм дә, культуралы тәрбияләнгән...

Ул үзе шикелле башкисәр иптәшләренә аркаланып, тагын нидер сөйләнде.

Надзирательләр килеп чыкмаса, эш нәрсә белән йомгакланыр иде, билгесез. Алар күренгәч кенә, төркем ике якка аерылып китте... Ләкин иртәгесен теге сәяси тоткынның алтын тешләре юк иде инде.

Ә икенче вакыт, тагын этап килгәч, әлеге бандит бер яшүсмергә бәйләнде. Нардан төште дә, оятсызларча кешнәп:

— Ба, бу минем беренче мәхәббәтемә охшаган,— диде.— Чибәр бу, чибәр.

Үсмерне уголовниклар әйләндереп алдылар. Икенчесе, тәмәке төпчеген чиртеп җибәрде дә, кулларын җәйде.

— Капшап карамыйча ышанмыйм,— дигән булып, ул аны сыйпый ук башлады...

Һәм шуның белән бичара үсмернең язмышы төнлә хәл ителде...

...Ярты елдан Мотаһирлар тагын этап белән киттеләр һәм бер урманчылык пунктына килеп юлыктылар. Дөресрәге, аларны юлыктырдылар. Бу лесопункт Мотаһирга таныш Төньяк Двина буенда иде.

Двина, Двина... Буксирда барганда аның киңлеге, көче сизелә, дулкыннары чайкала. Буксир селкенүенә, чайкалуына гел уйланып, күзәтеп барасың. Мотаһир кебек меңләгән тоткыннар ябылуда дөнья рәхәтләреннән мәхрүм булып ятса да, үз иркендәге кешеләр өчен тормыш әүвәлгечә дәвам итә иде. Әнә яр буенда, алар туктаган пристань янында, туй итүчеләр. Күрәсең, кунакларны озаталар: гармун дәртле моңын сибә, такта тротуар өстендә көчле аяклар тыпырдаша, частушка тавышлары бөтен тарафны иңләп ала...

Дәрья кебек киң булып агыла ул төньяк җыры, урман кебек төрле авазлар белән шаулый... Йөрәккә үтеп керә, күңелне кузгата... Каядыр болытларга да менеп китә, бөтен галәмгә тарала ул... Төньяк боз океанына кадәр барып җитәдер, анда булган кешеләрне дә җылытадыр, дәртләндерәдер бу җырлар...

Ә аларга... тагын лагерь, тагын эш — җаны теләмәгән, күңеле тартмаган эш...

Урманчылык пункты.

Яр буенда агач эскертләре. Ә агач һаман өсталеп тора. Чөнки аста, елга читендә саллар. Ул ярга беркетелгән һәм аннан агач күтәрәләр. Ләкин аны тартып менгермиләр, моның өчен махсус җайланма — транспортер көйләнгән.

Аста берничә кеше, бүрәнәләр өстендә йөреп, транспортер ягына озын саплы ыргак белән берәм-берәм бүрәнә этәрә. Җайсыз тертсә, кайберәүләр суга төшеп тә китә...

Әмма бередә дөньядан туйганнар, үзләре үк төшеп китүчеләр дә юк түгел. Мотаһир белән эшләгән берәү ялга туктаган саен сукранып, язмышыннан зарланып йөрде.

— Барыбер үләбез инде,— дип әйтә иде ул төшенкелек белән. Мотаһир аны юатырга тырышты:

— Туктале, Вася, сабыр ит.

— Күпме түзәргә була?!

Һәм беркөнне ул су астына китте. Билгеле, аны тартып чыгарырга да омтылмадылар. Чөнки бу гадәти нәрсә кебек: монда адәм җаны чебеннән дә бәһасезрәк.

Аның бер танышы килеп:

— Вася кайда? — дигән сорауга да битараф кына итеп:

— Суга төште,— дип кенә җавап бирделәр.



## XXVII

«Урман эчләрендә урман, керсәм чыгалмам инде...» Әйе, нәкъ җырдагыча — чыгарлык кына түгел иде Мотаһир килеп эләккән урман, эче-тышы чәнечкеле бит аның. Ниһаять, бүген дошманыңа да теләмәслек бу мәхшәрдән котыла. Юк, әле күңеле ышанмый, аңына барып җитми шикелле. Мөмкинмени бу хәл? Югыйсә, айлар-еллар буена көтте бу көнне, төн йокламый уйланып чыга иде. Соңгы вакытта бигрәк тә... «Хыяллана күрмим тагы»,— дип тә куя иде Мотаһир үз-үзенә. Гаҗәп түгел, нишләсәң дә гаҗәп түгел монда. Соңгы лагерьда егерме мең кеше, диделәр. Якташлары да байтак иде. Ә күпмесе исән калыр икән шуларның? Мотаһирның да, бетүләрем шушы икән, дип йөрәге өшегән минутлары аз булмады. Әмма түзде, тырышты-тырмашты, актыккы сулышын җыеп сазлыктан чыгарга омтылган кеше кебек ул да талпынды-калкынды, җанын-тәнен сакларга тырышты. Ачлы-туклы яшәргә күнеккән иде инде, ә менә җанны-бәгырьне телгәләгән кимсетүләр соңгы чиккә җитте. Гүя кемгәдер аның кайтмавы, моннан чыкмавы, бередә күргәннәрен иректәгеләргә җиткермәве кирәк иде. Гүя аны соңгы адымын ясарга, соңгы чиккә этәрергә тырышалар иде — йә лагерьдагы вәхшилектән канәгатьсезлек белдерергә, йә лагерь хуҗаларына, аларның рәхимсезлегенә протест йөзеннән, юлбарыстай өсләренә ташланырга, йә бу газапларга түзә алмыйча, әҗәл эзләп, чәнечкеле тимер чыбыкка таба атларга... Әмма тешен кысып түзде, тешләре шыкырдап кителеп төшкәнче кысты ул аларны. Менә хәзер шул кимсенү-җәберләүләргә түзүнең әҗере — ул өенә кайтачак, бу тәмугтан котылачак.

Ләкин Мотаһир уйлап җиткермәгән, башына да китермәгән тагын бер куркыныч аны сагалап тора икән әле. Башта ул моңа әллә ни әһәмият бирмәгән иде.

Аны озатканда лагерьның икенче бүлек башлыгы, Кокашинский фамилияле, Мотаһирга мөгамәләсе гел үк начар булмаган озын буйлы, киң җилкәле кеше әйтте:

— Нәбиуллин, өеңә кайтма. Әгәр анда кайтсаң, начар булыр.

Мотаһир, үзен ирекләрәк сизеп, теленә килгән беренче сүз белән җавап кайтарды:

— Моннан да начары булмас инде... Көне-сәгате белән төп-төгәл ун ел бит.

— Хәлеңне аңлыйм, Нәбиуллин,— диде Кокашинский.— Звоноктан звонокка хәтле... Күп, бик күп. Ләкин мин сине кисәтергә тиешмен. Үзеңә яхшылык теләп... Гел исеңә төшереп торырлар...

Ул кузгала башлаган Мотаһирны кире утыртты:

— Сабыр ит. Уйла.

— Белмим инде, гражданин начальник,— диде Мотаһир аптырап.

Ул ничектер икеләнә калды, коелып төште. «Сукыр тычкан юлга чыкса, буран булыр, ди. Менә миңа да гел уйламаган-искәрмәгән яктан карлы-бозлы җил чырайга китереп бәрде булып чыга түгелме?» Башта аның теләге каршы тору, бу мәхшәрдән котылу өчен үз-үзен яклау булса, хәзер аек акыл белән эш итү өстенлек ала башлады.

Өстенә көрән костюм кигән, һәрвакыт җитди чырайлы, итагатьле Кокашинскийның күзләренә карады Мотаһир. Әйе, хәзер ул башлыкларга да туры карарга батырчылык итә. Чөнки үзенә тигән «өлеш»не тулысы белән татыды бит. Ләкин бу минутта аның бөтен барлыгын нәфрәт түгел, ә корыда калган балыктай аптырау-бәргәләнү галәмәте биләгән. Каршында утырган начальник бу мизгелдә аннан өстен иде әле. Күрәсең, иленә кайтканнарның ачы язмышы аңа яхшырак таныш.

— Аның каравы, мин беләм,— диде Кокашинский һәм сабыр тыныч тавыш белән дәвам итте:— Бер ай сине көтәбез. Гаиләңне дә алып кил. Хәрби хезмәттә саналырсың. Үзеңә мәгълүм, без синең эшеңнән канәгать булдык, кулларың — алтын. Холкың да әйбәт.

— Рәхмәт анысына.

— Араны бөтенләй өзгәнче, уйлап кара,— диде икенче бүлек башлыгы янә баягы сүзен кабатлап.— Артыңда күперне яндырып китмә.

Мотаһирның иреккә чыгу бәйрәме, якты уйлары, өметләре тоныкланып калды. «Миңа хәзер бу гомерлек келәймә булыр микәнни? Бүренең ашаса да, ашамаса да авызы кан була, дигән кебек, «халык дошманы» дигән тамга гомер буена калыр микәнни? Мин бу кара таптан үлгәнче чистарына алмам микәнни? Моннан котылу чарасы юк микәнни?» Менә шундый уйлар аны көне буе бимазалап, миен бораулап торды. Ул үзен әхлакый зәгыйфьләнеп калгандай хис итте. Хәтта лагерь капкасыннан соңгы мәртәбә чыгып, кирза итекләре белән каты карга нык басып, ирек һавасын күкрәк тутырып сулаганда да аның ашына таракан төшкәндәй булды. Әмма, уйлый-уйлана торгач, ул күңеленнән сүз бирде: «Ачка үлсәм үләрмен, үз җиремдә үләрмен!» Аның сагынуы, җирсүе шулхәтле көчле иде ки, юл уртасына бер чүлмәк алтын чыгарып куйсалар да, туган җиргә кайту уеннан чигенмәс иде ул.

Бөтен төймәләрен дә каптырып өстенә телогрейка, колакчыннарын төшереп юка бүрек кигән, кечкенә чемоданына ике балык, өч буханка ипи салган Мотаһир станциягә җиткәнче артына борылып карамады. Гүя, кисәк кенә «Тукта!» — дигән команда яңгырар да, без шаярттык кына дип, аны кире борып, лагерьга алып китәрләр, азат ителү турындагы белешмәсен ертып ташлап, кабат чәнечкеле тимер чыбык эченә ябып куярлар төсле. Чөнки ул әле хыялының чынга ашуына — үзенең иреккә чыгуына ышанып җитми иде.

Ул бөтен барлыгы, арка тамырлары, тәненең һәр күзәнәге белән артта ни барын тоеп тора: тезелеп киткән агач баганалар, чәнечкеле тимер чыбык, почмакларда түбәсе такта белән ябылган агач каланчалар. Әнә текә баскычтан кораллы солдат менеп бара. Ул өске өлеше ачык калдырылган каланчадан лагерь эчен күзәтә. Әйе, дүрт-биш метр биеклектән аңа барысы да уч төбендәге кебек аермачык күренә: бихисап бараклар да, берәнсәрән йөргән хәлсез тоткыннар да...

Мотаһир кисәк кенә башын селкеп куя. Бу ямьсез уйлардан арынырга тели. Ул турыда уйламаска! Ул хәзер тоткын түгел. Срогын тутырып чыкты. Чыкты! Аның иреккә чыгуы — төш кенә түгел, өн. Артта калган нәрсәләр аңа кагылмый. Ул — иректә! Ул — исән! Исән! Нинди мәхшәрдән

исән чыкты. Иленә кайта! Туганнарын, якыннарын күрәчәк! Гаҗәп: каршына очраган кешеләр кебек ул теләсә кайсы якка таба атлый, китә ала, яисә туктап тора, теләсә кычкырып җырлап та җибәрә ала. Чыннан да, бу шулаймы? Ул сафка басмыйча яисә, пропускам фәлән сәгатькә хәтле генә иде, дип курыкмыйча, үз ирке белән йөри аламы?.. Үзе теләгән ризыкны сайлап ашый аламы?.. Мотаһир кесәсендәге барлы-юклы акчасын капшап карады. Җитәрме? Балаларга, хатынына күчтәнәчлек янга кәлдыра алырмы?.. Бөтен уй-теләк, үзеннән дә өлгеррәк булып, алга омтылган: үз авылына, якыннары, туганнары янына... «Газизләрем! Мин кайтам! Мин — азат! Сезнең янга, сезне сагынып кайтам! Сезне сагынып, бер күрергә тилмереп...» Мотаһирның сулышы кысылды, күз төпләре дымланды, хәле китте. Ул, бүтән чыдар әмәле калмагач, юл читенә чыгып, бер нарат кәүсәсенә тотынды һәм, тәкатьсез булып, иркенләп, беркемнән оялмыйча-курыкмыйча тойгыларына ирек бирде... Аның юка, бәләкәй гәүдәсе сыгылып төште, түмгәк хәтле генә булып калды... Күзләрен йомып, бөтен тәне-йөрәге белән ярсып-калтырап, җылады да җылады...

Бераздан сырлы телогрейка җиңе белән күзләрен, битен сөртеп, Мотаһир алга — кайту ягына атлады. Станциягә җиткәндә аның каршына төчкерә-төчкерә бер машина килә иде. Ул Мотаһирны узып кына китүгә, сискәндереп, артта шартлауга тартым аваз ишетелде. Мотаһир кисәк туктап, артына борылды. Ләкин анда ераклаша баручы, аны шүрләп калырга мәҗбүр иткән әлеге калтырча машинадан гайре берни дә юк иде.

Алда, еракта, вокзалның бер катлы агач бинасы күренде. Мотаһир якягына карана башлады. Аны көтәсе кеше шушы тирәдә булырга тиеш. Әйе, әнә ул. Мотаһирның эченә җылы керде, адымын кызулатты.

Вокзалга җитәрәк аны якын танышы — Дубинин каршылады. Ул Владивосток кешесе иде. Аңа да ун ел бирәләр. Ләкин срогын тутыргач та, биш елга хокукыннан мәхрүм итү булганлыктан, ул шунда ук эшкә кала.

Мотаһир белән ничектер бик тиз танышып-дуслашып киттеләр алар. Менә шул Дубинин аңа беркөнне:

— Михаил Иванович, котылып чыкканнарны, гадәттә, вокзалдан кире бору очраклары бар, — диде.

— Ничек алай? — дип сорады Мотаһир аптырап.

— Әйтик, вокзалда синең янга гади генә киенгән берәү килеп утыра. Тегене-моны сораштыра. Провакацион сораулар бирә. Аннары, таныклыгын күрсәтә дә, НКВДга чакыра. Анда, тентеп, сорау алып, тиз генә суд ясыйлар да, кабат ябып куялар.

— Кеше срогын тутырган бит. Кулында кәгазе, вакытлыча бирелгән паспорты бар.

— Булса ни.

Мотаһир коелып төште.

— Миңа нишләргә соң?

— Без болай итик, — диде Дубинин тыныч кына, — син вокзалга барма. Үзем билет алам. Кая хәтле алыйм?

— Бөгелмәгә.

— Кайда ул?

— Татарстанда. Акча...

Дубинин аны бүлдерде.

— Соңыннан бирерсең. Мин сине вокзалдан ике-өч йөз метр читтә көтеп торырмын.

Менә хәзер шушы изге адәм аны юлда көтеп тора иде.

— Әйдә, читкәрәк чыгыйк, — диде ул Мотаһир килеп җитәр-җитмәс. Алар бер йортка ышыкландылар.

— Менә сиңа билет, илле бер сумлык.

— Рәхмәт инде, — диде Мотаһир, аңа акча санап бирде.

— Ашыкма. Монда торыйк. Поезд китәргә ун-унбиш минут кала гына кузгалырбыз. Вагонда бер почмакта утыр, сөйләшмә. Сиңа беркем дә кирәк түгел.

— Ярар.

Аннары Дубинин кайларда күчеп утырырга кирәген аңлатты. Монда да кисәтүне кирәк тапты.

— Вокзалда утыр. Беркая чыкма. Сөйләшмә. Тагын шулай поезд китәр алдыннан гына чыгып утыр.

— Ярар.

...Тагын поезд тәгәрмәчләре тек-тек, шык-шык итеп рельска бәрелә. Ләкин бу тәгәрмәчләр моннан ун ел элек Казан—Киров—Котлас поезды кебек хәвефле шакылдамыйлар, бүген боларның көе башка, җыры бүтән: өй-гә, өй-гә... и-рек, и-рек, кай-там, кай-там, кай-там...

Такы-токы ашау-эчү (билет алгач, аның бары ике сум акчасы калды), йокылы-уяулы төн үткәрүләр, көндезләрен тәрәзәдән карап бару, юл буендагы станцияләргә курка-өркә генә төшеп менүләр, бер поездан икенчесенә күчеп утырулар — барысы да томан эчендә кебек кенә, ярым саташулы хәлдә эшләнгән сыман. Кайта-кайтышка Мотаһир уйланды: «Менә ул колхоз дип җан атып йөрде. «Кошлар сайраса, урман ямьләнә, колхоз яшәсә, көннәр ямьләнә», — дип сөйләнгән чаклары әле дә хәтерендә. Ә нәрсә килеп чыкты?.. Ревкомиссия составына сайлаганда, гәрчә аның инде колхозга бәйләнешы булмаса да, каршы килмәде. Комиссиянең рәисе вазифасын да сыкранмыйча, теләп башкарды, вакытын кызганмады, сәгатьләр буе күз чекрәйтеп төрле кәгазьләр актарды, документлардагы саннарның дөреслеген тикшерде, чагыштырып карады, бәхәсләште, дөреслек хакын кайгыртты. Янәсе, исәп-хисапсыз колхоз — ишексез өй. Ә аны нишләттеләр? Ишекле йорт — баш фатир таптылар үзенә: тимер капкалы, чәнечкеле тимер чыбык коймалы, сакчылар кизү торган каланчалы «өй»гә яптылар. Тамырың черсен дип, эт көненә калдырдылар. Нигә? Ни гаебе бар иде аның? Кемнең юлына аркылы төште?.. Шулар эше генә, шулар...

Мотаһир, тәүлекләр буе, урам буенча көл җыйган чана кебек, һәр станциядә туктый-туктый кайткан поездларда башы тубалдай булганчы уйланды. Хәзер ул белә кемнәргә аркылы төшүен... Колхоз рәисе, завхоз... ике туган алар... Күрше авыл керәшеннәреннән торыпшалар алу, аларга урланган ашлык илтү, акча үзләштерү... Аңа янаулары... Элек игътибар итмәгән кайбер нәрсәләр... Бар да искә төшә хәзер.

Юлга чыгуының тугызынчы тәүлегендә Мотаһир Бөгелмә станциясендә поездан төшеп калды. Шахтада эшләп кайтучы зимагур түгел — каршылаучы юк. Шулай да күңеле күтәренке: үз җирендә диярлек бит. Вокзал бинасы, әйләнә-тирәдәге йортлар һәм бәс сарган агачларына тикле таныш. Кешеләрнең йөз чалымнары да күңелгә якын. Сагынылган үз халкың. Дөрес, сине беркем белми, сүз катмый, хәлеңне сорашмый. Ләкин хикмәт андамыни?! Кышның салкыны да ул хәтле сизелми. Бу — туган җирнең бер кыры, изге ватанның кадерле төбәге иде. Һавалары ук икенче бит аның! Сулыш алулары ук рәхәт! Монда югалмас ул, биредә Мотаһир — үз кеше. Электән таныш шәһәрнең урамнарыннан җәяүләп, кайту ягына юл тотты. Тау менеп, бераз җир киткәч, шәһәр читендәге бер катлы өйләр шактый артта калгач, аңа бәхет елмайды: җан биргәнгә җүн бирә тагы — бер атлы аны үз чанасына дәште.

— Абзый, кунакла әйдә.

Юлчы атын туктатмый гына Мотаһирга урын бирде, үзе түргәрәк күченде.

— Рәхмәт, — диде Мотаһир һәм кыстатып тормыйча печән салынган чанага тезләнде.

— Юлың еракмы? — дип сорады олаучы егет.

— Түгәрәк Күлгә.

— Шулай укмыни? Ишетә беләм. Юкәледә туганнар бар минем.

— Шуннан ерак түгел инде.

— Беләм. Түлке барганым гына юк.

— Ә үзең кая кайтасың?

Егет Бөгелмәдән ун-унбиш чакрымдагы бер авылның исемен әйтте. Аннары, борылып Мотаһирга текәлеп карады да, сорамыйча түзә алмады:

— Сугыштанмы дисәм... Сугыш беткәнгә...

Мотаһир көттереп кенә:

— Юк, үскәнем,— диде.— Ерактан...

Мотаһир тәфсилләп аңлатып тормады. Ләкин барыбер кайдан кайтуын әйтергә туры килде. Чөнки шактый ара бергә үтәсе бит.

Егетнең өстендә киң якалы мул толып, башында күн бүрек, аягында чүсинкә, кулында тирс бияләй иде. Ул мосафирның юка өс-башына карап алды да, атын туктатты.

— Абзый, әзрәк калкын әле.

Мотаһир аңа сәерсенеп карап алды да, карусыз гына чанадан төште. Олаучы түрдән, печән астыннан толып һәм зур киез итек тартып чыгарды.

— Мә, абзый, ки әле шуларны. Мин абыйны стансага илткәнием. Ки, ки, тартынма. Ерактан кайтасың икән шул... Барысын да күрә ир башы...

Бераздан ат кузгалды. Сүз дә үз җаена гына бара. Мотаһир җылыда, чанага йә тезләнеп алга карый, йә утырып, артка күз сала. Юл буенда бөкрәеп-кәкрәеп беткән карт-коры кебек бер якка янтайган салам түбәле өйләре, ярым җимерек каралты-куралары белән фәкыйрь авыллар кала. Бөлгенлек, мескенлек һәр ихатадан диярлек чекрәеп карап тора иде.

Мәрхәмәтле олаучыдан аерылып, ике-өч чакрым чамасы җәяү тер-келдәгәч, Мотаһирны тагын бер ат куып җитте. Артта эндәшкән тавыш ишетеп, Мотаһир карга бата-чума читкә чыкты һәм юл сапты.

Ләкин аның белән тигезләшкәч, ат туктады. Чанада бер генә кеше иде. Олаучы, илле яшьләр тирәсендәге сакал-мыеклы агай, Мотаһирга текәлеп карады. Күрәсең, читтән кайтучының чамасын тартып каравы иде.

— Кайсы авылга?

Мотаһир әйтте.

— Шулаймыни?! Мин анда хәтле кайтмыйм кайтуын, шулай да егерме чакрым утыртып кайтам. Күпме бирәсең?

— Акчам юк шул.

— Нисең бар соң?

— Бер пар аяк чолгавым бар.

— Кая, чыгар.

Мотаһир, чемоданын чанага куеп, чолгавын алып күрсәтте. Олаучы аны карады да җәһәт кенә куенына тыгып та куйды.

— Утыр. Түлке тау менгәндә төшәрсең. Ат бик өшәнгән.

— Ярар.

Кузгалдылар. Бераздан олаучы, нәрсәдер исенә төшкәндәй кисәк кенә сорап куйды.

— Син, агайне, каян кайтам дидең әле?

— Ерактан.

— Кәнкрит?

— Тегеннән... утырып кайтам мин.

— Шулаймыни? Ни урлап тотылдың?

— Нахак сүз белән.

— Ә, халык дошманымыни?! Юк, юк, агайне, бәладән баш аяк. Мә пүртәнкәңне, берүк ал тизрәк. Төш әйдә, төш. Атым да бик бетерешкән. Аллам сакласын. Минем башым бераү генә. Анысын да себердә черетәсем юк...

Мотаһир сүз көрәштереп тормады, аттан төшеп калды.

## XXVIII

Кичә һәм бүген җәяүләп алтмыш чакрым юл үтсә дә, Мотаһирның кәефе күтәренке. Шулай булмыйча соң, әнә бит алда аның туган авылы. Ул киң булып, таралып, сай сулы елга буенда ята. Мотаһир адымын кызу-

латкан саен өйләр дә аңа каршы кочагын җәеп, ашыгып килә төсле. И газиз җир, туган авыл! Менә мин, мин кайттым! Сине сагынып, бер күрергә зар-интизар булып кайттым. Яу кырында җиңү яуламасам да, мең бәлаләрдән котылып, сират күперләрен кичеп, сине, якыннарымны күрергә дип кайттым. Алып чабата каккан сөзәк тауларыңны, иксез-чиксез тугайболыннарыңны, төшләремдә күреп саташкан биек талларыңны сагынып кайттым. Алар барысы да үз урынында икән: таллар да, озын-озын урамнар да, зират та...

Тик авылдан бер-ике чакрымдагы каенлык кына юк. Аны сугыш вакытында утынга кисеп ягуларын Мөсәмирә язган иде инде.

Мотаһир авылга керде. Әнә җанга якын кешеләр — авылдашлары да күренә башлады.

Көянтә-чиләк аскан бер хатын юл аркылы чыгып бара. Күрде. Тик мосафирны танымады. Мотаһир да аны танып бетермәде. Шулай да борынгыдан килгән авыл гадәте, әдәп буенча аны сәламләде:

— Исәнмесез.

Хатын да сәлам кайтарды:

— Исәнме, абый.

Мотаһир ары атлады. Урамда өч-дүрт малай кардан тау ясап, шунда ду килеп, этешә-төртешә уйныйлар, әүмәкләшәләр иде. Чит кешене күреп, туктап калдылар. Мескен бүрек, изүләре ачык иске бишмәт, олтанлы киез итек кигән унике-унөч яшьлек олы күзле берсенә Мотаһир текәлеп карады да:

— Син кем малае буласың? — дип сорады.

Малай Мотаһир каршына килде. Ләкин... килде дә тукталып калды: ул бу мосафирны танымады.

— Мөсәмирәнеке.

Мотаһирның тыны кысылды.

— Улым!.. Әллә танымыйсың? Мин синең атаң булам, — диде һәм калтыранган кулын сузды.

Күрештеләр.

Йә хода, Мотаһирның бу шатлыкны күрер көннәре дә бар икән. Ул киткәндә сандык буе гына малай буй тарткан егет булып җитә язган! Нинди бәхет, нинди сөенеч! Мотаһир малайны күкрәгенә кысты.

— Улым, әниең өйдәме?

— Өйдә, — диде әле ятсынуы һаман бетмәгән малай.

Малайлар, гаҗәпләнеп Әгъдәскә «Улым», — дигән кешегә карап торалар иде. Әлбәттә, аларның берсе дә бу ят абзыйны танымый. Мотаһир аларга рәнҗеми дә. Аны танучылар бар, дөресрәге, булыр. Әнә малае капкадан башын тыгып:

— Әнкәй! — дип кычкырды.

Өйдән малларга дип ашлы су күтәреп чыккан Мөсәмирәнең капка төбендә ят кеше күреп, чиләге чак кына кулыннан төшеп китмәде. Ул аны җиргә куеп өлгерде. Өс-башын каккалап, шәл-яулыгын рәтли-рәтли капкага таба атлады. Ләкин урамга чыгып өлгерә алмады, бу вакытта ачык капкадан Мотаһир үзе кереп килә иде.

Сулуы капкан Мөсәмирә, бер сүз дә әйтә алмыйча, иренең күкрәгенә капланды һәм елап җибәрде...

Мотаһир хатынын кочаклаган. Ул аны күкрәгенә кыса, сыйпый, иркәли, юата. Ул аның таянычы, терәге. Әйе, хәзер бу өйдә хуҗа бар, ир-ат бар. Һәм Мотаһир дымлы күзләре аша ихатага карый. Бакча коймасы буена калыплап сугылган тирес кирпече өелгән (төньяктагы исәпсез-хисапсыз агач, утыннан соң моны күрү гаҗәп иде), аның өстенә ябылган кабыкны кар баскан. Үзе утырткан алмагачы күршеләрнең йорты биеклеге булган. Салам түбәле усак өй дә кечерәеп калган: зур ак бүрек кигән бәләкәй малайны хәтерләтә, тәрәзә яртылаш кадакланган, нигезгә кар өелгән.

Менә хатыны да юкарып, үсмер кызлар кебек кенә калган бит.

— Исән-сау әйләнеп кайттыңмы? Ни белән кайттың? — дип сорады, ниһаять, Мөсәмирә яшьле күзләрен, борынын сөртеп.

— Аллага шөкер, — диде Мотаһир хатынының күптән таныш һәм шул ук вакытта бераз ятрак та ягымлы тавышына колак салып. — Юл читен булмады. Әзрәген ат белән кайттым. Бер авылда кунып чыктым.

— Әйдә, өйгә керик.

— Әсләф улым кая соң? Өйдәме?

— И-и, ерак әбиләренә киткәндер әле. Кайтыр.

Мотаһир ишек алдына үтте.

Шулчак аның аягына эт килеп сарылды.

— Әй, Актүш, син исәнмени?! — диде Мотаһир шатланып һәм аңа таба иелде. Бу вакытта Әгъдәс капка яныннан читкә китеп бара иде.

— Улым, син кая?

Анасы дәшкәч, малай туктады.

— Уйнарга.

— Өйгә кер. Атаң кайтты бит.

Әгъдәс иренен турсайтып:

— Үз малаен танып иде әле әткәй булса, — диде. — Ату, сорый, син кем малае, дип.

Мөсәмирә коелып төште. Ялт кына борылып карады. Мотаһир ишетмәде бугай.

— Улым, үпкәләмә алай, — диде Мөсәмирә өтәләнеп, Әгъдәсне юата башлады. — Әйдә, өйгә кер. Соңрак чыгарсың. Сине ничек танысын инде ул? Син бит атаң киткәндә кашык сабы хәтле генә идең. Хәзер — егет булып киләсең. Кер әйдә, кер.

Малай теләр-теләмәс кенә кире борылды.

Мотаһир ишек төбендә хатынын көтеп тора иде. Әле һаман аннан күзен алмыйча торган эткә күрсәтеп:

— Таныды бит, — диде.

— Танымыйча. Хуҗасы кайтты бит.

— Мәче исәнме?

— Ие.

— Һаман да дуслармы?

— Гел бергә инде алар. Әйдә, әтисе, өйгә кер.

...Гаҗәп икән дөнья дигәнең. Әле кайчан гына лагерьның салкын барагында, каты нарда аунаган хокуксыз тоткын, кисәк кенә өенә кайтып, йорт хуҗасы булып түрдә утырсын, имеш. Аны үз итеп, аяк астына килеп яткан карт песинең җылысын тоеп торган Мотаһир, түшәм-сайгакның һәр ботагына, бүлмә такталарының һәр сызыгына кадәр таныш, үз кулы тигән әйберләренә күз сала, өйне күздән кичерә. Бары да үз урынында кебек. Ләкин ярлылык, сугыш афәтенең зәмһәрир суыгы, ятимлек, ул югында бу өйгә дә хуҗа булып алганнар икән. Ирс сугышта йөрсә, Мөсәмирәгә әзмекүпме җиңеллек килер иде. Болай... налогын да, башкасын да тулысынча, бура төбен кырып-себереп, сабыйлар авызыннан өзеп түләгәндер шул. Чәй эчәргә чынаяк та юк икән. «Булыр, алла боерса, — ди Мотаһир үзүзенә, — булыр. Тырышырмын, җан көчем белән тырышырмын.» Әйе, хәзер ул өйдә. Гаиләсе янында. Моннан китәме соң, үз илен, туган авылын ташлап китәме соң?! Юк инде, иптәш Кокашинский, чакыруыңа рәхмәт...

Алар калҗыраган өстәл янында, артсыз урындыкларга утырып чәй эчкән арада туган-тумача җыелды. Сөйләшү, сораштыру өзлексез дәвам иткән кебек, җиз самавыр да гөжләүдән туктамады. Өйгә шатлык иңде. Җылынып алган туганнары арасында, үз өендә утыру Мотаһир өчен бетмәс-төкәнмәс бәхет иде.

Ул әледән-әле хатынына карап ала. Мөсәмирә бәбәй итәкле алсу күлмәк өстеннән ак алъяпкыч бәйләп куйган, кешелеккә саклап тоткан яулыгын да сандыктан чыгарган. Мотаһир, яшәреп-матурланып киткән хатынына сокланып, аның булганлыгына, җитезлегенә сөенеп бетә алмый.

Атасыннан да бигрәк, әледән-әле аңа килеп сыенган Әгъдәс бәхетле иде. Ул хәзер аннан ятсынмый инде. Өйдә мәш килүләр, сөйләшү — болар берсе дә малайга кагылмый шикелле. Аның үз уе: «Минем дә әткәй бар. Моннан соң, нибучь мәктәптә дә кыерсыта алмаслар, урамда да...» Әйе, олылар белеп, бала-чага аңлап-төшенеп җитмичә «халык дошманы малае» дип рәнҗетмәсләр Әгъдәсне бүтән. Энесе дә моннан соң, әткәй юктыр ул, дип аптыратмас. Мескен булмаслар, башларын югары тотып йөрерләр. Әтисе, бәлки, әйбәтрәк чаңгы да ясап бирер әле. Әгъдәснең чаңгысы бар-барын, тик башы начар бөгелде. Анысы быелга әллә ярар да әле. Өченче көн кәшәкәсе сынды менә. Әй, анысын Әгъдәс үзе мәтәштерә инде, атасын йөдәтеп тормас. Яз җитеп, тау башы кардан арчылуга шәмәйле уйный башларлар. Бер-ике аткый да кирәк икән әле. Шулай да, атасы булгач, Әгъдәснең хафалары бермә-бер кимеде. Җәйгә чыксалар, «уфалла» арбасы тартып та чиләнмәсләр, аяклары да чебиләмәс. Бәлки, атасы күн итек тә алып бирер әле. Узган ел бабасы ясап биргән күтәрмәле чабатасы тузмаган әле тузуын... Энесенә аннан калган кием дә ярап тора инде анысы...

Әгъдәс шулай уйлап та бетермәде, энесе, Мотаһирның кече улы — ун яшьлек Әсләф кайтып керде. Ул ишек катында бер мәлгә генә тукталып калды да, килеп, сәкедә утырган әтисе белән сабыр гына күреште.

— Исәнме, әткәй.

— Исәнме, улым, исәнме...

Түм-түгәрәк күзле ун яшьлек малаен Мотаһир беренче мәртәбә күрә иде. Ул аны күкрәгенә кысты. Шатлыктан күзләрен йомды...

Бер мизгел эчендә күпме уй башыннан йөгереп үтте. Ун ел бит ул, ун ел... Йөрәк майлары эреп саркыды бит шуларны күрер өчен. Ничек чыдады икән йөрәге?! Ничек түзде икән бәгыре?!. Аннары, шушы сабыйны күрәсе килү теләге хәсрәтле көннәрен җиңеләйткәне исенә төште Мотаһирның, һәм аның бөтен барлыгын олы бәхет биләп алды... Ун ел буе аны тилмереп көткән, хыялында аның якты рәвешен тудырган сабый исә әле моңа ышанып та җитми иде. Аталы булуның бөтен асылына, мәгънәсенә төшенеп тә җитми иде шикелле...

Мотаһирның бертуган энесе Әсләфтән:

— Әтиеңне ничек таныдың? — дип сорады.

— Монда ят кеше берәү генә бит, — диде малай.

Моны ишетеп, Мөсәмирә сискәнеп китте.

Кичке якта колхоз рәисе Гайдул керде. Ул кесәсеннән кәгазь бөкеле (сугыштан соңгы елларда бүлеп сатыла торган аракы бар иде) ярты чыгарды. Ләкин очрашу салкын булды. Мотаһир, балалар алдында бик җәелеп китмичә, аңа үпкә белдерде.

— Арыш мае белән чылатып җибәтмәкче булдыңмыни мине? Бар, шешәңне ал да чыгып кит. Мин синең белән бер табынга утырмыйм.

Теге чыгып китте. Каруын кайтарырга теләгән Мотаһирның бу эшеннән бераз шүрләп калды Мөсәмирә. Ләкин ул ирен аңлый. Чөнки теге кәгазьгә Гайдул да кул куйган бит. Мөсәмирә, әлеге бәндәне куып чыгарганга бераз хафаланса да, ире кайтуы, аның да яклар кешесе булуы күңелендә горурлык хисе уятты. Хәзер аны теләсә ничек мыскыл итә алмаслар. Ләкин үзеннән дә бигрәк, ул китек күңелле нарасыйлары өчен сөенә иде.

Мөсәмирә йөзен җыерчык баскан, картайган иренә карады.

Кисәк кенә: «Бу улмы соң, алты колак, дүрт күз белән көткән иреме соң», — дигән уй йөрәген телеп алды. Кая аның куе коңгырт чәчләре? Кая көләч, яшь йөзе? Бер генә мизгел күңелен нидер тырнап үтте. Ләкин бу шундук ирен җәлләү — кызгану, элеккечә якын итү белән алышынды.

...Эңгер иңгәч, Мотаһир урамга чыкты, ихатаны күздән кичерде, бәрәңге бакчасына языл — мунча тирәсен карап, янә ишек алдына керде. Моннан ун ел элек ул киткәндә дә җылы иде, бүген, 1947 елның егерме тугызынчы декабрь көнне исә яңгыр ява. Әйе, кыш уртасында яңгыр

сибәли. Күз яшедәй тама да тама яңгыр. Әйтерсең, аның кайту шатлыгы булып күктән бәхет тамчылары иңә... Алай гына микән? Бәхет кенә микән... Монда ун ел хәсрәт эчендә иңрәгәннәрнең күз яше дә бар... Әйе, монда тугыз ел газиз балаларын көтеп тә, аны күрү бәхетенә ирешә алмыйча гүр иясе булган ата-ананың кайнар күз яшьләре дә, ун ел салкын түшәктә йоклап, ун ел буе тормыш арбасын берүзе сөйрәүдән ярты картайган, калак сөякләре суелып, куллары агач тамырыдай катып-сөялләнеп беткән ярым тол хәлендәге хатынның каһәрле күз яшьләре дә, ун ел буе үксезлекнең, атаң халык дошманы, дип мыскыллауның җәбере бәгырьләренә сеңгән сабыйларның рәнҗүле күз яшьләре дә коела. Ә Мотаһирның үзенең чиккән газаплары... Аларны күз яшенә әйләндерсәң, өч урамлы зур авылны су басар иде.

Бу яңгыр тамчылары «Ирегез батырларча һәлак булды» дигән кара язу тотып, дүрт баласын ничек туйдырырга белми аптыраган, илереп елаган сеңлесенең ачы күз яшьләре түгел микән?

Әлеге су бөртекләрендә, дошман ядрәсеннән авып, якты кояшка соңгы тапкыр карашын төбәгән, әх, янымда энем булса, авыр сулышларым җиңеләер иде, дип уфтанган ир туганының үкенечле күз яшьләре дә бардыр.

Мотаһир хат аша авыл хәлләрен белеп, күп хәсрәтләнгән иде. Ләкин монда кайткач, әти-әнисен төп йортта күрмәгәч, абыйсының юклыгын бөтен тулылыгы белән тойгач, энесенең гариплегән үз күзләре белән күргәч, коелып төште. Алдагы өмет нуры сүнеп калган шикелле тоелды.

Авылның Зәһлүл кебек йөзләгән гайрәтле ир-егетләре сугышта кырылган иде. Кайтканнарының да байтагы гарип-гораба, күбесе эшкә яраксыз... Сәхау шикелле хәбәрсез югалганнар — тагын күпме...

Янында гына аяк тавышы ишетеп, Мотаһир сискәнеп китте, ялт борылды. Хатыны аны эзләп чыккан икән. Кеше алдында тыелып-тартынып торган Мөсәмирә, ирәнә сарылып, елап җибәрде.

— Мотаһир, бәгырем!

Алар икесе бер җан, бер тән булып, тавыш-тынсыз гына бер-берен назладылар. Күпме газап чигүләрдән соң татлы кавышуның чынлыгына ышанмагандай, инде чын икәнен шәйләгәч, тагын аерылышу куркынычы янагандай, кабат-кабат бер-берәнә омтылдылар.

— Мөсәмирә...

— Мотаһир...

Күк йөзендәге, Түгәрәк Күл авылы өстендәге йолдызлар, көянтәчиләген аскан Зөһрә кызлы Ай, оялмагыз, читенсенмәгез, болытлар арасыннан чыгып карагыз! Бу бахырлар кабат беркайчан да аерылышмасын иде, Сак белән Сок кебек икесе ике тарафта тилмермәсен иде, дип теләк теләгез! Теләгегез кабул булсын! Чөнки алар бер-берәнә тугрылык саклаган, намусларын сатмаган, авыр газапларны күтәрә алган батыр йөрәкле изге кешеләр! Бүген аларның бәхеткә хакы бар! Ай-йолдызлар, сез бүген кавышу шатлыгының шаһиты булдыгыз. Алар бәхеткә ирешсеннәр, гадел заман кешеләренә тормыш бүләк итсеннәр...

— Мотаһир, — диде Мөсәмирә бераздан, — мин синең кулга алынасыңны төшемдә күрдем бит.

— Ничек?

— Үзебезнең бозауны чит көтүгә илтеп куштым. И-и шул көнне кайгыруларымны белсәң...

— Син әүлиядер.

— Аннары, сугыш вакытында, Мөхтәс абыйны да төшемдә күрдем. Ул беркавым хәбәрсез торды бит.

— Аны ничек итеп күрдең?

— Ике аягы да яна икән, имеш, берсе каты яна, икенчесе — әзрәк. Әнигә әйттем. Мөхтәс абый исән, мин әйтәм, түлке ике аягы да ранный, берсе — нык, берсе — җиңелчә. Шуннан озак та тормады, хаты килде, яралануын язган.

— Ә бүген ни күрдең? — дип елмаеп сорады Мөсәмирәсен күзе туя күрмәгән Мотаһир.

— Сине күрдем. Ап-ак күлмәктән икәнсең, аягыңда күн итек, баздан-мы, чокырданмы чыгып киләсең...

— Рәхмәт сиңа, Мөсәмирә, — диде күз төпләре кымырҗыган Мотаһир.

— Үзеңә рәхмәт.

— Миңа... ни өчен?

— Исән кайтканың өчен... И-и ходаем, сине күрер көннәрем дә бар икән... Күпме төннәрем керфеккә керфек какмыйча үтте бит минем...

## XXIX

Кайтуының өченче көнендә Мотаһир җәяүләп район үзәгенә китте. Ачы хатирәләрне яңартмас өчен, әгәр кодрәтеннән килсә, ул башка юл сайлар, йә анда бөтенләй бармас та иде. Әмма дөнья ул дигәнчә генә түгел шул... Моннан ун ел элек узган юлны аңа тагын кабатларга кирәк. Дөрес, ул чагында кич иде. Ә хәзер — иртә. Аны ашыктыручы да юк.

Мотаһир авылны чыкты. Менә зират. Анда әти-әнисе күмелгән. Аларның кабере биек тупыллар артында. Әнә теге сирень агачларыннан ерак түгел. Туганнары олылап, шартын-йоласын китереп җирләгәннәр. Тик Мотаһирның гына бу изге эшкә кулы тимәде, ата-анасы каберенә туфрак сала алмады... Хатирәләрдән, ачы хәсрәт сагышыннан авырайган башын югары тотарга тырышып, ул атлый да атлый. Еракта-еракта зәңгәр урманнар, аксыл таулар, калкулыклар күренә. Зәңгәр күк йөзенә кояш нурлары иңгән. Юл буеннан читтә таллар караеп күренә, әрем, кура сабаклары кар астыннан башларын тырпайткан. Алар тымызык җилдә талгын гына селкенәләр. Тояк эзе, сирәк-мирәк ат тизәге белән чуарланган юл бөрөзлексез алга бара: әле үр менә, әле түбән төшә, йә уңга, йә сулга борыла. Ап-ак кар күзне камаштыра.

Бу вакытта атлы да, җәяүле дә сирәк була. Хәер, очрасалар да Мотаһирның кешедә эше юк, ул ашыкмый гына атлавын белә.

Ялан кырда берүзе барган Мотаһир тагын уйларына чума. Кичә ул Ихсан картларга кереп чыккан иде. Шактый озак сөйләшеп утырдылар. Аны озата чыккан Ихсан абзый шунда Мотаһирга:

— Олан, сиңа бер сүзем бар, — диде. — Хатыныңа авыр сүз әйтмә. Дөнья булгач, төрле чак булыр, төрле имеш-мимешләр дә ишеттерүчеләр табылыр, ихтимал... Ышанма. Хатының ун ел буе дөнья нужасын тартты. Кайчагында күрәдер идем дә, шаклар ката идем. Карга кадәр генә хатын, мин әйтәм, ә җегәрле-көчле үзе. Тел озайта башлаган ир-атның түбәсенә менеп төшәргә дә күп сорамады... Бүтәннәр беләгеннән тотуга сыгылып төшә... Иң авыр эштә ул булды. Сабый-сабыйлыктан эшләп үскән шул. Аның анасы да ничә бала үстерде — бәләкәй арбасының кырые тузды, төбе тузмады... Сүзем шул, Мотаһир, рәнҗетмә син аны.

Менә бүген шул искә төшкәч, Мотаһир елмаеп куйды. Ун ел эчендә ничәмә-ничә тапкырлар күңел түрендә яңарткан танышу-кавышуларын янә бер исенә төшерде. Мөсәмирә белән ныклап тәүге очрашу-сөйләшү иде бу. Бу хәл аулак өйдә булды. Бер уенда Мотаһирга пар булып күрше авылдан килгән кунак кызы туры килде. Ул түгәрәккә чыкты да егетнең кулын тотты. Ләкин шунда ук тартып та алды һәм кычкырып:

— Абау, кулың күн кебек икән! — диде.

Мотаһир да ялынмады:

— Һәй, тотмасаң, — дип кенә куйды.

Аннары парга Мөсәмирә чыкты. Тартынып-нитеп тормады, егетнең кулын ныгытып тотты. Аның үзенең дә учлары кытыршы, каты иде. Ул үзе дә яшьли эшләп үскән кыз иде шул. «Кызык, әгәр кунак кызы кулын тартып алмаган булса? Аңа пар булып Мөсәмирә чыкмаган булса?» Ә туйда аларга атап җырланган җырны Мотаһир бик еш Мөсәмирәнең колагына

пышылдый иде: «Ишек алдым яшел чирәм, кемнәр арыш тараткан. Икебезне пар иттереп, безне ходай яраткан». Билгеле, аларга «икегезне пар иттереп, сезне ходай яраткан», дип җырлаганнар иде.

Нинди күңелле чаклар булган лабаса. Нәни генә җырдан да тәм табып, шатлана белгәнбез. Хәсрәтсез чаклар шул. Хәер, хәсрәтләре дә булмады түгел.

Мотаһирның һич онытасы юк әтисен суктырганны. Элек әйбер урлап тотылган кешеләрне урам буйлап кыйнап йөртү гадәте бар иде. Атасын тимер чыбык урлауда гаепләделәр. Югыйсә шушы Ихсан абзый әйтеп торды:

- Ул аны басуда, багана төбендә тапты.

Юк, тыңламадылар. Әлеге дә баягы шул Гайдулның атасы башлап йөрде. И гарьләнде Мотаһирның атасы, и гарьләнде анасы... Чөнки алар кешенең энәсенә дә тими торган кешеләр иде. Нахакка бирелгән җәза йөрәкләрен телде. Ә менә Мотаһир үзе ун ел ни өчен утырып чыкты соң?..

Уйлар, уйлар... Болын-тугайлар кебек очсыз-кырыйсыз, таулар кебек катлы-катлы алар...

...Ниһаять, менә ул ярым авылча, ярым шәһәрчә тормышлы район үзәгендә. Әллә ни үзгәреш сизелми. Ике катлы милиция бүлеге дә үз урынында — бәләкәй агач йортлар өстендә масаеп, кукыраеп, аларны сытып изәргә әзер булып утыра. Ерактан аны күргәч, Мотаһирның йөрәге дөп-дөп тибә башлады. Тагын... Юк, юк, ул хакта уйламаска кирәк. Аның документлары чиста. Ә шулай да шикләндерә: биек авыр капканы ачып кергәндә дә, текә баскычтан менгәндә дә... Монда да яхшыга үзгәреш юктыр сыман.

Хәер, бераз үзгәреш бар икән: дежурныйның күк зәңгәр төстәге кителендә йолдызлы погоннар. Ә калганы тагын шул элеккечә: портупеялы каеш, кобуралы наган, кырыс караш...

Тиешле бүлмәгә кереп, эшләрен бетергәч, ул паспортын калдырырга булды.

— Үзегездә торсын,— диде милиция хезмәткәре коры гына.

— Миңа кирәк түгел,— диде Мотаһир үҗәтләнеп һәм, саубуллашып, чыгып та китте.

Район сәламәтлек саклау бинасы каршында аны шуннан чыгып килүче берәү — каракүл якалы зәңгәр пальто кигән, мамык шәл бәйләгән хатын танып алды.

— Бәттәч, Мотаһир абый, кайттыңмыни?

Бу район хастаханәсендәге терапевт, Сәмигуллина фамилияле врач иде.

— Әйе,— диде Мотаһир аның белән күрешеп.— Исәнмесез.

— Исән, исән, безгә чурт булсынмыни,— диде хатын көлеп һәм аның кулын ычкындырмыйча йөзенә карады.— Син әллә эшкә керергә йөрисеңме?

— Шулайрак иде...

— Бик әйбәт, бик әйбәт.

— Алсалар. Белмим шул, алырлармы?

— Курыкма, Мотаһир абый, алырбыз.

— Минем бит бер документ та юк.

Хатын, Мотаһирның бик җәелеп китмичә, сабыр-тыйнак сөйләшүенең сәбәбен аңлаганга күрә, тезгенне үз кулына алды.

— Әйдәле, алайса, бергә керик. Анда хәзер яңа кеше.

Шулай дип, врач аны җилтерәтеп дигәндәй бина эченә алып кереп тә китте. Үзе җәһәт-җәһәт алдан бара, үзе Мотаһир белән сөйләшә. Мөдир кабинетына керергә дә куркып-өркеп тормады, рөхсәт-мазар да сорамады — ишекне каерып ачты.

— Менә, иптәш Вагыйзова, бер дигән фельдшер! Эшкә ал!

Мөдир, тулы гәүдәле, чем кара чәчләрен баш түбәсенә өеп куйган чибәр генә хатын, елмаеп җибәрде.

— Синең кешеңә генә булмас инде. Әүвәл таныштырыр идең...

Бераздан, үз кеше сыйфатында якын итеп, ул Мотаһирга эндәште.

— Яз гариза. Документың бармы?

— Юк. Паспортымны да милиция бүлегендә калдырдым.

Врач Сәмигуллина чәчрәп чыкты.

— Нинди документ ди ул?! Менә мин аны беләм! Иптәш Вагыйзова, аны әләкләп кенә утырттылар. Ул бик әйбәт эшләде...

Ләкин ул көнне эшен бетерә алмады Мотаһир. Өенә кайтып кунды да, иртәнчәк тагын район сәламәтлек саклау бүлегенә китте. Боерык язылганда Мотаһирга таныш түгел бер ир кеше бар иде. Ул әле кәгазьгә, әле Мотаһирга карап-карап алды да, сорап куйды.

— Әллә медицина хезмәткәреме?

— Әйе.

— Каян килдең?

— Килмәдем. Кайттым.

— Каян?

Мөдир бер-ике сүз белән генә аңлатып бирде.

— Иптәш Вагыйзова, син аны миңа бир,— диде таныш түгел кеше.

Хатын башын селкеде.

— Юк. Түгәрәк Күлдә медпункт ачабыз.

Теге адәм күрше авылдагы участок шифаханәсенең баш врачы икән. Ялынып караса да, аның үтенече кире кагылды. Шулай итеп, кулына кәгазь тотып, Мотаһир өенә кайтып китте.

Кайтышлый ул авыл советына сугылды. Председатель Сәгыйрь шунда иде.

— Әле генә райздравтан кайттым,— диде Мотаһир аңа.— Авылда медпункт ачам, йорт табыгыз.

Председатель аны юньләп тыңламады да, сытык чыраен тагын да караңгылатып, аскы иренен ялап куйды.

— Каян табыйк? Кәнсәләрдә буш йорт бар дип белдеңмени? Сиңа кирәк бит — тап.

— Миңа түгел — халыкка кирәк,— диде Мотаһир, ләкин бүтәнчә мәгънәсезгә сүз көрәштереп тормады. Председательнең дә исәбендә андый ният юк иде, ахрысы, ул, тел астына тәмәке салып, күзлеген киеп, өстәлдәге кәгазенә кадалды.

Өенә кайткач, Мотаһир хатынына сөенечле хәбәрне җиткерде. Анналары, чишенгәч, малайлары белән мәш килде. Аларның кышкы каникул чоры башланган иде. Кичке аш хәстәрләгән Мөсәмирәдән сорап куйды:

— Кемгә генә барып сүз катарга икән? Кертүче булыр микән?

Мөсәмирә җавапны озак көттермәде:

— Кадернисәтти белән сөйләшеп карыйм әле. Бик чиста карчык, үзе генә тора.

Кичтән барып сөйләште дә, иртән әлеге карчыкка өен юарга-чистартырга да китеп барды Мөсәмирә.

Шкафлар куеп, урамга язу элеп, дарулар алып кайткач, Мотаһир медпунктны ачып та җибәрде. Аңа иптәшкә районнан тагын бер фельдшер бирделәр. Икәүләп матур гына эшкә керештеләр. Халык йөри, халык канәгать иде.

Мотаһир көнозын медпунктта була. Әйе, көн димәде, төн димәде, эш өчен көеп йөрде. Чакырганнар янына минуты-сәгате белән барып җитте, авыр хәллеләрне район яки участок хастаханәсенә озатты, тиешле профилактика чараларын үз вакытында үткәрде. Ни өчен шулай тырыша соң ул? Бердән, табигате шундый. Икенчедән, ул үзенең фәкать медицина хезмәткәре булганы өчен генә исән калуын аңлый, шул бурычны түли. Өченчедән, ил-көн алдында бары намуслы эш белән генә абруй казана алуына ышана иде. Ләкин бөтенесе дә ул дигәнчә җай гына бармый икән...

Беркөнне Мотаһир эштә чакта, Кадерниса карчык өенә усаллыгы белән балаларның гына түгел, авыл халкының да котын алып торучы мәктәп директоры Әблиев керде.

— Апа, заемга язылыгыз,— диде ул эре генә һәм портфеленнән кәгазьләр чыгарды.— Дүрт йөз сум.

— Үскәнем, акча юк бит.

— Табарсыз! — дип боерды галифеле чалбар хуҗасы.

Карчык, ак яулыгының почмагы белән авыз тирәсен каплап:

— Юк, минем акчам юк,— диде.— Малайларым сугышта үлде.

Симез битле Әблиев тавышын бөердән чыгарып, тузына ук башлады, ачуыннан тирләп чыкты. Мотаһир бу бәндәнең кансыз икәнен, бала-чагага кул күтәрүдән дә тайчанмавын ишетә белә иде. Әблиевнең җәй көне мәктәп түбәсенә менеп, бинокльдән басудагы хатын-кызның тышка чыкканына кадәр карап торуын да, кесәләренә берәр уч ашлык салганнарын күрсә, каршы барып һәрберсен тентүен, аларны оятсызларча капшавын да ишеткәне бар аның. Ә заемга яздырганда ул бигрәк тә вәхшиләрчә кылана: хатын-кызны авыл советындагы тимер сандык өстенә утыртып төн кундыра торган була. Моны беркөнне Мөсәмирәсе ачынып сөйләде. Ул бичара да берничә сәгать салкын сейф өстендә утырган. Бәхетенә, бер укытучы керөп, директорны тирги башлагач кына чыгып китә алган.

Шуңа күрә, үз хәлен бик яхшы белгәнгә, ничек кенә ачуы чыкса да, бу имансыз белән телгә килмәүне хуп күрде Мотаһир. Шуны сизеп, Әблиев торган саен ныграк тузынды, ятимә карчык алдында гайрәт чәчте. Аның соңгы сүзе шул булды:

— Алайса медпункт моннан чыксын!

— Соң минем язылырга чутым юк бит. Әз генә кызган инде. Ирем дә юк. Үзем ач. Балалар да юк...

— Җитте,— дип кырт кисте аны директор,— герман пулеметы кебек аттырып торма. Знать не знаю! Медпункт моннан чыксын!

Һәм шул явызның боерыгына буйсынырга, ятимә карчыкны ай саен килә торган әз генә акчадан мәхрүм итеп, медпунктны икенче бер тол хатын өенә күчерергә туры килде.

Мотаһир район үзәгенә баргалап йөрсә дә, анда Коры Елгада һәм Алабугада бергә утырган иптәшләрен очратмады. Аларның үзләрен яки гаиләсен эзләмәде. Дөрес, ул алар турында еш уйланды. Фәлән абзый, Фәлән кеше дип, исемнәрен дә хәтереннән барлады. Кайсының Таллыктан, кайсының Якты Тау яки Кызыл Бакчадан икәнен дә белә иде. Әмма рәхимсез заман аны шулхәтле сак булырга, үз кабыгына йомылып яшәргә өйрәтте ки, әгәр дә ул аларның берәрсе белән очрашкан тәкъдирдә дә кайда, ничек утырулары хакында сүз булмаячак иде. Бу — шул чор өчен язылмаган закон.

Бервакыт, участок больницасына баргач, Юкаленең Асылмәрдән исемле кеше белән очрашты ул. Тегесе Мотаһирдан берничә яшькә өлкәнрәк, якын-тирәдә исеме таралган сунарчы кеше иде. Мотаһир аны көчкә таныды: түгәрәк сакалы ап-ак булган, күрер күзгә үзе дә нык таушалган.

Әлбәттә, күрше авыл кешеләре буларак, алар бер-беренең утырып кайтуын, хәтта бер тирәдә — Архангельск өлкәсендә җәфа чигүләрен дә беләләр иде. Әмма очрашканда сүз исәнме-саумыдан ары узмады. Узган гомерләр хакында ләм-мим сүз дәшмәделәр, ни дә булса сорашмадылар, лагерь хәлләрен искә алмадылар. Утыз җиденче елның шәфкатьсез кагыйдәләре әле булса саклана иде. Ә бит башка юл узган, әйтик, сугыштан кайтучылар әнә ничек бер-бере белән гәп кора, полкташлар бер-беренә кунакка йөрешә, кулында үлгән сугышчан дусларының гаиләсенә хәл-хәленчә булыша. Ә болар... Югыйсә, алар да кеше бит, аларның да җаны бар, лабаса...

Шулай да еллар уза тора. Тормыш барыбер үзенекен итә, алга бара. Сугышта имгәнеп-яраланып кайткан ир-егетләрнең байтагы җәрәхәтләрдән мантымаса да, яшьләр үсә тора, авылга килен дә төшә, Мотаһирга «мәшәкать ясап», бәби дә таба торалар. Хәтта илле өченең мартында даһи юлбашчыбыз, барыбызны да ятим калдырып, вафат булгач, яше-карты

үксеп еласа да, тормыш тукталмады. Киресенчә, ирек җилләре исеп, һавалар сафлана башлады. Әмма аның шаукымы бары алтмыш дүртенче елда гына Мотаһирның китек күңеленә шифасы белән килеп кагылды.

Берчак, район үзәгендә Мотаһирны очратып, врач Сәмигуллина аны, гадәтенчә, җиңеннән тотып туктатты да:

— Син, Мотаһир абый, яз әле,— диде.— Кул кулны белә, закон юлны белә дигәндәй, барып ирешсен.

— Кая? — дип сорады Мотаһир аптырап.

— Иң югарыга! Генеральный Прокурорга!

Куркып-өркеп яшәргә күнектерелгән Мотаһир башын чайкады.

— Ай-һай...

— Сизмисеңмени дөньяның кая таба баруын?! — диде врач ханым.

— Сизәм дә...

— Шулай булгач...

Врач Сәмигуллинага үзенең бөтен ораторлык осталыгын, хатынкыз үҗәтлеген җигеп, дәлилләр китереп, аны бик озак үгетләргә туры килде.

Ниһаять, Мотаһир тәвәккәлләде. Үзенең җинаятьче булмавына нык ышану, нахакка утыртылуы, гаепсезгә рәнҗетелүе — болар аңа теләсә кая язарга хокук бирә иде. Хәлбуки, бер генә төн үткәрмәде Мотаһир әлеге үтенеч язуын сырлап. Һәр сүзен-җөмләсен кат-кат уйлап, җиренә җиткереп язарга, закон белгән кешеләргә таянып озатырга кирәк булды.

...Ниһаять, аны авыл советына чакырттылар.

Карап торуга чибәр һәм мөлаем яшь кенә капитан иде Казан кунагы. Әмма бик таләпчән һәм җеген-җеккә китерергә тырышучы кеше булып чыкты.

Ул бик итагатьле генә күреште, портфеленнән бер кәгазь тартып чыгарды. Аны Мотаһирга укытты. Аннары сораулар бирә башлады.

— Сезне белә торган кемнәр бар?

— Авылда бөтен кеше белә инде,— диде аптырабрак калган Мотаһир.

— Конкретно?

Мотаһир байтак олы кешеләрне санап чыкты.

— Әтиегез кем? Нинди кеше иде ул? Гаиләгез ишле идеме?..

Мотаһир боларына да тулы җавап кайтарды.

— Сезне кулак дип язганнар. Атасы муллалар белән дус иде, дигәннәр. Мөтәвәлли булып торды, дигәннәр. Шул дөресме?

— Юк.

— Хөкүмәттән ат алгансыз.

— Юк.

Тикшерүче, әлбәттә, боларны үзе уйлап чыгармаган. Барысы да Мотаһир өстеннән язылган кәгазьгә теркәлгән нахак бәлаләр иде болар. Утырыш ясап, шунда сөйләнгән сүзләр итеп теркәлгән яла. Мотаһир өстеннән язган биш кешедән хәзер берәү генә калган. Гайдул председательлектән төшерелгәч, ферма мөдире булды. Гаиләсен ташлап, яшь хатынга йортка керде. Ләкин бәхете озакка бармады — өч елдан асылынып үлде. Салган баштан мордар китте. Калган өчесенең дә сөякләре күптән черегәндер инде. Исән калган бердәнбер кеше — Тавис Тарханов. Тикшерүче аны чакырып кертте.

Ул алтмышның өстендәге, чаларган сакал-мыеклы, озын гәүдәсе бөкрәя төшкән, нык таушалган кеше иде.

— Исәнмесез,— диде ул йомшак кына.

— Исәнмесез,— дип аның сәламен алды тикшерүче һәм Мотаһирга мөрәҗәгать итте:— Абый, сез күрше бүлмәгә чыгып торыгыз әле.

Мотаһир тикшерүче сүзен үтәде. Ләкин ярым ачык ишектән аңа барысы да аермачык ишетелә иде.

— Сезнең исем-фамилиягез?

— Тавис Тарханов атлы булам мин.

— Гражданин Тарханов, мин сезне кисәтеп куям: әгәр ялган мәгълүмат бирсәгез, ике елга кадәр иреккегездән мәхрүм ителәчәксез. Аңладыгызмы?

— Әйе,— диде Тавис карт.

Шуннан тикшерүче сорау алырга керешге.

— Туган елыгыз?

— Мең тугыз йөз дә алтынчы елның...

— Яхшы,— дип бүлдерде аны тикшерүче.— Сез Түгәрәк Күлдә тудыгызмы?

— Әйе.

— Шушы авылда тордыгызмы?

Карт тамак кырып алды. Аз гына каушый калды, ахры.

— Тордым.

— Кемнәрне беләсез?

— Ничек?

— Авылда кемнәрне беләсез?

— Соң, авыл кешесенең һәммәсен беләм инде. Бала-чаганы гына танып бетереп булмый.

— Сезнең авыл ниндирәк?

Карт тагын тамак кырып алды.

— Әллә тагы... Авыл — авыл инде ул.

— Яхшы. Ачыграк итеп әйтәм, төшендереп бирәм: байлар күп идеме авылыгызда?

— Юк. Күп түгел. Ике-өчтән артмагандыр. Әрхәметдин Хаҗи...

— Аңлашылды. Ә кулаклар?

Карт дәшмәгәч, тикшерүче соравын янә кабатлады.

— Кемнәр кулак иде?

— Алары да күп түгел.

— Фарукшин Мотаһирны беләсезме?

— Беләм.

— Атасы кем иде?

— Гади крестьян.

— Гаиләсе зур идеме?

— Ишле.

— Үзе нинди кеше иде?

— Болай... Әйбәт кенә кеше.

— Мал-туар?

— Атасыныңмы?

— Әйе.

— Ат, сыер, сарыклары бар иде бугай. Хәтерләмим дә инде.

Картның башта шактый көр чыккан тавышы отыры юашлана төште. Утырган урындыгы да шыгырдап куйды. Әледән-әле тамак кыргалап ала.

— Фарукшинны ни өчен утырттылар?

— Белмим тагы... Тәгаен генә әйтә алмыйм. Ул заманда бит төрле имеш-мимешләр йөрде инде...

— Яхшы. Аны «халык дошманы» дигәннәр түгелме соң?

— Гөнаһысына керә алмыйм, ни дип тә әйтә алмыйм.

— Аны кемнәр утырткан?

— Белмим.

— Яхшы. Аңлашылды,— диде тикшерүче сузып кына һәм, урыныннан торып, Мотаһир утырган бүлмәгә дәште:— Абый, керегез әле.

Тикшерүче Мотаһирга таба күрсәтеп, Тавис карттан сорау алуын дәвам итте.

— Бу кешене беләсезме?

— Беләм,— диде Тавис Тарханов һәм су эчкәндә тончыккандай ютәлләп куйды.

Тикшерүче өстәл янына килде, аннан саргылт кәгазь бите алды.

— Ә менә бу кәгазь сезгә танышмы?

— Юк.

Картның чатнатып һәм бик тиз җавап бирүенә Мотаһир хәйран калды. Бу вакытта тикшерүче иң мөһим ноктага килеп җиткән иде. Ул кәгазен тотып, Тавис картның йөзенә якын ук китерде һәм төртеп күрсәтте:

— Менә бу кем имзасы?

Ләкин карт күзен дә йоммады һәм шактый катгый итеп:

— Минем имза түгел,— диде.

Моны ишетеп, Мотаһир ачудан чак кына кычкырып җибәрмәде. Ләкин хәлне тиз төшенде. Тикшерүче дә бу очракта үзенең көчсез икәнен аңлады: донос язучының уң кулы сугышта өзелгән, чагыштырып карап булмый. Тикшерүче аны чыгарып җибәрергә мәҗбүр булды.

— Рәхмәт. Китәргә мөмкин,— диде ул Тавис Тархановка карамыйча гына.

Тавис карт кергәндәге кебек куркып-өркеп түгел, ә нык тавыш белән:

— Исән булыгыз,— диде һәм Мотаһирга күтәрелеп карамыйча гына чыгып китте.

Капитанның Мотаһирга сораулары бетмәгән икән әле.

— Сез Викулов дигән кешене белә идегезме?

— Районда НКВД начальнигымы?

— Әйе. Димәк, беләсез.

— Миннән сорау алучыларның берсе шул. Аны белмәвең хәерлерәк.

— Ихтимал,— диде кунак Мотаһир белән килешеп.— Ә хәзер кайда икәнен белмисезме?

— Юк.

— Ярый, рәхмәт,— диде тикшерүче һәм кәгазьләрен караштырды.— Төп эшкә күчик. Кәефегез ничек? Арымадыгызмы?

— Юк.

— Сез, сугышка җибәрегез, дип помилование биргәнсез. Ни өчен алмадылар?

— Хәрби заводта эшләдек.

— Анда ни эшләделәр?

— Белмим. Утын ташыдык, яктык...

— Нәрсә ясадылар?

— Белмим.

— Пропускагыз булган бит.

— Ә ул тышка йөрер өчен генә.

Гәрчә ул заводта целлюлозадан дары ясасалар да, Мотаһир аңа бар белгәнен дә әйтмәде. Хәрби серне чишәргә хакы юк иде.

Теге бөтен нәрсәне үзе белән алып килгән икән.

— Сез гариза язгансыз икән? Үзегез яздыгызмы?

— Үзем.

— Менә бирегә язып карагыз әле.

Мотаһир, тикшерүче сузган кәгазьгә, мондый сүзләр язып куйды: «Мин, Фарукшин Мотаһир, Түгәрәк Күл авылында яшим».

Тикшерүче Мотаһирны байтак тинтерәткәч, килүенең төп сәбәбен әйтте.

— Болар барысы да эшне Верховный Судка куяр өчен кирәк.

Өч айдан Югары Судтан кәгазь килде. Анда болай язылган иде: «Фарукшин Мотаһир эше буенча Суд коллегиясе мондый карарга килде: җинаять составы булмау сәбәпле, эшне туктатырга. 22 февраль, 1964 ел».

## XXXI

Авылда аның үзенә, гаиләсенә караш та отыры үзгәрә башлады. Үз эшен җиренә җиткереп кенә түгел, ә таләпчәнлек һәм үҗәтлек белән дә башкара иде Мотаһир. Билгеле, бу кайберәүләргә ошап та җитми.

— Абый, безнең күрше Гөлҗәһирә апа чирләгән,— диде бер егет аны өйалдына чакырып чыгарып.

Мотаһир иңенә пинжәк кенә салып чыккан иде, ишектән кергән салкыннан, ачы җилдән куырылып куйды.

— Нәрсә булган, үскәнем?

— Эче авырта бугай. Миңа кызлары гына кереп әйтте. Атасы да өйдә юк икән.

— Ярар, барырмын,— диде Мотаһир һәм, өйгә кереп, җыена башлады.

Өстенә башлыклы кожан, аягына кирза итек, бер кулына иске сумкасын, икенчесенә озын таяк тотып, Мотаһир урам буйлап китте. Көчле җил агач башларында улый, ыжгыра, түбә калайларын шапылдата, аяк астындагы су лачтыр-лочтыр килә. Тигезле-тигезсез урамнан барганда аның сукыр кешенекедәй әле бер, әле икенче аягы чокырга төшеп-төшеп китә. Тыкрыкка борылгач, күзгә төртсәң берни күренмәс булды. Шулай да ул үзенә таныш юлдан атлавын дәвам итә.

Көч-хәл белән авыруның өенә барып җитте. Керде. Өс-башын салды. Унбер-унике яшьлек кыз бала Мотаһирны олы яктагы әнисе янына дәште.

— Абый, керегез.

Карт фельдшер кыз биргән урындыкка, авыру караваты янына утырды.

— Нәрсә булды, үскәнем?— дип сорады ул аның йөзенә карап.

— Эч бора, Мотаһир абый,— диде хатын чыраен сытып, тартынып кына.— Костым да.

— Шулаймы? Кайчаннан бирле авырта? Алай икән. Яле, карыйк әле. Тартынма. Менә шулай. Авыртамы?

— Юк.

— Болай?

— Әйе.

— Хәзер?

— Авырта.

— Ярар,— диде Мотаһир һәм эчтән генә, болай икән бу, дип куйды.— Бик борчылма, үскәнем. Аппендицит булырга охшый. Машина тапсам, больницага илтермен.

— Абый, монда гына үтмәсме?— диде хатын тилмереп.— Аталары да өйдә юк...

— Белеп булмый бит. Шулай да анда баруың хәерлерәк. Балалар янында кеше калмый дисәң, күршегездәге берәр карчыкка кереп әйтермен.

— Юк, абый, син йөрмә. Әнә кызым гына керер.

— Ярар алайса. Мин машина белешим.

Мотаһир машина эзләп китте. Колхоз рәисен йөртүче шоферны өендә очратып бик сөенде.

— Тәзбир, Гөлҗәһирә апаң чирләгән, Юкәлегә больницага илтик әле,— диде Мотаһир йомшак кына.

— Бармыйм,— диде шофер кырт кисеп.— Көне буе персидәтел көен көйләп тә туйган. Әле генә куйдым машинаны, кайтып кына кердем.

Мотаһир аны юмалап та, оялтып та карады, әмма ризалата алмады. Аптырагач, чыгып китте һәм рәиснең өенә юнәлде.

Аны рәиснең хатыны каршылады.

— Әйдә, абый, кер.

— Рәхмәт, керә тормыйм. Нәүфәл өйдәме, үскәнем?

— Ул ни... абый, ышерен-батырын түгел инде, «чирли». Нигә кирәк ие, абый?

— Гөлҗәһирә авырый. Юкәлегә илтергә кирәк.

— Алай икән,— диде председатель хатыны сузып кына.— Абый, әйт Тәзбиргә, барсын.

Мотаһир, ярар дип тагын караңгыга чыгып китте.

— Үскәнем, Тәзбир, председатель чирли.

— Беләм,— диде ашап утырган шофер дорфа гына һәм ризык чәйнәвен белде. Мотаһирның чыгып китәргә җыенмавын күреп, өстәл астына яшергән шешәне дә тартып чыгарды.

— Хатыны аның исеменнән әйтте, барсын, диде.

— Ни фәләнемә миңа аның хатыны сүзе?! Бармыйм!

Мотаһир әле кулына стакан тоткан йорт хуҗасына, әле аның сүз әйтергә куркып басып торган хатынына карады да, дәшми-нитми чыгып китте. «Акыл ияи белән керми шул».

Эзләп тапты партоешма секретарен. Аңлатты.

— Ярар, абый, барыр,— диде итагатьле партком секретаре һәм, өстәл янына барып, тиз генә язу язып бирде.— Тәзбиргә бирегез.

— Рәхмәт.

Саз ерып тагын китте шофер өенә. Мотаһир бу юлы да аны тыңлата алмады.

— Бу персидәтел язуы түгел,— диде шофер кәгазьгә күз төшереп алгач.— Мин персидәтелне йөртәм, партком секретарен түгел. Миңа акчаны персидәтел түли. Бармыйм.

— Туктале, үскәнем, кеше авыр хәлдә...

— Нәрсә син миңа бәйләндең әле? Минем таң тишегеннән торып эшкә китәсем бар. Ат җик тә илт. Канса канис, минем кеше төсле ял итәргә хакым бармы, юкмы?

Бу юлы шоферның хатыны да телгә килде.

— Тәзбир, бар инде. Ялан-ялан олы кешене йөртмә.

Мотаһирның да ачуы чыга башлаган иде инде.

— Мин нәрсә... Анда кеше чирли.

— Бармыйм,— диде теге һаман үҗәтләнеп һәм хатынына җикерде:— Ат дагалаганда бака ботын кыстырмый. Бар, урыныңны җәй!

Монысына инде Мотаһир чыдап тора алмады. Ул да тавышын күтәрде:

— Шулаймы? Бармыйсыңмы? Алайса, энем, иртәгә прокурорга барырсың.

— Нәрсә син мине прокурор белән куркытасың? Ул сиңа тансыктыр...

Шофер сүзен әйтеп бетерә алмады, хатыны кычкырып җибәрде:

— Тәзбир! Оятың кая?!

Мотаһир ачуын эчкә йотты һәм:

— Мин Гөлҗәһирәне сакларга киттем,— диде дә өйалдына чыкты.

Ул калтыраган бармаклары белән караңгыда ишекне кармалап тапты, ихата уртасында караеп күренгән машинага карамаска тырышып, бәләкәй капканың бисен шакылдатып ачты, тагын әлеге дә баягы озын таягына — ышанычлы юлдашына таянып, урам буйлап китте. Аның чигә тамырлары сулкылдый, йөрәге дөп-дөп тибә иде. Ләкин күбесе тирән, татлы йокыга талган авыл халкы карт фельдшерның дөньяның ачысын-төчесен күреп тузган-таушалган йөрәк тибешен ишетми. Аның бөкрәя төшкән юка гәүдәсен дөм караңгыда шәйләүче дә юк иде. Гүя бөтен галәмдә Мотаһир берүзе калган.

Ул авыруның өенә кереп чишенергә дә өлгермәде, урамда машина яктысы уйнаклады, гөрелте ишетелде...

Юкәлегә барып җиткәндә төн уртасы иде инде. Дежур врач, авыруны карагач, Мотаһирга:

— Әгәр төнгә калдырсагыз, үлер иде,— диде.— Операция ясыйбыз.

...Булды, әйе, булды андый хәлләр дә. Байтак алар саный китсәң. Әнә шулай көн арты көннәр уза тора. Кемнәр беләндер ачылышлы булырга да туры килә. Әмма барыбер Мотаһир үзенең изге эшен намусына хилафлык китерми дәвам итә, кешеләр өчен дип тырыша, шуннан тәм таба иде. Ләкин рәхәт белән михнәт янәшә йөри икән. Өч елдан ул чирләп аяктан егылды һәм... аның дөньяда бар икәнен дә оныттылар. Бары сиксәннең өстенә чыккан Ихсан карт кына, лыштыр-лыштыр кәлүшен сөйрәп, таягы-

на таянып, Мотаһир янына көн дә кереп хәлен белгәләде. Ул аны йомшак, ягымлы тавышы белән ипләп кенә юатты:

— Иншалла, Мотаһир, терелерсең... Үзең духтыр кеше, үз сырхавыңны беләсеңдер инде. Алып узган булса гына дәваның файдасы тими. Әле менә беркөн Нигъмәт бик кыстагач, үзем дә Коры Елгага, бульниска барып кайттым. Энә күзеннән үткәрделәр инде, кертмәгән кәбините, күрсәтмәгән брачы калмады. Берсе көлә, бабай, син бер дә таушалмагансың әле, карчыгың карыймы, киленнәреңме, ди. Карчыгым күптән гүр иясе, мин әйтәм, киленем карый. Бик әйбәт кеше икән киленең, ди теге духтыр. Әйе шул, мин әйтәм, үзе әйтмешли, сөйләп бетерерлек түгел, чуар кыягазга гына төрешле, дим. Көлештеләр. Шулай да берсе, бабай, бирәр дару бирикме соң, ди. Баш тарттым. Брачның бер төймәсен капканым юк, хөкүмәтнең укылын кадатканым юк, мин әйтәм, рәхмәт. Тагын көлештеләр. Сине әйтәм әле, Мөсәмирәң бик уңган, тырыш, болай озак ятарга ирек бирмәс.

Ихсан карт шактый озак утырып, Мөсәмирә куйган самавырдан берике чынаяк чәй дә эчеп, Мотаһирның күңелен күтәреп китә иде.

Бер керүендә ул:

— Карале, Мотаһир, сине атаң, бик зиһенле бала, дип мактый торганые,— диде.— Сабакташларыңнан да ишеткән бар ул сүзне. Әз-мәз менә боларны укыштыр әле. Дөнья хәлен белеп булмый, безнең хәзер алга таба түгел, гомер башына гомер ялганмый. Бездән соң да бала-чагага исем куясы, яшь-җилкенчәккә никах укыйсы, үлем-җитем булса, йоласын китереп, җирлисе булыр.

Ихсан карт аның кулына гәҗит белән тышланган иске китап тоттырды.

— Нәрсә бу, Ихсан абый?

— Үзең карарсың...

Бераз хәлләнгәч, район хастаханәсенә китте Мотаһир. Тикшерделәр, Ихсан карт әйтмешли, энә күзеннән үткәрделәр.

Әлеге дә баягы Сәмигуллина:

— Әй абый, иң белән генә түгел шул, йөрәгең белән күтәргәнсең дөнья нужасын,— диде.— Күргәнсең күрмешне. Йөрәгеңә авырлык килгән. Синең кан басымың югары. Бу эшеңне ташлап, физик хезмәт белән шөгыльләнәсеңме әллә?

Әйтергә генә ансат. Хәзер, медпунктта егерме ел эшләгәч, ничек эш алыштырасың. Пенсиягә чыкса гына инде. Мотаһир баш врачка керде.

— Богдан Гаврилович, чирлим әле. Нишләргә икән?

Җавап кыска булды:

— Син өч айга түләүсез ял ал.

Мотаһир райсобеска китте, пенсиягә чыгаруларын сорады.

Анда:

— Әгәр теләсәң — чык,— диделәр.

Тагын баш врачка керде.

— Богдан Гаврилович, син миңа, картлык буенча, дип яз.

— Алты айдан соң килерсең.

Ләкин Мотаһир бармады. Алтмыш яше тулгач та ярты ел эшләде һәм алтмыш җиденче елның алтынчы гыйнварында гына пенсиягә чыкты. Шулай да аны гел онытып бетермәделәр, сирәк-мирәк авырулар янына дәшкәләделәр.

Әнә шундый дәшүләрнең берсендә, шул ук елның ахырында, Мотаһир Тавис Тарханов белән дә очрашты. Хәер, бер авылда яшәгәч, ул аның белән күрешкәләп тора иде. Ләкин монысы икенче төрлерәк һәм Тавис Тарханов өчен бик кысен чакта булды.

Яңа ел киче иде. Авыл өйләрендә утлар балкый. Һәр җирдә шатлык: берәүләр кунак чакырган, икенчеләре үзләре барган, туган-тумача, таныш-белеш бәйрәм табынына җыелган; нур өстенә нур дигәндәй, ул өйләндереп, кыз биреп, туй ясаучылар да бар.

Мотаһирларның да ишегалдында берничә чана, кошевка, алты почмаклы өйнең тәрәзәләре гөлт иткән, гармун, җыр тавышлары урамга ук яңгырый. Мотаһир кече малаен — Әсләфне өйләндерә.

Мәҗлеснең иң кызган чагында, олы якның ишеген чак кына ачып, Мотаһирга кызы дәште:

— Әткәй чык әле.

— Нәрсә бар? — дип сорады ул чыккан уңайга, аннан соң гына Тавис Тарханов малаен күрде.

— Әнә, атасы чирләгән, — диде Мөсәмирәсе теләр-теләмәс кенә.

Тавис Тарханов малаен күргәч, Мөсәмирәнең йөзе үзгәргән иде, әлбәттә. Башка берәр үсмер булса, ул аңа бәлеш, йә ит кисәгеме, конфетпрәннекме тоттырган булыр иде. Ләкин Тавис малаена әйбер бирергә кулы күтәрелмәде. Мәҗлес булмаса, ул аны, бәлки, абыең өйдә юк, дип борып та чыгарган булыр иде. Бүген, туй көнне, картның өйдә юклыгына ышанмас.

Тарханов малае тотлыккан кешедәй сөйли башлады:

— Әнкәй, Мотаһир абыеңны алып кил, диде. Әткәй каты чирли. Сөйләшә дә алмый. Йөрәге ниткән, приступ.

Мотаһирның йөзе җитдиләнде. Ул Тавис Тархановның авыруын белә. Әгәр тиз генә укол кадамасаң, йөрәк приступыннан үләчәк.

— Мин пенсиядә бит, ускәнем, — диде ул. — Медпунктта эшләүчеләрнең өенә барырга иде.

— Берсе дә өйдә юк.

— Нишләп, кайда алар?

— Фәридә апа районнарына кайтып киткән, Гөлнур апа Юкәледә кунакта, ди.

Мөсәмирә малайга:

— Абыең бара алмас инде, ускәнем, — диде. — Кунак ташлап...

Малай еламсырап ишеккә борылды.

Мотаһирның кече кызы әтисенә карады.

— Әткәй, әллә бармыйсыңмы?

— Тик кенә тор! — диде аңа әнисе.

Мотаһирның башыннан төрле уйлар йөгереп узды. Кайчандыр аны Тавис гаиләсеннән аерган иде. Ничәмә-ничә еллар Мотаһир — малайларын, ә алар әтиләрен күрергә зар булып тордылар. Ничәмә-ничә еллар алар ятимнәр хәлендә яшәделәр, «халык дошманы» баласы дигән хурлыкны күтәрергә мәҗбүр булдылар. Менә хәзер Тавис үлем хәлендә. Мотаһирга мәңге онытылмаслык этлек эшләгән кешеләрнең берсе кабер якасында. Язмышы кыл өстендә. Аның да балалары бар. Менә — кечесе, тегеләре — зурлар. Тавис үлсә, алар ятим калачак. Аталарының этлегендә аларның ни гаебе бар? Юк...

— Тукта, ускәнем, — диде Мотаһир башын күтәреп. — Хәзер барам.

Мөсәмирә аптырап калды.

— Ул синең мәңгелек дошманың! Шуның аркасында ун ел төрмәдә черегәнеңне оныттыңмыни?! Минем күз яшьләрем төшкән аңа.

Мотаһир кызыннан пинҗәген сорап алды.

— Әгәр аны шул хәлендә калдырсам, бармасам, кешеләр күзенә ничек күренермен? Мин — врач. Мин фәкать шушы һөнәрем аркасында гына тегеннән исән кайттым. Кызым, бар, Әгъдәс абыеңны дәш.

Мотаһир олы малаена хәлне аңлатты.

— Мин озак тормам. Табынны үзең кара.

— Әткәй, борчылма, — диде Әгъдәс һәм янә олы якка кереп китте.

Мотаһир өстенә тун, башына бүрек киеп, кулына кызыл хачлы кечкенә иске чемоданын тотып чыгып киткәндә өй эченнән һаман җыр, гармун тавышы ишетелә иде.

Мотаһир юл буе уйланып барды.

Ул чагында да бүгенге кебек кар сибәли, ял көне иде бит. Яңа елга да күп калмаган иде. Әмма Мотаһир гаиләсе белән очрашканчы бик күп Яңа

еллар килде. Ул беренче тапкыр күргәндә икенче малае Әсләф инде укырга йөри иде...

Менә шундый уйлар белән Мотаһир тыкрыктан уңга борылды һәм биек коймалы, тимер торбалар утыртып эшләгән «комсомол» капкалы ихата каршысында туктады. Ул, бәләкәй капканы ачып, эчкә узды. Каршыда калай түбәле таш келәт, аның ишек төбендә эт оясы, уң кулда рубероид белән ябылган абзар-кура, бакчада карлыган куакларының кар астыннан башлары гына тырпаеп тора, сиртмәле коеның чиләгенә һәм чылбырына боз каткан. Сулда калай түбәле, алты почмаклы, пыяла верандалы зур йорт. Өй түрендә тагын бакча, дистәгә якын умарта ояларының башлары чак-чак беленеп тора, арырак калай түбәле ак мунча. Мотаһирның боларга, бәлки, күзе дә төшмәс иде, ләкин аның бу ихатага инде бик күптәннән аяк басканы юк. «Көнбагыш, бал сатып, элегрәк Пермьнән тегесен-монысын алып кайтып, соңгы елларда өендә аракы сатып, бу үзенең оясын ярыйсы ныгыткан икән»,— дип уйлады ул өйгә узганда.

— Исәнмесез.

Тавис Тарханов хатыны өтәләнеп каршы алды аны.

— Исәнме, Мотаһир абый. Сине борчыдык инде, туй мәшәкатегез дә бар иде бугай. Менә атасы чирләде бит көтмәгәндә.

Мотаһир, өс-башын салып, койкада яткан авыру янына килде. Башка вакытта урамда очрашсалар, башыннан салкын су койган кебек була, бөтен тәне калтырап китә иде. Исәнләшмичә китү уңайсыз булганга, моңа ни дип әйтим икән, дигән уй борчый иде. Бүген нигәдер карт фельдшер бу халәтне кичермәде.

Тависның йөзе ак, борын яфраклары киңәеп, еш-еш сулый, күзләре йомылган, кайтарып сүз әйтә алырлык түгел.

Фельдшер аның пульсын капшап карады һәм башын чайкап, болай икән бу, дип куйды. Чемоданына үрелеп, шприцны алды. Авыруның күлмәк җиңен терсәктән югары җыерып, укол ясаячак урынны спирт белән сөртте. Укол кадады. Бер кулы белән пульсын тотты һәм йөзенә карап, көтеп тора башлады.

Авыруның кан тамырлары сизелер-сизелмәс кенә тибә. Бераздан иреннәренә кызыллык йөгерде һәм күп тә үтми, ул күзен ачты. Янында Мотаһир торганын күреп, исе китте.

— Авыргансыз икән, хәлегез хәзер яхшыланды,— диде фельдшер.

Тавис Тарханов уңайсызланып, әкрен зәгыйфь тавыш белән, рәхмәт, дип кенә әйтә алды. Карт фельдшер дәшмәде. Әйберләрен җыеп, кулын югач, хуҗа хатын аңа сөлге бирде.

— Мотаһир абый, рәхмәт инде. Сине борчыдык. Чәй эчеп китәрсең. Менә куйган самавыр, аш та, бәлешләр дә әзер.

— Рәхмәт.

— Мәңге онытмабыз бу яхшылыгыңны, Мотаһир абый. Балаларны сөендердең, әтиләрен үлемнән йолып алдың. Мең рәхмәт сиңа.

Карт фельдшер дәшмәде.

Тавис Тарханов көч-хәл белән:

— Мотаһир,— диде,— барысы өчен дә кичер мине... әгәр булдыра алсаң.

Фельдшер аның сүзләренә артык игътибар бирмәде.

— Сезгә тынычлык кирәк, сөйләшмәгез.

— Юк, зыянлы түгел. Мин үземне беләм. Бүген аңлашмасак, башка вакытта сөйләшеп тә булмас. Мотаһир, бәхилләә мине, әгәр булдыра алсаң,— диде Тавис Тарханов, янә баягы сүзләрен кабатлап.

Авыруның сүзләре бары хәзер генә бөтен мәгънәсе белән карт фельдшерның аңына барып җитте. Менә нәрсә сорый икән ул. Мотаһир шарфын ураган җирдән туктап, аның йөзенә текәлеп, күзләренә карады. Элекке кебек гайрәт чәчеп торган Тавис түгел иде бу. Картайган, сакал-мыек та чаларган, чәчләре дә агарган. Ә күзләрендә әле һаман да элеккеге комсызлык, көнчелек һәм тагын, шайтан белсен, ниндидер ят нәрсәләр чагылган

төсле. Тик бу минутта аның әйткән сүзләренең ихласлыгына ышанмау мөмкин түгел иде. Менә бит ул тормыш дигәнең. Теге чакта ул үзенең Мотаһир кулына калачагын, аның яшәү-яшәмәвен берәр вакыт Мотаһир хәл итәчәген уйлап та карамагандыр.

Ул вакытта Мотаһир, ревкомиссия председателе буларак, утыз тиенлек бөятләрне документлаштырганда өчәр сумнан керткән һәм Камышлы керәшеннәреннән торыпша алганда урланган ашлык илтеп, колхоз акчасын үзләренә калдырган өчен, аннары тагын байтак гаеп-кыеклары өчен завхоз Тавис Тархановны һәм аның колхоз рәисе булган абыйсын колхозның отчет-сайлау җыелышында бик каты тәнкыйтьләп чыккан иде. Тегеләр исә Мотаһирны җәһәннәмгә төртеп төшерделәр. Хәзер шул бәндә гафу итүне сорый.

— Юк, Тавис, үлгәндә дә бәхил түгел. Син минем башымны ашадың. Анда чиккән җәфаларымны үзем беләм дә, бер алла гына белә...

Авыр тынлык урнашты. Тавис та, хатыны да фельдшерга текәлделәр. Ә ул инде киенеп беткән, чыгарга җыена.

— Мотаһир, нигә алайса терелттең мине?! Үләргә булышсаң, миңа җиңелрәк булыр иде. Мин инде күптәннән сиңа әйтергә йөргән идем: мин бит ул чагында кеше коткысы белән эшләдем, абый шулай кушканые.

Фельдшер авыруга тынычлык кирәген, аны борчырга ярамаганын аңлый иде, ләкин үзе теләгәч, әйтмичә булдыра алмады.

— Ә синең үз башың кайда иде?! Кеше сүзе белән йөрергә син балачага түгел идең бит?! Кеше сүзе кеше үтерә. Бинахакка мине ябачакларын белмәдеңмени?!

— Әх, заманасы шундый иде бит, Мотаһир.

— Заманга сылтама. Ул вакытта бөтен кеше дә намусын сатып бетермәде. Юк, сине бәхилләү кыен миңа. Ә сиңа ярдәм итүем — һөнәрем шундый, мәрхәмәтле һөнәр. Врач кеше хәтта үзенең дошманына — әсирләргә дә ярдәм күрсәтә. Аннан, балаларың кызганыч... — дип Мотаһир олы яктан карап торган кызларга, кызыл хачлы кечкенә чемоданын аңа биргән малайга карады.

Тависның күзеннән чыккан бер бөртек яшь мендәргә тәгәрәп төште.

— Бәхиллә, Мотаһир, балалар хакына. Алар каршында йөзем ак булсын...

— Мин нәрсә... Минем хатын, балалар бар бит әле. Ә алар сине гафу итәрме?!... Ничә күзләрне кан елаттың бит син!..

## XXXII

Тагын бер кыш үтте. Яз белән җәй дә йөгереп үтеп китте. Көннәр, атналар, айлар... Көз җитте. Ноябрь керде. Аның бер көне башланды.

Төнлә аз гына кар яуган иде. Җир өстен катырган. Томан тарала. Агач башында ике козгын карылдый, чыпчыклар чикылдый. Этләр өргәли. Казлар каңгылдаша: берсе кычкырып җибәрә дә, башкалары шуны күтәреп ала. Көтү туктамаган әле: кәлүш, чүсинкә, резин итек кигән түтиләр һәм агайлар, киленнәр һәм йорт хуҗалары мал-туарны урамга чыгарып җибәрә. Чокыр-чакырлы юл өстеннән, каткан балчык өстеннән даңгырдоңгыр арба үтә.

Мотаһир, төнлә кайтмаган казларын барлау өчен, елга буена төште. Елга шаулап ага сыман. Гүя ул көчле, зур, тиз агымлы. Чынында исә сул якта, бераз өстәрәк, буа шикелле нәрсә бар. Әмма ул җимерек һәм анда җыелыбрак торган су шулай шаулап ага. Су буенда казлар каңгылдаша, шапыр-шопыр коеналар, һаваны сызгырта-сызгырта канат кагалар, әйтерсең очып китәргә әзерләнәләр. Күрәсең, аларда борынгы бабаларының гадәте калгандыр. Казлар яр кырыендарак. Әнә бер үрдәк елганы аркылы

йөзеп чыкты. Агым көчле. Үрдәк агымга каршы караган, әмма теге якка таба турылап йөзә. Аннары ул яр кырыеннанрак өскә таба йөзеп китте.

Мотаһир оя-оя казлар арасыннан үзләренекен таныды. Санап чыкты. Барысы да исән икән. Инде кайтып китсә дә була. Ләкин ул, таякка таянган хәлдә, шактый озак вакыт тал-тирәкләргә, аргы яктагы болынга, еракта томанлы булып күренгән таулар-калкулыкларга карап тора бирде.

Аннары карашы тагын елгага күчте. Агым юк җирдә боз белән капланган урыннар күренә. Ә уртасы чип-чиста. Елга бер туктамый ага да ага... Үзенә күрә шөгыле бар. Ә Мотаһирның эше юк. Күпме шулай басып торса да сүз әйтүче, куалаучы юк аны. Әйе, пенсионерның эш җайлы икән: эшләмәсә дә акчасы килеп тора, ашау — байдан, үлем — ходайдан, дип, рәхәткә тарып, түшәмгә төкереп тик ят. Хәер, авыл кешесенә үлгәнче йорт тирәсендә, каралты-курада эш бетми анысы. Сыер асрамаса да, көн дә чәйлек сөт бирә торган җыйнак гәүдәле кәҗәсе, ике-өч баш сарыгы бар Мотаһирның. Әле казларын да бетерергә исәбе юк. Аларның су буеннан каңгылдашып кайтуы үзе бер ямь өсти урамга. Зарлана-зарлана, капка астына кысыла-кысыла үрдәкләре алпан-тилпән кайтып керә. Тавыкны аны әйткән дә юк инде. Көн саен түбәтәй яки бүрегенә салып күкәй алып керә Мотаһир. Шулай булгач, эше гел юк дип әйтеп булмый.

Өйдә тыныч: балалары үсеп җитте, кайсы кая таралышты. Иң әүвәл Әгъдәсе:

— Әткәй, укыйсым килә, — диде.

Димәк, калага юл тотачак. Ничек каршы киләсең. Башлы малай мәктәпне «дүрт» һәм «биш»кә генә бетерде. Аннары, авылда нужаны да нык татыган. Чит-ят җирдә кем баласы икәнен дә белмәсләр, дип фикер йөртте Мотаһир. Җибәрәсе килмәсә дә, сыкрап булса да:

— Ярар, улым, — дип ризалыгын бирде. — Бар, олы казанда кайнаган ит чи булмас. Киңәшем шул: иленә карап эш ит.

Шулай итеп, Әгъдәсе шәһәргә китте. Аның артыннан — башкалары. Берсен дә тотмады һәм тотып калырга теләмәде дә Мотаһир. Хәзер җәй көне күбрәк оныклар гына җыела... чагыштырмача тыныч... Юк, барыбер аның йөрәк түрендә юшкын. Йә, кайсы атаның җаны әрнемәс, әгәр баласы кайтып болай әйтсә:

— Эшемдә күтәрмәкчеләр иде, синең атаң утырган икән, диделәр, күтәрмәделәр.

Йә, кайсы атаның бәгыре теленмәс, әгәр баласы кайтып зарланса:

— Туристик путевка белән чит илгә бармакчы идем. Җибәрмәделәр. Синең атаң утырган, диделәр.

Намуслы хезмәте өчен район сәламәтлек бүлегеннән ике тапкыр хөкүмәт бүләгенә куеп карадылар. Юк, үтмәде... Җыену көнендә орден-медальләр таккан ветераннарны чәйгә җыялар. Ә аны дәшүче юк... Кемне гаепләргә? Кемгә үпкәләргә?.. Бар, әлбәттә, гаеплеләр. Кайдадыр бар. Әйе, авылда түгел. Чөнки Тавис Тарханов картлык көнендә авылын ташлап чыгып китте. Доноста имзасы булган башкалар күптән дөнья куйган.

Хәтта бөтен районны кулында тотып торган Викулов та үлемнең каты тырнагыннан ычкына алмаган. Моны әтисенә Әгъдәс кайтып сөйләде.

— Узган атнада безнең шәһәрдә бер кеше үлде, — диде ул бер кайтуында. — Мене шуны биш көннән соң гына җирләделәр.

— Нишләп алай? — дип сорады Мотаһир.

— Кабер казучы булмаган.

— Кем соң ул? Туган-тумачасы юкмыни?

— Анысын белмим. Кайдадыр лесник булып торган. Ә элек органнарда эшләгән. Фамилиясен Викулов, диделәр бугай.

Мотаһир дерт итеп китте, йөзе агарды.

— Викулов дисеңме?

— Әйе. Әллә беләдер идеңме?

— Белү генәме!...

Тынлык урнашты. Малае барысын да аңлады. Төсе киткән атасының йөрәген җәрәхәтләмәс өчен:

— Ахыр чиктә горисполком җирләткән,— диде дә сүзне икенчегә борды.

Әйе, шулай ул язмыш. Кеше күз яше җирдә калмый, дигән борынгылар. Күптән түгел Әблиевнең психбольницада үлүе турында хәбәр ишетелгән иде, әнә хәзер мәңге яшәр кебек кыланган Викулов та киткән бу якты дөньядан. Ә Мотаһир — исән. Уйлана торгач, Мотаһир әле барыбер үзен бәхетсез санамый. Күпме гаепсез җаннар әрәм булды?! Ни гөнаһлары бар иде аларның?! Ирек күрә алмыйча якты дөньядан киттеләр. Чит җирдә калдылар... Ә ул үзенең туган авылында, үз йортында, үз туфрагында... Үлсә дә үкенечле түгел...

Мотаһир, әнә шундый уйлар белән, өенә таба атлый.

Сүрән көяшлы көн дә үтеп китте. Тагын бер көн туа.

Мотаһир җомгадан кайтып килгәндә, капка төпләрендә җигүле ат күреп, аптырабрак калды. Күптән инде авылда тарантас күзгә чалынганы юк иде. Хәзер кая карама — машина да машина... Аты да, капка төбендәге эскәмиягә утырган күзлекле карт та ят иде.

Мотаһир, бераз шикләнә калса да, бу халәтен сиздермәскә тырышып, ул килеп җиткәндә урыныннан күтәрелгән ап-ак сакал-мыеклы картка кул сузды.

— Әссәләмәгаләйкем.

— Вәгаләйкемәссәлам.

— Кунак бар икән. Әйдәгез, өйгә керик.

— Ярар, рәхмәт. Җомгаданмы?

— Әйе.

— Җәмәгатең әйткән иде шул. Кайда укыйсыз? Мәчет юктыр.

— Чираттан йөреп. Әле беребездә, әлә икенче кешедә укыйбыз.

— Картлар байтакмы соң?

— Егермеләп җыела.

— Әле бар икән... Бик әйбәт, бик әйбәт.

Мотаһир, өстенә яхшы костюм-чалбар, башына эшләпә, аягына күн итек белән галош кигән, төс-кыяфәте белән Урта Азия халыкларына тартымрак ят кунакны өенә чакырды.

— Әйдәгез, өйгә керик. Атыгызны ишек алдына кертеп куйыйк.

— Ярар, Мотаһир туган, ат монда гына торсын, беркая да китмәс. Минем әллә ни йомыш та юк, озак юанмам.

— Алай килешеп бетмәс,— диде Мотаһир һәм, олы капканы ачып, атны ишек алдына кертте.— Тугарыйкмы?

— Юк, юк, хафаланма.

Өйгә кереп, түр якка узып, йортка дога кылгач, кунак сүз башлады:

— Син, Мотаһир, бу нинди кеше икән дип, аптырап та калгансыңдыр инде. Гаҗәп тә түгел. Күрмәгән-белмәгән кеше... Мин Баллы Күлдән булам, Мотаһир атлы. Димәк, без адашлар булабыз. Фамилиям — Нәбиуллин. Элекке фамилиям.

— Нәбиуллин?!

— Әйе. Адаш. Мин Мотаһир Нәбиуллин булам. Теге вакыт мин алардан ычкындым. Кисәтер-искәртер кешем бар иде. Ә менә сине эләктергәннәр... минем урынга. Хәзер төшенәсең булыр.

— Әйе, азрак аңыштым,— диде, чак зиһенен җыеп өлгергән Мотаһир.

Мөсәмирә чәй хәстәрләгән арада берничә минутка сүз өзелеп торды. Икесен дә авыр хатирәләр баскан иде. Ниһаять, өстәл янына утыргач, кунак янә телгә килде:

— Мин синең алда зур гөнаһлы, адаш, син минем өчен утырып чыккан икәнсең...

Моңарчы сүзнең ни турында баруын, кунакның кем булуын яхшылап белмәгән Мөсәмирәнең тәлинкә тоткан кулы калтырап китте. Ул, күтәрелеп, ят кунакка карады, аптыраштa калды. Ничек? Бу кем тагы?

Мотаһир, бераз күтәреп:

— Юк, үз-үзеңне зарэгә битәрләмә,— диде.— Мине барыбер, иртәмесоңмы, алып киткән булырлар иде. Мин сизенеп йөрдем. Шикаятьләр язылган булган инде минем өстән. Рәхәт күрсәтмәсләр иде.

Мотаһир, язмышына буйсынган кешедәй, күндәмлек белән юаш кына шулай дисә дә, каршында утырган картка текәлебрәк карады. Әлбәттә, аның күңел түрендә ниндидер нәрсә — рәнҗүме, үпкәме булырга тиеш иде. Әгәр теге чакта бу адәм өйдә булса... Мотаһир үзе Зәһлүл кисәткәннән соң читкә чыгып киткән булса... Күпме гомере заяга узмас, лагерьларда черемәс иде бит. Юк, бу да гомерен нужасыз гына үткәргән кешегә охшамаган. Кара-кучкыл йөзендәге җыерчыклар — картлык галәмәте генә түгел, хәсрәт эзләре. Шулай да, инде күпме гомерләр узганнан соң, кабат «теге» елларга әйләнеп кайту ифрат дәрәҗәдә авыр да, йөрәк әрнеткеч газаплы да, җан өшеткеч шомлы да иде. Аларны искә алмау хәерлерәк иде. Ләкин...

Карт сөйли. Тыңламыйча чараң юк.

— ...Шул китүдән мин кайтмадым. Казакъ-кыргыз далаларында гомер сөрдем, үзбәкләрдә канау казыдым... Әле күптән түгел генә, йорт сатып алып, Әлмәттә төпләндем. Берүзем. Теге вакыттан соң хатын белән ара өзелде. Ул да, баланы ияртеп, авылдан ук китеп барган. Үз тормышы белән яшәгән. Хәзер вафат инде. Ә мин ялгыз. Дөрес, яшьрәк чакта гел хатын-кызсыз да яшәмәдем. Анда йортка кереп, монда йортка кереп дигәндәй гомер узганын сизми дә калдым. Барыбер элеккегә рәхәтләр булмады. Гел куркып-өркеп, урын күчеп, фамилия алыштырып яшәдем. Бүгенге көндә фамилиям Дәүләтбаев.

— Алай икән...— диде Мотаһир сузып кына һәм кунакның чәен яңартты.— Әле хәзер каян килеш соң?

Карт күзләрен сөртте, мышкылдап, борынын тартып куйды.

— Авылга кунакка кайттым. Энеләр, туганнар бар. Җан түзми, кайтасы килә. Каяндыр табып, тарантас җигеп бирделәр. Ялгыз башым уйланып, үзебезнең җир-суларны карап килдем.

— Шулай инде, туган җир тарта.

— Шулаен шулай да... Их, Мотаһир, изде безне тормыш, нык изде. Бу илдән дә каһәрлерәк ил бар микән җир йөзендә...

Һәрчак сак эш итәргә өйрәтелгән Мотаһир тизрәк аңа каршы төште.

— Тәүбә диген, тәүбә... Үз җиреңне каргыйлармыни?!

— Әй, Мотаһир. Минем җирмени бу?! Синең җир дә түгел... Бер гаепсезгә ун ел гомереңне төрмәләрдә үткәр әле... Безнең хәзер генә әз-мәз күз ачыла төште бит. Ә моңарчы нәрсә белдек? Юк, син ни әйтсәң дә әйт, изге җир түгел бу, каргышлы язмышлар иле бу... куркаклар иле. Хәзер генә батыр сөйләшәбез. Гомер буе кан калтырап яшәдек ләбаса. Мин үземнән пример китерәм... тегендә бер ел, монда — ике... тагын кит... Төннәрен дер калтырап ят... Үз фамилияңнән үзең куркып, ваз кичеп яшә... Минем хәзерге фамилиям Дәүләтбаев. Әйттем бугай инде. Тегендә шулай дип кулга дукамит төшердем. Үзем дә кебек, чит кеше дә сыман... йә, шул да булдымы тормыш?!..

Мотаһир дәшмәде. Дөрес сүзгә җавап юк, дисеңме? Юк, агайне, син ялгышасың, дисеңме? Хаталанма, көфер сүз сөйләмә, дисеңме? Юатсынмы бу бетешкән картны...

Мотаһир җанына тынгылык таба алмады, бер эшкә кулы бармады. Алда тагын ниләр күрергә язгандыр? Ниләр күрсәтер бу тормыш? Балалары ничек яшәр? Үзе инде ашын ашаган, яшен яшәгән. Ә алар? Аларның балалары — оныклар... Нинди афәтләр килер икән ул газизләр башына? Ни көтә алда ил-көнне?

Мотаһир, зиһене таралып, капка төбендә утырды да утырды, вакыт узганын да сизмәде, үткән-сүткәнгә дә игътибар итмәде. Нәбиуллин китте. Ләкин үзе белән аның тынычлыгын да алып китте. Ул нигә килде икән?

Ни әйтергә теләде икән? Хәер, ни әйтсен. Әйтәсен әйтте бит. Ул да, бичара, йөрәгенә чыдый алмаганга килгәндер. Картлык көнендә бер бушанып, бәхиллек алып китәргә теләгәндер. Аның да җаны кыйналадыр. Язмышы җиңел булмаган бит, тормышы челпәрәмә килгән... Ул да кызганыч, Мотаһир үзе дә кызганыч.

Мотаһир авыр башын түбән иде. Аяк астына карап, терсәкләрен тез өстенә куеп, уйланып утыра бирде. Җан тырмашып, нидер майтарырга теләп, җирдә йөргән әнә теге бөҗәк ни дә, үзен көчле, гайрәтле, бар нәрсәдән өстен зат дип санаган кеше ни?! Бөҗәккә аяк белән саксызрак бассаң — бетте. Ә кешегә? Аны изеп-сытып булмыймыни?! Кемнәр исән, кемнәр юк...

...Мотаһир, йокларга ятар алдыннан мал-туарга күз-колак булырга, урам капкасын ябарга дип, комган күтәреп, тышка чыга. Карт алмагачка, күктә йөзгән сары айга, аның янәшәсеннән берөзлексез узып торучы карасу болытларга карый. Карасу болытлар аңа Архангельск якларын хәтерләтә. Дөрес, алар монда югары. Күк йөзе дә якты, өсте зәңгәр урыннар да күренә. Урам тын. Җил генә агачларга, кое чылбырына, сыерчык оясы кадакланган колгага, телевизор антеннасы челтәренә, капка баганасы янындагы пумала һәм багорга кагылып, выжлап үтә.

Ул җил, авыл халкы иганә җыеп, аның туган нигезенә — ата-анасы үлгәннән соң бушап калган урынга төзелгән яңа мәчетнең яп-якты биек манарасына да кагылып үтә. Ләкин җилнең ачуы сизелми...

Шушы тын, якты кичләр күңеленә рәхәтлек бирсә дә, барыбер заяга узган гомер үкенечле икәнен искәртә... Илгә күпме файда китергән булыр иде бит! Кырык бердә, хәрби хезмәт үткән медицина эшчесе һәм кече командир буларак, аны көне-сәгате белән үк фронтка дәшерләр иде.

Бәлки сугышта, изге Ватанын саклап, батырларча һәлак булыр иде. Авыл уртасындагы һәйкәлгә исемен чокып, алтын белән язарлар иде. Исән кайтса, күкрәк тулы орден-медален тагып, үзенең кордашлары-фронтовиклар белән бергә җиңү көннәрендә өстәл янында утырыр, мәктәп балалары аңа да болын чәчәкләре җыеп китерерләр, аның да рәсеме мәктәп һәм клуб диварларында эленеп торыр иде...

Ни генә булмасын, хәзер инде барысы да артта калды: каргышлы еллары да, узмас көннәре дә, караңгы төннәре дә, атмас таңнары да... Кабат аларны беркемгә дә кичерергә язмасын.

Артта калды. Ләкин... онытылмады. Кайчак ул еллар аның төшенә керә. «Лагерьда икәнмен. Ни ашармын, ходаем?» дип сискәнеп уянып китә Мотаһир. Уянып китә дә, ун ел буе аңа тугрылык саклап, аны көтеп яшәгән карчыгы Мөсәмирәнең җылы тәнен тоеп, тигез сулышын ишетеп сөенә һәм... җылый. Бу аның кайгы катыш шатлык яшьләре...

Көндезләрен ул күзлеген киеп ала да, алты почмаклы яңа өенең олы ягына чыгып, өстәл янына, яисә кәнәфигә утыра, гәзит-журнал караштыра, хатлар, китаплар укый... Карчыгы мал-туар тирәсендә йөргән чак була... Мотаһир онытылып укып утыра... Ләкин шунда кемдер килеп ишек какса, ул сискәнеп китә, чөнки аны тагын алып китәрләр төсле тоела...

*1989*

# ШИГЪРИЯТ

## Гөлшат Зәйнашева

### ЯҢА ҖЫРЛАР

#### Кайтырмын

Һаваларда болыт,
Ак җилкәннәр булып,
Кая бара, кая агыла?
Юк, йөрмәмен озак
Чит җирләрдә чыдап,
Кайтырмын мин туган ягыма.

Тау башында тургай,
Ялгыз калган бугай,
Очам диеп канат кагына.
Юк, йөрмәмен озак
Чит җирләрдә чыдап,
Кайтырмын мин туган ягыма.

Дуслар исән микән,
Хат, алалмыйм күптән,
Әллә кемне күңел сагына.
Юк, йөрмәмен озак
Чит җирләрдә чыдап,
Кайтырмын мин туган ягыма.

Поездларга карыйм,
Вагоннарын саныйм,
Кайтыйм дисәң, юллар табыла.
Юк, йөрмәмен озак
Чит җирләрдә чыдап,
Кайтырмын мин туган ягыма.

#### Сагыныр кешем бар

Зәңгәр күктә утлар уйный,
Йолдыз түгел, яшендер.
Яшәмәс тә идем бу дөньяда,
Сине сагыну өчен яшимдер.

---

Гөлшат ЗӘЙНАШЕВА — *танылган шагыйрә, күпсанлы китаплар авторы. Ул — Г. Тукай исемендәге Татарстан дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Сынды сабыр канатларым,
Сабыр кебек йөргәч тә.
Сагынмам дип, антлар итәм үзем,
Сагынырмын гүргә кергәч тә.

Күзләр җитсә дә бакчамда
Китми торган кошым бар.
Көч аламдыр бәлки сагынулардан,
Ярый әле сагыныр кешем бар.

## Мин бит кара карлыгач

Очыйм дисәм, канатым бар,
Мин бит кара карлыгач.
Очып килдем яннарыңа,
Бер күрергә зар булгач.

Мин бит кара карлыгач,
Канатым кыйгач-кыйгач.
Канатсыз калырмын, бәгърем,
Мин синнән аерылгач.

Китсәк икәү кошлар кебек,
Кайтыйк ерак илләрдән.
Бергә-бергә оя корыйк,
Үреп-үреп гөлләрдән.

Җырлыйк дисәк, сагыш тулы,
Моң тулы күңелебез.
Кирәксә икәү бу җиргә
Моң булып түгелербез.

Мин бит кара карлыгач,
Канатым кыйгач-кыйгач.
Канатсыз калырмын, бәгърем,
Мин синнән аерылгач.

## Син кирәк

Балыксыз бер күл кебек мин,
Чәчәксез болын кебек;
Карурманда адаштырып
Калдырган колын кебек.

Кинәт кенә аңлашылды
Минем шушы хәләтем:
Үксеп типкән йөрәгемдә
Юк икән мәхәббәтем.

Мәхәббәте булмагач соң,
Ничек яшәр ул йөрәк?
Йөрәккә бит үз дигәне,
Үз сөйгәне — син кирәк!

## Ап-ак итеп керләр юып элдем

Ап-ак итеп керләр юып элдем.
Нигә әле уйга калдым соң?
Күңелне дә шулай юсаң иде,
Калдырмыйча борчу, кайгысын.

Ап-ак итеп керләр юып элдем,
Җилфердәтә җилләр керемне.
Әллә шул җилләргә сөйлим микән,
Беркемгә дә әйтмәс серемне?

Ап-ак итеп керләр юып элдем...
Ап-ак сөлгем синең бүләгең.
Чәчләреңә ап-ак чал кергәндер,
Ничә еллар сине күрмәдем.

## Бишек җыры

Йолдызлар да йоклыйдыр зәңгәр күктә,
Кондызлар да йоклыйдыр зәңгәр күлдә.
Чәчәкле гөлбишектер бар табигать,
Йокла син дә, балам, ак мендәреңдә.
Йокла, бәбкәем,
Күгәрченкәем...

Курчагың да йоклаган инде күптән,
Песиләр дә инде йокыга киткән.
Чәчәкле гөлбишектер бар табигать,
Сиңа да, балам, йоклар сәгать җиткән.
Йокла, бәбкәем,
Күгәрченкәем...

# Зөлфәт Хәким

## Изге җир

Пәйда булса күктә бәла кошы,
Яшен сукса өмет-хыялымны,
Туган яктан килер якты аваз,
Томаннардан арындырыр юлны.

Туган ягым — мәңге кояш,
Йөрәк кыса сагынудан.
Туган якта яшел урман
Көн дә иртән әйтә азан.

Анда әле яши иман,
Изгелеккә инану бар,
Анда җанны чистартырдай
Матурлыкка соклану бар.

Анда кичен, дөнья тынгач,
Намаз укый бөдрә таллар,
Анда синә Яшәү биргән
Мәңгелеккә табыну бар.

Изге җирдән күз күрмәгән җепләр
Сузылганнар миңа еллар буйлап.
Язлар килгәч, мине сагынудан,
Каеннары юлга чыга елап.

Туган яктан хәбәр килсә,
Шунда карап син җырың әйт.
Туган якның һәр авазы —
Үзе үлмәс бер мөнәҗәт.

Анда әле яши иман,
Изгелеккә инану бар,
Анда җанны чистартырдай
Матурлыкка соклану бар.

Анда кичен, дөнья тынгач,
Намаз укый бөдрә таллар,
Анда — синә Яшәү биргән
Мәңгелеккә табыну бар.

---

Зөлфәт ХӘКИМ — *соңгы елларда сәнгатебездә үзгә бер урын алган талантлы шагыйрь, җырчы һәм юмор-сатира остасы. Казанда яши.*

## Төнге сәяхәт

Төн юрганын япкач Җир өстенә
Дәшә мине Шигырь — Төнгизәр:
Көмеш сулы хыял елгасында
Бер кечкенә салда мин йөзәм.

Ике яктан миңа кычкыралар,
Яңгыратып ярлар арасын.
Чайкала сал, йөзә бата-калка,
Ләкин килми ярга борасым.

Җырларымнан үрелгән салыма
Дулкыннарда — уен-шаяру,
Җирдәгеләр ах-вах килсәләр дә,
Уемда юк җиргә таяну...

Тик һәрвакыт таң атарга ашыга,
Гүя мине Кояш сагына,
Шаулы причал булып көн кул суза
Минем нәни, кыю салыма.

* * *

Килдем Дөньяга...
Күрдем... татыдым... шаккаттым.
Үзгәртмәкче булдым...
Тик шулай ук кояш баеды, таң атты.

Килдем Дөньяга...
Яшәп карадым, аңладым —
Ничек үзгәртә алсын Дөньяны
Дөнья биргән аңым?..

* * *

Үтте көн.
Янды да бетте
Вакытның бер күпере.
Тау өстендә шәфәкъ булып
Балкый утлы күмере.

Бер-бер артлы сүнә көннәр,
Булмый саклап калдырып.
Кире юл юк үткәннәргә,—
Үзе чыккан күперләрне
Китә Вакыт яндырып.

## Октябрь азагы

Тәмамланды бөек симфония
Туган якның урман-кырларында.

Сихерләнгән сыман тыңлап торам —
Соңгы аккорд алды көз-маэстро
Табигатьнең алтын кулларында.

* * *

Белмим, нигә кирәк бу тамаша,
Күңел ачу өчен мөгаен,—
Галәмнең бер нәни утарында
Кешеләрне асрый ходаем.

Анда давыл, буран, яңгыр коя,
Анда яши яман законнар,
Аңга сыймас хәлләр кайный анда.
...Җирдә шом бар адәм затыннан.

Тәкәбберлек кая качар икән,
Белсә ахыр көне киләсен?
Төпсез бушлык йота калса Җирне—
Галәм дисбесенең төймәсен...

* * *

Сабыйны юаткан кебек
Кочаклаган шәһәрне төн,
Йокы татлы булсын өчен
Сөйли серле әкиятен.

Һава тулы уенчыклар—
Саф алтыннан гына койган,
Уянса еламасын дип
Хәтта Ай да элеп куйган.

Шәһәр йоклый...
Төн югалгач
Йолдызлыклар арасына,
Таң килер— якты, бәхетле,—
Әкият ахыры сыман.

* * *

Әбием юк. Үлде. Татлы-татлы
Әкиятләр калды бүленеп.

Чоланында, изге ярымай кук,
Көянтәсе тора эленеп.

* * *

Кычкырды төн!—
Колакларны тондырып...
Томаланды дөнья.
Якты көтә караңгылык арасыннан.
Әллә кая качты гауга яктылыгы,
Куркып шушы тынлык авазыннан.

# Чәчмә әсәрләр

## Гаяз Исхакый

# КӨЗ

ПОВЕСТЬ

Көз иде. Шыбыр-шыбыр ява торган вак ягмур күзгә тортсәң күренмәс караңгы төнгә тагы караңгылык куша, авыр һавага тагы басынкылык бирә иде. Очы юк юешлек тәнне баса иде, албасты пәрисе баскан кебек изә иде. Кырые юк караңгылык жанны өшетә иде, иске яраларны ачып күңелне сыкрата иде. Күкне томалаган авыр болыт, җирне дә, суны да йотарга теләгән кебек, түбәннән түбәнгә төшә бара иде. Инде Иделнең бөтен ярларын каплап алган, бирешмәенчә барырга тели торган пароходның артын да, алдын да камалаган, тирәюньдә һичбер җан галәмәте калдырмаган иде. Барысы караңгылыкка баш игән, барысы да болыт астына баткан иде. Пароход кына шул төпсез-чиксез караңгылыкны ертып алга барырга маташа, үләр алдындагы буылган кеше кебек, карылган тамаклары берлә бик ямьсезләп кычкырта, тагы көпчәкләрен селкетеп поштыр-поштыр йөргән кебек була иде. Ләкин ул никадәр хәрәкәтләнгән булса да, караңгылыкны үтә алмый, никадәр ыңгырашып кычкырса, ялварса да, җавап ала алмый иде. Томан куера иде... Эз бетә иде, юл югала иде...

Нәфисә шул авыр һаваны суламас өчен, күңелсез тышны күрмәс өчен каютаның почмагына кереп поскан да утырган иде. Шул басынкыдан рухыны издермәс өчен кебек татлы хыяллар дөньясын сөйли торган җылы китап эченә чумган иде. Кичә генә көн буе пароход өстеннән кермәгән балалар — төн буе утка чумган пароходларны, һаваланып ага торган салларны сәердән туймаган балалар да үз почмакларыннан кыймылдамыйлар. Аларны да юеш томан, коточкыч караңгылык куып керткән. Аларны да үзләренең курчакларына, курчакларының туйларына, кода-кодагый сыйлауларына чумдырган иде. Һәр җирдә тынлык иде. Пароходта гүя бер җан юк кебек моңлы иде. Аш бүлмәсендә музыка да уйнамыйлар, бүлмәләрендә дә бертуктамаенча шылтыратып хезмәтче дә чакырып тормыйлар, түбәндәге классларда да озын көйләрдә гармун көйләмиләр иде...

Пароход кына һаман моңланып, зарланып кычкыруында, поштыр-поштыр бер урында поштырдавында дәвам итә иде. Менә әллә кайдан гына ерактан бер тавыш килгән кебек булды. Нәфисә китаптан күзен алды. Караңгыны көчләп ертып бер фонарь үтеп китте. Тагын тавыш килде. Тагын

---

Күренекле татар язучысы Гаяз Исхакый (1878—1954) эмиграциягә киткәч тә күп кенә әсәрләр иҗат иткән. Совет укучысы аларны бөтенләй диярлек белми. «Көз» повесте — әнә шул дәвернең бер истәлеге — беренче мәртәбә Берлинда 1938 елда басылган.

Повестьны журнал өчен фәнни хезмәткәр Лена Гайнанова әзерләде.

кызыл ут ялтырады. Тагын пароход ыңрашты. Ерактан гына кеше тавышлары ишетелгән кебек булды. Әллә кайда еракта гына утлар әле уңда, әле сулда мелт-мелт итте. Пароходның шытырдавы бетте. Нәфисә китаптан күтәргән башын яңадан төртә алмаенча, әллә кайдан ерактан килә торган тавышларны, ишетелеп бетми торган сүзләрне тыңларга, аларның мәгънәләрен иҗекләргә кереште. Ишек шакылды, ачылды, ике кулына чемоданнар тоткан, артына ике бала ияртkән бер хатын килеп басты. Ул, бүлмәдәге яктылыкта күзе чагылган кебек, бүлмәдәге җылылыктан куркып киткән кебек булып калды. Мондагы тынычлыкны бетерүе өчен, шул коры якты бүлмәгә шулкадәр юешлек, караңгылык алып керүе өчен үзен гаепле тапкан кебек, русча: «Гафу итәсез, монда урын бармы?» — диде... Нәфисә киемнәре юешләнеп тәннәренә сыланган, ябык куллары чөгендер кебек кызарган, нечкә ирене күгәргән, бите ак киндер булган шул хатынны, артында дер-дер килә торган боек балаларны күреп кызганды. Хатыннарда була торган бер кызгану берлә кызганды да тиз-тиз генә: «Бар, бар, монда без икесен генә аламыз, менә ул ике урын буш», — диде.

Хатынның юешләнгән балаларын чишендергәнне җентекли-җентекли, русчалап: «Бу кайсы пристань?» — диде. Кергән хатын борылмаенча гына: «Богородский. Унике сәгать пароход көттек, туңып беттек», — диде. Балаларның берсе юеш бишмәтен салып, Нәфисәнең курчак уйный торган балалары янына килеп тә басты. Балалар берсен-берсе караштылар да, Нәфисә балалары тагын уйнауларында дәвам иттеләр: «Бусы кодача буладыр, ди, бусы баш кода буладыр, ди, бусы әтисе, ди», — дип сүзгә керештеләр. Яңа бала татарчалатып: «Әтисенең шешәсе кая соң?» — диде. Балалар: «Ник әтисенең шешәсе булсын, әтисе доктор, ди, әтисе укый, ди», — диделәр. Яңа бала: «Юк, әтисе эчә, ди, әтисе эчә, ди», — дип моназарәгә* кереште. Нәфисә берлә яңа хатынның күзе күзгә очрашты. Алар икесе дә елмаештылар. Әллә нидән берсенә берсе мәхәббәт куйган елмаю берлә елмаештылар. «Кая барасыз? Кайдан киләсез?» — дип, татарчалап сүзгә керештеләр. Балалар да бергәләп уенга катыштылар. Нәфисә үзен өй хуҗасырак итеп хис иткәнгәме, әллә боларга каршы кызгану хисе бетмәгәнгәме: «Чәй эчәсезме, әле бит бирә торганнардыр, балалар бик туңганнар», — дип соальле итеп карады. Вә теге хатынның: «Ярый шул», — дигәненә чәй сорап, чәй урыны да хәзерләде. Ике хатын да кәрзиннәреннән әллә никадәр ашамлыклар чыгарып, берсен-берсе сыйлаша-сыйлаша, сөйләшә-сөйләшә чәй эчәргә тотындылар. Чәй янында алар тыштагы караңгылыкны, тыштагы сөякләргә үтә торган юешлекне оныттылар. Балалар дуслашты. Хатыннар якынайганнан-якынайды...

Чәй беткәч, балалар бик озак курчак уйнап арыгач, ятып йокласалар да, ике хатын да йокларга ашыкмадылар. Нәфисәдә бу ябык хатынга, бу зәгыйфь балаларга кызгану хисе уянганга, ул аларның хәлләрен сорашырга кереште. Яңа хатын элгәре кыскарак җавап биргәләсә дә, бара-тора сүзнең эченә кереп китте. Ул элгәре бер бай мирзаның кадерле кызы булган икән. Аны бик һәйбәт тәрбияләгәннәр, ул институт бетергән, һәм дә махсус мөгаллимә берлә музыкага да өйрәткәннәр. Аның кулын сораучылар бик күп булган. Никтер, анысын ул үзе дә белми, тәкъдирдер инде, ул хәзерге иренә кияүгә чыккан. Менә инде дүрт баласы да булган. Икесе, аллага шөкер, үлеп котылганнар. Менә бу икесе бар. Шул сүзне тасдыйк иткән кебек, балаларның берсе куркынып җибәрде: «Әни, әни! Әти килә, әти килә», — дип сикереп торды. Яңа хатын барып аны сылап-сыйпап яткызды. Нәфисә: «Ирең кем соң?» — дип сөаль бирде. Яңа хатын бик озак җавап бирмәенчә торганнан соңында: «Ничек дип әйтим икән... Ирем... инде...» — диде. Тагы авызы ябылды... Тагын бик озак уйлап торганның соңында: «Ул миңа өйләнгәндә әфисәр иде... Аннан соң аны урыныннан чыгардылар... Минем алып килгән дәүләтем зур иде. Аннан хезмәткә кермәде, ахырдан бик күп акча әрәм итүчән булды... Эшләр начарлана

* Моназарә — сүз көрәштерү, бәхәсләшү.

башлады. Аны земский начальнигы ясаттык... Аннан мәхкәмәгә* әләгеп, бик күп акча чыгарып көчкә котылды... — Шуларны тутырган кебек:— Ул бик эчә... Менә әле актык калган кечкенә генә җиремез, тегермәнемез бар иде. Шуны сатарга йөри, дип хәбәр алдым. Шунда барам... Бу балалар берлә бернисез мин нишләрмен»,— диде дә авыр гына сулап куйды... Нәфисәнең кызгануы тагы артты. Шуның берлә сүзне тәмамлаган кебек, яңа хатын урын салды. Нәфисә дә урынына сузылды.



Тышта пыштырдый торган ягмур һаман туктамады. Пароходның поштыр-поштыр килүе бетмәде. Аның ара-сыйра моңланып кычкырып җибәрүе, ике хатынны да үз уйларыннан яздырмады. Бераз тын ятканның соңында, хәерле кичәләрне әйтеп йоклаган булырга маташканның соңында, хатыннар тагын искәртмәстән сөйләшеп киттеләр... Никтер бу хатыннар берсенә-берсе үзләренең эчләрендә ябылып яткан кайгылары-хәсрәтләрен, шатлыкларын чишәргә теләп торганга, хәзерге хәлләреннән үтеп, бик тиз сөюләренә, кияүгә чыгуларына барып җиттеләр. Яңа хатынның: «Ничек соң сез кияүгә чыктыңыз?»— диюенә каршы, озын уйлап тормаенча, Нәфисә мендәренә таянып сүзгә кереште. Аның күзе елмайды, йөзе нурланды, тавышына әллә нинди йомшак бер аһәң катышты. Яңа хатын Нәфисәнең ачылган гөл кебек нурланып киткән йөзенә карап, моның бәхете минеке кебек түгелдер шул, дип, ике колагын тыңларга хәзерләде.

«Мин Оренбург шәһәренең уртача бер сәүдәгәр кызы. Мөселманча яхшы гына укыдым. Русча, өйгә китереп, бер марҗадан бераз укыттылар. Ләкин шәһәр кызы булганга, русчаны белә идем. Китаплар аңларлык булган идем. Безнең тирә-юньдәге кызларның кайберләре гимназиягә кереп укып китсәләр дә, аларның ак алъяпкычлары, соры киемнәре мине бик кызыктырса да, минем әти, бик иске кеше булганга, авыз да ачтырмады. Мин 17-18 яшькә җиткәч, буй кыз булып яши башладым... Ара-тирә: «Сәхибә карчык яучы килгән икән, Каргалыдан Вахит бай углына сорап карый, хәлфә баш кода булган икән»,— дигән сүзләрне ишеткәләсәм дә, бер колагымнан керде, икенчесеннән чыкты. Менә шулай көннәр үткәндә, театрда яңа әсәр куела, дип игълан булды. Әти үзе бармаса да, мине энем берлә театрга җибәрә иде. Ләкин һәрвакытта ложаны алып безнең янымызга йә күрше Мәрфугасын, йә исә асламчы Фәхриясен тагып җибәрә иде. Бу юлы никтер безгә кадәр ложалар сатылып беткән, энем партерда ике урын гына алып кайткан иде. Әтинең кәефе бик китсә дә: «Анда җыен малай-салай берлә чуалып йөрергә рөхсәт юк»,— дисә дә, безнең бик барасымыз килгәнгә, әни арага кереп, театрга киттек. Әти: «Сак булыңыз, пәрдә араларында чыгып йөрмәңез»,— дип кычкырып калды.

Урыннарны алып утырдык. Пәрдә ачылырга гына торганда минем уң ягымдагы урынны бер урыс килеп алды. Безнең Оренбургта урысларның безнең театрга килүләре сирәк булмаганга, мин аңарга дикъкать итмәдем. Сул ягымда энем булганга, мин хәзер киләчәктәге әллә кемнәрнең егетләр «берлә утырды» дип лыгырдавына юл ябылыр дип кәефләндем дә. Уен башланды. Бик тиз уенга батып киттек. Менә бер пауза арасында күршем урыска күзем төште. Шул уенның эченә кергән кебек күзен текән, тәмамән югалган... Урысның ихласына бераз гаҗәпләндем. Пәрдә төште. Ут яктысыннан һәммәбезнең күзләре камашып китте. Төрле җирләрдә биноккльләр берлә караулар, ерактан сәламләшүләр башланды. Минем энем ул вакыт барымыздан да качып тәмәке тартырга үгрәнә торган чагы булганга, ул бик тиз чыгып шылды. Мин урынымда калып, биноклем берлә уйный башладым. Бердән күршемдәге урысым: «Гафу итегез, туташ, программаңызны биреп тора алмассызмы, мин соң килдем дә программа таба алмадым»,— диде. Мин: «Рәхим итегез!»— дип шул урысны җентекләп карадым. Хәзер дә бөтен кыяфәтләре күз алдымда... карасу бер костюм, бер зәңгәррәк, бер карарак булып китә торган муен бавы, ап-пак якалар, тирән генә уйлы күзләр. Күршем: «Бу мөгаллимә ролендәге артист бик ях-

* Мәхкәмә — суд

шы уйный, ул искедән уйный торган кеше булырга кирәк»,— диде. Мин үзем белгән кадәр безнең труппамыз хакында мәгълүмат бирдем. Ул бердән: «Сез бәхетле туташ, үз халкыңыз арасында яши аласыз, аның һәр шатлыгына катыша аласыз, менә мин читтә, үз театрымызны күргәнем юкка менә инде бер ел булган иде... Бу әсәрне мин белми дә идем. Ишеткәнем дә юк иде... Бу бит бик зур мәхрүмлек»...— диде. Шуннан мин бу урысның урыс түгеллеген, әллә кайда читтә урыс арасында торса да, үз рухын сакларга маташа торган кеше икәнен күрдем. Шуны кызгандыммы: «Сез соң ник үз халкымыз арасында тормыйсыз?»— дидем. «Булдыра алмыйм, мин доктор, былтыр гына бетердем, әле менә үземне гаскәри хезмәткә алдылар да, кая җибәрсәләр шунда торырга мәҗбүрмен»,— диде. Шул сүзне кыңгырау тавышы бүлде. Пәрдә ачылды. Минем дикъкатем бүленде. Бер күзем берлә сәхнәгә карасам, икенчесе берлә күршемне сөзә башладым. Ләкин ул минем барлыкны да онытып сәхнә эченә чумды. Андагы хәят берлә яши башлады. Анда көлсәләр көлде, кайгырсалар хәсрәтләнде. Икенче пәрдә арасында күршем тагы үзенең урыс арасындагы тормышының күңелсезлеге, өч айдан менә тәмамән гаскәрлектән котылып йә Казан, йә Оренбург, Әстерхан кебек бер шәһәрдә җирләшергә теләвен сөйләп китте. Сүз арасында гына: «Сез кем буласыз?»— дип исемемне сорап алды. Бераздан: «Буфетка чыгып берәр нәрсә эчмисезме?»— диде. Мин: «Рәхмәт, беләсез бит, безнең халык әле андый эшкә чит карый. Безнең әти дә андый бергәләп йөрүне бер дә яратмый, гафу итеңез, чыга алмыйм»,— дидем. Шуннан: «Мин чыгып керим әле алай булса, мин әле яңа гына поезддан, вокзалдан килгәндә театрның игъланнарын күрдем дә, ашамадым-эчмәдем, юындым да килдем»,— диде дә чыгып китте. Мине әллә нинди яңа бер хис биләде. Бу яшь егет, урыс арасында тора торган яшь егет, мескен, ничек яши икән? Иртә чаенә аны кем уята икән? Бәйрәмендә-ниендә ничек көнне үткәрә икән? Ялгызлык хис итмиме икән?..

Шундый уйларны уйлап, уем агып, берәр маржасы-фәләне бардыр инде, безнең егетләр шулай бит, дигән фикергә килгән кебек булдым. Ләкин ул фикердә озак кала алмадым. Минем энем тәмәкесен тартып бетереп килә алмаса да, күршем килеп җитте. Ул кулына зур гына бер тартма шоколад тоткан, утырды да, ачып: «Рәхим итегез, туташ!»— дип миңа сузды. Егетләрдән сыйлану да безнең гадәткә сыймаса да, сүз кайтару моңа авыр тоелыр, дип рәхмәт әйтеп алдым. Ул арада минем энем дә килеп җитте. «Бу егет сезнең энеңез буламы?»— дип сораганның соңында, аңарга да тәкъдим итте. Энем дә авызындагы тәмәке исен бетерер өчен бик рәхәтләнеп кабул итте. Өченче пәрдә башланды. Минем күрше егетем тагы онытылды. Мин аның шулкадәр сусаган булуын кызганган булсам да, шулкадәр тиз ут кабып китүенә бераз гаҗәпләндем дә. Сәхнәнең яшьле җирләренә җиттек. Партерда меңер-меңер елау тавышлары ишетелә башлады. Минем күземә яшем тыгылса да, күршемнән оялып, тешләремне кыстым. Үземне тыйдым. Күземнең очы берлә күршемне сөздем. Ни күзем берлә күрим, яшь егетем мер-мер елый. Мин аптырап калу берлә кызганудан җыелган бер хис астында калдым. Аны юатасым да килде, аны оялтасым да килде... Ләкин театрны онытып аны сөзә башладым. Күземез күзгә очрашты. Аның яшьле керфекле күзендә әллә никадәр кайгы-хәсрәт, әйтеп бетермәслек йомшаклык, мөлаемлек күрдем. Күземне бик тиз аласым килсә дә, ала алмадым. Аның йөзенә кызыл йөгерде, ул борылды... Пәрдә төште. Күзләрендәге яшьләрен киптерер өчен кебек һәркем бик озак кул чапты. Минем күршем дә, әллә нидән оялган кебек кызарып, үзенең шоколадын миңа тәкъдим итте. Теге юеш керфек арасындагы яшьле күзләре аша, мин моның бөтен җанын күргән кебек булганга, күңелемдәге моңа ятлык бердән бетте. Мин үзем сизми дә моңарга үземнең хәлемне аңлата башладым. Үземнең тормышымны сөйләдем. Беркемгә дә сөйләнми торган кечкенә гаилә серләремне аңлаттым... Ахырдан бер көлке куелачак булганга, без тагы калдык. Пәрдә ачылыр-ачылмас күршем: «Бу шоколад савыты

тулы булмаса да, сезгә булсын, рәхим итеп алыгыз»,—диде. Мин: «Бик рәхмәт, гафу итәсез, гаепкә алмаңыз, безнең тормышта ул сыймый бит, миңа, кайдан алдың аны, дип колак итемне ашаячаклар»,—дидем. «Аңлыйм, аңлыйм... Менә шул инде безнең тормышның фаҗигасе»,—диде... Тагын бераз уйлап торганның соңында: «Сезне тагы күреп булармы соң, туташ?»,—диде. Мин бердән уйламаенча: «Менә ике көннән соң тагы театр була, мин бер театрны да калдырмыйм»,—дидем. Театр бетеп, китәр өчен күрешкәндә дә теге егет: «Сезне озату да мондагы йолага сыймый торгандыр инде, туташ»,—диде. Мин тагы: «Юк шул»,—дидем... Беренче мәртәбә үземнең шул йоладан җәберләнүемне хис иттем... Күрешкәндә ул минем кулымны бик озак кысты. Мин кызардым... Киткәндә ул аерым китсә дә, мин чыкканчы әллә нишләп мавыгып торды. Ишек янында тагы күземез очрашты. Бер сүз әйтмәенчә генә күз берлә хушлашты.

Мин төн буе әллә нинди татлы төшләр күреп йөдәп чыктым. Икенче театрны көтеп ала алмаенча йончыдым. Менә көне җитеп театрга киттек. Бу юлы безнең янымызга Мәрфуга әби дә тагылган иде. Мин юлга чыккач та Мәрфуга әбине калырга димләргә тотындым. «Соң бүген нишлиләр, Фәхри мирзаларның кызлары егетләр берлә кочаклашып биемиме соң?»—дип соравына каршы, «Юк, бүген бию юк»,—дигәч, «Алай икән. Чыгып сөйли генәме, андый такмазаны мин үзем дә беләм»,—диде дә үзенең ахирәте асламчы карчыкка керергә булды. Аны ат берлә илтеп куеп, кайтышлый алырга булып, театрга юнәлдек.

Урынымыз ложада иде. Кереп утырыр-утырмас, күзем берлә таныш егетне эзләргә тотындым. Ул партерда ике ягыннан буш ике урын арасында күзе берлә эзләнеп утыра иде. Күзебез очрашты. Баш иештек. Ләкин шуннан соң ул аптыраган кебек, мин монда, сез анда, дигән кебек борчылган бер хәлгә килде. Озак үтмәде, ул урыныннан торып чыгып китте. Безнең янга күрешергә килсә, инде каршы ложалардагылар күрерләр дә сүз булыр, дип куркынып торганда, кыңгырау шалтырады, утлар сүнде. Пәрдә күтәрелер-күтәрелмәс борын егетем ложамызга килеп керде. Күрешеп бетерер-бетермәс уен башланды. Шуңарга ул безнең ложада утырып калды. Ләкин уен бик шәп булмадымы, без арткарак тартылып утырдык та акрынлап кына сөйләшергә тотындык. Пәрдә араларында энем тәмәке тартыр өчен чыкты, керде. Ләкин нә ул, нә мин урынымыздан кыймылдамадык. Сүзгә мавыгып, мин тирә-юньнең сүзеннән куркуны да оныттым. Актык пәрдә арасында киләчәк театрда күрешергә булып аерылыштык.

Мәрфуга әбине алып өйгә кайттык. Без кайтканда әти яткан булса да, әни чәй әзерләп көтеп тора иде. Энем бик тиз чәен эчкәләде дә китеп ятты. Мин әллә нигә әнигә шул вакыйганы сөйләргәме-юкмы дип уйланып торганда, әни: «Нәрсә уйланасың, әллә берәр сүзең бармы?»—дип сорады. Әнидән яшерергә өйрәнмәгәнгә: «Бар шул»,—дип инәсеннән җебенә кадәр әнигә вакыйганы сөйләдем. Әни башын саллый-саллый тыңлады-тыңлады да: «Менә әтиең шул шуннан куркып театрга йөрүне яратмый, кем очраса шуның берлә буй кызга танышып йөрергә ярыймыни?»—диде... Мин: «Юк, ул начар кеше түгел, фәлән»,—дип бик кызып аны якладым. Аннан ары үземнең сүзләремнән үзем дә оялып кызардым. Әни: «Башта бар да яхшы була ул. Аннары гына начарлана. Кызларга сак булырга кирәк. Ата-ана ул белмәенчә бала-чаганы сакламый»,—диде... Мин төн буе шатлыклы-куркулы төшләр берлә борчылдым. Иртә торып чәй эчәргә утырганда, әтинең кыңгыр карамавын күреп, күңелем бераз тынычланды. Ләкин ашка кайтканда әти котырган эт кебек булган иде. Ул энемне бәреп җибәрде. Әнигә: «Балаларыңны үзең бозып бетерәсең!»—дип бик каты бакырды. Миңа килеп: «Сиңа кем кушты әллә нинди матамаллар берлә театрда кичәләр үткәрергә, ничек оялмадың? Ничек атам-анамның йөзенә кара ягам, дип алладан курыкмадың?» — дип акырды... Мин кызардым, бүртем, күзләреннән яшь ага торган әнине кызгандым, ләкин ни өчендер үземне гөнаһлы хис итмәдем. Эшләрем өчен бер вөҗдан газабы да сизмәдем. Әти бик озак дулаганнан соң: «Моннан соң театрга барырга рөхсәт юк!»—ди-

де... Иртәгәгә театрга дип алынып кайткан театр билетларын күреп, алардан үчен алган кебек, ваклап-ваклап ертып ыргытты. Аннан чәйнең тәме бетте, көн караңгыланды. Театр көнен, бигрәк кичен үткәрү бик авыр булды. Мин чигешемне алып утырсам да, бизәкләремне ялгыш чигеп, үрнәкләремне бутап, бармакларыма инә чәнчеп йөдәп беттем. Әти һаман дулаган кыяфәттә булса да, әни миңа элгәрегә караганда да шәфкатьлерәк кебек кыланды. Сәгать унбердән утларны сүндереп яттык. Әти: «Аятелкөрсиләреңезне укыңыз!»—дип кычкырды. Мин йокыга китә алмадым. Әтиләр бүлмәсе дә бик озак йокламаенча сөйләшеп ятты. Кайвакытлар салмак кына сөйли торган әнинең сүзләренең көе колагыма керде, кайвакытлар кайный торган самавыр кебек бер улап, бер гөжләп китә торган әтинең аерым сүзләре килеп бәрелде. Икенче көн тагы авыр булды. Минем эчем бик пошты. Теге егетне элгәре кызгандым, аннан соң сүзләрен ишетәсем килде. Аннан күптән бирле якынымнан аерылган кебек сагындым. Кулым эшкә бармады. Күңел күтәрелмәде. Көн үтте, тагы театр көне җитте. Әнидән тагы соратып карадым. Ул якын килмәде. Мин энемне генә җибәрергә уйладым. Аңарга тәмәке алырга үземнән акча да бирергә булдым. Ләкин әти аны да җибәрмәде. «Шул театрга моннан соң аяк басасыңыз булмасын!»—диде. Көннәр миңа бик авыр иде. Әллә нигә күңел ташыды, күзгә яшь тыгылды. Мин җырлаштыргаладым, өйдән өйгә, бүлмәдән бүлмәгә йөреп, бер эшкә дә кулым бармаенча көн үткәрдем.

Иртәгесен иртә сәгать унберләр булганда безнең капка төбенә бер ат килеп туктады. Ни күзем берлә күрим, арбадан теге егет килеп чыкмасынмы!... «Әни, килде!»—дип кычкырып җибәрдем. Әни урынынннан торып: «Кем килде?»—дип тәрәзә янына килде. «Теге егет!»—дидем. Әни: «Нәрсә кычкырасың, әллә кеше күргәнең юкмы?»—дип мине шелтәләп алганның соңында, егетне җентекли башлады. Үзе инде ни эшләргә дигән бер мәсьәлә алдында аптырап калды. Кыңгырау шалтырады. Әни әллә нәрсә уйлап катты. Ул бәлки асраугa: «Бар, исемен, йомышын сора да, абзый өйдә юк, дип кайтар»,—дияргә теләгәндер. Шул арада икенче кат кыңгырау булды. Мин: «Ник кешене көттерәсең?»—дидем дә, тизләп ишекне ачарга үзем чыгып киттем. Әни: «Нәфисә, ни эшлисең, тилердеңме әллә?»—дип кычкырып калды. Йөрәгем леп-леп итеп чыгарга теләгән кеби булганга, өй алдында бер сулу алдым да, үземне тотыбрак төшеп ишекне ачтым. Алдында берәр асрау чыгуны көтеп торган егетем аптырап калды. Мин дә аның аптыравын бетерер өчен: «Боерыңыз, боерыңыз, хуш килдеңез»,—дидем. Ул кызарды, каушады. Минем кулымны кысты. Өйгә керде. Әни бу көтелмәгән кунакка каршы ничек кылынырга лыгын белмәенчә, шәлен ябынып: «Боерыңыз, кунак!»—диде. Минем шатлануым йөземә йөгерде булырга кирәк, әни миңа күзе берлә әллә нәрсәләр ымлады. Ләкин мин аларны аңламадым да, тыңламадым да. Егетем: «Сез театрга бара алмадыңыз, туташ!»—диде. Мин бер авыздан: «Кая театрга барырга, әле тегесенең гөнаһларын да юып бетереп булмый. Сезнең берлә сөйләшеп утыруны әтигә сөйләгәннәр дә, әти кыямәт кубарды»,—дип, гүя, ул кыямәт беткән кебек сөйләп тә алдым. Әни тамак кырды, әллә нәрсәләр миңа ымлады, мин көлә-көлә, балалар кебек егеткә сөйли бирдем. Әни бер эш эшли алмаганга булырга кирәк: «Кызым, самавыр куярга әйт!»—диде. Егет: «Рәхмәт, рәхмәт, мин күрешеп чыгар өчен генә кердем, фәлән»,—дисә дә, мин дә аны чәй эчерәсем килгәнгә, икенче өйгә чыгып чәй урыны хәзерләргә куштым.

Мин кергәндә әни: «Сез кайдан, кем буласыз, әтиеңез, әниеңез кем, монда ник килдегез?»—дип сорашып утыра иде. Егет тә миңа күптән мәгълүм үзенең докторлыгын, хәзер гаскәргә алынганга, гаскәр хезмәтен доктор булып итүен, менә бер гаскәри һәйәт берлә хәзер Төркестаннан кайтышлый Оренбургта ике атнага туктауларын сөйли иде. Әни юри, миңа күп сөйләргә ирек бирмәс өчен кебек, сөйли, сөаль артыннан сөаль бирә бара, егетем дә җавапларны агызганнан-агыза бара иде. Менә самавыр керде. Чәй урыны хәзерләнде. Мин чәй салып ясарга утырдым. Әни, бер ка-

рарга кила алмаган кебек, алла ни уйлана башлады. Ахырдан ул икенче бүлмәгә чыгып телефон берлә әтине чакырды. Без егетем берлә икәүләп, бик шәпләп сөйләп утырганда минем колагыма әнинең акрынлап, салмаклап әйткән сүзләре арасында, әтинең кычкырган, бакырган тавышлары ишетелеп, куркытып куя иде. Мин тагы кунагым берлә сүзгә чумып аны онытa идем. Йөзе кәфен кебек ак булып әни керде. Урынына утырды. Үзе тирән иттереп: «Уф!»—дип сулап куйды. Аның авызыннан чыккан шул кайнар сулыш минем бөтен шатлыгымны яндырып, көйдереп китте. Минем йөрәгемә курку кабынды. Егетем дә әллә нәрсә сизенде. Әни: «Кызым, әтиеңә дә чынаяк куй, ул да хәзер кайта»,—диде. Шул сүзләр тагы мәҗлескә суыклык бирде. Егетем: «Сәүдәләр яхшымы, быел еллар ничек?»—дип сүзне дәвам иттерергә маташты. Ләкин әлгәре шактый ачылып киткән әни тагы тынды. Аның тавышына тутыгу кушылды, иреннәре ирене кенә әйләнә башлады. Күзен ишектән ала алмады.

Менә өй алдында дөбер-шатыр тавыш чыкты. Әни калтыранып китте. Минем бөтен тәнем буйлап бер суык йөгерде. Йөрәгем каты тибә башлады. Башы киселергә хөкем ителгән кеше кебек, башыма төшәчәк бәлане каршы алыр өчен кебек башым иелде. Егетем дә кызарды, бүртенде. Яшен ташы кебек әти килеп керде. Аның тавышына барымыз сикереп тордык. Ул әллә ни аптырап торган кебек булып китте. Беркем дә бер сүз дәшмәгән, дәшә алмаганга, озын бер пауза булды. Ул пауза шул кадәр озын сизелде ки, мин инде тәмам картайдым, чәчләрем агарды дип хис иттем. Аякларым дер-дер калтырады. Тешләрем бер-берсенә тиеп шыкылдады. Ахырдан әти акрын гына тавыш берлә: «Әссәламе галәйкем!»—диде... Шул дерелдәгән тавыш берлә әйтелгән сүз ата-ата дип торганда читтән тәгәрәгән яшен уты кебек, безнең барымызны да: «Аллага шөкер, калдык!»—дигән уйга китерде. Кызарган егет: «Вә галәйкем әссәлам!»— дип күрешергә кулын сузды. Әни: «Монда, карт, чынаягың монда!»—дип түргә урын күрсәтте. Мин: «Әти гафу кылды, егетне яратты»,—дип, көләч йөз берлә аның күзен эзли башладым. Күзләремез очрашты. Әти миңа: «Нигә бик сөендең? Бик зур эш эшләдем дип белдеңме?»—диде. Әни: «Менә чәең кайнарда эчеп ал!»—дип әтинең фикерен борырга тырышты. Тагы авыр бер тынлык басты. Егет: «Гафу итәсез, мин Оренбургтан үтеп баручы бер мөсафир, сезнең углыңыз, кызыңыз берлә театрда иттифакый урыннарымыз күрше тугры килде дә, сөйләшеп киттек. Шуның өчен сезгә кереп сәлам биреп чыгыйм дидем»...Әти тагы бер сүз дәшә алмаенча калды. Әни: «Рәхмәт, рәхмәт. Кунакка һәрвакыт ишегемез ачык. Безнең карт кунакны бик сөя»,—диде. Шуннан әни: «Кунак—доктор икән. Менә әле Төркестаннан әллә нинди бөтен авыруларны терелтә торган таш тапканнар икән. Шуны алып кайтып киләләр икән»,—дип, әтине сүзгә кушарга теләде. Әти кабыл итеп чәен эчеп ташлады. Тагы ясарга дип чынаягыны шалтыратып миңа төртте. Мин бөгелеп чәй ясарга керештем. Морҗа эченнән чыга торган тавыш берлә генә әти: «Бик яхшы, алай укыган егет булгач, шулай театрларда кызларны котыртып йөриләрмени? Хәлфәләрегез сезгә шуны өйрәттеме?»—диде. Егет әллә нәрсә әйтергә авызын ачты. Әни: «Андый эш юк бит, карт!»—диде. Минем кулларым калтырап самавыр борынын вакытында ябарга өлгерә алмаенча, чынаякларымны ташыттырып кулымны пешердем. Егет тагы кызарып бүртенде. «Мин урыс арасында яшим»,—дип үзенең мөселман гаиләсенә керергә теләгәненә дәлилләр китерергә өлгермәде, әти: «Яшә, урыс арасында яшә! Урыс арасында марҗасы беткәндерме?... Урысның себеркесе беткәндерме?... Алай бик мөселман булсаң, мөселман кызын юлдан яздырырга йөриләр димени?»—диде. Егет: «Гафу итәсез»...—дип тагы сүзгә керешә башлады. Әти ирек бирмәде, әллә ниләр сөйләп китте. Ахырдан: «Әле тагы оялмый, көпә-көндез өйгә килә бит, хурланып үләрсең»,—диде... Әни :«Мөселман кеше мөселман өенә ник килмәсен, һәммәмез бер ата-ана баласы бит»,—дип, сүз йомшартмакчы булды. Әти инде акырына-бакырына башлады. Егет берничә мәртәбә җавап бирергә маташты. Әти аны тыңламады. Мин аны кызгандым. Әтинең шу-

лай кылануыннан хурландым... Аңарга ярдәмгә килер өчен генә: «Тагы берне ясыйммы?» — дип сорадым. Ул: «Рәхмәт, рәхмәт!» — дип баш иде. Әтинең йөзе агарды. Чынаягын тоткан кулы суыкта туңган бала кебек дердер килде. Минем күземә яшь тыгылды. Егет, догасын кылып, йөзен сөртте дә аягүрә калыкты. «Рәхмәт хөрмәтегезгә, мин сезне борчыдым, гафу итегез!» — диде. Әти аптырап калды. «Утыр әле, берәрне эч!» — диде... Егет: «Рәхмәт... минем сезгә килүемдә һичбер начар уй, яман фикер юк иде... Урыс арасында яшәргә мәҗбүр булганга, үз тормышымызны сагынудан килгән бер яшьлек кенә иде. Гафу итегез!» — диде дә ишеккә таба борылды. Мин урынымнан тора алмаенча катып калдым, күземез күзгә очрашты. Мин күзем берлә әллә нәрсәләр әйтмәкче булдым, бик күп гафу үтенмәкче булдым. Күземнән мөлдерәп ике бөртек яшь тәгәрәде. Шуны күреп булырга кирәк, әти: «Бар чык үз бүлмәңә!» — дип кычкырды. Мин урынымнан торырга теләсәм дә, аягыма бик зур батман тимерләр тагылган кебек бер авырлык сизгәнгә, урынымнан кыймылдана алмадым.

Ишек ачылды, ябылды, егет югалды. Минем күземнән яшь агу туктамады. Түр башында әни тавышланып еларга керешге. Әти котырган бүре кебек әллә ниләр сөйләп, кычкырып бакырып, идән буе йөреп-йөреп шелтәләргә, тиргәргә тотынды. Минем башым үз фикерем берлә мәшгуль булганга, әтинең бер сүзен дә ишетмәдем. Кычкыру-бакыруына колак салмадым. Ләкин әнине бик кызгандым. Аннан да битәр мыскыл ителгән егетемне аядым. Аның алдында үземне бик зур гаепле хисаплап, эчемнән яндым, көйдем... Көн бик авыр үтте. Беркем беркем берлә сөйләшмәде.

Мин кич берлә намаздан соң бик озын коръән укып яттым, күңелем бераз басылган кебек булды. Ләкин иртәгесен тагын бер авыр йөк басты. Шәмси кодаларга кызлар мәҗлесенә чакыру килде. Әни бик җибәрергә теләсә дә, бармадым. Йомшарып килә торган әтинең сүзләренә дә җавап та кайтармадым. Әллә ник аның йөзен күрәсем, сүзен ишетәсем килми иде. Төн буе саташып, йөдәп чыктым. Егетемне әллә ничә төрле төстә, бер елый торган иттереп, бер көлә торган иттереп, бер әллә нинди марҗалар берлә бии торган иттереп күрдем. Ләкин һәммәсендә миңа таба омтыла, мине эзли кебек бер нәрсә күргән кебек булдым. Иртә берлә чәй дә эчмәдем. Аш вакытында аш та ашый алмадым. Әти дә, әни дә: «Аша, аша!» — дип кыстасалар да, моңаеп китеп, чыдый алмаенча еглый башладым, аштан торып китеп, үз бүлмәмә кереп бикләндем дә бик озак еглалдым, әни килеп юатса да, тәэсир итмәде. Мине бердән егетемне күрәсе килү хисе шулкадәр куәтле көенчә биләде ки, аңарга һичбер куәт каршы килерлек түгел иде... Мин аны күрер өчен юллар эзләргә тотындым. Телефон берлә сөйләргә булдым. Номерына барырга кадәр җиттем. Ләкин нә адресын белмим, нә урамын, нә башкасын. Мине әллә нинди бер куәт урамга таба төртә башлады. Анда әллә нинди микънатис* ташы, бик көчле микънатис ташы мине өстери башлады. Мин әнигә: «Башым бик авырта, ат берлә йөреп керим», — дидем. Әни: «Бар, кызым, бар», — диде.

Йорт карауччы да, су ташучы да, ат башында йөрүче дә булып тора торган, бер кулы чулак, аягы чатан Зарифны ат башына утыртып чыгып киттем. Иң әүвәл рус номерлары күбрәк урамнарга бардым. Күзем берлә урамның ике ягын да сөздем. Аннан соң халык күп йөри торган зур урамызга борылдым. Аннан да ике яклап эзләп чыктым. Анда да очрата алмадым. Шул бәхетсезлегемә көенеп, эчем тагы пошты. Адресыны сорап алмавым өчен тагын үземне-үзем шелтәләдем. Озын урам буйлап кайтырга дип атны бордым. Еракта гәзитә сатучы янында аның төсле бер шәүлә күрдем, атны кызулатып барып җиттем. Якынайган саен аңарга охшый иде. Барып җиткәч, ачык иттереп борылып карасам, бер урыс егете гәзит тоткан да укып бара. Шул урыс малаена аяк арасында чуалып йөрүе өчен шулкадәр ачуым килде, шуны төшеп бәреп-сугып егасым килде. Өметсезләндем, көчсезләндем. Уйларымны җыяр өчен Каргалы очына барырга куштым.

---

* Микънатис — магнит.

Кучер минем капризларымны тыңлый-тыңлый йөдәп беткәнгә, мыгырдарга тотынды. Мин алай да үз сүземне иттем, киттем. Ни күзем берлә күрим, бер урамның чатында акрын гына атлап егетем каршы таба килә. Ерактан ук таныдым. Йөзен-кыяфәтен җентекләргә тотындым. Әллә нинди бик тирән уйга чумган кебек тоелды. Кем белсен, бәлки, мине уйлый торгандыр, дидем. Тугрысына килеп җиткәч тә кычкырдым. Ул аптырап китте. Каретам ябык булганга, тавышның кайдан килгәнен белмәенчә, тирә-юнендә эзләнә башлады. Мин тагы көлеп чакырдым. Аның күзенә, йөзенә әллә никадәр гаҗәпкә калу чыкты. Ул ни эшләргә белмәенчә арба янында аптырап торганда: «Утырыгыз, бераз йөрик!»—дидем. Утырып киттек. Мин үземнең мәшәкатьләрем мәгънәле чыкканга, тагы кәефем килде. Ләкин, мәгаттәэссеф*, нә сезнең адресыңызны белмим, нә телефоныңызны... Мин сезнең алдыңызда бик зур гаепле. Әтинең алай кылынуы өчен мине шелтәләмәгез инде, ул бит иске заман кешесе, үз үлчәве берлә үлчи, сезне мыскыл да итте, мәсхәрә дә итте, гафу итегез»,—дидем. Ул тагы көтелмәгән бернәрсә алдында баскан кебек аптырап китте булырга кирәк, миңа җавап бирмәенчә калды. Мин, моның хурлануы бик тирән икәнен хис итеп, тагы: «Беләмсез, бу эш минем күңелемдә шулкадәр ачы яра ачты. Минем җанымны шулкадәр өшетте. Минем яшь башыма шулкадәр авыр бер йөк такты. Мин аны күтәрә алмыйм. Ул мине баса, ул минем башымны күтәреп айга-көнгә каравыма ирек бирми... Сез инде бәхил булыңыз! Миннән шул авыр бәхетсезлекне алыңыз, гафу итеңез!»—дидем, ялварып аның йөзенә бактым. Аның күзләре зурайган, йөзе кызарган, төсенә әллә никадәр көчләнү чыккан иде. Мин шуны күреп курыктым да, аптырадым да, калтырап та киттем. Ул, бердәнбер сүз әйтмәенчә, калтыраган-дерелдәгән куллары берлә минем кулымны алды да авызына китереп үпте.

Шуны җибәрергә теләмәгән кебек тагы бер үпте, тагы бер үпте. Шул үбүләрдән минем тамырыма әллә нинди тынычландыра торган җылы, йомшак бер агым акканга, мин кулымны да ала алмадым, каршы бер сүз дә әйтә алмадым. Менә мин кулыма ике бөртек җылы яшь тамганны хис иттем, күңелем әллә ни эшләп китте. Мин калтырандым. Егетем шуны сизепме, оялыпмы, кулымны җибәрде. Күзләремез күзгә очрашты. Егетнең керфекләре кипмәгән, күзлек арасында әллә нәрсә нуры—мәхәббәтме, бәхетме коела кебек тоелды.

— Бу мәсьәләдә бит гафуны сез түгел, мин сорарга тиеш. Мин бит тәмле тормышыңызга тупасча кереп тынычлыкны боздым. Мин бит сезнең берлә атаңыз арасында аңлашылмау ачылуга сәбәп булдым. Сез мине гафу итеңез!—диде. Шул сүзләрме, шуларның әйтелүеме, шундагы сүзләрнең эч күңелдән чыгуымы, мине тынычландырып җибәрде. Мин: «Димәк, бетте, сез үпкәләмисез?»—дидем. Егетем: «Бетте, ул сүз бетте, сезгә үпкәләмәдем дә, үпкәләргә хакым да юк. Ләкин менә, туташ, бу безнең очрашулар, минем алдымда яңа бер нәрсә ачты. Мин сезнең бик тирән күңелле икәнлегеңезне күрдем. Шул олуглык минем, ихтиярлы-ихтиярсыз, башымны идерде. Хәзер миңа сездән аерылып китү бик авыр булачак. Еракта гына булса да, сезнең барлыгыңызны хис итмәү, миңа бик зур мәхрүмлек булачак»,—диде. Мин һәрнәрсәне онытып: «Сез китәсезмени?»—дидем. Ул да кыска гына итеп: «Әйе»,—диде. Мин: «Бөтенләйме, һичбер кайтмаскамы?»—дип сорадым... Ул җавап бирмәде. Мин аптырап калдым, миндә, бердән, балалар кебек, мин дә барам, дип елыйсым килү, ялынасым килү уянды. Икенчедән, үземнең кызлыгымны хис итеп, үземне тоту фикере алга килде... «Кайчан соң?»—дидем... «Иртәгә!»—диде... Тагы тынлык басты. «Ник соң бик тиз?»—дидем. «Шулай булды, безнең комиссия иртәгә китәргә карар ясады. Мин бүген сезне күрә алмаммы дип көн буе йөдәп чыктым. Берничә мәртәбә телефоныңызны кактым. Кибетне китерәләр дә бирәләр. Йортыңыз тирәсеннән дә әйләндем. Төрле хәйләләргә

* Мәгаттәэссеф — кызганыч ки.

сапмакчы булдым. Ахырында тагын кыңгырау биреп өегезгә кадәр килергә дә уйладым. Сезне авыр хәлгә кую фикере тотып калды. Сезне күрмәенчә, китсәм, мин үземне бик зур бәхетсезләрдән санаячак идем»,— диде. Мин дә ничек күрергә теләүләрдән, ике сәгатьтән бирле шәһәр кыдырып йөрүемне сөйләдем. Бу сөйләүләр безнең арада калган соңгы бер пәрдәне дә алды. Ятлыкны бетерде. Безне тәмамән үзләштерде. Без тагы сүзгә баттык. Менә чулак чатан: «Инде миңа суга барырга кирәк, кайтамызмы?»— диде... Бу сүз бердән миңа башыма авыр нәрсә берлә суккан кебек булды. Мине уятып җибәрде, йортымызны, әтине, әнине күз алдыма китереп бастырды. Шуның янында кычкырынып китеп бара торган поезд да егетемне китереп куйды. Мин аптырап киттем. Егет тә агарды. Ул көчләнеп: «Безнең шул мөнәсәбәтемез шулай өзеләме инде... шунда тыныш куеламы?»— диде. Мин чулакның суга барасы килүе өчен, шул татлы минутларның бетүенә хурландым. Мыскылландым... «Юк!»— дидем... Ләкин чулакның артыннан әтинең шәүләсе, әллә никадәр гайбәтче хатыннарның сыннары килеп басканга аптырап калдым, икеләнгән кебек булдым. Шуны басар өчен тагы бер мәртәбә тирән иттереп: «Юк!»— дидем. Ул тагы минем кулымны кысты. Бер сүз дә әйтмәенчә күздән-күзгә вәгъдәләштек. Иреннәремез иренгә тиде... Егет: «Минем ике-өч айдан соң хезмәтем тәмам була, кулыма кәгаземне алгач та, минем беренче эшем монда чабып килү булачак. Сезне хәзерге кебек табуыма ышанып китәм»,— диде. «Ышан, ышан!»— дидем. Хатлар өчен адреслар алышып, озын көннәр күрешмәсәк тә, вәгъдәләрне беректереп аерылыштык. Егетем чулакка бер тәңкәлек көмеш тоттырганга, аның да мыгырдавы бетте.

Уема батып өйгә таба борылдым. Әллә нинди сүзне оныттым кебек, әллә нинди бер хәрәкәтне ясап бетермәдем кебек, күңелемнең бер кырыен әллә ни кытыклый башлады. Ахырдан, ник ядкарь өчен бер нәрсәсен алмадым, дигән уйга килдем. Аның артыннан ник үзенә бер сагынмаклык бирмәдем, дигән фикердә чуала башладым. Шул уйлар тагы әллә никадәр уйлар уятканга, иртәгә поездга мотлака төшәргә, дип, вә шунда бер бүләк чыгарырга, дип карар ясадым. Бердән күңелемә бер фикер кылт итеп төште. Чатанга: «Ашчы Сәхибәгә тукта!»— дидем. Чулагым мыгырдап туктады. Ут кебек сикереп төшеп, Сәхибә әбигә кердем: «Тозтүбәдә бер фәкыйрь кардәшемез кияүгә чыга, шуңарга чәкчәк бүләк җибәрмәкче булам. Иртәгә китүче бар, үземездә пешереп тора алмыйбыз, шуны иртәгә сәгать алтыда тәмамән өлгертеп бирә аламсың, әби!»— дидем. Поезд сәгать жиде дә унбиштә китә иде. Әбием: «Хәзер бит йомыркасы бәһале, мае кыйбат, балы да искиткеч, утын да күп китә»,— дип бик күп сөйләде. «Күпме кирәк соң?»— дигәч, цифрны әйтмәенчә тагы әллә ниләр сөйләп китте. Мин янчекне ачтым да бер егерме бишлекне бирдем. Әби акчаларны күреп булырга кирәк: «Тагы берәр юкмы?»— диде. Тагы бер унлыкны төртеп, вәгъдәсен ныгытып чыгып, татлы уйлар берлә өйгә таба киттем.

Капкадан керү берлә мин, башымны суык су койган кебек, дерелдәп киттем. Баягы шатлыгым, кәефем бердән югалды. Төн буе йоклый алмадым. Иртәгесен әллә нинди кәеф берлә кәефсезлектән мөрәккәб* бер хис астында калганга. Әни дә шуны күреп бераз аптырады. «Әллә, кызым, берәр нәрсә бармы?»— дип сорады да... Теге өйдә чулактан да әллә ниләр сорап маташты. Вакыты җитә башлагач, әнидән тагы йөреп керергә сорадым. «Бар инде, берәр нәрсә эшләп йөрми торгансыңдыр бит»,— диде... Рәтләп җавап та бирмәенчә, әти Мәкәрҗәдән бүләк итеп алып кайткан йөзегемне кидем дә, Сәхибә әбигә таба киттем. Как-төш искиткеч уңышлы чыккан иде. Камыры килешкән, май сеңдермәгән, балы каралмаган иде. Аның өстенә әбием ике ягына да төрле конфетлардан «Нәфисә» дип язган да иде. Бик кәефләнеп төреп алып вокзалга чаптырттым.

Поезд китәргә чирек сәгать кенә калган иде. Таныш-белеш очрар фәлән дип уйламаенча да платформага чыктым да, икенче, беренче класс-

---

*Мөрәккәб — торган.

ларның тәрәзәләреннән күземне йөртеп эзли башладым. Менә ачык бер тәрәзә алдында егетем ак сакаллы бер урыс берлә басканнар да сөйләшеп торалар. Мине күргәч аптырап китте, кызарды. Карт урыс көлеп әллә нәрсәләр әйтте. Бу миңа каршы чыкты. Коридорда очрашып сөйләшә башладык. Ләкин бик күп кеше йөри башлагач, ул мине купеларына алып керде. Карт урыска башымны идем. Кулымдагы чәкчәкне өстәл өстенә куеп: «Сезгә юл бүләге»,— дидем. Аннан тиз-тиз итеп имән бармагымдагы алмаз кашлы йөзегемне суырып алдым да: «Сагынмалык булсын, бер дә бармагыңнан төшермә»,— дип, кулына суздым. Егетем тагы аптырады, карт урыс н да оялдымы, кызарды, әле бер бармагына, әле бер бармагына кимәкче булып карады, берсенә дә сыймады. Мин кулын алдым да чәнчә бармагына кидердем. Урыс та, мин дә көлештек. Шуннан соң тагы теге вәгъдәләрне берничә мәртәбә ишеткәннең соңында мин китәргә калыктым. Бер нәрсә оныткан кеби уйландым. «Нәрсә, тагы әллә берәр сүз бармы?» — диде. «Миңа сагынмалык берәр нәрсәңне калдыр»,— дидем. Ул: «Мин очрашуны һич уйлый алмаган идем, бер нәрсә хәзерләмәдем»,— диде. Күзем өстәл өстендә ята торган бер китапка төште. «Бу синекеме?» — дидем. «Минеке»,— дип, Тургеневнең «Беренче мәхәббәт» дигән хикәясен сузды. Теге бабайга баш иеп, тагы күрешеп атыма утырып өйгә таба чаптым. Әтидән биш кенә минут элек өйгә кайтып өлгердем.

Әни әллә нәрсә сизенгән кебек булды. Мин хыял дөньясында гизә башладым. Менә әти тагы турсайды. Әтигә әллә кемнәр әллә ниләр килеп сөйләде. Мин өмет берлә өметсезлек арасында яши башладым. Юлдан, Мәскәүдән хатлар алгач, тагы тынычланып кәтә башладым. Театрга, әдәбият кичәсенә әти җибәрмәгәнгә, кызлар мәҗлесенә үзем барырга теләмәгәнгә, мин бөтенләй өйдән чыкмас булдым. Һәр мәҗлестән, театрдан калмый торган бер кызның болай ябылуы бик күп гайбәткә сәбәп булды. Вокзалда, театрдагы очрашулар тагы әллә ничә төрле иттереп сөйләнде, ахырдан: «Нәфисә бер урыс егетенә гашыйк булган икән»,— дигән бер гайбәт бөтен шәһәрнең авызында тәсбих кебек йөри башлады. Шулар әтине бик хурландырды, әнине дә бик кайгырттты. Алар, кызымызга урын чыкмый кала инде, дип төн буе кайгырышып сөйләшеп ята торган булдылар. Менә шул арада булмады, Орский шәһәреннән миңа яучы килде. Әтиләр, әниләр бик сөенделәр, тәмам бирергә вәгъдәләшергә хәзерләнделәр. Мин бөтен көчем берлә каршы килергә тотындым. Мин кияүгә чыкмыйм, дидем, авыруга башымны салдым, еладым, илтифат иткән булмады. Ахырдан әтигә егет берлә булган соңгы вакыйгаларны тәмамән аңлаттым. «Башка беркемгә дә чыкмыйм»,— дидем. Әни минем яклы кебек булса да, көчсез булганга, бер эш эшләвенә ышана алмадым. Егетемә хат өстенә хат яздым. «Эшләр бик мөшкел була башласа, телеграм бирермен, килергә хәзер тор»,— дидем.

Менә бер көнне әти: «Киләсе дүшәнбегә мәҗлескә аш-су хәзерләңез, колак сөенече мәҗлесе. Мин кибеттән өндәү чыгартырмын»,— диде. Мин ап-ак булдым. Калтырадым, дерелдәдем... Әллә ни әйтәсем килде, авызымны ача алмадым. Ахырдан теге егетемне, аңарга биргән вәгъдәмне хәтерләдем дә, әтигә туп-тугры иттереп: «Мин бармыйм, әти... Теләсәңез нишләңез! Бармыйм»,— дидем дә, бүлмәмә чабып чыгып киттем. Ябылып бик озак еладым. Әнинең сүзенә дә, юатуына да, тиргәвенә дә карамаенча, чыгып китеп почтага барып озын иттереп телеграм бирдем. Башым чуалган булганга, әллә ниләр язып бетердем. Шуннан тегеннән җавап көтә башладым. Хат та, хәбәр дә юк. Бик борчылдым. Гаскәр хезмәте тулыр өчен әле тагы айдан артык вакыт калганга, килә алуына бик шөбһәләндем. Менә көтә-көтә көт булып өметсезләнергә җиткәндә, бер җомга көнне үземне әллә ничек җиңелчә хис иттем. Күңелле төшләр күреп уяндым. Җырлапкөйләп бүлмәдән бүлмәгә йөри башладым. Шуны күреп әни дә кәефләнде. Ахырсы, минем күңелемдә үзгәрү булды дип уйлагандыр, миңа ул: «Һәрвакыт шулай була, язганнан узып булмый, ата-ананың догасыны алсаң, бик һәйбәт торырсың, фәлән»,— дип сөйләде. Ләкин мин аны ишетмәдем дә,

тыңламадым да. Менә җомга җитте, әти җомгага китте, әни тәһарәтен алып үз бүлмәсендә өйлә намазына утырды. Бердән телефон. Бардым, «Тыңлыйм!» — дим. «Нәфисә синме?» — ди егетем ачык тавыш берлә. Мин: «Синме, кайчан килдең?» «Бүген сәгать 10 да, менә телефон итәр өчен җомга башланганны көттем», — диде. Мин бер минутта бөтен вакыйганы сөйләп ташладым. Сәгать дүрттә шәһәремезнең бер урыс кибетендә очрашырга сүз алдым. Аңгынча карт хәзрәткә барып, мәсьәләне аңлатып, аны яучы итеп җибәрүнең кирәклеген белгерттем. Сүз арасында: «Ничек җибәрделәр соң, әле гаскәр хезмәтең бетмәгәндер бит?» — дип сорадым. «Синең чәкчәк аркасында. Ул карт — минем башлыгым, профессор иде. Чәкчәкне бик яратты, сиңа да Чәкчәк дип ат кушты. Телеграмың килгәч, тоттым да үзенә бардым. Мәсьәләне сөйләдем. Оренбургка командировка бирде дә җибәрде», — диде. Теге өйнең ишеге ачыла башлагач, телефонны кистек.

Мин бик һәйбәтләп тәһарәт алып, зур бер ихлас берлә намаз укырга керештем. Егетемне китереп җиткерүе өчен, миңа ярдәме өчен аллага шөкранәм шулкадәр зур иде, мин намазым беткәч тә, намазлыктан тора алмадым. Коръән укырга тотындым. Укыдым, укыдым, тагы аз булган кеби булды, тагы укыдым. Әти кайтты, самавыр керде, аш башланды. Мин һаман Коръәннән аерыла алмадым. Әни берничә мәртәбә килеп китте, ул да мине бүләргә базынмады. Догамны кылып, тәмам тынычланып чәйгә чыктым. Әти дә, әни дә мине Орскийгә бару фикеренә иялəшә дип уйлаганга, егетнең килүеннән хәбәрләре булмаганга, бик йомшак мөгамәләдә булдылар. Әти: «Менә кирәгеңез-фәләнеңез булса, кибеткә чыгыңыз, яңа маллар килде, сайлап алырсыз», — диде. Әни: «Чыгарбыз да шул!» — дип куйды. Мин: «Сабак абыстай берлә күрешеп киләсем килә иде», — дидем. Әни дә, әти дә: «Бар, бар! Ат җиктер дә бар», — диделәр. Әни тагы: «Үзенә берәр күлмәклек алып бар», — дип куйды.

Мин сәгать дүртләргә кадәр алай итеп, болай итеп вакытны суздым. Дүрттә тугры ук теге кибеткә барып кердем. Егетем почмакта әллә нинди яулыклар сайлап тора иде. Мине күрү берлә каршы килде. Мин аз гына кочагына атылмадым. Тиз генә алган нәрсәләрене алып, атка утырып чыгып киттек. Зират янына барып бик озак сөйләштек, сүзне беркеттек. Ул хәзрәткә барган, мәсьәләне аңлаткан. Хәзрәт тә бүген ястүдән соң яучы булып килергә вәгъдә биргән. Мин дә үземнең сабак абыстам, хәзрәтнең тол кызына барып сөйләячәгемне белгертеп, төрле ихтималга каршы төрле вәгъдәләр ясашып аерылыштык. Сабак абыстама туп-тугры киттем, бүләгемне бирдем. Догасыны үтендем. Үзем әллә ник моңаеп киттем дә еглап җибәрдем. Абыстай: «Яучы килгән дип әйтәләр, алла хәерлесен тугры китерсен, Орский шәһәре бик матур, фәлән», — дип мине юатты. Мин ачтым да мәсьәләне сөйләп бирдем. Сабак абыстай аптырап калды. Егетемнең монда килүен, карт хәзрәт берлә бүген бик озак сөйләшеп, аның яучы булып баруына вәгъдә алуын аңлаттым... Аңардан да: «Ярдәмдә булыңыз инде», — дидем... Сабак абыстай: «Изге эшкә без һәрвакыт ярдәмдә, мин бит әниеңнән башканы күрә алмыйм», — диде. Мин хәзрәткә сөйләргә үтенеп киттем.

Мин кайтканда өйдә бер дә яңалык юк кебек иде. Кичкә таба гына әти: «Ясигъдән соң хәзрәт киләм дигән. Пылау салып, чәй хәзерләп көтеңез!» — дип телефон итте. Мин көтәргә тотындым. Вакыт җитте, хәзрәт килде, чәй бирелде. Хәзрәтнең бер йомыш берлә килүе билгеле булганга, әни дә нәрсә сөйләгәнен ишетер өчен, мин дә әтинең ни җаваплар биреп, эшләр нигә барачагын күрер өчен, бүлмә ишеге янына килеп утырдык. Берәр чынаяк чәйдән соң хәзрәт сүзгә кереште. Миңа мәгълүм сүзләрне сөйләп әтидән җавап көтте. Моны ишеткәч әни: «Уф!» дип сулап куйды. Миңа күзен тирән иттереп батырды. Әти яшен суккан кебек бер сүз дәшә алмаенча, аптырап, җавапсыз калды. Хәзрәт егетне сөйләп китеп: «Урыс арасында тора торган кеше, үзен-үзе саклап, мөселман гаиләсенә катышырга теләве өчен мин тәхсин укыдым. Нишләр идек, бер марҗа тотып:

«Хәзрәт, никах укы»,—дип килсә, яисә никахсыз-нисез балалар атасы булып, урыс кубәйтсә. Мин бу егетне бик яраттым»,—диде. Әти: «Хәзрәт, сез дә шундый сүзләр сөйләгәч, безгә, надан кешеләргә ни кала инде»,—дип хәзрәт берлә моназарәгә керешге. Ахырдан: «Безнең инде, хәзрәт, Орскийлар берлә ярты вәгъдәмез бар. Рәхмәт сезгә! Ләкин, хәзрәт, сез шундый ярты урыслар артыннан олуг башыңызны кече итеп йөрү кирәкмәс иде»,—диде. Хәзрәт: «Без пәйгамбәр галәйһе әссәламның варислары. Кем безгә дин эшендә мохтаҗ һәммәсенә ярдәмгә итешү дини вазыйфабыз»,—дип тагы җавап бирде. Әти тагы әллә ниләр әйткәләгәнгә, хәзрәт кызып китеп: «Ахмак!»—дип, әтине тиргәп тә ташлады. Тагы йомшардылар, тагы сөйләштеләр. Әти тагы кисеп: «Юк!»—дип җавап бирде. Хәзрәт: «Җәмәгатең берлә сөйләшеп карарга кирәк, кызыңның хәлен дә белергә кирәк»,—дисә дә, әти һаман үз сүзендә торды. Чыгып киткәндә хәзрәт: «Хата итәсең, хата итәсең, үзсүзлек кенә итәсең, уйлаш, мин әле тагы килермен»,—диде. Әтинең: «Олуг башыңызны кече итеп йөрмәңез, хәзрәт»—дигән сүзенә каршы ул: «Башымыз шул шулай вакытында кече итә белгәнгә күрә ул олуг булган, изге эшне болай кисәргә ярамый, җәмәгатең, гаиләң берлә киңәшләш, иртәгә килермен»,—диде... Хәзрәт киткәч, әти тагы ду килде, әни тагы елады. Ләкин мин, ярты эш бетте кебек хис итеп, һичбер борчылмадым. Иртә берлә сәгать уннарда тагы хәзрәт килде. Бу юлы хәзрәт ачыктан-ачык минем хакта, минем разыйлыгым хакында сөйләп: «Эшне матур итәргә кирәк, егет бик һәйбәт. Сезгә нәрсәгә дәүләт кирәк, алла бәхетләрен бирсен, фәлән»,—дип бик күп үгетләде. Әти һаман сүзендә булды.

Өйләдән соң аш вакытында сабак абыстай килде. Әни ашасыннан әтигә бик күп сүз сөйләде. Әни разый булса да, әти тискәрелегеннән кайтмады. Мин, сабак абыстайны озату сылтавы берлә чыгып, егетем янына киттем. Ул тәмам куырылган, пәжегән иде. Хәзрәтнең сөйләгәннәреннән әтинең кылынуларын белеп, өметсезләнгән, аптыраган иде. Мин аңарга: «Мин актыгына кадәр барам, булмаса, синең берлә китәм дә, Уфага барырмыз да, анда собраниеда мөфти хәзрәттән никах укытырмыз»,—дидем. Ул минем кулымны тагы бик каты кысты, аның йөзе ачылды. Күңеле күтәрелде. Төрле планнар уйлап, без тагы йөреп киттек. Сөйли-сөйли вакыт озаеп киткәнгә, кич булды. Мин өйгә кайтудан тагы әтинең акыру-бакыруын ишетүдән курыктым. Шул мәсьәләнең эт эчәгесе кебек сузылып китүенә эчем пошты. «Әйдә хәзрәтләргә барыйк та, никах укырга сорыйк»,—дидем. Ул күзен тутырып, ышанмаган кебек: «Шуңарга кадәр барамсың?»—диде. «Ник бармыйм, әйдә!»—дидем. Ул: «Шуның ахырларын беләмсең, әтиең, әниеңнең никадәр рәнҗүләрен күрәчәксең?»—диде. Миңа шул сүзләр ул вакыт әллә нигә һич тәэсир итмәде. «Һәммәсенә разый!»—дидем дә атны хәзрәтләргә борырга куштым.

Хәзрәт безне икемезне бергә күргәч, бераз уңайсызланып: «Ни йомыш соң?»—диде. Егетем: «Хәзрәт, без сездән никах укытырга дип килгән идек. Үзеңез беләсез әхвалне»,—диде. Хәзрәт: «Ашыга төшәсез, ашыга төшәсез, яшьләр шул, яшьләр»,—диде... Тагы безне аерылып кайтып китәргә димләде. Үзе иртәгә тагы әти берлә сөйләшергә вәгъдә бирде. Без икемез дә бик каты торгач: «Мин менә намазга барып килим, аннан соң карарбыз»,—диде. Безгә самавыр куеп, чәй хәзерләделәр, озак үтмәде, әни килеп җитте. Мине кайтырга чакырды, елады, ялварды. «Кайтмыйм!»—дидем.

Хәзрәт берлә бергә ястүдән соң әти керде. Ул мине каргады, егетемне тиргәде, хәзрәт берлә моназарәгә керешге. Мине көчләп алып китмәкче булды. Мин кайтмадым. Хәзрәт: «Болай булмый, әйдәңез, барымыз да барып, өеңездә иҗабе кабул итик*»,—диде. Әти һаман разый булмады. Мин абыстай ашасыннан хәзрәттән никах укуын үтендем. «Булмаса, без барыбер Уфага барып та укытачакмыз»,—дидем. Бу эш әтине тәмам тилертте,

*Иҗабе кабул итү — ярәшү.

әнине дә шаштырды: «Син ни эшлисең? Син бит йөземезгә кара ягасың, фәлән»,— дип шелтәләргә тотынды. Ахырдан әти: «Ярый, әйдә, кайтсын, иртәгә карармыз, фәлән»,— диде. Мин: «Менә шунда никах укылмаенча, бу өйдән чыкмыйм»,— дидем. Хәзрәт аптырады. Әтигә тагы нәсихәт итеп карады. Ахырдан: «Без — шәригать кешесе, без диннең хөкеменә каршы килә алмыймыз. Кыз, егет икесе дә шуны теләгәч, никах укыймыз»,— диде. Әти һаман: «Мин разый түгел!»— диде дә торды. Хәзрәт чалмасын киде. Метрикасын алды: мәдрәсәдән ике хәлфәне чакыртты. Шулар алдында тагы бер мәртәбә әтигә әйтте, тагы әти: «Юк!»— диде. Әни кычкырып елларга тотынды. Хәзрәт кычкырып, безнең икемезнең дә разыйлыгымызны сорап, миннән өч мәртәбә «разыймын» дип үз авызымнан әйттереп, кычкырып никах укыды. Шуннан соң әтигә карап: «Инде нишлисез, болар хәзер ирле-хатынлы булды, ләкин һаман сезнең балаңыз, тискәреләнмәгез!»— диде. Әти бер сүз эндәшмәде, әни һаман елады.

Барымыз урамга чыктык, әти берлә әни алдан киттеләр. Без икәүләп артларыннан киттек. Капка төбенә барып җиткәч, никтер туктадылар. Минем күңелем йомшарды, бардым да әнигә: «Бәхил бул, әни»,— дип муенына сарылдым, елый башладым. Аннан әтине кочакладым. Өчемез дә елашырга тотындык. Егетем тик катып калды. Капка ачылды. Әти берлә әни керде. Мин басып калдым. Әти: «Әйдәгез, әйдә, Нәфисә!»— диде. Мин: «Ялгыз керә алмыйм, кермим»,— дидем. «Икеңез дә керeңез»,— диде. Кердек. Берәр атнадан соң мәҗлес ясап туй иттеләр, ләкин туемыз зур булмады. Бер атнадан мин киявем берлә Мәскәүгә киттем. Менә шуннан бирле бергә яшимез. Аллага шөкер, бу көнгә кадәр арамызга бер кер төшкәне юк»,— диде дә туктады. Үз бәхетеннән үзе шатланган кебек, аның йөзенә тагы елмаю йөгерде. Ул тәмле иттереп сулап куйды.

Гөлсем: «Сез бигрәк бәхетле булгансыз икән... Ләкин шул кадәр иттереп нык тотынырга сезгә кем гакыл бирде?»— диде. Нәфисә: «Беркемнән бер киңәш сорамадым. Беркем берни өйрәтмәде. Уйлап та тормадым. Күңелем ни кушты, шуны эшләдем, шул барып та чыкты»,— диде. Яңа хатын тагы кызыгып карап торганның соңында: «Бу соң сезнең беренче сөюеңез идеме?»— диде. Нәфисә: «Беренче һәм соңынчы сөюем... Безнең әле сөешүемез беткәне юк. Мин әле менә иремә барам, теге көнге хәзрәтләргә баргандагы хис берлә, күңел теләге берлә барам»,— диде. Тагы көлемсерәп уйга батты. Аның күзе алдында тагы күрешү монзарасы үсте, күрәсең, ул тагы эченнән көлде. Гөлсем: «Ирeңез соң кайда, кая барасыз?»— диде. Нәфисә: «Минем ирем Мәскәүдә үпкә авыруы докторы. Үткән елны бик күп эшләп, приват доцентлыкка имтихан тотты. Ләкин мөселман булганга, министр тәсдыйк итмәде. Шуңарга шактый борчылды. Иптәшләре арасында татар дип кимсетүгә дә хурланды. Бу урыс хезмәтнең кадерен барыбер белми, бала-чага да үсә, урыс арасында яшәүдән мәгънә чыкмас, дип йә Казан, йә Әстерханга урынлашыр өчен эзләнергә, белешергә дип чыгып китте. Йөри торгач, рәтле урын очрамагач, Мәскәүдә үк калырга карар иткән. Безнекенең Мәскәүдә кадере бик зур. Ул «Җәмгыяте хәйрия» рәисе, мәктәп комитетының башы. Аннан башка Мәскәүдә бер эш тә эшләнелми. Бөтен киңәш бездә, бөтен авырулар бездә, балаларга үз халкымыз арасында торырга уңай булсын дип, бер зур мөселман авылы янында кечкенә генә җирле, сулы, бакчалы бер утар сатып алган. Менә хәзер беренче мәртәбә шуны күрергә барамыз. Киләсе елдан, насыйп булса, ат, сыер алып, бөтен җәйне шунда үткәрәчәкмез. Бала-чага нинди тирә-юньдә үссә, шуның гадәтен ала... Без тора торган җирдә һаман урыслар гына иде. Менә инде, насыйп булса, үз илемездә яшьлекләрен үткәрәчәкләр»,— диде дә туктады.

* * *

Гөлсемнең күңеленнән үзенең балалары кичте. Бу бәхетле кешеләрнең балалары хакында шулай уйлаулары гаҗәп кебек тоелды. «Минем балаларым кем булыр икән соң? Алар хакында кем төшенә соң?»— димәкче бул-

ды. Тагы әллә нинди сәальләр бирмәкче булса да, фикере балаларына, балаларының тәрбиясенә, киләчәгенә киткәнгә, шул уйда батып калды, каюта тынды. Пароход бердән озын гына кычкыртты. Шуңардан куркып яңа бикәнең бер баласы тагы сикереп торып: «Әни! Әти килә, әти!» — дип кычкыра башлады. Яңа пристаньга килеп туктадылар. Тагы кешеләр йөрде, керделәр, чыктылар. Гөлсем, балаларын тынычландырып яткырганның соңында, урынына килеп утырды. Тәрәзәдән төшә торган фонарь яктысы аның болай да ак йөзенә саргылт бер төс кушты, ул мумия кебек катып Нәфисәне, үзеннән, үзенең бәхетеннән разый Нәфисәне сөзде. Аның тирән йокыда изрәп ята торган балаларын бик озын җентекләде. Тирәннән чыккан бер тавыш берлә: «Сез бигрәк бәхетле икәнсез... Мин башка, минем тормышым бөтенләй икенче юлдан китте. Икенче яр якасына мине дә илтеп ыргытты», — диде.

«Мин бер мирза кызы. Мин кечкенә чакта әнием үлде. Мин әти берлә ялгыз калдым. Берәр елдан әтинең сеңелесе, ире үлеп, кайтты да шул миңа аналык итте. Бик тиз мине укыта башладылар, ләкин русча укыта башладылар. Минем беренче таныган китабым урыс китабы булды. Беренче укыганым урыс тормышы булды. Шуннан мәктәпкә кердем. Анда да, билгеле, урыс мәктәбенә кердем. Тирә-юнемездә һәммәсе урыс иде, өйдә дә урысча сөйлиләр иде. Килгәннәр урыс була, барганнарымыз урыс була иде, бәйрәмнәр булганда гына мин үземезнең әллә нинди икенче төрле урыс икәнемезне, рождество ясамаенча, корбан бәйрәмен гает ясый торган урыс икәнемезне хис итә идем. Иптәшләрем арасында шул чынлап урыс булмавымыздан хурлана да идем. Әти бик күп эш эшли торган кеше булганга, тутакай үзен әле яшь дип уйлап, киенү-ясануны бик яратканга, миңа өйдә илтифат иткән кеше дә бик аз иде. Минем тәрбияче маржаларым әле берсе, әле берсе алышынып торганга, мин күбәләк кебек әле бер ут янында, әле бер ут янында оча идем. Җәйләрен кай елны Кырымга бара идек, кай елны Кавказга, кайбер елны Германияга да китә идек.

Менә шулай барганда, бер елны җәйне уздырыр өчен, без Уфа губернасында әнинең әнисе — әбиләргә киттек. Аларның Дим суы буенда бик матур утарлары бар икән. Анагы һавада да үзенә аерым төсле бер матурлык бар икән. Ул Кырымнан күңелле, Кавказдан төрле, Германиядан да татлы икән. Мин бару берлә әби мине бик ныклап карады, карады да: «Анасына охшаган, тәмам анасы», — диде. Мине сөйде. Моңача сөюләргә караганда йомшаграк сөйде. Монда да өйдәге тормыш тәмамән русча булса да, хезмәтчеләр бар да үз кешеләремез иде. Сүз, җыр һәммәсе үз телемездә иде. Мин барган көндә үк тау башына утырып курай тарткан малайларны күреп, аларның әллә нинди моң көйләрен ишетеп аптырап киттем. Мин үземне чит бер тирә-юнь эчендә күрдем. Ләкин, әллә ничек болар һәммәсе чит булса да, әллә кайчан ишеткән идем, шуның эчендә булган идем кебек бер нәрсә сизендем. Кунаклар килде. Кунакларга бардык, ләкин һәммәсендә шундый ярты урысча, ярты үземезчә бер тормышка очрадым. Менә минем әти китте. Тутакай бер шәһәргә барып, бер башка мирзаларга кунакка йөри башлады. Мин әбием берлә ялгыз калдым. Ул инде бик нык карчык булган иде, үзе мирза бикәсе булса да, башына зур калфак киеп, өстеннән яулык бәйли иде. Ул кай вакытларны тәһарәт алып намазга да утыра иде. Миңа әлгәрс болар бик гаҗәп төсле күренде. Мин, үземнең чын руслыгыма зарар килә, дип бераз курыктым да. Ләкин баратора өйрәндем. Әби шулай була төсле күренде. Менә бер көнне җәйнең иң матур вакытында без җиләк җыеп кайтсак, бөтен өйнең асты өскә килгән итеп таптым. Идәннәр юылган, мунчалар ягылган, әллә никадәр аш-су хәзерләнгән. «Нәрсә бар?» — дип сорадым. «Бүген сәхәр ашыймыз», — диделәр. «Нәрсә соң ул сәхәр?» — дидем. Хезмәтче кызлар көлеп: «Иртәгә рузага керәмез», — диделәр. Менә кич булды. Мин кызлар берлә бергә тәравих әйткәнне тыңларга киттем. Кич берлә сәхәр ашау бик күңелле булды. Ләкин иртә белән торгач та безгә чәй бирмәделәр. Җиләккә барырга рөхсәт итмәделәр. Мин уразага кердем.

Беренче көннәрдә ураза тоту читен булса да, мин бик тиз өйрәндем. Кызлар берлә азан әйткәнне, кич берлә тәравих әйткәнне тыңларга бару бик күңелле булды. Әби миңа, рамазанда урысча киенергә ярамый дип, татарчалатып итәкле күлмәк тектерде, башыма яулык бәйләтте. Менә мин шул торышка ияләшеп кенә беткән идем, тутакай кайтты. Ул: «Бу нинди эш бу? Мондый озын көндә баланы ураза тоттыр, имеш, ул болай да аз канлы, бу тилелеккә мин чыдый алмыйм, әтисенә язам, фәлән»,— диде. Әби берлә әйткәләшеп тә алдылар. Тутакай мине үзе берлә чәй эчерергә маташты. «Русчасы бөтенләй онытыла торгандыр, менә класста калыр дип»,— минем гувернанткамны тиргәп, безне дәрескә утыртты. Минем тормышымның рәте китте. Мин әбием өчен, шундагы кызлар өчен тутакайдан качып сәхәр ашый, азан тыңлый торган булдым. Тутакай өчен әбидән качып көндез чәй эчә торган булдым. Бәйрәмне көттермәенчә, баланы тәмам татарлатып бетерделәр, дип куркып, тутакай мине алып китте.

Шул елны мин укый торган мәктәпкә тагы ике мөселман кызы керделәр. Аларның әниләре начальницага килеп сөйләшеп, мәктәпкә мулла китереп, дин дәресе укыттырта башладылар. Начальница миңа да керергә кушканга, мин дә дин дәресенә йөри башладым. Шунда укырга, язарга өйрәндем, шунда догалыклар бикләдем. Шул юлда барганда мин буй үсеп җиттем. Мәктәпне бетердем, кыз булдым. Безгә Петербургның бөтен мирзалары, Кырым, Кавказның бөтен руслашкан түрәләре таныш-белеш иде. Төрле җирләрдә хезмәт итә торган Кавказ әфисәрләре, төрекмән егетләре бар да безгә килүчән-китүчән иде. Тутакай искедә бер әфисәр хатыны булганга, ул гаскәри киемдәге кешеләрне бик ярата, алар берлә чормалану, болгануны сөя иде. Картаеп килсә дә, ул әле яшь әфисәрләр берлә кылынгачлана иде, алар берлә әллә нишләп бетеп чуала иде. Мин кыз булып, үземне-үзем кыз итеп хис итә башламадым, минем артымнан әллә нинди кешеләр йөри башладылар. Бер полковник миңа бик еш чәчәк китерде. Телефон берлә исәнлегемне сорашып, тутакайлар берлә театрларга алып китте, миңа кавалер булып йөри башлады. Бервакытны бу минем алдыма тезләнеп, минем кулымны да сорады. Мин аптырап киттем, һичбер башымда, күңелемдә андый фикер булмаганга, бер сүз әйтә алмадым. Тутакай эшкә катышты. Полковникны миңа димләргә керешә. Миңа генералша булып торуны, зур рус дөньясына катнашып китүнең юллары ачылуны бик озын иттереп бизәкләндереп сөйләде. Мин кызыктым да, ләкин күңелемдә шул кешегә каршы һичбертөрле хис булмаганга, сүз бирә алмадым. Әти дә минем яклырак булганга, яшь әле, дип эшне кичектерделәр. Полковнигымның килүе сирәкләште, очрашканда ул үпкәләгән кыяфәтне бирәсе килде. Ләкин бер ике-өч ай вакыт үтмәде, ул карт кына бер тол хатынга өйләнеп тә китте. Аның эзе югалырга өлгермәде, бер кыргыз студенты, кыргыз ханының туруны* булып безгә йөрергә тотынды. Ул миңа бик күп әрмән анекдотлары сөйләде. Кыргызларның русча белмәүләреннән килеп чыккан көлкеле хикәяләрне аңлатты, үзенең университетны бетереп чыккач, уездный булып, нинди генә түрә булып торачакларын бизәде, бизәкләде. Менә бу да беркөнне театрның фойесында тавышларын калтыратып, бик озын иттереп сөйләп, мине сөйгәнен, минсез тора алмаячагын белдерде. Нә сүзләре, нә кылынышлары миңа һичбер төрле тәэсир итмәгәнгә, минем күңелнең нечкә кылларына барып тәртелмәгәнгә, моңарга да сүз кайтардым. Бусында тутакай да каршы булмады, әти дә бер сүз әйтмәде. Ул озын хатлар язды, чәчәкләр җибәрде, ялынды, ялварды, ләкин мин һаман үз сүземдә калдым. Укып бетереп китте дә, андагы кечкенә вакытыннан әйттереп куйган кызын алды да начальник булып тора башлады.

Аның артыннан бер кавказ инженеры килеп чыкты, аның артында бер Литва татары, аның артыннан бер иранлы принц, шулар арасында өйгә килеп йөри торган рус әфисәрләре, рус студентлары хатлар яздылар, шигырьләр әйттеләр. Ләкин һәммәсе дә күңелемне керләтеп калдырудан баш-

*Турун — оныК.

ка бер хис уятмадылар. Менә шулай торган чакта бер көнне безне татар студентлар түгәрәге үзенең кичәсенә чакырды. Кечкенә залда үз кешеләребездән генә җыелган кичә бик күңелле булды. Буфеты милли ашлар белән корылган, укучылардан милли оркестр төзелгән. Татарча кечкенә генә бер пьеса сайланган. Кычкырып укыр өчен матур җырлар, шигырьләр чүпләнелгән иде. Кичә миңа әллә ник үземнең кечкенә чактагы теге әбиләрдәге авыз ачуларны хәтерләтте. Мин чын күңелдән шатландым, тирән бер кәеф белән кәефләндем.

Егетләр, кызлар белән төрле уеннар уйнап йөргәндә бер студент гаепле калды. Мин хан идем. Аңарга җәза иттереп ни эшләргә белмәенчә аптырап торганда, берсе: «Татарча бер шигырь декламациясе»,— диде. Ул «Син» дигән бер шигырьне укыды. Шундый матур укыды, миңа шундый зур тәэсир ясады, мин изрәп киттем, мин хан булганга: «Тагы берне!» — дидем, яшьләр кул чабып каршы алдылар. Ул тагы берне укыды, тагы шәп чыкты. Шуннан без ул студент белән танышып киттек. Аның исеме бер төрек пашасының исеме булгангамы әллә ул төрекләрне бик яраткангамы, аңарга Паша дип йөриләр иде. Мине дә Паша дип таныштырганнар иде. Ул үзе дә шул исемне яратканга, мин дә Паша дип эндәшә башладым. Мин аны үземезгә дә чакырдым. Ул килә башлады. Ләкин бер дә моңарчага кадәр миңа йөргән егетләр төсле кылынмады, ул миңа татар әдәбияты, шигырьләре хакында сөйләде, хәзерге агымнар хакында мәгълүмат бирде. Ахырдан татарча китаплар китерде. Ул минем алдымда яңа бер дөнья ачты. Мин сусаган дәрт белән шуңарга тотындым. Әдәбият укыдым, шигырьләр бикләдем. Мәҗмугалар, гәзитләр алдырып, шул хәятның эченә керә башладым.

Менә җәй булды. Пашаны җәйгә безгә утарга кунакка чакырдым. Шуны да әйтеп китәм, баштан ук минем тутакай аны яратмады. Кешеләр алдында һаман аның гаепләрен табарга маташты. Миңа аның хакында һаман шикләр уята торган сүзләр сөйләде. Ләкин боларның берсе дә миңа тәэсир калдырмаганга, минем Пашага мөнәсәбәтем үзгәрмәде, җәйнең матур чагында бу безгә килде. Тутакай үзенең үлгән иренең әллә нинди кардәшләрен көтә икән. Егетнең килеп төшүе белә: «Инде моны кая урынлаштырыйк, фәлән бүлмә минем каен энем мирзага, фәләнс минем тудыгым мирзага, фәләне Мәрьям Ивановнага, фәләне Суфия Салиевнага»,— дип, бөтен өйне бүлеп куйды. Минем кунагыма чарлактан башка урын калмады. Минем шул эшкә кәефем китсә дә, тутакай белән сүзгә керешә алмадым. Паша һичбертөрле үзенең күңеле кырылганыны белгертмәде. Көннәр бик матур тугры килде, без иртә торып җиләккә киттек. Салкын төшеп, су буйлары шәүләләнгәч тә балыкка бардык, күрше урманга самавырлар алып чыгып, хозур кордык. Пашам көннән-көн өйрәнде, үзләнде. Тирә-юньдәге бөтен кеше үзенә мәхәббәт куйды. Әти дә аны яратты, хезмәтчеләр дә хөрмәт итте. Ләкин тутакай һаман үз сүзендә булды. «Каен энем мирза килсә нишләрмез, моны ни дип таныштырырмыз, моның бит өсте-башы да бер катлы, үзен тотуы да татарча. Нәселеннәсәбен дә алла белсен, кызы җиткән йортларга кунак чакыруда бик сак булырга кирәк»,— дип этигә бәйләнде. Егетнең бер генә җитмәгән җире булса, шуны зурайтып, ямьсезләтеп сөйләде. Карт хезмәтче хатын белә аңарга «затсыз» дип исем кушты. Кунак-төшем булганда аңарга урынны иң түбәндә, әнидән калган карт экономка белә беррәттән ясатты. Ләкин Паша сизмәдеме, сизенмәгәнгә сабыштымы, һичбер төсен, йөзен бозмады.

Ул миңа бик күп яңа татар китаплары алып килгәнгә, без кайвакыт бакчадагы шәүләле бер почмакта, сәгатьләр буе китап укыдык, кайвакыт, сүзгә керешеп китеп, аяклар кай таба барганны сизмәенчә дә урманга кадәр йөреп киттек, кайвакыт икемез ике кармакны салып, сузылып киткән тын суның тирәнендәге нәрсәләрне күрер өчен күземезне суга батырып, судагы бер-беремезнең шәүләләре белә күңелдән күңелгә сөйләштек. Бик озак тын торгач кына берсүзсез елмаешып алдык. Кармактан өзелеп киткән көмеш кебек балыкның «чүлт» итеп төшеп суны ярып

җибәрүеннән, зур бер көлке кебек, эч күңелдән көлештек... Кайвакытларны чәчәктән чәчәккә очып йөри торган умарта кортының бызылдавы, ерактагы чикерткә туеның җырлавы әле югары менеп, әле түбән төшеп лезгингә бии торган чиркәс кызы кебек әйләнә-бәйләнә торган карлыгачның моңнары, дәртләнүе астында изелеп киттек. Үземезне үземез югалттык, тирә-юньне оныттык.

Көннән көн үтте, көн үткән саен минем күңелемә бер тынычлык урынлашты, үзем күрмәгән бер бәхет мине томалады. Сизеп бетермәгән әллә нинди бер нәрсә мине сөйде, иркәләде. Мин ачылганнан ачылдым. Көн буе көлдем, җырладым, музыка уйнадым. Кич булдымы, биләүсәдәге бала кебек тирән йокыга чумдым. Иртә үк мине тагы шул ук бәхет, шул ук татлы тормыш каршы алды. Мин тазардым. Йөзләрем кызарды. Кулларым тулды. Үземдә әллә нинди зур бер көч хис иттем. Кара урманнан үтү дә куркынычлы булмас кебек күренде. Кичелмәс таулар аша атлау да берни тормас кебек сизелде. Паша да кызарды, янды, каралды. Аның күзләре тагы нурлыланды. Аның көлүе, елмаюы тагы җанлыланды. Ләкин минем тутакай һаман сеңерләнгәннән сеңерләнде. Ул мине: «Кызлар үзен шулай тотамыни?» — дип шелтәләде. Мине егет берлә бергә калдырмас өчен әллә нинди хәйләләргә сабышты. Паша артыннан ухаживать итәр өчен күрше боярларның сарыпсыз бер кызын чакырып китерде. Өйдә әллә никадәр буш бүлмә булса да, аны егетнең күрше бүлмәсенә чарлакка җирләштерде. Теге кыз бик тырышып кылынгычлана башлады. Пашаны артыннан йөртергә маташты, әллә нинди капризлар ясады. Атларга атланып урманнарга китте, егетне анда өстерәде, монда өстерәде. Берни эшли алмаса да, минем элгәреге татлы тормышымны тынычсызландырды. Пашаны да әллә нинди уңайсыз хәлләргә куеп сеңерләндерде, безнең бергә йөрүемез, сөйләшү, көлешүләремез авырайса да, бу нәрсә мөнәсәбәтемезгә күңелсез бер сызык сыза алмады.

Ләкин әти берлә тутакай әллә нәрсәләр киңәшләшә, әллә нинди җитди төс берлә сөйләшә башладылар. Кайвакытларны сәгатьләр буе бүлмәдә ябылып калдылар. Менә беркөнне теге кодаларның юлга чыгуларыннан телеграм килде. Тутакай ут булды. Өйләрне җыештыртты, бүлмәләрне хәзерләтте. Аш-су кирәк-ярагы, эчемлекләр алыр өчен шәһәргә кеше җибәреп, бөтен йортны аякка калкытты. Мине үзенә чакырып: «Каен энем мирзалар киләләр. Алар нәсел нәселдән мирзалар. Үзе охрана его величества хезмәт итә. Олуг кенәзләр берлә таныш. Тагы аның кардәше килә. Анысы тагы диктй дивизиядә әфисәр. Студентны нишлимез? Борчак оны берлә балны бит бергә бутап булмый. Ничек аларны бергә кушып кунак иттереп йөртәсең. Кайчанга китә инде ул..?» — диде. Мин кызардым. Бер яктан хурландым, бер яктан Пашаның мирза булмавы өчен кәефсезләндем... «Әүвәл аңарга аңлатырга кирәк... Ул үзе аңламас, ул бит общество күргән кеше түгел. Әйтергә кирәк, туп-тугры иттереп әйтергә кирәк, инде юлыңда бул, егет, дияргә кирәк», — диде. Мин: «Кунакны ничек алай итәсең», — дидем, ләкин каты иттереп Пашаны яклап китә алмадым. «Үзе дә китәм дип тора иде, шул арада китә инде», — дидем. Тутакай тагы: «Син үзеңне кеше төсле тот... Безнекеләр бик үткен кешеләр. Аяк басуыңнан сизәләр. Ул егетне синең кавалерың дип уйлый күрмәсеннәр... Аннан соң эш харап», — диде...

Чынлап та менә өч тройкада кунаклар килеп төште. Бөтен йорт яңа ирләр, яңа хатыннар берлә тулды. Кичке аш искиткеч тантаналы үтте. Тутакай кырык төрле аш хәзерләткән, кырык төрле эчемлекләр берлә өстәлне тутырткан. Мине яңа әфисәр янына утырттылар. Ул бертуктамаенча: «Виноват, виноват, прикажите!» — дип мине сыйлап йөдәтте. Аш араларында миңа әллә нинди полктагы хикәяләрне сөйләде. Пашаны тутакай, теге марҗага кавалер иттереп, өстәл артына гына, почмакка гына урынлаштырган иде. Мин аны рәтләп күрә дә алмый идем. Сүзен дә ишетә алмый идем, ләкин теге марҗаның чыр-чыр сөйләүләре, кайвакыт кылынгычланып көлүләре генә ишетелеп, эчне пошыра иде. Картлар эчеш-

тергәләделәр, минем күршем дә мине сыйлап-сыйлап җибәргәләде. Мин дә, аз гына капкаласам да, йомшабрак киттем... Аштан соң картлар ликерлар белә бүлмәләргә кереп карта уйнарга керештеләр. Яшьләр бакчада йөрергә чыгып таралды. Тутакай, мине чакырган булып, әллә ниләр сөйләп тотты. Паша янына теге марҗа килеп култыклап алгач кына, ул яңа әфисәрне чакырып китереп, әллә нинди йомышлар кушкан булып: «Йөрергә чыгасызмыни?» — дип, безне парлаштырып чыгарып җибәрде.

Төн тын иде, күк айлы-йолдызлы иде. Чәчәк, үлән исе тирә-юньне аңкыткан иде... Әллә нинди бер йомшак җылылык бөтен тамырлардан йөри, акыртын гына исә торган җылы җил яңадан-яңа хуш исләр китереп битне-чәчне сыйпый иде, сөя иде... Яңа әфисәрем, бераз кызып алып, бертуктамаенча анекдот артыннан анекдот сөйли иде. Бакчаның теге почмагында чырлый торган теге марҗа кычкырып-кычкырып әллә нинди әмерләр бирә иде. Еракта гына мәче башлы ябалак ямьсез тавышы белә кычкырып күңелгә тынычсызлык бирә, курку сала иде... Бакчаны без бер әйләнә идек, ике әйләнә идек... Кирәргә вакыт җитсә дә, мин Пашаны очратырмыз дип, кавалерымның тәмсез сүзләреннән көлгән булып һаман йөри идем. Менә без өйгә таба борылдык. Ишек төбенә барып җиттек, өйдәге лампадан багана кебек сузылып чыккан ут яктысында бердән Пашам килеп басты. Төнге якты белләдерме — аның йөзе саргылт иде, күзләре тирәнәйгән, эченә әллә нәрсә яшергән кебек караңгыланган иде. Йөзенә әллә нинди бер аңламаслык төс, сыкрану төсе чыккан иде. Бүген без бер сүз дә әйтешә алмаганга, мин: «Нихәл, исәнмесез?» — дип татарчалап сөйли башладым. Әфисәрем гафу үтенеп өйгә кереп китте. Без бер-ике сүз әйтешергә, күңелдәге төеннәрне әйтергә өлгермәдек, тутакай ут кебек чыгып җитте. «Әйдә, сине көтәләр, Гөлсем, өй хуҗасына шулай ярыймыни?» — дип җилтерәтеп алып кереп китте. Кич белә музыка уйналды, танец булды, яңа кунаклар бик шәп танцевать иттеләр. Мин дә әле берсе белә, әле берсе белә бии-бии арып беттем. Паша почмакка ялгыз утырды да тик калды. Ул карта уйный торганнар арасына да керә алмады, биючеләр арасына янында да катыша алмады. Ликер эчеп-эчеп гайбәткә чума торган хатыннар да урын була алмады, ялгыз калды, ялгызлыкка батты. Ул йөзеннән дә, күзеннән дә үзенең ялгызлык хисен яшерә алмады. Арып бетеп ятарга аерылганда, бөтен яңа кунаклар минем кулымны үбеп күрешкәндә, ул ялгыз гына үпмәенчә: «Хәерле кичләр!» — дип югалды. Бик арыганга, аз-маз шәрап, ликер эчештергәләгәнгә, бик начар йокладым.

Иртә тору белә без ашамак-эчмәкләр төяп, дүрт-биш атка төялеп су буена хозурга киттек. Әти, кода, тутакай бер атталар иде, мин, яшь әфисәр, бер кечкенә бала икенчедә идек. Башка хатыннар, вак-төяк кунаклар өченче, дүртенчеләрдә иде. Паша самавырлар төялгән карт экономкалы арбада утыртылган иде. Юлда арбалар әле берсе үтеп, әлә берсе узышып, уйнашып баралар иде. Ләкин Пашаларның арбасы гына һаман артта иде. Карт ат белә ул һаман үз юлында лырт-лырт йөгертеп килә иде. Егетнең мыскыл ителүе өчен күңелем бик борчыла иде. Эчем поша иде. Ләкин каты иттереп аны яклап катышырга минем көчем җитми иде. Тирә-юньдәге гадәт, өемездәге тутакайның башлыгы, әтинең өй эшләрендә бик йомшак булуы, Паша белә минем арадагы мөнәсәбәтнең ачылып бетмәгәнлеге мине кулы-аягы бәйләгән кебек тота иде. Менә елганың борылып ага торган бер җиренә атлар туктады. Хәтфә төсле яшел чирәм өстенә мәҗлес корылды, зур иттереп ут ягылды. Самавырлар куелды. Ашау-эчү китте. Сыйлану башланды. Ирләр, хатыннар урманнарга, болыннарга чәчәк җыярга, йөрергә таралдылар. Мин берничә мәртәбә Паша белә берләшеп сөйләшеп китәргә теләсәм дә, әле тутакай килеп чыгып мине алып киткәнгә, әле бер яңа хатын килеп бирәр йомыш белә сүзгә катнашканга, әле теге марҗа егетне җилтерәтеп өстерәп анда-монда тарткалаганга, бер минут вакыт бергә була алмадык, көн буе мин һаман шул яңа әфисәрем белә калдым. Көн буе хуҗа кыз булып әле бер кунакның

күңеле өчен, әле бер хатынның мәгънәсез сүзе өчен Паша берлә сөйләшергә биш минут вакытымны бүлә алмадым.

Халык бик күп булганга, баш тегермән кебек әйләнгәнгә, вакыт үткәне сизелми дә калынды. Ирләр коенырга киткәндә, без кызулап аш урыны хәзерләдек. Алар ликер эчәргә утырганда без коенырга киттек, күрше алпавытлар килгәч, тагы шәплəп чәй эчеп, көн үткәнне, кич булганны тоймый да калдык. Ай яктысында судан килә торган йомшак салкынча астында без бик озак куыш-куыш уйнадык. Әллә нинди уеннар берлә эштән чыктык, 'биедек, танцевать иттек, бергәләп, аерым-аерым җырладык. Яңа әфисәр берлә бер кунак хатын лезгинкә дә биеделәр. Соңгы төндә генә, арбаларга төялешеп өйгә таба борылгач кына, мин әллә нинди авыр бер хискә баттым. Әллә нинди үзем дә сизеп бетермәгән бер начарлыкны эшләгән кебек, күңелемнән сыкрана башладым. Арыган башым рәтләп эшләп бетерә алмаса да, ни булдыгы хакында ачык хисап бирә алмаса да, күңелемнең бер җирен әллә нәрсә кырды, бәгъремнең бер почмагы әллә ни өчендер көенде, еглады. Янымдагы әфисәрем әллә ниләр сөйләсә дә, рәтләп тыңламаенча гына өйгә кайтып җиттек.

Халык бик күп булганга, тавыш-туыш зур булганга, мин әллә нинди бер белмәгән нәрсә тарафыннан басылганымны хис иткәнгә, рәтләп күрешмәенчә дә үз бүлмәмә кереп яттым. Урынга сузылып, уйларымны бер җепкә тезгәч кенә бүген тагы Паша берлә бер сүз сөйләмәвемне, аның берлә кич күрешмәенчә дә керүемне хәтерләдем, кайгырдым. Аңарга каршы ясала торган шул бойкотта мине дә бергә дигән фикердә булмадымы икән, дип уйландым. Юктыр, дидем. Бардыр, дидем, иртәгә үзе берлә сөйләргә булып, мәсьәләне хәл итмәкче булып, борылып яттым. Өй дә зур умарта кебек уылдады, гөрләде. Бик озактан соң ул да тынды. Мин әллә ничә мәртәбә йокыга китә башласам да, тагы куркынып уяндым, тагы төрелеп яттым. Тагы өн берлә төн арасында чуалдым. Ахырдан тирләп-пешеп, башым янып, сикереп тордым. Пәрдәне тартып тәрәзәне ачтым. Бәрәкәтле кул берлә ташланган айның моңлы яктысы бүлмәмне тутырды. Күзне кытыклады, тыштан кергән салкынча һава тамырлардан йөгереп мине калтыратты.

Мин өстемә киеп айны, айның нуры берлә челтәрләнеп ага торган аклы-сорылы болытларны карарга, тик, тын тора торган агачларны сәер итәргә тотындым... Балалыгым күз алдыма килде... Беренче сәхәр тагы искә төште. Моннан бер генә атна элекке тынлыгым, тынычлыгым күздән үтте. Бүгенге күңелемдәге үземнән үзем разый түгеллек, бүгенге көндәге бәгырьнең әллә нинди тәтенсез, утсыз ут берлә януы алга басты. Ни булды, нинди үзгәрү булды, мин ни эшләдем? Уй китте, уй артыннан уй китте. Мин үз тирә-юнемдәге шул якыннарымны, шул кодаларны, шул кунакларны җентекләдем. Аларның табигатьләрен, йөрешләрен, кылынышларын тикшердем. Шуларның бер әгъзасы иттереп куйгач та, тәмәке тарта торган кешеләр берлә шыгрым тулган, бизәнгән, буянган хатыннарның тәмсез сүзләре берлә «у-у» килгән, тәрәзәсе ябык, ишеге юк, дүртенче классның вагонында кебек үземне үзем хис иттем... Йөрәгем «шу» итте, тәнем калтырады, күңелем сыкрады, ишекнең юклыгы, бу сасыдан, бу былчырактан чыгарга, котылырга юлның юклыгы минем котымны алды. Мин көчсез, ярым һушсыз көенчә урындыгыма сузылдым. Ай мине коендырды. Акрын гына искән җил, агач башларын берсенә берсен бәрештереп, моң гына тавышландырды. Еракта гына мәче башлы ябалак кычкырды да кычкырды. Мин куркудан аякка калыктым. Әллә ни эзләгән кебек, күземне бакчага тектем. Агачлар арасында әллә нинди бер шәүлә акрын гына селкенә кебек булды. Шул тынлык, шул ялгызлык эчендә шул шәүләне табуыма сөенгән кебек булдым. Шул шәүлә генә мине шул авырлыктан коткара кебек булды. Мин шуны күрергә зур өмет берлә шәүләнең якынаюын көтәргә керештем. Менә ай яктысы берлә тулган яланга шәүләм чыкты. Ни күзем берлә күрим, Паша!... Туктады, бик озак бер ноктага таба карады. Бәлки, айга карагандыр, бәлки, йолдызны сәер иткәндер, ләкин ул вакыт ул ми-

нем тәрәзәмә карый кебек булды... Мин тәрәзәдән башымны тыктым. Паша калтырап китте. Акыртын гына: «Сезме?» — дидем. «Әйе»,— диде. Ни эшләгәнемне белмәенчә: «Хәзер чыгам!» — дидем дә, өстемә шәл салдым да, туфли берлә генә чыктым да киттем.

Паша тетри, калтырый, тешләре шак-шак килә иде, үзе каткан кебек тик тора иде. Кулы суп-суык иде. Бу авырлыктан чыгар өчен: «Ник йокламыйсыз?» — дидем. «Сез ник?» — диде. «Мин арыганмын, халык бик күп булды, баш бик чуалды, фәлән»,— дидем. Акыртынлап сөйли-сөйли беседка артындагы бөтен кешеләрдән яфраклар берлә капланган үземезнең сөйгән урынымызга кереп утырдык. Минем күңелем тулган булгангамы: «Сез гафу итегез, бу эштә минем гаебем юк»,— диярга булдыра алмадым. Бернәрсә булмаган кебек, бер дә җитди эш юк кебек күренергә тырыштым. Паша чыдый алмады: «Мин, туташ, сезне өч көннән бирле күрә дә алмыйм, сөйли дә алмыйм... Ләкин шул өч көн эчендә мин бик күп нәрсә күрдем, бик күп эшкә минем күзем ачылды. Бик күп төрле карарлар да ясадым. Ләкин берсен дә эшкә куя алмадым. Миңа бит әллә кайчан китәргә тиеш иде. Әллә кайчан үземне-үзем, бу ят халык, миңа дошман халыкның мыскыллавыннан, мәсхәрә итүеннән качарга тиеш иде, ләкин мин аны эшли алмадым. Әллә ничә мәртәбә эшләргә беркетсәм дә, эшли алмадым, әле дә эшли алмыйм. Кечкенә генә туган өметләр мине биләде, минем аягым-кулымны баглады. Мыскыл өстенә мыскылны күтәрергә мәҗбүр итте. Башымны игәннән иярга әмер итте. Сезнең мондалыгыңыз, микънатис ташы кеби, мине тартты, тотты. Канаты көячәк булса да, утка чаба торган күбәләк кебек мине дә шул ут тирәсендә әйләнергә кушты. Ни эшлим, туташ, шулай булды... Ләкин боларның барысын да, туташ, мин сездән бер күз караvы алыр өчен, сездән бер елмаю күрер өчен эшләдем... Бәлки, бу яңа кунаклар килмәсә, мондагы яңа планнарны белмәсәм, мин элекке кебек сезне хөрмәт итеп, сезне эчтән бик зур күреп, киләчәктәге күрешүләргә ышанып китеп тә барган булыр идем. Ләкин хәзер китә алмадым. Сезне күрмәенчә, сөйләнмәенчә китә алмадым. Китә алмыйм. Мин шул өч төндә һич йокламадым. Мин бик күп сыкрадым, бик күп газапландым. Мин сезне шулкадәр тирән сөю берлә сөйгәнемне аңладым. Миңа сездән башка тормыш юк»,— диде. Мин аптырадым. Бер сүз әйтә алмадым, ләм-мим дип җавап бирә алмадым. Күңелемнән шуны көтсәм дә, бу кадәр дары кебек бердән шартлар дип уйламаган идем. «Шулай булгач, мин ни кадәр хурлыклар күрсәм дә, ничек сезне шул баткаклык эчендә, шул сазлык эчендә калдырып китим... Сезгә каршы корылган шул кадәр ямьсез планнарны күрә торып, мин сезне ничек ялгыз ташлыйм! Бу минем көчемнең читендә... Сез, туташ, сазлыкта үскән бер гөл. Тирә-юнегез баткаклык, эчкән суыңыз сазлык суы, сулаган һаваңыз черегән сазлык һавасы, монда гөлгә үсәргә, гөл булып яшәргә имкян* юк. Бу тирә-юньдә сез бетәчәксез, сез дә башкалар кебек сазлыкка батачаксыз. Сезне бу сазлыктан алсаң гына, сез мәңгегә гөл булып кала беләчәксез... Чыгыңыз моннан... Чыгыйк моннан, сарылыңыз минем кулыма, туташ»,— диде... Мин: «Алай ук түгел, сезнең хыялыңыз бик зур, фәлән»,— дидем. Ул ишеткән, күргәннәрен сөйләде. Иртәгә йә берсе көнгә мине теге әфисәргә рәсман сораячакларын, әтинең разыйлыгын, тутакайның шуны булдырыр өчен бөтен көчен сарыф итүен, һәммәсене аңлатты. Мин үзем дә шуларны күңелемнән сизенеп торсам да, әллә нинди җепләр берлә шул йортка, шул кардәш-кабиләгә, шундагы гореф-гадәткә бәйләнгән булганга, Пашаның чын күңеленнән чыккан сүзләренә: «Ярый инде»,— дип җавап бирә алмадым. Икеләнебрәк: «Әле сөйләшермез, фәлән»,— дидем. Мәсьәләне озайттым.

Шул араны аяк тавышы ишетелде, акрын гына сөйләгән сүзләр колакка бәрелде. Без тындык, аларның сүзләрен ишетер өчен түгел, үземезне сиздермәс өчен тындык. Аяклар павильонга кереп утырдылар. Акрынлап тагы сүзләренә дәвам иттеләр. Сөйләүчеләр тутакай берлә кода иде. Кода-

* Имкян — мөмкинлек.

ның сүзләрен ишетеп бетерә алмасак та, тутакай ачык тавыш берлә: «Минем сүзем сүз, мин кызның вәгъдәсен алдым, аны сөйләп тору да урынсыз... Ләкин шуны онытма... Мин бит тол, электән полковник хатыны, мин шул аена илле тәнкәлек пенсиягә тора алмыйм. Тора алмыйм... Менә кияү дә, син дә кул куеп, 40 мең тәнкәлек вексель бирсәңез, туйны эшлим... Юк булса, мин үземне үзем бушлайга урамга ыргыттырыр хәлем юк... Гөлсем кияүгә чыккач, мин кем?.. Юк!» — диде. Кода тагы әллә нәрсә сөйләде, тутакай: «Әйтәм бит, ул авыру, безнең Гали авыру (ул минем әтием хакында иде), йөрәк авыруы берлә авыру, бүген, ярты рюмка артык эчте исә, иртәгә юк... Мин аңарга ышана алмыйм. Шул вексельне бирсәңез, иртәгә — бетте», — диде. Паша минем күземә карады, мин агардым, бүртендем. Чыгып: «Мине сатарга телисезме, мине үз акчама сатарга телисезмени?» — дип кычкырасым килде. Булдыра алмадым, аягым калтырады, тешләрем шак-шок килде. Тегендә базарлык бетте. Килештеләр. Акрын гына сөйли-сөйли киттеләр. Мине Паша кызганды булырга кирәк, җәрәхәтемә тоз сибәчәк бер сүз әйтмәде, яңа җәрәхәтемә зәһәр салмады. Мин тордым, ул да акрын гына җиреннән калыкты. Бер сүз дәшмәенчә бакчаны үттек, яланга чыгар алдында ни булса да бер сүз әйтеп аерылырга кирәк, дип уйлап торганда, теге сарыпсыз марҗаның бүлмәсендә ут алынды. Анда нечкә пәрдә ашасыннан теге яңа әфисәр берлә теге марҗаның башлары күренде. Кыяфәтләре, киемнәре-салымнары кемне дә оялтырлык булганга, мин яшен суккан кебек булып киттем, дерелдәдем, калтырадым, егылмас өчен, бер агачка сөялдем. Паша бик озак мине сөзде, бераздан: «Аңладыңызмы? Бу сазлык сезнең җир түгел. Аңлаңыз, туташ! Сезгә башка һава кирәк, әйдәңез!» — диде. Минем кулымны тарткан кебек каты кысты. Минем бөтен тәнемнән суык йөгергәнгә, дерелдәп, моңланып күзенә карадым. Бик озактан соң: «Минем башым хәзер эшләми, иртәгә сөйләшермез. Иртәгә», — дидем. Өйгә чабып кереп киттем. Ул баскан җирендә катып калды.

Мине моңганча һичбер булмаган яңа бер хис беләде. Мин хурландым. Үз-үземне сарык кебек сатарга теләүләренә хурландым. Җирәндем, үз-үземнең шул былчыраклар арасында булуымнан җирәндем. Мин яндым, көендем, үз-үземнең шул баткаклыкны ташлап китәргә көчем юклыгыннан яндым. Шул тирә-юнемне чормалаган былчырак бака күлмәкләреннән арынып китәргә куәтем юкка яндым, көйдем... Бер яктан тутайкайның: «40 меңлек вексель биреңез!» — дигән сүзләре колагымда чыңлады. Тәрәзәдә күргән теге сарыпсыз марҗа берлә теге әфисәрнең кылынышлары күз алдымда уйнады. Чын күңеленнән моңланып әйткән Пашаның өметле тавышлары, рәхмәт фәрештәсе суры* кебек, минем җәрәхәтле бәгъремне сылады, сыйпады, иркәләде. Күземә актарылып яшь агарга тотынды. Тавышланып, тавышсыз бик озак еладым. Күңелем басылган кебек булып тагы яттым, тагы ямьсез фикерләр мине чолгады, тагы еладым, тагы тордым, тагы яттым, тагы еладым, тагы киенеп чыгып бакчада Пашаны эзләмәкче булдым. «Әйдә, китик, әйдә!» — дип аңарга ялынмакчы булдым. Тагы ишек төбенә баргач, бусаганы атларга көчем җитмәде. Тагы чишендем, тагы яттым. Тагы көйдем, тагы яндым, тагы еладым. Иртә булды. Кояш чыкты. Кошлар сайрарга тотынды, умарта корты безләргә керешә. Минем керфегем керфеккә тимәде. Еглый-еглый кызарып беткән күзләремне күрсәтмәс өчен, үземнең эчемдәге яна торган ялкынсыз утымны яшерер өчен, суык сулар берлә юындым. Күзләремә сөрмәләр тарттым, киендем, ясандым... Йөземә көләчлек бирмәкче булдым. Ләкин көзгегә барып карагач та, үземнең сары йөземне, уелып, тирәнәеп киткән өметсез күзләремне күрдем дә, тагы ихтыярсыз яшькә баттым. Әллә кемгә барып серемне сөйлисем килде, әллә кемнең муенына асылынып кайгымны аңлатасым, хәсрәтемне чишәсем килде. Әллә нинди мине бик аңлый торган бер кешегә бөтен кайгымны түгәсем килде. Күз алдыма үләр алдындагы анам

* Сур — боргы.

килеп басты. Аның моңлы күзләре миңа таба карый кебек, айый кебек булды. Күземнән ятимлек яше тәгәрәде. Әтигә барып сөйләмәкче булдым. Аңарга эшне аңлатмакчы булдым. Ләкин аның белән арадагы хисапсыз бер якынлык булмавы мине тагы тотып калды.

Ишек шакылдады. Кызгылт кофта кигән, чәчләрен бөдрәләтеп тараган тутакай килеп керде. Аның белән бергә әллә нинди исле май, пудра исләре бүлмәне тутырды. Мин аның йөзенә куркынган кеше кебек карадым. Ул миңа шул вакытта, зур шәһәрләрдә кызлар тотучы юан симез яһүд хатыны кебек күренде. Җирәнгеч бер хис уятты: «Әйдә, кунаклар тордылар. Тиз бул! Бөтен халык сине чәйгә көтә!» — диде. Минем күлмәгемнең якаларын рәтләгән кебек булды. «Чык моннан, кит, йөзең кара!» — диясем килсә дә, әйтә алмадым. Көчсезләндем. Изрәдем. «Ярый, хәзер», — дидем. Йөзләремне тагы бер мәртәбә одеколон белән сөртеп, акрын гына аш бүлмәсенә төштем. Ду килгән кунаклар бар да аяк үрә торып миңа юл бирделәр. Теге әфисәрем килеп кулымны чуп иттереп үпте. Аның авызыннан кулыма әллә нинди бер былчырак селәгәй ябышып калды кебек булды. Паша калтыраган кулы белән кулымны кысты. Күземнең эченә карады. Беркем дә бер сүз дә дәшмәенчә берәр чынаяк чәй эчтек. Әфисәр миңа әллә ниләр сөйләсә дә, тыңламадым. Тутакай әллә нинди көлкеләр белән миңа мөрәҗәгать итсә дә, җавап бирмәдем.

Чәйдән соң мине әти бүлмәсенә алып керделәр. Анда тутакай, селкенә торган урындыкка утырган да, тибрәнеп-салланып әллә ни сөйли иде. Мине күрү белән әти көлеп: «Нишләп торасың, Гөлсем!» — дип сүз башлады. Үзе әллә ни әйтергә теләсә дә, сүзе чыгып җитмәде. Аңарга ярдәмгә тутакай житеште. Көлеп-көлеп сүзгә кереште. Ул да нигәдер тугрыдан-тугры әйтеп бетерә алмаенча, каен энесен, теге әфисәрне бик мактады. Сүзен очлап өлгерә алмады, ишек шакылды. Аннан яңа гаскәри киемнәрдә кода белән теге әфисәр килеп керделәр. Кода керер-кермәс русчалап: «Мине гафу итегез, менә бу егет, кызлар тәрбияле, оялчан, эченнән янса-көйсә дә, үз хисен әйтергә батырлык итә алмый», — диде. Теге әфисәр дә, команда иткән солдат кебек, бик тиз килде дә минем янымa тезләнде, русчалап: «Мине бәхетсезлеккә салмагыз, колыгыз булырга рөхсәт итегез!» — диде дә минем кулымны үпте. Мин аптырадым. Бер сүз әйтә алмадым. Тутакай мине шул уңайсызлыктан чыгарыр өчен кебек: «Сез аны оялттыгыз, ул бит яшь кыз әле, әнә, күрәмсез, йөзенә кызыл йөгерде, ул инде разыйлык галәмәте... Алла сезгә мәхәббәт бирсен», — диде. Мин күземне ачтым, башымны күтәрдем, үземнең сатылганымны тагы ныграк сизендем, дерелдәдем, калтырадым. Каушаган тавыш белән русчалап: «Гафу итәсез, мин һичбер вакыт сезнең хатыныгыз булачак түгелмен, һичбер вакыт!» — дидем. Күземә яшь тыгылганны хис иттем дә сикереп тордым. Әллә ни оныттым кебек булдым. Тагы борылып кечерәеп әтине, кызарынган-бүртенгән тутакайны, пәжегән шалкан кебек булган коданы, нишләргә белми аптырып калган яшь әфисәрне сөздем дә кычкырып: «Һичбер вакытта!» — дидем дә, ашыгып чыгып үз бүлмәмә кереп бикләндем.

Түбәндә тавыш купты. Анда чаптылар, монда чаптылар, әллә ниләр сөйләделәр, кычкырдылар, бакырдылар, минем ишекне килеп кактылар. Берсенә дә җавап бирмәдем. Яттым, егладым-егладым да яттым. Башым янды. Тәнемне суык алды. Калтырандым, өшедем, кайнарландым, тирләдем, пештем. Калкынган кебек булдым, йоклаган кебек булдым, ишекне тагы шакыдылар, ачмадым. Тагы шакыдылар, урынымнан кыймылданмадым... Менә колагыма кыңгырау тавышлары керде. Әллә нинди тавыш ишеткән кебек күземне ачтым. Тәрәзәгә бардым. Бер начар гына чуваш аты җиккән авыл трантасына Паша менеп килә иде. Минем йөрәгем «шу» итте. Китә дип, актык өметем югала дип котым очты. Өстемә шәлне салдым. «Китмә, китмә, кал!» — дип чыгып асылыначак булдым. Ишекне ачтым. Ләкин тагы бусаганы үтә алмадым. Аягым калтырады, йөрәгем типте. Тәрәзәгә килеп, ичмасам: «Хуш!» — диясем килде. Авызымнан сүз чыкмады. Паша минем тәрәзәмә борылып карады да, чуваш аты кузгалды.

Мин хәлсезләнеп егылдым. Тагы шакыдылар. Тагы кыңгырау тавышлары ишетелде. Мин өн берлә төн арасында саташыр-саташмас бикләнеп калдым.

Икенче көнне мин юынып чәйгә төшкәндә бездә бер кунак та калмаган иде. Тутакай картайган, изрәгән, ләпшердәгән иде. Әти төссезләнгән, күңелсезләнгән иде. Без бер сүз сөйләмәенчә көнне үткәрдек, кичкә таба әти: «Мин Петербургка барам, иртәгә хәзерләнегез»,—диде. Мин дә, тутакай берлә каласым килмәгәнгә: «Әти, мин дә синнән калмыйм»,—дидем. «Алай булгач, мин ник калыйм, буе җиткән кызны ялгыз җибәрергә ярыймыни, әле ниләр булганны күрмәдеңмени?»—дип тутакай катышты. Мин бер сүз дәшмәенчә тыңладым да, тордым да чыктым. Икенче көнне, вакыт килмәгән булса да, без барымыз җыенып, тирә-күрше боярлар берлә күрешмәенчә дә, Петербургка киттек. Киткән чакта гына бер хезмәтче кыз: «Туташ, теге чарлакта торган егет сезгә бирергә дип бер хат биргән иде. Тутакай кулымнан тартып алды»,—диде. Мин: «Шул көнне ни булды соң?»—дип сорадым. «Сөйләмә инде, мондый мәсхәрәне мин гомеремдә күргәнем юк иде»,—дип сөйләргә тотынган иде, тутакай килеп тагы сүзне бүлдерде.

Мин Петербургта, Пашадан хат булмый булмас, дип көтә башладым. Бер атна көттем, ике атна көттем, ай көттем, һичбер хәбәр булмады. Көз килеп уку башлангач, аны сораштым, Петербургтан күчеп киткән, диделәр. «Кая соң?»—диюемә кайсылары Мәскәүгә, кайсылары Киевкә, диделәр. Шулай итеп, Паша югалды. Аның берлә бергә минем өметем дә югалды. Менә моң гына кыш үтеп килгәндә, әти читтә юлда чакта бер иртә берлә телеграм килеп төшмәсенме! Ни күзем берлә күрим, телеграмны әллә нинди бер стансадан станса начальнигы бирә. «Әтиегез поездда үлгән табылды. Тиз килегез, фәлән поездда»,—дигән бу хәбәр миңа шулкадәр авыр тәэсир итте, һушымны югалттым.

Мин күземне ачканда әти инде өйгә китерелеп салынган. Аның баш очында мулла коръән укып тора иде. Мин җансыз шәүлә кебек бүлмәдән бүлмәгә йөрдем, һичбер нәрсә аңламаенча, һичбер нәрсәгә күңел куя алмаенча, вакытны үткәрә алмаенча йөдәдем, йончыдым. Әллә кемнәр килде, әллә ниләр сөйләде, берсен дә тыңламадым да. Менә төн үтте. Озын авыр караңгы төн үтте.

Гәзитә китерделәр. Минем берлә тутакай исеменнән әтинең үлүе җеназасы хакында бирелгән матәм игъланы янында зур хәрефләр берлә: «Надежда Ивановна кадерле ире, балалары Коля, Леля кадерле әтиләре үлүен игълан итәләр, фәлән мәчет йортында җеназа укылачагын белдерәләр»,—дип икенче игълан басылган иде. Бу хәбәр мине кайнарлатты, өшетте, суытты, еглатты, газаплатты, мыскыл итте. Җеназа вакытында чынлап та җеназа артына кара кием кигән юан гына, карт кына бер марҗа ике бала берлә безнең янда урын тотты. Әллә нинди без танымаган руслар, марҗалар аңарга килеп тәгъзия итте*, ул еглаган тавыш берлә әллә нинди җаваплар бирде. Ул булмады, мирас хакында суд китте. Мин әтинең бер генә баласы булганга, бөтен дәүләт миңа калырга тиеш иде. Теге хатын мәхкәмәгә бирде, мине судка чакырдылар. Ике балалы хатын мәхкәмәдә әллә нинди тәмсез сүзләр сөйләп, әтинең исемен былчыратты. Мин хурландым, еглап җибәрдем. Шуны күреп теге марҗаның ике баласы да еглады. Шул күз яшь арасында, чынлап та болар минем сеңелләрем, энеләрем түгелме икән, дигән сөаль башыма килеп басты. Мәхкәмә минем файдама хөкем итте. Ләкин эчемнән мин шул эштә хаклыгыма ышанып җитә алмаганга, эчем пошып калды. Теге марҗа бик тәмсез телле пычрак марҗа булганга, үзе бик алдакчы булганга, аның берлә сөйләшеп мин хакыйкатьне аңлый алмадым.

Шул авыр кайгылар астында изелгәндә минем өметем һаман теге Пашада иде. Әтинең үлүе, мәхкәмәләре гәзитәләрдә язылганга, ул аларны

* Тәгъзия итү — юату.

укыячак, миңа кечкенә генә булса да бер тәгъзия язачак дип ышана идем. Ләкин бу өметем дә бушка чыкты. Мин тиздән тормыштан туеп, тутакайдан арып, әтинең ерак бер кардәше бер тутакайга Уфа губернасында кыш үткәрергә киттем... Анда бераз тындым, башымны җыйдым. Дөньяда үз башыма үзем генә калганны бик каты хис итеп, ялгызлыкка чумдым, аннан да арыдым. Нишләргә белми аптырап торганда бер җәй көнендә хәзерге иремне очраттым. Ул миңа ул вакыт бик йомшак кылынды. Минем кайгыларым өчен бик хәсрәтләнгән кебек булды. Сүзләремне бик ихлас берлә тыңлады. Озак үтмәде, шулай иттереп минем ышанычымны казанды. Көннәрнең берсендә бу минем кулымны да сорады. Күңелемдә аңарга каршы һичбер хис булмаса да, ялгызлыкка бик туйганга, тутакай янына барып тагы бергә торудан курыкканга разый булдым. Туй ясадык, өйләндек... Ләкин бал атналарымыз үтмәде, мин иремнең лаякыл исерек икәнен белдем. Мин үземнең бер тәмугдан икенче тәмугка күчкәнемне сиздем. Менә инде ун ел шул тормышны өстерим. Кайчанга кадәр тартырмын, анысын да белгән юк»,— диде. Аның күзенә яшь тыгылды, ул тавышланыр-тавышланмас елый башлады.

Нәфисә: «Юк, иншалла, рәтләнер әле»,— кебек сүзләр сөйләде, юатты, ләкин Гөлсем яшь арасыннан: «Хәзер ни булсын инде, яшьлек харап булды, көч бетте, дәүләт бетте. Калган нәрсә менә шулар»,— дип балаларына күрсәтте. «Болардан да ни чыгачак, алкоголик балалары бит»,— диде... Тагы үксеп-үксеп елларга тотынды. Нәфисә су салып эчерде. Тагы юатты. Тагы өметле сүзләр сөйләде. Гөлсем бераз тынды. Ахырдан гына: «Мин шунысына гаҗәпкә калам, ник соң ул егет тагы бер хат язмаган, ник соң ул тагы бер мәртәбә ничек булса да сезне күрергә тырышмаган?» — диде. Әллә нинди кадерле бер нәрсәсе мыскыл ителгән кебек, Гөлсем сикереп торды: «Язган ул! Бик күп мәртәбә язган. Мин кияүгә чыккач, моннан дүрт-биш ел элек безнең уртак танышымыз — ул вакыттагы бер курсисткага очрадым, шул аңлатты. Ул хат язган, ләкин мин берсен дә алмадым. Алар бар да безнең тутакай кулына төшкәндер, дип уйлыйм. Миннән җавап булмагач, ул бәлки мин дә үзенә каршы кампаниядә бергәдер, уртактыр дигән фикергә килгәндер. Килерлек тә бит инде... Тагы бәхетсезлек инде. Минем бәхетсезлегем»,— диде тә тагы елавында дәвам итте.

Төн ауды, таң атты, тирә-юнь яктырды. Ике хатын тагы бик озак сөйләшкәннең соңында, берсе иртәгә бәхетле көнен көтеп, икенчесе иртәгә янына киләчәк бәлане көтеп йокыга киттеләр... Иртәнге яктыда Гөлсемнең яшьли картайган битен бик күп җыерчыклар каплады. Эчкә җыя алмый күзләрдән ташып чыккан бәхет елмаюы, Нәфисәнең йөзенә яшеннән дә артык яшьлек буявы сөртте. Бүлмә тынды.

Иртә торганда күк йөзе зөмрә кебек зәңгәрләнгән, болытлар, яланнар яшәргән, урманнар сарылы-яшелле кушымталы бер төс алганнар иде. Идел дә, озын Идел дә, бик күп язларны, бик күп көзләрне күргән Идел дә, йомшак нурлы кояшка каршы күп агудан арыган кебек, моңланып, сузылып яткан иде. Пароход тирәсен чолгап алган акчарлаклар да, җылы матур һавага, тышка тулган халык берлә бер туктамаенча сөйләшеп кычкырышып баралар иде. Киләчәктәге пристаньга төшәргә булганга, Нәфисәләр, Гөлсемнәр дә балаларын киендереп, әйберләрен хәзерләп, ерактан күренгән пристаньны көтәргә тотынганнар иде. Пароходта иттифакый туры килгән ике хатын озын бер караңгы төнне бергә үткәреп, әллә ничек сүзгә кереп китеп, берсенә-берсе йөрәкләрен, йөрәкләренең эчендә җиде йозак берлә бикләнгән почмакларындагы серләрен түгеп салышканга, иске белешләр кебек, мәктәп аркадашлары кебек дуслашканнар иде, берсенә берсе кардәшчә, туганча бер хис биләшкәннәр иде.

Менә озын иттереп, моң иттереп тагы пароход кычкыртты, Нәфисәнең балалары әниләрен чолгап алып: «Әни, әтигә килдек, әтигә!» — дип сөенешә, сикерешә башладылар. Гөлсемнең балалары да, әллә нинди зур бер куркынычлы букәйне көткән кебек, әниләренең янына килеп: «Әни! Әти юкмы? Әти булмасын инде!» — дип, аңарга катыдан-каты сарыла баш-

ладылар. Пароход, бии торган куштан кызның әйләнүе кебек матурлап борылып, пристаньга якынайды. Гөлсем дә, Нәфисә дә пристаньга таба күзләрен текteләр, икесе дә шуннан көтә торган нокталарын берсе үзенә бу кадәр бәхет биргән, тынычлык, дуслык багышлаган, аерылуына еллар үткән кебек сагынган ирен, әтиләрен, икенчесе яшьлеген хәрап иткән, кыска гына гомердә аны яшьли картайткан, карчык иткән үзенең кара язмышын, үзенең бәласен эзли иде. Татлы көтү, матур өмет берсенең күзенә йомшак кына, җылы гына елмаю куйды. Курку, кот очу, өметсезлек, көзән җыерган кешедәге кебек, икенчесенең йөзенә бер җәберләнү, көчәнү, җирәнү төсен бирде. Нәфисәнең балалары беренче булып әтиләрен таныдылар, алар: «Әти, әти!» — дип кычкыра башладылар. Нәфисә яулык селкеде. Пристаньнан тагы яулык селкү җавабын алды. Еракта гына күзләр күзгә очраштылар. Теге беренче мәртәбә театрда очрашкан тәм берлә очраштылар. Алар икесе дә елмаештылар. Бик мәгънәле елмаештылар.

Шуның берлә мәшгуль булганда Нәфисә Гөлсемне дә онытты. Ләкин пристаньдагы ярты гаскәри киемдәге бер кешенең исерек көенчә әле күпернең бер ягына барып бәрелүен, әле бер яктагы бөккән, калач, алма сата торган бер марҗаны барып кочакларга теләвен күреп, чыдый алмаенча, шаркылдап көлеп җибәрде. Теге пристаньдагы кеше һаман әллә ниләр кычкырып, төрле кешеләргә бәйләнеп йөрегәнгә, алар да аны һич шәфкатьсез бәреп, төртеп, туп кебек күпернең бер ягыннан бер ягына, бер юан марҗадан икенче марҗага төртеп йөрткәнгә, бу кәмитне бүлешер өчен күршесенә: «Гөлсем ханым, Гөлсем ханым! Кара әле зинһар шул тилене»,— дип, көлүенә чыдый алмаенча, аңарга борылды. Аның йөзе үләргә хәзерләнгән кебек ап-ак, ирennәре зәңгәр, күзе курку, өметсезлеккә баткан итеп тапканга, Нәфисәнең көлүе яртысындаябылды. Ул аптырап, кызганып Гөлсемне сөзде. Гөлсем дә, тагы сүзгә керешмәс өченме, калтыранакалтырана борылып китте. Әйберләрен күтәреп ишеккә таба юнәлде. Нәфисә, пароход өстеннән ире берлә, исәнме-саумы дип, берәр сүз алышып алмаенча китәсе килмәгәнгә, пароходның якынлашуын көтте вә шуның берлә чыгарга соңга калды.

Пристаньда чыга торган халык агымы эченнән хатынын, балаларын көтә торган доктор һич уйламаганда, көтмәгәндә, Гөлсем берлә кара-каршы килде. Аларның күзләре очраштылар. Доктор, бу карчыкны кайда күрдем соң, дип озак уйлап торганның соңында, җимерелгән, кипкән карчыкта ул 18—19 яшьлек, күбәләк кебек оча торган Гөлсемнең, үзе бер вакытларны бөтен хәятын фидә итәргә йөргән Гөлсемнең шәүләсен күрде. Бер минутта аның күз алдыннан үзләренең бөтен үткән вакыйгалары үтте. Ике кулында ике баласы барлыгын күреп торса да, ул: «Гөлсем туташ, сезмени?» — дип, кулын сузды. Гөлсемнең боздан суык кулларын кысканның соңында, ул Гөлсемнең көчләнеп көлгәннән чыккан йөзендәге җыерчыкларын күреп аптырады, кызганды, аяды. «Сез һаман мондамыни?» — дип сорашырга тотынды. Сүзләргә җавап булыр-булмас теге исерек, бер эполеты* бөтенләй төшкән, берсе иңсәсенә аткырыйлы итеп эленгән, гаскәри шинельдәге исерек докторны килеп төртте. Гөлсемнең кулыннан әйберен алмакчы булды. Доктор, бу исерек башка марҗаларга бәйләнгән кебек, Гөлсемне мыскыл итәргә тели, дип уйлап, аны сакларга маташканга, исерекнең йөзе кызарды. Ул урысчалап: «Бу минем хатыным, бу минем хатыным!» — дип тагы докторны төртте. Гөлсемнең кулыннан төенен алды. Доктор аптырап Гөлсемгә карады. Гөлсем күзе күзгә очрамасын өчен башын иде, тизләп култыклап исерек ирен алып китмәкче булды.

Шул ара да булмады, Нәфисәләр килеп чыктылар. Балалар әтиләренең муенына сарылдылар. Әллә нинди сөальләр берлә, сүзләр берлә тирәюньне тутырдылар. Нәфисә иренең култыгына кереп, тагы бер мәртәбә: «Нихәл, исән тордыңмы?» — дип, бәхетле күзе берлә ирен сөзде. Кулын кысып алып, алга таба атлый башлады. Күпернең яртысына җиткәндә тагы

* Эполет — хәрбиләрнең киеменә тагыла торган парад погоны.

тавыш чыкты, теге исерек Гөлсемнең кулыннан ычкынып китеп, күпернең уртасына килеп, ике аягын җәеп басты. Үзе сәгать теле кебек әле бер якка, әле бер якка селкенеп, үтә торган кешеләргә юл бирмәскә маташты. «Туктагыз!» — дип кычкырды. Кычкырып көлә торган, калач сата торган марҗаларга карап: «Понимаете, потомственный почетный дворянин!» — дип күкрәгенә сукты. Халык аптырап туктап калды. Гөлсемнең балалары егларга тотынды. Үзе тоз кебек эреп югалды. Нәфисә иренең култыгыннан ычкынды да, исерекнең янына барып аны култыклады. Юлны ачып, алга таба бара башлады. Аңарга татарчалап әллә ниләр сөйләде. Исерек тагы туктап Нәфисәгә гаскәри сәлам бирде, аның кулын үпмәкче булды. Нәфисә аны каты иттереп тотып, җибәрмәенчә күпердән алып чыкты. Бердән Гөлсем балалары ире белән, Нәфисә балалары ире белән докторның аты янында тупландылар. Һәммәсе ни эшләргә белмәенчә аптырап торганда, Нәфисә: «Кая таба барамыз соң?» — диде. «Гөлсем ханымны болай балалары белән калдырып китәргә ярамый бит!» — дип, иренә мөрәҗәгать итте.

Сөйләшә торгач, боларның борылышка кадәр әле бергә барачагы мәгълүм булды. Исерек түрәгә Нәфисә белән бергә барырга карар ителде. Гөлсем: «Рәхмәт, без инде өйрәнгән»,— дип караса да, Нәфисә ирек бирмәде. Бер арбага балалар белән Гөлсем, доктор утырдылар. Икенче арбага Нәфисә көчләгән кебек итеп исерекне утыртты. Исерек тагы сикереп төшеп кычкыра, бакырына башлаганга, Гөлсемне бик каты иттереп үз арбасына чакырганга, Нәфисә: «Сезнең белән мин утырып барасым килә»,— дип аның янына үзе утырды. Кәрван кузгалды. Беренче арбада балалар бер туктамаенча кычкырып сөйләп барсалар да, Гөлсем дә, доктор да тирән-тирән уйларга, үзләренең үткән гомерләрен, баштан кичкән хәлләрен яңадан күздән кичерүгә чумдылар. Икенче арбада исерек әллә ниләр кычкырынды, бакырынды, әллә кемне тиргәде, әллә кемгә ялынды, йодрыгын йомарлап әллә кемгә янады. Ахырдан ул егларга тотынды. Нәфисәнең кулын үпте. «Сез алтын кеше, сез бәхет савыты, ә минем хатыным кем? Ул чүпрәк, мине харап итте»,— диде дә, күзеннән елгалар кадәр яшь агызып егларга кереште. Аның еглавы куәтләнгәннән куәтләнде. Ул яшь арасында: «Менә сез миңа очраган булса идеңез, ничек дөньяны тетрәткән булыр идек»,— диде... Нәфисә гомерендә мондый моназарәгә очраганы булмаганга, ачулану белән кызгану арасындагы бер хистә буылып калды. Ахырдан аны кызгану хисе биләде. Ул төрле сүзләр белән исерекне юатырга тотынды. Исерекнең фикере икенчегә ауды булырга кирәк, ул елмаеп көлде. Исерек елмайган кебек елмаеп, авызын ачып Нәфисәнең тасвир иткән матур манзараларын күргән кебек тыңлады. Аның йомшак сүзләрен тыңлый-тыңлый калгый башлады. Озак үтмәде, ул Нәфисәнең җилкәсенә башын сөяп йокыга да китте. Нәфисәдә, элгәре сулавыннан искәргән аракы исе аңкый торган кешене төртеп җибәрү хисе уянса да, аны кызгану җиңде. Ул: «Йокласын, мескен»,— дип, үзенә уңайсыз булса да, исерекне кузгатмады.

Арбада ялгыз калганга, ире; балалары теге арбада булганга, ул тәләртеләмәс уйга чумды. Теге арбадагы гомерен, яшьлеген харап иткән Гөлсемне, бу арбадагы шул кешелектән чыккан исерекне күз алдыннан җибәрә алмады. «Ник соң бу болай? Ник болар уртача гына бәхет белән тора алмаганнар? Ниләре житешмәгән, икесе дә укыган, икесе дә тәрбия күргән... Икесе дә яшь булган... Икесе дә бай булган... Ник?» — дип башын ватты. Бу соальләргә төрле җаваплар тапкан кебек булса да, берсе дә канәгатьләндермәгәнгә, уйга тыныш куя алмаенча, үз тормышына күчте. Яңадан үзенең яшьлегеннән бирле үткәргән гомере, көне-көне белә кебек күз алдыннан үтте. Ул тормышындагы тулы бәхетне яңадан таныды. Шуның тәмнәре, татлы хыяллары эчендә ул рәхәтләнеп изрәп китте. Шул тулы тормышны багышлаган ирен хәзер барып кочаклыйсы килде. Аның кулын барып үбәсе килде. Аңарда иренә каршы сөю, ир итүгә башка әйтеп бетерелмәслек зур бер хөрмәт уянды. Язмышыннан разыйлык аны биләде.

Ул шул сөю-сөешү эчендә үткән гомере өчен, ул хәзерге аталы-балалы тыныч тормыш өчен, әллә кемгә, әллә нигә каршы тез чүгәсе, тезләнәсе килде. Әллә кемгә, әллә нигә: «Рәхмәт, рәхмәт, мең мәртәбә рәхмәт, мин бит менә болай булмадым, болар да бит адәм баласы, рәхмәт, миңа мондый тулы тормыш бирдең. Рәхмәт, мине шундый газаплардан котылдырдың»,—диясе килде.

Аның күңеле йомшады, ул көзге кояшка каршы чабып бара торган арбаның җиле астында, акрын гына коръән укырга кереште. Исерекнең авызыннан чыгып тора торган искергән аракы исе аны борчыганга, кайвакыт аның авызына кадәр кереп китеп теләндә әйләнә торган коръән сүзләрен мәсхәрә итә кебек тоелганга, ул иңсәсенә яткан исерекне уятмаслык иттереп кенә башын читкә борды. Үзе аңлап бетмәгән коръәннең сүзләре, бигрәк шуның көе аның күңеленә әллә нинди бер йомшак җылылык бирде. Аның тамырларына әллә нинди әйтеп бетерә алмаслык тынычлык таратты. Ул үзе дә сизмәенчә тавышын зурайтканнан зурайтты. Коръән моңы, көпчәк тавышына кушылып, яңа бер төс алды. Акрын гына исә торган көзге җил ул тавышны алга-артка чәчте, сипте. Нәфисә үз көенә үзе батып, коръән артыннан бара торган тирән бер шөкранә берлә басылганнан басылып башын иде, бик түбән иттереп башын иде. Шул тормышны биргән тәңресенә каршы сәҗдә кылмакчы булып буен сынды.

Аның колагына исерекнең гырлавы ишетелде. Аның борынына исерекнең искергән аракысының исе бәрелде. «Ирең шундый булса, ни эшләр идең»,—дигән куркулы бер фикер аны килеп сукты. Язгы көннең болыты кебек, ул да тиздән югалды. Тагы тормышның кояшы ялтырады. Ул кулын догага күтәрде. Үзе белгән бөтен догаларын укып бетерде. Аның берлә генә тулмады кебек хис иткәнгә, ул кулын төшермәде. Кыска сүрәләр укыды. Татарчалап аллага ялынырга, ялварырга, шул биргән бәхетле тормышын озын иттерергә ялварырга тотынды. Аның күңеле моңайганнан моңайды, күзеннән ике бөртек яшь тәгәрәде. Шуның берлә күңеле дә тәмам тынды, тынычланды. Ул, йөзен сөртеп, догасын бетерде. Атлар баруында булды. Исерек гырлавында дәвам итте.

Теге арбада бик озакка кадәр сүз юлына кереп китмәде. Балалар берсе-берсе берлә шаярышып, чупырдашып барсалар да, әле оча торган бер кош хакында, әле мәрҗән кебек тезелгән миләш хакында сөальләр биреп зурларны йөдәтсәләр дә, нә Гөлсем, нә доктор үз уйларыннан аерыла алмадылар. Иске дустча яисә яңа танышча сүзгә чумып китә алмадылар. Арада үткән вакыйгалар, шуннан соң булган хәлләр, боларны әллә ничек берсеннән берсен көчләтебрәк булса да ераграк тотарга мәҗбүр иткән кебек булды. Менә балалар арбаның йомшак саллануы астында изрәнгәләп, берәм-берәм йокыга киттеләр. Гөлсем берлә доктор икесе генә күзгә-күз калдылар. Гөлсем бер яктан кичә Нәфисәгә ул кадәр ачылуыннан үкенеп, икенчедән, көтелмәгәндә килеп чыккан шул очрашудан аптырап калып, язмышның шул авыр йөге астында башын игәннән-иген иде. Ул докторга күзен күтәреп карый алмады. Аңарга бер сүз берлә дә башлап китә алмады. Эченнән генә: «Мине гафу итеңез, теге вакыттагы эшләр өчен!»—димәкче булды. Авызын ачарга булгач кына сүзе онытылды. Фикере чуалды. Икенче яктан, серен бирмәенчә: «Алларга шөкер, бик шәп торам»,—дигән уйны калдыру өчен искене оныткан кебек сөйләп китмәкче булды. Исерек иренең кылынышлары күз алдына килде дә, тагы ул карарны эшли алмады. Доктор да элгәре моңарга каршы үпкәләгән, бик күп хатларына каршы җавап булмаганга, хурланган итеп үзен һаваны тотарга теләсә дә, язмыш тарафыннан шулкадәр изелгән Гөлсемнең йөзен күрү берлә, ул да вазгыятьне* саклый алмады, аны кызгану басты. Менә Гөлсемнең бер баласы бердән куркынып уянды. Гөлсем докторга карап: «Менә тиктән шулай куркынып уяна, сез бит доктор кеше, аны ни эшләргә

* Вазгыять — торыш, халәт.

кирәк?» — дип докторга карады. Доктор: «Сеңерледер, тынычрак тотарга кирәк!» — диде дә тагы сүз өзелде.

Тагы икесе дә сүзне башлап китәр өчен берәр хәйлә эзләргә тотындылар. Доктор: «Соң сез, Гөлсем туташ, һаман шунда торасызмы, мин сезне инде моннан киткән дип ишеткән идем»,— диде. Гөлсем: «Юк, вакытлы гына киләмен, эшем генә бар»,— дип җавапланды да сүз киселде. Үзе эченнән: «Соң сез минем язмышымны беләсеңез килсә, минем кайдалыгымны белмәгән булыр идеңезмени?» — дип шелтәләмәкче дә булды. Ул сүз дә авызыннан чыкмады. Доктор: «Кайда торасыз соң, әтиеңез үлгәч, мин сезгә Петроград адресыңыз берлә дә, мондагы адресларыңыз берлә берәр хат язган идем. Җавабы да булмады, хаты да кире кайтмады»,— диде... Гөлсем кып-кызыл булды: «Мин сездән һичбер хат алмадым, һичбер! Теге көнге күрешкәннән соң бер сүз ишетмәдем, бармак буе бер кәгазь алмадым... Мин бик көттем... Сез мине, үзеңез әйткәнчә, шул баткаклыкта ялгыз калдырмассыз дип көттем, бик көттем, ләкин бер сүз ишетмәдем, бер хат алмадым»,— диде дә тагы башын иде. Доктор: «Минем китүемнең ничек булганын белә торгансыз, сезнең теге әфисәргә «бармыйм» җавабыңыздан соң бөтен бәла миңа ауды. Бөтен кеше мине гаепләргә тотынды. Теге әфисәр мине дуэльгә чакырам дип бәйләнде, карт мирзасы мине эт итеп сүкте. Сезнең тутакаеңыз бөтен халык алдында: «Чыгып кит!» — дип мине куды. Мин шулкадәр хурлану, мәсхәрәләнү алдында сезне онытмасам да, сезне күрергә һичбер төрле юл булмагач, берничә адрес күрсәтеп, сезгә хат язып калдырдым, аны шундагы сезнең хезмәтче кызыңызга бирдем». Гөлсем: «Ул хатны минем тутакай алган, мин аны күрә алмадым»,— диде. Доктор: «Аннан җавап булмагач, мин сезнең икс адресыңыз берлә дә хат яздым, тагы җавап булмады, тагы яздым. Петроградка бардым. Сезне күрер өчен кулдан ни килсә, шуны эшләдем. Театрга йөрдем, сезнең өй тирәсендә көннәр буе каравылладым, телефон шалтыраттым. Ләкин сезгә һичбер тугры килә алмадым, аннан соң беркөнне үземнең адресым берлә бөтен хатларым кире кайтты. Сезнең язуны, кул түгелме икәнене белмәгәнгә, тагы шул арада сез әллә нинди бер кавказлыга кияүгә чыгасыз дигән хәбәр дә йөргәнгә, бу сезнең тарафтан эшләнгән эш дип ышандым. Шуның өчен өметсезләндем. Петроградта яшәү бик авыр булды. Киев дарелфөнүненә күчеп киттем. Аннан да әле бәйрәмдә сезгә котлап тәбрик җибәрдем»,— диде. Гөлсемнең күзләрен ут алды. Ул кып-кызыл булды. «Ышанамсыз, юкмы, ни кадерлеңез бар, шуның берлә ант итәм, валлаһи, бер хатыңызны алмадым, һичбер хатыңызны сезгә кире кайтармадым»,— диде. Үзенең күзеннән икс бөртек яшь тәгәрәде.

Шуңарга каршы доктор ни эшләргә белмәенчә торганда ат туктады. Кучер: «Менә шунда инде аерылыш»,— дип борылды. Гөлсем тагы калтырады, тагы дерелдәде. Тагымыни аерыла, әле генә кушылган иде, тагымыни аерыла? «Аерылмасын!» — димәкче булды. Күзе дүрт балага төште. Ул күзен күтәрде, докторга карады. «Әйе, шунда юл аерыла шул!» — диде. Арба туктауга, бердән бөтен балалар аякка калыкты. Тирә-юньдәге миләш асылган агачны күрү берлә мәче балалары кебек берсе артыннан берсе йолт-йолт җиргә сикерде. Арттан килеп туктаган арбадагы Нәфисә кулы берлә изи-изи боларны чакыра башлады. Доктор да, Гөлсем дә, әллә берәр нәрсә булдымы, дип куркынып, Нәфисә арбасына ашыктылар. Анда алар Нәфисәнең иңсәсенә башын аударып яткан исерекне тирән бер йокы эчендә, авызыннан селәгәйләре аккан көенчә, Нәфисәне дә капканга кысылган кебек, тартылып башын тискәрегә таба борган хәлдә таптылар. Беренче хисләре икесенең дә Нәфисәне котылдырыр өчен шул күсәкне төртеп җибәрү булды, ләкин Нәфисә: «Акрын-акрын бер мендәр генә китереңез, бик шәп йоклый, мескен, йокласын, азрак айныр»,— дигәнгә, икесендә дә кызгану хисе җиңде. Кызулашып мендәр алып киленде, уятмаенча баланы урыныннан күчергәндәге кебек йомшаклык берлә исерекнең башын Нәфисә иңсәсеннән мендәргә күчелды. Нәфисә азат иттерелде. Уйланмаенча утырышканда Нәфисә берлә исерек докторларның арбаларына утырган

булганга, хәзер аны уятып арбадан арбага күчерү, аны тагы исерек хәленә кайтару булачак булганга, тегенең йокысы туюны, айнуын көтәргә карар бирелде.

Көн иртә матур булганга, су буендагы яланга атлар да туарылды. Бик күп коры-сары җыелып, ут ягылды. Ялчыларның чәйнекләре алынып, чәй хәзерләнде. Урман эченнән әллә никадәр миләш, балан җыелып килende. Көзге кояшның җылы, йомшак нуры астында бөтен җәмагать чәйгә утырды. Нәфисәнең күңелендә үзенең хәленә шөкранә хисе бик тулы булганга, ул шул кызганыч хатынны, шул хәстә балаларны бик кадерлисе килде. Аларга аз гына булган шул тыныч вакытны тулырак үткәрәсе килде; ул, өендә кунак кабул итә торган ханым кебек, бөтен эшне эшләде, чәйне әзерләде, кәрзиннәрне ачты, ашамак-эчмәк чыгарды. Балаларны җирле җиренә утыртты. Аларга тәмле-томлы таратты. Чәй ясарга утырды. Мәҗлес күңелле үтте. Чәй тәмле чыкты. Гөлсемнең йөзендәге җыерчыклар качты, аның йөзенә бер кызару йөгерде, битенә елмаю килде. Ул үзен-үзе онытып, рәхәтләнеп бер сулыш алды. Чәй бетәр-бетмәс балалар тагы урманга таралдылар. Доктор берлә Гөлсем дә акрын-акрын атлап, әллә кайчан куелган очрашуга барган кебек, урман арасына кереп югалдылар. Нәфисә генә, ашны-суны җыя-җыя, кучерларга чәйне эчерә-эчерә, соңга ялгыз калды. Урман бала тавышы берлә тулды. Яфраксыз, шыр ялангач агач араларыннан күренгән кызыл миләш сабаклары аларны әле бер якка, әле бер якка йөгертте. Агач башында гына эләгеп калган дүрт-биш чикләвек аларның бөтен көчләрен шуны алырга сарыф иттерде. Агачтан агачка сикерә торган тиен элгәре аларны куркытты. Аннары көлдерде, аннары йөгертте. Гөлсем дә, доктор да бер сүз эндәшмәенчә һаман алга атлауларында дәвам иттеләр.

Менә бердән икесе дә туктадылар. Көтелмәгән бер киртәгә барып терәлгән кебек туктадылар да берсенә берсе караштылар. Алларында зур бер агач сап-сары яфракларга сарылып һаваланып утыра иде. Аның төбендә кечкенә генә итеп төшкән яр астында су борылып-борылып китә, борылганда әллә нигә эләгеп китеп шырлап-шырлап көйләп ага иде. Суның теге ягында озын киң ялан, ямь-яшел яшьләвеккә батып, иртәнге чык бөртекләре берлә кояшка каршы җемелдәп-җемелдәп уйный иде. Аның артында зур урман башыннан аягына кадәр яшелгә бөркәнгән чыршы берлә ак киндергә сарылган каен, акрын җил берлә шылтыраган тавыш чыгара торган сары яфраклар берлә бизәлгән усак. Бу төсләр бер генә түгел, йөз генә түгел, меңләп-меңләп берсе арасына берсе кереп, озын-озын, зур-зур аклы-сарылы бер букет ясыйлар, берсен берсе куа торган төрле киемдәге кешеләр кебек, берсеннән берсе узышып еракка-еракка китәләр иде. Доктор да, Гөлсем дә шул манзара астында изелгән кебек, әллә нинди бер хәтеренә килеп бетмәгән нәрсәсен эзләгән кебек, катып калганнар иде. Күзләрен еракка таба текәннәр дә калганнар иде, икесенең дә күз алдыннан элгәреге көннәр үтә иде. Элгәреге татлы өметләр, тәмле хыяллар, манзаралар кичә иде. Әнә бу җирдә алар бергә икәү генә балыкка килгәннәр иде. Гөлсем алсурак бер күлмәктән, чәчләре бераз тузылган көенчә, шул ярга утырган иде. Әнә теге таштан битләре янган тап-таза егет Хәлил икенче кармакны суга салган иде, әнә алар икесе дә суга караганнар да күз текәннәр иде. Гүя, судагы көмеш балыкларны эзләгән кебек, бер-берсенең күзләрен эзләгәннәр иде. Судагы шәүләләренә әллә никадәр сүзләр сөйләшеп, мәхәббәтләренә белгерткәннәр иде. Әнә шунда... Менә Гөлсем тагы кармагын тартты. Аның җебенең очында ялтыраган көмеш балык сикерәнә-сикерәнә су өстенә чыкты, менә ул тагы өзелеп «чолт» итеп суга төшеп китте. Менә тагы су тынды. Тагы бер-берсен күрделәр, тагы елмаештылар. Ихтыярсыз куллары кулга очрады, Хәлилнең кайнар кулы эченә Гөлсемнең суык кулы кереп суыктан җылына башлады. Берсенә берсе карадылар. Хәлил: «Менә шунда бит без бергә балык тоткан идек»,— диде. Гөлсем: «Әйе, шунда...— диде дә сүзен дәвам иттерә алмады, күзеннән яшь мөлдерәде:— Мин сезнең алдыңызда гаеплемен, ул вакыттагы сезгә каршы

эшләнгән начарлыкларда катышым булмаса да, сезне яклап бер эш эшли алмадым. Гафу итегез, көчем булмады. Менә шуның җәзасын күрәм»,— диде. Үзе үксеп-үксеп еларга тотынды. Хәлил аны биленнән алды. Башын үзенең иңсәсенә куйды. Балаларны сөйгән кебек аның башын, чәчен сыйпады. Гөлсем, әллә нидән качкан кебек, аның кочагына кергәннән-керде. Әллә нинди зур бер бәладән сыенгын кебек янашканнан янашты. Аның кайнар сулышы Хәлилнең битенә бәрелде. Аның йөрәк тибүе Хәлилнең колагына ишетелде. Ул юешләнгән керфекләр арасыннан йөзенә моңланып-моңланып карый торган Гөлсемне йомшак кына иягеннән тотты. Акрын гына иттереп битен борды. Бит биткә тиде, авыз авызга очрашты. Бердән урман җанланды. Анда да, монда да балалар кычкыра башлады. Гөлсем балаларының елаган тавыш берлә: «Әни, әни!» — дип акырулары, Хәлил балаларының: «Әти, әти! Син кая?» — дип аваз бирүләре боларны уятты. Бердән берсе-берсеннән читкә киттеләр... Берни аңламаган кебек, берсенә-берсе карашып торыштылар. Менә «А-ау!» — дигән Нәфисәнең ерактан эзләгән тавышы килде. Гөлсем куркып селкенеп китте. Хәлил: «Әү!» — дип сузып җавап бирде. Гөлсем куәтене туплады, көчләнеп, тагы форсатны качырмыйм дип: «Мин һәрвакыт сине сөйдем, хәзер дә сөям»,— диде... Хәлил җавапка авызын ачарга өлгермәде, балалар өеме килеп чыгып, кайберләре аталарына, кайберләре аналарына сырылдылар. «Елан күрдек, елан!» — дип сөйләргә тотындылар. Хәлил Гөлсемнең күзенә бик мәгънәле иттереп карады, балаларны күздән кичерде: «Инде көз булды, Гөлсем туташ, көз; һәр агачның җимеше пеште, миләшнеке миләшчә, алманыкы алмача!» — диде... Күзенә яшь тыгылды. Шуны куәтләгән кебек, урман өстеннән бер җил үтте. Агач ботаклары берсенә-берсе бәрелде. Бик күп сары яфрак Гөлсемне каплады. Ул арада булмады, Нәфисә килеп җитте. Ул боларның аптырабрак торганнарын күреп: «Нәрсә бик моңайдыгыз?» — диде. Гөлсемдә шул хатынның бәхетеннән көнләү уянды, аз гына булса да шуны чәнчәсе килде, ул: «Яшьлекләр искә төште, без монда тормышның язында Хәлил әфәнде берлә очрашкан идек, менә тагы көзендә дә тугры килдек»,— диде... Нәфисә: «Сез электән таныш идегезмени?» — дип Хәлилгә карады. Хәлил: «Әйе, мин студент чакта!» — диде.

Нәфисә озын гына иттереп: «Алай икән»,— диде дә икесен дә сөзде. Үзе бераз икеләнеп торган кебек булды да, бер кулы берлә ирен җитәкләп, бер кулы берлә Гөлсемне алды: «Әйдәгез, әнә тагы болыт чыгып тора. Көзге кояшка ышанырга ярамый»,— диде. Гөлсемгә: «Сезнең иregез дә торды»;— диде. Акрынлап арбага таба юнәлде. Юлга әзерләнү бик тын үтте. Исерек айнып уянганга, ул бик оялды, хурланды, күзен югары таба күтәреп карый алмады. Яшьлегенең иң матур, иң пакъ бер битенең көтелмәгәндә болай бердән кырт киселүе, йөрәкнең иң тирән почмагында сакланган соңгы өметнең көзге сары яфраклар берлә каплануы, томалануы Гөлсемне тагы басты, тагы изде. Тормыш йөге астында изелгән аның биленe тагы бөкте. Нәфисә берлә үткән тулы мәгънәле тормыш эчендә күптән онытылган яшьлек хатирәләре, көтмәгәндә килгән шайтан туе кебек, Хәлилнең тыныч күңелен болгатты, дулкынлатты. Бәхетле гаилә тормышының калын өресе астында, үзенең эсселегеn, кайнарлыгын яшергән, саклаган аның йөрәк уты шул көзге җилнең искәртмәстән исүе берлә пәрдәсез, калкансыз калды. Аның уты тышка чыкты. Аның ялкыны дөньяга күренде. Ул йөрәкнең көйгән исе Нәфисәнең йөзенә бәрелде. Хәлил үзенең бәхетле тормышының остасы, зур күңелле шул саф хатынының алдында оялды. Аның олуглыгы астында муен иде. Башын бөкте.

Нәфисә дә, бөтен гомерен кешеләргә ышануга, кешеләрнең яхшылыгына корган Нәфисә дә, ун ел эчендә баштанаяк иренә ышануга, инануга баткан, чумган Нәфисә дә, шул ара-тирә кызыл миләшләр, баланнар берлә генә бизәкләнгән сары яфрактан, сары кәфен киенгән көзге урман эчендәге шул юешле, суыклы көзге җил, аның күңелендә иренә каршы беренче мәртәбә шөбһә уятты. Иренең тугрылыгына каршы, кешеләрнең яхшылы-

гына каршы йөрәгенә шик салды. Ул шөбһәне тиздән бетерә алмаганга, шуны кирәкмәгән чүп кебек читкә төртеп ташлый алмаганга, тормышның кәкереле-бөкереле тыкрыклары, почмаклары эчендә ул адашкан кебек булды, ул да көләчлегене югалтты, күңеленә әллә нинди бер исемсез эчпошыргыч (нәрсә) җирләште, әллә нинди күрелмәгән бер көя аның тынычлыгын ашый башлады.

Коры гына күрешеп атларга утырдылар. Юлның аерылган почмагыннан ике арба ике якка киттеләр. Ихтыярсыз ике арбадагы да күзләр берсен-берсе сөзеште. Ике арбадагы күзләр дә берсенә-берсе әйтелеп бетмәгән соңгы сүзләрне әйтеште. Озак кына тик барганның соңында Нәфисә Хәлилнең йөзенә карады, күзенә карады. «Шулмыни беренче мәхәббәтең»,— диде... Хәлил: «Әйе!» — дип башын иде. Бераз паузадан соң: «Әллә син көнләдеңме?» — диде... Нәфисәнең күзе ялтырады, йөзе кызарды, әллә нинди бер авырткан җиренә тигән кебек сыкраган тавыш берлә: «Әстәгъфирулла, әстәгъфирулла, моннанмы? Шул мескеннәнме?» — диде... Тавыш туктады. Бераздан, шул фикерен дәвам иттергән кебек, Нәфисә Гөлсемгә каршы сузып кына: «Тиле!» — диде... Шул сүзен авыррак таптымы... кешенең бәхетсезлегеннән көлү кебек булып киттеме: «Мескен...» — диде...

Икесе дә Гөлсемнәрнең арбалары китеп барган юлга күзләрен текteләр. Анда көзге җил өермә куптарган иде. Шайтан туе, сары яфраклар, сары саламнар, иске тузаннарны җыеп Гөлсемнәрне куа иде, аларны җитәм-җитәм, дип ашыга иде. Менә тагы җил, тагы бер өермә, әнә аларның өстендә сары яфраклар, көзге сары яфраклар оча... Әнә арбаның дугасы гына күренә, әнә ул да югалды, әнә ул да юк... Менә көзге вак ягмур акрын гына сибәли башлады. Менә ул тирә-юньне томалап, һаваны басты. Нәфисә аркасыннан әллә нинди юеш бер суык йөгергәнне хис итте. Ул тызырак итеп иренә таба сыенды. Хәлил таза кулы берлә аны кысты... Күзләре күзгә очрашты, елмаешты, көлеште. Оршышканнан соң килешкәндәй була торган кебек бер җылы икесен дә биләде. Тәмле иттереп, татлы иттереп биләде. Хәлил кучерга: «Тизрәк тот, ягмур җиткәнче кайтыйк!» — диде. Кучер чыбыркыны шартлатты. Атлар алдырып киттеләр. Кыңгыраулар берсенә-берсе җитә алмаенча, өйгә таба, җылы вә ягмурсыз, җилсез өйгә таба ашыга башладылар.

*Берлин,*
*1923.*

---

Повестьның фотокүчермәсен Төркиядән Г. Исхакыйның кызы Сәгадәт ханым Чагатай вафаты алдыннан безгә юллаган иде. (Л. Гайнанова искәрмәсе.)

# Хәмит Төхфи

## Газәл

Яндырыйм дип ут кабыздым, әмма утлар янмады.
Алгысынды бу йөрәгем, барлыгыннан танмады.

Ул үзен белде — адәм дип, ул үзен белде — камил,
Һәм үзеннән түбәннәргә, ялварып та бармады.

Юл сабу дип аңлады ул аз гына чиккәнне дә,
Ник бу кадәр мин фәкыйрьне язмышым нык алдады?!

Ут та алды, алды су да дүрт ягымның һәммәсен,
Нигә соң ул утлары минем үземне алмады?!

Ак иде бит, хак иде бит мин иман иткән хыял,
Ул хыял һәм ул өметнең чаткысы да калмады.

Ашкынып торган күңелне мин бүген нәүмиз күрәм,
Нинди дәһшәт хәл бу, золмәт бар йөрәкне ялмады.

Тик каләм төшми кулымнан — эзләнә ул, эзләнә,—
Бәлки бардыр алда таңнар,— эзләнеп һич армады.

Эзләгән — тапкан диләр бит, белмәсәң бел, и Хәмит,
Мәңге яратуга лаек яр күзеңне арбады!

## Томан

Иңкүләрне, уйсуларны ураган томан,
Томаладым дөньяны дип кылдымы гөман?

Фараз итте, минем кулда диеп хакимлек:
Бөтен сахра минеке дип, минеке киңлек!

Чыккан иде нурлы кояш көлеп бер заман,
Калмады бер күләгә дә хәтта томаннан.

---

Хәмит ТӨХФИ — *Кытайда туып-үсеп, хәзер Ташкентта яши. Шигырьләре, мәкаләләре Татарстан көндәлек матбугатында, шул исәптән журналыбызда да басыла килде.*

Булмагандай, иңкүләрдән югалды томан...
Томаладым дөньяны дип, кылмагыз гөман!

## Фәрдләр

Һәрвакыт риза кадерләнүче.
Шикаять итә — җәберләнүче.

И илаһым, шик сакламыйм, барлыгың рас...
Тәкәбберлек миңа түгел, иблискә хас.

Мин бик арзан, арзанрак мин хәттәки судан.
Саклый күрсен, сакла хода кыйбат булудан.

Сөйли-сөйли бу дөньяның хәсрәтен, зарын
Онытыйммы тормышымда куаныч барын?

Хатын-кызлар яраталар сөйгәнеңне,
Ирләр исә багынып баш игәнеңне.

Үзең олы, могътәбәр бер ил агасы,
Үзең ятлар икмәгенә май ягамсың?

Заман ахыры — кояш сүнгәндә.
Кояш сүнә миңа — үлгәндә.

Элек уйла берлек турында.
Аннан инде хөрлек турында.

Зарарлы икән бит, әй,
Хәйям хуп күргән бу мәй.

Сөйгән ярыңда кимчелек булмый, булмый бер гаеп.
Аның янында уздырган көннәр бәйрәм һәм гает.

Чамасында булса, тәмле — шикәр дә, бал да.
Кимәленнән артып китсә — туйдыра ял да.

Халык бай, халык тук булса, мин дә тук.
Халыкта булмаса, миндә дә тәгам юк.

Күп бездә «югары белем» алганнар.
Кайдан килә ләкин укымышлы наданнар?!

* * *

Үлми торган кем бар соң, диләр.
Ә мин әйтәм, бар дим, бар: Хозыр!
Абелхәят эчкән изгенең
Хикәясе — үзе бер җырдыр,
Аны тыңлавы да хозурдыр.

Үлми торган адәмнәр дә бар!
Кояштыр, бу сүземнең чыны.
Аһ, табалсам һәм эчсәм мин дә,
Абелхәят дигән шул суны!
Гел яшәтер шул тере суны!

Барыр идем җәһәннәмгәчә,
Җир астына илтсә дә бу юл.
Хозыр эчкәч, бар Абелхәят!
Кайда икән ләкин, кайда ул?
Кем күрсәтер, кайда аңа юл?

# Фәнәвис Дәүләтбаев

## Язмыш

Мөлдерәмә тулы сагыш белән
Яшьлек артта калды, югалды.
Ымсындырып, һаман элеккечә
Бәхет кошы оча югары.
Бәхет кошы кулга төшеп кунмас,
Аны гына аңлар чакларым.
Ярсый-ярсый зәңгәр биеклеккә
Томырыла хыял чаптарым.
Юлга чыккач кире борылу юк.
Яшен яшьни. Уйный зилзилә.
Утлы давыл эчендәдер, бәлки,
Миңа дигән бәхет, кем белә?

## Бии каен

Яфракларын талпындырып
Ярсу җил искән саен
Сылу кыздай онытылып,
Дәртләнеп бии каен.
Бии каен, гүя аны
Шатлыгы җилкендерә.
Әллә аның туе бүген?—
Менгән бәхет түренә?
Юк, куанып биидер ул
Туган җирем ямьлегә...
Җил тынар, әйләнер каен
Гашыйклар һәйкәленә.

## Таң алды

Вакыт килде. Болыт китте өстән —
Шик-шөбһәләр кинәт таралды.
Халык көткән, күпне вәгъдә иткән
Илнең бүген яңа таң алды.
Сизеп таңны, хәтта хушлашмый да,
Эреп юкка чыкты кара төн.
Күп алдады элек «синоптиклар»,
Ничек булыр икән яңа көн?
Ничек булыр икән бу яңа көн,
Көн буена кояш балкырмы?

---

Фәнәвис ДӘҮЛӘТБАЕВ — *Актаныш районының Татар Суксуы авылында яши. Шигырьләре Татарстан Язучылар берлеге оештырган махсус семинарда тикшерелде. Журналыбызда беренче мәртәбә басыла.*

Үзгәрерме халык яшәеше,
Гүзәллекләр җирдә артырмы?
Асылыннан җисем үзгәрмичә,
Исем белән уйнау булмасмы?
Яңарышта туган башлангычлар
Чәчәк сулган кебек сулмасмы?
Ә чынлыкта яңарыш ул — ташкын.
Боз кузгалган, инде тыйгысыз!
Их, җаннарны тизрәк биләп алсын
Ышаныч һәм өмет тойгысы!
Яңарыш ул — халык ихтыяры,
Халык нигезендә яралды.
Шатлыклыдыр йөрәк салган хәбәр:
Илнең бүген яңа таң алды!

## Рок-музыка

*(Шаяру катыш)*

Тәмле төшләр күреп, софасында
Йоклый әле шәһәр баласы.
...Авыл хәле башка: таңнан торып
Малкайларга азык табасы.

Монда безнең гади үзьяшәеш,
Рок-музыка бездән еракта.
Рокларыңны егып сала торган
Дуңгыз чыйнаулары — колакта.

## Чалгы тавышы

Йөрәгемә якын җыр шикелле —
Чалгы тавышларын ишетәм.
Безне егет иткән шул тавышка
Сандугачлар моңын иш итәм.

Туган якның үлән-чәчәкләре
Тезелепләр кала теземгә.
Чапкан саен тәндә уйнап торган
Көч барлыгын тоям үземдә.

Чалгы тотып болыннарга чыксаң
Хуш ислярдән башың әйләнер.—
Шушы минем — шау-шуларсыз гына
Күптән көткән күңел бәйрәме.

Фаяз Дунай

# ИМАННАР КАКШАГАН ДӘВЕР

*Аллам гадел,*
*Иманым камил булганда,*
*Дөньяда мин — Салсал батыр!*

Мәгълүм булганча, халыкларның әхлагы, рухи мәдәнияте һәрвакыт нинди дә булса бер тәгълимат белән, иман белән бәйләнгән була. Безнең ерак һәм якын тарихыбызда аеруча ике тәгълимат: дин-шәригать һәм марксизм-ленинизм тәгълиматының йогынтысы зур булды. Хәзер бик күбәүләр менә шул ике идеология, ике тәгълимат турында еш уйлана, бәхәсләшә, көрәшә... Иман өчен, дөньяга карашлар өчен дау бара хәзер җиһанда.

Кыйбланы яңартыр дәвер килде.

## I

Диннәр һәм фәлсәфи агымнар тарихы белән ныклап кызыксынган шәхесләр икеләнмичә раслыйлар: дини тәгълиматларның нигезендә озын-озак тарихи гомер, эволюция кичергән кешелек дөньясының хыял-фантазиясе, ният-теләкләре, иман-идеаллары ята. Бу халык иҗаты, бу иман-идеаллар гомерләр агышында, яңа буыннар җанында инде әкият-миф итеп кенә түгел, ә кайдадыр, кайчандыр булган хәл-әхвәлләр итеп, гыйбрәт-сабак сыман кабул кылына. Дини тәгълиматны тудыру максатында болар Тәуратка, Инҗилгә, Зәбургә, алар аша Коръәнгә язылып теркәлгән. Халыкны инандыру, аның күпсанлы сорауларына җавап бирә алырдай изге кодрәтле дәреслеккә һәм идеология кануннарына әверелгән. Хәер, бу хакыйкатьне Коръән үзе дә инкарь итми: «Кешеләргә житәкчелек итү өчен без Тәурат белән Инҗилне индердек,— ди ул,— соңра шушы Коръәнне. Алланың бу китапларына ышанмаучыларга җәза яман каты булачак» (Коръән, «Гыймран сүрәсе», 2-3 аятьләр).

Диннәр арасындагы аерымлыклар хакында бәян итүне дин белгечләренең үзләренә калдырыйк та, ул диннәргә хас уртак чишмәләрне генә телгә алып узыйк. Нәкъ менә шул уртаклыклар хакында еш кына уйланам-уйланам да мин, ихтыярсыз, янә «Лә илаһе иллаллаһе...» ягъни «Бер алладан гайре алла юк...» дигән әлеге гыйбарә исемә төшә. Күңелемнең катгый түгел, ләкин шактый ышанычлы сиземләве белән: «Шәт, чыннан да дөньядагы барлык халыклар өчен дә, аларның нинди дин тотуларына һәм кайсы телдә сөйләшүләренә карамастан, Алла бердән-бердер ул, бер Алладан гайре алла юктыр...» дигән нәтиҗәгә киләм. Әнә, Коръән үзе дә бит гаять гадел, демократик рәвештә «Сездә — Сезнең иман. Миндә — Минем иман» дип раслый һәм башка дин тотучыларны да хөрмәт итәргә, кимсетмәскә өнди. Ул асылда бары тик динсезләрне, Алласы булмаганнарны, гомумән, имансыз, кешелексез шәрә җаннарны гына «кяферләр» дип атый. Коръәннең үзендә үк язылган түбәндәге аять-сүрәләрне зиһен салып укыгыз әле: «Тәурат әһелләренә әйт,— ди Алла Мөхәммәткә.— Без Тәурат индердек, анда хаклык, анда нур.» («Мандә» сүрәсе, 48 аять). Тәурат кешеләренә (яһуд динендәгеләргә) әйт, ди Алла: Без үзебезгә иңгән Коръ-

әнгә һәм сезгә иңгән Тәуратка ышанабыз, диген. Сезнең Алла да, безнең Алла да бер, диген, без шул бер Аллага ышанабыз инде, диген.» («Ганкәбут» сүрәсе, 45 аять.)

Мөхәммәт пәйгамбәр сөйләгән хәдисләрдә исә бу уртаклык-бердәйлек тагын да ачыграк әйтелгән: «Барча пәйгамбәр бер ата балалары булып, аналары гына башка, ә халыкларга алып килгән диннәре бердер.» (277 хәдис.)

Әле безнең заманда да, гомеренде бер генә тапкыр булса да, Алла турында уйланмаган кешеләр сирәктер. Андыйлар очраса да рухи шыр ялангач, гарип «кяферләр» генәдер. Хәтта катгый дәһри кеше дә бу хакта уйланмый калмый ич!

Минем өчен Алла — Табигатьнең, Яшәешнең, Галәмнең әлегәчә һич кенә дә мин төшенеп җитә алмаган ниндидер куәте, кодрәте ул, яшерен-серле объектив законнары, үз диалектикасы ул. Минем өчен Алла — Миһербан һәм Шәфкать символы ул, тормышымның иң хәтәр, четерекле, гаять авыр чакларында миңа ярдәмгә ашыгучы ниндидер илаһи, зирәк җегәр иясе ул, кылган ялгышларымны аячы, гөнаһларымны ярлыкаучы, тән һәм җәрәхәтләремне савыктыручы мәрхәмәтле-миһербанлы изгеләр, әүлияләр җитәкчесе ул! Белмим, кайда тереклек итәдәр, кайда изге хөкемдарлык кыладыр: Галәм-күктәдерме, үзенең бер бәләкәй тереклек бакчасы Җирдәдерме, бәлки гади-гадәти тормыш-яшәешнең үзендә үктер, хәтта минем үз рухым-җанымда уктыр?!...

Бәй, зиһен салып баксаң, җаның-йөрәгең белән сизенсәң, Алла рухы, Алла символы, Алла образы, әнә, рус егетләре, балта остасы Павел Афанасьев, шагыйрь Николай Алешков, украин егете слесарь Михайло Редько, чуваш егете Алексей Язынин, кореялы врач Саю Ким һ. б. өчен дә нәкъ мин сыйфатлаган, нәкъ мин хыял иткән, фараз иткән төсмер, рәвешләрдә яши икән бит! Мөгаен, шуңа күрә дә: нәкъ минә Тәнре, Ходай, Алла төшенчәсе бердәй асыл, серле, илаһи миһербанлы сыйфатларны үзенә туплаганга һәм төрле дин тотуларына, кайсы телдә сөйләшүләренә карамастан, бихисап табигать балаларына уртак инану-иман, уртак илаһи кодрәткуәт, уртак рухи таяныч һәм уртак идеал булганы өчен, мин «Лә илаһе иллаллаһе...» ягъни «Бер алладан гайре Алла юк...» диган гыйбарәне изге дога итеп кабатлыймдыр. Мөгаен, шуңа күрә дә тормышымның иң хәвефле, үтә авыр чакларында мин бар калебем белән:

«Йә, ходаем, шәфкатеңнән ташлама!» яки «Йә, ходаем, үзең сакла!» яисә «Йә, Аллам, ниләр кылыйм?»,... дип, шул кодрәтле, серле Олы рухыма ялварамдыр. Йә, ходаем, гомер бакый шул инану, шул хисләрдән, шул миһербанлы өметтән, шундый рухи идеалдан, зинһар, мәхрүм итмә безне! Алласыз, имансыз булу — шәп-шәрә рухи ялангач булу, зәгыйфь-гарип булу, бәхетсез, өметсез булу бит ул! Мөгаен, шуңа күрә дә, «алласыз», «имансыз» яки «тәүфикъсыз» кебек усал сүзләрдән безнең җаннарыбыз тетрәнеп, тәннәребез чирканып, өшеп китә...

Диннәрнең мәгарифкә, мәдәнияткә, хәтта әхлак-әдәпкә дошман булуы турында бик күп китаплар, язмалар бар. Әлбәттә, аларның күбесе агымдагы сәясәткә яраклашкан язмалар булды. Нишләтәсең, һәр тәгълимат көрәш-дау белән туа һәм үзенең позицияләрен дә көрәшсез, тырышлыксыз саклап бара алмый. Мин үзем, бу дөньяда күбрәк яхшылыкны, матурлыкны, гаделлекне эзләүче шәхес булганлыктандыр шәт, диннәрнең нәкъ менә мәгърифәтне, әхлак-әдәпне камилләштерүдә әйтеп бетерә алмаслык илаһи йогынты ясауларын, нәкъ менә чишмә башы булуларын исбат итәргә тырышам. Беләсез ич, күбаллалылык дәверендә үк грекларда мәгърифәт, фән, әдәбият-сәнгать искиткеч үскән, әхлак-әдәп камилләшкән. Без әле дә Аристотель, Софокл, Гераклит, Платон, Гомер, Эсхил һ. б. акыл ияләрен, әдәбият-сәнгать даһиларын, аларның үлемсез хезмәтләрен олылап телгә алабыз, сокланып укыйбыз, өйрәнәбез. Олимпия-спорт уеннары да шул дәвердә үк туган, ә хәзер аның тантаналы, миһербанлы утлары, иллрдән илләргә күчеп, бөтен җир шарын ямьли, халыкларны татулыкка, гүзәллеккә өнди. Безнең болгар-татар халкының да Сабан туен Җирнең төрле төбәкләрендә әле дә онытмыйлар. Киресенчә, аның эчтәлеге заманыбызның яңа бизәкләре белән баий бара.

Диннәр, гомумән, халык иҗаты, халык идеалы, халык фантазиясе җирлегендә туган, формалашкан. Бер Алланы тану стадиясенә ирешкәч тә, ул диннәр мәдәнияттән, әхлак-шәригатьтән һич аерылгысыз. Беренчедән, төп дин китаплары үзләре үк — мәгърифәт, фәлсәфә һәм әдәбият җимешләре.

һәм шул чыганаклар үзләре үк, чишмә башы булып, әдәбиятны-сәнгатьне тагы да үстерәләр. Дини сюжетларга нигезләнгән һәм дини фикер, идеяләрне, дини-рухи фәлсәфәне халыкка ирештерүче әдәби әсәрләрне, сәнгать әсәрләрен, белмим, дөньяның кайсы гына библиографлары санап чыга алыр икән?!

Икенчедән, затлы-сәнгатьле ул дини биналар, ул мәһабәт собор-чиркәүләр, ул сөйкемле, нурлы мәчетләр, төрбәләр... Алар үз чорындагы фән-техниканың, камил технологиянең казанышларын белүче архитекторлар, рәссамнәр, инженерлар һәм таш, пыяла, мәгъдән, агач бизәү осталарының фидакарьлеге, эстетик зәвыклары, эстетик идеаллары белән корылганнар, лабаса! Әгәр без бөек рәссам-анатом Микельанджело исемен телгә алабыз икән, Ватикан соборларындагы искиткеч һәм кешеләргә гомер бакый эстетик ләззәт бирәчәк сын-символларны күз алдына китерәбез. Ә мәшһүр рус рәссамы Андрей Рублев исә православие чиркәүләрендәге серле-уйчан, боек кыяфәтле, жете чуар сурәт-рәсемнәрне ясаган... Дин белән мәгърифәт-мәдәниятнең, әдәбият-сәнгатьнең үзара бер-берсен тулыландырып, куәтләп, камилләштереп гомер бакый табигый бәйләнештә яшәвен һәр дәвердән бихисап дәлилләр китереп расларга мөмкин. Әгәр бер төркем надан руханилар яки холыксыз бәрәр хөкемдар Галилейны, Коперникны, Мирза Олуг бәкне яисә берәр шәрыкъ шагыйрен дошман күргән, җәзалаган икән; әгәр диннәр тарихында инквизаторлык, дини сугыш-газаватлар шаукымы булгалаган икән — бу гаделсез гамәлләрне диннең үзендәге капма-каршылыклар, төркем низаглары, караш-агымнар көрәше дип кенә аңларга кирәк. Асылда Миһербан, Шәфкать, Вөждан аклыгы, тән пакълыгы идеясы белән сугарылган диннәрне уптым илаһи мәгърифәт-мәдәниятнең, әдәбият-сәнгатьнең, әхлак-әдәпнең дошманы итеп расларга маташу — акылсызлык, наданлык, мокытлык ул!

Дөнья, Галәм дә бит әнә ничек яратылган! Ай, Кояш тотылган, бозлы давыл, зилзиләләр котырган, янартаулар бәреп чыккан... Җир тетрәгән, метеоритлар чәчрәп очкан чаклары да була тора аның... Ә яшәеш, мәңгелек илаһи хәрәкәт, тереклек һәм гаделлеккә, гүзәллеккә омтылыш дәвам итә...

...Мөхәммәт галәйһиссәлам искиткеч тырыш, түземле, эшлекле, зирәк акыллы шәхес булган. Яшьли ятим калып, әтисе белән бертуган Әбүталип агасы тәрбиясендә унике яшенә кадәр кәҗә-сарыклар көтеп үскән, аннары, шул ук агасына ияреп, илдән илгә күчеп, сәүдә итеп йөргән. Бу илаһи талантлы шәхес, укый-яза белмәгәне хәлдә, әкренләп һәр өч диннең тәгълиматына тирән төшенгән. Аның Мәккәдән ерак түгел Хират магарәсенә кереп уйлана, хыяллана торган гадәте булган.

Көннәрдән бер көнне Мөхәммәт күктән үз исемен ишеткән сыман була. Кемдер аңа күктән эндәшә, аңа киңәш бирә. Бу хәл әледән әле кабатлана. Ниһаять, ул Җәбраил фәрештәнең Алладан үзенә вәхи (хәбәр, боерык, әмер) алып килгәнлеген төшенеп ала. Җәбраил фәрештә аңа: «Син Алланың рәсүле...» (илчесе) дип игълан итә һәм «Укы» ди. Мөхәммәт «Укый белмим»,— дигәч, Җәбраил фәрештә аның иңенә кагылып, янә «Укы!» дип вәхи кычкыра. Мөхәммәт өенә кайтып йоклагач та, Җәбраил фәрештә аның төшенә кереп, «Укы!» дигән әмер бирә...

Сизенәсездер, Мөхәммәдерәсулланың шәхси тормыш юлын тасвирлаганда ук менә шул «Укы!» дигән мәгърифәтле риваятьтән үз тәгълиматын башлаган ислам дине ничек итеп шул ук мәгърифәт-мәдәниятнең дошманы булсын ди инде?! Әйткәнебезчә, Мөхәммәт-азамат сәргаскәр һәм зирәк дипломатик акыллы юлбашчы гына түгел, бик тә хыялга, фантазиягә бай, садә тәэсирләнүчән философ һәм «җенле шагыйрь» дә ич әле! Һәм ул ижат иткән Коръәннең (барча каршылыкларына, төрле беркатлы мифларына карамастан) кешелек дөньясындагы бәясе, йогынтысы әйтеп бетергесез! Бу мәшһүр китап — дин-шәригать китабы гына түгел. Гарәп халкының ул чордагы тормышын-көнкүрешен, уй-фикерләрен, өмет-хыялларын, бик тә чуар тарихын чагылдырган зур энциклопедик әсәр ул.

Коръән — «законнар һәм карарлар җыентыгы итеп иңдерелгән» («Рәгыд» сүрәсе, 17 аять) язмалар гына да түгел. Мөхәммәт галәйһиссәлам — күпкырлы талант, табигать күренешләре, галәм киңлекләре турында да бик илһамланып һәм матур сөйли, аның әсәрендә ул дәвердәге медицина, анатомия, физиология, биология өлкәсеннән бик күп мәгълүматлар бар. Әлбәттә, Мөхәммәт пәйгамбәр бу мәгълүматларны гыйлем тарату, кешеләрнең сәламәтлеген саклау һәм аларны санитария-гигиена кагыйдәләренә өйрәтү максаты белән үз китабына туплаган. «Коръән — мөселманнар өчен табиплык гыйлеме».— ди ул «Фоссыйләт» сүрәсенең 44 аятендә.

Тагын шунысы бәхәссез: әдәбият-сәнгать әсәре буларак Коръәндә һәркемне сокландырырлык кыска-оста сүрәләр, шигъри-фәлсәфи аятьләр аз түгел. Коръән шигърияте дә, проза һәм драматургиянең дә асыл сыйфатларын үзенә сеңдереп, хис белән фикерне аеруча моңлы-давыллы, динамик үсештә чагылдыручы нәсер стиле белән язылган. «Җир тетрәр, телгә килеп, үзенең хәлен сөйләп бирер. Җир тетрәр, таулар җимерелеп, туфракка әйләнер. Болытлар белән бергә күк ярылыр...

Кояш боргычланыр. Ай тоныкланыр... Күк эрегән бакыр кебек булыр... Кешеләр ояларыннан куып чыгарылган күбәләкләр хәлендә булырлар. Әчми исерек булырлар. Сабыйларның чәчләре агарыр...

Ул көнне Алла без яшәгән җирне алып ташлап, бүтән Җир китереп куяр. Күкләрнең җидесе дә кодрәт иясе каршына килеп тезләнер.» («Ибраһим» сүрәсеннән.)

Коръәннең матур әдәбиятка булган йогынтысы хакында сөйләп бетермәле түгел. Менә, дин китапларының бик күбесендә урын алган, дөньяви чын да сыман, ләкин гаҗәп нәфис романтик һәм сәнгатьле символик булган бер өзек парчаны гына укыгыз әле:

«Коточкыч караңгы, искиткеч тын төн иде. Бөтен табигать хәрәкәтсез калган, гүя бөтен нәрсә үлеп беткән. Әтәчләр, этләр тынган, җил тынган, арыклар, сулар, агудан туктап, тынып калганнар. Мөхәммәт үзенең бикәче Хәдичә белән бер гамьсез йоклап ята...

Төн уртасы җиткәндә, Мөхәммәт кемнеңдер үзенә эндәшкәнен ишетеп уяна.

— Йокыңнан тор, әй Мөхәммәт!—ди аңа кемдер.

Мөхәммәт күзен ачып җибәрсә—Җабраил фәрештә! Канаты, һәрвакыттагыча, җитмеш, өстендә энҗеләр, алтыннар белән чигелгән озынча күлмәк. Җабраил ялгыз түгел, янында Әлбрук исемле оча торган ат, җәннәт аты. Канатлары—бөркет канаты. Коерыгы—мисле коерыклы йолдыз, күзләре—таң йолдызы...

— Атлан үзенә, әй Мөхәммәт,—ди Җабраил һәм атның тезгенен пәйгамбәргә тоттыра.

Мөхәммәт шундук Әлбрукка атланып күккә аша...

Бу өзек (Мөселманнар рәҗәп аенда бәйрәм итә торган Мигъраҗ (күккә ашу) кичәсе турындагы риваятьтән.

II

Марксизм тәгълиматы диннәргә караганда унөч гасыр соңрак дөньяга чыкты. Бу тәгълимат та, үз язмышыннан уза алмыйча, көрәш һәм дау, бәхәс-низаглар, бихисап кан коюлар, катгый-рәсми декретлар, законнар һәм дипломатик чаралар белән үзенә юл ярды.

Бу тәгълиматның да төп игътибарында Кеше шәхесе, социаль Гаделлек урнаштыру максаты тора иде. Хезмәт ияләрен капитал коллыгыннан, ягъни эксплуатациядән азат итүне үзенең төп программасына һәм стратегик-тактик максатларына нигезләп, марксизм-ленинизм да башта гуманистик, гадел лозунглар күтәрде һәм халык массаларын шул дөньяви лозунглар астына өндәде. Хезмәт ияләренең үзләрен завод-фабрикалар хуҗасы итү, җирне крестьяннарга бирү, гадел булмаган сугышларны бетерү, дәүләт белән идарә кылу эшенә халык вәкилләрен күтәрү, кешенең хезмәтенә карап гадел эш хакы түләү, милләтләрне тигез хокуклы итү, мәгърифәтне-мәдәниятне үстерү һ. б. бик тә зарур лозунглар белән бу тәгълимат та халык массаларының теләктәшлеген, кыю яклавын тапты. Тагын шунысы үзенчәлекле: бу тәгълимат «киләчәктә руслар бөтен дөнья халыкларының рухи үсешен җитәкләячәкләр» дигән тәкәббер, дәгъвалы идеягә инанган, шуна да патша хөкүмәте, башка халыкларны кысып, шовинистик руслаштыру сәясәтен—«Империя! Бөек держава!» идеясен—һәрдаим тәкърарлаган һәм шул юнәлештә рәсми чаралар күреп торган чуар, каршылыклы Россиядә үзенә зур плацдарм булдыра алды. Әйткәнебезчә, оҗмахны ахирәттә түгел, ә дөньялыкта дип вәгъдә иткән бу тәгълимат һәр ситуациядә үзенең тактик алымнарын үзгәртә барып, иң әүвәл «халыклар төрмәсе» булган Россиядә кыска дәвердә революцияләр, кискен ватып җимерү һәм үзгәртеп корулар ясый алды. Аның героик, романтик «уңышлары», удар бишьеллыклары булды, коммунистлар партиясенә юлбашчылык һәм хөкемдарлык вазыйфаларын биреп, ул әлеге партия ихтыяҗынча илнең сәяси дәүләт төзелешен, идарә аппаратын үзенчә корды, социаль-иҗтимагый һәм милләтара мөнәсәбәтләрне билгеләде, мәгълүм дәрәҗәдә үз культурасын, әдәбиятынсәнгатен үстерде, тантаналы бәйрәмнәре, үз йолалары туды...

Лəкин, әнә, безнең совет матбугаты да хәзер шул революцион тәгълиматның лозунгларына яраклаштырылган социализмның дәһшәт-трагедиләрен, тормышның күп тармагында Кеше шәхесен санга сукмыйча, галәмәт күп явызлыклар, хаталар кылуы турында бәян итә.

Асыл табигатендә кешелекле, гуманистик идеаллары булган бу тәгълиматтан реаль чынбарлыкта, тормыш агышында бик күпләр, аеруча соңгы буыннар йөз чөерделәр. Хәзер инде бездә бер тәгълиматка да инанмаган, салкын робот акыллы кешеләр адым саен диярлек. Андыйлардан культура, миһербанлы әхлак-әдәп таләп итүе сәер эштер.

Лəкин төп сәбәпләр нәрсәдә соң? Шул хакта уйланып алыйк.

Төрле үсеш дәрәҗәсендәге халыкларны берүк сыйнфый карашларга, хәтта «бөтендөнья революциясе» лозунгларына инандырырга тырышкан һәм шул юнәлештә аларны көрәшкә-дауга әйдәүче, оештыручы куәтле идеология булган яңа тәгълимат, иң әүвәл, үзе дошман күргән икенче куәтле идеологиягә — дини тәгълиматка каршы «аяусыз фронт ачты». К. Маркснын «Дин ул — халыклар өчен әфьюн» яки В. И. Ленинның «Дин — җәмгыять өчен хурлык, дин — җәмгыятьнең палачы» дигән һәм шуңа охшашлы башка гыйбарә-фикерләре, большевиклар властьне үз кулларына алу белән үк, физик көрәш, физик тар-мар итү чарасына, дәүләт аппараты коралына әверелделәр. Диннең теге яки бу өйрәтүләрен, әйтик, дөньяның барлыкка килүе, Җирнең, Күкнең ясалышы... кебек риваять-әкиятләрен, шәригатьнең кайбер ямьсез йолаларын акыл һәм сабырлык белән, фән-техниканың соңгы казанышларына таянып инкарь итү яки уртак нәсихәт, гыйльмият эзләү, табарга тырышу булмады. Дингә каршы террор, авантюра, кимсетү, мәсхәрә итү һ. б. Шундый кешелексез дәһри ысуллар белән көрәш башланып китте. Һәрбер дингә каршы «аяусыз көрәш». Алласыз булу большевиклар партиясенең программа-уставларына катгый беркетелде һәм диннәрне юк итү илкүләм максат итеп куелды.

Сүз җаенда, гыйбрәт өчен, тарихи бер дәлилне искә төшереп узу кулай булыр, мөгаен.

Беләсездер, Чыңгыз ханның үзе җиңеп алган җирләрдә урнаштырган тәртип-законнарны туплаган «Олуг Яса» китабы һәм «Белекләр»е бар. Үзе бер динне дә тотмаган, укый-яза да белмәгән, ләкин галәмәт акыллы һәм таләпчән булган Чыңгыз хан чиксез олы дәүләтенең төзелешен, гаскәри тәртибен генә түгел, идеологиясен, әхлак-әдәп канунннарын да булдырып, урнаштырып, башка буыннарга да васыять итеп калдырган икән. Без «кыргый, вәхши» дип йөрткән Чыңгызның «Яса»сы буенча, һәр яулап алынган җирдә дин әһелләре хөрмәт ителергә тиеш булган, беркемнең дә динен кимсетергә, чикләргә, эзәрлекләргә ярамаган. Бер-бер кешенең динен кимсеткән өчен үлем җәзасы бирелә торган булган. Бер генә дин әһеленнән дә, бер генә гыйбадәтханәдән дә гошер — дини салым алынмаган. Бу канун, бу васыять буыннардан-буыннарга җиткерелгән һәм катгый үтәлгән. Менә шуңа күрә дә монгол-татар яулары беркайчан да гыйбадәт урыннарын ватмаганнар, руханиларга кагылмаганнар. Чыңгыз хан урнаштырган шул катгый, ләкин кешелекле тәртип һәм башка диннәргә дә ирек хокуклары биргән ислам тәгълиматы, белгәнебезчә, безнең Болгар иленә, Алтын Урда дәүләтенә һәм Казан ханлыгына да килеп кергән. Бу ил-дәүләтләрдә мәчетләр белән бергә үк, берүк калада яки салада чиркәүләр дә төзелгән, аларның руханилары хәвефсез, иман яшәгәннәр. Буыннардан буыннарга шундый иман инандыруны шул Чыңгыз ханның «Яса»сы, «Белекләр»е биргән һәм моны ислам дине гарантияләгән хөррият, вөҗдан ирекe дип аңларга, гадел бәяләргә кирәк.

Ә без исә,— үзебезне егерменче гасырның цивилизацияле уллары-кызлары санаучылар,— Чыңгыз хан дәвереннән сигез гасыр үткәннән соң да, дингә — Аллага каршы, пәйгамбәрләр-фәрештәләр рухына каршы «аяусыз көрәш» ачып, дистә-дистә еллар буе явыз-сөмсез погромнар ясый тордык. Бихисап дин әһелләрен, руханиларны, мәдәният эшлеклеләрен аттык, зинданнарга яптык, хур итеп сөргеннәргә сөрдек. Үз халкын, милләтен генә түгел, хәтта кан кардәшләрен дә «сыйнфый дошман»га, «халык дошманы»на санаучы, дененнән-өммәтеннән язган һәртөрле адәм актыклары, надан, мокыт, кансыз, әхлаксыз-әдәпсез мөртәтләр, халык әйткәнчә, «агач коммунистлар» һәм «кызыл авызлар» мәчет манараларын кистеләр, затлы-затлы гыйбадәт йортларын вәйран иттеләр, чиркәү-монастырьларны шартлаттылар, халык изге санаган садә урыннарны пычраттылар. Ә бит асылда, иң кешелекле сыйфатларга өндәүче һәм үгетләүче бу затлы, сәнгатьле биналар халыкның рухын, зәвыгын, идеалларын гәүдәләндерәләр иде. Күп

очракта алар халыкның хәләл үз акчасына, милләтнең химая кылуы белән, маһир осталарның фидакарь хезмәте белән корылган иде.

Мәдәни дигән даирәләрдә исә, гомумән, динне логикасыз, реаль дәлилләрсез «фаш итү», этәчләнеп сүгү бик күпләрнең көн итү — тамак туйдыру әмәленә әверелде. Диннәрне, шәригатьне сүгеп бихисап китаплар язылды, кандидатлык, докторлык диссертацияләре яклангы... Кыскасы, үзләренең бер төркем диктатор-юлбашчыларына карусыз буйсынырга мәҗбүр булган большевиклар яки коммунист билетын элэктергән һәртөрле мөртәтләр илебездәге бөтен шәхесне, үз дине, үз милли бизәкләре һәм әдәп-әхлагы булган барча халыкны бер рәсми һәм шәфкатьсез идеологиягә күндерергә, гайре табигый лозунглар астына куып кертергә тырыштылар. Ә бит буыннар чылбырын тоташтырып килүче дин (католик, христиан динеме ул, мөселман яки будда динеме ул, яһудләр динеме) илне-көнне, дәүләтләрне нығытучы өскорма һәм сыналган идеология генә түгел, ә халыкларга чын-чыннан мәгърифәт-мәдәният нуры, әхлак-әдәп тәрбиясе бирүче юмарт изге чишмә, илаһи учак булды, шифалы җил булды. Кыскасы, дин-шәригать — халыкларның, милләтләрнең рухи таянычы, рухи куәте иде. Яңа тәгълимат диннең менә шушы асыл сыйфатын, Кеше шәхесенә рухи юаныч, өмет, кодрәт бирүчән шул рәвешен санга сукмыйча, аны бары тик җимерү, юк итү максаты белән эш итте. Һәм шуның белән кешеләр җанында үзенең абруен җуйды, дәрәҗәсен төшерде. Шул кыска гомерле, сезонлы идеологиягә, күп очракта ялган, кызыл мәдәнияткә, партиялесыйнфый моральгә халыкларның акылын һәм җанын баглатырга тырышкан административ-команда системасы үзе ныклы имансыз, әдәпсез-әхлаксыз, таш бәгырьле, «корыч һәм керпе куллы» булды. Ул йөз меңнәрнең, дистәдистә миллионнарның язмышларын чәлпәрәмә ватып, канга-зарга батырып, нужа өстенә нужа, михнәт өстенә хәсрәт китереп яшәде...

### III

Дингә каршы көрәштә җәмгыятьне физик һәм рухи зәгыйфьләндерүдән тыш башка уңышка ирешә алмаган яңа тәгълимат үзенең төп гыйльми-теоретик чыганакларын, состав өлешләрен ничегрәк тормышка ашырды? Аларның игелеген халык күрә алдымы соң?

Хыялый француз социализмының гадел, миһербанлы идеяләрен марксистлар иң элек, әлбәттә, дәүләт төзелешен үзгәртү, башта пролетариат диктатурасы урнаштыру юлы белән тормышка ашырырга ниятләделәр. Ләкин аларча бу диктатура вакытлы гына, тора-бара илдә бөтенхалык власте булачак, янәсе. Бөек рус гыйсьянчысы М. А. Бакунин исә К. Маркснын бу теоретик өйрәтүләренә кыю каршы чыкты һәм мондый диктатураның гамәлгә ашмаячагын, көчләп урнаштырылган тәкъдирдә халыкларны кол итәчәген, аеруча крестьяннарны изәчәген, житештерү средстволарына хуҗа булып алган дәүләтнең бары тик «дәүләт социализмы яки авторитар коммунизм» рәвешенә әвереләчәген, илдәге бөтен идарә рычагларының «дәүләт машинисты — диктатор, император» кулына, ә аппаратның «кызыл бюрократия», «коммунистик партия начальниклары» хакимиятенә күчәчәген алдан кисәтте. Һәм аның шундый зирәклегенә, алдан күрүчәнлегенә гаҗәпләнми мөмкин түгел.

Революциядән соң илнең житәкче органнарына пролетариатның кайбер вәкилләре сайлана һәм күтәрелә алсалар да, алар халык язмышын җиңеләйтердәй хәлиткеч көчкә әверелмәделәр, үзләре үк партия-дәүләт чиновниклары булып утырдылар. Галим-социолог Бакунинның сүзләре рас килде. Социализм идеаллары, Октябрь революциясеннән соң, халыкның өмет-ышанычын алдап, рухын-җанын җәрәхәтләп, «хәрби коммунизм», «бараклар социализмы», «казарма социализмы», «лагерьлар социализмы», «ГУЛАГ социализмы», «паспортсыз ярымкол крестьяннар социализмы», һ. б. шундый ирексез, малсыз-мөлкәтсез халыклар «социализмы», «коммунистик элита диктатурасы» сыйфатларында гамәлгә ашырылды. Социализм төшенчәсе бихисап гаделсезлекнең, кансызлыкның, законсызлыкның кызыл максатына әверелде.

К. Маркс үзе үк әйткәнчә, «тарихи трагедиянең иң югары акты — революция»дән соң, (ә мондый революция ясауны Г. Плеханов, К. Каутский, А. Бебель, М. Горький һ. б. акыл ияләре җинаятькә санадылар.— Ф. Д.) бер төркем большевизм лидерлары «сыйнфый дошманнарны», санап бетергесез «чит элементларны», бихисап «контрларны», «империализм ялчыларын» юк итүне көндәлек иң мөһим максатка санап, илне-көнне мәхшәргә әйләндерделәр. Бик күп язмышлар вәйран булды, җан-рухлар хур ителде.

Ул да түгел. бу большевик «юлбашчылар»ның үз сафларында «Ленинның варисы» булыр өчен, ягъни власть өчен мәкерле сугышлар башланды. «революциянең үз балаларын ашар» дәвере житте. Үзе бихисап явызлык кылып, шул иблислеген көндәшләренә, дошманнарына сылтап, шул мәкерле, үтә хәйләкәр ысул белән халыкны алдарга, үзенә ышаныч, илаһи хөрмәт, дан-шөһрәт яуларга гадәтләнгән Сталин «һәр бишьеллыклар саен социализмны корычтай ныгыта барды», «социализм идеяләрен күп илләрнең маягына әверелдерде», «куәтле социалистик лагерь-тынычлык һәм бәхет гаранты барлыкка килде».

Аннары Н. Хрущевның үз «ижади социализмы» шаулый башлады. сиксәненче елларга коммунизм вәгъдә ителде. Ә Л. Брежнев хакимлек иткән чорда бу «ожмахизм» «тулысынча һәм тәмам жинде»...

Әйткәнебезчә, Кеше шәхесен, кеше Рухын олылаучы дини тәгълиматка, рухи-дини фәлсәфәгә каршы куелган һәм һәр генсекның ихтыярына, субъективизмына яраклаштырылган бу «ялганизм»ның метаморфозаларын санап бетерерлек түгел. Шуңа күрә дә «социалистик лагерь» чатный, шартлый бара, фәлән илләр «социализм», «социалистик» сүзләрен дәүләт һәм партияләр исеменнән үк алып ташладылар. СССР күләмендә дә бу сүзгыйбарәләр банкротлыкка чыкты. КПСС дигән партия-мафия таркалды.

Россия марксистлары Октябрь революциясенең беренче атналарында ук завод-фабрикаларны, рудникларны, гомумән эре предприятиеләрне шәхси хужалардан тартып алдылар. Ләкин бу милек, К. Маркс ният иткәнчә, социализация рәвешендә халыкка түгел, национализация ысулы белән бөтенләй дәүләт аппаратына бирелде. Бу милек һәртөрле комиссариатларга бүленеп, катгый үзәкләштерелде. Тиз арада дәүләт капитализмы, административ-команда системасы туды. Илдәге милекнең, хужалыкның барлык тармакларына сыйнфый караштан башканы бик чамалы белүче «кызыл директорлар» куелды. Ләкин алар үзәктәге комиссариат рөхсәтеннән узып, «бәдрәф тә кора алмыйлар иде». Нәтижәдә, эш кешесе, хезмәт коллективлары тудырган өстәмә табыш, өстәмә байлык та үзәк тарафыннан сыпырып алына башлады. Эксплуатациянең тагын да кырысрак яңа формасы туды. Илдә эшчеләрнең, матросларның яңа чуалышлары, крестьян фетнәләре купты. Шул экономик-сәяси һәм социаль-иҗтимагый каршылыклар аркасында хәрби коммунизм тәртипләреннән баш тартырга мәжбүр булган В. И. Ленин яңа лозунг күтәрде. Аның планнары буенча, «социализмның иң югары принциплары — цивилизацияле кооператорлар» булырга һәм алар житештерү культурасын, хезмәт житештерүчәнлеген күтәрергә тиешләр иде.

Чынлап та, егерменче елларның ахырына кадәр бу экономик-сәяси платформа илебез тормышына сизелерлек уңышлар да китергән. Гражданнар сугышы жәрәхәтләре төзәтелгән, продукция житештерү арткан, мөстәкыйль ижади көчләр куәтләнеп алган, мәгърифәт-мәдәният, әдәбият-сәнгать бик жанланган. Ләкин Ленин үлеп дүрт-биш ел узуга илнең экономикасы агымдагы политикага, партия-дәүләт башлыкларының ниятләренә, катгый боерыкларына буйсындырылган. Бу тенденция аеруча милли-территориаль төбәкләрдә ныклы күзәтү астында тотыла. Һәм хәзер дә шулай. Бу төбәкләр иркенрәк көн итәрдәй кайбер миһербанлы законнар чыккаласа да, «үзәкләштерелгән талау» диктатыннан һич котыла алганыбыз юк. Милли хисләр кимсетелә, милли мәгърифәт-мәдәниятнең үсеше токтарлана. Халык әнә шуңа күрә дә мөстәкыйльлек, милли тигез хокук даулап шаулый...

Хезмәт иялре жан тире түгеп житкергән өстәмә табыш партия-дәүләт аппаратының галәмәт күпсанлы хәдимнәрен асраурга, күпсанлы кораллы көчләрне, милицияне, ВЧК, ОГПУ, НКВД, КГБ, суд, прокуратура, һәртөрле контроль комиссияләрен көчәйтүгә, бай мөлкәтле партия-дәүләт дачалары, махсус профилакторий-больницалар, ау йортлары салуга, «тынычлыкны һәм социализмны» яклаган булып кыланучы чит илдәге «тугры дусларга» бик юмарт тотылды. «Партия-дәүләт ожмахында яшәүче» күпсанлы «житәкче элита» һаман үрчи торды. Әгәр булдыра алсагыз, уртача бер шәһәрнең житәкчеләренә тотылган чыгымнарны гына белегез әле сез — торып-торып исегез китәр...

Менә шуңа күрә дә хезмәт кешесе үз хезмәте нәтижәләреннән суына бизә барды, продукциянең сыйфатын, хезмәт житештерүчәнлеген күтәрергә, техниканы, технологияне камилләштерүгә битарафлык һаман артты. «Заводлар, фабрикалар — халык милке, димәк, синең дә мөлкәтең» дигән абстракт һәм буш сүзләрдән хезмәт кешесе әрнү белән көлде генә.

Кеше жаны — буш вакуум түгел. Ул туктаусыз хәрәкәттә, эзләнүдә. Намуслы хезмәтеннән игелек күрә алмаган эш кешесе теләр-теләмәс «сул

шөгыльләргә», «чәлдерергә», үзе эшләгән предприятие-хуҗалыктан ни дә булса «кыстырып» чыгарга, тора-бара «умырып урларга» гадәтләнеп өлгерде.

Кеше һәм җир. Кеше рухы һәм табигать. Илаһи бер гармония бу! Үзе үк табигать баласы булган Кеше гомер бакый тереклек чыганагын да, рухҗан чишмәләрен дә, олы фикер-хисләренә кодрәтне дә шул ук җирдән, табигатьтән табып яши. Бу гармонияне бозу илне-көнне ярлы итә, кешеләрне хиссез итә, хыял-фантазияне чикли. Кыскасы, Кеше Рухына әйтеп бетерә алмаслык зыян, зәгыйфьлек китерә...

Октябрь революциясеннән соң, асылда сабыр, салмак табигатьле крестьяннар тикмәгә генә фетнә арты фетнә күтәрмәгәннәр. В. И. Ленин тәкъдим итәргә мәҗбүр булган «Җир кодексы»да авылларда, чынбарлык тормышта кеше җанына игелек, шатлык китерә алмады. Крестьянга вәгъдә ителгән җир-сулар, урман, көтүлекләр һәм, әлбәттә, алардан кергән табыш та, «кагылгысыз дәүләт милке»нә әверелде. «Сыйныф буларак кулакларны бетерәбез! Авылларда социалистик күмәк хуҗалыклар төзибез!» дигән шаулы лозунглар (чынлыкта репрессияләр белән) астында сөйләп-санап бетергесез корбаннар, фаҗигалар кылынды. Партия-дәүләт вәгъдә иткәнчә, авыл белән шәһәр арасындагы аерымлыклар, каршылыклар һич бетерелмәде, киресенчә, «индустрияне үстерәбез!» дип авыл кешесен карусыз диванага санап, авылларны талау исәбенә көчәя генә барды ул. Бөек Җир баласы ярымколга әверелде, үз бишеге — табигатьтән, җирдән, халкының моңыннан-аһәңеннән, дин-шәригатеннән, ата-бабаларының нигезеннән, аларның ихлас васыятьләреннән баш тартырга яки бизәргә мәҗбүр булды. Илгәкөнгә янә мәхшәр килде, кытлык килде. Авыл кешесе җай чыгу белән туган туфрагыннан качып, әкренләп манкортлашты: зәгыйфь җан, кыерсытылган, кимсетелгән рух буларак формалашты. Бу процесс һаман дәвам итә. Тәгәрәп еларлык рухи фаҗига, социаль дегенерация...

Бездәге «социализм» шартларында өстәмә табышның, милли керемнең гаять зур өлешен йотып торган коралды көчләр турында фәһемлерәк язасы килә.

Большевикларның илгә иминлек вәгъдә итүләре, белгәнебезчә, халыкка юаныч җим ташлау гына, ә чынбарлыкта ул нигезсез ният кенә булып чыкты. Кан коюлар белән башланган революция террорларга, гражданнар сугышына, һәртөрле фетнәләрне, крестьян чуалышларын, милли-азатлык хәрәкәтләрен, табигый һәм ясалма уйлап чыгарылган күпсанлы заговорларны шәфкатьсез бастыру сугышларына әверелде. Бәлки мондый хәлләр кешелек дөньясының бер формациядән икенчесенә күчкәндә була торган табигый, логик ихтыяҗыдыр, канунлыдыр, ә?..

Бу илдә тыныч еллар сирәк булды. Хәтта аз-маз имин елларда да СССРга (элеккеге Россия империясенә) укмаштырылган халыклар, милләтләр һәрдаим «тышкы һәм эчке дошманнардан интервенция, агрессия, провокация, искәртмәс һөҗүмнәр» көтеп, һәрдаим уяу һәм сак, көчле кораллаланган хәлдә яшәделәр, «наш бронепоезд в запасном пути» дигән кисәтү җырын еш кабатларга мәҗбүр булдылар.

Марксистлар үзләре үк дөньяны болгатып, халыкара мөнәсәбәтләрне кискенләштереп, «Европада шәүлә йөри — коммунизм шәүләсе» дип, Коминтернны оештырып, үзләре үк дөньяның барлык мөлкәтле, зыялы кешеләренә янап, гөрзи кизәнеп, шик-шөбһә салып яшәделәр түгелме соң?

Менә шундый сәер һәм киеренке атмосфера тудырганга күрә дә, чит илләрдә безгә дошманлык артты, ә үзебезгә коралды көчләрне туктаусыз ишәйтергә туры килде. Өстәмә табышның, милли табышның зур өлеше армиягә тотылды. Ә «социализм төзибез!» дип, илһамланып-исәрләнеп тир түккән хезмәт ияләренә, җан асрарлык паектан һәм ударникларга талон белән бирелгән күнитек, кызыл косынка, аз-маз ситса, ара-тирә костюмлык тукымадан кала, бүтән товар тәтемәде. Егерменче еллардан башлап утыз дүртенче елларга кадәр СССР да ачлыктан үлгән кешеләрнең исәбен алу, мөгаен, хәзерге компьютер дәверендә дә кыендыр. Галәмәт зур аграр держава, табигый байлыкларын да санап бетергесез гигант илдә бит әле бу ачлык!

Юк-бар сылтау табып, (дөреслектә көндәшлек белән һәм бер төркем сталинистның диктатын халык аңына сеңдерү, аларның шөһрәтен күтәрү өчен) хәрби белгечләрне даими үтереп тору, алар урынына яңаларын хәзерләү, НКВД потенциалын даими көчәйтү — барысы да хезмәт кешесенең ризыгын кисеп, җанын шомландырып торды. Молдавиянең, Украинаның, Белоруссиянең чикләрен киңәйтү, Балтик буе республикаларын «советлар

канаты астына алу өчен». Финляндиягә булган дәгъваларны хәл итү өчен, чынлыкта яңа стратегик басып алулар өчен барган «бәләкәй сугышлар» да безгә өстәмә экономик чыгымнар һәм мораль-политик зыян гына китерделәр. Хәтта Бөек Ватан сугышы кебек тарихта тиңе булмаган афәт, трагедиядән, бихисап җанлы һәм матди-экономик югалтулардан соң да без хезмәт кешесенең шәхси мәнфәгатен хөрмәт итәргә, аның тормыш шартларын рәтләргә бигүк ашыкмадык. Киресенчә, яңа сылтаулар табып, миллионнарны бушлай эшләтә торган ГУЛАГ лагерьларына бикләдек. Иректәгеләргә җан асрарлык кайбер чаралар күрелде дә, сугыш җимерекләрен тиз арада төзәтә алган шул ук фидакарь хезмәт кешесе тир түгеп таякан табыш янә сыпырып алына барды. Янә узышып, ашкынып коралланырга керештек. «Салкын сугыш» дәвере башланды. Галәмәт дәү үз дәүләтебезнең һәр төбәгендә генә түгел, «Социалистик лагерьны киңәйтәбез, ныгытабыз, аны тынычлык таянычы итәбез!» дигән дәгъвалы стратегия һәм тактика, субъектив сәясәт, идеология, дипломатия белән шапырынып-алданып, Россия империясе чорыннан ук калган колонизаторлык чиреннән котыла алмыйча, Польшада, Венгриядә, Чехословакиядә, Көнчыгыш Германиядә, Монголиядә һ. б. илләрдә дистә-дистә хәрби берләшмәләр тоттык. Хәтта марксизм-ленинизм тәгълиматына, социализм кыйбласына таба аз гына да йөз бормаган Әфганстанга гаскәр кертеп, меңнәрнең гомерен кистек, меңнәрне рухи һәм физик гарипләр итеп калдырдык, миллиард сумнарны исраф иттек. Кешелек алдында зур гаделсезлек, әхлаксызлык, әдәпсезлек тә булды ул Әфган сугышы...

Без революциягә тиңләгән хәзерге үзгәртеп кору дәверендә дә, тапканыбызның зур өлеше дәүләт-идарә аппаратын асрауга тотыла. Дөрес, кайбер ведомство, министрлыклар кыскартылды, берләштерелде анысы. Ләкин бит урта эшелоннарда башка исемнәрдә яңа идарәләр, идарәчеләр, яңгырдан соң баш калкыткан гөмбәләр сыман, үрчеп кенә торалар! Илдәге ризыкның, кием-салымның, мебельнең — кыскасы, товарларның иң затлысын, «дефицитлысын» форсат һәм «блат белән» умырып алып баручы привилегияле дәүләт-идарә аппараты хадимнәре бездә күптән түгел генә рәсми рәвештә 17,7 млн. кеше исәпләнә иде. Әле дә шуннан ким түгелдер. Артык булмаса...

Шөкер, илдәге соңгы үзгәрешләр җәмгыятьнең иҗади кодрәтен җанландырып җибәрде, инициативага, шәфкатьле теләк-омтылышларга җайлы шартлар туды. Хәзер бездә һәртөрле җәмәгать оешмалары: аеклар җәмгыяте, китап сөючеләр, сугыш һәм хезмәт ветераннары, инвалидлар, әфганчы-интернационалистлар, Культура фонды, Балалар фонды, Миһербанлык фонды һ. б. санап бетергесез. Тик, хәерсез, һич уйламаган бу ягы да бар икән: ул җәмгыять, оешма, фондларның үз идарә аппаратлары, бер дә җәмәгать тәртибендә генә эшләми, күләмле генә акча алалар. Аларга да ходайның һәр бирмеш көнендә ипи-тоз, сөт-каймак, кием-салым... Һәм бар ягы җитешле тормыш-көнкүреш кирәк...

Димәк, теләсәк-теләмәсәк тә шундый катгый нәтиҗәгә киләбез: марксистик-коммунистик тәгълиматның экономик сәясәте дә реаль чынбарлыкта, бездәге социализм моделе шартларында кешеләр шәхесенә файда, куаныч, прогресс китермәде. Ул иҗади мохит-даирә тудыра алмады. Киресенчә, аларны дәүләт капитализмының сәяси ирексез, хосусый милексез ялчыларына, көнлекчеләренә әверелдерде, хезмәткә гайрәтләрен чигерә барды. Кешене КЕШЕ иткән хезмәт культурасы, хезмәт этикасы, иҗади әхлак югала барды. Шуларга бәйле рәвештә Рух, җан бозылды, саекты, имгәтелде. Шул яман чир яңа буыннарга күчте.

Хәзер, әнә күп санлы сәяси реформаторлар, экономистлар, хуҗалык белгечләре... социализмны кризистан чыгаруның төрле чараларын эзләргә ябырылдылар. Мондый эзләнүләр чыннан да ихлас булса, алар сәяси-юридик хокуклар белән гарантияләнсә, хуҗалык итүнең кулай формалары, чаралары, чишмә-чыганаклары табылыр, мөгаен. Алла һәм табигать кешегә искиткеч акыл, зирәклек, кодрәт-куәт биргән. Бөлгенлектән чыгу юлын халык үзе үк табыр! Ләкин «Кеше үз хезмәтенең игелеген күрергә тиеш!» — дигән изге, табигый хакыйкать онытылмасын иде.

Марксизмның өченче чыганагы һәм состав өлеше, французларның XVIII гасырдагы метафизик материализмыннан метафизикасын, немецларның диалектик идеализмыннан — соңгысын төшереп калдырып, диалектик материализм исемендәге философия рәвешендә барлыкка килде. Нигездә ул марксистлар төзисе социалистик җәмгыятьнең өскормасын, идеологиясен тәэмин итәргә тиеш иде. Димәк, мәгърифәт-мәдәниятнең, әхлак-әдәпнең,

әдәбият-сәнгатьнең дә яңа куәтле учакларын кабызып, дөрләтеп торырга һәм үз ачышларына, үз иманына халык массаларын инандырырга, аларның җанына, рухына сеңәргә тиеш иде.

Диалектик материализмның, әлбәттә, гыйльмият буларак формалашкан-чы ук, тормыш-кануннары юк түгел. Әйтик, материянең һәрдаим хәрәкәттә булуы, бердәйлек һәм капма-каршылыклар көрәше, инкарьне инкарь итү, сан-микъдарның сыйфатка күчүе кебек категорияләр... Шәт, шуңа күрәдер дә, бу гыйльмиятнең кайбер уңышлары да булмады түгел. Без диалектик материализм фәлсәфәсенең казанышы булган Г. Плеханов әсәрләрен яки В. И. Ленинның «Сугышчан материализм турында»гы мәкаләсен әле дә югары бәялибез. Реаль чынбарлыкта да, әйтик, егерменче елларда мәгърифәтнең тормышчан зарур яңа формалары табылды, яңа шартларда яңа эчтәлекле, яңа формалы әдәбият-сәнгать әсәрләре иҗат ителде, дөньяга яңача карашлы шактый шәхесләр үсеп чыкты, коллективизм, интернационализм хисләре көчәйде һ. б.

Ләкин... К. Маркcның социализмны ялгыш фәлсәфи нигезләрдә төзергә җыенуын кыю тәнкыйть иткән М. Бакунин, мондый «авторитар коммунизмда» экономика һәм сәясәттә генә түгел, идеологиядә дә катгый диктатура урнашачагын алдан кисәтте. Кызганычка каршы, бу бөек гыйсъянчының юраулары юш килде. Чынлап та, диалектик материализм гыйльмиятен белер-белмәс һәм катгый субъектив рәвештә агымдагы политикага яраклаштыру, буйсындыру, исемен тәкърарлап та, җисемен теләсә ничек «бөгештерү» аркасында халыкларның күпчелеге аны үз кыйбласы, үз иманы, фарыз тәгълиматы санап кабул итмәде. Кеше җанында теге яки бу дингә каршы тора алырлык рухи инану була алмады ул.

Марксистик-ленинчыл философиянең гомумнигезләре, категорияләре, чагылыш һәм сәнгатьләр теориясе, педагогика, коммунистик мораль һ. б. ш. иҗтимагый мәсьәләләр буенча бихисап хезмәтләр язылды. Марксистик-ленинчыл фәлсәфәне киң пропагандаларга, кайбер тормыш дәлилләрен шул фәлсәфә калыбына яраклаштырырга тырышучы, ләкин асылда субьектив сәяси булган академиклар, профессорлар, доцентлар ишәя торды, ә халык күңеленә хуш килгән, аның рухи дөньясын бизәгән тормышчан акыллы, мавыктыргыч, дәлилле һәм игелекле фәлсәфә фәне туа алмады. Фәлсәфи гыйлемнәрнең башка юнәлешләренә, әйтик, дини-рухи фәлсәфәгә яки шәхес-индивидуум фәлсәфәсенә катгый рәвештә юл бирелмәде.

Мәгълүм булганча, большевиклар К. Маркcның «Философы лишь различным образом объяснили мир, но дело заключается в том, чтобы изменить его» (Маркс К. Энгельс Ф. Сочинения, т. 3, с. 4) дигән атаклы тезисын фанатикларча зиһеннәренә, каннарына сеңдерделәр дә, илне ватаргаҗимерергә, үзләренчә «үзгәртергә» керештеләр. Революция ясауда, сыйнфый дошманнарын гына түгел, шул ук революцион көрәштә үзләре белән иңгә-иң торып көрәшкән көндәшләрен, эсерларны һәм меньшевикларны да тар-мар итүдә, гражданнар сугышында һәм дингә каршы җинү белән масайган, азынган большевистик лидерларның берсе (Лев Троцкий бугай): «Әгәр кояш буржуазияне генә җылытса — без кояшны сүндерербез!» дигән үтә кызыл, гайре табигый лозунглар кычкыруга барып җитте. Атаклы татар шагыйре Һади Такташның: «Җир безнеке булыр! Ачулансак, шлем кигертербез айга да...» — дип язуы, менә шундый лозунглар шаукымы ул! Нишләтәсең, Һ. Такташ та үз дәверенең тәртә арасына кертелгән илаһи талантлы бер хадиме булган шул. Аннары, шәрыкъ халкының «Уллар аталарына караганда, күбрәк үз заманнарына охшыйлар» дигән мәкале дә бар бит...

Материалистик философия бездә агымдагы политикага яраклаштырылып, чынлыкта бер төркем «кызыл бюрократиянең» башбаштаклык кылуын аклаучы идеология законына әверелде. Өстәвенә, бу большевик «юлбашчылар»ның күбесе (бер Ленин гына түгел, Троцкий, Бухарин, Радек, Ярославский, Володарский, Сталин, Жданов та шулай...) үзен «күренекле теоретик» итеп санады. Алар иҗтимагый фәннәрнең теләсә кайсы тармагына тыкшынып, К. Маркcның үз сүзе белән әйтсәк, «үзенең карлик размерында» социализмны һәм коммунизмны идеаллаштырып, директив, ортодоксаль «фәнни нәтиҗәләр» чыгарды: Бөтендөнья революциясе һәм кыска дәвердә коммунизмны төзеп җиткерү, вак кустарьларның «капиталистларга әверелүе», бер милләттә ике культура булуы, партияле әдәбият-сәнгать теориясе, Сталинның социализм ныгый барган саен сыйнфый көрәш көчәя, дигән уйдырма фәлсәфәсе яки тел белеменә, экономикага кагылышлы катгый «фәнни ачышлары», Бухаринның Есенин иҗатына биргән бәяләре, Жданов-

ның марксистик-ленинчыл философия турындагы казенный-кызыл нотык. докладлары һ. б. лар анә шуна ачык мисал.

Дәүләт төзелеше структурасын яки мәгълүм дәрәҗәдә хуҗалык итү тәртибен үзгәртү, сыйныфлар, милләтләр арасындагы мөнәсәбәтләрне, калаларны яки салаларны үзгәртү — бусы әле бер хәл. Ә менә дөньяны, табигать һәм галәм законнарын, вакыт агышын үзгәртү, мөмкин булмаганын фанатик марксистлар төшенергә дә теләмәделәр. Лысенко ише партияле авантюрист укымышлыларның хәтта генетика, биология фәннәренә «кызыл күсәк» белән ташлануларын әнә шул зарарлы иллюзия, большевикларның дөньяны «үзгәртү» фәлсәфәсенә куштанлануы дип аңларга кирәк.

А. П. Чеховның бер акыллы гыйбарәсе күңелгә уелып калган: «Халыкның куәте — аның намуслы яши, фикер итә һәм эшли белә торган интеллигенциясендә,— ди реалист әдип.— Интеллигенция яңадан-яңа социаль, техник, экономик, фәнни идеяләрне тудыра, шул рәвештә, җәмгыятьне алга этәрә...»

Белгәнебезчә, большевизм лидерлары шул зыялыларны (ә бит алар арасында эшче-крестьян, һөнәрче, мөгаллим, вак сәүдәгәр... уллары-кызлары да шактый иде!), иң әүвәл, «тотрыксыз», «икейөзле», «аумакай», «черек либераль» дип, «Милләтнең баш мие түгел, ә бугы» (Ленин В. И. Пол. собр. соч. т. 51. стр. 48) дип, ил алдында кимсетергә, хурларга, береаздан бөтенләй илдән куарга яки «тәрбия лагерьларына» ябарга керештеләр. «Мы сами с усами» янәсе, безнең сыйнфый сизгерлегебез бар янәсе... Властька хезмәт итмәгән, хәтта битараф булган интеллигент кирәкми, дигән шәфкатьсез сәясәт һәм золым илнең интеллектуаль байлыгын, куәтен, әхлаксыз сәяси үләт, чир башланды...

Мәгълүм булганча, мәгърифәт-мәгариф өлкәсе үтә тарайды, иҗтимагый фәннәр бары тик большевиклар ихтыяҗына буйсындырылды һәм яраклаштырылды. Аеруча мәдәният туктаусыз золымнарга дучар ителде: Берүк милләттә ике культура була, имеш. Соң, Рафаэльның «Мадонна»сын капиталист яки дин гыйлеме профессоры да, һөнәрче дә, игенче дә сокланып карый, ә Бетховенның «Аппасионата»сын миллионер Гарриман да, Ленин үзе дә тыңлаган, Тукайның «Шүрәле»сен татар сәүдәгәре Апанаев та, грузчик Гыйлем Камай да мавыгып, елмаеп укыганнар, лабаса! Әлбәттә, әдәбият-сәнгатьнең мондый гүзәл әсәрләрен һәркем үзенчә аңлый, үзенчә кабул итә. Дөньяви яки дини мәдәният җимешләрен һәр милләт, һәр сыйныф вәкилләре үз күргән, якын иткән, олылаган! Шөкер, дөньяда матурлык һәм миһербанлык революцион яки реакцион, материалистик яки идеалистик карашлардан бәйсез яши!

Әйткәнебезчә, егерменче һәм утызынчы ел башларындагы, хәлләрне сурәтләүгә, Бөек Ватан сугышының кайбер вакыйгаларын чагылдыруда әдәбият-сәнгать матур гына уңышларга ирешә алды. Ләкин чирек гасыр дәвамында бу рухи өскорма «социалистик реализм» дигән бер генә фокуслы күзге кысасына ярашырга мәҗбүр булып, реаль яшәешне дөрес чагылдыру, табигый гәүдәләндерү хокукларыннан мәхрүм ителде. Әдәбият-сәнгать — революцион үсешне, «социализм тантанасын» сәнгатьле чаралар белән тырышып якларга һәм мактарга тиеш иде. Большевизм лидерларын, партия работникларын пәйгамбәрләр, барча проблемаларны хак һәм гадел хәл итүче фидаиләр дәрәҗәсенә күтәреп сурәтләргә, шуңа күрә дә гайре табигый вакыйгалар, ясалма сюжет-уйдырмалар белән эш итәргә мәҗбүр булды. Бу рәсми идеологик координаттан аз гына читкәрәк атласаң да — төрмә, лагерь яки «очраклы» кабер иде. Яисә, җаен таба алсаң, чит илгә кач... Хәтта партиянең, совет строеның үзенә үк тугры һәм ихлас хезмәт итеп йөргән язучы, рәссам, музыкант, актер һ. б. иҗат вәкилләренең үзләрен үк, тегебу сылтау табып, лагерьларга бикли тордылар. Газета-журналга мөхәррир булган шәхес, чынбарлыкта йомышчы хадим, райкомның, обкомның яки Үзәк Комитетның идеология башлыкларыннан узып, кырыс цензураның рөхсәт штампысын бастырмый торып, чыпчык борыны кадәр яңарак фикере булган язманы да дөньяга чыгара алмый иде.

Сәнгатьтә дә шулай: төп хөкемдар, баш белгеч һәм баш тәнкыйтьче булып җитәкче партия аппаратының идеологы санала иде. Менә шундый административ-команда шартларында алла-табигать законнарыннан, тарихның хак, объектив логикасыннан, халыкның реаль тормышыннан, аеруча аның матди көнкүреш хәленнән, шәхес мәнфәгатьләреннән тәмам аерылган, илдәшләребезне, аеруча яшь буыннарны ясалма, купшы, берьяклы коммунистик идеаллар, мавыктыргыч әфьюн белән саташтыра, рухи чикли торган әдәбит-сәнгать, кем әйтмешли, «образлы агитация тузганаклары» котырып үсте. Менә шундый мәҗбүрият шартларында әдәбият-сәнгатьнең иман пакь-

леге, аның миһербан һәм камил рух, вөждан, социаль Гаделлек, якты Өмет һ. б. затлы, асыл, илаһи сыйфатлар өчен көрәшергә тиешлеге, хөр-азат булырга тиешлеге бөтенләй диярлек гамь ителмәде.

«Социалистик реализм» һәм «партияле-сыйнфый әдәбият» таләп иткәнчә, бар хасиятен коммунистик лозунгларга, агымдагы календарь, актуаль темаларга багышланган, социаль заказ белән язучы, ә чынлыкта имансыз, принципсыз, көнлекче шагыйрьләр, әдипләр, аумакай-куркак тәнкыйтьчеләр, плакатчы рәссамнар, режиссерлар арта барды. Аларның күбесе — бигрәк тә таланты сай, белеме, сизгерлеге чикле, социаль тормыш тәҗрибәсе чыпчык тезеннән генә булганнары — үтә сөмсезлек, әрсезлек белән властька, төшемле, җылы-җайлы урыннарга үрмәләделәр. Әдәбият-сәнгать эше чираттагы сәяси-идеологик кампаниягә, түбәтәй чигеп, түбәтәй сату кебек гадәти шөгыльгә әверелде. «Иҗат кешесе», «интеллигент кеше», «гыйлем кеше» дигән төшенчәләрнең кадере калмады. Һәм шул инерция әле дә дәвам итә.

Кайчандыр «буржуазия интеллигенцияне сатып ала» дип шарран ярган марксист-большевиклар СССР шартларында бу социаль катламны урта кул итекчедән дә, сантехниктан да кысанрак, ярлырак, мөшкелрәк хәлгә төшерде. Мисаллар, дәлилләр санап китү кирәкмидер. Укучы бу хәләхвәлне бездән күбрәк тә белә...

Безнең телгә этеп-төртеп кертелгән «коммунистик мораль» хакында сүз кузгатсак та, иң әүвәл, бу әхлакның шул ук марксистик тәгълиматка бәйләнгән булуын күрербез. Без, әлбәттә, К. Марксны, Ф. Энгельсны, Г. Плехановны, В. Ленинны, Ф. Дзержинскийны һ. б. материалист-коммунист юлбашчыларны үз шәхси тормышларында әхлаксыз булганнар, дип гаепләмибез. Егерменче гасырның һәм тарихи борылышның күренекле, катлаулы шәхесләре алар! Һәм, гөнаһлы булмыйк, марксизмның әхлак мәсьәләсендәге теоретик идеаллары да ямьсез, шәфкатьсез түгел. Тик менә... әлеге «социалистик», «коммунистик» дигән максат-ниятләрне тормышка ашыра башлау белән үк әхлак төшенчәсенең гомумкешелеккә хас сыйфатлары тәмам җуелган икән бит. Чөнки «дөньяны үзгәртергә» керешкән большевикларга үз максатларына ярашлы «сыйнфый-коммунистик» әхлак кына кирәк булган! Дөресрәге, алар әхлакны үзләренең узурпаторлык максатлары кысаларында гына кабул иткәннәр һәм үзләрен хаклы санаганнар. Күренекле француз социалисты Җан Җорес әйткәнчә, «революция — прогрессның вәхши формасы» булганлыктан, бу вәхшилек теге-бу әхлак белән санашып тормый. Ул иң элек, җай чыгу белән, көч-мәҗбүриятне, җәбер-золымны корал итеп, үз «якты киләчәгенә» таба юл чистарта. Үз дошманнарын, көндәшләрен аса, кисә, йә колы итә... Мәкальдә әйтелгәнчә, «цель оправдывает средства...»

Большевик лидерларның берничә генә әмерен искә төшереп узыйк: «Террор — это средство убеждения». (В. И. Ленин. т. 39, стр. 405) «Суд должен не устранить террор, обещать это было бы самообманом или обманом, а обосновать и узаконить его принципиально, ясно, без фальши и без прикрас.» (т. 45, стр. 190).

«Огонек» журналында (№ 10, 1990) эсерлар лидеры булган Виктор Черновның истәлегеннән бер өзек басылган: «...я ему и говорю: Владимир Ильич, да приди вы к власти, вы на следующий день меньшевиков вешать станете! А он поглядел на меня и говорит: «Первого меньшевика мы повесим после последнего эсера», прищурился и засмеялся». 1911 нче елда булган бу сөйләшү. Асылда, Октябрь переворотыннан соң ук, В. И. Ленин шул ниятне тормышка ашыра башлаган түгелме? Менә аның юстиция халык комиссарына язган мәгълүм боерыгы: «т. Курский! По-моему, надо расширить применение расстрела (с заменой высылкой за границу)... ко всем видам деятельности меньшевиков, с.-р. и т. п. найти формулировку, ставящую эти деяния в связь с международной буржуазией» (Курсив и разрядка Ленина. Ленин В. И. ПСС. т. 45, стр. 139)

Чынлап та, Владимир Ильич олы теоретик кына түгел, реаль практик та булган, сүзендә тора белгән дими, ни дисең!... Революцион көрәш юлларында күргән-кичергәннәре, корбаннары, фаҗигалары уртак булса да, дәүләт властен уртак итәргә бер дә теләмәгәннәр шул. Власть дигән татлы, тылсымлы, ләззәтле идарә рычагы уртаклыкны, көндәшлекне сыйдыра алмый, күрәсең. Юкса, халыкның үзидарә органы булачак Советларны төзү идеясен 1905 елда ук «Искра» газетасында меньшевик лидерларның берсе Ф. Дан күтәреп чыга һәм Петербургтагы беренче Советның рәисе дә меньшевик Зборский була. Хәзер дә шул, Советлар идеясенә, Советлар структурасына кайттык түгелме соң без?...

Лев Троцкий исә «Устрашение является могущественным средством политики, и надо быть ханжой, чтобы этого не понимать» — дип раслый һәм революциягә тугры булган меңнәрчә кызылармеецларны, кызыл командирларны аттыруны гадәти чарага саный башлый. Ә Николай Бухарин: «В революции побеждает тот, кто другому череп проломит» дип, «Принуждение во всех своих формах, начиная от расстрелов и кончая трудовой повинностью,... является методом выработки коммунистического человечества из человеческого материала капиталистической эпохи» дип «коммунистларча тәрбияләү»нең методикасын да күрсәткән.

Башка большевик лидерлар да аяусызлыкка, революцион шәфкатьсезлеккә өндәү һәм шул юнәлештә шәхси үрнәк күрсәтү гамәлендә бер дә кимен куймаганнар. Лидерлар үзләре шундый күрсәтмәләр биреп торгач, зур хокукларга ия булган һәм коралланып алган ВЧК, ГПУ хезмәткәрләре йөзәрләп, меңәрләп атканнар кешеләрне! Россия империясенең төрмәләренә генә сыймагач, бушап калган чиркәү һәм монастырьларны лагерьларга әйләндереп, ул тимер челтәрле зоналарга һәртөрле «шикле», «чит элементлар»ны, берәр туганы аклар армиясендә булган бичараларны яки продразверстка салымын түли алмаган «заложниклар»ны тутырганнар. Шундый мәхшәр заманында, әлбәттә, рәхим-шәфкать, әхлак турында авыз ачарга да мөмкин түгел.

Хәзер партияле кайбер тарихчылар бу миһербансызлыкны ул дәвернең мәҗбүрияте һәм совет властеның язмышы кыл өстендә булу белән аңлатырга тырышалар. Әмма җәмгыятьнең рухи дөньясына, мәдәниятенә, шәригатенә килгән бу коточкыч афәтне тарих аклый алмый бит! Аклый алмый!

Ленинның «тугры дәвамчысы» булган Сталин дәверендәге шаккаткыч җәбер-золымны, вәхшилекне хәзер бөтен дөнья белә. Сугышларда, зур яуларда түгел, тыныч-имин елларда һәм һаман да шул «социализм тантанасы» хакына, үз илендә үк 60 миллионга якын үз гражданнарын, Л. Берия әйткәнчә «лагерь тузанына әйләндергәннәр». Партия-совет диктаторлары, чынлап та, «дәһшәтле тәмугны дөньялыкта булдырганнар».

Ул хәтәр дәвердә кешеләргә золым-золмәт мөһере итеп сугылган 50 нче статьяның шомлы пунктлары, кешене үзенә үзе яки якыннарына, танышларына яла ягарга мәҗбүр итәр өчен кулланылган җәзалау алымнары хакында укыганда гына да зиһенең томаланып алгандай була, тәннәрең туңып китә. Җаныңда үкенеч, әрнү, нәфрәт давыллары дулый.

Вөҗдан, Миһербан, Әхлак сыйфатлары бөтенләй юк ителгән бу шәфкатьсез дәвернең яңадан-яңа дәлилләрен санап тормыйм мин. Тик менә бу мәгълүм фаҗигале парадокска игътибар итегез әле: коммунистик тәрбия, коммунистик әхлак турында бик күп нотыклар сөйләп, үгет-нәсихәт биреп йөргән һәм шул хакта китаплар чыгарган «Бөтенсоюз старостасы» М. И. Калинин үзе дә гаепсез хатынын Сталин золымыннан саклап кала алмый! Дөнья халкын ачлыктан коткару идеясе белән янып яшәгән академик Н. Вавиловның үзен ачлыктан интектереп үтерәләр... Мондый тоталитар вәхшиң шартларда нинди әхлак турында сүз булуы мөмкин?!

Илгә Н. С. Хрущев җитәкчелек иткән «җепшек елларда» «Коммунизм төзүченең мораль кодексы» дигән бер «кызыл доганы» кызыл такталарга ак буяу белән язып яки киресенчә бизәп, һәр предприятиенең, учреждениенең, мәктәп-институтларның үзәк урыннарына кадаклап элделәр. Шул «мораль кодекс» турында шау-шулы кампания башланды, көнлекче каләм батырлары бер-бер артлы китаплар да язып өлгерттеләр. Ләкин илдәшләребезне рухи яктан камил итәргә тиешле бу «кодексны», минемчә, берәү дә җитди чарага санамады, бизәкле такталар кубып төшеп, теләсә кайда аунап ятты, китаплар макулатурага китте. Чөнки бу «мораль кодекс» реаль тормыштагы экономик-сәяси һәм социаль-иҗтимагый шартлар белән тәэмин ителмәде. Шуңа күрә дә, «Ялганчының өе янган, берәү дә ышанмаган» дип татар мәкалендә әйтелгәнчә, халыкны ул «кодекс»ка һич ышандырып булмады.

Л. Брежнев лидерлык иткән елларда исә «мораль» сүзе кабат рәсми идеологиядә телгә кергәләсә дә, әхлак мәсьәләсе реаль чынбарлыкта хаҗәтсез булып калды. «Ни телим — шуны кыланам», «Үзем тапкан мал түгел, халыкныкы — җәл түгел» дигән иҗтимагый-психологик чир, башбаштак атмосфера тагын да көчәеп китте. Чамасыз эчкечелек, ришвәтчелек, күз буяучылык, әшнәлек, кода-кодагыйлык ишәйде...

Кыскасы, зур сынаулар, фаҗигалар, корбаннар, экономик-сәяси һәм социаль-иҗтимагый борылышлар белән узган ул киеренке җитмеш елда без үзебез ният иткән гадел социалистик җәмгыятьне дә, аның ышанычлы һәм ныклы, кешелекле идеологиясен дә, әхлагын-әдәбен дә булдыра алмаган-

быз. Ниятләре матур булган социалистик-коммунистик тәгълиматның реаль чынбарлыкта бер генә чыганагы һәм состав өлеше дә үзен акламады. Административ-команда системасы бу тәгълиматны гел үзе теләгәнчә кулланып, җәмгыятьне, илне-көнне экономик һәм сәяси торгынлыкка китерде, бөлгенлеккә, тирән кризиска төшерде. Буыннан-буынга кешеләрне үз ирке, үз ихтыяры, үз фикере булмаган «винтикларга» янсә социаль-иҗтимагый хамелеоннарга әйләндерү процессы дәвам итте.

Хәзер без Казандагы һәм Чаллыдагы яки башка калалардагы яшүсмерләрнең җан өшеткеч шәфкатьсезлеге, имансызлыгы, җинаять өстенә җинаять кылулары, женси азгынлыклары, эчкечелек һәм наркомания белән чирләүләре, милли патриотик хисләрдән мәхрүм калулары турында күп сөйлибез, еш язабыз. «Заманына күрә — зары» дигәндәй, төптән уйлансаң, бер дә сәер түгел: хәзерге бозык, эшлексез, имансыз яшьләрнең күбесе — әнә шул житмеш ел дәвамында дин-шәригатьтән биздерелеп, һәрдаим кинәт үзгәртелеп торган идеология йогынтысында, кысан-кыен, кырыс шартларда буыннан-буынга әхлаки деградация кичергән, рухи зәгыйфьләнә барган ата-аналарның балалары, оныклары ич алар.

Хәзер инде янә икенче чиккә ташландык! Шәхес азатлыгына шартлар тудырабыз, янәсе. Теге яки бу милләтнең гореф-гадәтләрен, әхлак-әдәп йолаларын бөтенләй санга сукмыйча, белмим, кемнәрнең рөхсәте, кемнәрнең хирыс тырышлыгы беләндер, чат саен «Видео» заллары булдырылды. Әлегә тәне дә, җаны да ныгып житмәгән яшь жилкенчәкләр, бал тирәсенә сарган чебеннәр сыман, шул «мажара бүлмәләренә» ябырылалар. Ә анда күрсәтелә торган төсле «могҗизаларның» күбесе миһербансыз кыюлык-елгырлыкны, кансыз «суперменнарны» «фәхишлек, гомосексуализм «ләззәтләрен» төрле вариант-вариацияләрдә күрсәтеп мактый...

Патша Россиясе һәм СССР шартларында бөтен держава буйлап, куәтле дулкыннар сыман, өзлексез агылып-болганып торган миграция, без мактанганча ук, «халыклар дуслыгын һәм интернационализмны» ныгытмаган, киресенчә, берәүләрне туган туфрагыннан, үз халкының мәдәни-әхлаки даирәсеннән аерып, рухи сукбай, зат-ырусыз алаканат иткән: ә икенче берәүләрнең, аеруча жирле халыкның көнкүреш шартларын кинәт үзгәртеп, тарихи асыл бизәкләрен, мәсләген, телләрен, моңнарын-җырларын чикләгән, табигый байлыкларыннан мәхрүм калдырган. СССРда ел саен 20 миллионга якын кеше урыннан-урынга күченә, рус авылларында яшәүчеләрнең 21 проценты һәр елны милли төбәкләргә «халыклар дуслыгы урнаштырырга» китә... (В. Переведенцев. Прописка и демография. «Московские новости» № 20, 1988)

Яу кырларында уртак дошманга каршы бергәләп көрәшү яки өмә белән завод салу, ГЭС кору — дөньяви традицион зарурлык ул, ләкин Рух, Җан гамәлендә шәхеснең үз тутәлендә үсүе хәерле бит! Авыл агае да яхшы белә: бер үк басуга кушып чәчелгән бодай, арпа, люцернаның берсе дә рәтле уңыш бирми, атлар белән дуңгызларны бер үк болында көтмиләр...

Әйе, СССРны житәкләгән административ-команда системасы, объектив таләпләрне, ихтыяҗны санга сукмыйча, мәҗбүрият-диктатны кулай күрде. Нәтиҗәдә, милләтара мөнәсәбәтләрдә матур сыйфат-бизәкләрдән күбрәк, тискәре, дәгъвалы, каршылыклы, нәфрәтле яклар көчәя барды. Бу юнәлештә дә илдәшләребезнең рухына, көнкүрешенә, милли горурлыгына, милли үзаңына зыян тиде. Рус әйткәнчә, «перекати поле», татарча «пәри үләне»дәй характерлы, бер генә милләтнең дә мәдәни-рухи кыйммәтләрен хөрмәт итә белмәүче буыннар ишәйде.

...Ихтыярсыздан уйлар давылы үткәннәрне урап кайта. Чал тарихның гомер тынмас дулкыннары теге яки бу державаларны, бөек ханлык-патшалыкларны чәлпәрәмә китереп җимерә дә, чорлар мәйданына яңаларын калкыта. Фәлән халыкларны «эретә» дә, башкаларны гаять кодрәтле, мәдәниятле итә... Гомер бакый шулай булган һәм шулай булачактыр». Илләркөннәр дәрьясының әлегәчә без белмәгән, һич алдан чамаларга, сизенергә, фараз итәргә дә мөмкин булмаган яшерен агымнары, үз катгый диалектикасы бармы соң әллә? Мөгаен, шулайдыр.

Шундый тарихи тетрәүләр, зур давыллар килгән чакта, киләчәк язмышларың ничек булыр, әй, болгар-татар халкы?..

Ни кадәр генә изелү һәм шәфкатьсезлек кичерсә дә, һәр халыкның асыл затлары буыннар мәдәниятен, буыннар әхлагын, шәригатен, генетик рухи сыйфатларын саклау өчен көрәшә. Мөмкин булган бар чаралар белән

бу хәзинәне ишәйтергә, аны алмаш токымга да тапшырырга тырыша. Рухи учакларны әдәбият-сәнгать сүндерми саклый, аз гына җай булды исә аны дөрләтеп җибәрә. Һәм, гомумән, нинди «изм»нарның ничек хакимлек итүенә карамастан, кешелек дөньясы прогрессив хәрәкәтсез яши. Коллыкка, мәхбүслеккә төшерелгән хәлендә дә! Хәтта лагерь, оккупация шартларында, төрмә-зинданнарда үлемсез әсәрләр язылган, фәнни ачышлар ясалган, иҗтимагый-фәлсәфи фикерләр, идеяләр туган, лабаса! Кешелекнең табигате, асыл диалектикасы шундый.

Без хәзер чын-чыннан катлаулы, хәтәр-шомлы дәвер кичерәбез. Фән-техника прогрессы дәвам итә, кеше акылы аллалар тәхетенә, аллалар кодрәтенә ирешмәк булып, туктаусыз эзләнә, тәҗрибә-экспериментлар үткәрә, бер-бер артлы фараз-гипотезалар уйлап чыгара. Ул инде, әнә, тулы бер планетаны, Җиребездәге кешелек, тереклек дөньясын бөтенләй юк итәрлек һәртөрле кораллар арсеналын да әзерләп куйды. Тик, барыбер, никадәр үрсәләнмәсен, Алла-табигать каршында, галәмнәр масштабында кеше заты әлегә хәлиткеч куәт-кодрәт була алмый. Без идеал иткән, без сизмәлләп олылаган Алла тәхете аңа һич насыйп түгел! Дөньяның бихисап яңа серләре, яңа могҗизалары туа тора! Хәзер шактый еш күренә, телләрдә сөйләнә торган НЛО һәм алар белән идарә итүче җан ияләре турындагы хәбәрләр хакында гына уйланыгыз әле. Галәмнәр масштабында диалектик фикер иткәндә, бер дә битабигый хәлләр түгел ич бу могҗизалар!

Шунысы аяныч: фән-техника прогрессы куәтләнгән саен кеше заты үзенең рухи дөньясында ярлылана, хирыс рационалистка әверелә бара түгелме? Димәк, хәзер кешелек дөньясы өчен Миһербанлы Акыл аеруча кадерле! Рухны санга сукмаучы салкын, эгоистик акыл Җиребезне, илебезне һәлакәткә китерәчәк. Һәр ике олы тәгълиматның кешеләргә йогынтысы зәгыйфьләнү нәтиҗәсендә без хәзер рухи кризис, торгынлык, төшенкелек кичерәбез. Үкенү хисе нәфрәткә, гыйсьянга әверелеп, халыкларны мәйданнарга, митингларга, һәртөрле җыен-җыелышларга куып чыгара. Һәртөрле катгый таләпләр, сәяси лозунглар күтәртә, кабат җимерү кайнарлыгына өнди, тормыш-яшәешне янача төзү ниятләрен дөрләтеп ала. Һәртөрле оешма, партия, фронт, берләшмә, союзларның исәбе-саны юк. Тик, кызганыч, әлегә аларның берсенең дә ныклы һәм тормышчан тәгълиматка нигезләнгән реаль, конкрет перспективалы максат-программалары эшләнмәгән. Бу хәрәкәтләр олы максатлы, реаль көчле һәм булдым политик партияләргә, хәлиткеч социаль-иҗтимагый союзларга оеша, формалаша алырлармы? Әйтүе кыен. Тик бер афәттән ходай сакласын иде: тарихта сәяси дәүләт режимнарының теге яки бу рәвешләрдә кабатлану гадәтләре бар. Һәртөрле стихияле хәрәкәт, башбаштаклык тираннарны тудыра!

Нәкъ менә шундый афәтне кабат китермәс өчен дә Миһербанлы Акыл кирәк безгә!

Шөкер, кешене өмет яшәтә. Һәм шул тылсымлы кодрәт адәм баласын башка җан ияләреннән өстен иткән. Риваятьләр вәгъдә иткәнчә, ислам динен торгызачак Мәһди җиргә инәрме? Дәҗҗал гаскәрен тар-мар итәчәк Гайсә пәйгамбәр кайчан фәрештәләр канатында күктән төшәр? Яҗүҗ-Мәәҗүҗ дигән коточкыч бер хәшәрәт көн саен җирне ашап менүен дәвам итәрме? Исраил фәрештә, быргы кычкыртып, кайчан фани дөньяның бетүе турында хәбәр итәр? Яки, марксистик-ленинчыл тәгълимат өмет иткәнчә, кайсыдыр бер илдә коммунизм җәмгыяте төзелә алырмы? Яисә кыю фантаст Циолковский фараз кылганча, кешеләр Җир-бишектән Кояш тирәсенә якынрак планеталарга, космик шәһәрләргә күчә башларлармы?...

Мондый бихисап, әкин көнүзәк олы сорауларга хыял белән җавап бирүләре дә җиңел түгел. Андый ук зирәк акыл, гыйльмиятне Алла-табигать насыйп итмәгән безгә. Ләкин андый җавапларның биреләсен зиһен дә, күңел дә көтә. Сизә бит, сизенә бит җиһан баласы! Һәм менә кайбер тормышчан, мәрхәмәтле үзгәрешләрне тоеп та сөенә башладык инде. Әнә, диннәр яңарып, терәкләнеп килә. Вөҗдан ирекe, милли тигез хокуклылык һәм Кеше шәхесе, аның мәнфәгате турында да уйлана, эзләнә башладык. Кем белә, бәлки, киләчәктә кешелек дөньясының барча реаль теләкләрен, миһербанлы идеалларын чагылдыра алган яңа тәгълимат барлыкка килер? Мөмкин, бик мөмкин. Барысы да Алла-табигать кодрәтендә...

Амин!

*Апрель, 1991 ел.*

# Газиз Кашаф-Үзиле

# ФАҖИГА

Әле без яшәгән егерменче гасырның башында ук шагыйрь:

> ...Тау башына салынгандыр безнең авыл,
> Бер чишмә бар, якын безнең авылга ул.
> Авылыбызның яме, суы тәмен беләм,
> Шуңар күрә сөям җаным, тәнем белән,

—дип язып калдырган.

Сөекле шагыйребез Габдулла Тукайның бу юллары безнең аңыбызга бала чактан ук урнашкан һәм инде, нинди генә ерак җирләргә китеп йөрсәк тә, без аны онытмыйбыз, оныта алмыйбыз.

Ни өчен? Чөнки бу юлларда тасвирланган җирләр—минем дә, синең дә, башканың да туган җире ул. Безнең Яңа Үзи авылы—Габдулла Тукайның да туган авылы булган ахрысы,—дип уйлый идем мин бала чагымда. Югыйсә каян белгән ул безнең авылның да тау башына салынганын? Безнең авыл янында менә дигән чишмә барлыгын?...

Аннары аңладым: безнең борынгы бабайлар авыл өчен урынны сайлый белгәннәр. Аны табигатьнең иң күркәм җиренә, яшәр өчен бөтен уңайлыклары, беренчә нәүбәттә, эчәр суы булган төшләргә нигезләгәннәр. Алар матурлыкны аңлый да, аңардан файдалана да, аны саклый да белгәннәр.

Без, үзебезне борынгыларга караганда акыллыга, тәҗрибәлегә санап йөрүчеләр, шул кагыйдәләрне үтибезме соң?

Кызганычка каршы, ул таләпләрне үтәргә теләп тә карамадык. Чөнки без «табигатьтән рәхимлекләр көтеп тормаска, аңардан бөтен нәрсәне үзебез үк тартып алырга» өйрәтелгән кешеләр идек... Ләкин табигатьтән, әгәр дә син аның кадерен белмисең икән, мәрхәмәт көтмә.

Без, шушы җирнең газиз балалары, Җир-ананы, аның табигатен, җирен-суларын, урман-болыннарын, тауларын-урманнарын кадерли беләбезме соң?

Мин авыл белән тыгыз бәйләнештә яшим. Мин, аңа кайтмыйча бер генә ай торсам да, әллә нигә ямансулый башлыйм. Җаным үзенә урын тапмый, әллә нинди бер көч-кодрәт иясе мине тагын шушы төшкә—Татарстанымның тыныч, тыйнак бер ягындагы авылыма тартып кайтара.

Ләкин, һәр яңа язда, һәр яңа көздә туган авылым—туган бишегемә кайткан саен, аның тәнендә яңадан-яңа яралар күрәм. Алардан кан сава, алар ачы күз яшьләре белән елыйлар кебек. Чөнки туган-җирне кадерләүче дә, аңа туйдырып торучы анага карата булырга тиешле мөнәсәбәт тә юк.

Минем авылдан чыгып киткәнемә утыз ел тулды. Дөрес, мин ел саен диярлек кайтып йөрдем, башта, еракта чакта, елга — бер, аннары, инде Татарстанга әйләнеп кайткач та, елга берничә тапкыр әйләнә идем. Минем хәтта, туган авылымны сагынып кайтып, урман буенда басып, аның манзарасына карап торып, яңадан борылып китеп барган чакларым да булгалады. Минем өчен кайтып шушы җиргә бер караш ташлау да җитә, җанымны тынычландырып җибәрә.

Кызганычка каршы, кайткан саен мин аның сыкранып-әрнеп торган яңадан-яңа яраларын күрәм. Дәшмичә кала алмавым, газеталарга язып, телеэкраннардан сөйләгәнем, әлеге яраларны салучыларны фаш итүем өчен хәзер инде авылның житәкче урыннарда эшләгән, үзләрен «түрә» итеп санаган кайбер якташларым мине дошманга санау дәрәҗәсенә җиттеләр. Хәзер инде мин аларда заман чире—аллергия кузгатучы бер яман затка әверелдем бугай. Телевизордан ясаган бер чыгышым өчен үз вакытында ниләр генә ишеттермәделәр?!

Табигать хәтле табигатьне җәлләмәгән, аны мәсхәрәләгән, ашаган табакларына нәҗес ташыган, эчкән суларына түккергән, олау-олау агулы матдәләр ташлаган һәм шуны күкрәк киереп: «Менә без нинди уңышларга

---

Вакытсыз арабыздан киткән каләмдәшебезнең соңгы язмаларыннан берсе.

ирештек!».— дип мактанып сөйләгән адәм актыкларыннан ни көтәсең?! Әйткәннәрен үтәрләр, үтәмичә калдырмаслар, әлбәттә.

Әмма без, Җир-ананың балалары, аның табигатенә гашыйк булган, үзебезне дөньяга тудырган өчен рәхмәтле кешеләр, андый нәрсәләрдән калтырап калмыйбыз, теләсә генә нинди көчләргә каршы да көрәшкә чыга алабыз. Әйе, әлегә без күп очракта җиңеләбез, ләкин белегез, белегез сез, үзегезне «түрә» дип санаган бәндәләр: бер көн килер, табигать, Җир-ананың түземлеге бетәр һәм сез дә, бүтән яклардагы ишләрегез кебек үк, үзегезгә тигән өлешне алырсыз. Кызганыч, күп очракта әлеге җәза гаепсезләргә барып тия.

Мин бу юлы намуссыз бәндәләргә кире кагарга һич тә мөмкин булмаган дәлилләргә таянып язарга уйладым. Ләкин кисәтеп куям: бу фаҗигаларны кылучылар бүгенге «түрә»ләр генә түгел, моны инде берничә буын «эшкуарлар» башкарды. Тагын шунысы да бар: бу гаделсезлекләрне, Җир-ананы, табигатьне мәсхәрә кылучылар үзләренә дәрәҗә итеп алырга ашыкмасыннар, алар — бу эшләрне башкаручы аңсыз маңкортлар, шахмат тактасындагы «пешка»лар гына. Төп гаеп, бәлки, аларда да түгелдер, төп гаеп югарырак, кызганычка каршы, көчлерәк нәрсәләрдә: иҗтимагый системада, авторитар-тоталитар дәүләтнең булыр-булмас законнарында...

Безнең авыл, Аксубай районының иң матур, оҗмах бакчасына охшаган төшендә иде. Аның һәр ягы урман, елгаларына һәм күлләренә балык тулган... Ул безнең күлләр!..

Безнең Яңа Үзи авылында яшәүчеләр эшкәртеп, иген игеп яшәгән җирләрен борын-борыннан кадерле белгәннәр. Авыл аша уза торган ярыйсы гына мул сулы елгасы булуга да карамастан, гасыр башында, каһәр суккан патша заманасында — кайдан гына акчасын тапканнар да, ничек кенә башкарып чыкканнардыр, — авыл янына берне генә түгел, икене дә түгел, өч күл казыганнар. Мин аларны адымлап үлчәмәдем, әмма, чама белән әйткәндә дә, берсе-берсе генә дә хәзерге стадионнардагы футбол кырыннан һич ким булмас. Өч күл. Юк инде, нинди экскаваторлар, нинди техника булсын ди ул вакытларда? Билгеле, кул көче белән, көрәкләр белән казыганнар.

Аның беренчесе — КӘРӘКӘ күле дип атала. Ул күл авылдан ерак түгел, күп булса, бер чакрымдадыр. Кояш чыгышы ягында. Безнең авылдан аерылып чыккан чуваш туганнарның Беловка дигән авылы белән ике арада җәйрап ята иде.

Ул күлне гасыр башында, тагын да төгәлрәк әйтсәк, 1914 елда — Беренче Бөтендөнья сугышы башланган җәйдә — Волков Хәлил бабай җитәкчелегендәге бер төркем ир-егетләр казыган. Алар — Могыйн, Куян Шәрифулла, Тычкан Фарзалый, Хөсәен, Сәмигыл Гыйлаҗетдине, бай Шәрифулла, Зәйнулла Вәлиулласы, Мөхсин, Минабетдин, Кәбир, Зәйнулла Вәлиулласының энесе (исемен хәтерләмәдем инде, гафу итсен) һәм тагын байтак кына кеше.

Рәхмәт ул бабайларга. Безгә, әле илленче, алтмышынчы елларда яшәгән кешеләргә дә, табигатьнең матурлыгын күрсәттеләр. Алай гынамы, байтак кына ачлыкларда, егерме беренче, утызынчы, кырык җиденче еллардагы ачлыкларда да үзләрен һәм балаларын саклап калырга ярдәм иткән өчен мең рәхмәт!

Түгәрәкләнеп торган бу күлдә кәрәкә балыгының иге-чиге юк иде. Тимер чыбык кармакны тегәрҗепкә тагасың да, иренмәсәң, бер-ике сәгатьтән бөтен гаиләңә берничә көн ашарлык балык тотып кайтасың. Ә күл суының чисталыгы, салкынлыгы — исләрең китәр! Күлнең төбе ялтырап күренеп тора, андагы балыклар да аермачык күренә. Аның ян-якларындагы, чишмәләр чыга торган җирендәге камышлыкларның куелыгы, ул камышлык арасында киек казлар, кыр үрдәкләре, хәтта аккошларның да булганын, бала чыгарганнарын әле мин дә күргән идем. Күл тирәсендәге болыннан печән чабып алганым да хәтердә, бик хәтердә әле.

Ләкин... 1957 белән 1960 еллар арасында «Верный путь» колхозының җитәкчеләре, бик зурдан кубып, авылның ир-егетләрен, хатын-кызларын көчләп дигәндәй, шушы күл янына җыйдылар. Ниятләре: ишетүемчә, «Күлне чистартабыз, яхшы балык җибәрәбез, аннары». — диделәр бугай. Күл ул чагында да әле кимендә ике метр тирәнлектә иде, без, чумып, аның төбеннән балчык та ала алмый идек.

Кәрәкә күлен иң «авырткан» җиреннән, Сөлчә елгасына таба төшә торган биек ярыннан ерырга керештеләр. Көне буена сабан туендагы кебек халык булды анда. Күрше чуваш агайлар килеп: «Нишлисез сез, акылыгызга килегез, кардәшләр», — дип тә карадылар. Ләкин, кая ул, күркә сыман

кабарынып йөргән «түрә»ләр: «Сез берни аңламыйсыз», — дип кенә җибәрделәр. Чөнки күл безнең колхоз басуында... Китте Кәрәкә күленең суы, китте безнең әби-бабайларның шатлыгы агып... Күл саекты, балыгы бетте, кая инде сап-сай күлгә балык җибәрү дә, кая инде ул балыкны үрчетү? Ерылган җирне янадан кумәргә тырышып караган кеше дә булмады, әйләнеп тә карамадылар. Хәзер генә, еллар үткәч кенә аңладым: ул елларда колхозга «җир җитми» иде. Хисапсыз җирләрне, болын-тугайларны сөрү хисабына «уңыш» арттыру иде максат. Кәрәкә күле тирәсендәге камышлыкларны киптерү булган «түрә»ләрнең максаты... Ирештеләр алар үзләренең максатына, ирештеләр. Хәзер инде Кәрәкә күле урынында һичнинди гамәлгә ярамый торган уйсулык кына утырып калды. Һәрвакыттагы, һәр эштәге кебек бертөрле сөйләп, шуның капма-каршысын эшләргә күнеккән «кызыл авыз»лар үзләре теләгәнгә ирешә алмадылар, әмма матурлыкны, бабайларның ядкәрен харап иттеләр. Хәзер бу урында күл дә, камышлар да, киек казлар да — берсе дә юк инде...

МҮКЛЕ КҮЛЕ авылның көньягында, урман буендагы бик матур урында иде. Ие... Аның тирәсендә дә чишмәләр тибеп тора, камышлар үсеп утыра, кош-корт өчен тыныч, искиткеч бер гүзәллек-хозурлык иде.

Кызганычка каршы, шул ук «түрәләргә» Мүкле күле дә ошамаган, алар аңа да теш кайрап йөргәннәр икән. Ләкин монысын ерып җибәрерлек түгел. Хәер, тырышып карадылар, ләкин күл бирешмәде. Алар ерган якка борылмады, шуннан инде башта «Верный путь», аннары ул еллардагы шаукым буенча эреләндерелгән һәм «Дружба» дип ят-яманат кушылган татар һәм чуваш авылындагы күмәк хуҗалык җитәкчеләре анда «лагерь» оештырдылар. «Гулаг» тәҗрибәсе зур, зур иде шул... Колхозның кәҗәдән дә азрак сөт бирә торган сыерларын елның елында шул күл тирәсендәге сазлыкка куып чыгаралар һәм күл буйларын издерәләр, таптаталар, нәҗес белән тутыралар.

Мүкле күл утыз еллык җәза кичерә. Үлмәскә тырыша әле. Ләкин, чынлыкта, ул, үле күл инде. Аның исемен дә хәзергеләр Мүкле дип түгел (кая инде мүк калсын ди?!) — «Лагерь күле» дип атыйлар. Аны хәзер чистартырга берәүнең дә теләге юк.

Ә бит Мүкле күлне казыган елны ук Фарзалый бабайлар Сөлчә елгасыннан балык тотып, шул күлгә ташыйлар. Чык тамчысыдай чиста күлдә бер-ике ел эчендә сансыз-хисапсыз балык үрчи. Фарзалый бабайлар да, аларның туганнары да, авыл кешеләре дә балыкка рәхәтләнде. Иренмә генә... Ә инде 1928—32 елларда бу Мүкле күл янына, Яңа Үзидән утызлап гаилә аерылып чыгып, кечкенә генә авыл сала. Ләкин утыз икенче елда көчле янгын ул «Якты күл» дип аталган авылны харап итә. Кешеләр янадан төп йортларына күченә.

Хәзер инде Мүкле күл, әй лә, «лагерь күле» үлем газапларын кичереп соңгы елларын яши. Озакламый ишелгән яр, кәҗә-сыерларның нәҗесе аны тутырачак...

Өченче күл, казыган елларда БИКЧАБАР КҮЛЕ дип йөртелә. Анысы Югары як урманы буенда, Бикчабар исемле коры елганың биек яр башыннан башланып киткән басу уртасында иде. Ие...

Аны да шушы ук ундүртенче-унбишенче елларда казыганнар. Аның янында да чишмәләр, камышлар һәм кош-корт рәхәтләнеп яшәгән. Соңрак ул күлнең исемен алыштыралар. Моның үзенә күрә бер риваяте дә сакланып калган әле. Ул якта элек чувашлар яшәгән. Шул тирәгә күмелгән Трофим исемле бер чувашның өрәге чыгып йөри икән, имеш. Бикчабар буеннан урманга йөрүчеләр Трофимны күреп куркалар, котлары алына икән. Шулай байтак кына интектергәч, Трофимның мәетен кабереннән кабат казып алалар да яңа урынга (ул күл янында үлгән була) күмәләр. Шуннан соң Трофимның өрәге күренми, күлгә исә бөтен халык Трофим күле дигән исемне куша.

Трофим күлен сугыштан соң ук киптерделәр, хәзер анда инде басу, ләкин ни хикмәттер, шушы күл урынына ни генә чәчсәләр дә үсәр-үсмәс була.

Ягыбызның иң олы байлыгы — ОЛЫ СӨЛЧӘ елгасы. Бу игелекле елга авылны кыл урталай ярып, боргаланып-боргаланып, авыл арасында гына да әллә ничә тугай хасил итеп уза. Әйтерсең, ул дала ягы белән таулы якны бүлеп килә-килә дә, Яңа Үзине яратуыннан, аның урамнарын ташлап чыгып китүдән куркып шулай кыска юлын озын итеп суза... Бу елга безгә күп еллар, мөгаен, гасырлар буена яшәү чыганагы булып торган. Туендырган, чистарткан, мал-туарны эчерткән, сусауны бастырган. Әле кайчан гына аның ярлары биек, текә, суы мул, балыгы хисапсыз, игелеген санап бе-

термәслек иде. Язларын бер ярсып-ярсып ала иде дә, аннары җәйләр, көзләр, кышлар буена тымызык кына дулкынланып агар да агар иде.

Сөлчәдә, авыл саен диярлек, су тегермәннәре эшли иде. Иске Тимошка тегермәне, Иске Кыязлыныкы, Иске Үзинеке...

Безнең авылны матурлап, Сөлчәне мул сулы итеп торганы Иске Үзидәге буа иде. Ул аның халыкка кылган игелеге!.. Элек-электән, ягъни безнең юлбашчыларыбыз: «Совет кешеләренең хәзерге буыны коммунизмда яшәр!» дигән догматик лозунгны җилләргә кушып ил өстенә сипкәннән бирле, тәгәле — 1965 елга хәтле, Иске Үзидәге буа тегермәне уртак иде. Анда теләгән кешегә ашлык тарттырырга, үсемлек мае чыгартып кайтырга, йон теттерергә мөмкин иде. Буаны да ел саен атлар-сыерлар белән урманнан чыбык-чабык ташып, җир ташып, салам кушып шундый итеп бөяп куялар иде ки, бернинди ташу да ала алмый үзен. Яз житкәч, бер урынныннан суны ерып җибәрәләр дә, аннары тагын эшкә кушалар иде. Шул авылда, Иске Үзиләр, бездән егерме биш-утыз елга алданрак электр уты кабыздылар һәм аның рәхәтен күреп яшәделәр. Алтмыш бишенче елда гына Зәй ГРЭСыннан килгән чыбыклар ул утны сүндерделәр, ут белән бергә буаның да кирәге калмады сыман. Бетерделәр буаны, тегермәннең ташларын һәм тегермәннең үзен... Бабайлар рухы да югалды, аны берәү дә «кирәккә» санамады, чөнки инде рух та, әхлак та сатылган, сөрелгән, күмәкләштерелгән иде...

Хәер, мелиорация дигән шөгыль барлыкка килгәч, басуларга су сиптерергә буалар яңадан кирәк булды булуын, ләкин инде элеккегечә буа куярлык кеше калмаган иде. Ике авылда да күз өстендәге каш сыман, әллә кайлардан күренеп, авылларга ямь өстәп торган Кызыл Ярларны күрде түрәләр. Бульдозерлар белән шул ярларның ярмалы туфрагын, үзле балчыгын иштереп буа ясарга керештеләр. Бу мәрхәмәтсезлек, кыргыйлык — ашаган табагына, эчкән суына нәҗес салу хәзергәчә дәвам итә. Бульдозерлар җирне төртеп ишә-ишә буа ясый, унбиш-егерме көн су сипкән булалар да, беренче көчле яңгыр ук, «буа»ны ишеп, пычрак-балчыклы Сөлчәнең буй житмәс чоңгылларына тутыра, елга саега, сусыз булгач, ярлары ишелә, таллары-өянкеләре корый, юкка чыга, балык тончыга, чишмәләр томалана...

Әй, бичара Олы Сөлчә, рәнҗисеңдер, ничекләр генә рәнҗи торгансыңдыр инде син безгә — мәрхәмәтсез, миһербансыз бәндәләреңә. Хәер, син инде хәзер рәнҗеми дә торгансыңдыр, синең инде күзләрең-чишмәләрең күптән күмелеп бетә язган, төпсез чоңгылларың да юк хәзер. Су перилэре дә үлеп беткәндер. Аларның нәселләре дә калмагандыр.

Мин синең, Сөлчә, кайткан саен яннарыңа төшеп, алларыңа тезләнеп мәрхәмәтсез түрәләр кылган җинаятьне кичерүеңне теләп ялварам. Күкләргә карап ялварам. Безне, шул җинаятьләргә, коточкыч фаҗигаларга юл куйган балаларыңны, кичер, каргама инде, бәхил кыл инде дип ялварам. Алай гынамы, Сөлчәкәем, мин синнән ерак-еракларга киткәч тә, диңгезләр, океаннар ярында, алтынсу җылы комнарда кызынып яткан чакларда да синең исләремә төшерәм. Син, Сөлчәкәем, анда да минем төшләремә килеп керәсең дә үзәкләремне өзеп-өзеп куясың. Бөтен рәхәтләрне ташлап, синең яныңа кайтасым, алларыңа барып тезләнәсем, ярларыңа ятып елыйсыларым килә... Кичер безне, Сөлчә, булдыра алсаң...

Сөлчә хәтле Сөлчә шулай харап ителгән икән инде, аны туендырып торучы вак-төяк инешләргә ни сан булсын?

Кәрәкә күленнән бирерәк Тегермән елгасы, икенче төрле әйткәндә — Чикширмә бар иде. Бөтен буе бер чакрымга тулгандырмы юктырмы?! Юктыр, мөгаен. Аның тирәләрендә печән шаулап үсә. Сөлчәгә койган җирендә тагын бер тегермән бар иде. Анысын инде аның сугышка хәтле үк, «дан»лы күмәкләштерү, чынлыкта, крепостнойлыкка кире кайтару вакытында ук харап иткәннәр. Ләкин без, балалар, аның бинасына керә идек, ашлык исен тоябыз, игелекле ташларны карыйбыз. Алар инде актарылып-актарылып ташланган, ләкин ватылмаган иде әле, күреп соклана, алар арасында, алар өстендә әллә нинди уеннар уйный идек әле... Хәзер инде аның эзе дә, әсәре дә юк... Хәер, Тегермән елгасы — Чикширмә үзе дә юк диярлек инде. Ул ерганак булып, янәшәсенә куелган дуңгыз, сыер фермаларыннан агызылган нәҗескә тончыгып ята. Аның инде хәзер күз яшьләре дә күренми, үлгән инде ул. Аның белән бергә, басу ягындагы үзәнендә үскән камышлар, печәнлекләр барысы да юкка чыкты... Анда, чәчсәләр дә, берни үсми, буш җир, ташландык җир булып ята бирә...

Урман буеннан, Мүкле күлнең ике ягыннан, авылга таба сузылышып төшкән тагын ике елга бар иде. Аның берсен төрлечә атыйлар иде. Кемнәр

Сали елгасы, кемнәр Колхоз елгасы, ә кемнәр Озын күпер елгасы диләр иде.

Хуш инде! Тыныч кына йокла инде, өч исемле елга... Хәер, ул таптапталу-изелү, агулы балчыкка, трактор мазутына, тимер-томырга күмелгән елганың үлеме табигый, йокысы тыныч була аламы соң?!

Мулла елгасының авыл эчендәге өлеше яши әле, ул бирешмәскәрәк тырыша, чөнки язгы ташулар вакытында Сөлчә аңа бераз җан өрә, сулыш өсти. Ләкин инде урманнан алып авылгача булган өлеше... Бәхил бул, печәнгә бай болынлы, Мулла елгасы, яки Мүкле елгасы... Әй, әле без яшүсмер чактагы печән чабулар, ул вакытлардагы уен-көлке... Кайда хәзер ул бәхетле елларның шау-шуы, кайда ул печәннәр, ул тургайлар, бытбылдыклар тулы елга тирәләре?!

Печән болыннары бетте бетүен, ләкин «санга кермәгән иген кыры» ясарга нихәтле генә тырышмасыннар, бирешми әле болын. Үле килеш тә бирешми, мәрхәмәтсез түрәләр әмерен санга сукмый. Уңыш бирми, тәки шулай җәйрәп ята...

Бу елгалар тирәсендә печәнлекләр күп иде. Билдән биек булып, хуш исле үләннәр үсә иде. Хәзер берсе дә юк. Бәхил булыгыз, авылым тирәсендәге болыннар, анда үскән әллә нинди, без исемнәрен дә белмәгән, безнең балалар исә аларның барлыгын да белмәячәк үләннәр, чәчәкләр, кош-кортлар! Кичерегез...

Яңа Үзи авылының урамнарына бер керсәң, бигрәк тә җәйләрен һәм көзләрен, шул урамнардагы яшел келәмнәргә сузылып-сузылыплар ятсаң, валлаhи әгәр, качышлы уйнарга мөмкин иде. Яшел чирәмгә күмелә идең, күренми идең. Казлар, тавыклар гына ул үләннәрне рәнҗетми иде. Малларны, көтүдән каршы барып алып кайтуга, ишегалларына кертеп ябалар иде. Ходаем сакласын, кемнең дә булса капкасы ачылып китеп кәҗә-сарыгы шул урамга чыксамы... Оятыңнан ни кылырга белмәс идең, авылдашурамдашларга күренергә дә куркып йөрер идең... Чөнки иртә язда, май бәйрәмнәре җитәр алдыннан, һәрбер хуҗа урамның үз турысын тырмалап алыр иде, себерке белән чүп-чардан аралап торыр иде.

Хәзерме?.. Әгәр дә мәгәр резин итекләреңне киярге онытып кайтсаң, аз-маз гына яңгыр сибәләп китсә, эш харап — атаң-анаң, әби-бабаң янына кермәмен димә. Муеныңнан төшеп батасың, замана гыйфритләре: трактор һәм машиналар казыган төпсез чокырларга чумасың — вәссәлам...

Әйе, безнең авылда, әнә хәзер ничә ел инде, медпунктта эшләргә кеше юк, шуңа күрә анда күрше авылдан шәфкать туташы килгәнне көтеп утыралар. Һәлакәтләр дә юк түгел, алар әледән-әле булгалый тора. Кеше егыла икән, ул инде тормаска да мөмкин, чөнки аңа вакытында медицина ярдәме күрсәтелми.

Шуның өстәвенә, басулардан агулы матдә, әлеге дә баягы, Сөлчәгә ага, анда үскән үләннәрне маллар ашый, малдан алган ризык: сөте, мае, катыгы һәм ите белән бергә кеше организмына үтеп керә, шуңа күрә илле яшенә җиткән исән кеше юк диярлек. Ул агу — иген кырларында һәм чөгендер басуында. Агуны сибеп чыгарга өлгермиләр, аны эшкәртергә, сирәкләргә, утарга кирәк ич...

Авылыбызның ике ягыннан зур-зур тасмалар рәвешендә сузылып киткән урманнарның да өстенә караплык түгел. Монысын инде дәүләтнең туймас тамагына турап-кисеп тутырдылар. Мондый адымнар белән һәлакәткә таба атлаганда, озакламый урман урынында да шундый ук файдасыз, кеше аягы кермәслек чытырманлыклар гына калуы ихтимал.

Кайдадыр укыганым бар: явызлык ул үзенең кемлеген бик яхшы белә һәм шуның өчен дә һәрвакыт иң изге ният һәм максатлар пәрдәсенә төренеп килә. Безнең авылларны да әнә шундый япма бөркәнгән явызлык гасырлар буена төзәлмәслек фаҗигага китерде. Бернинди кануннар белән дә акланмый торган җинаять түгелме соң бу?!

Кызганычка каршы, шулай, без — җинаятьчеләр, табигатькә каршы баручылар.

Ләкин мин беләм, җаным-тәнем белән ышанам: Җир-ана, Табигать мәрхәмәтле ул. Әгәр дә без бүгеннән үк үзебезнең барлык байлыгыбыз: җирне, суны, урманнарны, болыннарны, күлләрне, урамнарыбыз мохитен дәваларга керешсәк, аңа миһербанлылык күрсәтсәк, ул безне кичерер сыман. Әгәр шушы юнәлештә үзебезнең тырышлыкны арттырсак, һәрхәлдә, аны бимазалаудан туктасак, табигатебез үзен-үзе дәваларга көч табар әле, иншалла...

*6 май 1991 ел.*

# ФАҖИГАЛЕ ЯЗМЫШ

***Журналның бу санында укучылар игътибарына 1929 елның язында һәм көзендә Мирсәет Солтангалиевтән сорау алуларга бәйле яшерен материаллар тәкъдим ителә.***

***Лубянкада 45 көн тотылганнан соң, 1923 елның июнь азакларында Солтангалиевне азат итәләр. Ә бу вакыт эчендә илнең сәяси тормышында шактый гына үзгәрешләр була. Төп вакыйгаларның берсе итеп Мәскәүдә 9—12 июньнәрдә Милли республикалар һәм өлкәләр эшлеклеләренең РКП (б) ҮК тарафыннан уздырылган 4-киңәшмәсен әйтеп үтәргә кирәктер. Анда Сталинның Милли республикалар хокукын кысу сәясәте җиңеп чыга. Бу утырыш чынлыкта Үзәк Комитетның пленумы була, чөнки утырышта сәяси лидерларның барысы да диярлек катнаша. Чыгыш ясаучыларның күпчелеге Солтангалиевнең кулга алынуын хуплап сөйли. Һәм аңа карата каты җәза бирелүен таләп итә. Фәкать берничә кеше генә «Лубянка тоткыны»ның гаепле булуына шик белдерә һәм Үзәк Комитет алып барган сәясәт хакында җентекләбрәк сөйләшергә тәкъдим итә. Ләкин бу кыюсыз чыгышлар кискен рәвештә кире кагыла, ә Сталин, Куйбышев, Троцкий һәм утырышта рәислек итүче Каменев янаулардан да тайчынып тормыйлар. Соңрак Каменев Троцкийга Солтангалиевне сәяси эшлекле буларак юк итүдә Сталинга ирек бирүенә чын күңелдән үкенүе хакында әйтә. Чыннан да, нәкъ менә шушы утырыштан соң Сталин, үзенә ни кыланса да ярый, дип уйлый башлый. Ләки.. Л. Б. Каменевның күзләре тик иКе елдан, баш өстендә Сталин балтасының шәүләсе уйный башлагач кына «ачыла». Иосиф Сталин корбаннарын үзара дошманлаштырып берәм-берәм кыйнауның чын остасы була. Ул азат ителгән Солтангалиевне кабул итә һәм аңа берәр елдан партия сафларына яңадан торгызуда булышырга вәгъдә бирә. Ләкин 1924 елның декабрендә Үзәк Контроль Комиссиясе Солтангалиевнең үтенечен кире кага. Куйбышев, Ярославский һәм Шкирятовның Сталин каршында дер калтырап торулары яхшы билгеле булганга, аларның бу гамәлен Генсекның ихтыярын үтәү дип бәяләргә кирәк. Шуннан соң узган дүрт елда Солтангалиев сәяси сөргендә яши, Охотсоюзда йөреп эшләүче инструктор була. Тарихтан мәгълүматлары җитеп бетмәгән кайбер кешеләр һәм милли нигилизм авыруы тигән бәндәләр, еш кына Солтангалиевнең якты истәлегенә тап төшерергә маташып, аны фәкать Милләтләр буенча халык комиссариатының вак бер хезмәткәре генә булган, диләр. 1923 елга кадәр, ягъни кулга алынганчы, ул халык комиссары урынбасары, Милләтләр эшләре комиссариатының коллегия әгъзасы вазифаларын үти. 1920-1923 елларда Совет Көнчыгышыннан шундый югары урын биләгән башка милли эшлекле булмады дисәк, ялгышмабыз. 4-утырышта Солтангалиевне яклап ясаган чыгышы өчен Сталинның үпкә белдерүенә каршы Шәрекънең күренекле эшлеклесе Торар Рыскулов Үзәк Комитетның, Халык Комиссарлары Советының һәм Генсекның үзенең дә бу кешегә нинди зур ышаныч күрсәтүләре турында юкка гына әйтми.***

***Икенче мәгънәсез һәм зарарлы гамәлләр дә күренә башлады. Бүген кайбер галимнәр Солтангалиевкә хас булмаган сыйфатларны, эшләмәгән эшләрне аңа тагарга маташалар. Мисалга, бер брошюрада аңардан остазы М. Вахитов урынына мөселман хәрби коллегиясенең беренче рәисен «ясаганнар». Башка шундый тузга язмаган нәрсәләр дә җитәрлек. Солтангалиевнең якты истәлеге мондый күпертүләргә мохтаҗ түгел, аңа бутәннәр даны кирәкми.***

***Партиядән чыгарылгач, Солтангалиев иң вак чиновник дәрәҗәсенә төшерелә... Ләкин гомеренең шушы авыр һәм рухсыз елларында да ул, милли һәм сыйнфый мәнфәгатьләрне кушуның иң яхшы вариантларын, революция җиңелгән очракта көрәшнең яңа юлларын эзләвен дәвам итеп, доньядагы һәм илебездәге милли мәсьәләне тикшерү өлкәсендә теоретик эшчәнлеген туктатмый. Аның фикерләре үз вакытын күпкә узып китә. Чит илләрдәге иҗтимагый фикер вәкилләре***

*аны юкка гына өченче дөньяның «революцияләр атасы» дип атамыйлар. Колониализм хәрабәләрендә пайда булган яшь дәүләтләрнең кайбер җитәкчеләре дә Солтангалиевне юкка гына үзләренең остазлары дип санамыйлар. 1928 елның декабре. Казанда һәм Йошкар-Олада булып кайткан Солтангалиев Уфага үзенең соңгы командировкасына җыена. Ләкин яшьлеге каласына барып җиту, анда атасын һәм якыннарын күру аңа насыйп булмый. Удмуртия җирендә, Глазовта, ул кабат кулга алына һәм махсус сак астын а Мәскәүгә, таныш Лубянкага җибәрелә. Аны монда өч ай дәвамында «эшкәртәләр». Юк, ул чакта югары дәрәҗәдәге тоткыннарга карата кыйнау кулланылмый әле. Ләкин гаиләсенең һәм якыннарының алдагы язмышлары белән куркытып, тиешле мәгълүматлар алу инде гамәлгә кергән була.*

*Ниһаять, 1929 елның җәендә бирелгән сорауларга җавапларның бер өлеше сиңең алда, укучы. Алар 60 елдан артык дәүләт сере иде. Ә іе, Солтангалиев караш лары Сталин сәясәтенә туры килми. Ләкин аларда бернинди дә җинаять юк. Хәтта ул заман законнары буенча да.*

*Моннан берничә ел элек СССР Прокуратурасы һәм Дәүләт иминлеге Комитеты вәкилләреннән торган абруйлы комиссия «Солтангалиев эше»нең ОГПУ тарафыннан оештырылуын ачыклады. Комиссиянең материалларын карагач, СССР Югары суды моның белән килеште һәм М. Солтангалиевне тулысынча аклады.*

Б. СОЛТАНБЕКОВ.
Д. ШӘРӘФЕТДИНОВ.

# Мирсәет Солтангалиев

## МИН ЯЛГЫ ШТЫММЫ?

**(1929 ЕЛНЫҢ 27 ФЕВРАЛЕНДӘ ВКП(б) ҮЗӘК КОНТРОЛЬ КОМИССИЯСЕНӘ БИРГӘН ҖАВАПЛАРЫМ)**

...Ә хәзер исә шәхсән үзем башкарган оештыру эшләренә күчәм.

Алдан ук әйтүемчә, минем бу өлкәдәге хезмәтемне «уңнар»ның гомуми эшеннән аерып карарга кирәк. «Уң коммунистлар' төркеме куйган конкрет максатлардан һәм бурычлардан шактый киң булганга, минем эшчәнлегем тар партия кысалары белән генә чикләнмәде, аннан читкә дә чыкты. Татарстан һәм Кырым кебек аерым төбәкләрдә, милли мәсьәләдә булсын яки конкрет эшләрдә, «уңнар»ның программ бурычлары һәм максатлары минем программам белән тулаем колачланды, ләкин аны тулаем ачып сала алмады. Аерым өлкәләрдә мин алардан алгарак киттем. Ләкин, вакыйгалар агымыннан чыгып, мин ахыр чиктә программам акрынлап «уңнар» программасына да кертелер, дип өметләндем. Бу җәһәттән әле күбрәккә дә исәп тоттым: тора-бара шушы программага «сул» коммунистларның да шактый гына өлеше кушылыр, дип уйладым.

Мин түбәндәге мәсьәләләрдә «аһыктым».

1. **Россиядә социалистик революциянең язмышы мәсьәләсендә.**

Көнбатышта капитализмның хәле тотрыклануга, Көнбатыш Европа пролетарияты арасында социаль-демократиянең позицияләре көчәюгә һәм аерым эчке каршылыклар килеп чыгуга бәйле рәвештә Россиядә социалистик революциянең үсеше котылгысыз рәвештә һәлакәткә очрар, дип фараз иттем. Россиядә революцияне ике юл белән юк итәргә мөмкин икәнлекне аңладым: беренче юл — эчке һәм тышкы фронтларда төрле ташламалар ясарга мәҗбүр булган коммунистлар партиясенең һәм Совет властенең акрынлап дәүләт капитализмы һәм буржуаз демократия юлына басуы; икенче юл — Совет властеның дөнья буржуазиясе белән кораллы бәрелеше нәтиҗәсендә тар-мар ителүе. Оппозициядән аермалы буларак, беренче очракта да, икенчесендә дә, бу һәлакәтне вакытлы хәл дип санадым. Революция җиңелгәч, беркадәр вакыттан соң аны, күп кенә капиталистик

дәүләтләрне һәм колониаль илләрне дә колачлап, тагын да зуррак күләмнәрдә кабатланачак, дип уйладым. Ул гына да түгел, беренче социалистик революция никадәр шау-шу белән тар-мар ителсә, икенчесе шулкадәр тизрәк киләчәк һәм аның иҗади куәте дә гаять зур булачак. Һәр ике очракта да революциянең җиңелүе Совет власте чорында үзләренең мөстәкыйль яшәүгә хокуклары чынлыкта ни дәрәҗәдә булуына бәйсез рәвештә, үзбилгеләнгән милли районнарны янадан колония хәленә (яисә «бердәм һәм бүленмәс» составында, яки «мандат нигезендә» теге яки бу капиталистик держава тарафыннан идарә ителә торган территория сыйфатында) төшерер иде. Менә шуннан соң бу районнарда революция вакытлыча чигенеп, аның урынына җирле милләтчелек килергә тиеш. Аңа таянып, реакция белән көрәш алып бару мөмкинлеге туар иде. Соңгы минутта, хәл ачыклангач, партия Үзәк Комитеты бу мәсьәләдә үзе дә безгә мөрәҗәгать итәр, дип уйладым. Бу фикерне җирле партия даирәләрендә 1921-1922 елларда, яңа икътисади сәясәткә (НЭП) күчү һәм беренче партдискуссия вакытында партиядә бүленү куркынычы килеп тугач ук пропагандаларга керештем. Ул чакта мәсьәләне революциянең җиңелүе «котылгысызлыгы» яссылыгында түгел, ә «җиңелергә мөмкин» булуы яссылыгында куйдым. Милли республикаларның автоном хокукларын, аерым алганда исә, аларның икътисади һәм мәдәни үсешләрен киңәйтүне таләп итеп, без нәкъ менә күздә шуны тоттык та. Бу мәсьәләләр 1922 ел ахырында Советларнын X съездында һәм соңрак партиянең XII съездында күтәрелде.

Беренче мәсьәләдә «вакыйгаларны ашыктыруым» СССРда төрки халыклар проблемасын конкретлаштыруда да ашыгычлык китереп чыгарды. Моңа өч фактор сәбәп булды:

а) Рим, Гарәп, Чыңгыз хан, Тимер һәм Госманлы империяләре кебек, узганның күпсанлы дәүләтләре мисалында, Россиянең дә мөстәкыйль милли дәүләтләргә таркалачагы тарихи котылгысызлык. Россиядә социалистик революциянең һәм урыс дәүләтенең шул рәвешле үсүе беренче чиратта Совет дәүләтенең федератив, ә икенче чиратта Совет Социалистик Республикалары Союзы рәвешендә төзү фикерен тудырды да төсле. Череп бара торган күп милләтле һәм ярымфеодал-капиталистик дәүләттә социалистик революция проблемасын киңәйтү буенча Ленинның планы нәкъ менә шуңа кайтып кала да иде. Ильич Россиядә «милли мәсьәләне бетерергә түгел», ә «хәл итәргә» кирәклеген яхшы аңлады. Татар республикасы игълан ителер алдыннан без Ильич янында булдык. Сәетгалиев шул чакта: «Татар мәсьәләсен, ниһаять, бетерергә кирәк»,— диде. Моңа каршы Ленин: «Бетерергә түгел, ә хәл итәргә кирәк»,— дип җавап бирде. Бу Ленинның үз теле белән әйтелгән сүзләре. Моны мин урыс дәүләтенең таркалу процессын «туктатырга» маташмыйча, революция мәнфәгатьләренә туры китереп җайга салырга кирәк гамәл дип аңладым. Шуннан чыгып, Совет Социалистик Республикалар Союзын Конституциядә иң әүвәл теркәлгән рәвештә, ягъни фәкать РСФСР, Украина, Белоруссия, Кавказ арты республикалары составында гына игълан итү СССРдагы аерым районнарның милли аерымлану мәсьәләсен хәл итми, дигән фикергә килдем. Аңлаешлырак булсын өчен ул чакта Үзбәкстан һәм Төрекмәнстан союздаш республикаларының әле яшәмәвен, ә РСФСР составында Төркестан АССРның гына булуын әйтеп китәргә кирәктер. Шуңа күрә, СССР игълан ителгәч, андагы төрки халыкларны мөстәкыйль дәүләтләр итеп бүлеп чыгару проблемасын да кичектермичә хәл итәргә кирәк, дип уйладым.

б) СССРдагы төрки халыкларны һәм алар белән чиктәш Шәрекъ мәмләкәтләрен (Кытай Төркестаны, Әфганстан һәм Иранның төрки районнары) бер дәүләт итеп берләштерүнең тарихи зарурлыгы һәм котылгысызлыгы. Моңа озак тукталып тормыйм. Бу — төркиләр яши торган төбәкләрдә борынгы феодал строе таркалып, капитализмның үсеп китүе белән бәйле күренеш. Россиядәге социалистик төзелеш бу процессны көчәйтте һәм тирәнәйтте генә. Эчке хасияте белән чын революцион һәм прогрессив хәрәкәт булганга, дөньяда аңа каршы тора алырлык көч юк, дип уйлыйм. Аны сузарга, «тоткарлап торырга» мөмкин, ләкин юк итеп булмаячак. Туып килә торган төрки милли буржуазия бу тарихи процессны үз мәнфәгатьләрендә файдаланырга омтыла. СССРдагы кан-кардәшләрен Совет властеннан һәм социалистик революциядән «азат итү хакында» өндәмәләр ташлый. Буржуаз-милли хәрәкәт буларак, пантюркизмның асылы да нәкъ менә шунда. Ә мин исә СССРда һәм аңа чиктәш көньяк-көнчыгыш дәүләтләрдә төрки халыкларның берләшүгә омтылуы социалистик революция тарафыннан Урта Көнчыгышта үзенең икътисади, сәяси

һәм стратегик позицияләрен ныгыту өчен файдаланыла алачак һәм файдаланырга тиеш, дип уйладым.

в) Соңгы елларда Шәрекътәге революцион хәлләр аерым колониаль һәм ярымколониаль илләрдә (Кытай, Һиндстан) милли-азатлык хәрәкәтенең сүнә баруы, ә халыкара империализмның ныгуы хакында сөйли. Уемча, бу хәл Кытай һәм Һинд-Әфганстан тарафыннан Урта Азия һәм, гомумән, СССРдагы төрки районнарга куркыныч тудыра. Ә моңа бәйле рәвештә төркиләр проблемасы тагын да кискенләшә һәм кискенләшәчәк тә. Шуңа күрә Совет власте һәм партия бу юнәлештә максатчан эш җәелдерер һәм төрки халыкларны ыру-кабиләләренә карап вак-вак өлешләргә бүлү сәясәтенә чик куелыр, дип өметләндем. Ә болай эшләмәгәндә, реакция килгән очракта, вак «мөстәкыйль» төрки дәүләтләрне берәм-берәм кабып йоту аңа һич тә кыен булмаячак. Кыскача гына әйткәндә, Совет властена Кытай һәм Һиндстан ягыннан халыкара империалистик көчләр һөҗүме була-нитә калса, аңа каршы көчле һәм нык буфер дәүләт — Төрки Совет Республикалары Федерациясе каршы куелырга тиеш дип уйладым. Соңгысының исә Украина белән бертигез хокукларда Союз составына керүе зарури иде.

Менә шушы өч нәрсәдән чыгып, революциянең җиңелүе очрагына әзерләнү йөзеннән, Федератив Совет Социалистик Республикасы сыйфатында Советлар Союзы составына кергән, дәүләт капитализмына нигезләнгән халык-демократик республикасы рәвешендәге Туран дәүләтен төзү фикерен алга сөрдем. Бу бердәмлекнең мөстәкыйль булуы реакциягә каршы киң халык күтәрелешләрен оештырырга мөмкинлек биргән булыр иде. Ә моны, чыннан да, көн тәртибеннән төшереп калдырырга ярамый, чөнки революция җиңелсә, халыкара буржуазия, стратегик мәнфәгатьләреннән чыгып, «Россия территориясенең бүленмәслеген саклау» өндәмәсен ташламас, ә милли буржуазия урыс капиталистлары белән килешүгә бармас һәм үзенең «милли» аппетитын буржуаз «автономия» белән чикләмәс, дип кем ышанып әйтә ала? Фаразым буенча, мондый күтәрелешләрне җирле милләтчеләрнең экстремистик өлеше белән бергә «уңнар» битлеге астына яшеренгән урындагы коммунистлар житәкләргә тиеш. Алар үз гамәлләрендә крестьяннарга, эшчеләргә һәм шәһәрнең вак буржуасына, башлыча һөнәрчеләргә һәм кустарьларга таяна ала. Җирле зыялыларны исә түбәндәгечә бүлдем:

а) чиновниклардан торган иске, урыслашкан «милли» зыялылар. Сан ягыннан алар күп түгел һәм тәмам бетеп баралар. Бу затлар элек башлыча җирле дворяннардан укмашты һәм революция вакытында «аклар» ягында эшләде. Болар — җирле феодализм калдыклары. Максатларыма бөтенләй ярамаслык булганга, аларны тулаем кире кактым. Революция җиңелгән очракта «зыялылар»ның бу төркеме җирле монархистларга таяныч булып кына хезмәт итә ала.

б) вакытында төрки халыклар арасындагы җәдитчеләргә каршы көрәшкән иске реакцион зыялылар. Алар патша охранкасына тугры хезмәт итеп килделәр һәм Татарстан, Башкортстан кебек төбәкләрдә тәмам бетүгә таба баралар. Ләкин Урта Азия якларында, бигрәк тә Бохара тирәләрендә, алар шактый күп әле. Башлыча иске руханилардан торган бу «зыялылар» төркеме дә максатларым өчен ярамый иде. Татарстанда һәм Башкортстанда алар урыс монархиясенә йөз тотса, Урта Азиядә хан хакимиятен яклап чыгачак иде.

в) революциягә кадәр төрки халыкларның мәдәни-ислах хәрәкәтен җитәкләгән «җәдитчеләр». Болары вак буржуа зыялылар. Төрки халыкларның милли-азатлык хәрәкәте кысаларын башлыча мәдәни тәрәккыять белән генә чикләгәнгә, аларны да кире кактым, фикерләрен хыялый һәм тормышка ашырып булмый торган нәрсә дип уйладым. Әгәр мөмкинлек бирелсә, бу зыялылар фәкать милли-мәдәни автономия таләп итүдән дә ерак-карак китә алмаслар иде.

г) буржуаз зыялылар — сәяси көрәшкә сәләтсез һәм сатлык булганга, аларны да кабул итә алмадым. Буржуаз стройны торгызырга дигәндә бу халык, минемчә, теләсә кемгә иярергә мөмкин. Ул урыс милләтчеләре белән төрле кабахәт килешүләргә барырга, бер тиен бакыр хакына аңа хезмәт итәргә әзер.

д) шәһәр һәм авылның хезмәт халкы катламыннан чыккан, беркадәр революцион чирканчык алган һәм күпмедер дәрәҗәдә марксистлар мәктәбен узган яңа яшь совет зыялылары. Бу төркем, башлыча, укучы яшьләрдән тора. Яңа партиянең зыялыларын мин нәкъ менә шуннан табарга уйладым да.

Партия большевизмның оештыру принциплары буенча төзелергә тиеш иде. Анда барлык төрки халыклар вәкилләрен дә мөмкин кадәр күбрәк кертергә кирәк, дип санадым.

Инде күрсәтеп үткәнемчә, яңа партиянең төп кадрлары «уңнар»дан һәм алар лагерена күчкән яки күчә торган җирле «сул» коммунистлардан оешырга тиеш иде. Шул ук вакытта «уңнар» социалистик революциянең җиңелүенә кадәр уртак компартиядә калырлар, дип фараз кылдым. Гадәттән тыш хәл килеп чыккан очракта алар, уемча, оештыру ягыннан өч төп төркемгә бүленергә тиеш иде: аның бер өлеше уртак компартия белән идән астына китәргә, икенчесе — мөстәкыйль җирле коммунистлар партиясе булып укмашырга (уртак компартиядәге бәла-казадан качар өчен) һәм өченчесе — ачыктан-ачык эшли торган Туран эшче-крестьяннар социалистик партиясендә яшерен эш алып баручы өлешенең үзәген тәшкил итәргә тиеш иде. Шәхсән үзем хакында әйткәндә, хәлләр соң дәрәҗәдә киеренкеләнгәч һәм, ул бар кешегә булмаса да, компартиянең житәкче даирәләренә тәмам ачыклангач, соңгы минутта Үзәк Комитет белән килешергә мөмкин булыр һәм ул минем программамны кабул итәр, дип өметләндем. Шуннан соң яңадан партия сафларында торгызылып (ул чакта үзара «үпкәләр» онытылыр һәм миңа ышаныч күрсәтелер, дип уйладым) подпольедан торып үземә ярдәмгә бирелгән иптәшләр белән бергә җирле коммунистларның өч төркеменең өчесендә дә яки «сул» төркемнәрнең икесендә эшләргә кирәк, дигән фикергә килдем. Болар бар да капиталистик дөнья белән кораллы бәрелеш нәтиҗәсендә Совет властена үлем куркынычы янаганда гына эшкә ашырылырга тиеш иде. Ә компартия һәм аның белән бергә Совет власте да үзләренең үсешләрендә капитализм юлыннан киткән очракта (хәзер сез аны партиядәге уң куркыныч дип атыйсыз. жирле «уңнар»ның беренче төркеме компартиядәге сул оппозиция белән идән астына китәргә тиеш иде. Эшләр болайга борылганда, планым буенча, кораллы күтәрелеш оештыру һәм шушы максатларда мөстәкыйль Туран Республикасы өндәмәсен күтәрү, үзен ничек атаса да, капиталистик юлдан киткән хакимияткә каршы юнәлдерелер һәм анда Россиядән тулысынча мөстәкыйль дәүләт булып аерылып чыгу таләбе куелыр иде. Партиянең һәм Совет властеның хәзерге халәтен мин әле берничек тә билгели алмыйм, алар большевизм идеалларына тугрылыклы калдымы-юкмы — әйтә алмыйм. Бер нәрсә ачык, бүген партия һәм дәүләт аппаратындагы кайбер буыннарда революция идеяләреннән читләшү күзгә күренеп тора. Мәгълүм уңай шартлар туган очракта, ул тулаем үзенең йөзен югалтырга һәм моның белән чын буржуаз реакциянең тантанасына җирлек булып хезмәт итәргә мөмкин. Алга китеп булса да әйтәм, партия бу бәндәләрне юк итү өчен үзендә кирәкле күләмдә көч тә, ихтыяр да тапты һәм минем фикерләремнең ялгыш булуын раслады. Мин монда Үзәк Комитетның ноябрь пленумын һәм алга таба партия тормышының үсешен күздә тотам.

Мөстәкыйль партия, дөресрәге аның состав өлешләрен, төзү буенча мин киң һәм әзлекле эш алып бармадым. Беренчедән, мине бу гамәлдән пролетар революциянең характеры һәм киләчәге хакында үзем ясаган анализның һәм нәтиҗәләрнең дөреслегенә шикләнү тотты. Дөресен әйтергә кирәк, Көнбатышта революцион конъюнктураның (1923 елдагы Германия революциясе, 1925 елда инглиз шахтерлары стачкалары) һәм Көнчыгыштагы хәлләрнең (Кытай революциясе — Шанхай пролетариатының җиңүле восстаниесе) бер тукталмый үзгәреп торуы мине шактый аптыраштa калдыргалады. Икенчедән, мин иртәме-соңмы партия сафларына кайтырмын, дигән өмет белән яшәдем. Өченчедән, партиядә вакыт-вакыт барлыкка килгән оппозиция, җирле оешма төземичә дә, мин теләгән сәяси эшне алып барырга мөмкинлек бирер, дип уйладым. Соңгысы, минемчә, аеруча әһәмиятле. Чөнки әгәр еш кабатлана торган мондый оппозицияләр булмаса, тәмам төзәлеп җиткән партияле буларак, мин хаталарымны таныр идем яисә СССРдагы яшәп килгән компартиягә һәм колониаль оппозициягә — Коминтернга каршы милли оппозиция төзү буенча яшерен эш алып баруымны кинәйткән булыр идем. Аларның берсе икенчесенә нык бәйләнгән иде шул. Бу хакта сорау алуның беренче көннәрендә үк сөйләгән идем инде. Ләкин ахыр чиктә беренче юлдан киткән булыр идем, дип уйлыйм.

Партияләләр арасында эшемне фәкать татар, Казан даирәсе белән генә чикләдем. Кырым беренче планда түгел иде. Башта шушы җирләрдә әзерлек эшләре алып барырга, аерым эшлекләләрнең аңын тиешле бер дәрәҗәгә җиткерергә һәм фәкать шуннан соң гына алар аша үз йогынтымны башка төбәкләрдәге милли эшлекләләргә җиткерергә уйладым. Шулай да беренчеләренә тәэсирем йомшак булды төсле. Бу җәһәттән «эшчәнле-

гем» билгеле бер кысалар белән чикләнгән иде. Сезгә алар хакында сөйләдем инде.

Партиясезләр арасында алып барган оештыру эшем дә алай нәтиҗәле булмады. Ул башлыча Казан һәм Әстерхан студентлары белән генә чикләнде диярлек. Казандагы яшерен түгәрәк белән 1926 елның көзендә Бакиев, ә Әстерханныкы белән 1927 елның көзендә Шәрекъ этник мәдәниятләре фәнни-тикшерену институты аспиранты Шәмсетдинов Вәзыйх аша элемтәгә кердем. Юныс Вәлидев монда булганда Мәскәүдә дә пропагандистик түгәрәк оештырырга маташып карадык. Ул, үз чиратында, партиядән куылганчы Тимирязов исемендәге авыл хуҗалыгы Академиясе студентлары белән бәйләнеш тота иде. 1924 елда, Татарстанда «уңнар» эш башыннан киткәч, Юныс Вәлидев партиядән чыгарылгач, бу хакта без бер төркем студентлар белән сөйләшүләр дә алып бардык. Беренче тапкыр Мәскәү тирәсендәге дачаларның берсендә, Пушкинода булса кирәк, очраштык. Хәзер төгәл генә хәтерләмим инде. Безне Академиянең соңгы курсы студенты Шахмәмәтев чакырды кебек. Ул үзе әллә элеккеге партия әгъзасы, әллә комсомол оешмасын житәкләгән кеше — анык кына әйтә алмыйм. Шахмәмәтевтән, миннән һәм Юныс Вәлидевтән кала, сөйләшүләрдә шул ук Академиянең югары курс студентлары партиясез Хаҗаев (Әстерхан) һәм Хантимерев (Саратов) катнашты. Бу җыен безнең тәкъдим белән чакырылды. Без дачалар артындагы кырда сөйләштек. Сүз, башлыча, көннән-көн көчәя барган урыс милләтчелегенә каршы көрәшне җанландыру өчен татар һәм, гомумән, Шәрекъ студентлары арасында пропагандистик түгәрәкләр оештыру кирәклеге хакында барды. Урыс милләтчелегенә «панрусизм» дигән билгеләмә бирдек. Студентлар безнең чынлыкта коммунистлармы, әллә милләтчеләрме булуыбызны ачыклауны сорадылар. Моңа каршы, партиядән чыгарылуыбызга карамастан, коммунист булып калуыбызны әйттек: «Фәкать милли мәсьәләдә генә безнең аерым үз фикеребез бар, революциядә милләтләрнең сәяси һәм икътисади хокукларын киңәйтүне таләп итәбез», — дидек. Студентлар үзләренә боларның мәгълүм түгеллеге, мәсьәләне бөтенләй башкача аңлаулары хакында әйттеләр һәм моңа кадәр бу эш белән таныш булмаганга, студентлар арасында нинди дер эш алып бару турында әйтергә кыенсынуларын белдерделәр. Сүз шуның белән тәмамланды. Ләкин Вәлидев белән миндә, алар икейөзле бәндәләр түгелме икән, дигән шик калды. Чөнки шул ук көнне, шул ук дачада, кыяфәтенә караганда кем артыннандыр күзәтә бу дигән тәэсир калдырган агентыгыз Агеевны ике тапкыр очраттык. Аның монда юкка гына йөрмәве безгә бик яхшы аңлашылды. Сез бу очрашу хакында белгәнсез дә, ул булырмы-юкмы икәнен төгәл ачыклап кайту өчен, аны җибәргәнсез, дип уйладык. Шәхсән үзем, сезгә бу хакта Шахмәмәтев тишкәндер, дигән фикергә килдем. Чөнки ул, беренчедән, очрашуны үзе оештырып йөрде, икенчедән, без сөйләшкәндә ләм-мим дәшмәде. Шуңа күрә саграк булырга карар бирдек.

Икенче очрашуыбыз берничә айдан соң Нескучный бакчасында булды кебек. Бу юлы очрашуга Шахмәмәтев, аның әле генә Мәскәү университеты медицина факультетын тәмамлаган энесе Рәүф, Юныс Вәлидев һәм мин килдек. Башка кеше булганын хәтерләмим. Хантимерев янсә Хаҗаев килергә мөмкин иде. Төгәл белмим. Бу юлы сүз Рәүф Шахмәмәтевне Казанда эшләү өчен файдалану (ул анда эшкә китәргә җыена иде) һәм безнең программабыз турында барды. Рәүф Шахмәмәтев безнең алга саф милләтчелек рухындагы фикерләрне куйды. Без Юныс Вәлидев белән моңа каршы чыктык, үзебезнең коммунист булып калуыбызны һәм ул социалистик революцияне, Совет властен тулысынча кабул иткән, милли мәсьәләдә безнең карашларда торган очракта гына хезмәттәшлек итәргә әзер булуыбызны әйттек. Шахмәмәтев белән без күпмедер вакыт качышлы уйнадык һәм, ниһаять, аңа үзебезнең шигебезне әйттек. Ул үзенең сезнең белән бәйләнештә булуын кискен рәвештә инкарь итте. Юныс, аңа ышанырга кирәк, диебрәк сөйләнде, шуннан файдаланып Шахмәмәтев судка кадәр дә, суд вакытында да аның янына килеп йөрүен дәвам итте. Эшне тикшергәндә үз-үзеңне ничек тотарга кирәклеге хакында киңәшләр бирде. Ә мин исә ышанмадым һәм үземнең шикләремне З. Грзина аша Сезгә дә җиткердем. Ул чакта сүз тагын бер партияле студент турында да барды. Ул үзе Бөгелмәдән, фамилиясен хәтерләмим. Студентлар тулай торагында танышып киткәч, ул безгә килеп-китеп йөри башлады. Ә шул очрактан соң фатирыма юлны бөтенләй онытты. Дөрес, Шахмәмәтевкә бу хакта бер сүз дә әйтмәдем, ләкин очрашкан чакларыбызда без фәкать юк-барны гына сөйләшә торган булып киттек.

Хантимерев белән Хажаевка килгәндә, Вәлидев хөкем ителгәннән соң, алар милли районнарда бәйсез республикалар төзү өчен киң хәрәкәт оештыру турында безнең программаны уртаклашмаулары, ә төрки халыкларының яшәп килгән чикләрдә, партия һәм Совет власте тарафыннан бирелгән хокуклар күләмендә эволюцион үсешен яклаулары һәм без тәкъдим иткән юнәлешләрдә пропагандистик эш алып барудан баш тартулары хакында белдерделәр. Шул ук вакытта алар икесе дә бөтен көчләрен авыл хуҗалыгын күтәрү мәсьәләләренә һәм фәнни эшкә бирергә җыенуларын әйттеләр. Хантимер исә үзенең безнең сафларга басарга җыенмавын 1918 елда күпмедер вакыт мобилизация буенча акларда хезмәт итүе белән дә аңлатты. Соңгарак калып булса да әйтелгән бу хәбәре өчен рәхмәт белдердем һәм алга таба аның белән барлык сәяси бәйләнешләремне өздем. Соңрак 1926 һәм 1928 елларда Казанга командировкага килгәч, Бакиевтан һәм аның белән бәйләнештә торган студентлардан Хажаев белән Хантимернең эшчәнлеге хакында сораштым. Моңа каршы алар тискәре җавап бирделәр һәм соңгыларының үзләрен «эшкә тартырга» тырышуга каршы килгәннәрен әйттеләр. Казанга соңгы килүемдә телефон аша Хантимернең хәлләрен сораштым. Ул үзенең быел җәй Әзәрбайҗанда булуын һәм аннан тәмам «сулланып» кайтканын әйтте. Аңардан: «Ленинчы булдыңмыни?» — дип сорадым. Хантимер көлеп куйды һәм: «Ленинчы гына түгел, ә гомумән...» — дип җавап бирде. Сүз шуның белән тәмамланды.

Казанның партиясез студентлары белән элемтәләрем 1926 елның язында башланды. Бу хакта бер яшь татар эшчесе аша миңа Казан университеты клиникасы ассистенты — үзе әйтүенчә, милли тайпылышы өчен партиядән чыгарылган Бабиков мөрәҗәгать иткән иде. Чынлыкта бу партиясез Казан студентларының турыдан-туры минем белән бәйләнешкә керергә омтылыш ясауларының икенчесе иде. Алар беренче мәртәбә судтан соң, 1925 елның язында мөрәҗәгать иттеләр. Ул чакта ниндидер яшерен татар студентлары түгәрәге исеменнән Вәлидев янына Казан авыл хуҗалыгы институты студенты Фәйзуллин килгән булган. Соңрак ул Киев түгәрәгенә әләгә һәм алар белән элемтә урнаштырырга тәкъдим итә. Мин аның белән очрашудан баш тарттым һәм Юныс Вәлидевкә дә шуны ук киңәш иттем. Боларның барысы да безне партиясезләр белән бәйләнешта тотар өчен сезнең тарафтан эшләнә дип уйладым. Ләкин Вәлидев мине тыңламады һәм, тәкъдимнең асылында ни ятуын ачыклар өчен, очрашуга китте. Аннары ул бу сөйләшү хакында төкми-чәчми миңа җиткерде. Аның сүзләренә караганда, ул Фәйзуллинны тыңлаган, ләкин тәкъдимгә карата шиге булуын әйткән һәм Казанга барып бу түгәрәкнең нинди икәнен белми торып бер гамәл дә кылынмаячак, дип белдергән.

Вафат булуы сәбәпле Ю. Вәлидев «түгәрәк» белән таныша алмый калды.

Инде әйткәнемчә, Казандагы икенче кеше табиб Бабиков иде. Мине аның белән Химтрест заводларының берсендә эшләүче Җиһанша Енаев таныштырды. Соңгысын 1919 елдан, ул әле Комнарвостокта товар белгече булып эшләгән чагыннан ук белә идем. Енаев Бабиковны бала чагыннан ук беләм диде, шуңа күрә аңа ышанарак төштем. Бабиков сүзнең башында ук үзенең яшерен рәвештә эшли торган татар студентлары түгәрәгенең вәкиле булуын һәм миннән революциянең язмышы, милләтчеләр арасында эшне нинди юнәлешләрдә оештырырга кирәклеген белү өчен җибәрелүен әйтте. Аңа берничә сорау бирдем, шул исәптән, Фәйзуллин турында, Казанда партиясезләр арасында нинди дә булса түгәрәк эшләмиме, әгәр эшләсә, алар җирле «уң» коммунистлар белән элемтә тотмыймы, дип кызыксындым. Бабиков боларның барысына да «юк» дип җавап бирде. Ә мин, үз чиратымда, тиешле нәтиҗәләр ясадым. Беренчедән, түгәрәкләр яши икән, ул милли зыялыларның Татарстандагы хәлләрдән һәм тәртипләрдән канәгать булмавын күрсәтә.

Икенчедән, бу «түгәрәкләр» белән бер генә сәяси көчләрнең дә җитәкчелек итмәвен аңладым. Һәм, иң мөһиме, Бабиковның сезнең тарафтан җибәрелгән кеше булуын төшендем. Ләкин, шулай да, аны кызыксындырган сорауларга туры җаваплар бирүне кирәк таптым. Әгәр алар Бабиков аша сезгә дә мәгълүм булса, һич тә зыян итмәс, киресенчә, Татарстанда һәм милли республикаларда иҗтимагый-сәяси тормышны җанландырып кына җибәрер, дип уйладым. Партия һәм Совет власте, хәлләрне белеп, аларны җайга салу өчен тиешле гамәлләр кылырга алынмасмы, дигән өмет тә бар иде. Бабиков белән ике-өч сәгатьләп сөйләштем. Аңа Россия революциясе, Кытай инкыйлабы, халыкара күтәрелештә милли мәсьәләнең әһәмияте һәм

роле, моңа карата үземнең фикерләрем хакында бәян иттем. Үземнең милли мәсьәләдә партия белән килешмәвемне дә яшереп тормадым. Сүз «уңга авышу» аркасында революциянең җиңелергә дә мөмкин икәнлеге хакында да барды. Бу очракта башланып китәчәк реакциягә каршы оешкан төстә каршылык күрсәтүнең зарурлыгы хакында әйтелде. Революция җиңелә калса, урысның карагруһ монархистик оешмалары, Казанны, Татарстанның, Башкортстанның районнарын кулга төшереп, татар халкын суюны оештырачагына һич тә шигем юк иде. Әлбәттә, беренче чиратта, алар зыялыларны юк итәргә керешәчәкләр, дип уйладым, чөнки аларның барысы да диярлек Совет властен яклап чыкты һәм аны ныгыту өчен, шактый зур көч куйган иде. Бу суешны булдырмый калу өчен, беренче чиратта, яшерен милли революцион оешма төзергә һәм реакция башланганны көтеп тормыйча, милли районнарны бәйсез дәүләтләр дип игълан итәргә кирәк, дигән фикердә тордым мин. Теге яки бу сәбәп аркасында бу эш барып чыкмаса, җирле халыкның баш күтәрүен оештыру максатка яраклы булыр, дип фараз иттем. Шулай итеп, кайсы очракта да революцион көчләрнең төп өлешен алдан әзерләп кую муафыйк иде. Шунан чыгып, татар табибларыннан оешкан түгәрәкне саклап калу һәм аның эшчәнлеген тагын да киңәйтү ягында тордым. Ләкин түбәндәгеләрнең үтәлешен шарт итеп куйдым: «беренчедән, яшерен сәяси эш һич тә Совет властена һәм компартиягә каршы юнәлгән булырга тиеш түгел. Безгә бөтен көчебезне милли төбәкләрдә туып килгән бөек урыс милләтчелегенә каршы куюга, аның җирле партия һәм совет аппаратына йогынтысын йомшартуга бирергә кирәк.

Икенчедән, түгәрәк хәзерге вакытта эшчеләр һәм крестьяннар арасында фәкать пропаганда гына алып бара һәм акрынлап куәтле сугышчан революцион оешма төзүгә юл тота. Совет властен яклау өндәмәсенә, аның аерым чаралары безгә ошаса яки ошамаса да, һәм кайбер төркемнәрнең аңа карата нинди мөнәсәбәттә торуына карамастан, ахыргача тугры калу, аны сүздә генә түгел, эш белән дә раслау кирәк, дигән фикерне үткәрдем.

Иң ахырда, Совет властена һәм компартиягә каршы агитация фәкать алар үз мәсләкләреннән тайпылган очракта гына башланырга мөмкин, дип өстәдем.

Моңа каршы Бабиков ләм-мим дәшмәде. Соңрак Бакиев белән элемтәгә кердем һәм аңардан Казанда студентларның яшерен түгәрәге эшләве хакында белдем. Аннары, җаен туры китереп, шундый ук түгәрәкнең табиблар арасында да булуы белән кызыксындым. Бакиевның җавабыннан Бабиковның бернинди түгәрәккә дә кермәвен, җәмәгать эшлеклесе буларак Казанда бөтенләй мәгълүм кеше түгел икәнен аңладым. Минә шуннан соң инде аның провокатор, сезнең тарафтан җибәрелгән кеше булуына тәмам ышандым. 1928 елның язында Бабиковны кабул итмәдем һәм аның белән сөйләшүдән баш тарттым.

Ә хәзер Бакиевка һәм аның «түгәрәгенә» күчәм. Бакиев белән нинди шартларда очрашуым хакында сөйләгән идем инде. Тагын бер кат искә төшереп китәм: бу бәндә белән Октябрь революциясеннән соң татар милләтчеләренә каршы көрәш кызып җиткән бер заманда таныштым. Аны Казан мөселман социалистлары комитеты органы булган «Кызыл Байрак» газетасы мөхәррирлегеннән төшергәннәр иде инде. Сөйләшә торгач, Бакиевның әле 1919 елда ук Исмәгыйль Рәхмәтуллин һәм аның компаниясе тырышлыгы белән партиядән дә чыгарып атылуы ачыкланды. Бу хакта ул гаҗизләнеп сөйләде, үзенә инде фиркагә кире кайту өчен барлык юлларның да ябылуын әйтте.

Алга таба ул Татарстанда җитәкче урыннарда утыручы татар коммунистларының, аерым алганда Габидуллин төркеменең, эшеннән канәгатьсезлек белдерде. Ул чакта соңгылары үзләрен «урталыкта торучы суллар» дип атыйлар иде. Ләкин Бакиев «ультра суллар»га да үзенең тискәре мөнәсәбәттә торуын әйтте. Ул «уңнар» саналучы Исхак Казаковтан, Ганиевтан да канәгать түгел икән. «Сул»ларның Фатыйх Сәйфи, Габидуллин кебекләрен ул карьеристлар яки партиядә торуларын үз максатларында файдаланучы авантюристлар, дип санады. Татарстандагы хәлләргә ул тискәре бәя бирде һәм «сул»ларның гамәлләре белән Совет властен, партияне хакарәт итүләрен генә әйтте. Аның уйлавынча, болар бар да урыс халкы арасында милләтчелек хисләрен кабызуга китерә икән.

Очрашуларның берсендә ул үзенең Казанда оешкан яшерен түгәрәккә йөрүен һәм аңа миннән күп кенә мәсьәләләр буенча фикерләремне белү бурычы йөкләнүен әйтте. Миңа үз вакытында Бабиковка сөйләгәннәрне яңадан бәян итәргә туры килде, тик бу юлы күп кенә мәсьәләләргә киңрәк тукталынды. Мин дөньядагы революцион хәрәкәткә мөнәсәбәтемне

белдергәч, халыкара империализмның һөҗүмнәре яки партиянен үз мәсләген үзгәртүе нәтиҗәсендә аның тар-мар ителү куркынычы барлыгын әйттем. Менә шушы шартларда яңадан торгызылачак буржуаз-монархистик стройга каршы тору өчен халыкны кораллы сугышка күтәрергә туры киләчәк. Ә моны фәкать милли җирлектә генә оештырып була. Һәм шуңа күрә төрки халыклардан торган берлек — Туран халык-демократиясе республикасын төзү иң мөһим бурыч дип аңлаттым. Чыннан да, совет властен алыштырган буржуаз хөкүмәтне нығыту һәм Шәрекъ мөселманнарының сәяси яктан үсеп, ныгып китүеннән курыккан Европа империализмы Россиядәге көнчыгыш районнарның аерылып чыгуын хупламаячак. Аларның Шәрекъкә бәйсезлек дигән өндәмәләре фәкать уен гына, иртәгә үк капиталистлар аңардан баш тартачак, дигән фикерне уздырдым. Минем уемча, халыкның мәгълүм дәрәҗәдәге активлыгына таянып, Украина, Кавказ һәм Россиянең башка төбәкләрендәге аерымлануга булган омтылышларыннан файдаланып, Якын һәм Урта Көнчыгыштагы Әфганстан, Иран һәм Төркия белән хәрби-сәяси килешү төзеп, бу максатларга ирешеп була, дип фараз иттем. Ләкин мин монда бер «вак-төякне» онытып җибәрдем. Әгәр халыкара империализм СССРны җиңә алырлык көчле булса, алда әйтеп үтелгән өч дәүләтне дә үзе теләгәнчә укмаштыру бер ни дә тормас иде һәм ул, төзелгән очракта, Туран дәүләтен дә кулына алыр һәм уенчык итәр иде. Әфганстандагы бүгенге хәлләр шул хакта сөйли.

...Түгәрәккә йөрүчеләр белән мин Казанга килгәннең беренче көнендә элеккеге партия әгъзасы, студент Һади Урманчиев фатирында очраштым (Вознесенская урамы, беренче яки икенче йорт). Анда Бакиев, Һади Урманчиев, элеккеге анархист-журналист, авыл хуҗалыгы институты студенты Фәйзуллин бар иде. Бакиев ахырга кадәр утырмады, шул ук көнне Башкортстанга Кустпромсоюз курсларына китәргә ашыгуын сылтау итеп чыгып китте. Түгәрәккә мине ул алып килгән иде. Бакиев белән Мәскәүдән Казанга бергә килдек. Монда Фәйзуллиннан кала башкалары миңа таныш кешеләр булып чыкты. Хафизовны мин Мәскәүдә чыга торган татар газеталарында эшләүче бердәнбер татар анархисты буларак 1919 елдан белә идем. Һади Урманчиев белән 1919—1922 елларда Үзәк Мөселман Коллегиясендә, ә аннары Шәрекъ коммунистик университетында (ул анда укыды, ә мин лектор идем; беркадәр гомер Төркестанда эшләп алды, шунда партиядән чыгарылды) эшләгән чагымда таныштым. Шулай итеп, җыелышта партиядән куылган өч кеше, бер анархист һәм бер фиркасез катнашты. Мин монда берничә максатны күздә тотып килдем. Беренче чиратта аның нинди түгәрәк булуын, кемнәрне берләштерүен, нинди бурычларын куюын, киләчәген ачыкларга теләдем.

Максатыма тулысынча ирешә алмасам да, түгәрәкнең әле оешып кына килүен һәм башлыча пропагандистик эш кенә алып баруын белдем. Кайберәүләр аерым мәсьәләләр буенча рефератлар язганнар, ләкин алар фәкать үз араларында гына укылганнар икән. Минем алда сүз Һади Урманчиевның «фәлсәфәне тәнкыйтьләү схемасы» хакында барды. Автор аның «философиягә тәнкыйть» дигән хезмәтнең бер өлеше генә булуын әйтте. Бу әйбер белән танышкач, мин анда күп кенә каршылыклар һәм төгәлсезлекләр таптым, аның өстендә эшләгәндә материалистик карашларга нигезләнергә тәкъдим иттем.

Җитәкчеләренең сүзләренә караганда, түгәрәкнең эше Казан студентлары белән генә чикләнә, әгъзаларының саны да 20-30 кешедән артмый. Аның кайчан туув хакында сорашмадым. 1925 елга кадәрдер, мөгаен, чөнки Фәйзуллин безгә Мәскәүгә килгәндә, ул эшли торган булган инде. Җентекләп кызыксынмадым, аларга эшчеләр һәм крестьяннар арасында да оештыру эшләре алып барырга киңәш иттем. Аңлавымча, түгәрәкнең программасы шактый кызыклы һәм житди иде. Алар Татарстанның икътисади, сәяси һәм мәдәни бәйсезлегенә ирешүне төп максат итеп куеп, урыс зыялылары арасында карагруһчылыкка һәм, гомумән, бөек урыс шовинизмына каршы көрәш ачу кирәклегенә басым ясыйлар. Программада шулай ук төрки республикаларны федератив берләштерү, Совет власте җимерелүгә дучар ителгән очракта карагруһ-монархистик реакциягә каршы коралы каршылык күрсәтүгә әзерләнү, татар авылларының мәдәни үсешенә ярдәм итү кебек мәсьәләләр дә урын алган иде.

...Бу җыелышта миңа да шактый гына сораулар бирелде. Аларны, беренче чиратта, булачак республиканың нинди нигезгә корылачагы кызыксындырды: пролетариат, крестьян, буржуазия яки «блок» диктатурасы урнаштырылачакмы?

Моңа каршы мин, мөстәкыйль дәүләт төзү мәсьәләсе социалистик революция җиңелеп, милли төбәкләрне яңадан торгызылачак карагруһ-монархистик көчләрдән, «бердәм һәм бүленмәс» Россия тарафдарлары булган урыс шовинистларыннан сакларга туры киләчәген искәрткәннән соң, крестьян «утрауларыннан» торган төрки районнарда пролетариат диктатурасын саклап калу хакында уйларга да кирәкми, бу принципны «сыйныфлар блогы» белән алыштырырга туры киләчәк һәм анда крестьяннар катламы хәлиткеч рольне уйнаячак, дидем.

Икенче сорау революция җиңелгән очракта безнең халыкара империализмга һәм аерым капиталистик дәүләтләргә мөнәсәбәтебез хакына иде. Алар бу дәүләтләрдән кредитлар, корал һәм башка нәрсәләр алып булсын өчен безнең империализмга каршы өндәмәләребезне вакытлыча яшереп торырга туры килмәсме, дип сорадылар.

Россиядән аерылган Туран республикасына кертелергә тиешле халыкларның эчке көчләренә ышанганга, бу мәсьәлә минем алда тормады, әгәр ул килеп чыга калса, аны гаять сак хәл итәргә кирәк, чөнки аз гына ялгыш атланган адым да безне киң халык массаларыннан гына түгел, ә читтәш колониаль һәм ярымколониаль Шәрекъ илләреннән дә читләштерергә мөмкин, дидем.

Зыялылар хакында сүз чыккач, алар миннән руханиларга карата нинди мөнәсәбәт булырга тиешлеген сорадылар. Мин бу мәсьәләдә сабырлык күрсәтергә, чын хезмәт иясе катламнарыннан чыккан укымышлылар тәрбияләү өлкәсендә эшләргә, ә руханилар һәм буржуаз зыялыларга килгәндә, аларны үз мәнфәгатьләребезне уздыру өчен файдаланырга кирәк, дидем.

Безнең җыелышта башлыча шушы мәсьәләләр хакында сөйләнде. Аларны төгәл һәм аныклабрак кую өчен без 1928 елның кышында яки 1929 елның язына таба Мәскәүдә корылтай янсә конференция чакырырга кирәк дигән фикергә килдек. Безнең бу сөйләшүләр, чынлыкта, бер-беребезне капшап карау иде. Шуңа күрә күп нәрсәләр игътибардан читтә калды.

Казан түгәрәгендә башкача булырга туры килмәде. Һади Урманчиев белән икенче тапкыр командировкаларга килгән чакларда гына очраштыргаладым. Беренчесендә аның «фәлсәфәгә тәнкыйть» керешенең кульязмасы белән таныштым, икенчесендә Кызыл Кокшайдан кайтканда сугылдым һәм аңа үземнең бу якларга сөрелгән халык дошманнары белән очрашуым хакында сөйләдем.

Ничектер бервакыт урамда Хафизовны очраттым (1928 елның августы). Ул үзен эзәрлекләүләреннән, тынычлап эшләтмәүләреннән зарланды һәм шушы авыр мохиттан качып Урта Азия янсә нинди дә булса бер милли төбәккә күчеп китәргә җыенуын әйтте.

**Рафаэль Мостафин,**
**Рәис Даутов**

# РЕПРЕССИЯЛӘНГӘН ТАТАР ЯЗУЧЫЛАРЫ

Кайбер тарихчы галимнәрнең раславы дөрес булса, 1917 елдан башлап илдә урнашкан тоталитар режим шартларында язмышлары пыран-заран килгән — махсус оештырылган ачлык фаҗигаләрендә һәлак булган, йорт-җир һәм туган төбәкләреннән сөрелгән, яки, бер гаепсезгә кулга алынып, нахак хөкем карары белән гомерләре киселгән, концлагерьларга озатылып, ерак Себер тайгаларында, кырыс табигатьле төньяк өлкәләрдә, Казакъстанның сусыз далаларында иза чиккән, авыр кол хезмәтеннән, кыйнау-рәнҗетүләрдән шунда әҗәлен тапкан, яисә ирекккә сәламәтлекләрен тәмам югалтып, инвалид булып, рухи сүнеп чыккан кешеләрнең, ягъни репрессия корбаннарының гомуми саны 30—40 миллионга җитә икән. Бу — ил халкының чиреге чамасы дигән сүз. Сталин репрессияләре бер генә төбәкне дә, бер генә халыкны, бер генә милләтне дә читләтеп узмаган. Бу яктан ул чын мәгънәсендә интернациональ күренеш — илдәге милләтләрнең уртак фаҗигасе. Хәер, соңга таба, бигрәк тә сугыштан соңгы елларда, репрессив сәясәт, теге яки бу милләтнең аерым шәхесләрен, яки мәгълүм бер төркемен — «контрреволюцион элементларын», «җинаятьчел оешмаларын» юк итү белән генә канәгатьләнмичә, бөтен бер халыкларга, милләтләргә каршы геноцид мәгънәсендә дә кулланыла башлый. Сугыш һәм сугыштан соңгы беренче елларда Кырым татарларының, калмыкларның, Идел буе немецләренең, кайбер Кавказ халыкларының (чичән, ингуш, карачай, балкар һ. б.) егерме дүрт сәгать эчендә туган җирләреннән сөрелеп, гражданлык хокукларыннан мәхрүм ителүе һәм мөстәкыйль милләт булып яшәү өчен бөтенләй яраксыз, кыен шартларга куелуы әнә шул геноцид сәясәтенең бер мисалы иде.

Башка халыклар кебек үк, татар халкы да тоталитар режим аждаһасына үзеннән күп корбаннар биргән. Октябрьдән соңгы беренче елларда ук «буржуаз сыйныф вәкилләре» буларак репрессияләнгән һөнәр-сәнгать эшлеклеләре, сәүдәгәрләр, дин әһелләре, зыялылар, гражданнар сугышы корбаннары, 1921 елгы ачлык фаҗигасендә һәлак булган меңнәрчә гаиләләр, көчләп күмәкләштерү чорында «дошман сыйныф», «кулак», «кулак иярчене», «нэпман» тамгасы астында судсыз-нисез атып үтерелгән яки бөтен гаиләләре белән Себергә озатылган меңнәрчә крестьяннар, җир хуҗалары, эш-һөнәр осталары, җәмәгать-дәүләт эшлеклеләре, хуҗалык җитәкчеләре, мәдәният әһелләре, галимнәр, язучылар, мөгаллимнәр, табибләр, рәссамнар һ. б. — татар халкы биргән бу корбаннарның төгәл санын хәзер, мөгаен, ачыклап та бетереп булмыйдыр.

Репрессияләр иң беренче нәүбәттә милләтнең, халыкның әнә шул иҗатчыл өлешенә, иҗтимагый фикердә һәм мәдәни хәрәкәттә йогынтылы роль уйнаган хөр карашлы катламына каршы юнәлтелгән була.

Мәгълүм ки, татар әдәбияты, XX йөз башында аеруча бер иҗади күтәрелеш чоры кичереп, революциягә тотырыклы милли-демократик традицияләргә нигезләнгән, үзенчәлекле, күп жанрлы, җитлеккән, яшь талантларга бай, киләчәге өметле бер әдәбият булып каршылый. Дөрес, милли-азатлык хәрәкәтендә чыныгу алган өлкән буын әдипләрнең бер өлеше (Г. Исхакый, С. Максуди, Г. Баттал, Ф. Туктаров һ. б.), Октябрьне кабул итмичә, ватаны

ташлап чит илгә китәргә мәҗбүр булалар. Илдә торып калганнары исә, яшекарты, революция вәгъдә иткән «якты киләчәк» һәм милли үсеш хакына чын күңелдән илһамланып, иҗади эшләрен дәвам иттерергә тырышалар, яки яңа хакимият белән якын хезмәттәшлектә булмасалар да, һич югы аңа карата лояль мөнәсәбәт саклыйлар (мәсәлән, Ф. Кәрими, Дәрдемәнд). Әмма егерменче елларның башында ук илдә диктатура көчәюе һәм бөтен иҗтимагый тормышны идеологик кысалар эченә көчләп кертү нәтиҗәсендә, язучыларның иҗат хөрлеге көннән-көн кысыла-тарая бара, язган әсәрләренең кыйммәте фәкать сыйнфый көрәш күзлегеннән генә бәяләнә башлый. Әдәбият белемендә «вульгар социологизм» дип даны чыккан ялган теория әдәби мираска карата да мөнәсәбәтен үзгәртә. Мәсәлән, Тукайга «вак буржуа интересларын яклаучы милләтче шагыйрь» ярлыгы тагыла, Дәрдемәнд белән Ф. Әмирханга «эре буржуа әдипләре», Г. Камалга «либераль буржуа» язучысы, С. Рәмиевкә «индивидуалист, символист шагыйрь» дигән мөһерләр сугыла. Г. Газиз, Җ. Вәлиди, Г. Рәхимнәр исә, гомумән, пролетар әдәбиятка татар буржуасының милләтчелек карашларын үткәрергә тырышучы агентлар итеп күрсәтелә. 1925—26 елларда гарәп хәрефен латин әлифбасына күчерү мәсьәләсе буенча матбугатта һәм гыйльми конференцияләрдә кабынып киткән кызу бәхәсләр барышында гарәпчеләрнең (Г. Ибраһимов, Г. Алпаров, Г. Шәрәф һ. б.) чыгышлары соңыннан, солтангалиевчелек шаукымы башлангач, мәдәният тарихы ноктасыннан бәяләнеп түгел, бәлки «татар буржуасының сыйнфый интересы белән бәйләнгән» сәяси бер вакыйга итеп карала. Гарәп әлифбасын яклап матбугатта мөрәҗәгать белән чыккан татар зыялыларына (мәгълүм «82 имза»): «Болар —турыдан-туры пролетариат диктатурасына, марксизм идеологиясенә каршылар, болар ачыктан-ачык эре буржуа сыйныфларының яклаучылары булганга, алар яңалиф хәрәкәтенә провокация төсен бирергә тырыштылар, алар бу хәрәкәттән үзләренең контрреволюция оешмалары өчен файдаланырга тырыштылар»,—дигән тамга салына.

Гомумән, 1928 ел ахырында Сталинның шәхси күрсәтмәсе буенча ОГПУ органнары тарафыннан фальсификация юлы белән мәйданга чыгарылган һәм «Солтангалиевнең контрреволюцион оешмасы» дип исемләнгән сәяси процесс татар интеллигенциясенең милли кадрларын системалы рәвештә юк итүгә юнәлтелгән беренче зур террор акты иде. Бу «эш» буенча 77 кеше җавапка тартыла. Аларны буржуаз милләтчелектә, бөтен төрек-татар халыкларын бергә җыеп, бербөтен милли дәүләт төзү өчен яшерен әзерлек эше алып баруда гаеплиләр. Асылда исә бу—милли сәясәт өлкәсендә Сталин җитәкчелегеннән ризасызлык күрсәткән милли интеллигенция вәкилләренең авызларын томалау максаты белән эшләнгән иде. 1930 елның 28 июлендә ОГПУ коллегиясе солтангалиевчелектә гаепләнүче җитмеш җиде кешенең егерме берен иң югары җәзага—атарга, унбер кешене—ун елга, егерме дүрт кешене—биш елга, унбер кешене—өч елга концлагерь хезмәтенә һәм тугыз кешене өч еллык сөрген җәзасына хөкем итә. 1931 елның 13 гыйнварында шул ук ОГПУ коллегиясе, алдагы карарын үзгәртеп, үлемгә хөкем ителгәннәрнең җәзасын ун еллык концлагерь белән алыштыра. Әмма монда шуны искәртеп үтәргә кирәк: соңрак, 1937—38 елгы «олуг террор» вакытында, солтангалиевчелектә гаепләнгән бу кешеләрнең һәммәсе диярлек, шул ук «җинаятьләре» өчен кабат җавапка тартылып, НКВД «өчлек»ләре («тройка») карары белән атарга хөкем ителәләр. Танылган җәмәгать, дәүләт, партия-совет эшлеклеләре белән бергә бу исемлектә күренекле язучылар, журналистлар, сәнгать кешеләре дә була (Ф. Агиев, С. Сүнчәләй, Һ. Атласи, Б. Урманче, Г. Мансуров, И. Терегулов һ. б.).
Солтангалиевчелекне тар-мар итү сылтавы белән Татарстанда контрреволюцион милли төркемнәрне һәм оешмаларны «фаш итү» кампаниясе тагын да көчәеп китә. ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты пленумы үзенең 1929 ел, 9 ноябрь карары белән «барлык партия әгъзаларын солтангалиевчелекне тамырыннан йолкып атарга, артта калган халык массалары арасында милли хорафатларга каршы көрәшне көчәйтергә, әлегә кадәр безнең аппаратларда сакланып калган солтангалиевчел идеологияне алга сөрүче кешеләрне фаш итәргә» чакыра. Шундый карарларны, күрсәтмәләрне үтәү йөзеннән язучылар даирәсендә мифик бер «Җидегән» оешмасы уйлап табыла, матбугатта ул «контрреволюцион яшерен оешма» әгъзалары Н. Исәнбәт, Ченәкәй, Г. Кутуй, Г. Минскийларның «пычрак эшләре» фаш ителә. Алар, әдәбият мәйданыннан куылып, бүтән эшкә күчәргә яисә бөтенләй Казаннан чыгып китәргә мәҗбүр булалар. Мәсәлән, Г. Минский башта Чиләбегә, аннан Бакуга кача, Казанга сугыштан соң—1952 елда гына әйләнеп кайта. Н. Исәнбәт «Спартак» фабрикасына гади эшче булып яллана, аннан, авылга китеп, мәктәптә эшли. Г. Ку-

туй да, язучылар даирәсен ташлап, Казан техникумнарында студентлар укытып йөри. Бу чорда һәр татар язучысының иҗатында нинди дә булса сәяси хата эзләнә. Ф. Бурнаш солтангалиевчеләр тегермәненә су коючы милләтче әдип — «сарайлар, ханнар, кенәзләр, мәчетләр шагыйре» («Яңалиф» журн., 1929, № 22), Ченәкәй — «Диния нәзараты, сырахано, лото, алимент һәм чүпчарлар шагыйре» («Яңалиф», 1931, № 1) дип игълан ителә. К. Тинчурин — «милли демократизм» тарафдары, ягъни «иске авылның гореф-гадәтләрен, халык уеннарын идеаллаштыра; Ш. Усманов фәкать «татар комиссарларына гына игътибар итә», бары аларны гына «алгы планга чыгара»; Г. Ибраһимов «авылны шәһәргә каршы куеп» яза («Адәмнәр» повесте күздә тотыла) кебек ярлыклар уңга да, сулга да ябыштырыла башлыйлар. Хәтта «пролетар шагыйре» Мансур Крыймов иҗатыннан да «вак буржуа карашларыннан арынмаган шигырьләр» эзләргә керешәләр.

«Бер-берсен мактау, пролетариат язучыларына, пролетариат әдәбиятына күчү юлында булган юлаучыларга аяк чалу, шулай итеп, оешу ягыннан милли демократизмга нык җирлек тудыру — менә аларның оештыру сызыгы буенча алга сөргән контрреволюцион хәрәкәтләре! — дип нәтиҗә ясый Г. Толымбай үзенең бер мәкаләсендә, «җидегәнчеләр»не «фаш итеп» («Яңалиф», 1929, № 9 — 10).

Пролеткультчылар тәнкыйтендәге мондый «фаш итүләр», өркетүләр, әлбәттә, әдәбиятыбызның табигый үсешен тоткарлаган, аның сәләтле кадрларына иҗади мөмкинлекләрен тулысынча ачарга комачаулаган. Революциягә хәтле үк исемнәре танылган кайбер әдипләрнең (Н. Думави, М. Укмаси, З. Ярмәки, Ә. Сәгыйди, Б. Рәхмәт, З. Бурнашева һ. б.) утызынчы елларда актив иҗат эшеннән читләшүләре, бәлки, әнә шушы идеологик чикләүләр, өркетүләр белән аңлатыладыр.

Ләкин парадокс хәл: егерменче һәм утызынчы елларда әдәби тәнкыйтьтә туктаусыз дәвам иткән һәм торган саен кискенләшә барган әлеге «сыйнфый көрәш» (Сталин тезисы!) әһелләре һәммәсе диярлек — тәнкыйтьчеләре дә, тәнкыйтьләнүчеләре дә — 1937 елгы «олуг террор» афәтеннән котыла алмыйлар. Бу чорда инде диктатор режимы талымлап тормый: милли интеллигенциянең исеме күзгә ташланырдай һәрбер вәкилен таш капчыкка җыя бара. Хөкем тегермәнен тизрәк эшләтү һәм закон таләпләре, кагыйдәләре белән мәшәкатьләнмәс өчен һәр республикада, өлкәдә өч кешедән (партия өлкә комитетының беренче секретаре, Эчке эшләр халык комиссары, хәрби прокурор) торган махсус «өчлекләр» («тройка»лар) булдырыла. Татарстанда, мәсәлән, шундый ике «өчлек» — «өчлек» һәм гади «өчлек» эшләгән. Махсус «өчлек» гаепләнүчегә һәрвакыт үлем җәзасы биргән. Гади «өчлек»нең сирәк кенә очракларда лагерь срогы бирү белән канәгатьләнгән чаклары да булгалаган. 1937 — 1938 еллар арасында бу «өчлек»ләр аша меңнәрләгән «халык дошманы» узып, үзләренең гомер юлларын тәгәлләгәннәр. Мәсәлән, шул ике ел эчендә партиянең өлкә комитетына әгъза булып сайланган алтмыш бер кешенең илле дүрте, өлкә комитеты әгъзалыгына кандидат итеп сайланган егерме бер кешенең уналтысы юк ителә.

Татарстан Язучылар берлеге дә нәкъ шушы елларда иң зур югалтуларга дучар була. 1934 елда СССР Язучылар берлеге төзелгәч, Татарстаннан әгъза яки әгъзалыкка кандидат (стажер) итеп рәсмиләштерелгән утыз татар язучысының уналтысы репрессиягә эләгеп, шуларның унысы НКВД тырнаклары астында һәлак була. Язучылар берлегендә тегә яки бу сәбәпләр аркасында (күп очракта шул ук идеологик сәбәпләр) әгъза булып тормаган, әмма иҗатлары, исемнәре белән халыкка танылган башка репрессияләнгән каләм әһелләрен дә кушсак, әлеге сан күп дистәләргә җитә.

Хәзерге хәбәрдарлык чорында шәхес культы корбаннары турында тарихи дөреслекне, гаделлекне торгызу, аларның исемнәренә кайчандыр ягылган кара тапны юып төшерү, шуңа бәйле рәвештә аларның тормыш юлларына ачыклык кертү, аларның биографияләрен фактик хаталардан арындыру юнәлешендә шактый гына уңышлы эшләр эшләнә. Укучыларда, бигрәк тә яшь буында әдәбиятыбызның үткәненә, ул әдәбиятны тудыручыларга, аларның тормыш юлларына булган кызыксынуны күздә тотып, журналның шушы санынан башлап, утызынчы-кырыгынчы елларда һәм илленче еллар башында репрессияләнгән әдип-мөхәррирләребез хакында кыскача мәгълүматлар бирә башлыйбыз. Бу, бер яктан, аларның саф-пакь исемнәрен тагы бер мәртәбә хөрмәт белән искә төшерү булса, икенче яктан, кеше язмышларны белән уйнаган диктатор режимнарының халыкны нинди афәтләргә салырга мөмкин икәнлегенә бер ишарә-кисәтү дә булыр.



## Фәхрелислам Агиев

Фәхрелислам Нигъмәтулла улы Агиев 1887 елда элекке Тамбов губернасы Тимникәү өязенең Тенеш авылында мулла гаиләсендә туа.

1907 елдан яза башлап, Казанда чыга торган «Әльислах», «Әхбәр», «Кояш» газеталарында һәм «Аң», «Мәктәп» журналларында күп кенә мәкалә һәм хикәяләрен бастыра. Мәктәпләр өчен дәреслекләр, уку китаплары төзү эшенә дә үзеннән өлеш кертә. 1913 елдан үз нәширлегендә «Ак юл» исемле балалар журналы чыгара башлый. Әдипнең балалар психологиясен тирән аңлап язган хикәяләре, шигырьләре, тәрҗемә әсәрләре күбесенчә шул журнал битләрендә дөнья күрә. Аның «Кәкре аяклы тавык» исемле шигъри әкияте заманында балаларның яратып укый торган китапларыннан берсенә әверелә.

Революциядән соң Ф. Агиевның әдәби иҗат эшчәнлеге, идеологик чикләүләргә бәйле рәвештә, шактый сүлпәнләнә. Бу чорда ул нигездә әдәбият тарихына кагылышлы мәкаләләр, истәлек язмалары авторы буларак билгеле.

Ф. Агиев — 1928 елның ахырында ОГПУ тарафыннан фальсификация юлы белән оештырылып, «Солтангалиевнең контрреволюцион оешмасы» дип исемләнгән «эш» буенча кулга алынган кешеләрнең берсе. 1930 елның 28 июлендә ОГПУ коллегиясе аны иң югары җәзага — атарга хөкем итә. 1931 елның 13 гыйнварында шул ук коллегия, алдагы карарын бераз үзгәртеп, үлемгә хөкем ителгәннәрнең җәзасын ун еллык концлагерь белән алыштыра. Ләкин бу «эш» белән гаепләнүчеләрнең күбесе, 1937 — 1938 елларда кабат җавапка тартылып, НКВД «өчлек»ләре карары белән атарга хөкем ителәләр. Шулар исемлегенә Ф. Агиев та эләгә. Ул 1938 елда Мәскәү төрмәсендә атылган дип фараз кылына (әлегә төгәл вакыты ачыкланмаган).

## Әсгать Айдар

Әсгать Харис улы Айдаров 1906 елның 6 июнендә элекке Самара губернасының Иске Сорочи авылында мулла гаиләсендә туа.

Язучының әдәби мирасы күләм ягыннан артык зур түгел. Сугышка кадәр аның ике шигъри җыентыгы һәм берничә кечкенә күләмле повесте басыла («Ак каенлыкта», 1929; «Ташбай», 1932; «Соңгы сулышта», 1935). Сугыштан соңгы елларда тагын ике күләмле повесте — «Солдат хикәясе» һәм «Таулар легендасы» дөнья күрә. Талантлы әдипнең мондый сүлпәнлеге җитди социаль сәбәпләр белән аңлатыла.

1935 елны ул Сирин (Батыршин) һәм тагы берничә язучы белән берлектә кулга алына. Нахак җинаятьләрдә гаепләнеп, берничә ел төрмәдә утырып чыга. 1938 — 1941 елларда, Казанда репрессияләрнең иң нык кызган чагында, Урта Азия якларына китеп, Сәмәрканд өлкәсендә яшәргә мәҗбүр була. Ватан сугышы елларында фронтта батырларча сугыша, орден-медальләр белән бүләкләнә. Демобилизацияләнеп Казанга кайта, яңадан әдәби эшчәнлеген җәелдереп җибәрә. Әмма эзәрлекләү дәвам итеп, яңадан кулга алыну куркынычы тугач, ул 1948 елны янә Урта Азия якларына китә һәм, әдәбияттан читләшеп, гомеренең соңгы еллары культура-агарту учреждениеләрендә эшли.

Ә. Айдар 1959 елның 24 гыйнварында вафат булды.



## Сәлах Атнагулов

Сәлахетдин Садретдин улы Атнагулов (әдәби псевдонимнары — Азамат, Сәләй) 1893 елда хәзерге Башкортстан республикасының Бәләбәй районы Суыккүл авылында туган.

Февраль революциясе көннәрендә татар-башкорт милли хәрәкәтенә кушылып, 1917 елның июлендә Идел-Урал штатын гамәлгә ашыру коллегиясенең сәркатибе итеп сайлана. Октябрьдән соң, 1918 елда большевиклар партиясенә кереп, Мәскәүдә Үзәк мөселман комитетында эшли, гражданнар сугышы чорында «Кызыл яу» фронт газетасы (Уфа) редакторы, ВКП(б) ҮК каршындагы Көнчыгыш халыклары бюросында инструктор, аннары «Кызыл Армия», «Эшче» (Мәскәү, 1921—1922), «Кызыл Татарстан» (Казан, 1925—1927) газеталары редакторы, Татар дәүләт китап нәшриятында әдәби хезмәткәр һәм бүлек мөдире (1927—1929), Гыйльми Үзәк җитәкчесе вазифаларын башкара. Гомеренең соңгы алты елында ул педагогия институтында укыта һәм фәнни эш белән шөгыльләнә.

Күп төрле җәмәгать һәм дәүләт эшләреннән тыш, С. Атнагулов матбугат мәйданында да үзен сәләтле журналист, үткен телле публицист, әдәбият тәнкыйтьчесе һәм язучы итеп таныта. Ул — «Гарантияле мәхәббәт» (1927), «Петиция һәм башка әкиятләр» (1927), «Кечкенә шахтер» (1925), «Каф тавы артында» (1928) исемле хикәя һәм очерк китаплары авторы.

1936 елның 2 сентябрендә ул, әүвәл эсерлар партиясендә, соңыннан «сул коммунистлар» төркемендә торуда гаепләнеп, кулга алына. Ф. Сәйфи-Казанлы, З. Гыймранов, И. Рәхмәтуллин һ. б. «троцкийчы контрреволюционерлар» белән бергә, аны Мәскәүгә алып китәләр. 1937 елның 15 августында СССР Югары судының Хәрби коллегиясе С. Атнагуловны үлем җәзасына хөкем итә. Карар шул ук көнне гамәлгә ашырыла.

Җирләнгән урыны билгесез.



## Гыйлемдар Баембитов

Җәмәгать эшлеклесе, журналист, язучы, тәрҗемәче Гыйлемдар Солтан улы Баембитов 1886 елда Уфа губернасының Бәләбәй өязе Чакмагыш авылында земство фельдшеры гаиләсендә туа.

Г. Баембитовның совет чорында язган һәм аерым китап булып басылган әсәрләре: «Сәяси икътисад» (политэкономия буенча фәнни-популяр очерк), Казан, 1922, 328 б.; «Асылган» (өч пәрдәлек пьеса), Казан, 1924, 110 б.; «Патша төшерәләр» (авыл тормышыннан пьеса), 1924, 36 б. «Асылган» пьесасы 1924 елда Казанда Татар дәүләт театры сәхнәсендә дә куела. Г. Баембитов шулай ук тәрҗемә эше белән дә шөгыльләнгән: русчадан татарчага сәяси-фәнни эчтәлектәге брошюралар, Н. Бухаринның «Тарихи материализм» исемле китабын һәм Этель Войничның атаклы «Кигәвен» романын тәрҗемә итеп бастыра (1932).

Татар, башкорт халыклары арасында совет властен ныгыту өчен җаны-тәне белән тырышып йөрүенә карамастан, Г. Баембитов утызынчы еллардагы репрессияләрдән котылып кала алмый.

Хәзер мәгълүм булганча, егерменче еллар ахырында, ил экономикасында, бигрәк тә авыл хуҗалыгында җибәрелгән җитди ялгышларны корткычлыкка, дошман сыйныфның «контрреволюцион эшчәнлегенә» сылтап калдыру максаты белән, Сталин һәм аның тарафдарлары хөр, мөстәкыйль фикерле партия-совет, хуҗалык, гыйлем-фән эшлеклеләренә каршы һөҗүм башлыйлар. Моның өчен ОГПУ органнары ярдәмендә үзәктә һәм республикаларда

«контрреволюцион оешмалар» уйлап чыгарыла. Шул рәвешчә Татарстан җирлегендә дә Галимҗан Әминев, Гыйлемдар Баембитов һәм Миңлегәрәй Сәгыйдуллин җитәкчелек иткән һәм «Крестьяннар иттифакы» дип аталган ялган «террорчы кулаклар оешмасы» пәйда була (янәсе, башында галим-экономист А. Чаянов, Н. Кондратьевлар торган уйдырма «Крестьян-хезмәт партиясе»нең «филиалы»).

1932 елның декабрендә «иттифакчы»ларны җыю башлана. Барысы илле сигез кеше кулга алына. 1933 елның 10 һәм 28 маенда ОГПУның махсус коллегиясе, җавапка тартылганнарның «җинаятьләрен» тикшереп, хөкем карарын игълан итә. «Иттифакчы»лардан биш кеше, шул җөмләдән Г. Баембитов, иң югары җәзага — атарга, ә калганнары төрле срокка хезмәт колониясенә хөкем ителә.



## Сафа Борһан

Сафа Вафа улы Борһанов (әдәби псевдонимнары — С. Борһан, Сабур) 1899 елның декабрендә Уралдагы Серебряный приискасында шахтер гаиләсендә туган.

1921 — 1924 елларда Мәскәүдә Коммунистлар университетында укый, аны тәмамлагач, 1926 елга кадәр ВКП(б)ның Башкортстан өлкә комитетында бүлек мөдире вазифаларын башкара.

1926 елда С. Борһан Казанга килә һәм Татарстан дәүләт нәшриятының баш редакторы итеп билгеләнә. 1928 — 1933 елларда ул — «Кызыл Татарстан» газетасының баш редакторы, «Красная Татария» газетасында баш редактор урынбасары, бүлек мөдире, Казан авиация заводының күп тиражлы газетасы редакторы, ә 1934 елдан «Известия» (Мәскәү) газетасының Татарстан буенча махсус хәбәрчесе булып эшли.

С. Борһан үз чорының матбугат дөньясында публицистик һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләре, очерклары, театр сәнгате турындагы рецензияләре белән танылды. 1928 елда «Үткәндәгеләр» дигән озын хикәясе һәм «Бозлар арасында» (1929) исемле очерклары аерым китап булып басылып чыга. Аның техникумнар өчен татар әдәбияты буенча төзегән хрестоматия-дәреслек китабы, дини йолаларга, диннәр тарихына багышланган «Ураза, корбан, сәдакалар», «Алла исеме белән» дигән публицистик хезмәтләре берничәшәр басмада дөнья күрәләр.

С. Борһан 1936 елның 30 декабрендә «солтангалиевчелектә» гаепләнеп кулга алына. Казан төрмәләрендә ярты елдан артык утырганнан соң, 1937 елның 3 августында СССР Югары судының Хәрби коллегиясе үзенең күчмә сессиясендә әдипне башка бик күп тоткыннар белән бергә үлем җәзасына хөкем итә. Карар шул ук көнне җиренә җиткерелә.

Кабере билгесез.

## Фәтхи Бурнаш

Фәтхелислам Закир улы Бурнашев 1898 елның 13 гыйнварында элекке Сембер губернасының Буа өязе Бикшик авылында мулла гаиләсендә туа.

Әдәби иҗат юлындагы беренче адымнары «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укыган чорда ук башлана. Ул «Сәйяр» труппасы өчен пьесалар тәрҗемә итә, «Язмыш» исемле беренче оригиналь пьесасын, аннан «Сукбай» (1915), «Саташкан кыз» (1916) h. б. пьесаларын яза. Революциягә хәтле үк язучының «Ак юл», «Аң» журналларында шигъри әсәрләре дә басыла башлый. Революцион хәрәкәтләр белән рухланып, ул үзенең атаклы «Яшь йөрәкләр» драмасын һәм «Таһир-Зөһрә» исемле трагедиясен иҗат итә. Егерменче елларда әдип «Чәчәктән һәйкәл», «Гөлчәчәк», «Сахра каны», «Мөхәммәтҗан», «Ак каен», «Әҗәл» исемле романтик поэмаларын бастыра. «Адашкан кыз» (1920), «Камали карт» (1925), «Авыл яшьләре» (1929), «Лачыннар» (1931), «Ялгыз

Ярулла» (1940) һәм башка бик күп талантлы пьесалары белән ул татар драматургларының алгы сафына баса. Моннан тыш ул йөздән артык публицистик һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләре авторы. Әдәби тәрҗемәче буларак та нәтиҗәле эш алып бара.

1940 елның 24 августында кулга алына. Советка каршы коралды восстание әзерләүдә һәм милләтчелек пропагандасы алып баруда гаепләнә. 1941 елның 24 гыйнварында ТАССР Югары суды аны ун елга ирегеннән мәхрүм итүгә һәм биш елга хокукларын чикләүгә хөкем итә. Хөкем чыгарылганнан соң әдип Самара өлкәсендәге Безымянка лагерена җибәрелә. Монда чакта аны тоткыннар арасында контрреволюцион пропаганда алып баруда гаеплиләр. 1942 елның 15 июлендә НКВДның Махсус кинәшмәсе (Особое совещание, өч кешедән торган, вәкаләте чикләнмәгән «тройка») аны үлем җәзасына хөкем итә. Язучыны 1942 елның 1 августында Самара шәһәрендә атып үтерәләр.

Кабере әлегә билгесез.

## Мәхмүт Бөдәйли



Мәхмүт Кәшфелһади улы Бөдәйли 1895 елда хәзерге Татарстанның Мамадыш районы Ямаш авылында туа. Революция алды елларында типографиядә хәреф җыючы, Троицк шәһәрендә «Акмулла» журналы идарәсендә сәркатиб, казакъ телендәге «Айкап» журналында корректор булып эшли, аннары «Акмулла», «Шура» журналлары, «Вакыт» газетасының Төркестандагы хәбәрчесе була. Ташкентта чыга торган «Садаи Төркестан» (1914—1915) газетасында «Мөселманнар хәятыннан бер ләүхә» исемле мәкаләсе өчен төрмәдә дә утырып чыга.

М. Бөдәйли — юмор-сатира жанрында язылган күп санлы кыска хикәяләр, шигырьләр, фельетоннар, пародияләр, лөгать-сүзлекләр авторы. Алар төрле имзалар астында (Кигәвен, Автолиф, Кәшфелзадә, Дулкын, Карт студент һ. б.) шул заманның газета-журналларында («Акмулла», «Кармак», «Шәпи агай», «Чаян» һ. б.) дөнья күрәләр.

М. Бөдәйли «М. Солтангалиевнең контрреволюцион оешмасы» дип игълан ителгән «эш» буенча 1929 елны кулга алына. 1930 елның 28 июле һәм 3 августында, аннары 1931 елның 8 һәм 13 гыйнварында узган суд утырышларында ОГПУның Махсус коллегиясе әлеге «эш» буенча җавапка тартылган 77 кешене (шул җөмләдән М. Бөдәйли, Ф. Агиев, С. Сүнчәләй, Б. Урманче, И. Биккулов, Һ. Атласи кебек күренекле әдәбият-сәнгать, фән әһелләрен) төрле срокларга ирекләреннән мәхрүм итәргә карар чыгара. М. Бөдәйли, ун ел срок алып, хезмәт концлагерена (Соловкига) озатыла. Анда хөкем срогын тутыргач та, 1955 елга кадәр сөргендә иза чигәргә мәҗбүр була. Казанга ул 1955 елда, ягъни 24 елдан соң гына кире әйләнеп кайтты. «Гаепләреннән» тәмам акланып, гражданлык хокуклары кире кайтарылган булса да, Хрущев-Брежнев заманындагы «негласный» чикләүләр аңа матбугат дөньясында җиң сызганып эшләргә мөмкинлек бирмәде. Гомеренең соңгы елларында тырышып төзегән «Татар матбугатында псевдонимнар» исемле хезмәте дә үз вакытында дөньяга чыкмый калды.

М. Бөдәйли 1975 елда Казанда вафат булды.

## Гальгаф

Гальгаф — язучы, әдәбият тәнкыйтьчесе һәм тәрҗемәче Гали (Нургали) Галиевнең (1902—1940) псевдонимы. Газета-журналларда бу исем егерменче еллар башыннан күренә башлый. Соңга таба өч мөстәкыйль китабы — «Буталчык көннәрдә» (1925) дигән бер пәрдәлек пьесасы, «Авылыма хат» (1927) исемендә шигырьләр җыентыгы һәм «Маневрдан соң» (1927) исемле хикәяләр китабы басылып чыга. Моннан тыш аның берничә тәрҗемә хезмәте дә билгеле. Мәсәлән, рус язучысы А. Неверовның заманында зур по-

пулярлык казанган «Ташкент — город хлебный» дигән повесте татарчага Гальгаф тарафыннан тәрҗемә ителгән («Ташкент — икмәкле шәһәр», Казан, 1929, 170 б.). Гомумән, Гальгаф егерменче еллар әдәби тәнкыйтендә өметле яшь каләм буларак телгә алына.

Гальгаф 1929 елда яки утызынчы еллар башында «солтангалиевчелек»тә гаепләнеп кулга алынган булса кирәк. Шундый ук «гаеп» белән кулга алынып хөкем ителгән М. Бәдәйлинең бер язма таныкламасына таянганда, Гальгаф 1940 елда Соловки концлагеренда авыр хезмәт һәм ачлыктан вафат булган.



## Җамал Вәлиди

Җамалетдин Җәләлетдин улы Вәлидов 1887 елда Казан губернасының, Тәтеш өязе Апас авылында мулла гаиләсендә туа.

Революция алды елларында «Шура» журналында һәм «Вакыт» газетасында актив язышa, үзе дә редакция составында эшли. Беренче мәкаләләре белән үк үзен сәләтле тәнкыйтьче итеп таныта. «Татар әдәбиятының барышы» (1912), «Милләт вә миллият» (1914) исемле монографияләрен бастыра. Әдипнең Тукай иҗатына багышланган хезмәтләре аеруча игътибарга лаек. 1923 елда Петроградта Җ. Вәлидинең «Очерк истории образованности и литературы татар» исемле русча язылган фәнни тикшерүе басылып чыга. Күренекле әдәбиятчы галим, тел белгече буларак, ул — дистәдән артык җитди фәнни хезмәтләр авторы. Алар арасында бигрәк тә 1927 һәм 1929 елларда аерым-аерым ике зур том булып чыккан «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»н күрсәтеп үтәргә кирәк. Җ. Вәлиди хезмәтләре татар әдәбияты һәм тел белеме үсеше тарихында мөһим казанышлар булып торалар.

Җ. Вәлиди 1931 елның 6 маенда ГПУ органнары тарафыннан кулга алына, «контрреволюцион милли үзәк» төзүдә гаепләнә. 1932 елның 11 маенда ОГПУ коллегиясе тарафыннан биш елга ирегеннән мәхрүм ителә. Истәлекләргә караганда, тикшерү вакытында, нахак гаепләүләргә түзә алмыйча, бинаның өске катыннан сикереп үз-үзен үтерергә омтылыш ясый. Бик каты имгәнә, аякларын сындыра, әмма исән кала. Шул көенчә аны Ак диңгез — Балтыйк каналы төзелешенә җибәрәләр. Шунда ул берничә айдан соң дөнья куя. Үлеменең төгәл датасы билгеле түгел. Архивта НКВД идарәсенең 1932 елның 22 декабрь датасы куелган һәм Җ. Вәлидине «срогыннан алда азат итәргә» дигән карары язылган рәсми кәгазе генә табылды.



## Г. Газиз

Газиз Салих улы Гобәйдуллин (әдәби псевдонимнары — Г. Газиз, Г. Сәлман, Әбү Сәлман һ. б) 1887 елның 27 июнендә Казан шәһәрендә сәүдәгәр гаиләсендә туган.

Студентлык елларыннан башлап тарихи хезмәтләре һәм әдәби язмалары белән көндәлек матбугатта катнаша. Әдип-язучы буларак, 1913 — 1917 еллар арасында өч дистәдән артык сатирик һәм юмористик хикәясе, күп санлы фельетоннары, рецензияләре дөнья күрә. Революциядән соң ул нигездә тарих һәм әдәбият фәннәре буенча эшли. Галимнең «Русия тарихы» (1919), «Татар тарихы»(1922), «Татар әдәбияты тарихы» (Гали Рәхим белән берлектә, 1922 — 1924), «Борынгы болгарлар» (1924), «Татарларда сыйныфлар тарихы» (1925), «Пугачев хәрәкәте һәм татарлар» (1927), «Хазарларның килеп чыгышы» (1927), «Тимуридлар империясенең таркалуы һәм үзбәк чоры» (1928), «Әзәрбайҗанда коллык» (1930) кебек, татар, рус, үзбәк,

әзәрбайҗан телләрендә дөнья күргән хезмәтләре төрек-татар халыкларының тарихын өйрәнү юлында үзенчәлекле казаныш булып торалар.
Егерменче елларның урталарында әдәбият белемендә һәм иҗтимагый фәннәрдә вульгар социологизм карашлары көчәеп китеп, төрле эзәрлекләүләр, «буржуа идеологы» кебек ярлыклар тагыла башлагач, 1925 елны Г. Газиз Баку шәһәренә күчеп китә. Шул ук елны ул Әзәрбайҗан дәүләт университетының приват-доценты итеп сайлана. 1928 елда аны Көнчыгыш тарихы кафедрасы профессоры, ә 1930 елда Беренче Мәскәү университетының штаттан тыш профессоры итеп раслыйлар.
1937 елның март аенда Әзәрбайҗан Фәннәр академиясенең зур бер төр м галимнәре белән бергә Г. Газизне дә кулга алалар. Аны солтангалиевчелектә, фән хезмәткәрләре аша һәм студентлар арасында милләтчелек, пантюркизм идеяләре таратуда, яшерен контрреволюцион оешмада әгъза булып торуда һәм Төркия, Германия, Япония файдасына шпионлык эше алып баруда гаепләүләр һәм, шул елның сентябренә кадәр өзлексез дәвам иткән сорау алу, тән җәзалары нәтиҗәсендә, әлеге «гаепләрне» танырга мәҗбүр итәләр. 1937 елның 7 сентябрендә әдип-галимнең «эше» буенча тикшерү тәгәлләнеп, шул ук елның 12 октябрендә СССР Югары судының Хәрби коллегиясе Җинаятьләр кодексының 63,[1] 64, 69, 70, 73 нче маддәләре буенча «Газиз Салих улы Гобәйдуллинны, шәхси милкен конфискацияләп, иң югары җәзага — атылуга» хөкем итә. Шул ук төнне, ягъни 1937 ел, 13 октябрь таңында, Газиз Гобәйдуллинның гомере өзелә.
Кабере билгесез.

## Гомәр Гали



Гомәр Билал улы Галиев 1900 елның 16 июнендә Татарстанның хәзерге Буа районы Иске Тинчәле авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа.
1919 — 1920 еллардан башлап Сембер татар көндәлек матбугатында публицистик мәкаләләре һәм очерклары белән катнаша башлый. Егерменче елларда Казан матбугатында күп санлы хикәяләре («Биктимер ничек эшче булды?», «Ат саклаганда», «Кубань буйларында», «Таң кияве», «Беренче мәхәббәт», «Утыз бишәү, әти» һ. б.) һәм тәнкыйть мәкаләләре, рецензияләре басылып чыга. Утызынчы елларда исә Г. Ибраһимов, К. Тинчурин, Һ. Такташ, Х. Туфан, М. Крыймов кебек язучыларның иҗатларына багышлап тирән анализлы мәкаләләре дөнья күрә.
Г. Гали 1937 елның 9 мартында кулга алына. Аны «контрреволюцион троцкийчы оешмада» торуда гаепләләр. 1937 елның 15 августында СССР Югары судының Хәрби коллегиясе әдипне ун елга ирегеннән мәхрүм итәргә һәм тагы биш елга гражданлык хокукларын чикләргә дигән хөкем карарын игълан итә. Әдип башта Владимир, аннан Орел шәһәрләре төрмәсендә утыра. Төп срогын исә Норильск концлагеренда үткәрә, Металлургия заводын төзешә, заводның корыч кою цехында эшли.
1947 елның 10 мартында срогын тутырып иреккә чыга. Башта берничә ай шул ук заводта завхоз вазифасын башкара. Аннан, туган авылына кайтып, ярты елга якын ата-аналары янында тора. 1948 ел башында аңа Казанга, гаиләсе янына кайтырга рөхсәт итәләр. Ул Иске клиникада медстатист булып эшли башлый. 1949 елның 23 июнендә яңадан кулга алынып, гомерлек сөргенгә җибәрелә. Красноярск краеның Подпорожье поселогында (Казачий районы) тора, төзелештә десятник, шифаханәдә санитар булып эшли. Шунда ул 1954 елның 5 июлендә ниндидер бер бандит тарафыннан вәхшиләрчә үтерелә.

*(Дәвамы бар).*

# ЕЛЛАР АВАЗЫ

«Казан утлары» журналының чыга башлавына 70 ел тула. Ул 1922 елның май аенда «Безнең юл» исеме белән Казанда чыга башлый. Журнал — әдәбиятыбыз, мәдәниятебезнең тарихы, көзгесе. Тик мин аны һич тә «тутыкмас вә күгәрмәс, саф вә рәүшан (якты) көзгеседер» дип әйтергә җыенмыйм. «Социалистик» дип аталган җәмгыятебезнең бөтен күгәрекләре бу көзгедә дә урын алды — ләкин бит болар да безнеке, болар да — тарих. Көзге бит, ни бар — шуны күрсәтә, арттырмый да, киметми дә! «Казан утлары» журналы үзенең җитмеш еллык тарихында безнең җәмгыять узган бөтен юлларны яктырткан: гражданнар сугышында йөргән «кызыллар»ны мактаган, азатлык алган татар халкына мәдхия җырлаган, ачлык фаҗигаларына урын биргән, ачларга ярдәм оештырган. Аннары «халыклар атасы» уздырган геноцидка да күпмедер хезмәт иткән. Нихәл итик? Бу да безнең тарих. Журнал Солтангалиевне дә сүккән, Гаяз Исхакыйны да, «җидегәнчелек»не дә, булмаган пантюркизмны да, уйдырма панисламизмны да.

Ватан сугышы, сугыштан соңгы еллардагы эйфория — бу темалар барысы да шунда. Торгынлык еллары да шунда. Ләкин шул ук журналда элек һәм бүген яшәгән барлык татар язучысы да тәрбияләнде, әдәби осталыкка өйрәнде. Бу журналда әсәреңне бастыру — олы юлга чыгу буларак бәяләнеп килде.

Татар әдәбиятының сикәлтәле тарихын беләсең килсә — «Безнең юл», «Атака», «Совет әдәбияты», «Казан утлары» журналларының төпләмнәрен актар. Ул төпләмнәрдә бүгенге көнебез өчен бик кызык булып күренерлек мәкалә, хикәя-повесть, роман, шигырь һәм поэмаларга юлыкмый калмассың.

Түбәндә «Безнең юл» журналында 20—30 нчы елларда басылган кайбер әсәрләр китерелә. Күп кенә сүзләрнең шул вакыттагы язылыш-әйтелеш үзенчәлекләре саклана.

**Мөхәммәт МӘҺДИЕВ.**

# Ч е н ә к ә й

## Бер җыр

I

Өзгәләнеп
  Сызлана бит
  Бер тамыр.
Ут йөрәктә
Шул бәлагә
  Бер дәва юк,
  Бер чара юк,
  Бер сабыр.
Сызлый башкай,
Сыкрый күкрәк...
  Аһ... Күңелсез!
  Ой... Авыр!...

II

Ник йөрәккәй телгәләнде,
Ник кабынды-янды соң?..
Мин балага
Бу бәлане
Нинди көчләр салды соң?..
    Кайда ярдәм?
    Яхшы дуслар
Кайсы җирдә калды соң?!

III

Кайда качыйм,
Кайда качыйм?
    Кай урыннарга барыйм?..
Күзләремне кайда ташлыйм?..
Кайсы йолдызга карыйм?

———————

    Әйтегез!
Бу хәнҗәремне
    Кайсы шәйтанга кадыйм?!..

## Бирегезсәнә кызыл чәчәкне

Кан кырында,
Көрәш чорында
    Мин югалткан идем юлымны;
    Мин югалткан идем юлымны,
    Мин чуалткан идем уемны
    Ялкынланган җиңү туенда;
    Яза-яза меңнәр турында
    Мин оныткан идем җырымны.

# Г. Кутуй

## Октябрьдә

I

Көн көнендә,
Җир
Җирендә
Ай үбешә
Җир белән
Бакыр башлар
Кузна уйный
Ут эчендә
Җил белән.

II

Көн ватылган,
Күк
Егылган,
Җир төрелә,
Төн...
Яна...

Чатыр... чатыр...
Өйләр ишелә.
Җан бирәләр...
Ха-ха-ха-ха.

III

«Мең»-
гә мең мичкә тәгәри,
Таһарәтләр алына.
Ут әтәче: ки..ки..ки-
ри-
кү!
Җир зырылдый —
Октябрьдә Коминтернга
Машыйна!

# Г. Рәхим

## Госманлы җыры

Кош кебек, очкан идем мин
Күккә зур гайрәт белән,
Сынды да көчле канатлар,
Мин егылдым шул түбән.
Җилкәләргә йөк булып тик
Калды дәрт-хәсрәтләрем;
Йөз дөягә йөк булырлык,
Һай, минем ул дәртләрем.
Кышкы салкын, җил, буранда
Мин йөрим таулар гизеп;
Кайгым артымнан килә гел,
Кайда барганым сизеп.

## Сәгыйть Рәмиевнең үлеме турында

Сәгыйть Рәмиев революциядән элекке татар әдәбиятының иң көчле, иң бөек таланты иде. Сәгыйть күтәрелгән югарылыкка ул вакытта татар шагыйрьләреннән берәү дә күтәрелә алмады бугай. Бу вакытлар «Сәгыйтьме, Тукаймы?» кебегрәк сөальләр йөрсә дә, берәү дә чыгып Тукайның Сәгыйтьтән югарылыгын дәгъва итәргә базмады, яхут базса да, исбат итә алмадылар шикелле. Дөрес, Тукайга караганда ул бик аз язды, аз җырлады, ләкин сүз һәм мәгънә ягыннан ул Тукайга караганда, һич шөбһәсез, күп югары торды. 1917 елның февраль революциясенә чаклы Сәгыйть кулындагы бу беренчелекне һичбер кеше ала алмады. Сүзләрдән генә түгел, хәтта шөбһәләрдән дә югары торганы хәлдә, ул аны ифрат зур бер дан һәм шәүкәт белән саклап килде...

Сәгыйть белән мин революциягә чаклы таныш түгел идем. Аның белән беренче тапкыр 1922 елда Уфада таныштым. Ул вакытларда әле аның безнең эшебезгә, революциягә карашы әйле-шәйлерәк төсле күренәдер иде. Ләкин соңгы еллар инде аның карашында ифрат зур үзгәреш тудырганнар иде. Күптән түгел булып үткән шундый бер вакыйганы хәтерлим мин.

Гәзит укучыларының исендәдер, күптән түгел Төркия гәзитләреннән алынып, Гаяз Исхаков турысында безнең гәзитләребездә бер хәбәр басылды. Гаяз Исхаков анда ниндидер бер төрек гәзитендә большевикләрне сүгеп бер мәкалә язган икән, шуңар каршы төрек гәзитләре бик зур гауга куптарып, Гаязга каршы протест мәкаләләре язганнар һәм, Советлар Союзы белән без-

нең арадагы дуслыкны бозарга йөриләр диеп. Гаяз ише контраларның Төркиядән сөрелүен таләп иткәннәр иде. Сәгыйть бервакыт шушы хәбәрне укый да әйтә:

— Бу Гаязга мин әле булса бераз ихтирам саклап йөридер идем... Йә соң инде революциянең тугызынчы елында, большевиклар тоткан юлның дөреслеге бөтен дөнья алдында исбат ителеп торган бер вакытта, шундый ахмаклык сатып йөреп буламы соң?—ди. Ул Гаяз һәм аның яраннарына нисбәтән үзендә ифрат түбән бер караш туганлыгын сөйли. Менә бу вакыйга, минемчә, Сәгыйтьнең соңгы вакыттагы карашын һәм аның нинди фикерләр белән сулу алганлыгын бик ачык күрсәтә. Сәгыйтьнең соңгы вакыттагы юлы менә шул иде. Үзенең шушы юлда торганын ул эш белән дә исбат итте һәм гомеренең калган өлешен бөтенләе белән совет эшенә, совет илендәге төзү эшләренә багышлап үлде..

**Газыйм КАСЫЙМОВ**

## Татар буржуазиясенең фантазиясе

...Әдәбият тарихында реализмның ачык консерватизм белән кочаклашып барганын күрергә мөмкин булган кебек, романтизмның да прогрессив төсендә булган моментларын күп кенә очратырга мөмкин. Татар буржуа әдәбиятының йөзен билгеләгәндә бу моментларга бик нык игътибар итәргә кирәк...

...Романтизм хәзерге вакытта пролетариат әдәбияты өчен бөтенләйчә чит, кирәксез, баштанаяк консерватор агым. Дөньяга диалектик материалистларча караган (карарга тиешле булган) пролетариат язучылары романтизмның һичбер төренә мохтаҗ түгелләр...

...Ф. Әмирханның китаптан укып булса да Марксны белүенә без бик нык шикләнеп карыйбыз. Хәтта ачыграк иттереп: Фатих Марксны китаптан гына укып булса да белмәгән дип әйтергә мөмкин. Аның социаль фәннәр, иҗтимагый тәгълиматлар белән танышуы һичбер вакытта да Марксны белүгә чаклы күтәрелә алмаган.

**Г. ГАЛИ**

## Фатих Әмирхан ни өчен төшенкелеккә бирелде?

...Фатих Әмирхан, буржуа сыйнфы сәнгатьчесе буларак, буржуа сыйнфы алга барганда алга барды. Буржуа сыйнфы бетүгә йөз тоту белән бергә ул да зәгыйфьләнде, төшенкелеккә йөз тотты. Пролетариатның бөек хәрәкәте идеяләреннән авыз итмәде... тәнкыйтьчеләр бер сыйныфның бетүгә йөз тоткан вакытында ул сыйныфның сәнгатьчеләрендә дә төшенкелек, зәгыйфьләнә башлау килеп чыгуын күрә алмадылар...

...Әгәр Ф. Әмирхан пролетариатның ирек хәрәкәтләреннән беркадәр авыз итәрлек хәлдә булса иде, билгеле, ул үзенең көчен мәгълүм бер үлчәүдә арттыра алган булыр иде.

**Г. ТОЛЫМБАЙ**

## Тагын Дәрдемәнд әсәрләре турында

...Дәрдемәнд—либераль, аңлы буржуа. Ул башка милләтләрнең алга киткәнен, татар милләтенә шулар кебек булганда гына яшәргә мөмкин икәнлеген, шул вакытта гына татар буржуасының тулы чәчәк атачагын бик яхшы күрә ала. Монда да ул үзенең шигырьләрен үз сыйнфының файдасына хезмәт иттерә,—алга атларга, тәрәккъыйгә өнди:

Кил, и башчы, агачны юнма юкка,
Кирәк булмас... угыңны як, кил, утка!
Ачып гайрәт* белән гыйбрәт күзеңне,
Кара читләргә... туплар китте хутка!

—ди. Укны ташлап, тупка күчәргә өнди. Бу бит иң эре кул буржуа идеологиясе.

Дәрдемәнд болар белән генә чикләнми. Ул үзенең «нәсихәт»ендә ачыктан-ачык агитациягә тотына; дөнья куарга куша:

Җитәкләргә тырыш дөньяви дүнәнне,
Икенең берсе: йә сине җитәкләр.
Алып барыр үзеңне бер чокырга,
Барырсың — бардырыр, тәртер, этәкләр.
Моңа ни ул усал карчыкның име:
Ку артыннан, ярыймы, юкмы диmи.
Җитеп тә бер сикертеп типсәң артын,
Дәни бит ул — үзең тигәнгә тими.

Күрдегезме?..

...Дәрдемәнд белән җәмгыятьнең зур бер өлеше — хезмәт халкы арасында даими рәвештә җәнҗал булырга тиеш. Ул никадәр генә эшчеләргә:

Гәрчә күрсәң ата-анадан җәфалар күп заман,
Син җәфа итмә аларга, бәлки — хөрмәт, и угълан!

— сүзләре белән сыйнфый көрәштән туктатырга тырышмасын, ул көрәш көннән-көн үсә, кискенләшә генә бара. Ул көрәшне җанландыручылар, аңа көч бирүчеләр, аның энтузиазмын күтәрүчеләр дә табыла. Менә монда инде эшләр бөтенләй башкача тора. Монда инде Дәрдемәнд, бу көрәшкә үз шигырьләре белән ярдәм итмәү генә түгел, башкаларны да тыя башлый...

...Безнең алдыбызда пролетариат һәм аның белән элемтәдә булып социализм төзүдә кулга кул бара торган батраклар, авыл ярлылары, уртача хәлле крестьяннар әдәбиятын төзү тора. Әнә шул төзү өстендә бик күп кенә санда яшь көчләр эшләп яталар...

...Ләкин буржуа мирасы белән файдалану ул зур сәяси сыйнфый сизгерлек сорый; ул мирасны масса арасына таратканда, аның эчендә булган сыйнфый йөзне бик нык ачып бирергә кирәк. Моның өчен шул мирасның сәяси, иҗтимагый кыйммәтен бик нык аңларга, чын-чыннан марксизм белән коралланырга кирәк...

С. МОРТАЗИН.

*Текстларны матбугатка әзерләүче* — Искәндәр МӘҺДИЕВ,
*Казан дәүләт университеты студенты.*

*Ялгыш китерелгән; дөресе исә—хәйрәт (аптырау, хәйран булу, гаҗәпләнү) — И. М.

# ТАРИХИ КАТЛАМНАРЫБЫЗ

Туган җир, туган туфрак, туган нигез. Алар һәркем өчен газиз һәм кадерле. Моның шулай икәнлегенә мин Ульян өлкәсендә урнашкан татар авылларына топонимик экспедициягә чыгу вакытында тагын бер тапкыр инандым. Туган якларын, туган туфракларын өзелеп ярата торган халык яши икән бу төбәктә.

Бу өлкә авылларына килеп кергәч, күзгә ташлана торган иң беренче үзенчәлек — ихаталарның төзек, йортларның нык һәм күркәм итеп салынуы, халыкның тормышы мул һәм яхшы булуы. Авыл урыннары оста сайланган, алардагы йорт тәрәзәләреннән ниндидер якты ямь һәм нур сирпелеп тора. Ул нур һәм ямь йөрәкнең һәр күзәнәгенә килеп кагыла һәм күңелне хозурландыра: кайда гына яшәсә дә, югалмый икән кардәшләребез. Ныклы гаиләләр төзиләр, акыллы һәм эшчән балалар үстерәләр, әти-әни, әби-баба хакын һәм хәтерен саклауны югары дәрәҗәгә куялар. Туганнар, нәсел-нәсәп бер-берсе белән тыгыз аралаша, авыл халкы, күршеләр үзара дус көн күрә, авыр минутларда һич кичекмичә ярдәм кулы сузышалар. Балалар да монда тыңлаучан, күңелләренә шәфкать, миһербан кебек төшенчәләр ят түгел. Ата-ананың балаларны, яшь буынны тәрбияләүгә зур көч куюы нык сизелә.

Республикабызда һәм аннан читтә яши торган милләттәшләребез башка халык вәкилләре белән дус яши, даими аралашып тора, үзләрен дә кимсеттерми, башкаларны да какмый. Төрле милләтләр арасында кузгалган хәвефле низаглар заманасында бу аеруча игътибарга лаек. Татарларның хезмәт яратучы халык буларак даны еракларга таралган. Өйләр, авыллар чисталыгы да үрнәк булып торырлык. Бу гадәтләр ерак әби-бабалар тарафыннан буыннан-буынга тапшырылган һәм ул халыкның канына сеңгән.

Шунысын да әйтергә кирәк: бу якларда яши торган милләттәшләребез дә борынгы болгар җиренең игелекле туфрагында көн итә. Алар салган авылларның күркәмлеге — борынгы бабаларыбыз төзелеш традициясен дәвам итү нәтиҗәсе.

Күпсанлы урта гасыр чыганакларын анализлап чыкканнан соң, Р. Хеннинг дигән галим, Хәзәр каганаты җирләренең төньяк-көнбатыштагы чикләре вакыты белән Ука елгасына кадәр җиткән, дип яза. Идел-Кама болгарлары дәүләте чикләре дә шул ук су ярларына кадәр сузыла. Бу фикер тарихи чыганаклардагы мәгълүматлар белән шөбһәсез дәлилләнә. Гомерен Болгар дәүләтен, Болгар каласын өйрәнүгә багышлаган Мәскәү археологы А. П. Смирнов:«Болгар шәһәре Идел буе төбәгенең генә мәдәният үзәге булып калмаган, бәлки көнбатышта урнашкан өлкәләргә дә шундый ук көчле йогынты ясаган», дигән нәтиҗәгә килә. Идел ярына урнашкан Самара, Саратов, Ульян һ. б. өлкәләр җирләрендә дә археологлар болгар дәүләтенә мөнәсәбәтле шәһәр һәм авыл хәрабәләре табалар. Башка тарихи чыганакларда да Идел буйларында болгар төркиләренә нисбәтле күп мәгълүматлар бирелә, аларда Каспий диңгезе Болгар диңгезе дип тә атап йөртелә. 965 елда Киев кенәзе Святослав Хәзәр каганатын тар-мар иткәннән соң, туздырылган каганат биләмәләренең күп өлеше Идел суы ярларында урнашкан, чикләре Каспий диңгезе тирәләренә кадәр килеп җиткән Идел-Кама болгарлары дәүләте җирләренә кушыла. Святослав Болгарга һөҗүм иткәннән соң, болгарларның бер өлешен тәшкил иткән суарлар Түбән Идел тирәләренә күчеп утыралар. Алар шул тирәдәге Сәкъсин шәһәрен төзүдә дә катнашкан, ахры. Урта гасырлар галиме М. Кашгари Сәкъсин шәһәрен искә алганда, аны суарлар шәһәре дип атый. Авыр сынау килгән вакытларда сәкъсинлеләр һәрвакыт болгарларның уң кулы, ярдәмчеләре булган. Бу турыда урыс елъязмаларында күп мәгълүматлар саклана. Аларда Иделнең түбән агымындагы халык «түбән болгарлар» дип тә йөртелә. XII йөз авторы әл-Гарнәти мондый мәгълүмат калдыра. «...Сәкъсин шәһәре уртасында болгарлар һәм аларның әмире яши. Аларның бу шәһәрдә җомга укый торган җәмигъ мәчетләре бар». 1229 елда монголлар һөҗүме башлангач, Сәкъсин халкының күп өлеше Идел-Кама болгарларына булышырга килә.

Халкыбызның үткәнен ачыклауда төрле атамаларны, шул исәптән, Чирмешән исемен тикшерү кызыклы нәтиҗәләр бирә. Чирмешән төрле тарихи чыганакларда очрый. 921—922 елларда Идел Болгарстанына Багдад халифәтеннән килгән илчеләр арасындагы Әхмәт ибн Фазлан язмаларында ул Җәрамсан, рус елъязмаларында Черемшан, Әлки районының Ташбилге авылы янында табылган кабер ташы язмаларында Чәримсан язылышында бирелгән. Чирмешән — тарихи актларда, Казан, Самара, Сембер губерналары-

ның торак пункт атамаларын исәпкә алу исемлегендә, тарихи-географик, географик-статистик, тарихи-этнографик һ. б. чыганакларда еш телгә алына.

Республиканың көньягында Олы Чирмешән елгасы ярына район үзәге Чирмешән авылы урнашкан. Кече Чирмешән елгасы ярында да Чирмешән авылы нигезләнгән. Казан шәһәре писцовая кенәгәсендә Казан артындагы Нурма суы бассейнында Чирмешән авылы булуы әйтелгән һәм бер тарихи чыганакта шул ук төбәктәге Әшнәк суының уң кушылдыгы Чирмешән гидронимы теркәлгән. Апас районында Чирмешән суы — Боланың сул кушылдыгы. Чирмешән суы якасына Чирмешән авылы урнашкан. Аның янында борынгы болгар чорына мөнәсәбәтле авыл хәрабәләре табылган. Тарихи чыганаклардан күренгәнчә, хәзерге Апас районындагы Багыш исемле авыл элек Өченче Чирмешән исемендә йөргән. Апас районында чирмешән сүзе белән шактый микротопонимнар ясалган: Чирмешән чаты (кыр), Чирмешән чишмәсе, Чирмешән буе һ. б. Н. Ф. Калинин Тәтештән 15 чакрым түбәндәрәк Чирмешән елгасы булуын язган.

Чирмешән атамасы табылган төбәкләр йә Идел болгарлары дәүләте составында, яисә аның сәяси һәм икътисади йогынтысын үзләренә сеңдереп яшәгәннәр. 1236 елгы вакыйгалардан соң үз туган нигезләрен ташлап китәргә мәҗбүр булган болгар халкы күңеленә якын таныш атаманы яңа урыннарда үзләштергән су чыганакларына һәм шулар ярына үзләре төзегән торак пунктларга биргәннәр. Кармасан һәм Чирмәсән — Башкортстандагы гидронимнар. Чирмәсән исемле кичү 1773—1775 еллардагы Пугачев хәрәкәте белән бәйләнешле документларда очрый. Пермь өлкәсендә дә Чирмешән суы һәм аның ярында Чирмешән авылы бар. Мари республикасының Бәрәңге районында да ул очрый. Саратов өлкәсенең Хвалын шәһәреннән алты-җиде чакрым ераклыкта, христиан динендәге монахлар яшп торган Чирмешән исемле атаклы монастырь булган. Элекке Болгар дәүләте җирләренә урнашкан шул ук шәһәр янында Чирмешән атамасын ике күл, бер санаторий һәм ике ял йорты алган. Самара шәһәрендә бер урам Чирмешән исемен йөртә. Дмитровград каласында бер футбол командасына Чирмешән исеме бирелгән. Югарыда саналган барлык Чирмешән атамалары Идел болгарлары белән бәйләнешле. Чирмешән исемен Алтайда, Югары Иртеш бассейнында бер елга йөртә икән. Әгәр бу атама соңыннан барлыкка килмәгән булса, Чирмешән болгар чорларына кадәрге төркиләргә мөнәсәбәтле була. Бу күренешнең дөреслеге тарих һәм археология чыганаклары белән раслана. Борынгы төрки кабиләләр болгарлар арасына кереп үз атамаларын югалтмаганнар, бергәләшеп гомер кичергәннәр.

Чирмешән сүзенең килеп чыгышы, нәрсә аңлатуы белән күп галимнәр кызыксына. Г. Саттаров бу гидронимны Чирмешләр елгасы, ягъни ярында марилар яшәгән елга дип карый. М. Зәкиев бу атаманың мәгънәсе чирмешән «майлы, сагызлы урман елгасы» дип аңлата. Чынлап та элек бу елга бассейны калын урманнар белән капланып алган була. Р. Г. Әхмәтьянов чирмешән сүзен «гаскәр җыела торган урын», «гаскәр җыела торган урынга ориентир» дип уйлый. Нәкый ага Исәнбәт әлеге сүзне төрки кабиләләр белән бәйләп карый. Аныңча, Чирмешән атамасы борынгы дастаннар батыры Чиру Мәмшәнгә мөнәсәбәтле. Чиру — гаскәр дигән сүз, Чиру Мәмшән гаскәр йөртүчене, гаскәр башын аңлата. Равил Фәхретдинов Олы Чирмешән һәм Кече Чирмешән елгаларына археологик яктан тоташтан бик җентекле разведка ясап чыга. Ләкин яр буйларында, тирә-юнендә мари-чирмешләргә нисбәтле булган бер генә истәлек тә тапмый. Ул, Чирмешән атамасының төрки телләр нигезендә аңлатылырга тиешлегенә һич шикләнми. Мари галиме Ф. Гордеев Чирмешән атамасы, халыкларның бөек күчеше вакытында хәзерге Башкортстан җирләреннән Урта Идел буйларына кысып чыгарылган соңгырак чор сарматларга бәйләнешле, сармат этнонимына нисбәтле, ягъни Сармат елгасы дип уйлый. Төрки телләр фонетикасында киң әйтелешле а авазының и гә һәм и е күчеше табигый күренеш (Сабир-Сибир-Себер, Сармат-Сирмеш-Чирмеш һ. б.). Татар теле шивәләрендә шулай ук с-ч-т авазлары күчеше дә күзәтелә. П. Д. Шестаков та сармат сүзе белән сярмысның аһәңдәшлегенә, охшаш яңгырашына игътибар итә. Димәк, сярмыс-чирмәш фонетик төрдәшләр. Яр буйларына үзләре килеп урнашкан елганы үз этнонимнары белән Сармат суы дип атаулары бик ихтимал. 1988 елның җәй аенда Уфа археологлары Оренбургтан йөз чакрым көнбатыштарак урнашкан Филипповка авылы янындагы сармат курганнарыннан өч йөзгә якын бик матур итеп эшләнгән әйберләр тапканнар. Табылдыклар арасында иң күбесе — болан, сайгак, кабан, бүре, юлбарыс, балык, ташбака, фантастик кошлар һәм башка җәнлек, кош сурәтләре. Галимнәр уйлавы буенча, скиф кабиләләренең бер өлеше төрки телдә сөйләшкәннәр. Алар үз культураларын төрки сарматларга, сарматлар

һуннарга, һуннар болгарларга, болгарлар бәҗәнәк, угыз, кыпчак һәм башка төрки халыкларга биргәннәр. Димәк, Идел суы буендагы бу җирләрдә бары тик болгарлар гына яшәгән дигән караш та дөрес булмас иде. Монда тагын башка төркиләр: һуннар (сөннәр), бәҗәнәкләр, угызлар, кыпчаклар һәм аларның бер өлеше булган нугайлар, төрле бүтән кабиләләр яшәгән. Бер генә халык та саф, ялгыз этностан гына оеша алмый. Төп нигезендә болгарлар ят-кан татар халкы формалашуга югарыда саналган кабиләләр дә өлеш кертkән. Алар бу җирлектә үз эзләрен географик атамалар рәвешендә калдырган.

Димәк, тарих, археология кебек фән мәгълүматлары белән беррәттән, татар халкының килеп чыгышы мәсьәләләрен хәл иткәндә географик атамаларны, шул исәптән су чыганаклары исемнәрен дә өйрәнү әһәмиятле. Чөнки бер кше атамалар тирә-юньнәрендә элек яшәгән кабилә-кавемнәргә мөнәсәбәтле рәвештә барлыкка килгәннәр. Димәк, елга-су һәм кизләүләр халыкның үткән тарихын тикшерү өчен ышанычлы чыганак буларак та зур әһәмияткә ия булып торалар.

Соңгы вакытларда газета битләрендә Урта Идел тирәләрендә, ягъни элек-электән фин-угыр халыклары яшәгән җирләрдә татарлар — килмешәк халык, дигән фикер үткәрелә. Галимнәр тарафыннан, елга-су атамалары барлык төр географик атамаларга караганда да борынгырак, дип игълан ителә. Югыйсә Урта Идел буйларындагы иң зур елгалар — Идел һәм Чулман (Кама) атамаларын абориген дип йөртелгән фин телле халыклар үз телләреннән чыгып атый алмаганнар, әзер төрки атамаларны гына кабул иткәннәр. Мариларның бабалары Иделне төрки сүзгә тоташа торган Иул, ә Чулманны (Кама) Шолман дип атаганнар. Бу исә фин телле кабиләләрнең бу тирәләрдә беренчел булуын бик нык шик астына куя.

Татарларның нигезен безнең эраның беренче гасырларында һәм аннан да элек яшәгән җирле төрки кабиләләр тәшкил итә. Аның тарихы IX—XIV гасырларда Европаның төньяк-көнчыгышындагы матди һәм сәяси яктан шактый алга киткән Болгар дәүләте белән бәйләнгән. Бу дәүләт Идел һәм Урал буйларындагы халыклар тарихында әһәмиятле урын алып тора, ә антик кабиләләр бу тирәләрдә яшәгән төрки халыклар, беренче чиратта, татар халкы формалашуда зур роль уйный. Галимнәр фикере буенча, Идел-Чулман болгарлары, этник яктан күп төрле кабиләләрдән торган. Борынгы Византия чыганакларында болгарлар һун кабиләләре буларак искә алына. Һуннарның төрки икәнлеге фәндә күптәннән исбат ителгән. Димәк, Идел-Кама болгарлары төзегән дәүләттә төркиләр күпчелек һәм әйдәп баручы көч булганнар. XII йөздә Идел-Чулман Болгарстанын үзе килеп күргән Әбү Хәмит әл-Гарнәти Болгар шәһәренең тирә-юнендә бихисап төрки кабиләләр яшәвен яза. Башка урта гасыр чыганакларында да болгарлар төрки кабиләләр итеп карала. Зәкиев, болгарларны комплекслы тикшереп, ягъни тарих, археология, этнография, тел, антропология һ. б. фәннәр мәгълүматларын искә алып, алар гадәти төрки телдә сөйләшкәннәр, дигән нәтиҗәгә килә. Азов диңгезе яры буйларында VI—VII йөзләрдә яшәгән Бөек Болгар дәүләте хәзәрләр тарафыннан тар-мар ителгәч, болгарларның бер төркеме кардәш төркиләр янына, Урта Идел буйларына килеп утырган. Болгар сүзенең тамырлары бик борынгы, безнең эрага кадәрге заманга барып тоташа. Мәсәлән, әрмән географы Мовсес Хоренацинның «География» (V йөз) дип аталган хезмәтендә сүрияле Мар Аббас Катина хәбәренә таянып, безнең эрага кадәр 149—127 елларда ук Азов буе болгарларының Әрмәнстанга басып керүе турында яза.

Академик Б. Д. Греков һәм Н. Ф. Калинин Болгар шәһәренең буш урында төзелмәвен, бәлки аның борынгы авыл нигезендә барлыкка килүен язалар. 1938 елда Болгар шәһәре хәрабәләренең төньяк-көнчыгыш өлешендә алып барылган археологик тикшеренү нәтиҗәләре күрсәткәнчә, бу урында безнең эраның беренче меңъеллыгының беренче яртысында ук авыл булган. Нинди культурага нигезләнгән, нинди авыл ул, дигән урынлы сорау туарга мөмкин. Урта Иделдә болгар алды чоры мәдәнияте дип галимнәр имәнкискә кабиләләре калдырган истәлекләрне әйтәләр. Яшәүләренең соңгы дәвере VIII йөзгә карый. Археология мәгълүматлары күрсәткәнчә, болгар шәһәрләре һәм авыллары шушы культурага караган җирлектә салына. Алар Урта Иделнең Зөя сулары аккан җирләреннән алып көнчыгышта Дала Зәе (Степной Зай) елгасының түбән агымнарын, Чулманның уңъяк яры буйларын, ә көньякта Майна-Чирмешән киңлекләренә кадәр булган үзәк районнарны биләгәннәр. П. Н. Старостин һәм Р. Фәхретдиновлар язуына караганда, болгар заманына кадәрге төрки культурага мөнәсәбәтле бу кабиләләр, болгар мәдәниятен алып килүче болгарлар белән бергә кушылып, бердәм Идел-Кама Болгарстаны культурасын формалаштырганнар.

Ә безнең эраның беренче меңьеллыгыннан да элек Урта Идел буйларындагы урман-дала зонасында кемнәр яшәгән? Безнең эрага кадәр VIII гасырлардан алып II йөзләргә кадәр бик киң җирләрне: Алтай, Монголия, Тибет, хәзерге Казагстан, Кавказ, Дунай һәм Кара диңгез буйларын антик дөньяда скиф исемен йөрткән күп төрле кабилә-кавемнәр җыелмасы били. Күп кенә галимнәр, скифлар арасында төрки телдә сөйләшә торганнары да булган, дигән фикердә тора. Икенчедән, әлеге җирләр борынгы төрки халыклар карамагында булган төбәкләр белән туры килә. Өченчедән, борынгы төркиләр тарихын җентекләп өйрәнгән М. И Артамоновның тикшеренүләренә караганда, күрсәтелгән җирлекләрдә табылган археологик истәлекләрнең Кара диңгезнең төньягында, Идел буенда һәм Урта Азиядә табылган һәм өйрәнелгән шундый ук истәлекләр белән этник тугандашлыгы борынгы Кытай чыганакларында китерелгән мәгълүматлар белән дә дәлилләнә. Дүртенчедән, антик скифлар чорыннан калган кайбер исемнәр һәм алар составында очрый торган кайбер компонентлар һәм калып формалары, соңыннан шул ук җирләрдә яшәгән төрки халыклар һәм Идел буе татарлары да куллана торган географик атамаларга охшаш һәм аваздаш. Мәсәлән, Геродот тарафыннан скифлар теленнән язып алынган легенда персонажлары Таргитай, Колаксай, Арпаксай һәм Липоксай исемнәре безнең өчен зур әһәмияткә ия. Аларның мәгънәләре төрки телләр материалыннан чыгып аңлатыла ала икән.

Төрки халыклар яши торган төбәкләрдә Арпаксай, Колаксай һәм Липоксай исемнәре белән типологик яктан охшаш булган дистәләгән топонимнар табыла. Хәзерге Татарстанда, Бөгелмә районында Аксай суы — Зәй кушылдыгы, Аксай — Куйбышев районындагы Актай бассейнындагы күл. Башка төрки җирлекләрдә: Сай — Ош һәм Сәмәрканд өлкәсендәге топонимнар. Аксай-Курмояр һәм Аксай-Есаул — Дон суының сул кушылдыклары, хәзер Цимлян сусаклагычына коялар. Кавказ, Урта Азия, Төрекмәнстан, Казагстан һәм Алтайдагы күпләгән елгалар Аксай исемен йөртә. Шунысы әһәмиятле, югарыда аталган скиф исемнәрендә төрки телләрдә булмаган бер генә аваз да юк. Алардагы ачык һәм ябык иҗекләр системасы төрки телләрдәгечә. Синтаксик яктан төрки телләрдәге сүзләр бәйләнешенең борынгы формасы, ягъни изафәнең беренче тибына нигезләнгәннәр. Сүзләр бәйләнешенең мондый төре болгар чорында чәчәк аткан Җүкәтау һәм Тубылгытау шәһәрләре атамаларында да күзәтелә.

М. Зәкиев һәм И. Мизиевларның язуына караганда, Геродот тарафыннан аңлатылган аерым скиф сүзләренең мәгънәләре төньяк иран телләре материалыннан чыгып ачыклана алмаган вакытта, төрки тел материаллары нигезендә бик җиңел генә аңлатыла ала икән.

Көнчыгыш Европада иң зур елгалардан Идел һәм Җаек атамалары безнең эраның II гасырында яшәгән Птолемей әсәрләрендә Ител һәм Даик рәвешле телгә алына. Монда күрсәтелгән фактлар төрки телле кабиләләрнең Идел һәм Урал буйларында антик чорлардан ук яшәүләрен күрсәтә. Татар халкының этник тарихы бик борынгы заманнардан бирле Көнчыгыш Европада яшәгән төрки телле кабиләләргә барып тоташа. Бу фикер урта Идел буйлары сәнгатен тирәнтен өйрәнгән галим Фоат Вәлиев ясаган нәтиҗәләр белән аваздаш. Ул болай дип яза:«Урта Идел һәм Урал буйлары сәнгате үзенең башлангычын бик борынгы заманнардан ала. Культура ягыннан үсеш дәрәҗәсе төрле баскычлардан торган, соңгы палеолит гасырлардан алып (безнең эрага кадәр 40 мең еллар элек) башланган һәм урта гасыр чорларына кадәр бер-берсен алмаштыруларын дәвам иткән кабилә-кавемнәр сәнгате белән нык бәйләнешле».

Кызганыч, борынгыдан килгән төрки атамалар алыштырыла баралар. Шушы җәһәттән төрки исемнәрнең СССР картасыннан төшеп калуын, гомумән, тарихи атамаларның яңалары белән алмаштырылуын аныклап күрсәтү өчен бер мисалны басым ясап әйтәсе килә. Чөнки шул бер атама гына да халкыбыз тарихы өчен никадәр зур әһәмияткә ия. Ә алыштырылган борынгы атамаларның саны бихисап. Әйтик, Кырымдагы Акмәчет авылы Белая Церковь, Сөт елгасы — р. Молочная һ. б. дип алмаштырылган. Үзебезнең Татарстан төбәгендә дә борынгы болгар бабаларыбызга мөнәсәбәтле Болгар, Суар, Ашлы һ. б. кебек атамаларның тамырлары көчләп киселгән, алар республика картасында юк инде. Элекке карталарда Самара өязе җирләрендә Моча исемле елга билгеләнгән. Ул Идел суына сул яктан кушыла (хәзер Саратов сусаклагычы кушылдыгы). Гәрчә бу елгага Чапаевның бернинди мөнәсәбәте булмаса да, атама Чапаевка дип үзгәртелгән. Моча атамасы 921—922 елларда Әхмәт ибн Фазлан язмаларында ук әле Бачаг язылышында искә алына. Татар теле сөйләшләрендә б һәм м авазлары чиратлаша. Әлеге Моча атамасы белән бер ояга тагын Түбән Новгород һәм Мәскәү

өлкәләрендәге Моча атамалы сулар (Иделнең сул һәм Пахраның уң кушылдыклары) кергән атамалар Советлар Союзының барлык төбәкләрендә бик күп икән. Бу очракта әлеге атамаларның славян, төрки һәм фин-угыр телләренә мөнәсәбәтләрен аерып күрсәтергә кирәк. Бөтен мондый атамаларны бер ояга җыеп тутыру дөреслеккә туры килми. Иделнең түбән агымнарында «юеш тозлак урын», «кипми торган төш» мәгънәсен белдерә торган мочаг, Тувадагы мочага, Урта Идел буйларындагы моча, мочали формалары безнең фикерне куәтлиләр. Моча тамырын эченә алган түбәндәге атамаларны югарыда әйтелгән фикергә таянып анализларга кирәк. Бу рәткә Татарстан республикасы һәм Самара өлкәсендәге Мочали, Мари республикасының Звенигов районындагы эшчеләр поселогы Мочалище, Ульян өлкәсендәге Мочалейка гидронимы һәм аның ярына урнашкан Иске Мочалей һәм Яңа Мочалей авыллары, Ука суы бассейнындагы елга һәм чокыр атамалары Мочалей һәм Олы Мочалей керә. Моча(ә) иле Мочали мочалы (чагыштыр: Сувари — Суварлы, Сәкъсини — Сәкъсинле) соңыннан мордва теле яңгырашына яраклаштырып үзгәртелгән һәм «мочалей» дип йөртелә башлаган (мордва халкының эрьзя төркеме телендә лей «елга» мәгънәсендә кулланыла). Борынгы төрки чорларда эл-ил сүзләре ил, авыл төшенчәсен белдергән. Кайбер очракларда урыс әйтелешендәге атамаларда борынгы төзелеш калыплары сакланып калган. Бу очракта да вакыт узу белән атаманың татарча әйтелеше беркадәр үзгәргән: Мочали-Мунчәле. Сөйләмнәре «ц» лаштыра торган мишәрләр (сергач, буа, керенский) яши торган җирлектә Мочалы атамасы алган торак пунктлар еш очрый. Р. Мөхәммәтова, Мочалы атамалары «мочарлы»дан кыскарып үзгәргән этнонимик термин «мочар»га мөнәсәбәтле, мочарлар исә төркиләшкән угырлар дип фараз итә. Хәзерге Мочали атамасы әлек, күрәсең, Моча(г) иле рәвешле кулланылган булса кирәк. Сузык авазлар кыскаруы нәтиҗәсендә ул Мочали рәвешен алган. Мочар, мажар, мишәр атамалары бер тамырга барып тоташа һәм аларның нигезендә мишә сүзе ята дигән фикер бар. Мажар белән мишәр сүзләренең әйтелешендә фонетик яктан беркадәр үзгәреш бар (а — и h. б.). Төрки телләрдә киң әйтелешле авазларның тар әйтелешле авазларга күчүе законлы күренеш: сабир — сибир — себер h. б. А авазының Ә гә күчүе татар теле сүзләрендә еш күзәтелә. Чистай шәһәре зиратында 1311 елга караган болгар кабер ташында Мажар исеме теркәлгән.

Мишә атамасының килеп чыгышын борынгы төрки бабаларыбыз телендә кулланылышта йөргән бишә — «урман, куаклык, агачлык» сүзе белән бәйләп карыйбыз. Татар теле сөйләшләрендә б-м тәңгәллеге хас икәнлекне исәпкә алып, бишә-мишә сүзенең бер үк булуын һәм югарыда күрсәтелгән мәгънәдә йөрүен күрәбез. Элек Мишә елгасы тирәләрендә калын кара урман үскән. Суы күп булган. Аның суларыннан сал агызганнар. Урман арасына килеп урнашкан борынгы бабаларыбыз бер-берсен судан агып килгән йомычкага карап су юлы белән кире барып таба торган булганнар. Тирә-юньдәге су чыганакларына атама биргән вакытта халык аларның күзгә бәрелеп тора торган характерлы үзенчәлекләренә игътибар итә. Тайгага охшаган калын кара урман арасыннан аккан елганы җирле халыкның «Урман елгасы» дип атап йөртүе гаҗәп түгел. Кардәш төрки халыклар телләрендә дә мишә сүзе агачның төрләрен, урманны белдерә торган мәгънәдә йөри. Мисалга, әзербайҗан телендә мешә «урман» мәгънәсендә кулланыла.

Тарихчы галимнәр эзләнүләрен нигез итеп алып, М. Зәкиев болай яза:«Көнчыгыш Европаның иксез-чиксез киңлекләрендә башка кабиләләр белән аралашып яшәгән мажар, мишәр кабиләләренең эзләре безнең эрага кадәр VII—V йөзләргә карый (Геродот тарафыннан искә алынган акацир, агадирлар). Археологик мәгълүматлар күрсәтүе буенча, безнең эраның II йөзләреннән Ука суының урта агымында яшәгән мишәрләр борынгы заманнарда фин-угыр телле халык буларак, соңыннанрак исә төрки телле дип танылган. Ука елгасының урта агымы, мишәрләр яшәгәнгә күрә, урыслар тарафыннан мишәрләр яши торган як (Мещерский край) дип йөртелгән. 1152 елда Юрий Долгорукий монда шәһәр сала. 1471 елда бу кала Мишәр шәһәре (Мещерский городец.) соңыннан Касимов дип аталган. Урыслар арасында азчылыкта яшәгән мишәрләрнең күбесе урыслашкан.

Казан өязендәге мишәр авыллары турындагы мәгълүматларны без XVI—XVIII гасырларга караган тарихи чыганакларда табабыз. Әйтик, әле Казан ханлыгын Явыз Иван алганга кадәр үк 1540—1550 елларда әлеге төбәккә мишәрләр үтеп керә башлавы тарихи чыганакларда басым ясап күрсәтелә. 1565 елларны эченә алган «Зөя өязе писцовая кенәгәсендә» без Зөя суының сул кушылдыгы Бәрле суы ярында татар-мишәрләр авылы булганлыгын беләбез. Бу авыл Казан ханлыгы заманында да искә алына. Шулай

ук XVII йөзләргә мөнәсәбәтле тарихи актларда Кече Чирмешән елгасының сул кушылдыгы Мораса суы ярында да (хәзерге Октябрь районы) өч мишәр авылы турында сүз алып барыла. Чистай өязендә йөргән вакытта В. Казаринов Тубылгытау авылы мулласы белән татар-мишәрләр турында сөйләшкәндә шуңа игътибар итә. Мулла мишәрләрнең татарлар кебек үк булуларын һәм Казан губернасында аерым халык буларак билгеләнмәвен шуның белән аңлата. Составында мадьяр, мишәр булган атамалар илебезнең төрле төбәкләрендә очрый, чөнки урыс дәүләтенең үсүе һәм ныгуы аркасында шуңа хезмәт итә торган йомышлы татарлар буларак, мишәрләр Рәсәйнең төрле урыннарында, аерым алганда, хәзерге Башкортстан, Чувашстан, Мари республикалары, Оренбург, Чиләбе, Самара, Ульян, Түбән Новгород һ. б. өлкәләрнең җирләренә күчеп утыралар һәм рәсми рәвештә мещеряк, ягъни мишәрләр дип йөртеләләр.

Ульян өлкәсе җирләреннән ага торган Кече Зөя кушылдыгы Калда суы (халык телендә Калны (Канлы) һәм аның ярына урнашкан шул ук исемдәге авыл атамасы игътибарга лаек. Бу атама тарихи чыганакларда еш кулланыла. Галимнәр фикеренә караганда, ул бәҗәнәк (печенег) этнонимы канлы каңлыга барып тоташа. Атаманың фонетик яктан үзгәрүе шушындый юнәлештә барган булса кирәк: Калда Калны Каңлы. Тикшеренүләр күрсәтүенчә, каңлы кавемнәре берлеге Урал яны далаларында бәҗәнәк-угыз кабиләләре нигезендә IX—XI йөзләрдә барлыкка килә. Каңлы сүзе яңгырашына караганда, бәҗәнәкләрнең үзатамалары кангар белән якынлаша, Тамырлары урта гасырлар белән тоташкан каңлы кабиләләре кыргыз, казакъ, каракалпак, үзбәк, гагауз, нугай, кырым татарлары һ. б. халыкларны формалаштыруда катнашкан. Казан арты төбәгендә табылган Канлы куак дип аталган топоним да шушы этноним белән бәйләнешле. Идел һәм Кама сулары ярларына урнашып дәүләт төзегән болгарлар үз казаннарында гына кайнап ятмаганнар, бәлки төрле-төрле, мәсәлән, бәҗәнәк, угыз, төрек, бирәндей һ. б. кабилә-кавемнәр белән тыгыз бәйләнештә булганнар. Билгеле ки, болгар ханы Алмыш угыз гаскәре юлбашчысы кызына өйләнә. 921—922 елларда Идел буендагы Болгар дәүләтенә гарәп хәлифәлегеннән килгән илчелекне озата йөри торган тылмач гарәпләргә угызлар белән дә, болгарлар белән дә аралашырга ярдәм иткән. XII гасыр галиме Идриси мәгълүматлары күрсәтүенчә, Болгар шәһәре янында төрки бәҗәнәкләр (бәҗәнәк мин әт-төрек) җирләре урнашкан.

Ульян өлкәсендә Кыпчак атамалы елга, күл, тау бар. Болгар-татар кабер ташы язмаларын өйрәнгән Һ. В. Йосыпов татарларда ширин, барын, аргын, кыпчак һ. б. ыру-кабилә атамалары булганлыгын яза. Татарстанда да Кыпчак исеме белән географик берәмлекләр шактый. Кыпчак кабиләләренең тамырлары бик борынгы заманнарга барып тоташа. Алар турында беренче хәбәрләр VIII гасырга карый. Уйгыр каганы Муенчура истәлегенә куелган һәйкәлдә «төрки-кыпчаклар» дип язылган сүзләр бар. Кыпчаклар күп төрки халыкларны: нугай, каракалпак, кырым-татар, казакъ, башкорт, гагауз һәм бүтәннәрне формалаштыруда катнашканнар. Кыпчак атамалы авыллар Башкортстанда, Пермь, Чиләбе өлкәләрендә, госманлы төрекләре яши торган төбәкләрдә, Урта Азия, Төньяк Кавказда, Украинада, Молдованың гагаузлар яши торган районнарында очрый. Мариларда да Кыпчак шәхес исеме буларак кулланыла икән.

Ульян өлкәсе җирендә яши торган татар-мишәрләр бу тирәләргә рус дәүләте чикләрен саклау өчен күчереп утыртылган. 1578 елдан алып 1684 еллар арасында хәзерге Мордва республикасы, Рязань, Тамбов, Пенза, Ульян, Самара өлкәләре җирләре аша һәм Иделнең уңъяк яры буйлап үтә торган өч ныгытма төзелә. Бу ныгытмаларның берсе — Сембер исемлесе, Кама аръягы буйлап та үтә. Ул 1652—1657 елларда корыла. Татар-мишәрләрнең Буа һәм Сембер өязләренә килеп урнашулары XVII йөз урталарына туры килә. Ул Карлы, Сембер, Самара ныгытмаларын төзү, саклау өчен һәм ирекле күчеп утырулар белән бәйләнешле. Тарихи чыганакларда аларның күпчелек өлешен («ц» лаштыра торганнарын) Түбән Новгород татар-мишәрләренең варислары дип карыйлар. Ләкин алар арасында башка җирләрдән (Пенза, Мордва республикасы һ. б.) килеп утырганнары да бар. Кайдан гына килеп утырсалар да, алар хәзер бер йодрык булып оешканнар, бердәм татар милләтен тәшкил итәләр.

**Фирдәүс ГАРИПОВА,**
филология фәннәре кандидаты.

Марсель Әхмәтҗанов

# САБИРҖАН АКЫН

Татар әдәбиятының тугандаш казакъ әдәбияты белән тарихи бәйләнешләре турында Алма-Ата галимнәре тарафыннан сүз әйтелде инде[1]. Өлеге хезмәттән күренгәнчә, бәйләнешләребез ерактан килә икән.

Шушы бәйләнешләрне ныгыту юлында кемнәр генә булмаган: Хәсән Кайгы, Мифтахетдин Акмулла, Кәшафетдин Минзәләви, Мөлкәй Юмачиков, Әкрәм Галимов, Сабир Шәрипов һәм тагын бик күпләр. Бу исемлек, тикшеренүләребез тирәнәя барган саен, тулылана бара.

Югарыда искә алынган исемлеккә Сабирҗан акын исемен дә икеләнмичә өстәргә мөмкин. Ләкин аның тормышы һәм иҗаты турында укучыларыбыз бик аз белә әле. Әдәбият тарихыбызда аның исемен беренче тапкыр Нәкый Исәнбәт искә ала[2]. Шуннан соң Сабирҗан акынга кагылышлы кайбер мәгълүматлар бер мәкаләбездә бирелгән иде[3].

Соңгы елларда акын турында яңа материаллар тупланды һәм өйрәнелде. Алар нигездә Татарстанның Олы Мәңгәр авылында Сабирҗанны белгән кешеләрнең истәлекләре, архив белешмәләре, шәҗәрә китабы һәм аның басылып чыккан китапларыннан алындылар.

Кем булган соң ул Сабирҗан?

Сакланып калган мәгълүматларга караганда, ул — казакъ халкы арасында йөргән шактый билгеле бер акын импровизатор, шагыйрь. Аның иҗат дәвере XIX гасыр ахыры — XX гасырның башына туры килә. Иҗат иткән регионы — Көнбатыш Казагыстандагы Кече җүз казакълары җирләре. Китапханәләрдә эзләнү аның әсәрләре басылып чыккан булуларына да ачыклык кертте. Казагыстан Фәннәр академиясенең Гыйльми китапханәсендә аның: «Кызның үләне» (Казан, 1903), «Тирмә казакъныкы» (Казан, 1903), «Җомбак казакъ телендә», «Казакъ телендә табышмак». (Казан, 1903), «Казакъның туй бәетләре» (2табгы, Казан, 1912) әсәрләре саклана. Ихтимал, акынның басылып чыккан китаплары болар белән генә чикләнмидер дә, чөнки ул үзенең бер әсәрендә: «Бастырып чыгарсагыз, алты китап бирдем, тагын да язармын», дип искәртеп куя («Җомбак казакъ телендә», 12 б.). Бу юнәлештә эзләнүләр шат уңыш китерер.

1980 елда археографик экспедиция вакытында Олы Мәңгәр авылында булырга туры килде. Анда Сабирҗан акынны хәтерләүче һәм белүче кешеләр белән таныштык. Алар Гани Закиров (1898 елда туган), Харис Ибраһимов (1910 елда туган), Госман Хөсәенов (1907 елда туган) агайлар иде. Бу танышлык нәтиҗәсендә без Сабирҗан акын хакында күп кенә кызыклы фактлар белдек. Олы Мәңгәрдә акынның якын туганнары калмаган икән инде, ләкин ул туган йорт нигезен беләләр иде. Өлеге агайларның сүзенә караганда, Сабирҗан 1880 ел тирәсендә туган. Бу дәлилне без Татарстан дәүләт архивы материаллары ярдәмендә тикшереп карадык. Архивта Олы Мәңгәр авылының метрика дәфтәрендә аның биографиясенә кагылышлы кызыклы, төгәл хәбәрләр табылды. Сабирҗан 1878 елның искечә 19 июлендә (яңача 1 август) Олы Мәңгәрдә игенче Мөхәммәдсадыйк Мөхәммәдшәриф улы гаиләсендә туган[4]. Анасы Хөсниҗамал исемле булган.

Акынның нәселләре турында хәбәрләр Олы Мәңгәр авылының шәҗәрә китабында да бар (күчермәсе авторда саклана). Аннан күренгәнчә (китапның 129 бите), шагыйрьнең нәселе түбәндәгечә: Сабирҗанның Шакир, Нигъмәтҗан исемле бертуган агалары була, аларның атасы — Мөхәммәдсадыйк (кушаматы Күрки), аның атасы — Мөхәммәдшәриф, аның атасы Мортаза, Мортазаның атасы Сәгыйд баба була.

---

[1] Бөркет Ыскаков. Казакъ-татар әбәди байланысы. Алматы, 1976, 173 б. Казакъ телендә.

[2] Татар халык мәкальләре. 1 том. Казан, 1959, 70 б.

[3] Азат хатын, 1980, № 11, 17 б.

[4] Татарстан үзәк дәүләт архивы. 4 коллекция, Казан губернасы, Казан өязенең туу, никахлашу һәм үлү фактларын теркәгән 1878 нче елгы метрика дәфтәре, 261 бит.

Сабирҗан тугыз яшендә Коңгырт шәһәренә килә («Җомбак казакъ телендә», 11 б.). Авылдашы Гани Закировның әйтүенә караганда, ул анда Шакир агасы белән киткән. Яшьли казакъ арасында йөреп, аның телен, горефгадәтләрен, фольклорын казакътан туган казакъ баласыдай камил үзләштергән. Һәр әсәрендә милләтен нугай, ягъни татар дип күрсәтсә дә, аларны ул казакъ халкы өчен язуын ачык белдереп, «казакъ халкым» дип эндәшә («Җомбак казакъ телендә», 12 б.).

Сабирҗан акынның әсәрләре белән танышкач, аның тормышына кагылышлы күп кенә мәгълүматлар ачыклана:

*Сорасаң, Казан дигән туган җирем,*
*Иләк, Җаек, Уел гуй ускән җирем,*
*Сәмәрканд, Шәһре Болгар күргән җирем,*
*Дәхи дә Коңгырт дигән белгән җирем.*
*Иләктән мин бардым Кара Ботак салага,*
*Туры бардым Хөснетдин Алмай дигән адәмгә.*
..................
*Айҗарык дигән остага,*
*Барып тордык соңгарак,*
*Барып кердек өенә,*
*Көрпә салды түренә.*
*Шуннан бертуган остаңыз*
*Сөйлә диде эн(е)сенә.*
*Ку думбра кулга алып,*
*Арлы-бирле кузгалып...*
..................
*Кырым яктан килгәндер бабаларым,*
*Шушы көн ун буынга килә якын.*
*Сорасам уз атамны, Садыйк диде,*
*Сабирҗан, яз дип әйтте, хәреф диде,*
*Сорасаң минем атым — Сабир акын,*
*Китапта куп урында минем даңкым...*[1]

*(«Җомбак казакъ телендә», 11 б.)*

*Сабирҗан җырчы мин идем,*
*Кай җырчыдан ким идем.*
*Яз җәйләвем сорасаң —*
*Агыйделнең сагасы*[2].
*Кыш кышлавым сорасаң,*
*Казан дигән каласы.*
*Казакай акын токымы,*
*Яуны курсә котырган,*
*Яу карасын күргәндә,*
*Аламын дип омтылган...*

*(«Тирмә казакъныкы», 14 б.)*

Болардан тыш акын Көнбатыш Казагыстанда үзе яшәгән Түбәнге Тугыз, Аккитә Майлы бай, Аксоңкар, Сары Исәк, Байкә ыруларын искә ала. Китерелгән мәгълүматлар Сабирҗан акынның яшәгән төбәкләрен конкрет күрсәтәләр. Бу маршрут белән эзләнгәндә, аның биографиясен һәм иҗатын тагын да тулырак күз алдына китерергә мөмкин булыр иде.

Олы Мәнгәрдә тупланган истәлекләр Сабирҗанның тормыш-көнкүреш яклары хакында да мәгълүмат бирә. Ул бер ярлы кеше була. Үз кул көче белән көн күрә. Тиреләр иләп, алардан үзе үк бүрек, бияләйләр тегеп, шуларны сатып көн иткән. Сабирҗан туган авылына еш кайтып йөргән. Кайткан чакларында аның лачыннар тотып, аларны өйрәтеп — казакъ арасына илтеп сатып йөргәнен дә сөйлиләр. Ярлылык сәбәпле, ул казакъ арасында өйләнә алмаган — аңа кыз бирмәгәннәр. Шунлыктан ул кайтып Иске Мәнгәрдән Хәкимулла абзыйның Майшәкәр исемле сазаган кызын алып китә. Аларның бер кызлары туа. Олы Мәнгәргә соңгы кайтулары 1922 еллар тирәсендә була. Сабирҗан авылга кайткан вакытларында үзенең акынлык осталыгын да күрсәтә. Аны тыңлаган Гани Закиров: «Ул думбрасын чалып-чалып, «ай чырагым, вай чырагым» дип, шашып-шашып уйный иде», дип искә ала. Сабирҗан халыкка үзенең акыннар ярышында җиңеп чыгуы хакында сөйләгән. Бер ярышта ул казакъның кыз акыны белән ярышкан һәм аны җиңгән. Бу вакыйга Сабирҗанның «Җомбак казакъ телендә» әсәренең сюжетында да чагылган. Әлеге китапта кыз белән егетнең кара-каршы җыр-табышмак әйте-

[1] Даңкым — бу урында исемем, билгем мәгънәсенә туры килә, ягъни танык булу.
[2] Сагасы — бу урында яры мәгънәсендә.

шеп ярышулары хакында сөйләнә. Сабирҗан бу әсәрендә, борынгы акыннар гадәтенчә, үзенең нәселен, кем икәнен, ни эшләгәннәрен шигырь белән әйтеп биргән. Әсәр нигездә казакъ телендә булса да, анда татар теленә хас элементлар мул күренә.

Сабирҗан дөньяви шагыйрь, дини мотивлар аның иҗатында сирәк очрый. Ул үзе дә: «Бер дога изге юлдан кылалмадым»,[1] — ди.

Акынның дөньяга карашы кызыклы. «Тирмә казакъныкы» (6 бит) җыентыгында аны гел хәрәкәттә, үзгәрештә дип саный ул:

*Монау торган бар дөнья,*
*Бер урында тормаган,*
*Һич яхшылык кылмаган,*
*Дип уйлыйсыз ахмаклар.*

Патриархаль-ыруглык шартларында яшәүче казакъ җәмгыяте эченә үтеп керә барган капиталистик мөнәсәбәт күренешләре дә Сабирҗан акын игътибарыннан читтә калмаган:

*Шул сәбәпдин куркамын:*
*Ахры заман булганда,*
*Алван-алван җан чыкты,*
*Хәере юк бай чыкты,*
*Самавыр дигән чәй чыкты,*
*Саусаң сөте чыкмаган,*
*Акча дигән мал чыкты,*

*Йөрсә кузе курмидер,*
*Тырантас дигән ат чыкты,*
*Ат җикмәсәң йөрмидер,*
*Үңгәреп лә торадыр*
*Ярлы җаяу йөридер,*
*Менгәне аның кук-ала,*
*Бутасы[2] юк җир-дала.*

*(«Тирмә казакъныкы», 6 б.)*

Үзенә хәтле булган татар-казакъ акыннарыннан аермалы буларак, Сабирҗан әсәрләрендә реалистик тормыш күренешләрен сурәтли. Ул сюжетны борынгы романтик, мифологик, ерак тарихи темаларга кормый. Әсәрләрендә XIX гасыр ахыры — XX гасыр башы казакъ халкының реаль тормышы. Шушы ягы белән аның әсәрләре казакъ халкының алга китешенә хезмәт иткән, әдәбиятын баеткан.

Акынның «Кызның үләне», «Казакъның туй бәетләре» китаплары казакъ халкының тормыш-көнкүрешен, йолаларын табигый тасвирлауга багышланганнар. Аның әсәрләрендә казакъның киез йорты, анда яшәүче һөнәрле казакъ кызы һ. б. сурәтләр реалистик планда бирелгәннәр:

*Буз өенең өсте киез, асты келәм,*
*Башында мамык ястык, бер куч тушәк.*
*Җеп-ефәк, алтын инә, көмеш уймак,*
*Буз өйдә утыручы иденң тегеп бишмәт.*

*(«Кызның үләне», 6 б.)*

«Казакъның туй бәетләре» китабы «Туйны мактау», «Кызны мактау», «Үгет», «Кодаларны мактау», «Без килдек әй, Корбыжан, туегызга», «Тулгау» исемле бүлекләр аша казакъ туеның бөтен нечкәлекләрен белеп язган әсәрләрнең берсе булып тора. Сабирҗанның бу өлкәдәге уңышын Галимҗан Ибраһимовның «Казакъ кызы» романы сурәтләре белән тиң дәрәҗәдә дисәк тә, ялгыш булмас. «Казакъның туй бәетләре» әсәре әдәбиятчы, фольклорчы, этнограф һәм тюркологлар өчен дә файдалы, бай чыганак. Бу әсәрне татар йола фольклоры белән чагыштырып өйрәнгәндә, борынгы һәм уртак гореф-гадәтләребезнең тамырлары, хасиятләре ачыграк күренер иде.

Йомгак итеп шуны әйтергә кирәк. Сабирҗан акын, тугандаш казакъ халкының рухи тормышын бизәүдә катнашып, шул халыкның тормышын белеп чагылдырган игътибарга лаек әсәрләр калдырган. Аның казакъ әдәбиятына күрсәткән хезмәтләренә кардәш халыкның галимнәре тиешле бәяләрен бирерләр һәм мәдәни бәйләнешләребезгә яңа сәхифәләр өстәр әле дип өмет итәбез.

---

[1] Акын үзе язуга оста булмаган, күрәсең. Аның барлык китапларын Олы Мәнгәрдә аларның күршеләре булган Мөхәммәтҗан Мөхсинов язган. Бу хакта һәр китапның титул битендә язылган. М. Мөхсинов үзе Олы Мәнгәрдә яшәгән һәм шунда Октябрь революциясеннән соң үлгән.

[2] Бутасы — дөя баласы.

# ТЫЕЛГАН ИСЕМ ҺӘМ ИҖАТ

Фәннәр фәне, барлык бүтән фәннәргә, гыйлемнәргә нигез бирә торган фән бар. Ул — фәлсәфә. Фәлсәфә атамасы безгә грек теленнән кергән (фило+софия), «яратам+акыл» дигән мәгънәне аңлата, ягъни акыл, зирәклек эшчәнлеген сөюне, шуның белән шөгыльләнүне белдерә. Фәлсәфә — фән буларак иҗтимагый аң чагылышы, чынбарлыкка, анда кеше тоткан урынга бәйле карашлар һәм фикерләр системасы. Ул кешенең дөньяны танып-белүен, чынбарлыкка мөнәсәбәтен, табигать үсешенең гомуми кануннарын, танып-белү, фикерләү ысулларын тикшерә, тереклек килеп чыгышын, яшәү мәгънәсен ачыклый. Материя һәм рух, чынбарлык һәм аң бәйләнешләре, дөньяны танып-белү мөмкинлеге яки мөмкин түгеллеге мәсьәләләре фәлсәфә гыйлеменең төп эчтәлеген тәшкил итә.

Фәлсәфә фәнен үстерүгә Парменид, Гераклит, Сократ, Платон, Аристотель, Әл-Кинди, Әл-Фараби, Әбугалисина, Галилей, Бэкон, Декарт, Дидро, Гегель, Фейербах — төрле халыкларның меңнәрчә акыл ияләре өлеш кертә һәм әнә шулай гаять бай фикер хәзинәсе барлыкка китерелә.

Дөнья фәлсәфәсе хәзинәсе белән таныштыруда үткән заманнарда мәдрәсәләребез даими эш алып бара. Ш. Мәрҗани, К. Насыйри, Ш. Күлтәси кебек укымышлыларыбыз бу юлда бигрәк тә зур казанышларга ирешә — алар үз уй-фикерләрен дә уртак хәзинәгә кушып җибәрәләр.

Маркс, Энгельс, Ленин һәм аларның тарафдарлары бөтен дөнья фәлсәфәсенең үзләре кабул иткән һәм табынган кыйммәтләре, матдәләре нигезендә «марксизм-ленинизм фәлсәфәсе»н формалаштыралар. Совет дәверендә коммунистлар партиясе корган тоталитар режим шартларында бары шушы «марксистик-ленинчыл фәлсәфә» генә иң хак, бөтен нәрсәләрне дөрес аңлата торган тәгълимат дип игълан ителде. Шуның кысаларына сыймаган карашлар, фикерләр һәм уйлар — саташу, ялгышу, кеше күңелен чуплн торган зарарлы «гыйлем» дип танытыла башлады. Маркс һәм аның тарафдарлары пәйгамбәр дәрәҗәсенә күтәрелгәндә, аларча уйламаган борынгы һәм хәзерге фәлсәфәчеләрнең дәрәҗәсе төшерелде, аларга кара ягылды.

Тоталитар сәяси системаның җимерелүе безнең рухи эзләнүләребезгә дә чикләнмәгән мөмкинлекләр ача. Дыңгычлап марксизм тутырылган миләребезне җилләтү, дөнья фәлсәфәсе мирасының җитмеш ел буе игътибарыбыздан читтә калдырылган хәзинәләренә мөрәҗәгать итү ихтыяҗы торган саен ныграк сизелә. Бу — чынбарлыкны бөтен тулылыгында һәм каршылыклы рәвешендә танып-белү, үзебезне тирәнрәк аңлау, акыл һәм хисләребезне кешелек мең еллар буе туплаган тәҗрибәләр, белемнәр белән баету, рухи тотрыклылык саклап, күркәм әхлак кысаларында яшәр өчен кирәк. Казарма социализмыннан котылу, рухи хөррияткә ирешү максатында журналыбыз укучыларын яңадан яңа акыл ияләре, аларның гыйбрәтле мирасы белән таныштыру урынлы булыр.

Советлар илендә иҗади мирасы һәм исеме тыелган күренекле фәлсәфәче һәм язучыларның берсе Фридрих Ницше (1844—1900) иде. Аның турында «Кече совет энциклопедиясе» (3 басма, том 6. М., «БСЭ», 1959. Бит 648) түбәндәгечә яза:«Немец идеалист-фәлсәфәчесе, фашизмга идеологик нигез әзерләүчеләрнең берсе. Байтак әсәрләрендә тышкы дөньяның хыялыйлыгы турында субъектив-идеалистик фикерләр тарата, «гадәттән тыш кеше» — ялгызак ихтыярын иҗтимагый үсешне билгеләүче көч итеп карый. Халыкны «коллар» дип белдереп, өстен сыйныфларның — «сайланма» кастаның әхлакны теләсә ничек бозуын аклый».

Фашизм идеологиясе ПАНГЕРМАНИЗМ, АНТИСЕМИТИЗМ, СЛАВЯНОФОБИЯгә, ягъни немецларне генә өстен күрү, яһүдләргә дошман булу, славяннарны өнәмәүгә нигезләнә. Баксаң, Ницше немецларне һич тә өстен, мак-

таулы халык санамаган, яһүдләрне көчле, славяннарны талантлы дип исәпләгән, киләчәктә немес-урыс дуслыгы ныгуын теләгән, ә үзе бабасы ягыннан поляк булган һәм шуның белән горурланган да икән. Аның дөньяга карашы, хакыйкатьне билгеләүдә иманы, зәвыгы гомер иткәндә шактый үзгәргән. Иҗади мирасында хәтсез каршылыклар очрый. Шуңа да карамастан, Ф. Ницшеның бөек фикер иясе булуы, бөтен дөнья фәлсәфә хәзинәсенә күренекле өлеш кертүе «социалистик лагерь»дан читтә инде күптән танылган, аның әсәрләре җыелмасы хәзер 40 том күләмендә берьюлы итальян, француз, немес телләрендә басылып ята.

Ф. Ницше һәм бүтән шундый мәшһүр шәхесләр, аларның бай иҗаты турында укучыларыбызга тәфсилләп сөйләү — фәлсәфәче галимнәребез бурычы. Алар якын елларда Г. Исхакый, М. Бигиев, Г. Акъшларны сүгүдән, аларга кара ягудан бушап, ниһаять, безне чын гыйлем белән сугара башлар, рухыбызны баетырлык уй-фикер дөньясына алып керер, дип өметләник. Ә хәзер һәркем үзе бәяләсен, кызыксынып китсә, галимнең башка әсәрләрен үзе эзләп табып укысын өчен, Фридрих Ницшегә сүз бирик. Шартлы рәвештә «Уймак уйлар» дип аталган түбәндәге өзекләр аның «Кешеләрчә, чамадан тыш кешеләрчә» дигән хезмәтеннән алып тәрҗемә ителде. Искиткеч зур иҗади мирасның нәни генә өлеше!

**Тәүфикъ ӘЙДИ**

# Фридрих Ницше

## УЙМАК УЙЛАР

Теләсә нинди хатын-кыз мәхәббәтенә ана мәхәббәте чаткысы салынган була.

Әгәр өйләнешүчеләр бергә яшәмәсә, бәхетле никахлар ешрак очрар иде.

Ике як та бер-берсе аша мәгълүм шәхси максатка ирешүне, әйтик, хатын ире аркасында мәшһүр, ир хатыны аркасында сөйкемле булуны күздә тотса, никахлары нык берегәчәк.

Хатын-кызларның күбесе күренекле кешене ярата һәм аны үзенеке генә итәргә тели. Әгәр мин-минлекләре карышмаса, алар хәләл җефетен йозак астында бикләп кенә асрарлар иде — әнә шул мин-минлекләре иренең күренекле кеше булуын бүтәннәргә дә сиздерергә ашкына.

Камил хатын-кыз камил ир-аттан югарырак тора һәм сирәгрәк очрый. Хайваннар табигатен өйрәнү шушы хакыйкатьне раслый.

Яхшы дус, мөгаен, яхшырак хатынга тап булыр, чөнки әйбәт өйләнешү дигәнең дуслашу сәләтенә бәйле.

Ата-ана холкы һәм алар фикер йөртүендәге ятышсызлыклар бала күңелендә яңгыравын дәвам итә һәм алар бала интегүләренең эчке сәбәбе була.

Һәркемнең күңелендә әнисеннән килә торган хатын-кыз образы яши. Шуңа бәйле рәвештә адәм баласы хатын-кызны, гомумән, хөрмәт итә яки күралмый, яисә аңа тулаем битараф мөнәсәбәттә кала.

Уллары барлыкның йөген күтәрү өчен әти кешеләргә бик күп эшләргә туры килә.

Үзен-үзе сөймәгән ирнең чирен акыллы хатынның мәхәббәте тизрәк дәвалый.

Әгәр уңыш казанса, аналар улларын аның иптәшләреннән дә көнли башлый. Гадәттә, ана улын түгел, улына күчкән үзен күбрәк ярата.

Эчке дөньясы буш, бары битлектән генә гыйбарәт хатын-кызлар бар. Үтәкүренмәле дип әйтерлек, берничек тә канәгатьләнмәячәк әнә шундый затка чәчләрен бәйләгән кешене кызганмый мөмкин түгел. Әмма нәкъ

менә шундыйлар ир-атны күбрәк ымсындыра: ул аларның күңеленнән сер эзли — гомер буе эзли!

Өйләнергә җыенганда бер нәрсәне ачыкларга тиешсез: бу кыз белән картайганчы әйбәт сөйләшә алачагыңа ышанасыңмы? Никахның бүтән яклары әһәмиятле түгел, аралашуның күпчелек өлеше сөйләшүгә корыла ич.

Тәҗрибәсез кызлар, ир-атны бәхетле итәргә мөмкинлегем җитә, дип алдана. Соңрак алар төшенә: бәхетле булыр өчен ир-атка кыз гына кирәк, дип уйлау аны артык түбән бәяләү икән. Хатын-кыз мин-минлеге исә ирнең гаилә бәхетеннән югарырак күтәрелүен таләп итә.

Нәфрәтләнгән хәлдә хатын-кыз ирләрдән куркынычрак: беренчедән, аларның кайный башлаган дошманый хисләре һичнинди гаделлек төшенчәсе белән авызлыкланмый, нәфрәтләре тыелгысыз рәвештә соңгы чиккәчә үсә һәм, икенчедән, алар теләсә кемдә, һәрбер партиядә булган йомшак урынны табарга күнеккәнлектән, шуңа басым ясый, бу эштә аларга кылычтан үткен гакыллары бик әйбәт хезмәт итә (ирләр исә яра күргәндә тотнаклырак һәм миһербанлырак, килешүгә һәвәсрәк була).

Ят телдә начар сөйләшүче яхшы сөйләшүчегә караганда аралашудан күбрәк сөенеч ала. Рәхәт чигү ярым-йорты галимнәр өлешенә генә тия.

Тамыр җибәргән карашлар — хакыйкатьнең ялганнан да хәтәррәк дошманы.

Кешеләрне кайгы уртаклашу түгел, шатлануга теләктәшлек күрсәтү дуслаштыра.

Үзең турында бөтенләй авыз ачмау — иң затлы икейөзлелек.

Тирән фикер йөртүче кеше, ни генә эшләмәсен һәм уйламасын, үзенең һәрвакыт хаксыз булачагын белә.

Бөтен аңлаешсыз һәм караңгы нәрсә аңлаешлы һәм якты нәрсәдән әһәмиятлерәк күренә.

Көчле агым — күп кенә ташларны һәм чыбык-чабыкны, көчле акыл күп кенә аңгыраларны һәм адашкан башларны үзенә ияртә.

Начар күрүче һәрвакыт бүтәннәрдән азрак күрә; начар ишетүче һәрвакыт кирәкмәгән берәр нәрсәне ишетә.

Хәтерең начар булу да әйбәт — бер үк яхшы нәрсә кабат-кабат беренче мәртәбәсендәге кебек рәхәт кичертәчәк.

Кеше ниндидер пычрак нәрсә турында уйлаудан оялмый, әмма әнә шул пычрак фикерен бүтәннәр белү ихтималыннан ояла.

Үзебезне акыллы күрсәтергә күбрәк мөмкинлек бирүенә карап кына без теге яки бу нәрсәне мактыйбыз йә исә яманлыйбыз.

Авыруга киңәшләр бирүче, сүзенә колак салалармы-юкмы, үзен белдекле һәм өстен хис итеп кинәнә. Гарьчел һәм горур авырулар исә киңәш бирүчене чиренә караганда да күбрәк дошман күрә.

Тигезлеккә сусау йә бүтәннәрне үз дәрәҗәңә түбән сөйрәп төшерү (кечерәйтү, күрмәмешкә салышу, аяк чалу), йә үзеңне алар дәрәҗәсенә күтәрү (тану, булышу, кеше уңышына шатлану) рәвешендә гамәлгә аша.

Оялчак кешеләргә булышуның, аларны тынычландыруның иң әйбәт чарасы — бик нык мактау.

Без нинди дә булса фикергә, бары әйтелү рәвеше ошамаганга күрә генә, бик еш каршы төшәбез.

Кайчак бүтән берәүгә мөнәсәбәтебездә дуслык канат җәйсен өчен, үз ягыбызның үлчәү тәлинкәсенә бернича бөртек гаделсезлек салынуы хаҗәт.

Үзебездән зыян күргән кешегә еш кына тапкыр сүз әйтү һәм шулай бездән көлү мөмкинлеген бирергә кирәк — шуннан соң ул канәгатьлек кичерер һәм хәтта безгә дустанә карар.

Үз фикерләрен бозга күмеп саклый алмаган кеше кайнар бәхәскә кереп маташмаска тиеш.

Тирә-ягында атказанган шәхесләрне күргәч, үз-үзеңне олылау хисе югала, ялгызлык тәккәбберлекне үстерә. Яшьләр, үзләре кебек әле бернигә дә ирешмәгән, ләкин югарырак үрләргә теләгән иптәшләре чолганышында яшәгәнлектән, борын күтәрергә яратучан.

Аралашканда, салам кыстырып, уяулыгыбызны җуярга теләүчеләр безгә йокы даруы шикелле хәвефле нәрсә каптыра. Әгәр аңа бирешмәсәк, уяулыгыбыз ныгыячак кына.

Рухи сәләт ягыннан мәшһүр затның гуманлыгы гади кешеләр белән аралашканда үзенең хаклы түгеллеген рәт белән тануда күренә.

Җәмгыятьтә үзен ышанычлы тоймаган бәндәләр, өстенлекләрен күрсәтер өчен, форсаты чыккан саен кемнедер мыскыл итәргә тотына.

Казанышларга ия кешенең мин-минлеге казанышсыз кешенең мин-минлегенә караганда күбрәк ачуны китерә. Чөнки безне аның ниндидер казанышка ия булуы көнләштерә.

Шөһрәт сөяләре чамасыз булган ике кеше очрашса, бер-берсе хакында начар фикергә киләләр; чөнки алар, сөйләшкәндә үзләре хакында яхшы тәэсир калдыру белән генә мавыгып, иптәшенең мөгамәләсенә һич тә игътибар итмиләр. Икесе дә, тырышлыкларының бушка китүен күргәч, гаепне бер-берсенә аударалар.

Берәү — фикерләре, икенчесе — симпатия яки антипатияләре, өченчесе — танышлыклары, дүртенчесе — ялгызлыгы белән кызыклы күренергә тели, ләкин һәммәсе үз исәбендә ялгыша. Чөнки аларны тыңлап торучы кеше эченнән бары үзен генә игътибарга лаек бердәнбер шәхес дип саный.

Яшьләр, чынмы яки ялганмы, бөтен кызыклы һәм гадәттән тыш нәрсәләрне ярата. Җитлеккәнрәк акыллы кешеләр хакыйкый кызык һәм гадәттән тыш нәрсәне ярата. Ниһаять, тәмам җитлеккән башлар бик гади һәм беркатлы, гади кешегә эчпошыргыч тоелган хакыйкатьне дә ярата, чөнки алар хакыйкатьнең иң бөек хикмәте тыштан үтә наив рәвештә ачылуын белә.

---

*Котлыйбыз!*

## Кадыйр Сибгатка 50 яшь



Шагыйрь Кадыйр Сибгат — 1978 елдан бирле СССР Язучылар берлеге әгъзасы.

Шагыйрь Кадыйр Сибгат (Минкадыйр Идиятулла улы Сибгатуллин) 1942 елның 15 февралендә Татарстанның Балык Бистәсе районы Балыклы Чүкәй авылында туган. Урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, Казанга килә һәм 4 нче техник училищега укырга керә. Училищедан соң Казан оргсинтез заводында электромонтер булып эшли, хәрби хезмәткә чакырыла.

Армиядән кайткач, Кадыйр Сибгат үз һөнәренә тугрылык саклый. Ә 1966 елдан исә ул — журналистика эшендә. Балык Бистәсендә чыга торган гәзит редакциясендә эшләү елларында ул, читтән торып, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый. Ә 1978 елдан бирле Чаллы шәһәрендә яшәп иҗат итә.

Кадыйр Сибгат мәктәптә укыганда ук шигырьләр яза башлый. 1974 елда аның беренче җыентыгы басылып чыга. Хәзер инде ул — дистәгә якын китап авторы. Аның шигъриятенең үзенчәлеге — тормыш турында фәлсәфи уйлану, ягымлы-кайнар лирика. Шуның өчен Кадыйр Сибгат шигырьләре укучылар арасында популярлык казанды.

Татарстан Язучылар берлеге һәм «Казан утлары» журналы редакциясе коллективы юбилярны ихлас күңелдән котлый һәм аңа ныклы сәламәтлек, илһамлы озын гомер тели.

## Илбарис Надир

# ФИНЛЯНДИЯ ТАТАРЛАРЫ

Финляндиядә, финнәр үзләре атаганча әйтсәк, Суомида гомер итүче татарларның иҗтимагый-социаль яктан, шулай ук дини-милли һәм рухи-мәдәни эчтәлеге буенча шактый, шул ук вакытта гыйбрәтле генә тарихлары бар. Ул гомумтатар тарихының тирән игътибарга лаек бер өлешен тәшкил итә. Бу тарихны тулы хәлендә тасвирлаган китаплар әлегә булмаса да, аның аерым сәхифәләренә багышланган мәкаләләр, хәбәрләр байтак кына. Алар Финляндия һәм Швециядә, Германия һәм Төркиядә, Япония һәм Кытайда төрле вакытта, төрле телләрдә һәм төрле мәҗмуга, газета битләрендә дөнья күргәннәр. Соңгы егерме ел дәвамында Татарстан матбугатында да Суомида яшәүче милләттәшләребез турында аерым мәкаләләр басыла башлады. Нәтиҗәдә, язылачак тарих өчен таяныч булырдай шактый материал тупланган дияргә була.

## Мөһаҗирлек тарихыннан сәхифәләр

Мөһаҗир — безнең телгә гарәп теленнән кергән сүз булып, «башка җиргә, чит илгә күчүче», дигән мәгънәне аңлата. Халык телендә дә, әдәби телдә дә бу сүз хәзер бик сирәк очрый. Гадәттә, без «эмигрант» сүзен кулланырга күнеккәнбез.

Финляндия татарлары ул илгә мәҗбүри рәвештә түгел, ә ирекле рәвештә күчеп киткән мөһаҗирләр. Аларның анда күченүләре һәм тотрыклы тупланып яши башлаулары Финляндиянең әле рус дәүләте составында чагына туры килә.

Мәгълүм булганча, Финляндия 1809 елгы солых нигезендә Швеция составыннан Россиягә күчерелә һәм «Бөек князьлек» дигән исем астында автоном бер ил булып яши башлый. Озакламый бу князьлек җирләрендә урыс гаскәренең бернечә гарнизоны барлыкка килә. Аларда татар гаскәриләре дә хезмәт итә. Свиаборг ныгытмасындагы татарлар турында мәгълүматларны андагы хәрби имам аерым дәфтәргә теркәп барган. Хельсинки архивында 1836, 1850, 1871 елларга караган дәфтәрләр сакланган. Аларда Свиаборгтагы татарларның бер өлеше Нижний Новгород губернасының Сергач өязенә кергән авыллардан булуы хәбәр ителә. Фин галиме Гарри Гален әйтүенчә, узган гасыр урталарында Финляндиягә килгән татар мөһаҗирләренең беренчеләрен шул гаскәриләрнең нәселдәшләре тәшкил итеп, тора-бара аларга Петербургта, Мәскәүдә вак сәүдә эшләре белән шөгыльләнүче якташлары — асламчылар, кырыктартмачылар кушылган. 1870—1871 елларда Хельсинкидә торучылар турындагы белешмәдә мулла Гыйззәтулла Тимергалиев исеме телгә алына. Җәмгысе бу елларда Хельсинкидә яшәгән татарлар саны кырык алтыга җитә[1].

---

Илбарис НАДИР (1925) — *филология фәннәре кандидаты, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Г. Тукай исемендәге Татарстан Дәүләт премиясе лауреаты, татар фольклоры буенча күп кенә китаплар, гыйльми хезмәтләр авторы. Казанда яши.*

[1] Гарри Гален. Финляндиядәге төрки азчылыкның матбугат эшчәнлеге турында библиографик белешмә. Инглиз телендә. Хельсинки, 1979. 4 бит.

Алай да Финляндиягә юнәлүче мөһаҗирләрнең төп өлеше XX гасыр башына туры килә. Озын гомер юлы узган Хәсән ага кулъязма истәлегендә: «Бабам Хәмидулла Петербургта сәүдәгәр булып йөри торгач, 1868 елда Финляндиягә барып чыга һәм андагы Виипури шәһәрендә урнашып кала,— дип яза.— Шунда яшәү дәверендә ул фин халкының самимиятле, культуралы булуын, монда җир-су күплеген күрә, тырышкан кешегә мал табарга уңайлыклар җитәрлек икәненә төшенә. Шуннан соң ул Сергач өязендәге Актук авылында торучы уллары Хәйретдин, Хисаметдин һәм Низаметдингә (бусы минем булачак әтием) хат яза. Җәй чыгу белән монда килегез, эш тә, аш та булыр, ди. Көннәрнең берендә Хәмидулланың өч улы кинәт кенә юкка чыккач, авыл халкы аптырап кала. Ахырдан, сер ачылгач, хәбәр тарала. Имеш, Хәмидулла Финляндиядә хәзинә тапкан, улларын шуңа чакырган. Дөрестән дә бабамның өч улы монда яшәр өчен иркенлек, хәлләнер өчен мөмкинлек табалар. Өчесе дә асламчы булып эшли башлыйлар. Актуккә кайтып йөриләр. Өйләнмәгәне өйләнә. Тора-бара семьяларын да алдыралар, акча туплагач, кибет ачалар. Мин үзем әтием чакыруы буенча Финляндиягә 1915 елда килдем. Шуннан бирле менә шушы илдә гомер кичерәм». (Истәлек Хәсән аганың улы Гомәр Хәмидуллада саклана.)

Хельсинки университетында укытучы татар профессоры Гомәр Таһирның бер интервьюсыннан: «Әтием Зариф Финляндиягә узган гасыр ахырында килгән, сәүдә белән шөгыльләнгән. Сергач ягындагы туган авылы Куйсуга ул еш кайтып йөри торган була. Ил өчен авыр 1921 елда мине, ике туганымны бөтенләйгә дип Хельсинкигә алып килә. Бу вакытта мин әле унбер яшьтә генә идем». («Казан утлары», 1986, № 4. 116 бит).

Финляндиядә яшәп вафат булган сәүдәгәр һәм җәмәгать эшлеклесе Ибраһим Арифуллага (1901—1955) багышланган озын некрологтан бер өзек китерик: «Ибраһимның туган авылы Яңапар авылы булып, ул анда балачагын уздырды. 1914 елда Финляндиягә килеп, әтисе Габделфәттах янына эшкә керде. Шул ук вакыт ул хосусый сурәттә һәм курсларга йөреп укуын дәвам итте. 1925 елда Имад Җамалетдиннең Хельсинкидәге фирмасына эш башкаручы булып керде...» («Мәхаллә хәбәрләре». Финляндия җәмгыяте исламиянең фикерләрен вә эшләрен белдерүче җыентык. Хельсинки, 1955, № 12—13. 12 бит).

Шул ук җыентыкның 1962 елга караган санындагы бер хәбәргә күз салыйк. Ул «Финляндия җәмгыяте исламия»нең фәхри әгъзасы Гомәр Габдерәхимнең 80 яше тулу уңае белән язылган. «Гомәр Габдерәхим әфәнде 24.03.1882 тарихында Русия мәмләкәтенең Нижний вилаятендә Актук исемле авылда дөньяга килмештер... 1898 дә Хельсинкидә сату белән яши торган абзасы Хәлил Насыйбулла янына килә. Дүрт-биш ел абзасы хисабына сату иткәч, 1903 ел язын Актуккә төшеп Галимә Садыйк кызы Сафиян белән өйләнә. Көзен тагын Хелсьинкигә кайтып абзасы кибетендә сатуын дәвам иттерә.

.1905 елдан башлап үз хисабына ялгыз сату итә башлый. 1912 елда кибет ачкан йорттан фатиры да булгач, авылда калган өч баласы белән хатынын алдырып, тулы гаилә һәйәте белән яши башлый. Моннан соң алланың ярдәме, үзенең тырышлыгы аркасында сатуы зурайганнан-зурая барып, Хельсинкинең игътибарга лаек сәүдәгәрләреннән берсе булып китә» («Мәхаллә хәбәрләре», 1962, № 27, 13 бит).

Хельсинкидә тукымалар кибете тотучы Нури Сәмәрхан турында минем бер мәкаләм басылган иде. («Яңа аваз» 1991, № 8). Анда аның үз авызыннан язып алынган тәрҗемәи хәле дә тасвирлана. Нуриның әтисе Финляндиягә 1915 елда барып чыга, якташлары белән бергә сәүдә эшендә йөри. Егерменче еллар башында ул Куопио дигән кечкенә бер шәһәрдә кибет ача, хәлләнеп алгач акча җибәреп, гаиләсен үз янына чакырта. 1924 ел башында биш яшьлек Нури әнисе, абыйсы, бер тутасы һәм әбисе белән Финляндиягә киләләр. Тора-бара Нури фин мәктәбендә укый, татар теле буенча курсларга йөри, дини дәресләрдә иман шарты өйрәнә. Сәүдәгәр буларак берничә шәһәрдә яшәгәннән соң, 1975 елда Хельсинкидә төпләнә. Аның дүрт баласы, алты оныгы бар. Нури Сәмәрхан хатыны София ханым белән Казанда ике тапкыр булып, 1990 елда туган авыллары Актукка да кайттылар.

Китереп үткән мисалларда Финляндиягә күченеп киткән татарлар тарихына хас уртак сыйфатлар шактый ачык гәүдәләнә. Сергач ягыннан Хельсинкигә юл тоткан соңгы мөһаҗир Хәйдәр Гали була. Ул анда 1928 елда бара. Тик аны чик аша үткәрми җәфалыйлар. Аңа хәзер 84 яшь. Ул соңгы вакытка кадәр Хельсинки мәхәлләсенең мәәзине булып эшләде.

Егерменче еллар ахырында Финляндия белән Советлар иле арасындагы чикләр тәмам ябыла. Сталин хакимиятенә хас «тимер пәрдәләр» барлыкка

килеп, ике илдә гомер итүче кан-кардәшләр, туган-тумачалар бер-берләре белән күрешү-йөрешү ирегеннән бөтенләй мәхрүм ителәләр. Бу хәл, мәгълүм ки, соңгы елларгача дәвам итте.

Финляндия татарларының асыл туган җирләре Нижний Новгород губернасының Сергач өязенә кергән һәм бер төбәккә урнашкан берничә авыл булып, мөһаҗирләрнең иң күбесе Актук (борынгырак исеме Яңапар) авылына туры килә. Моннан кала Куйсу, Уразавыл, Суксу, Чөмбәли, Өчкүл авылларын атап үтик. Менә шушы авыллар һәм шул әйләнәдәге башка авыллар Финляндиядә гомер кичерүче татарларның тарихи хәтерендә туган як, туган җир, Ватан кебек кадерле төшенчәләрне бергә җыйган газиз бер төбәк, изге бер урын булып күзаллана. Моңа мисал рәвешендә Финляндия җирлегендә иҗат ителгән үзенчәлекле бер җырны телгә аласы килә. «Авыллар» дип аталган бу җырда Сергач тирәсендәге унике татар авылының исемнәре санап үтелә. Бу, әлбәттә, коры санау гына түгел, җырның һәр тезмәсе туган илне сагыну тойгысы белән сугарылган:

*Уразавыл, Кадымавыл, Атаравыл, Кызмавыл,*
*Туган-үскән илләремнән аерылып тору авыр.*
*Куйсуында, Ырбичада су буенда таллар юк,*
*Өчкүлдәге матурларны сагынмыйча хәлләр юк.*

(«Җыр дәфтәре», Финляндия төрекләре берлеге. Хельсинки, 1974. 13 бит).

Санап үткән авыллардан күчеп китүчләр Финляндиянең кайсы шәһәрләренә урнашканнар соң? Кызганыч ки, бу дәвамлы тарихны бөтен төгәллеге белән күз алдына бастырырдай демографик белешмә юк. Алай да кайбер саннар сакланган. Алда телгә алган «Мәхәллә хәбәрләре» дигән мәҗмүгада ««Финляндия җәмгыяте исламия» рәисе Зуһур Таһирның 1955 елда Хельсинкидә үткәрелгән бер милли кичәдә ясаган чыгышы басылган. Ул анда «Финляндиядәге 900 гә якын ислам төрекләре (сүз татарлар турында бара. И. Н.) 18 зур вә кечкенә шәһәрләргә бүленеп яшәмәктәләр» дигән мәгълүмат китерә дә, аларның яшәеш-хәятләренә кагылып шулай ди: «Хельсинкидә һәрвакыт җыелышлар, мәҗлесләр, төрекләр берлегенең чәй кичәләре булып тора. Һәр атна мәчеткә 40—50 кеше җыелып җомга намазы укыла, никадәр булса да мондагы халкыбыз үзара аралаша, яшьләребез берберләре белән танышып, күрешеп торалар. Ләкин дә ягада, бигрәк тә кечкенә шәһәрләрдә яшәгән әгъзаларыбызның, яшьләребезнең хәле башкадыр. Алар аеруча ят мохит эчендә яшиләр, дип әйтеп була. Аларны онытмау, үз арабызга алырга тырышу безнең бер вазыйфабыздыр» («Мәхәллә хәбәрләре», Хельсинки, 1955, № 10—11. 19 бит).

Бу мәҗмүганың 1958 елда чыккан 18—19 санында мәхәллә салымын түләгән әгъзалар исемлеге китерелгән. Шул уңай белән анда әле генә телгә алынган 18 шәһәрнең уналтысы санап үтелгән. Моннан ике ел әүвәл миңа мәхәллә ярдәме белән ул 16 шәһәрдә торучылар санын ачыкларга мөмкин булды. Тик монда шундый бер искәрмә ясап үтү сорала, кайбер шәһәрләрдә яшәүчеләр санын төп-төгәл исәп белән түгел, якынчарак саннарда атадылар. Нәтиҗәдә, түбәндәге күренеш хасил булды: Хельсинкинең үзендә 500 дән артык татар яшәсә, Тапередә гомер итүче милләттәшләр саны 160, Туркуда 105, Ярвинпәдә 70, Коткада 30, Раума, Васса шәһәрләрендә егермешәр, Хувинкәдә уннан артык, Коккала, Куопио, Оулу һәм Пори шәһәрләрендә бишалтышар, Лахти, Варкаус, Каркку, Форсса шәһәрләрендә икешәр-өчәр кеше яши дип санала. Шулай итеп, хәзерге көндә Финляндия җирендә барлыгы 950 гә якын татар гомер итә дип әйтергә нигез бар.

Бу урында Финляндия татарларының социаль тормышына, кәсеп һәм шөгыльләренә бер караш ташлыйк. Аларның күбесе сәүдә эше белән мәшгуль. Бу традицион кәсеп. Швециядә яшәүче татар тарихчысы Туркер Соуккан швед телендә басылган бер хезмәтендә болай ди: «Финляндия татарлары әүвәл-әүвәлдән базар дөньясына якын булган. Чәчбаулары, чуклар, көзгеләр, кульяулыклар, шәл, сабын һәм башка шундый көнкүреш әйберләре белән сату иткәннәр. Тора-бара бер өлеше үзләренә кибет ачкан. Күн һәм мехлар сәүдәсенә күчкәннәр» (Медделанден. 1985, № 10. Стокгольм, 103 бит)[1]. Әйтелгән фикерне «Финляндия татарларының музыкасы» дигән хезмәтләрендә (ул «Антропологик эзләнүләр» исеме астында инглиз телендә чыккан китапта басылган (Стокгольм, 1978) фин галимәләре И. Коленмайнен һәм М. Марямаки да куәтли: «Өлкәннәрнең бер өлеше келәмнәр, мехлар, ту-

[1] Бу мәкаләне швед теленнән татар теленә күчереп җибәргәне өчен Хельсинкидә торучы Айгөл Байбулатка самими рәхмәтемне белдерәм.

кымалар һәм өс-баш киемнәре белән сату итә, алар кибетләр тоталар. Яшь буын исә сәүдә юлыннан гына китми, башка һөнәр һәм шөгыль сайларга омтыла» (133 бит). Дөрестән дә, яшьләр арасында югары уку йортларын тәмамлап инженер, табиб, юрист, экономист кебек белгечлек алган кешеләр саны елдан-ел арта бара.

Финляндия шәһәрләренә таралышкан татарларның фамилияләрен күздән кичергәндә бер күренешкә гаҗәпләнми мөмкин түгел. Анда бер төрле фамилияләр бик күп. «Мәхәллә хәбәрләре»ндә ел саен басылып барган исемлек нигезендә, йә булмаса «Финляндия мөселманнарының телефоннар каталогы»на таянып, шундый берничә фамилияне санап үтик. Әгәр Шакир, Гайнетдин, Хәйретдин, Хәмидулла фамилияле гаилә башлыклары утыздан алып кырыкка хәтле кабатланса, Сәгъдетдин, Җамалетдин, Гали, Бәдретдин фамилияләре илледән алып җитмешкә кадәр кабатлана. Бер үк фамилиядәге гаиләләрнең күплеген миңа Финляндиядәге татарлар арасында ыру-нәсел, туганлык бердәмлегенең көчле булуы белән аңлаттылар.

Туганлык, кардәшлек тойгысы татар дөньясына хас изге хисләрдән санала. Финляндия татарлары өчен бу хиснең аларны бер тирәгә җыеп, таркалудан, югалудан саклап калучы аеруча бәрәкәтле, олы хис икәнлеген аңлавы кыен түгел.

XX гасыр башында Финляндия татарларын рәсми яктан берләштергән оешмалар булмаса да, Хельсинкидә корылган мәчет эшләрен башкаручы бер идарә эшләп килә. Ул төрле шәһәрләрдә урнашкан милләттәшләр белән элемтә булдырып, аларның дини һәм милли мәнфәгатьләренә хезмәт итүне төп бурычы дип саный, аерым кануннарга нигез сала. Мәсәлән, 1897 елда ук мәхәллә әгъзалары өчен еллык салым шартлары турында низамнамә (устав) кабул ителгән була. Җәмгыяте исламиянең 1958 елда үткәрелгән гомуми җыелышында бу низамның 17-маддәсен (бүлекчәсен) үзгәртү турында карар чыгарыла.

Финляндия татарлары тарихының XX гасыр башына караган чорын аларның ул илдә урнашу-утраклашу чоры дип атау дөрес булыр.

## «Финляндия исламия җәмгыяте» һәм аның эшчәнлеге

Бу җәмгыять 1925 елда корыла һәм рәсми рәвештә расланып, яңа устав нигезендә эшкә керешә. Финляндия татарлары үз тарихларының икенче чорын шушы елдан башлыйлар. Андагы милләттәшләр өчен бу чыннан да тарихи ел, язмышның алар алдына «нишләргә» дигән җитди бер сорауны куйган елы. Туган җирләрдән күчеп-күченеп килүләр тукталган, чикләр ябылган чак. Сергач яклары белән дә, Татарстан җөмһүрияте белән дә элемтәләр тәмам өзелгән, хәтта Уфадагы диния нәзарәте белән электән килгән бәйләнешләр киселгән кыен бер заман. Менә шундый борчулы, шомлы бер вакытта Финляндия татарларының аксакаллары бердәнбер хәкыйки юл сайлыйлар: ят илдәге якташларны берләштерергә һәм мөстәкыйль дини-милли колония булып яшәргә хезмәт итүче җәмгыять коралар. Финляндия татарлары Исламия җәмгыятенә нигез салучылар итеп дүрт кешене саныйлар: Гомәр Габдерәхим, Гыймадетдин (Имад) Җамалетдин, Нурмөхәммәт Гали һәм Вәлиәхмәт Хәким. Болар — бу җәмгыять тарихына мәңгелеккә язылган мөхтәрәм исемнәр.

Үзенең яшәү дәверендә Исламия җәмгыяте санаусыз күп файдалы эшләр башкара. Аның эшчәнлеге күп тармаклы булса да, бу тармаклар һәммәсе бер максатка — Финляндия татарларының дини-милли йөзен югалтмый яшәтүгә юнәлдерелгән. Моның дәлилләре «Мәхәллә хәбәрләре»ндә аз түгел. Менә бер язма: «Ямьле һәм тыныч фин мәмләкәтенә безнең халкыбыз узган йөз башыннан бирле килеп йөри башлаган булса да, бөтенләй монда урнашып яши башлавыбызга 30—35 елдан артык түгелдер. Мәхәлләбез моннан 30 ел элек корылып, шул заманнан бирле, мәхәлләбез корылганга кадәрге кебек, үз милли барлыгыбызны, ата-бабаларыбыздан күреп өйрәнгән үз милли вә дини гадәтләребезне саклап киләбез». («Мәхәллә хәбәрләре», 1955, № 12—13. 8—9 битләр).

Алда искә алган чыгышында Зуһур Таһир Финляндиядәге татар яшьләренә багышлап мөтәвәллият исеменнән түбәндәге теләк-киңәш белән мөрәҗәгать итә: «Беренчедән, ана телебезгә кадер-мәхәббәт белән карап, татарча чиста итеп сөйләшә белү фарызлыгын һәрчак истә тотарга, борынгылардан калган күркәм гореф-гадәтләрне, йолаларны онытмаска, бай рухи мәдәни традицияләрдән читләшмәскә. Икенчедән, милли барлыкны киләчәктә дә югалтмас өчен башка милләт кешеләре белән өйләнешүләрдән

тыелып торырга, бу хәлнең тора-бара милләтебез нигезен какшатуга алып баруын хәтердән чыгармаска. Өченчедән, ислам диненә, иманга тугрылык саклап, мөселман дөньясында кабул ителгән кануннарны ихтирам итәргә («Мәхәллә хәбәрләре», 1955, № 10—11. 20 бит).

Бу киңәшләрдә Исламия җәмгыятенең күз уңында торган төп вазифалар анык итеп әйтелгән.

Менә шушы вазифаларны һәм мәхәллә, мәчет алдында торган күп төрле башка эшләрне тормышка ашырыр өчен һәр ел саен март аенда (нәүрүз буенча) җәмгыять җыелышы тарафыннан мөтәвәлли һәйәте (идарәсе) сайлана. Аның эчендә җиде кеше булып, һәр әгъзага эшнең билгеле бер өлкәсе йөкләнә. Болар арасында дини эшләрдән тыш, хәзинәдер, мәхәллә йортларын караучы, салымнар җыю вазифасын үтәүче, балаларга милли тәрбия бирү, дини дәресләр укыту һәм китаплар бастыру эшләрен оештыручы, зиратны тәртиптә тоту өчен җаваплы әгъзалар бар. Болардан тыш мөтәвәлли һәйәте тарафыннан һәр ел саен башка шәһәрләрдәге татарлар арасыннан «йомышчылар» билгеләнә. Аларның максаты ике арада даими бәйләнешләр булдырудан гыйбарәт.

Исламия җәмгыяте эшчәнлегендә үзәк фигуралар икәү — берсе мәхәлләнең имамы, икенчесе — мөтәвәллият рәисе. Төп йөкне шулар тарта, дилбегә шулар кулында. Җәмгыять оешкан көннән башлап 1962 елга кадәр аның имам хатибы һәм мөдәррисе булып Вәлиәхмәт Хәким хәзрәт эшли. Үзенең фидакарь һәм намуслы хезмәте белән ул Финляндия татарларының самими хөрмәтен яулый. 80 яше тулган көннәрдә бу мөхтәрәм аксакалны «Финляндия җәмгыяте исламия» үзенең иң беренче фәхри (мактаулы) әгъзасы итеп сайлый.

Хәким хәзрәтне Төркиядән чакырылган Әхмәт Нәгыйм Атасевәр алмаштыра. Тумышлары ягыннан аның әти-әнисе Бөгелмәдән булып, Атасевәр дини гыйлемнәрен шәрык илләрендә ала. Хельсинкида егерме еллар хезмәт күрсәткәннән соң, аны Австралиягә — андагы татар мәхәлләсенә имам итеп чакыралар. Хәзерге вакытта Хельсинки мәчетенең баш имамы — Габдерахман Каййа хәзрәт. Ул да Төркиядән килгән. Икенче имам — Әнвәр Йылдырым да шул ук илдән. Икесе дә татарлар, икесе дә гарәп телендә мөкәммәл итеп Коръән укыганнары кебек, туган телләрендә күңелне хушландыра торган вәгазьләр сөйлиләр.

Шунысын да әйтергә кирәк, Тампере, Турку, Ярвинпә, Котка кебек эрерәк шәһәрләрдә татарларның үз мәхәлләләре, үз имамнары бар. Соңгыларының исемнәре Исламия җәмгыяте тарихында шулай ук хөрмәт белән телгә алына.

1975 елда «Финляндия исламия җәмгыяте» үзенең 50 еллыгын олы бәйрәм рәвешендә билгеләп үтә. Юбилейга багышланган тантаналарда ул илдә гомер итүче барлык татарлар да хозурланып катнаша. Чит мәмләкәтләрдән килгән кунаклар да бу бәйрәмне төрки халыклар һәм мөселманнар тарихы өчен күренекле бер вакыйга дип атыйлар. Шул ук елны Хельсинкида бу дата уңае белән фин телендә бер китап басыла. Рәсемле альбомны хәтерләткән бу китапның кадере-кыйммәте елдан-ел артачак кына. Чөнки анда тарихи мәгълүматлардан тыш, Финляндия татарларының иҗтимагый-рухи тормышына караган мөһим вакыйгалар, тармаклар, дин һәм милләт өчен күп хезмәт куйган шәхесләр турында язылган. Шулар исәбеннән мөтәвәлли һәйәтендә озак еллар дәвамында күркәм эшләр башкарган берничәсен күрсәтеп үтик: Зуһур Таһир, Госман Гали, Габдулла Гали. Соңгы дүрт елда мөтәвәллияттә рәислек хезмәтләрен Окан Таһир алып бара. Ул Казандагы татар галимнәренә таныш булган профессор Гомәр Таһирның улы, белеме буенча юрист һәм филология фәннәре кандидиты. Аның Казанда дүрт-биш тапкыр булганы бар, соңгы мәртәбә 1989 елда Болгар дәүләтенә ислам дине кабул ителүгә 1100 ел тулу уңае белән оештырылган бәйрәм көннәрендә Финляндия делегациясенең башлыгы буларак килгән иде.

Исламия җәмгыяте урнашкан биш катлы мәһабәт йорт — Хельсинкинең үзәгендә, юллар чатында. Аны, гадәттә, «Мәхәллә йорты», йә «Ислам йорты» дип йөртәләр. Ул илленче еллар ахырында җәмгыять акчасына салынган. Бу акчаның сизелерлек өлешен анда яшәүче бай татарлар һәм аерым фирмалар бүләк иткән. «Ислам йорты»нда Финляндиядәге бөтен мөэмин-мөселманнарны күз алдында тотып җиһазланган зур мәчет залы, мәдәни-тәрбияви эшләр белән шогыльләнүче «Төрек берлеге» дигән җәмгыять, яшьләр клубы, «Йолдыз» исемле спорт җәмгыяте, китапханә бар. Бу бинада ел дәвамында дини бәйрәмнәр (рамазан, корбан, рамазан шәриф, мәүлет шәриф) үткәрелә, һәр җомга көнне карты-яше намаз укырга, вәгазь тыңларга килә. Клубта ай саен диярлек «Милли кичә», «Җыр кичәсе», «Чәй кичәсе» дип аталган ял

кичәләре оештырыла, балалар өчен тәртипләнгән төрле милли кичәләр дә шушында уздырыла. Шул ук йортта аерым гаиләләр оештырган корбан ашлары, туй мәҗлесләре була. Төрле вакытларда Казаннан барган артистлар, галимнәр белән булган аерым очрашулар һәм мөселман илләреннән килгән кунаклар белән күрешүләр дә шушы бинада үткәрелә.

Бу йортта минем берничә тапкыр булганым бар. Соңгы баруымда (1989) якын танышым Нури Сәмәрхан мине үзе белән җомга намазына алып барды. Залга сиксәнгә якын кеше җыелган иде. Дикъкатьне җәлеп иткәне шул булды: арада Хельсинки татарлары гына түгел, Финляндиягә төрле гарәп илләреннән, Төркиядән килгән мөсафирлар да, анда даими яшәүче аерым илчелек вәкилләре дә бар иде. Намаздан соң алар татар телендә сөйләнгән бай эчтәлекле вәгазьне дә ихтирамлы игътибар белән тыңлап утырдылар. Нури Сәмәрхан әйтүенчә, чит ил мөселманнары бу мәчеткә гел йөриләр һәм алар арасында ислам диненә күчкән европалы кешеләр саны елдан-ел арта бара икән.

Җәмгыяте исламия башкарган игелекле эшләрнең берсе итеп, аның дини әдәбият һәм андагы балалар өчен уку китаплары, дәреслекләр бастырып таратуын күрсәтергә кирәк. Бу изге эшчәнлек утызынчы еллар уртасыннан башлап дәвам итә. Басылган китаплар саны кырыкка якын... Соңгы елларда мәхәлләнең баш имамы Габдрахман Каййа тарафыннан чыгарылган өч китап аерым игътибарга лаек. Алар өчесе дә латин хәрефләре белән Хельсинкидә югары сыйфатлы фин кәгазендә басылган, өчесенең дә тышлыклары зәвык белән эшләнгән. Китапларда кулдан ясалган рәсемнәр дә, фоторәсемнәр дә бар. Куләмнәре дә кечкенә түгел. Исемнәрен санап китик: «Иман һәм гыйбадәт» (1986, 161 бит), «Иман шартлары» (1988, 108 бит), «Ислам шартлары» (1989, 203 бит). Аларда ислам диненең төп нигезләре бәяләнә. Коръән һәм башка дини китаплар тасвирлана, төрле сүрәләргә, аятьләргә, шулай ук намазга һәм башка дини йолаларга аңлатмалар бирелә. Шунысы да бик әһәмиятле, гарәп телендә китерелгән дини текстлар татарчага тәрҗемә ителгәннәр. Китаплар ахырында дини атамаларга сүзлек өстәлгән.

Мәхәллә китапханәсендә «Төрек халык мәктәбе» тарафыннан нәшер ителгән китаплар шактый. Шул исәптән пәйгамбәрләр тарихына багышланган берничә китапны, Һади Максудиның дини йолалар турындагы әсәрләрен, Г. Тукайның «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» дигән җыентыгын (1953, 137 бит), укытучы Фәридә Бикчуриның өч кисәктән торган «Уку китабы»н телгә алыйк. «Төрек халык мәктәбе» 1948 елда ачылып, 1969 елга кадәр яши. Аның мәгариф өлкәсендәге эшчәнлеге Исламия җәмгыяте белән тыгыз элемтәдә булып, дәресләр татар, төрек, фин телләрендә алып барыла. Бу мәктәпне оештыручылар һәм анда укытучыларның берсе Гомәр Таһир була. Төрле елларда биредә дәресләр биргән аерым укытучылар Төркиядән һәм Германиядән килеп йөриләр. Алар арасында күренекле татар тарихчысы Габдулла Баттал-Таймас, шулай ук Галимҗан Идриси, Закир Кадыйри, Сания Гыйффәт, Наилә Бинарк, Фәридә Бикчури кебек язучылар, җәмәгать эшлеклеләре, журналистлар бар. Милләт өчен көчләрен аямаган бу зыялыларны Финляндия татарлары бүген дә хөрмәт белән искә төшерәләр.

«Төрек халык мәктәбе» халыкка егерме елдан артык хезмәт күрсәткәннән соң, укучы балаларның елдан-ел азая баруы сәбәпле, эшчәнлеген туктатырга мәҗбүр була. Аның урынына мәхәллә каршында атнага берничә мәртәбә сабак өйрәтүче тел-әдәбият курслары ачыла. Бу курслар бүген дә хәрәкәттә. Аларны кичке курслар дип йөртәләр. Дәресләр татар һәм төрек телләрендә алып барыла. Укучы балалар шушында ук дин буенча дәресләр тыңлыйлар, догалар өйрәнәләр. Җәйләрен исә һәр елны мәхәллә тарафыннан Хельсинкидән читтәге «Мәнсәлә» дигән бер ямьле урында махсус курслар оештырыла. Биредә милли, дини дәресләрдән тыш балалар өчен төрле уеннар, бәйрәмнәр үткәрелә. Алар табигать кочагында ай буе хозурланып ял да итәләр.

Мәхәллә курсларында укучы шәкертләр һәм балалар бакчасында тәрбия алучы сабыйлар өчен Исламия җәмгыяте соңгы ун елда дистәдән артык китап чыгара. Монда иң әүвәл «Балалар бакчасында» дигән берничә җыентыкны, әкият китапларын, А. Алиш, Дәрдемәнд кебек язучыларның балалар өчен язган әсәрләрен, җыр мәҗмугаларын күрсәтергә кирәк. Соңгы китап «Сандугачым, син дә сайра» дигән исем астында 1990 елда чыккан. Анда балалар өчен язылган 91 татар җыры ноталары белән бергә бирелгән. Китапларның байтагы андагы үзешчән рәссамнар тарафыннан бала зәвыгына туры китереп бизәлгән булуын әйтү дә артык булмас. «Әтәч патша» дигән әкият китабына (1982) язган кечкенә керештә укытучыларның берсе Фазилә Насретдин шулай ди: «Финляндиядә кечкенә генә бер азчылык булып яшәү сәбәбеннән,

ана телен саклау һәм дә аны балаларга мөмкин кадәр бай рәвештә күчерү тәрбиячеләр өчен катлаулы һәм кыен бер эш. Телне сакларга теләгәндә иң мөһим нәрсәләрдән берсе — китап». Менә шуны истә тотып, Финляндиядәге татарлар өчен милли телдә китаплар бастырып тарату эшен Исламия җәмгыяте үзенең изге бер вазифасы дип саный. Күпчелек китапларны матбугатка әзерләүдә, Фазилә ханымнан тыш, күп еллар буена балалар тәрбиячесе һәм мөгаллимә сыйфатында файдалы эшләр башкарган Фәридә ханым Низаметдиннең хөрмәткә лаек хезмәт куюын билгеләп үтү гадел булыр[1].

Алдарак телгә алынган «Мәхәллә хәбәрләре»нә киңрәк тукталасы килә. 1949—1963 елларда дөнья күргән һәм инде кыйммәтле тарихи чыганакка әйләнгән бу җыентык Финляндия исламия җәмгыятенең рәсми басмасы. Аның төп максаты — «Җәмгыятьнең эшләрен һәм фикерләрен белдерү». Үз гомерендә җыентыкның утыз саны дөнья күргән бу мәҗмуганың баштагы саннары гарәп хәрефләре белән басылган. Соңрак гарәп һәм латин хәрефләре аралашып барган. Ахыргы берничә санындагы хәбәрләр исә тулысынча латин хәрефләрендә бирелгәннәр. Менә бу чуарлыкта Финляндия татарларының алфавитларга мөнәсәбәт тарихы да чагыла кебек. Соңгы утыз ел дәвамында андагы басмаларда, кагыйдә буларак, латин алфавиты кулланыла. Төгәллек хакына шунысын да әйтик, бу алфавит латинның бүгенге көндә Төркиядә кулланыла торган варианты һәм ул унга якын хәреф билгесе белән без белгән һәм, кызганыч ки, гомере кыска булган үз латиныбыздан аерылып тора. Финляндия татарлары арасында кириллицаны белүчеләр дә бар. Ләкин анда бу алфавитның абруе юк. Андагы милләттәшләр Татарстан илендә кабат латинга кайтуыбызны хуп күрәләр һәм шуңа өмет итәләр.

«Мәхәллә хәбәрләре»ндә Финляндия татарларының дини, иҗтимагый, мәдәни хәятләренә караган кызыклы мәгълүматлар аз түгел. Җыентык битләрендә Исламия җәмгыятенең еллык эшләре хакындагы хәбәрләр, булачак ел бюджеты, мәхәллә салымын түләү, укыту эшләре кебек мәсьәләләр даими яктыртылып барган. Күренекле кешеләрнең юбилейлары уңае белән язылган мәкаләләр, шулай ук некрологлар да урын алган биредә. Ел саен демографик белешмәләр басыла.

Бу белешмәләр уңаеннан түбәндәге мәгълүматны да өстәү сорала кебек. Финляндия татарлары тормышында социаль яктан котылгысыз, әмма динимилли яктан аклавы авыр булган бер күренеш — катнаш никахлар да очрый. Тарихчы Туркер Соукканның алда телгә алынган мәкаләсендә шундый юллар бар: «Финляндия татарлары арасында ятка өйләнүчеләр дә бар һәм хәзерге заманда андыйлар саны арта бара. Алай да аларга яхшы күз белән карамыйлар, мондый адым җәмәгать арасында хуплау тапмый» (107 бит).

Исламия җәмгыятенең тагын бер тарафтагы эшчәнлеге — аның халыкара бәйләнешләре. Соңгы кырык ел дәвамында бу җәмгыять чакыруы буенча дөньяның унга якын ислам иленнән (Мисыр, Тунис, Алжир, Пакыстан, Согуд Гарәбстаны, Иран һ. б.), шулай ук безнең илдәге дини нәзарияттан күп кенә рәсми вәкилләр һәм кунаклар килгән. Шул вакыт эчендә Финляндия мөселманнар җәмгыяте дә төрле ислам илләренә һәм Советлар иленә (Казан, Уфа, Ташкент, Сәмарканд һ. б.) үз вәкилләрен җибәреп, алар үзара мөнәсәбәтләрне саклау һәм ныгыту эшенә телгә алып сөйләрлек өлеш керткәннәр. Бу бәйләнешләр хакында җәмгыятьнең 50 еллыгына багышланган китапта да, «Мәхәллә хәбәрләре»ндә дә байтак мәгълүмат бар.

Финляндия татарлары Төркия, Америка һәм Швециядә яшәүче татарлар белән милли-мәдәни бәйләнешләрдә торалар. Үзләренең ял вакытларын Төркиядә үткәрүче гаиләләр байтак. Аннан кыз алучылар яисә кыз бирүчеләр саны да дистәдән артып киткән. Ниһаять, Финляндия татарлары арасыннан йөзгә якын кеше — өлкәннәр һәм яшьләр сиксәненче еллар ахырында туристлар сыйфатында Татарстанда булдылар. Аларның бер төркемен Хельсинки аша килгән Америка татарлары тәшкил итте. Кунаклар Казанда, татар иленең борынгы мәркәзе Болгарда, Тукай туган кадерле урыннарда булдылар, арадан берничәсе ерак бабалары яшәгән Сергач якларына да сәяхәт ясады.

Финляндия татарлары арасыннан хаҗга баручылар саны утыздан артып киткән. Хаҗга сәяхәт кылу, хаҗ кылмаге кию, хаҗи исеменә лаек булу анда зур мәртәбә санала. Гомере буена сәүдә эшләре белән шөгыльләнгән һәм шул ук вакытта язучы булып танылган Хәсән ага Хәмидулла хаҗда хәтта ике тапкыр була. Үзенең «Хаҗ хатирәләре» дигән ике китабында (1968, 1971) ул бу сәяхәтләре хакында бәйнә-бәйнә итеп, мавыгып сөйли.

---

[1] Бу мәкаләне язганда мин Фәридә ханым Низаметдин җибәргән төрле чыганаклардан да файдаландым. Аңа үземнең самими рәхмәтемне әйтәсем килә.

Финляндия Исламия җәмгыяте ирешкән казанышларны танымый мөмкин түгел.

«Америка, Япония, Төркия һәм башка мәмләкәтләрдә яшәүче диндәш һәм иректәшләребез мәхәлләбезнең вазгыятен вә башкарган эшләрен белеп, чын күңелдән шатланганнарын язалар, динебезне, милли барлыгыбызны саклау юлында тырышуларыбыз өчен рәхмәтләр укыйлар,— диелә бер мәкаләдә. — Төрле мәмләкәтләрдә яшәүче Казан төрекләре арасыннан Финляндия мөселманнарында дини-милли эшләр иң тәртипле сурәттә алып барыла, дип әйтсәк, бу сүз һич тә арттырып әйтелгән сүз түгелдер, дип уйлыйбыз». («Мәхәллә хәбәрләре», 1958, № 18—19. 61 бит).

## «Финляндия төрекләре берлеге» һәм мәдәният мәсьәләләре

Сүзне бер хатирәдән башлыйсы килә. 1969 елның маенда без танылган тел галиме Искәндәр Абдуллин белән Хельсинкида фәнни командировкада булган идек. Безне анда Хельсинки университеты профессоры һәм Г. Тукай исемендәге җәмгыять җитәкчесе Гомәр Таһир чакыртты. Көннәрнең берендә «Финляндия төрекләре берлеге» оештырган бер кичәдә катнаштык. Ул Хельсинкигә спорт ярышларына килгән төрек боксерлары белән очрашуга багышланган иде. Мәхәллә йортының зур залына өч йөзгә якын кеше җыелган. Өстәл өсләрендә тәмле чәй, татлы ризыклар. Хатын-кызлар аерым, ир-егетләр аерым утырганнар. Аерым өстәл артында төрек спортчылары һәм Төркиянең Финляндиядәге илчелек вәкилләре урын алган. Һәркайда Финляндия һәм Төркия флаглары. Кичне төрек берлегенең ул вакыттагы рәисе Әнвәр Хәйрулла ачты. Ул татар сүзләрен төрек сүзләре белән катнаштырып кунакларны сәламләде, Төркия белән Финляндия арасындагы дуслык мөнәсәбәтләре турында сөйләде. Аның «Без аслымыз белән Казан төрекләре» дигән сүзләре истә калган. Төрек кунакларыннан берәү чыгыш ясаганнан соң, Хельсинкидәге татар яшьләре матур гына концерт бирделәр. Кумәк һәм ялгыз җырлар, биюләр башкарылды. Концертта катнашучылар төрек телендә дә берничә җыр җырлап, кунаклар күңелен күрделәр. Ә ахырдан залдагы бөтен халык дәррәү рәвештә «Туган тел»не җырлаганда, без дә кушылдык. Кемдер шунда:«Безнең кумәк кичәләр һәркайчан «Туган тел»не җырлап тәмамлана»,— диде.

Бу хатирәне искә төшерүнең мәгънәсе бар. Төрле уңай белән мәхәллә йортында бәйрәм кичәләре үткәрү, сәхнә әсәрләре уйнау, концертлар оештыру — болар барысы да «Финляндия төрекләре берлеге»нең төп вазыйфаларыннан берсе. Андый кичәләргә Хельсинкидән читтә яшәүче милләттәшләр дә чакырыла.

«Финляндия төрекләре берлеге» 1935 елда оештырыла. Аның уставы бар. Әгъзалар саны ике йөздән артык. Еллык взнос күләме 300 фин маркасы. Һәр ел башында берлекнең гомуми җыелышы булып, анда тугыз кешедән торган идарә сайлана. Бер елдан соң ул идарә үз эшләре хакында халык алдында исәп-хисап бирә.

Берлек алдында торган үзәк максат бер генә: милли хис-тойгыларга куәт бирү, халыкның рухи тормышын мөмкин кадәр эчтәлекле һәм бай итү. Моңа ирешү өчен берлек үз эшчәнлеген берничә юнәлештә алып бара. Мисал өчен 1961 ел хисабына күз салыйк. Ел дәвамында Хельсинкидә халык өчен татар телендә биш лекция укылган. Сүз Төркиядән килгән татар профессоры Рәшит Рәхмәти, Әкъдәс Курат, Габдулла Баттал-Таймасларның милли һәм тарихи мәсьәләләргә, баш имам Вәлиәхмәт Хәкимнең ислам диненә һәм әхлакка, икенче имам Әхмәт Наим Атасеварнең милли телне саклауга багышланган лекцияләре турында бара. Бу елда татар яшьләре өчен алты мәртәбә чәй кичәсе үткәрелгән. Анда катнашучылар милли җырлар җырлап, уеннар уйнап ял иткәннәр. Моннан тыш өч мәртәбә милли кичәләр уздырылган. Аларның берсендә һәвәскәрләр тарафыннан сәхнәдә татар драматургы Галиәсгар Камалның «Хуҗа һәм приказчик» исемле комедиясе уйнала, аны 400 дән артык кеше тамаша кыла. Балалар өчен оештырылган аерым бер кичәдә исә төрек халык мәктәбендә укучылар «Ятим бала» дигән пьеса күрсәтәләр. («Мәхәллә хәбәрләре», 1962, № 27. 10—12 битләр).

«Финляндия төрекләре берлеге» үзенең эшен һәр елны менә шушы рәвешле оештырып бара. Г. Галенның алда искә алган библиографиясенә төрле елларда үткәрелгән милли кичәләрнең программалары да кертелгән. 1943 елда, мәсәлән, андагы һәвәскәрләр сәхнәгә Г. Исхакыйның

«Җанбаевич» дигән комедиясен куйганнар. Берничә тапкыр уйналган пьесалар арасында Мольерның «Саран»ы, Г. Исхакыйның «Зөләйха»сы, М. Фәйзинең «Асылъяр» һәм «Галиябану»ы, Г. Камалның «Банкрот», «Бүләк өчен», «Беренче театр»ы бар. Соңгы вакытта (1984) балалар өчен А. Әхмәтнең «Үги кыз» әкияте сәхнәләштерелгән.

Миндә «Финляндия төрекләре берлеге» чыгарган унга якын җыр җыентыгы бар. Беренчесе — «Халкыбыз көйләре» 1952 елда басылган. Соңгысы — «Җырлыйк бергә» 1990 елда дөнья күргән.

Арада иң күләмлесе 1980 елда басылган «Безнең җырлар» китабы . 460 биттән торган бу җыентыкта 477 җыр тексты үзләренең көйләре, ягъни ноталары белән бирелгән. Дөресен әйткәндә, җырлар басу тарихында мондый зәвыклы, бай итеп эшләнгән китапның Казанда әлегә кадәр беркайчан да дөнья күргәне юк. Андагы әсәрләрнең яртыдан артыгын татар халык җырлары, калган өлешен татар, башкорт шагыйрьләре һәм композиторлары иҗат иткән җырлар алып тора. Дистәгә якыны Финляндия татарлары арасында таралган һәм безнең фольклор фәненә әүвәл мәгълүм булмаган әсәрләр. Шуларның берсе — Сөембикә турындагы тарихи җыр анда бүген дә популяр санала. Китапта төрек халык җырларыннан да берничә үрнәк бар.

Милли-мәдәни мәсьәләләрне «Берлек» башкармасы еш кына ислам җәмгыяте белән бергәләп хәл итә. Моның матур мисалы — татар музыкасын саклау, таратуга юнәлгән күркәм эшләр. Күз алдына китерегез, саннары бер меңгә дә тулмаган Финляндия татарлары өчен соңгы елларда гына милли җырлар, көйләр язылган дүрт музыкаль тәлинкә һәм ике кассета чыгарыла. Дәрәҗәле фирмаларда бизәкләп эшләнгән бу язмаларның бөтен дөньяга сибелгән татарлар өчен милли моңнар һәм хисләр, куанычлар һәм юанычлар чишмәсе булуын һәм шуның белән кадерле бер хатирәгә әйләнүен әйтми калу мөмкин түгел. Мәгълүм «Азатлык» радиосының татар бүлеге, Казаннан барган музыка язмалары белән бергә, Финляндия җирендә башкарылганнарын да даими тапшырып килә.

Искә алган тәлинкәләргә (Финляндия татарлары аларны «такта» дип йөртә) һәм кассеталарга андагы һәвәскәрләр ансамбле һәр хор түгәрәге башкарган иллегә якын җыр-көй язылган. Эстрада ансамблендә алты музыкант һәм ике җырчы булса, хорда кырыкка якын һәвәскәр катнаша. Хор башкарган һәм нигездә татар халык җырларыннан торучы «Ак Идел буйлары» исемле тәлинкә (1986) тышлыгында һәр җырга карата инглиз һәм татар телләрендә түбәндәге кыска гына фикерләр әйтелгән:

«Без, Финляндиядә яшәүче татарлар, ата-бабаларыбыздан калган үз гадәтләребезне, милли барлыгыбызны саклап киләбез. Милли җырларыбыз шатлык бәйрәмнәрендә һәм көндәлек тормышыбызда яңгырый. Әнкәләребез бишектән башлап үз көйләребез белән үстергәннәр. Шуның өчен җырларыбыз безгә якын, алар күңелләребезгә сеңгән». Тәлинкәләрнең берсе — «Сагынам, дусларым» (1979). Тышлыкта — катнашучыларның рәсемнәре.

Аларның күбесе Казан, Чаллы, Мәскәү татарларына таныш. Чөнки бу һәвәскәрләр 1989 елның җәендә Финляндиядән килеп, саналган шәһәрләрнең тамашачылары алдында күңелле концертлар биргәннәр иде. Халык аларның җырларын, моңнарын яратып, сокланып, гаҗәпләнеп, алкышлап тыңлады. Матбугат битләрендә ансамбль чыгышларына югары бәя биргән рецензияләр чыкты. Юк, бу гадәти концерт кына түгел,— диелгән иде аларның берсендә. Бу — чит илдә гомер итүче милләттәшләребезнең туган телдә сөйләшә, аңлаша алу шатлыгы да, үзләренең сагыну хисләрен түкми-чәчми китереп җиткерә алуларына горурлану да, рухи ихтыяҗларының газиз кайтавазын тоюга рәхмәтле булулары да иде» (Гөлнур Гобәйдуллина. «Кош җитмәгән җиргә җыр җитә». «Социалистик Татарстан», 1989, 20 июль).

1991 ел башында бу ансамбльнең «Кизләү» дип исемләнгән яңа кассетасы чыкты. Башкаручылар төркеменә яшь музыкантлар өстәлгән. Аларның икесе татар, икесе фин егетләре. Репертуардагы яңа әсәрләрнең байтагы танылган композитор Л. Батыр-Болгарый җырлары. Кассетадагы ике әсәр аерым игътибарга лаек. Берсе Финляндия татарларының бабаларыннан калган «Сулар буйлап» җыры. Борынгы булса да, аның беренче яңгыравы. Икенче җырның музыкасын һәм шигырен ансамбль җитәкчесе, Финляндия җирендә мәгълүм гитарист Дәнис Бәдретдин язган. Төп шөгыле буенча ул коммерсант. «Әлмира» исемле җырны автор, үзе әйткәнчә, Европага хас стильдә иҗат иткән. Татар моңы бик чамалы булса да, әсәр яңалыгы белән истә кала.

Соңгы елларда «Финляндия төрекләре берлеге» Казан белән, татар мәдәнияте һәм фәне белән бәйләнешләрне ныгытуга аерым игътибар күрсәтә башлады. Берлек чакыруы буенча атаклы артистыбыз Хәйдәр Бигичев җитәкчелегендәге бер төркем 1989 елда Хельсинкидә булып, андагы

милләттәшләр күңеленә хуш килердәй концертлар биреп кайттылар («Социалистик Татарстан», 1989, Х.15). Казан университеты доценты, әдәбият галиме Хатиб Миңнегулов Хельсинки университеты чакыруы буенча фәнни командировкага баргач, төп эшләреннән тыш, андагы татарлар өчен борынгы әдәбиятыбыз турында берничә лекция укый. «Берлек» тарафыннан оештырылып, мәхәллә йортында укылган бу лекцияләрне зур кызыксыну белән тыңлыйлар («Социалистик Татарстан», 1990, Ү. 6).

Ни өчен бу мәдәни оешма «Финляндия төрекләре берлеге» дип атала соң?

Иң беренче чиратта моңа безнең илдә егерменче еллар ахырында тамыр җәя башлаган тоталитар режим гаепле. Алдарак әйтелгәнчә, нәкъ шул елларда Финляндиядә гомер итүче татарлар төп Ватаннарыннан мәхрүм ителгән бер хәлдә калалар, ике ил арасындагы сәяси мөнәсәбәтләр киеренке төс алгач, аралашуларга катгый чик куела. Финляндия җире андагы татарлар өчен мадди яктан бай һәм житеш булса да, дине, теле ягыннан ят ил. Шуңа күрә аларның бер өлеше дини, мәдәни яктан үзләренә кыйбла итеп Төркияне сайлау фикерен яклыйлар. Төркия — төрки халыклары арасында мөстәкыйльлеген югалтмаган бердәнбер суверен дәүләт. Өстәвенә, татарлар белән төрекләр арасында борынгыдан килүче тарихи-мәдәни традицияләр яшәве мәгълүм, анда гомер итүче күренекле татар зыялылары Финляндиягә даими килеп йөриләр. Дөрес, төрекләр татар дигән этнонимны үзләренчә атыйлар, алар өчен без «Казан төрекләре», «шимал төрекләре». Бу атаманы Финляндиядәге татар колониясе җитәкчеләре дә кабул итеп ала. «Мәхәллә хәбәрләре»ндә, кагыйдә буларак, «Финляндия төрекләре», «шимал төрекләре» дигән төшенчәләр генә кулланыла. Шуңа күрә 1935 елда оештырылган мәдәни оешманың «Финляндия төрекләре берлеге» дип аталуы гаҗәп түгел. Шул ук вакытта бу исемгә тарихи килергә кирәк. Заманында ул Финляндия татарларына үз-үзләрен ислам динендәге төрки халык буларак саклау өчен кирәк булган. Ләкин монда исем белән җисемнең бер-берләренә туры килмәве дә күзгә бәрелеп тора. Андагы татарлар үз туган телләрендә сөйләшә, ата-бабаларыннан калган йола-гадәтләргә тугрылык саклый, милли әдәбиятны һәм музыканы берни белән дә алыштырып булмый торган рухи хәзинә дип саный. Күрәсең, шул сәбәпледер, әүвәлрәк үзен даими сиздереп торган һәм бәхәсләр кузгаткан исем һәм җисем каршылыгы соңгы елларда югала бара. Фәнни мәкаләләрдә генә түгел, балалар өчен чыгарылган китапларда да, аерым музыкаль тәлинкәләрдә дә Финляндия татарларының үз этнонимнары белән, ягъни татарлар дип аталуы һәм гомумән «татар» атамасын кулланудан тартынмаулары шуның бер дәлиле булып тора.

## Тукай җәмгыяте турында

Габдулла Тукай исеме — бөтен татар галәме өчен изге исем, ул милләтнең рухи юлбашчысы да, фидаи байракчысы да. Финляндия татарлары хәятендә дә Тукай кадерле һәм мөкатдәс урын били. Ел саен шагыйрь туган көндә татарлар яшәгән эре шәһәрләрдә аңа багышлап милли кичәләр үткәрү гадәте яши. Анда шагыйрьнең китаплары басылып тора, аның турында мәҗмугалар чыга. «Габдулла Тукай шигырьләре» дип аталган җыентык шагыйрьнең әсәрләреннән торса (аны әдәбият һәвәскәре, сәүдәгәр Хөсәен Садыйк әзерләгән), «Татар шагыйре Габдулла Тукай» дип исемләнгән китапта аның тәрҗемәи хәле һәм иҗаты турында төрле мәкаләләр, хәбәрләр тупланган. Соңгысын Тампере имамы Хәбибрахман Шакир белән шул шәһәрнең мәдәният эшчәне Гайсә Хәкимҗан әзерләгәннәр.

Мәгълүм булганча, 1967 елдан башлап Финляндиядә Габдулла Тукай исемен йөртүче мәдәни җәмгыять эшләп килә. Аның оештыручысы һәм җитәкчесе — Хельсинки университетында төрки телләр укытучы профессор Гомәр Таһир. Ният-максатының кыюлыгы һәм яңалыгы ягыннан бу җәмгыять аерым игътибарга лаек. Чөнки монда сүз Финляндия татарларын тарихи ватаннары белән, милли мәркәз саналган Казан белән якынайту турында, икенче төрле әйткәндә, ничәмә еллар буе корыч куллы мәрхәмәтсез сәясәт аркасында, бер-берләреннән ясалма читләштерелгән бер милләт кешеләре арасында дустанә мөнәсәбәтләргә юл ачу турында бара. Шушы игелекле максатка ирешү өчен Тукай җәмгыяте егерме елдан артык яшәү дәверендә хөрмәт белән тәкъдир ителердәй күп эшләр башкарды. Бу эшләрнең кыйбласы Финляндия татарларының рухи-мәдәни ихтыяҗлар дөньясына юнәлгән.

Билгеле булганча, милли тел һәм әдәбият, сәнгать һәм тарих — халык гомеренең, халык рухының төп таянычлары. Халыкны шулар яшәтә. Шуны истә тотып, Тукай җәмгыяте Казаннан танылган татар артистларын, сәнгать

осталарын һәм галимнәрне чакыртып, алар катнашында Хельсинкидә һәм башка шәһәрләрдә җыелышлар, очрашулар үткәрүне төп максаты итеп саный. Үткән еллар дәвамында җәмгыятьнең унҗиде җыелышы уздырыла. Аларда Казаннан барган унбиш артист һәм тугыз галим катнаша. Финляндиядәге татарлар күңелен үзенә тарткан җыелышлар, концертлар, лекцияләр, документаль фильмнар — болар барысы да ике илдә яшәүче милләттәшләр арасындагы мәдәни багланышларны көчәйтүгә һәм үзара яхшырак аңлашуга зур өлеш кертә. Шунысын да әйтергә кирәк, Казан артистларының концертлары уңаеннан фин матбугатында татар музыка сәнгатенә, аның осталарына карата соклану, хозурлану һәм хөрмәтләү хисләре белән сугарылган дистәгә якын җылы, самими бәяләмәләр басыла.

«Илле ел чамасы ана йортымыздан бөтенләй аерылган кебек чит җирләрдә үксез балалардай яшәп килдек,— дип яза Гайсә Хәкимҗан «Шатлык» дип аталган мәкаләсендә.— Финляндиядә туып үскән яшьләремезнең ана йортымыздан һич хәбәрләре булмаганлыктан, алар Финляндиядә генә татарлар бар, дип уйлыйлар иде.

Моннан берничә ел элек һич көтмәгәндә, кара болытлар астыннан нурлы кояш ярып чыккан кеби, ана йортымыздан Хельсинкигә татар артистлары, галимнәр килә башлады. Аларның килүләре Финляндиядәге татарларның җаннарын яңадан тергезеп җибәрде. Үзләрен татар дип әйтергә куркып йөргәннәр дә гайрәтләнеп, аяк өсләренә шатланып бастылар, төрекләшкән татарларның да күзләре ачылып, оятлы булган кебек булдылар. Шулай итеп, ике арамыздагы юллар ачылып китте» (1969, 28 август).

«Казан утлары» 1986 елда (№ 4) Тукай җәмгыятенең эшчәнлеген шактый этрафлы итеп тасвирлаган бер әңгәмә бастырды. Андагы мәгълүматларны кабатлап тормастан, соңгы биш елда Тукай җәмгыяте ярдәме белән дөнья күргән ике китапны телгә алыйк. Аларның «Татарика» дип аталганы 1987 елда Хельсинкидә басылды. Бу күләмле хезмәттә татар халкының тарихына, теле һәм әдәбиятына багышланган егерме сигез мәкалә урын алган. Авторлар арасында бөтен дөньяда танылган һәм төрле илләрдә яшәүче тюркологлар бар. Мәкаләләр биш телдә басылганнар. Бу олы хезмәткә «Советская тюркология» (1988, № 6) һәм «Казан утлары» (1989, № 9) битләрендә югары бәя бирелде. Икенче хезмәтнең авторы — күренекле татар археологы һәм тарихчысы профессор А. Халиков. Аның «Кемнәр соң алар, татарлар?» дигән монографиясе әле күптән түгел генә Хельсинкидә фин телендә дөнья күрде. Тукай җәмгыятенең алдагы планнарында татарча-финчә, финчә-татарча сүзлекләр төзеп чыгару нияте барлыгын да белдереп үтик.

Җыйнап әйткәндә, Тукай җәмгыяте Финляндия татарлары белән Казан татарлары арасында мәдәни һәм фәнни күпер салуга олы өлеш кертте. Шушы хезмәте белән ул андагы милләттәшләр тарихында үзенә аерым сәхифә ачкан җәмгыять дип саналырга хаклы.

## Матбугат тарихыннан берничә сүз

Кайда гына яшәсәләр дә, татарлар гыйлемгә, китаби сүзгә, уку-язуга хирес халык. Финляндия татарларының матбугат һәм матбагачылык тарихы белән якыннан танышканда бу фикернең раслыгына кабат-кабат ышанасың. Анда гомер кичерүче бер уч милләттәшләребез арасыннан китап язучылар һәм язылган әсәрләрне төрле ысуллар белән бастырып дөньяга таратучылар исемлегендә йөзгә якын кеше бар. Алдарак Исламия җәмгыяте һәм төрекләр берлеге, халык мәктәбе һәм Тукай җәмгыяте кебек оешмаларның эшчәнлеген күздән кичергәндә, алар тарафыннан нәшер ителгән китаплар турында да сүз булды. Болар белән чагыштырганда аерым авторлар чыгарган мөстәкыйль басмалар саны бермә-бер күбрәк.

Финляндиядә 1925 елдан алып бүгенгә хәтле, ягъни алтмыш биш ел эчендә татар телендә дөнья күргән төрле басмалар (дини китаплар, дәреслекләр, җыентыклар, әдәби әсәрләр) саны ике йөзгә җитә. Ул китапларны төркемлисе, тәфсилләп тасвирлыйсы, тарихи-танып белү күзлегеннән һәм әдәби-эстетик яктан бәялисе бар. Хәзергә исә мин Хельсинкидә гомер иткән һәм үзем күреп белгән бер язучы турында гына тулырак мәгълүмат бирүне күз алдымда тотам.

Хәсән Хәмидулла (1895 — 1988) озын гомер юлы үткән, үз вакытында бәхет эзләп Польша, Төркия илләренә барып чыккан, күп йөргән, күп белгән, гаҗәеп тырыш, зирәк, туры сүзле бер кеше. Сәүдә дөньясын гына түгел, ки-

тап дөньясын да әйбәт белүче зат. Татар мәгърифәтчеләренә хас киң карашлы һәм милли тойгыларга бай булуы белән аерылып тора. Профессор Гомәр Таһирның фикердәше һәм кардәше. Финляндия җирендә бүген аның балалары, оныклары яши. Зур китапханәсендә күп китаплар саклана. Аерым бер шкафта үзе язган әсәрләр — романнар, хикәяләр, драмалар, шигырьләр.

Үзенең күп тармаклы иҗатын Хәсән Хәмидулла журналист буларак башлый. Кеми дигән кечкенә бер шәһәрдә торган елларда . 1925 елдан алып «Мәгърифәт» дигән газета чыгара. Аңа «фәкать җомга көннәрендә чыга торган сәяси, милли вә әдәби газетадыр» дигән искәрмә бирелгән. Бу газетаны ул өендәге басмаханәсендә күбәйтеп Финляндиядәге татарлар арасында тарата, Төркиягә, Кырымга һәм Ленинградка җибәреп тора.

1945 — 1977 елларда чыгып килгән «Шимал очкыннары» исемле журналны Х. Хәмидулла алда искә алган газетаның дәвамы итеп санаган. Анда төп урынны нәширнең үзе тарафыннан язылган әдәби әсәрләреннән һәм публицистикасыннан тыш, дини сабаклар, сүрәләр һәм догалар алып тора. «Шимал очкыннары» — безнең мондагы халык өчен мәгърифәт таратучы бердәнбер популяр журнал булды. Аны карты да, яше дә яратып укый иде»,— дип язды миңа Гомәр Таһир бер хатында.

Хәсән Хәмидулла фидакяр журналист булу өстенә, егерме тугыз китаптан торган әдәби әсәрләр авторы, фольклорчы һәм тарихчы. Ул бай әдәби мирас иясе: шигъри җыентыклары — унбер («Ватансызлык», 1946; «Моңлы таңнар», 1949; «Сүнгүә табан», 1951; «Илһам җимешләре», 1970 һ. б.), драма һәм комедияләре — җиде («Хәйрелниса», 1943; «Өзелгән өмет», 1960; «Алдым-бирдем», 1976 һ. б.), проза әсәрләре — дүрт («Тәкъдир каршында», 1950; «Мөһаҗир бәхете», 1953 һ. б.). Болардан тыш аның тарих белән бәйле өч әсәре («Яңапар тарихы», 1954; «Ник алай?», 1977 һ. б.), ике сәяхәтнамәсе («Хаҗ хатирәләре», 1968, 1971) һәм фольклор хәзинәләре тупланган ике җыентыгы («Борынгы картлар сүзе», 1951; «Татар халык җырлары һәм моңнары», 1975) бар.

Хәсән Хәмидулланы ислам дөньясында да яхшы беләләр. Чөнки ул үз гомерендә егермегә якын дини һәм дини-дидактик китап (шул исәптән «Коръән», «Иман шартлары») бастырып, аларны төрле илләргә таратучы да.

Моннан шуны да әйтү зарури. Хәсән Хәмидулла бөтен китапларын үзенең шәхси матбагасында (типографиясендә) бастырып килде. Бу эштә аңа ярдәм итүче бердәнбер кеше — хатыны Гөлсем ханым гына иде. Минем ул матбаганы күргәнем бар. Өйләренең аскы катындагы зур бүлмәдә хәреф җыя торган төрле машинкалар тезелгән. Гарәп хәрефләре дә, латин да бар. Төрле төстәге буяулар, төргәк-төргәк кәгазьләр. Уртада матбага машинасы. Хәсән ага аны эшләтеп күрсәтте, аңлатмалар бирде. Катлаулы, могҗизалы дөнья. Дистәләгән китапларына ул үзе рәсемнәр ясый, кирәк сызымнарны сыза. Барысына да ничек өлгерә ул? «Мин бик аз йоклыйм, юкса өлгереп булмый»,— дигән сүзләре истә калган.

Сәүдә өлкәсендә армый-талмый эшләве өстенә (аның радио-товарлар магазинында хәзер улы Гомәр сату итә), каләм остасы булып танылган бу шәхеснең иҗат мирасын махсус өйрәнеп, аның чит илләрдәге татарлар барлыкка китергән матур әдәбият тарихында тоткан урынын билгелисе бар. Ул моңа һәр яктан лаек затларның берсе.

1985 елда Хәсән Хәмидулланы Финляндия язучылары ассоциациясенә әгъза итеп алалар. Бу — язучының әдәби эшчәнлегенә югары бәя бирү.

Финляндия татарлары арасында әдәби иҗат белән шөгыльләнүче тагын берничә кешене телгә алып узыйк. Мин аларны шәхсән күреп беләм, әсәрләренең шактые китапханәмдә саклана. Сүз өч һәвәскәр турында бара: Садри Хәмит (1905 — 1987) — кечкенә күләмле утызга якын китап авторы, Гайса Хәкимҗан (1896 — 1972) — өч кисәктән торган шигъри җыентыклар иясе, Гәүһәр Туганай (1911) — ике шигъри мәҗмүга авторы, бүген дә иҗат эшчәнлеген дәвам итә, кайбер шигырьләре «Азат хатын» журналында (1969, № 3) дөнья күргән иде.

## Финляндиядә татар спорты турында

Финляндиядә яшәүче милләттәшләребезнең спорт белән бәйле үз тарихы бар. Аның беренче сәхифәләре утызынчы елларда языла башлый. Иң әүвәл Хельсинкида яшәүче егетләрдән бер футбол командасы оештырыла. Аңа «Алтын Урда» дигән исем бирәләр. Бу команда 1934 елдан алып Икенче Бөтендөнья сугышы башланганчы сафта була.

Сугыш беткәннән соң, 1945 елда Хельсинкида мөстәкыйль спорт җәмгыяте оеша һәм аңа «Йолдыз» дигән исем кушыла. Әлеге җәмгыять бүгенге көнгә кадәр актив эшләп килә. Аның үз уставы бар. Идарәсе ике ел саен сайланып тора. «Йолдыз» берничә бүлекне берләштерә. Футбол, гимнастика, теннис төп бүлекләрдән санала.

Беренче вакытта бу җәмгыять башкармасында рәис булып Вәлиәхмәт Гали тора, аннан Наим Җамалетдин, Габдулла Галиләр җитәкчелек итә. Алардан соң рәислекне егерме ел буе (1958—1978) Госман Габдерәхим алып бара. Бу тарихны бәян иткәндә аның истәлекләре дә файдаланылды. Соңгы унике ел арасында Равил Газиз, Ирхан Низаметдиннәр тырышып эшләде. Хәзерге вакытта рәислек вазифаларын Айфар Хәкимҗан алып бара. Ул — рәислек эшләрен башкаручы беренче хатын-кыз.

Хельсинкидәге татар футбол командасы әүвәлрәк түбәндәге лигада булса да, акрынлап өскә үрли һәм хәзерге вакытта алдынгы командаларның берсе санала. Аны клуб исеме белән «Йолдыз» дип йөртәләр. Футболчыларның майкаларында милли эмблема уелган. Ярты ай һәм йолдыз.

Татар футболчылары ел саен үз лигаларындагы унике команда белән очрашулар үткәрәләр. Узган ел алар лигада өченче урынны яулауга ирешә. Сиксән тугызынчы елның сентябрь аенда «Йолдыз» командасы Төркиягә барып, анда Истанбул, Анкара шәһәрләрендә студентлар белән берничә матч уйнап кайта. Татар футболчылары ике уенда җиңеп чыгалар. Алар кайткач, «Йолдыз» клубы бу сәяхәткә багышлап халык өчен зур кичә оештыра.

Уенчыларның күбесе — Хельсинкидә яшәүче татар егетләре, төп эшкәсепләре ягыннан сәүдә хезмәткәрләре.

Финляндиядә гомер итүче татарлар арасыннан чыккан һәм андагы мәмләкәттә генә түгел, Скандинавия, көнбатыш Европа илләрендә дә танылган берничә татар футболчысы булуын да әйтергә кирәк. Хәйрулла Сафкан, Тәлгать Исмай, Атик Исмай, Дәнис Бәшәретдиннәр уеннарын «Йолдыз»да башлап, соңрак Финляндиянең танылган командаларына чакырылалар, ә Атик Исмай Финляндиянең җыелма командасында уйнаган атаклы футболчы санала. Фин газеталарында «Йолдыз» командасы турында, аерым спортчылар турында хәбәрләр басылып тора. Татарлар арасыннан спорт буенча бер журналист та бар. Ул — Габбас Бәшәретдин. Танылган спортчылар арасында марафончы Әнвәр Бәдретдин, йөгерүче Сәмигулла Газиз, боксер Исмай Ногман, тимераякта шуып чемпион булган Хәсән Габдерәхим, йөзү буенча танылган Фәйзрахман Гали, оста атучы Суна Сафкан да бар. Мөнип Җамалетдин дигән хоккейчының күп еллар буе фин хоккей командаларында судья булып эшләвен дә телгә алырга кирәк.

«Йолдыз» җәмгыяте җәйләрен дә, кышларын да спорт көннәре, хәрәкәт көннәре оештыра. Миндә «Йолдыз» башкармасы тараткан төрле белдерүләр, чакырулар саклана. Аларның берсендә сүз Паюлахти дигән зур стадионда җәй көне оештырылган спорт бәйрәме турында бара. Анда Айнур Низаметдин дә катнаша. «Без илледән артык кеше идек,— диде ул.— Теннис, волейбол уйнадык, су коендык. Бу күңелле ял ике көн дәвам итте. Мәчет алдыннан автобуслар белән киткән идек, шул ук автобуслар кире кайтарды». Ике ел элек «Йолдыз» үткәргән сабантуйны искә төшерәсе килә. Мин аны үз күзләрем белән күрдем. Ул көнне Хельсинкидән һәм Тампередән бик күп халык үз машиналарында Ярвинпэ шәһәренә җыелды. Бу шәһәр үзәгендәге агач мәчет мәйданында матур итеп сабан туе үткәрелде. Төрле милли уеннар уйналды, ярышлар оештырылды, милли җырлар җырланды. Халык өчен «Йолдыз» бушлайга милли ашлар әзерләгән иде. Әйтүләренә караганда, мондый ял бәйрәмнәре ел саен берничә тапкыр булып тора.

Германиядә яшәүче мәгълүм татар тарихчысы, сәясәтче Гали Акыш Финляндиягә еш килеп йөри. Бу илдә аның туганнары яши. Бер килүендә ул: «Икенче дөнья сугышыннан соң чит илләрдәге шимал төрекләре арасында тәртипле һәм матди багымнан тәэмин ителгән оешмалары белән фәкать вә фәкать Финляндия төрекләре генә калдылар... Сезләр, күкрәкләрегезне киереп, үзегезнең милли-дини барлыкны саклап калган бер оешма буларак мактана аласыз»,— дип белдерә. («Мәхәллә хәбәрләре», 1958, № 18—19. 42 бит). Бу сүзләрдә бүген дә хаклык һәм гаделлек көче бар.

Финляндиядә гомер итүче татарларның әлбәттә үз проблемалары күп. Матди һәм рухи мәнфәгатьләрне акыллы бәйләнештә, ирешелгән югарылыкта саклап калуга юнәлгән көндәлек көрәш алардан күп егәр, сәләт, оешканлык һәм бердәмлек сорый. Бу сыйфатлар исә аларда бар. Алар үз кадерләрен белеп, сайлаган кыйблаларына тугрылык саклап яшәргә омтыла. Моңа Финляндия татарларының гасырдан артыкка сузылган бай тарихы шаһит.

## Рәфкать Кәрамигә 50 яшь



Рәфкать Кәрами 1942 елның 18 февралендә Татарстанның Сарман районы Рангазар авылында туган. Авылда җидееллык мәктәпне, 1959 елда Алабуга мәдәният техникумын тәмамлагач, ул баянчы, клуб мөдире, производствода рәссам, гади эшче, электрик һәм машинист ярдәмчесе булып эшли. Аннары өч ел Хәрби диңгез флотының яр буе частьларында хезмәт итә.

1964—1977 елларда ул «Казаньхимстрой» трестында эшли. 1970 елда хезмәттеннән аерылмыйча, Казан дәүләт университетының тарих бүлеген тәмамлый.

1969 елда Рәфкать Кәрами «Дүрт кешелек каюта», 1970 елда «Кичке уйлар» һәм 1974 елда «Капитан Хәкимов» исемле повестьларын бастырып чыгара.

1977—1979 елларда ул Мәскәүдә СССР Язучылар берлеге каршындагы Югары әдәби курсларда укып кайта.

1978 елда Рәфкать Кәраминең «Очар кошлар белән янәшә» исемле күләмле әсәренең («Казан утлары», 9, 10 саннар) беренче кисәге дөнья күрә. Трилогиянең икенче кисәге — «Ашкыну» 1982 елда, ә өченче китабы «Чыңыгу чоры» исеме белән 1985 елда басылып чыга.

Рәфкать Кәраминең «Сагышлы кояш» һәм «Йөрәгемне ут алган» повестьларын укучылар аеруча яратып кабул итте.

1982 елда Минзәлә татар дәүләт драма театры аның «Яратуың чынмы?» исемле пьесасын сәхнәләштерде.

Ул — 1972 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы. 1989 елда аңа «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде.

## Әхмәт Гаделгә 50 яшь



Шагыйрь Әхмәт Гадел (Әхмәт Һади улы Гаязов) 1942 елның 2 февралендә Татарстанның Мамадыш районы Ак Чишмә авылында туган. 1959 елда Балык Бистәсе районындагы Котлы-Бүкәш урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, Лубян урман техникумында белем ала. 1962—65 елларда Совет Армиясе сафларында була. 1966 елдан башлап, Ә. Гаделнең тормыш һәм хезмәт юлы түбәндәгечә: ул — Түбән Кама районы газетасында хәбәрче, заводта компрессорчы, тракторчы, Шомыртбаш авылы мәктәбендә укытучы, Үзбәкстанда производство гимнастикасы инструкторы; Тольятти шәһәрендә слесарь-монтажчы, Казан телевидениесендә тәрҗемәче, республика халык иҗат йортында методист, «Социалистик Татарстан» газетасында корреспондент, 1983—84 елларда СССР Литфондының Татарстан бүлеге директоры, Татарстан мәдәният министрлыгында — методист, бүген исә анда мәдәни әлемтәләр буенча белгеч... 1977 елда Ә. Гадел, читтән торып укып, М. Горький исемендәге Әдәбият институтын тәмамлый.

Беренче шигырьләрен, мәкаләләрен русча язып, армия газеталарында бастыра. Казанга кайткач, татарча яза һәм матбугатта күренә башлый. «Күгәрченнәр» исемле коллектив җыентыкка кергән (1971, Ташкент) шигырьләре, «Чам» исемле беренче китабы (1978) кырым-татар телендә дөнья күрә. Шул ук 1978 елда «Яшьлек урамы» исемле китабы Казанда басылып чыкты. Ә. Гадел — унга якын шигырь китабы авторы, актив иҗат белән яшәүче шагыйрь.

Аерым шигырьләре, русчага тәрҗемә ителеп, «Октябрь», «Молодая гвардия» журналларын һәм бүтән басмаларда дөнья күрде, шулай ук немец, монгол, венгр, поляк һәм илебез халыклары телләрендә дә басылды.

*Татарстан Язучылар берлеге идарәсе һәм «Казан утлары» журналы редакциясе юбилярларны кайнар котлыйлар, аларга сәламәтлек һәм иҗат уңышлары телиләр.*

## ДЕПУТАТЛАР ҖЫЕНЫ

1991 елның 23—26 декабрендә Казан шәһәрендә Татарстан Республикасы Югары Советының сигезенче сессиясе эшләде. Анда унбиш мәсьәлә каралды. Алар арасында «Татарстан ССРда җирле үзидарә турында», «Татарстан ССРда бәйрәм көннәре турында», Татарстан Законы проектлары, Татарстан ССРның Дәүләт гербы турында, Бәйсез Дәүләтләр Бердәмлеге турында һ. б. мөһим мәсьәләләр бар иде. Аларның күпчелеге депутатлар тарафыннан кабул ителде.

Сессия эшендә Татарстан Республикасы Президенты М. Ш. Шәймиев катнашты һәм чыгыш ясады.

## ҖӘЛИЛЧЕЛӘР ХАЛЫК ХӘТЕРЕНДӘ

Инде матбугатта хәбәр ителгәнчә, каһарман шагыйребез Муса Җәлилнең көрәштәшләре озак еллардан соң I дәрәҗә Бөек Ватан сугышы орденнары белән бүләкләнгәннәр иде. 1991 елның 24 декабре көнне ТССР Югары Советы бинасында Татарстан Президенты М. Ш. Шәймиев әлеге орденнарны җәлилчеләрнең туганнары һәм якыннарына тапшырды.

Алар олуг бүләкне кабул итеп алырга Татарстан җөмһүриятенә төрле төбәкләрдән килгәннәр. Рәхмәтләр белдереп алынган ул орденнар җәлилчеләрнең туганнары тарафыннан Татарстанның әдәбият музеена тапшырылды.

Җәлилчеләрне искә алып һәм аларның каһарманлыгы алдында баш иеп, бүләкләрне тапшыру тантанасында Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Р. Мөхәммәдиев, язучылар Р. Мостафин, Г. Ахунов, Т. Миңнуллин җавап сүзе сөйләделәр.

## ТӨРКИ ӘЛИФБАЛАР СИМПОЗИУМЫ

1991 елның 18—20 ноябрендә Төркиянең Истанбул шәһәрендә бүгенге төрки халыклар әлифбаларын үзара якынайту һәм камилләштерү хосусында халыкара симпозиум булып узды. Аны Мәрмәрә университетының Төркия тикшеренүләр институты оештырды. Симпозиумда Төркия галимнәреннән тыш Совет иле төрки халыклары вәкилләре — күренекле телчеләр, тарихчылар, фикер ияләре катнашты. Алар арасында Татарстаннан Г. Ибраһимов исемендәге ТТӘТИ директоры, филология фәннәре докторы М. Зәкиев, шул ук институтның гыйльми хезмәткәре Р. Мөхәммәтдинев, шагыйрь Р. Вәлиев, драматург Р. Батулла, Уфадан Башкортстан университеты татар теле һәм әдәбияты бүлеге галиме А. Шәйхулов та бар иде. Гыйльми җыйналышта чит илләрдә яшәүче милләттәшләребездән Әнкара университеты профессоры Әхмәт Тимер, Истанбулның Мәрмәрә университеты доценты Надыйр Дәүләт (симпозиумны оештыручыларның берсе), «Азатлык» радиосының татар-башкорт редакциясе мөдире Фәрит Агый (Германия) да катнашты.

Симпозиум бертавыштан төрки халыкларның уку-язуын 34 хәрефтән торган латин әлифбасына күчерүне хуплады, шушы нигездә кардәш милләтләрнең үзара аңлашуы, мәдәни берлеге уңышлы үсәчәгенә ышаныч белдерде.

## ХАЛЫКАРА КОЛЛОКВИУМ

Төркиянең «Йени Форум» журналы узган елның сентябрь уртасында «Совет — Төркия хезмәттәшлеге»нә багышланган зур фикер алышу уздырды. Эгей диңгезе буендагы Ялыкавак шәһәрчегендә үткәрелгән бу җыйналышта АКШ, Германия, Совет иле һәм Төркия галимнәре, мәдәни эшлеклеләреннән йөзләп кеше, шул исәптән, Татарстаннан фән докторы М. Зәкиев, язучылар Р. Вәлиев, М. Маликова, Р. Мөхәммәдиев, Т. Әйди катнашты һәм чыгыш ясады.

Коллоквиум тәмамлангannan соң, милләттәшләребез чакыруы буенча, Т. Әйди Төркиянең күп кенә шәһәрләре һәм авылларында булды, татар-төрек багланышларын яктырту өчен мәгълүматлар туплады.

## ЯҢА СОВЕТ: БЕРЕНЧЕ ЯКЛАУ

1991 елда, җөмһүриятебез суверенлыгының бер җимеше буларак, Казан университеты каршында филология буенча докторлык Советы эшли башлады. 18 доктордан торган бу махсус Совет белән әдәбият галиме, профессор Т. Галиуллин җитәкчелек итә. Анда «СССР халыклары әдәбияты», «төрки телләр» белгечлекләре буенча докторлык диссертацияләре яклау күздә тотыла.

Узган елның 28 ноябрендә Советның беренче утырышы булды. КДУ доценты Хатип Миңнегуловның «Татар әдәбияты һәм көнчыгыш классикасы (Үзара багланышлар һәм поэтика мәсьәләләре)» темасына язылган докторлык диссертациясе тикшерелде.

Рәсми оппонентлар — филология фәннәре докторлары — Татарстан премьер-министрының беренче урынбасары М. Хәсәнов, Башкорт университетының журналистика кафедрасы мөдире М. Гайнуллин, Ташкент университеты профессоры Б. Касимов, авторефератка рецензия җибәргән Тарту һәм

Таҗик университетлары профессорлары С. Исаков һәм С. Вахидов, Азәрбайҗан академигы К. Талибзадә, утырышта чыгыш ясаган фән кандидатлары Ш. Абилов һәм Ә. Мөхәммәдиев, профессорлар Л. Савельева, М. Госманов, Н. Юзеев, А. Әхмәдуллин хезмәткә җентекле анализ ясап, аңа югары бәя бирделәр, диссертациянең гаять актуальлегенә, гыйльми һәм практик яктан мөһимлегенә басым ясадылар, аның татар әдәбиятын өйрәнүгә генә түгел, ә ориенталистикага, әдәбиятларны чагыштырма өйрәнү фәненә дә зур өлеш кертүен күрсәттеләр.

Махсус Совет, яшерен сайлау юлы белән, Хатип Миңнегуловка филология фәннәре докторы дәрәҗәсен бирү турында бертавыштан карар кабул итте.

## «ХӘСРӘТ ДӘРЬЯСЫ» ДӨНЬЯ ГИЗӘ

Айдар Хәлимнең Вильнюста чыккан «Хәсрәт дәрьясы» исемле китабы киң катлам укучыларында зур кызыксыну уятты. Китап шулай ук илнең җитәкче даирәләре тарафыннан да кызыксынып укыла икән. Казагыстан президенты Н. Назарбаев, мәсәлән, аның китабы белән танышкач, бик җылы хат җибәрде. «Хәсрәт дәрьясы»н АКШ конгрессы китапханәсе дә соратып алдырды. Шул ук вакытта әлеге хезмәтнең Михаил Горбачев, Россия Президенты Борис Ельцин, РСФСР Югары Советы Рәисе Руслан Хасбулатов, күренекле политиклардан Александр Яковлев, Эдуард Шеварднадзе, академик Сахаровның хәләл җефете Елена Боннэр, Россия Президентының милләтара мөнәсәбәтләр буенча киңәшчесе Галина Старовойтова һ. б. тарафыннан алынуы турында да китап авторына хәбәрләр килде.

## БЕЗНЕҢ САФЛАРГА

Чаллы төбәгендә берничә китап чыгарган, укучыларның игътибарын яулаган байтак кына язучылар, шагыйрьләр яши. Узган елның декабрь азагында Чаллыга Татарстан Язучылар берлегенең әгъзалар кабул итү комиссиясе язучылардан Аяз Гыйләҗев, Мөхәммәт Мәһдиев, Магъсум Хуҗин, Рөстәм Мингалим, Әхмәт Рәшит килде. Комиссия Чаллы язучылар оешмасында күчмә утырыш үткәрде. ТССР Язучылар берлегенә әгъзалыкка тәкъдим ителгән һәр кандидат турында җентекләп сөйләшкәннән соң күпчелек тавыш белән «Аргамак» журналының шигърият бүлеге мөдире Хәниф Хөснуллин, балалар шагыйрәсе Заһирә Гомәрова, инженер Данис Хәйруллин, КамАЗ акционерлык җәмгыяте нәшрияты баш мөхәррире прозаик Вахит Имамов, «Мирас» җәмгыятенең Кама буе регионы буенча вәкаләтле вәкиле, публицист язучы Фаяз Дунай ТССР Язучылар берлеге әгъзалары итеп кабул ителделәр.

Казан язучылары хезмәт коллективларында, «Нур» газетасы редакциясендә, «Ләйсән» әдәби берләшмәсендә очрашулар үткәрделәр, татар әдәбияты һәм мәдәниятенең бүгенге хәле хакында сөйләштеләр, үз фикерләрен уртаклаштылар. Бу тема шәһәр Советы башкарма комитеты рәисе Р. Алтынбаев белән очрашуда да үзәк урынны алды.

## ХАТИРӘ КИЧӘСЕ

Танылган татар язучысы һәм җәмәгать эшлеклесе Кави Нәҗминең тууына 90 ел тулды. Шул уңай белән аның иҗатына һәм тормыш юлына багышланган кичә узган елның 13 декабрендә Актерлар йортында үткәрелде. Аны кереш сүз белән ТССР Язучылар берлеге идарәсе рәисе Р. Мөхәммәдиев ачып җибәрде. Казан университеты укытучысы, «Мәгърифәт» газетасының мөхәррире Р. Фәттахов язучының әдәби мирасы, эзләнүләрдәге яңалыклар белән таныштырды. Язучылар И. Сәләхов, Г. Ахунов, профессор Ш. Сарымсаков, К. Нәҗминең кызы — шәфкать туташы С. Нәҗметдинова, якташы — Нижний Новгород өлкәсендәге Чечнов районының Кызыл Утрау авылы укытучысы Ф. Баһаветтинова истәлекләре белән уртаклаштылар. Тантанада җөмһүриятебезнең күренекле һәм яшь артистлары чыгыш ясады.

Кичәдә ТССР Премьер-министрының беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов катнашты.

## ӘДӘБИ ОЧРАШУЛАР

Узган елның декабрь башында драматург Фоат Садриев, шагыйрь Харрас Әюп һәм прозаик Фәрит Гыйльми үзләренең туган төбәкләре — Мөслим районында әдәби очрашулар үткәрделәр. Дусай, Яңа Карамалы, Әмәкәй, Метрәй авылларында, район үзәге Мөслимдә булган кичәләрдә язучылар белән берләттән тамашачылар да чыгыш ясадылар, әдәбиятка, бүгенге сәяси һәм икътисади хәлебезгә карата үзләренең фикерләрен белдерделәр. Язучылар яңа әсәрләрен укыдылар, күп санлы сорауларга җавап бирделәр.

Кубок, Әмәкәй, Мөслим урта мәктәпләрендә, шулай ук Яңа Карамалы башлангыч мәктәбендә укучылар белән очрашулар да истә калырлык булды.

## КЕЧКЕНӘ МУСАНЫҢ ЗУР УҢЫШЫ

Совет мәдәният фонды «Яңа исемнәр» дигән халыкара программа белән таныштырды. Анда безнең җөмһүрияттән яшь талант Муса Маликов та катнашты.

Муса моңа кадәр тамашачыларга оста җырчы, гармунчы буларак билгеле иде. Мәскәүнең «Октябрь» залында узган бәйгедә ул үзен талантлы скрипкачы буларак күрсәтте: А. Вивальдиның скрипка һәм оркестр өчен язылган ля минор концертының беренче кисәген башкарды. Аның чыгышы югары бәяләнде. Совет мәдәният фонды аңа 1992 ел өчен стипендия билгеләде. Якын көннәрдә Муса Маликов Сәгуд Гарәбстаны һәм Төркиядә чыгыш ясарга барырга әзерләнә.

# РӘИС ГАИТОВ ИҖАТЫ

Татар сынлы сәнгате соңгы елларда яңа эчтәлек, яңа иҗади көчләр һәм яңа иҗади ысуллар исәбенә баеды. Дөньяны бер яктанрак һәм тупасрак чагылдыручы реализмнан баш тарткан рәссамнар сәнгать тарихында булып узган, яисә соңгы елларда күренгән эстетик юнәлешләрнең иҗат нәтиҗәләрен үзләштереп яки, киресенчә, алар белән бәхәсләшә-бәхәсләшә, күп кенә кызыклы әсәрләр тудырдылар. Алар модернизм, авангард, абстракционизм һәм сюрреализм дигән элек тыелган «изм»нарның иҗат җимешләреннән азыкландылар. Шулай ук шәрекъ дөньясына хас күзаллау, сәнгатьчә сынландыру, шартлылык, конкретлык һәм башка шундый иҗади принциплар дәрьясына килеп керделәр.

Казан, Мәскәү, Уфа, Санкт-Петербург шәһәрләрендә яшәп актив рәвештә иҗат итеп килгән татар рәссамнары иҗаты хакында сәнгать белгечләре элегрәк «лубок», «примитив», «халык рәсеме» дигән терминнарны куллана килделәр. Шул ук вакытта алардагы иҗади җегәргә, новаторлык хисенә гаҗәпләнеп, татар сәнгатенең бу киң агымын «милли романтизм» дигән зур төшенчә белән билгеләделәр.

Уфада яшәүче татар сәнгатькәре Рәис Гаитовның иҗади омтылышлары да әнә шул юнәлештә. Аның үзенең инде бернычә аерым күргәзмәсе булган, эшләре Башкортстан һәм Татарстан музейлары белән беррәттән Германия, Израиль, Америка Кушма Штатлары һәм Голландиядәге галереяларга сатып алынган, әсәрләре үзәктәге һәм чит илләрге сәнгать белгечләре тарафыннан югары бәяләнгән.

36 яшьлек Рәис Гаитов иҗаты белән без Санкт-Петербургта һәм Казанда үткәрелгән «Татарт-91» күргәзмәсе аша таныштык. Журналыбызның бу санында исә без үз укучыларыбызга аның әсәрен тәкъдим итәбез.

Әлбәттә, бу хезмәт без күреп ияләнгән рәвештә түгел. Ул — бик тә үзенчәлекле сәнгать әсәре. Аның үзәгендә дә һич көтелмәгән образ — Хуҗа Насретдин образы тора.

Әнә ул ишәгенә менеп атланган. Ләкин атлануы да кешечә түгел — Хуҗа артка таба карап утырган. Үз язмышын, шулай итеп, ул аңгыра ишәге ихтыярына тапшырган...

Рәссамның менә шушы кинаясе, бик тә тирән мәгънәле. Анда тирән социаль эчтәлек бар. Минемчә, биредә мөселман дөньясындагы бүгенге сәяси хәлләр дә аңлашыла. Гүяки рәссам безнең көннәрдә шундый уй, сорау тудыра: «Бүген без үзебез артка карап утырган Хуҗа Насретдин кебек түгелме соң? Янәшәдә генә упкын торган вакытта безгә Хуҗа Насретдин кебек булу ярыймы соң?»

Рәссамның башка әсәрләре дә үзенчәлеклеләр, тиз истә кала торганнар. Аның «Дога кылучы мөселман» дигән эше турында шулай ук озаклап сөйләргә мөмкин булыр иде. Биредә дога ритуалы гына түгел, ә адәмнең үзен тудырган галәм белән тоташу, берләшү мизгеле дә аңлашыла.

Ә соңгы елларда Рәис Гаитов үзенең иҗади эзләнүләрен тагын да киңрәк җәелдерде. Аның яңа әсәрләрендә инде без төрле рухларны, илаһи затларны, мәҗүси җан ияләрен, кешелекне тудыручы мифик җир-ананы, төңрене һ. б.ларны күрәбез... Төрле затларның бер-берсенә әверелешләре дә тасвирлана ул әсәрләрдә... Кыскасы, мөселманлыктан да ераграк чорлар, караңгы дәверләр кайтавазы ишетелә сыман аларда. Әсәрләрдә әнә шул тормышның шигърияте, матбугатлыгы табылган. Бу кешелек аңы һәм фән тарафыннан әле үзләштерелмәгән өр-яңа халәт сыман кабул ителә. Мөгаен, шулайдыр ул...

Сәер һәм гүзәл әсәрләр остасы Рәис Гаитовның эшләрен әле без тора-тора тагын да тирәнрәк аңлаячакбыз.

**Розалина ШАҺИЕВА,**
сәнгать белгече.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** танылган язучы, М. Җәлил бүләге лауреаты Фәнис Яруллин.

**Юрий ФИЛИМОНОВ** фотолары.

*Киләсе санда:*

**Галимҗан Ибраһимов:**

«...татар мирзалары типлары һәркемгә мәгълүм: болар урыс хөкүмәтенең чиновниклары иделәр. Ихлас күңел белән шуңа хезмәт кылдылар. Үзләренең сыйныфдашлары урыс дворяннары белән бергә, бер рәвештә тәрбияләнеп, урыс мәдәнияте эчендә кайнап, татар халкыннан аерылып яшәделәр. Боларның бөтен көнкүрешләре урыс мәдәниятенә, урыс теленә баглы иде. Менә шул бытие татарның бу катлавында, тик урыс мәдәнияте аркасында гына яшәргә мөмкин, татар мәдәнияте юк, булса да — кыйммәтсез, аны күтәреп, үстерергә тырышып маташу — нәтиҗәсез эш, дигән сознание тудырды...»

«...Бездә хәзер бу яңа мирзалар аерым бер катлау булып киләләр: болар татар әдәбиятын, татар матбугатын укымыйлар, татар телендә язарга белмиләр, моны үзләре өчен кимчелек дип тә карамыйлар, үзенең бу наданлыгын ул нииндидер эчке бер «мәдәни» мактану белән әйтеп куя. Балаларын, якыннарын, әлбәттә, урыс мәктәбенә, урыс йортына, урыс курсларына бирәләр...»


Әдипнең бу фикерләрен сез «Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак?» дигән хезмәтеннән табачаксыз.

Укырга ашыгыгыз!

Бәясе 1 сум 80 тиен

Индекс 73210

Аерым сатып алучылар өчен 3 сум



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)

Журнал включен во Всесоюзный каталог